Уильям Шекспир
**Избранные произведения**
В ДВУХ ТОМАХ

ТОМ
2
Трагедии, комедии

Казань
Татарское книжное издательство
2007

Сайланма әсәрләр

ИКЕ ТОМДА

2

ТОМ

Трагедияләр, комедияләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2007

УДК 821.111-2
ББК 84 (4 Англ.)-6
Ш39
Төзүчесе

***Фәрит Бикчәнтәев***
**Шекспир У.**

Сайланма әсәрләр: 2 томда / Уильям Шекспир; төз. Ф.Бикчәнтәев — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006 — 2007. — ISBN 5–298–03997–9

2 т.: Трагедияләр, комедияләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 518 б. — 2000 д. — ISBN 978–5–298–01537–0

Бөек инглиз драматургы У.Шекспир (1564–1616) әсәрләренең бу томына популяр трагедияләре һәм комедияләре керде.
Китап татар театрының 100 еллыгы уңаеннан чыгарыла.
ISBN 978–5–298–01537–0 (2 т.)
ISBN 5-298-03997-9
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Бикчәнтәев Ф.Р., төзү, 2007

# Гамлет

## Трагедия

Биш пәрдәдә

Нәкый Исәнбәт
*Тәрҗемәсе*
**КАТНАШАЛАР:**

Клавди — Дания короле.
Гамлет — элекке корольнең улы һәм атасы белән бертуган хәзерге корольнең энесе.

Фортинбрас — Норвегия принцы.
Полони — сарай түрәсе.
Горатсио — Гамлетның дусты.
Лаэрт — Полонининың улы.
Вольтиманд
Корнели
Розенкранц
Гилденстерн
Озрик
Джентльмен
Поп.
Марсел
Бернард
Франсиско — солдат.
Рейнальдо — Полонининың хезмәтчесе.
Артистлар.
Ике мәзәкче — кабер казучылар.
Капитан.
Англия илчеләре.
Гертруда — Дания королевасы, Гамлетның анасы.
Офелия — Полонининың кызы.

Лордлар, ханымнар, офицерлар, солдатлар,
диңгезчеләр, илчеләр һәм сарай хадимнәре.
Гамлет атасының өрәге.

Вакыйга Эльсинорда бара.

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Эльсинор[1]. Сарай ныгытмасы алдында мәйдан. Франсиско сакта басып тора, аңа каршы яктан Бернард керә.

Бернард

Кем бирелә?

Франсиско

Юк, үзең әйт, тукта, кем син?

Бернард

Яшәсен Королебез!

Франсиско

Бернардмы бу[2]?

Бернард
Әйе, үзе.

Франсиско

Килдегез нәкъ сәгатендә.

Бернард

Әле генә уникене сукты; бар, ят, Франсиско.

Франсиско

Алмаштырган өчен рәхмәт. Бигрәк салкын; җаннарыма хәтле сыкрый.

Бернард

Син торган чакта ул-бу булмадымы?

Франсиско

Чебен дә селкенмәде.

Бернард

Ул чагында —

Хәерле төн. Әгәр минем иптәшләрем
Горатсио, Марсел сиңа очрый калса,
Аларга әйтче, зинһар, тиз булсыннар.

Франсиско

Мин ишетәм, әнә шулар килә бугай.
Туктагыз! Кемнәр анда?

Горатсио белән Марсел керәләр.

Горатсио

Ил дуслары!

Марсел

Һәм Король кешеләре.

Франсиско

Алай булса,
Хәерле төн сезгә.

Марсел

Сау бул, туры солдат. Сине кем алыштырды?

Франсиско

Бернард килде.
Хәерле төн.

Чыга.

Марсел

Һәй, Бернард!

Бернард

Әйт, Горатсио
Килдеме?

Горатсио

Әйе, менә бер кисәге. *(Кул бирә.)*

Бернард

Хуш киләсең, Горатсио, син дә, Марсел.

Марсел

Йә, ничек, бүген төнлә теге әйбер
Күренмәгәндер ич тагын?

Бернард

Мин берни дә күрмәдем.

Марсел

Горатсио әйтә менә:
Ул сезгә тик хыялыгыз күренгән, ди.
Без ике рәт күреп калган куркынычлы
Ул нәрсәгә ышанырга һич теләми.
Шунлыктан бүген аны үзем белән
Каравылга алып килдем. Безнең белән
Төн буе, әйдә, бергә сакта торсын,
Теге әйбер күренә калса, без күргәнне
Үзе раслап, аның белән сөйләшсен, дим.

Горатсио

Юк сүз, юк сүз, күренмәс ул.

Марсел

Утыр әле,
Ике төн рәттән безнең күргән хәлне
Син нихәтле ишетмәскә тырышсаң да,
Тагын бер кат сөйлик әле.

Горатсио

Ярый, яхшы,
Утырыгыз, тыңлап карыйк, сөйлә, Бернард.

Бернард

Үткән төнне әнә Казык йолдызыннан
Сулдарак бар бит йолдыз, шул үз юлын
Әйләнеп йөреп чыгып, әнә хәзер
Күк йөзендә янып торган урыны бармы,
Нәкъ шунда җитүенә, Марсел да мин,
Сәгать берне чалт сугуга...

Өрәк керә.

Марсел

Эндәшмә, чү,
Күрәсең, әнә тагы килә бит ул.

Бернард

Кыяфәте — нәкъ ул, безнең үлгән Король.

Марсел

Син галим, эндәш аңа, Горатсио.

Бернард

Корольгә охшаган бит?! Яхшы кара, Горатсио.

Горатсио

Нәкъ шул, үзе. Гаҗәп хәл бу. Аптырап калдым әле.

Бернард
Ул сүз көтә.
Марсел

Син сораш, Горатсио.

Горатсио
Кем син болай
Нәкъ җиде төн уртасында, Даниянең
Вафат булган хөкемдары йөргән кебек,
Сугышчан, мондый әйбәт эре сында
Йөренүче? Алла хакы өчен, сөйлә!

Марсел
Хурланды.
Бернард

Күрәсеңме, читкә атлый.

Горатсио

Тукта! Сөйлә! Тылсымлыйм мин сине, сөйлә!

Өрәк китә.

Марсел

Китте, җавап бирәме соң?

Бернард

Йә, ничек соң,
Горатсио? Син тетрисең, агарындың,
Коры бер хыял гына түгел бит бу!
Йә, ни дисең син бу хакта? Ни уйлыйсың?

Горатсио

Валлаһи, күрмәсәм үз күзем белән,
Ышанмаган булыр идем.

Марсел

Охшаганмы Корольгә?

Горатсио

Син үзеңә-үзең охшаган кук.
Теге мәгърур Норвик[1] белән сугышканда,
Король дә нәкъ шундый панцырь кигән иде.
Бер шулай, ачу белән сүзгә килгәч,
Полякларны чанасыннан берәм-берәм
Күтәреп боз өстенә бәргән чакта,
Нәкъ шушылай ул җыерган иде кашын.
Гаҗәп хәл бу.

Марсел

Шул җиде төн уртасында
Ике рәт, нәкъ шушылай, хәрбиләрчә
Салмак атлап үтеп китте безнең алдан.

Горатсио

Мин белмим моны ничек юрарга да;
Тик, гомумән, шулай уйлыйм, безнең илгә
Берәр хәтәр булачакка галәмәт бу.

Марсел

Утырышыйк. Син әйт әле, менә безне
Ник болай төннәр буе йоклатмыйча
Каравылда тоткан булып азаплыйлар?
Нигә һаман көне-төне бакыр туплар
Коялар да читтән корал китертәләр?
Кораблар ясау өчен ирексезләп,
Осталарны якшәмбе дә ял иттерми
Эшләтәләр? Бу кадәрле нык ашыгып,
Төннәрне көнгә ялгап эшләтерлек
Безгә нәрсә яный әле ул кадәрле?
Йә, кайсыгыз моны миңа әйтеп бирер?

Горатсио

Әйтеп карыйм. Ким дигәндә, шундый сүз бар:
Өрәге әле генә күзебезгә
Күренгән мәрхүм Королебезнең, сез
Беләсез, көнче, мәгърур Фортинбрас
Дигән Норвик тарафыннан бергә-бергә
Сугышырга чакырылганын. Безнең шушы
Баһадир Король Гамлет (аның инде
Батырлыгы бөтен җиргә мәгълүм хәл ич!) —
Беләсез, Фортинбрасны үтергәнен.
Әмма ләкин Фортинбрас, рыцарьлыкның
Бөтен гадәт-йолалары кушуынча,
Шартнамә белән, үзен җиңүчегә,
Үзенең башы белән бергә кушып,

Үз илен дә тапшырырга булган иде.
Безнең дә Королебез үз җиреннән
Шуңа каршы бер өлешен залог куйды.
Шарт буенча җирен алды безнең Король,
Әгәр дә Фортинбрас җиңгән булса,
Безнең җир дә аңа күчкән булыр иде.
Хәзер яшь Фортинбрас, аның улы,
Яшьлегенең гайрәтенә кабынган да,
Каяндыр акча табып, азык биреп,
Норвегия ярларында эшсез йөргән
Йортсыз-җирсез браматлардан гаскәр җыйган,
Янәсе, нindидер бер кирәк эшкә.
Болар бар да, безнең илгә басып кереп,
Атасының киткән җирен алыр өчен.
Моны безнең хөкүмәт тә сизгән хәзер.
Менә шул, мин белгәнчә, безнең мондый
Әзерлекнең, монда сакта торуларның,
Безнең илдә күтәрелгән бу тәшвишнең
Сәбәбе шул.

Бернард

Минемчә дә, тик шул гына.
Соң, шушы сугышларның чыгуына
Сәбәп булган Корольнең нәкъ үз сыныдай
Бу өрәкнең шундый шомлы кыяфәттә
Коралланып, безнең постка үзе килеп
Күренүе бушкамыни? Бары шуңа.

Горатсио

Борчый бит бу күңел күзен, чүп кергән күк.
Римда да бит шулай булган, аның данлы
Дөньяны дер селкеткән көннәрендә,
Гайрәтле Юлий Цезарь[1] үтерелер
Көн алдыннан, кинәт гүрләр ярылган да,
Мәетләр кәфен сөйрәп, лыбырдашып
Йөргәннәр, сыктый-сыктый урам буйлап.
Йолдызлар, болгап утлы койрыкларын,
Канлы чыклар төшеп, кояш тапланган да,
Нептунга[2] хөкем йөрткән күкнең ае
Гарасат купкан кебек сүнеп калган.
Нәкъ шундый ук шомлы хәлләр галәмәтен,
Язмышның хөкемен алдан сиздергәндәй,
Менә хәзер күк белән җир бергәләшеп
Безнең илгә хәтәр барын белдерәләр.

Өрәк кире кайта.

Акрын, чү! Йә, ул менә тагын килә!
Юлын кисәм, әнә мине көл итсенче.
— Тукта, хыял! Әгәр тының, телең булса,
Әйт син миңа!
Әгәр дә мин сиңа ярдәм, үземә дан
Булырлык бер яхшылык итә алсам,
Әйт син миңа!
Әгәр илгә килә торган бер-бер хәлне
Син белеп тә, аны кире кагып булса,
О, җавап бир!
Яки син гомерең буе талап җыйган,
Җиргә күмгән казнаң өчен, кем әйтмешли,
Җаныңа урын тапмый йөрсәң әгәр,

Әтәч кычкыра.

Әйт шушында. Тукта! Үзен тотчы, Марсел!

Марсел

Айбалтам белән чабыйм.

Горатсио

Әйе, әгәр
Китмәк булса.

Бернард

Ул биредә.

Горатсио

Монда!
Өрәк күздән югала.

Марсел

Китте!
Ул шундый патшаларча олы булгач,
Юкка без аны көчләп кимсетәбез.
Аңа бит тиеп булмый: һава кебек,
Кизәнүең бушка гына, бары хурлау.

Бернард

Сөйләшә иде, этәч кычкырды бит.

Горатсио

Кычкырып җибәрүгә, ул сискәнеп,
Гаепле күк куркып китте. Ишетә беләм,
Имеш, этәч — таң быргысы, тавышы белән
Көн тәңресен йокысыннан уята, ди,
Кычкырып җибәрдеме — суда булсын,
Утта булсын яки җирдә, җилдә булсын,
Иректә гизеп йөргән нинди рух бар —
Үз урынына ашыга, ди. Моның шулай
Икәнлеген бу рух безгә исбат итте.

Марсел

Әтәч тавышын ишетү белән юк та булды.
Әйтәләр: имеш, һәр ел шул Гайсаның
Дөньяга килгән көне тирәсендә
Таң этәче төн буе гел кычкыра, ди;
Тавышына рухлар йөрми, тик тора, ди;
Төне имин, бер йолдыз да атылмый, ди,
Ияләр дә йөрми, җеннәр тылсымламый,
Шундый изге, бәрәкәтле, имеш, ул төн.

Горатсио

Ишеттем мин дә аны. Ышанам да
Бераз аңа. Чү, көнчыгыш тауларыннан,
Чык сулары өсләреннән ал киемле
Таң якынлый. Киттек без дә каравылдан,
Минемчә, без болай итик: төнлә монда
Ни күргәнне яшермик без яшь Гамлеттан,
Ант итеп әйтәм, безгә дәшмәгән рух,
Әлбәттә, аның белән сөйләшәчәк.
Ризамы сез, безгә дуслык һәм бурычыбыз
Кушканча, әгәр моңы ана әйтсәк?

Марсел

Әйе, кирәк; аны кайда очратырга
Җайлы җирне мин бүген үк беләчәкмен.

Чыгалар.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сарайда тантана бүлмәсе.
Быргы тавышлары. Король, Королева, Гамлет, Полони, Лаэрт, Вольтиманд, Корнели, лордлар һәм сарай хадимнәре керәләр.

Король

Агабыз Король Гамлет үлүенең
Җәрәхәте күңелебездән китмәсә дә,
Безгә дә бәгыребезне мәңге телеп,
Бар мәмләкәт белән бергә бу кайгыны
Чигү бик тиешле эш булса да, без
Хисебезне акыл белән җиңгән кадәр,
Мәрхүмгә матәм тоту белән бергә,
Үзебезнең ниятне дә онытмадык:
Шунлыктан, кайгы белән шатлык чигеп,
Күзебезнең берсе елап, берсе көлеп,
Туйда сыкрап, җеназада күңел ачып,
Кайгы һәм куанычны бер иттек тә
Сугышчан бу дәүләтнең мирасчысы
Булып килгән сеңлебезне үзебезгә
Бүген хатын — Королева итеп алдык.
Бу эштә безгә сезнең арагыздан
Төпле киңәш биргәннәргә карышмадык,
Алар да бу адымны хуп күрделәр;
Һәммәсенә рәхмәт. Инде эшкә күчик.
Беләсез, Фортинбрас дигән егет,
Белмим, безнең дәрәҗәне түбән санап,
Әллә мәрхүм агабызның бу үлеме
Илебезне таркатты дип уйлаганга,
Үзен ул бездән өстен куйган булып,
Җибәреп һаман монда илчеләрен,
Безне борчый; ул егетнең атасыннан,
Шарт буенча, безнең мәрхүм агабызның
Барлык алган җир-суларын кире сорый,
Монсы — бер; инде хәзер бу мәҗлестә
Без бу яшь Фортинбраснық агасына
— Норвегия королена — бер хат язйик,
Чөнки ул тормый, авырып ята икән,
Шунлыктан энесенең бу рәвешле
Этлекләрен белми булыр, анда аның
Гражданнары арасында, гаскәр җыю
Һәм һәртөрле корал туплау бара икән;
Без дә язйик: моннан ары энесенең
Бу төсле узынуын туктатсын ул.
Бу йомышка син — Корнели әфәнде, һәм
Вольтиманд — икегезне җибәрәбез:
Карт корольгә безнең хатны тапшырырсыз.
Без сезгә шушы хатта күрсәтелгән
Чиктә генә илчелекне тапшырабыз.
Хушыгыз, йөкләмәне тиз тотыгыз.

Корнели һәм Вольтиманд

Моңа хәтле ничек булсак, бусында да
Үзебезне тырышлыкта сынатмабыз.

Король

Ансында һич шигебез юк, сау булыгыз.

Вольтиманд һәм Корнели чыгалар.

Йә, хәзер син, Лаэрт, сөйлә хәбәреңне,
Ни гозрең бар синең безгә, әйтеп җибәр.
Тәхтебезгә нинди генә йомыш белән
Килсәң дә син, сүзең җирдә ятып калмас.
Ни генә сорама син — аны үзең
Сораганчук бирәчәкмен. Безнең данлы
Даниянең тәхете белән синең атаң
Бер-берсенә шулчаклы нык бәйләнгән ки —
Йөрәк белән баш та шулай нык ялганмас,
Авызга кул да шулай булыша алмас.
Ни телисең, йә, әйт, Лаэрт.

Лаэрт

Бөек милорд[1] ,
Франциягә мине кире җибәрегез,
Сорыйм сездән. Мин бит бире Даниягә
Сезнең таҗ киюегез бәйрәмендә
Катнашу өчен генә аннан кайттым.
Әйтә алам, хәзер бурычым өстән төште.
Бар уем тагын тарта Франциягә.
Ризалык бирерсез дип мин йөз тотам
Сезнең мәрхәмәтегезгә.

Король

Әтиегез
Ризамы соң? Йә, Полони ни дип әйтә?

Полони

Ул, милорд, бик ялынып йөдәткәчтен,
Ахырында мин ризалык бирдем инде.
Китәргә сез дә рөхсәт бирсәгезче.

Король

Хәерле сәфәр, Лаэрт. Әле кулда
Форсатың бар чагында нык файдалан,
Рәхәтләнеп бер яшәп кал. — Йә, син ничек,
Энем һәм улым Гамлет, синдә ни хәл?

Гамлет
*(читкә)*

Эне микән — белмим, ләкин улың түгел.

Король

Өстеңдә әле булса кара болыт
Китми торамыни?

Гамлет

Киресенчә, милорд,
Кояш миңа кирәгеннән артык карый.

Королева

Газизем Гамлет, зинһар, бу караңгы
Төсеңне ташла да син Даниянең
Өстенә дуслык күзең бер генә сал.
Күпмегә кадәр йөзең түбән иеп,
Гүр иясе атаң эзен эзләрсең син?
Беләсең, үлем шундый уртак нәрсә —
Һәр яшәгән — бер үләчәк. Бар табигать
Мәңгелеккә бер бетәчәк.

Гамлет
Әйе, ана,

Бу хәл уртак.

Королева

Шулай булгач, соң ни өчен
Сиңа бу бер аерым нәрсә булып тоела?

Гамлет

Тоела дисең, тоелу түгел, ул бар нәрсә.
«Тоела»ны белмим дә мин. Ләкин минем
Бу кара ябынчам, әй, газиз анам,
Бу киемнең йола кушкан җитди төсе
Яки авыр көрсенүем, һәм шулай ук
Бу күзләрдән берөзлексез аккан яшем
Һәм түбәнгә иелгән бу моңлы йөзем,
Бу нәрсәләр барысы бергә берләшсә дә —
Чын хәлемне белдерергә көче җитмәс.
Өстеңә кигән нәрсә — кием генә,
Болар бар да тик кыланыш булу мөмкин:
Ә минем үз эчемдә нәрсә ята —
Ансын берни: кайгы төсе, бер бизәк тә
Белдерә алмас.

Король

Атаң өчен мондый матәм
Тоту үзе синең яктан бик күркәм эш.
Белергә тиешсең тик: синең, атаң —
Ул да бер югалткан бит үз атасын;
Ансы тагын үзенекен. Инде аның
Урынына исән калган баласы да,
Нәтиҗәдә бераз матәм тотса хаклы.
Әмма инде карыша-карыша матәм тоту,
Өзлексез аһ-ваһ чигү — бу килешмәс
Тискәрелек, бу адәмчә кайгы түгел;
Килешкән эш түгел бу ир кешегә.
Бу күрсәтә тәкъдир белән килешмәүне,
Баш тартуны, җанындагы карарсызлык,
Йөрәктәге кирелекне, хәтернең дә йомшаклыгын;
Начар исәп, беркатлылык күренеше бу.
Чөнки бит бер булырга тиеш нәрсә
Гадәттәге юлы белән булмый калмый,
Моның шулай булачагы безнең өчен
Алдан ук мәгълүм икән, мөмкинме соң
Балаларча үзсүзләнеп, аның өчен
Сызланырга? Гөнаһ бит бу хак каршында,
Мәетләр һәм табигать каршында да;
Башка сыймый, чөнки ул бит әйтеп тора:
Аталарның үлеме, ди, иң тәү башлап
Үлүчедән безгә калган бер мирас ул;
Һәм ул шулай булырга да тиеш бер хәл.
Үтенәбез, син бу кысыр көегеңне
Ташла да, безне күр син ата итеп,
Күрсен дөнья, безнең дәүләт тәхетебезгә
Барсыннан да син иң якын икәнлекне,
Минем дә, аталарның иң яхшысы
Үз улын никадәрле яраталса,
Сине шундый якын күрә икәнлекне.
Инде син тагын университетка —
Виттенбергка[1] кире китәм дисең икән,
Син аңла, монсына без күнә алмыйбыз.
Мин сорыйм, риза бул да син кал монда;
Иң асыл дус, кардәшебез һәм ишебез

Булып безнең, тәхетебезнең яме өчен,
Шатлыгыбыз, сый-хөрмәт һәм кадер өчен
Кал биредә.

Королева

Әниеңнең үтенечен
Җиргә салма, Гамлет, кал син яныбызда.
Китмә син Виттенбергка.

Гамлет

Мин хәлемнән
Килгән кадәр буйсынырга әзер сезгә.

Король

Һай, бу ни гүзәл җавап, ипле җавап!
Яшә бергә безнең кебек. Киттек, ханым.
Гамлетның болай җайлы күнүенә
Кәефем килде; бүген менә шуның өчен
Король аның саулыгына үз касәсен
Күтәргәндә, туплар атып, бу салютны
Болытларга җиткерсеннәр. Әйдә Король
Күтәргән касәсенә бөтен күкләр
Яңгырап, таулар шуңа җавап бирсен.
Киттек.

Быргылар тавышы. Гамлеттан башкалар бары да чыгалар.

Гамлет

Аһ, бу тәнем, артык каты булган тәнем,
Чык булып күтәрелсен иде эреп!
Ичмасам шул мәңгелекнең кануны да
Үз-үзеңне үтерүне тыймасае!
Ярабби! Дөньяның бар булган эше
Никадәрле җан җиләткеч, кыршылган, вак,
Кирәксез тоела миңа. Тфү! Ямьсез!
Ул — бакча, ләкин кыргый, уталмаган,
Чүп-чарлар аны басып күмеп киткән,
Йә эш шуңа килеп җитсен! Үлүенә
Ике ай булсын бары, ике дә юк,
Шундый әйбәт Король, моны чагыштырсаң,
Аполлонның янында бер сатир[2] бит бу.
Анамны шулкадәрле сөйде атам,
Йөзенә җил тидертмәде. Әй, җир-күкләр!
Онытаммы соң?! Анам аңа шулхәтле нык
Бирелгән иде — гүя үз гомеренә
Күңеле аннан кайтмас кебек тоела иде.
Бер ай үтте. Менә! Аһ, куй! Әй, хатын-кыз,
Вафасызлык синең исемең! Ай дигәндә!
Ниобея[1] кебек батып күз яшенә,
Атамның җеназасын озатканда,
Киеп барган башмагы да тузмаган бит,
Шушы хатын, ничек соң ул?.. Раббым! Аңсыз
Ерткыч җанвар — ул да аннан озаграк
Матәм чиккән булыр иде. Әмма анам
Тотты да шул агама — этиемнең
Энесенә иргә чыкты. Мин нихәтле
Геркулеска охшамасам, этиемә —
Шулхәтле дә охшамаган энесенә!
Ай дигәндә! Шул оятсыз күз яшенең
Әче тозы күзен уеп кызартканы
Бетәргә дә өлгермәсен, иргә чыксын!
Шулкадәр ашкынулы нәфес белән,

Кардәш канын катыштыру, уйнаш өчен
Ташлансын чыбылдыкка! Юк, бу эштә
Яхшылык юк, булырга да мөмкин түгел.
Тик, йөрәгем, ярыл, әмма сак бул, телем!

Горатсио, Марсел һәм Бернард керәләр.

Горатсио

Сәлам сезгә, принц.

Гамлет

Сине күрүемә
Мин бик шатмын. Горатсио, ялгышмасам?

Горатсио

Үзе, милорд, һәм гомергә хезмәтчегез.

Гамлет

Сэр, син минем якын дустым, хезмәттәшлек
Арабызда уртак булсын. Йә, син нишләп
Виттенбергтан бирегә кайттың, Горатсио?
Марсел, сине күрәм!

Марсел

Әйе, принцым, мин.

Гамлет

Сезне күрүемә шатмын. *(Бернардка.)* Хәерле кич,
Рас, син нишләп Виттенбергтан кайттың әле?

Горатсио

Эшсезлектән, принц.

Гамлет

Моны хәтта синең
Дошманыңнан ишетергә дә мин теләмим.
Үз өстеңә сөйләвеңә ышанырга
Колагымны көчләмә дә. Тиккә генә
Йөрүче дип белмим сине. Эльсинорга,
Йә, нәрсә тартты сине? Син киткәнче,
Без эчәргә өйрәтербез сине монда.

Горатсио

Мин атаңның җеназасын озатырга
Кайттым, милорд.

Гамлет

Миннән көлмә, студент дус,
Аннан бигрәк анам туен күрергәдер?

Горатсио

Әйе, принц, берсе артлы икенчесе.

Гамлет

Исәп белән эшләнгән эш, Горатсио!
Кырыгына пешкән ашлар туй ашына
Ярап куйды. Аһ, бу көнне күргәнче мин,
Оҗмахта хас дошманым белән яшәү
Яхшырак булыр иде миңа, дустым.
Аһ, шул әткәм күз алдымда торган кебек.

Горатсио

Кайда, принц?

Гамлет

Үз күңлемдә, Горатсио.

Горатсио

Минем дә истә: ул чын Король иде.

Гамлет

Кеше иде, бөтен яктан кеше иде.
Андыйны күрү инде насыйп булмас.

Горатсио

Принц, аны кичә төнлә күрдем бугай.

Гамлет

Күрдең, кемне?

Горатсио

Әткәгезне, ул Корольне.

Гамлет

Әткәйне?

Горатсио

Чак кына сез сабыр итеп
Тыңлагыз минем нәрсә әйтеремне:
Сүзләремә мин бу ике офицерны
Танык итәм.

Гамлет

Зинһар өчен, сөйләгезче.

Горатсио

Ике төн рәттән, шушы ике дустым
Марсел, Бернард, үлем кебек кара төндә,
Сакта торып менә нәрсә күзәткәннәр:
Көтмәгәндә баштанаяк коралланган
Агагыздай бер күләгә күренә дә
Мәһабәт, эре, салмак йөреш белән
Яннарыннан үтеп китә. Бу икәүнең
Нык акайган күз алдыннан өч мәртәбә
Сөңге буе җирдән генә шулай үткәч,
Болар да, куркытудан тынсыз калып,
Тик торганнар. Бу хәлләрне куркынычлы
Бер сер итеп, бу иптәшләр минем белән
Бүлешкәч, өченче төн алар белән
Чыктым мин дә. Нәкъ шул әйткән сәгатендә,
Аларның әйткәннәрен раслагандай,
Нәкъ шул сыйфат, шушы сында
Күренде ул өрәк тагын. Атагызны
Күреп беләм, менә сезгә ике кулым —
Алар да бер-берсенә шулкадәрле
Охшамастыр.

Гамлет

Кайсы җирдә күренде ул?

Марсел

Нәкъ без каравыллаган чатта.

Гамлет

Ә сез сөйләштегезме соң аның белән?

Горатсио

Әйе,
Мин сөйләштем, әмма җавап бирмәде ул.
Шунсы истә: сөйләшергә иткәндәй ул
Күтәрде башын бер кат. Ләкин шунда
Кычкырып җибәрде дә таң әтәче,
Шул тавышка ул да шунда ялт! — бер якка
Тартылды да юкка чыкты.

Гамлет

Бик гаҗәп хәл.

Горатсио

Ант итеп әйтәм, принц, башым белән,
Бу хак. Моны әйтүне дә бурычыбыз дип
Без санадык сезгә.

Гамлет

Шулай, әфәнделәр,
Тик мине бу хәл бик нык сискәндерә.
Бүген дә төнлә сакта буламсыз сез?

Марсел, Бернард

Әйе, принц.

Гамлет

Коралланган дисез бит сез.

Марсел, Бернард

Әйе, милорд, коралланган.

Гамлет

Баштанаяк?

Марсел, Бернард

Әйе, милорд, баштанаяк.

Гамлет

Алайса, сез күрмәдегез аның йөзен?

Горатсио

Ә юк, нигә? Йөзен ачып үтте бит ул.

Гамлет

Нәрсә, йөзе бик чытыкмы?

Горатсио

Ачулыдан
Бигрәк ул кайгылырак төсле иде.

Гамлет

Йөзе акмы, кызарганмы?

Горатсио

Ап-ак иде.

Гамлет

Карап та тордымы сезгә?

Горатсио

Әйе, туктап.

Гамлет

Аһ, мин шунда булган булсам!

Горатсио

Сезне тәмам
Аптырашка салган булыр иде бу хәл.

Гамлет

Бик мөмкин. Озакмы соң күренде ул?

Горатсио

Салмак кына йөзгә чаклы санар вакыт.

Марсел, Бернард

Юк, күбрәк, озаграк.

Горатсио

Мин күргәндә
Шулай гына.

Гамлет

Чал идеме сакаллары?

Горатсио

Тере чакта күргәнемчә, көмеш-кара.

Гамлет

Бүген үзем каравылга чыгам. Бәлки,
Ул тагын да килер.

Горатсио

Моңар мин ышанам.

Гамлет

Әгәр дә ул чын да атам төсле булса,
Ажгырып әнә бөтен җәһәннәме
Нигә шунда эндәшмә дип тормый миңа,
Анда да мин сөйләшермен, һәммәгездән
Үтенәм шуны: моңар хәтле ничек
Бу турыда дәшмәсәгез, моннан соң да
Сер саклагыз. Бүген төнлә нинди генә
Хәл булса да, күңелебезгә алыйк, ләкин
Телебездән ычкындырмыйк. Сездән күргән
Яхшылыкны кайтарырга тырышырмын.
Сау булыгыз, сәгать унбер-уникедә
Килермен чатка, сезнең яныгызга.

Барысы бергә

Сезнең хезмәтегезгә без әзер, принц.

Гамлет

Дуслык бергә уртак булсын. Сау булыгыз.

Гамлеттан башкалар чыгалар.

Гамлет

Атамның рухы кулга кылыч алган,
Хәерлегә түгел бу хәл. Бер шом сизәм,
Тизрәк төн җитсен иде. Тын, йөрәгем!

Яман эшләр җир астына күмелсә дә,
Барыбер күз алдына бер чыгачак.

Китә.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Полони өендә бер бүлмә.
Лаэрт белән Офелия керәләр.

Лаэрт

Минем бар юл ярагым көймәдә. Йә,
Исән-сау бул. Инде, сеңлем, җае килеп
Уңай җилләр безнең якка искән саен,
Йоклама, хат-хәбәрең җибәрә тор.

Офелия

Әллә моңа шигең бармы?

Лаэрт

Ә Гамлетның
Синең арттан йөрүенә килсәк, син бел:
Болар бары җилбәзәклек, кан уйнавы,
Язын чәчкә аткан умырзая гына
Иртә ата, нәфис исле, тик гомерсез,
Юанычы бер минутка, артыгы юк.

Офелия

Бары шулай гынамыни?

Лаэрт

Ышан миңа,
Табигать бездә буй һәм көч үстереп
Кенә калмый; тән гыйбадәтханә кебек,
Анда акыл, рух көче дә бергә үсә.
Бәлки, ул хәзер сине сөядер дә,
Бәлки әле, аның изге ниятләрен
Хәйлә-мәкер таплары да пычратмыйдыр,
Тик аның дәрәҗәсен истә тот та
Курык син аннан. Үз ирке юк аның, чөнки
Үзенең тумышына буйсынган ул.
Һәрбер гади кеше кебек, ул үзенә
Үзе берни сайлый алмый. Чөнки бөтен
Дәүләтнең иминлеге һәм тормышы
Аның сайлавына бәйле. Шунлыктан ул
Баш булып мәмләкәтнең гәүдәсенә
Береккән күк, үзенә кыз сайлауда да
Илнең ничек табуына нык бәйләнгән.
Инде ул сине сөям дисә, син дә
Акыллы бул, үзенең бу әйткәннәрен
Дәрәҗәсе белән күпме аклый алса,
Син шулкадәр генә ышан; димәк ки, бел:
Сүзе раска чыгу бөтен Даниянең
Ничек мәгъкуль күрүенә карап йөри.
Аның гыйшык җырларына күңел бирсәң
Яки, аның башсыз теләгенә җиңелеп,
Аңа сафлык хәзинәңне ачсаң, уйла.
Исәпләп кара үзең, синең исемең
Нәрсә булып калыр иде? Шунсыннан курык,
Офелия, сак бул, сеңлем, үзеңнең син

Һәлакәтле дәртләреңнән бер читтә тор.
Айга карап йөз пәрдәсен ачкан чакта,
Иң әдәпле кыз да артык юмарт була.
Гайбәт теле яхшыга да тиз тиючән,
Бөреләргә ачылганчы иртә яздан
Кортлар төшкән кебек, яшьлек таңында да
Чык төшкәндә дымлы һава тиз йогучан.
Саклана күр, курку — синең чын юлдашың,
Саф яшьлеккә оят үзе чын ярдәмче.

Офелия

Синең яхшы киңәшеңнең йогынтысын
Йөрәгемә сакчы итеп куям, абый.
Тик син, абый җаным, азгын поплар кебек,
Башкаларга мәшәкатьле оҗмах юлын
Күрсәтеп тә, үзең гамьсез, типкеч булма.
Үзең биргән киңәшеңне үзең тотмый,
Рәхәт сукмагыннан гөлләр иснәп йөрмә.

Лаэрт

Һәй, син минем өчен курыкма. Озакладым.
Әти дә килә әнә.

Полони керә.

Икеләтә
Дога алучыга ике савап була;
Миңа да ике кабат саубуллашу
Насыйп булды.

Полони

Син китмәдеңмени, Лаэрт?
Бар корабка, бар, тизрәк; җилкәнеңдә
Җил кабарган, сине генә көтә алар.
Миннән дога сиңа. Әйтер сүзләремнең
Кайберләрен исеңдә тот:
*(Кулын Лаэрт башына куеп.)*
Башыңа һәр килгән уйны телдән әйтмә;
Уеңа килгән һәрбер эшне кылма.
Кеше белән гадел бул, тик һичкем белән
Син дә мин булма; тупас, дорфа булма.
Нык сыналган дусны корыч билбау кебек
Үзеңә бәйлә, ләкин һәрбер тәү очраган
Юньсезгә син сыйлар биреп кул кабартма.
Бәхәскә кермә, сак бул; керештеңме —
Очына чык. Шунда дошман синнән куркыр.
Һәркемгә дә колагың сал, ләкин үзең
Сирәк сөйлә, һәр тәнкыйтьне исеңә ал,
Әмма ләкин үз акылың булсын башта.
Кесәң күпме күтәрә ала — шулкадәрле
Яхшы киен, тик чамасыз киенмә дә.
Бай булсын, тик шыйк булмасын, чөнки кеше
Күбрәк сине өс-башыңа карап үлчи.
Франциядә вельможалар һич кенә дә
Тел тимәслек зәвык белән киенә белә.
Бурычка алма, үзең бурыч бирмә,
Биргән акчаң белән бергә дустыңнан да
Язарсың, үзең алсаң, хуҗалыгың
Рәттән чыгар. Иң кирәк эш — үз-үзеңә
Туры бул син. Ул чагында, төн иярә
Көн килгәндәй, һәркемгә дә дөреслегең

Мәгълүм булыр. Сау бул, шушы үгет белән
Догам сиңа юлдаш булсын.

Лаэрт

Хөрмәт белән
Саубуллашам, милорд.

Полони

Тиз бул, форсатыңны
Качырма, бар, ялчың көтә сине.

Лаэрт

Сау бул,
Офелия, минем әйткән киңәшләрне
Нык тот истә.

Офелия

Алар миндә нык бикләнгән,
Ачкычын үзең белән алып кит.

Лаэрт

Хуш.

Китә.

Полони

Ул сиңа нәрсә әйтте, Офелия?

Офелия

Принц Гамлет турында ул, кирәк булса.

Полони

Бик урынлы кузгатуы. Әйбәт бу сүз.
Ишеттем мин дә, соңгы чакларда ул
Еш кына буш вакытын синең белән
Бүлешә дип. Син дә аны үз катыңа
Иркен җибәрәсең икән. Мине шулай
Кисәтеп әйткәннәре дөрес булса,
Мин дә әйтим, минем кызым булган кызның
Намусына нәрсә лаек икәнлеген
Әле яхшы төшенмисең. Арагызда
Нәрсә бар? Кыл дөресен әйт син миңа.

Офелия

Үзенең миңа чиксез соклануы
Турында бу көннәрдә күп мәртәбә
Ышандырды мине, милорд.

Полони

Соклану, ди;
Үзең өчен шулкадәрле хәтәр эштә
Тәҗрибәсез кызлар кебек сөйләп куйдың.
Син соң нәрсә, әйткәнеңчә, аның шушы
Ышандырган сүзләренә ышандыңмы?

Офелия

Мин ни дип уйларга да белмим, милорд.

Полони

Менә сиңа кирәк булса. Алай булгач,
Үзеңне бала дип бел, мин өйрәтим:
Син аның бер тиен дә тормый торган

Икърарларын чын акча дип кабул итсәң,
Үзеңнең ул икърарлардай кыйммәтрәк
Торганыңны үзеңә дә икърар ит син.
Йә бу сүзне очлау өчен әйтим, миннән
Үзеңнең юләрлегең икърар иттер.

Офелия

Мәхәббәте турында ул һәрвакытта
Әдәп-хөрмәт белән генә әйтте, әти.

Полони

Әдәп-хөрмәт, имеш. Тагын!

Офелия

Үз сүзләрен
Изге күкләр белән раслап әйтте, әти.

Полони

Бар да песнәк, тәллә тәвеч тозагы бу.
Үзем беләм, дәрт белән кан кабынганда,
Телнең ничек антка юмарт булганлыгын.
Бу кабынуны ут дип уйлый күрмә, кызым.
Балкый, ләкин җылытмый ул, ялкын булып
Әверелгәнче пышт итә ул. Моннан болай
Кыз күңелеңне саран өләш. Очрашуны
Кыйбат санат, аңа ирешү авыр булсын.
Гамлетка килсәк, ышан яшьлегенә,
Ышан сиңа караганда аның киңрәк,
Иркенрәк бер тышауда йөрүенә,
Тик ышанма антларына, Офелия.
Алар бар да эчтән пычрак ниятләрне
Каплау өчен тыштан тәти чара гына.
Бары шәбрәк алдау өчен ул ниятләр
Саф вәгъдәләр кабыгына төренә дә
Гөнаһ эшкә ялчы булып хезмәт итә.
Кисәтәм: инде принц Гамлет белән
Сөйләшеп вакытың бушка әрәм итмә,
Кара аны, әйтеп куйдым. Йә, бар инде,
Юлыңда бул.

Офелия

Мин тыңлармын сезне, әти.

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кечерәк бер чат.
Гамлет, Горатсио һәм Марсел керәләр.

Гамлет

Ай-һай, җиле нинди ачы. Суык та соң.

Горатсио

Чеметтереп ала бит бу.

Гамлет

Ничә сәгать?

Горатсио

Уникеләр буладыр, шәт.

Марсел

Сукты инде.

Горатсио

Суктымыни? Ишетмәдем. Алай булса
Өрәкнең гадәттәге йөри торган
Вакыты җитә.

Быргылар һәм сәхнә артында туп атышлары.

Нәрсә булды соң бу, принц?

Гамлет

Туй анда — Король бүген күңел ача.
Төн буена егылганчы бии анда.
Кызылны тамагына салган саен,
Бу гайрәтен хәбәр итеп киң дөньяга,
Барабан, быргылары күк күкрәтә.

Горатсио

Шундый йола бармы?

Гамлет

Йола дисәң дә вай.
Гәрчә мин үзем шунда туып үсеп,
Мондагы гадәтләргә күнексәм дә,
Алай да, миңа калса, бу йоланы
Тотудан да тотмау яхшы. Безнең ямьсез
Бу типкечлек көнчыгышка, көнбатышка, —
Бөтен җиргә безнең яманатны сата.
Эчкечеләр, диләр безне, дуңгыз, диләр,
Бу безнең булган бөек эшләрнең дә
Бәясен, казанышын гел юк итә.
Һәрбер аерым кешедә дә шундый хәл бит:
Тумыштан нindидер бер гаебе була,
Яки аның акылын-фикерен юк шикелле
Күрсәтерлек нindидер бер ягы була,
Йә әдәпсез бер гадәте була аның;
Адәмнең, рас, үз табигать яралышын
Үзе сайлап алуында үз ирке юк,
Бу кешеләр бу гаептә гаепсез дә
Булсын, әмма тумыштанмы, очраклымы
Алар шундый гаеп белән бер танылгач,
Үзләре әнә барсын, саф та булсын,
Камиллектә тиңсез булсын, изге булсын,
Башка тагы җитеш яклар тулып ятсын,
Ләкин алар бүтәннәрнең уенча, шул
Бер кимчелек өчен һәлак булган халык.
Бер мичкә таза балны бозар өчен
Бер тамчы дегет җитә.

Өрәк керә.

Горатсио

Карагыз, ул!

Гамлет

Әй күк кошы — фәрештәләр, шәфкать сездән!
Син изгеме яки бер-бер мәлгунь рухмы,
Оҗмах яки тәмуг җилен китерәсеңме,

Ниятең изгедерме, явыздырмы,
Ләкин төсең мине шундый җәлеп итте —
Синең белән сөйләшергә тиешмен мин.
Мөрәҗәгать итәм сиңа: Гамлет, Король,
Әтием! Даниянең хөкемдары,
Җавап бир миңа, мине белемсезлек
Тәмугында интектермә! Әйт, ни өчен
Күмелгән синең изге сөякләрең
Кәфеннәрен ярып чыкты? Нидән безнең
Олылап күмгән синең тирән каберең
Үзенең салкын мәрмәр авызын ачып,
Пөскереп сине кире чыгарды соң?
Ни булды да, син бер җансыз, тынсыз мәет
Яңадан төренеп бу корычларга
Куркынычка салып төнне ай нурында
Йөрисең? Моны ничек аңларга соң?
Нигә безне, табигатьнең кәмитләрен,
Без күтәрмәс киң колачлы хыял белән
Бу кадәр аптырашка саласың син?
Әйт, ни өчен? Нәрсәгә бу? Нишлик соң без?

Өрәк Гамлетка ымлый.

Горатсио

Ул сезгә үз артыннан барырга дип
Ымлый, сезгә әйтер сүзе бар шикелле.

Марсел

Карагыз, ул сезгә, нинди йомшак итеп,
Читкәрәк барырга дип ымлый. Ләкин
Аның белән бармагыз.

Горатсио

Юк, һич бармагыз.

Гамлет

Монда җавап бирми, барам артыннан мин.

Горатсио

Кирәкми, принц.

Гамлет

Нәрсә, нигә куркыйм?
Үз башымны энә хәтле дә күрмим мин.
Ә инде җаным аның үзе кебек
Үлемсез булгач, миңа нишли алыр?
Ул яңадан ымлый миңа. Барам аңа.

Горатсио

Ул сезне тартса, принц, төпсезлеккә;
Яки диңгез упкыннары өстендәге
Очлаеп алга чыккан, куркынычлы
Таш кыяга илтеп сезне, үзе дә бик
Куркынычлы, башка берәр төскә керсә,
Шуның белән башыгыздан исне алып
Сезне тәмам шашындырса? Исәпләгез;
Упкыннарга карап, аста, төпсезлектә
Диңгезнең үкергәнен ишеткәндә,

Һәркемнең башына да үз-үзеннән
Яман шашкын уйлар килер.

Гамлет

Тагын ымлый.
Бар син анда, мин дә барам артыңнан.

Марсел

Юк,
Сез бармассыз анда, принц.

Гамлет

Ал кулыңны!

Горатсио

Исегезгә килегез сез, ярамый бу.

Гамлет

Мине чакыра үз язмышым. Тәнемдәге
Бөтен вак, иң кечкенә нервыма да
Нәмәй арысланы[1] көче керә минем.

Өрәк ишарә итә.

Һаман чакыра? Җибәрегез, джентльменнар[2],

Алардан китәргә йолкына.

Анттыр әгәр, мине тоткан кем булмасын,
Үзе дә әйләнәчәк ул өрәккә.
Чиген, димен! Син бар, мин дә синең арттан.

Өрәк белән Гамлет чыгып китәләр.

Горатсио

Ул хәзер тәмам шашкан, хыялланган.

Марсел

Артыннан без дә барыйк, кушмаса да.

Горатсио

Кала төшеп барыйк. Бу ни булып бетәр?

Марсел

Дания дәүләтенең чие бар бер.

Горатсио

Алла белсен.

Марсел

Юк, артыннан барыйк әле.

Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мәйданның икенче ягы.
Өрәк белән Гамлет керәләр.

Гамлет

Кая алып барасың? Әйт, артык бармыйм.

Өрәк

Алай булса, тыңла.

Гамлет
Тыңлыйм.

Өрәк

Вакыт якын.
Яңадан тынчу күкерт утларында
Интегергә мин кайтырга тиешлемен.

Гамлет

Бичара рух.

Өрәк

Кызганма син мине, ләкин
Минем сиңа әйтер сүзгә нык колак сал.

Гамлет

Мин ишетергә тиеш. Сөйлә.

Өрәк

Һәм ишеткәч
Үч алырга тиешсең син.

Гамлет

Нәрсә, нәрсә?

Өрәк

Мин синең атаң рухы. Төннәр йөреп,
Көндезен мин үткәндәге яман гөнаһ,
Җинаятьтән табигатем арынганчы,
Тәмугларда янар өчен салынганмын.
Әгәр дә тәмугымның серләрен мин
Сөйли алсам, рөхсәт булса, шундый хәлләр
Сөйләр идем сиңа, аның бер сүзеннән
Йөрәгең ярылып синең, котың чыгар,
Яшь каның боздай туңар, ике йолдыз
Күзләрең үз кучәреннән атылып чыгар,
Дулкынлы куе чәчең бөдрәләре
Ачуланган дикобразның каурыйлары
Шикелле һәрбер төге үзалдына
Үрә торыр иде. Ләкин бу мәңгелек
Серләрне ишетергә тән белән кан
Иясе кешеләрнең көче җитмәс.
Тыңла, тыңла, аһ, тыңлачы, әгәр дә син
Кадерле әткәеңне кайчан да бер
Яраткан булсаң...

Гамлет

Раббым!

Өрәк

Үчен ал син
Бу кабахәт үтерешнең.

Гамлет

Үтерешнең?

Өрәк

Әйе, һәрбер үтереш ул — кабахәтлек;
Әмма ләкин бу тагы да кешелексез
Һәм шомлырак.

Гамлет

Белдер тизрәк аны миңа,
Мин дә хыял яки гыйшык дәртеннән дә
Җиңелрәк канат белән омтылыйм шул
Үчне алыр өчен.

Өрәк

Күрәм, син әзерсең.
Инде дә син бу хәлемнән сискәнмәсәң,
Лета[1] суы өстендәге тынчып үскән
Нерен дигән үләннән дә симез, авыр,
Хиссезрәк булыр идең. Алай булгач,
Ишет, Гамлет, минем хакта хәбәр йөри:
Бакчада йоклап яткан чакта мине,
Имештер, елан чагып үтергән дип.
Үлүем турындагы шул уйдырма
Хәбәр белән бар Дания алдатылган.
Тик бел, егет, әтиеңне чаккан елан
Хәзер атаң таҗын киде.

Гамлет

Күңелем дөрес
Сизгән икән. Агаммы ул?

Өрәк

Шул уйнашчы,
Кардәшенә өйләнүче, ерткыч хайван.
Шушы кеше, акылының кара көче,
Хыянәткә таланты бар шушы кеше
(Аһ, бозарга көче җиткән мондый акыл,
Мондый талант нинди шомлы һәм әшәке!), —
Шул оятсыз нәфсе белән минем болай
Тугры кебек хатынымны үз мәеленә
Каратты. Аһ, Гамлет, нинди тәгәрәү бу!
Минем кебек, аңа никах көнемнән үк
Биргән вәгъдә сүзләремнән аерылмыйча
Яшәгән бер кешене, аның кебек
Табигать тарафыннан миннән бик күп
Өлешсез яратылган, түбән торган
Бер кешегә алыштыру! Рас икән шул,
Бозыклык саф күңелгә күпме генә
Сырышмасын, ул бирелми исән калыр,
Бозык кеше үзе оҗмах түрләрендә,
Пакь фәрештә кочагында рәхәт чиксен,
Барыбер ул чумар өчен пычрак эзләр.
Ләкин тукта! Таң һавасы сизелә миңа.
Кыска тотыйм. Гадәтемчә, төш вакытында
Бакчамда йоклаганда, минем гамьсез
Шул чагымны синең агаң саклап торып,
Шаукымлы тилебәрән суы салган
Шешә тотып, посып кына килгән миңа.
Шул бозгыч сыгымтасын әкрен генә
Колагымның эченә үк агызмасмы?!
Хасияте шундый аның — ул сыгымта
Адәмнең каны белән шундый дошман,
Тәннең бөтен үткеленә, юлларына
Терекөмеш кебек шундук үтеп кереп,
Тап-таза сәламәт кан шул минутта
Бөтерелеп, әче тамган сөт шикелле

Эреп китә. Миңа да нәкъ шул хәл булды.
Кинәт Әйюп тәне кебек, яман кутыр
Бөтен шома тән өстемне кабык кебек
Каплап алды. Шулай итеп мин йокымда,
Үз туганым кулы белән, гомеремнән дә,
Тәхтемнән дә, бикәмнән дә бердән яздым.
Гөнаһларым тулы чәчкә атып торган
Чагында киселдем мин, тәүбә күрми,
Дога күрми, дөнья белән хисап өзми,
Үземнең барлык кылган гөнаһыма
Хисап бирергә мин калдым — яман хәлем,
Яман, яман! Аһ, бик яман! Әгәр синдә
Йөрәк булса, бу хәлгә син түзеп торма;
Дания патшалары ятагын син
Кан кардәше белән уйнаш, кәеф-сафа
Түшәгенә әйләнергә ирек бирмә.
Тик бу эшне ничек кенә башкарсаң да,
Анаңа үз күңелеңнән яман карап,
Пычратма үз җаныңны; ансын калдыр
Бер Ходайга, үз эчендә тулып яткан
Тигәнәкләр үз йөрәген чаксын аның!
Сау бул, инде вакыт. Әнә утлы бөҗәк,
Таң җиткәнен хәбәр итеп, төссез утын
Сүндерә ул. Сау бул, сау бул, кичер мине.
Онытма.

Китә.

Гамлет

Әй, сез, күкнең бар көчләре!
Әй, җир! Тагын нәрсә калды? Тәмугкамы
Иш булырга? Уф, туктачы, басыл, йөрәк!
Сез дә, минем сеңерләрем, бердән генә
Картаймагыз, әле мине нык тотыгыз.
Синең хакта онытыргамы? Бичара рух,
Әлеге таркау, шашкын бу башымда
Акылым барда, сине онылу? Һич югында,
Хәтеремнең дәфтәреннән гомерем буе
Барлык җыйган истәлегем, тәҗрибәмне,
Барлык образ, китап сүзен сызып атып
Ташлармын да, минем акыл китабымда
Тик шул синең һични белән катышмаган
Васыятьләрең генә калыр нигез булып.
Аһ, валлаһи, корткыч хатын!
Аһ, түбән җан! Елмаючы каһәр, ләгънәт!
Йә, дәфтәрем, моны язып куй әле син:
Көлемсерәп яшәргә дә, көлемсерәп
Явыз, ерткыч булырга да мөмкин икән!
Бигрәк тә Даниядә. *(Яза.)* Шулай, агам,
Сез биредә, менә монда. Хәзер минем
Лозунгым шул: «Сау бул, сау бул, онытма син
Мине». Шуңа мин ант эчтем.

Горатсио белән Марсел
*(тыштан)*

Принц, принц!

Марсел
*(тыштан)*

Принц Гамлет!

Горатсио
*(тыштан)*

Алла, үзең сакла аны.

Гамлет

Шулай булыр.

Горатсио

Илләү, һәй-һәй[1], принц!

Гамлет

Илләү,
Һәй-һәй, монда кил, карчыгам!

Горатсио белән Марсел керәләр.

Марсел

Ничек, милорд?

Горатсио

Нәрсә булды, принц?

Гамлет

Хәйран, хәйран эшләр.

Горатсио

Сез әйтегез, принц.

Гамлет

Юк, сез сөйләнерсез.

Горатсио

Мин ант итәм сезгә, принц, миннән чыкмас.

Марсел

Һәм миннән дә.

Гамлет

Сезгә ничек күренер бит?
Кем уйлар бит! Ләкин серне сакларсызмы?

Горатсио белән Марсел

Әйе, кояш йөзен күрмик әгәр, принц.

Гамлет

Даниядә аңардан да чая, явыз
Кеше булмас.

Горатсио

Безгә бары шуны әйтер
Өчен генә булса, рухка кабереннән
Торасы да калмаган.

Гамлет

Хак, дөрес әйттең.
Шунлыктан, артык сөйләп тормыенча,
Әйдә, куллар бирешик тә таралышыйк.
Һәркемнең бит үз эше бар, үз нияте,
Сез барыгыз үзле-үзегезгә, ә мин
Үз башыма төшкән икән, ярый, киттем

Гыйбадәт кылу өчен.

Горатсио

Болар, принц,
Барысы да тик бәйләнешсез, кыргый сүзләр.

Гамлет

Бу сүзләрнең хәтерегезне калдыруы
Бик аяныч, ихлас чыннан, бик аяныч.

Горатсио

Үпкәләрлек эш юк монда, принц.

Гамлет

Бик бар.
Изге Патрик исеме белән, анттыр әгәр,
Горатсио, үпкәнең дә бик авыры,
Инде килсәк бу әйбергә, дөресен әйтим,
Бу — яхшы рух. Ләкин безнең арада ни
Булганлыгын белергә дә тырышмагыз.
Инде сез студент та һәм солдат та
Буларак, миңа якын дуслар булгач,
Минем сезгә кечкенә бер үтенеч бар.

Горатсио

Нәрсә, принц? Без әзербез.

Гамлет

Бу күргәнне
Һич вакытта белмәскә дә сөйләмәскә.

Горатсио белән Марсел

Бетте, принц.

Гамлет

Юк, сез шуңа ант итегез.

Горатсио

Ихлас, принц, һич сөйләмәм.

Марсел

Мин дә, милорд,
Ихлас.

Гамлет

Юк, сез минем кылычым өстендә дә.

Марсел

Ант бирдек бит.

Гамлет

Тагын кылычым өстенә ант!

Өрәк
*(җир астыннан)*

Ант итегез!

Гамлет

Аһа, син дә шулай дисең?
Син дә бире, дускай? Йә тиз, ишетәм сез
Җир астыннан? Ант итегез.

Горатсио

Сүзләрен сез
Әйтегез, принц.

Гамлет

Монда ни күргәнсез —
Бервакытта сөйләмәскә. Шушы кылычым
Өстенә сез ант итегез.

Өрәк
*(җир астыннан)*

Ант итегез!

Гамлет

Hic et ubique[1]? Алмашыйк урыннарны,
Бире торыйк, джентльменнар.
Тагын куеп кулыгызны кылычыма,
Монда ни ишеткәнсез — беркайчан да
Сөйләмәскә ант итегез.

Өрәк
*(җир астыннан)*

Ант итегез!

Гамлет

Яхшы әйттең, карт алаңгыр! Шулкадәр тиз
Казыйсың син җир астында. Тагын, дуслар.

Горатсио

Аһ, ай белән көндер әгәр. Бик ят эш бу!

Гамлет

Шул ят булган өчен күнеп эшләгез дә.
Җирдә, күктә хикмәт эшләр шундый күп ки,
Аларны сезнең философларыгыз
Төшендә дә күрмәгәннәр, Горатсио.
Тагын кучтек. Рәхмәт сезгә. Анттыр шуңа:
Мин үземне берәр төрле сәер тотсам,
Ихтимал, бу башымны вакыты белән
Юләргә салырга ук туры килсә,
Сез шул вакыт, минем белән очрашканда,
Кулыгызны шапрыш куеп йә баш чайкап,
Йә ымлап, «Ярый, ярый, беләбез» дип,
Яки «Әйтеп булса әгәр», йә булмаса
«Әйтергә без теләсәк» дигән сыман
Яки башка шундый шикле сүзләр белән
Минем хакта сезгә мәгълүм булган эшне
Бертөрле дә сиздермәскә ант итегез.
Аннан Алла ярдәм итсен эшегездә.

Өрәк
*(җир астыннан)*

Ант итегез!

Гамлет

Тынычлан, әй тынгысыз рух.
Джентльменнар, шулай сезнең кулыгызга
Тапшырам үз-үземне чын күңелдән.

Сезгә дуслык мәхәббәтен күрсәтергә
Гамлет кебек бер бичара нишли алса,
Иншалла, шул эшләнер. Киттек бергә;
Авызыгыздан сүз чыкмасын, сорыйм сездән,
Онытмагыз! Замананың көпчәкләре
Эздән чыкты. Әй бу шомлы язмыш юлым,
Шул көпчәкне рәтләр өчен бер мин тудым!
Ярый, булсын, бергә киттек.

Китәләр.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Полони өендә бер бүлмә.
Полони белән Рейнальдо керәләр.

Полони

Шул хат белән шул акчаны аңа тапшыр,
Рейнальдо.

Рейнальдо

Яхшы, тапшырырмын, милорд.

Полони

Аның белән күрешкәнче, әгәр дә син
Читтән аның акылын-фигылен сорап белсәң
Бик акыллы иткән булыр идең, Рейнальдо!

Рейнальдо

Мин шулай итәрмен дип торам, милорд.

Полони

Менә бик шәп, менә әйбәт. Син кара, сәр,
Башта сораш, ул Парижда безнең илдән
Кемнәр яши, нинди эштә, кайда яши,
Ничек яши, нинди-нинди компаниядә,
Нәрсә белән киченәләр — барын да бел;
Шулай читтән сораштыргач, алар минем
Улым белән танышлармы икәнен дә
Белеп алгач, аннан инде үзең сораш:
Кара ләкин, хәйлә белән; аны бераз
Читтән белгән кеше кебек күрсәтеп әйт:
Атасын, дус-ишләрен белә идем,
Үзен дә аз-маз беләм, дигән булып
Җибәрерсең. Төшенденме, Рейнальдо?

Рейнальдо

Әйе,
Бик шәп, милорд.

Полони

Үзен дә дип, аз-маз гына;
Төпле белмим, тик шунсы бар, бик җилкуар
Кеше диләр аны шунда, дигән булып,
Тагын шундый фәлән-фәсмән. Монда инде

Син аның өстенә өй теләсә ни.
Тик, билгеле, аның исемен пычратырлык
Итмичә; ансын кара, ансын сак бул.
Юк, син бары яшьлеккә һәм хөр егеткә
Хасрак булган шуклык яки мутлык сөйлә.

Рейнальдо

Әйтик, карта уйнау, милорд.

Полони

Әйе, әйе,
Эчү, сүгенү, кылыч белән йә сүз белән
Җиңешүләр, типтерүләр кебек шунда.
Ул хәтлесен әйтсәң ярый.

Рейнальдо

Ләкин аны
Бу пычрату булыр, милорд.

Полони

Юк ла тагы.
Соң, боларны син бит бераз йомшартырсың.
Син аны эштән чыккан тотнаксыз дип,
Әкәмәтләр таратырга тиеш түгел.
Алай түгел, син тик аның гөнаһларын
Ул яшьтәге һәркем өчен хас бернәрсә
Кебек итеп йә хөрлекнең артыграк
Бер күренеше, дәрт, кызулык, кан уйнавы,
Артыграк башсызлану кебек итеп,
Оста гына төрттереп әйт.

Рейнальдо

Ләкин, милорд...

Полони

Болар нигә кирәк, димсең?

Рейнальдо

Әйе, милорд,
Белер идем.

Полони

Менә нәрсә минем ният:
Минемчә, бу шәп тә чыгар, шуны кара:
Улымны син аз-маз шулай гаепләгәч,
Әгәр аның шул саналган гөнаһларда
Гаебе булса, улым исемен әйтү белән,
Бу сорашкан кешең сиңа мөгаен дә
Йә килешеп фикерең белән, йә бүлешеп:
«Хөрмәтлем» дип әйтер, яки «дус кеше» дир,
«Әфәндем» дир, ансы инде үз иленең
Йә үзенең гадәтенчә.

Рейнальдо

Шулай, милорд.

Полони

Аннан ул, сэр, моны нитәр, нитәр... Нәрсә
Әйтә идем? Валлаһи, бит мин нәрсәдер
Әйтмәкче идем. Яле, нидә калдым?

Рейнальдо

«Йә килешеп фикерең белән, йә бүлешеп,
«Хөрмәтлем» дип әйтер, яки «дус кеше» дир».

Полони

«Фикерең белән килешеп», әйе; болай килешер,
Әйтер: «Мин ул джентльменны беләм бит», — дир,
Кичә яки беркөн күрдем, йә шул чакны
Теге фәлән белән бергә күрдем аны,
Нәкъ сез әйткән кыяфәттә карта уйный,
Яки эчкән чагы иде, йә тегендә
Туп уйнаган чакта күрдем, ызгышты, дир.
Йә, ихтимал, бер притонга кереп барган
Чагында күрдем, дияр, йә шинкарга.
Яки тагын беткәнмени?
Күр дә тор, ялганыңның кармагына
Дөреслекнең балыгы — шалт! — капмасамы!
Шулайтеп, без, зирәк акыл кешеләре,
Читтән-миттән тозак салып, кәкре атып,
Әйләнгечтән үзебезгә кирәк юлны
Табабыз. Син дә тотсаң минем сүзне,
Улымны тиз сынарсың. Аңладыңмы?

Рейнальдо

Әйе, милорд.

Полони

Ак юл сиңа. Хуш, исән бул.

Рейнальдо

Яхшы, милорд.

Полони

Холкын-ниен яхшы күзәт.

Рейнальдо

Күзәтермен, милорд.

Полони

Әйдә, сыбызгысын
Тик үзенчә бызылдатсын.

Рейнальдо

Яхшы, милорд.

Полони

Хуш!

Рейнальдо китә. Офелия керә.

Йә, нихәл, Офелия! Нәрсә булды?

Офелия

Аh, әткәй, шулкадәрле мин буталдым.

Полони

Нәрсәдә? Алла хакы өчен сөйлә.

Офелия

Үз бүлмәмдә чигү чигеп утыра идем,
Кинәт кенә принц Гамлет килеп керде.
Камзулы — ычкындырган, эшләпәсез,
Оеклары сыйрагына сыдырылган,

Пычранган, ике тезе дер-дер килә.
Йөзләре — күлмәгеннән болай аграк.
Шундый ачы кыяфәттә, әйтерсең лә
Шомлы хәбәр сөйләргә дип, җәһәннәмнән
Атылып төшкән кебек, килеп алга басты.

Полони

Гыйшкыннан шашкан мәллә?

Офелия

Белмим, әткәй.
Ләкин шул, шуннан куркам.

Полони

Ни диде соң?

Офелия

Тотты да ул беләгемнән ныгытып кысты.
Икенче кулын шулай каш өстенә
Куеп, минем йөземә ул үзе шундый
Төпчеп карый, әйтерсең лә рәсемем яза.
Озак торды шулай. Аннан, ахырында,
Кулымны ычкындырып җибәрде дә,
Башын шулай өч кат кагып, шундый тирән
Бер көрсенде, мин күкрәге ярылдымы,
Җаны чыктымы дип торам. Аннан мине
Җибәрде ул. Үзе, миңа башын борып,
Тилмереп шундый карый, барыр юлын
Күрми атлап, ишектән үк чыгып китте.

Полони

Әйдәле син, эзләп табыйк без Корольне.
Күренеп тора, монда гыйшык тилелеге.
Дөньяда безнең барлык дәртләр кебек,
Гыйшыкның да тинтерәткеч, һәлак иткеч,
Куркыныч хасияте бар бит аның.
Куркам, аңа бу көннәрдә ни дә булса
Син бик каты авыр сүзләр әйтмәдеңме?

Офелия

Юк, кадерле әткәм. Ләкин, сез кушканча,
Хатларын алмадым мин. Үземә дә
Үзен якын җибәрмәдем.

Полони

Менә шуннан шашкан да ул.
Нишләп соң мин әле моны баштук сизми,
Уйламыйча, саксыз, җиңел караганмын!
Мин бит аны шаяра дип, сине харап
Итәргә җыена дип уйлап йөрдем.
Тфү, шушы урынсызга шикләнүләр!
Валлаһи, яшьләр өчен ни дәрәҗә
Саксызлык хас әйбер булса, безнең яшьтә
Ирләрдә артыграк саклану бар.
Әйдә Король янына. Ул бу нәрсәне
Белсен әле. Мәхәббәтне яшермәүгә
Караганда, аны яшерү аркасында
Күбрәк бәла килеп чыга. Әйдә киттек.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сарайда бер бүлмә.
Быргылар тавышы. Король, Королева, Розенкранц, Гилденстерн һәм сарай хадимнәре керәләр.

Король

Хуш килдегез, Розенкранц, Гилденстерн!
Сезне күптән күрәсебез килгән иде.
Эшебез сезгә төшкәч, инде сезне
Бик ашыгыч чакырырга мәҗбүр булдык.
Гамлетның үзгәрүе турында сез
Кайбер нәрсә ишеткәнсездер дип уйлыйм.
Үзгәрү дип атавым шул: анда хәзер
Ни эченнән, ни тышыннан элеккегә
Охшаш нәрсә һич калмады. Атасының
Үлеме аны шулай акылыннан
Яздырырлык эш булыр дип уйлый алмыйм.
Сез яшьтән аның белән бергә үскән,
Яшьләрегез, фигылегез дә аңа якын,
Шуның өчен сорыйм сездән, икегез дә
Беразга бездә калып торсагыз ла.
Аны тартып арагызга, уйнап-көлеп,
Бергә-бергә йөрерсез, һәм аны шундый
Зур кайгыга сала торган, без белмәгән
Берәр яшерен нәрсә юкмы, шуны белеп,
Җае килсә ансына да күз салырсыз.
Шуны белсәк, без дә аңа хәлебездән
Килгән кадәр ярдәм итә алыр идек.

Королева

Джентльменнар, ул сезне еш искә алды.
Мин ышанам, аңа сездән сөйкемлерәк
Дөньяда бүтән ике кеше булмас.
Әгәр дә сез, рәхим итеп, бераз бездә
Калыр өчен вакытыгызны бирә алсагыз,
Безгә ярдәм күрсәтергә теләсәгез,
Без сезнең хезмәтне дә патшаларча
Кайтарыр идек сезгә рәхмәт белән.

Розенкранц

Сез, падишаһ, моны бездән сорап тормый,
Иркәгезне хөкемдарлык көче белән
Боерып кына әйтсәгез дә җиткән безгә.

Гилденстерн

Баш орып сезнең аяк йөзегезгә,
Буйсынып икебез дә үзебезне
Баштанаяк сезнең кулга тапшырабыз.
Сездән — фәрман, бездән — хезмәт.

Король
Рәхмәт сезгә,
Розенкранц һәм ягымлы Гилденстерн.

Королева

Рәхмәт, Гилденстерн, рәхмәт, Розенкранц,
Барсагыз ла, аһ, тиз генә шул чамасыз
Үзгәреп киткән угылым янына сез.
Кем дә булса хәзер аңа илтсен сезне.

Гилденстерн

Алла биреп, безнең шушы килүебез
Аңа файда булып чыга күрсен.

Королева

Амин.

Розенкранц, Гилденстерн һәм берничә сарай хадиме чыгалар. Полони керә.

Полони

Королем, Норвегиядәге безнең
Илчеләр әйбәт кайтты.

Король

Синнән гел-гел
Сөенеч хәбәр.

Полони

Рас түгелме, падишаһым?
Ышаныгыз, бөек Король, җанымны мин —
Алла өчен, хезмәтемне Король өчен
Асрыйм. Әгәр минем мием зур эшләрдә
Сизгерлеген югалтмаса, тагын шул сүз:
Гамлетның шашынуы нидән килә —
Аның да төп сәбәбен ачтым бугай.

Король

Соң шуны әйт. Мин ишетергә ярсып торам.

Полони

Башта сез илчеләрне күрсәгез лә.
Минем сүзем туй мәҗлесе ахырына
Тәмле җимеш булып килсен.

Король

Үзең зурлап,
Аларны каршы алып бире китер.

Полони китә.

Ул әйтә, Гертрудам, бу Гамлетның
Кайгысының чыганагын мин таптым, ди.

Королева

Миңа калса, аңа сәбәп тик бер генә:
Атасының үлүе дә безнең никах.

Король

Яхшы, моны без күрербез.

Полони Вольтиманд һәм Корнели белән кире кайталар.

Хуш кайттыгыз,
Якын дуслар. Йә, Вольтиманд, сөйләп җибәр:
Ни ди безнең Норвик туган?

Вольтиманд

Бик күп сәлам,
Алкыш сезгә. Ишеткәч тә бу хәбәрне,
Иң элек ул энесенең гаскәр җыю
Эшен тыйды. Чөнки Норвик ул гаскәрне
Польша белән сугышырга туплыйлар дип
Белгән икән. Ләкин ныклап танышкач та,
Турыдан-туры аны сезнең җәнабегез
Белән сугышыр өчен икәнлеген белде.
Үзенең хәлсезлеге, картлыгыннан,
Авыруыннан шулай файдалануларын

Белгәч тә, бик борчылып, Фортинбрасны
Шундук тотып үз каршына китерттерде.
Ул тиздән килеп җитеп, карт Норвиктан
Шелтә алгач, сезнең бөек затыгызга
Моннан соң һич тә корал күтәрмәскә
Ант итте. Карт Норвик та шул шатлыктан,
Һәр ел өчен аңа өч мең крон акча
Бүләк тә билгеләде һәм бу җыйган
Солдатларын элеккечә шул Польшага
Сугыш белән баруына рөхсәт итте.
Шул максат өчен, монда язылганча,
*(Кәгазь бирә.)*
Мәмләкәтнең иминлеген һәм хокукын
Тәэмин итү шарты белән, ул гаскәрне
Сезнең җирләрегез аша үткәрергә
Рөхсәт сорый.

Король

Без бу эшкә кул куябыз.
Бушагач, укып җавап кайтарырбыз,
Уйлашырбыз. Өстегезгә алган эшне
Уңышлы үтәвегез өчен рәхмәт
Укыйбыз. Хәзер барып ял итегез;
Кич бергәләп типтерербез. Хуш кайттыгыз.

Вольтиманд белән Корнели китәләр.

Полони

Бу эш пеште. Падишам һәм патша бикәм,
Патшалык ул үзе нәрсә, бурыч нәрсә,
Ни өчен көн — көн була, төн — төн була,
Вакыт нигә вакыт була, көн — төн үзе
Вакыт булып чыкмыймы дип баш ватулар
Үзе шушы көнне, төнне һәм вакытны
Юкка гына әрәм итүдер ләбаса?
Шунлыктан кыска сүзне — җан азыгы,
Озын сүзне баш казыгы, димен дә мин
Кыска тотып әйтәм: сезнең асыл затлы
Улыгыз акылыннан шашкан; әйе,
Акылыннан, дидем, чөнки шашкан кеше
Акылыннан шашкан була. Шул. Вәссәлам.

Королева

Бизәге калып торсын, эшкә килик.

Полони

Бу сүзләрдә бер бизәк юк, анттыр, ханым,
Шашкан икән — бу хәл дөрес. Кызганыч хәл,
Бу да дөрес; дөреслеге дә кызганыч,
Ахмакча сүз әйләнеше. Хәер, калсын.
Бизәмичә генә сөйлим. Ярый. Аны
Акылыннан шашкан дип без килештек, ди.
Килештекме, ул чагында безгә кала
Бу эффектның яки, дөресе, бу дефектның
Төп сәбәбен ачып салу. Чөнки эффект
Үзе бит ул сәбәпсез дефект булмый.
Бар калганы шушы һәм шул бар калганы.
Шуннан уйлыйк хәзер: минем бер кызым бар,
Ул минеке булган кадәр минем кызым,
Минем кызым булган кадәр ул буйсына,
Игътибар итегез сез, шул буйсыну

Бурычын үтәп, миңа ул ни бирде.
Тыңлагыз да хәл итегез, хөкем сездән.
*(Укый.)*

«Җанымның тәңресе, фирештәм Офелия». — Бу начар әйтем, әшәке әйтем; «Фирештәм» — чәйнәлгән әйтем. Ләкин сез шуннан соңгысын ишетегез әле. Менә. *(Укый.)* «Аның тиңсез ак күкрәгенең кесәсенә бу», һәм, һәм... башкалар.

Королева

Шушыны аңа Гамлет язамы?

Полони

Ханым әфәнде, чак кына көтегез; мин сезгә барын да сөйләп бирермен. *(Укый.)*
«Шик тот йолдызларның балкуына,
Шиклән кояш күктә йөзгәнгә,
Шиклән расның ялган булмавына,
Тик син сөюемә шикләнмә.

Аһ, кадерле Офелия, миңа шигырь үлчәүләре кыен бирелә. Мин үземнең аһ-ваһларымны үлчәүгә сала белмим; ләкин мин сине наз белән сөям, аһ, бик назлап сөям, моңа ышан. Хуш. Бу тән дигән механизм минеке булып торганда, әй, асыл кыз, мәңгелеккә синеке булган Гамлет».
Тыңлаучан кызым миңа биргән әйбер
Шушы. Аннан аның ничек үз артыннан
Йөрүен, кайчан, кайда, ничек вакыт
Уздыруын — барысын, барысын сөйләп бирде.

Король

Кыз соң аның гыйшкын ничек кабул иткән?

Полони

Минем хакта ничек диеп уйлыйсыз сез?

Король

Бик хөрмәтле һәм намуслы кеше дип.

Полони

Мин
Шуны исбат итәргә дә телим. Ләкин
Әгәр дә мин Гамлетның бу кайнар гыйшкын
Белгәч тә (ә мин, дөресе, кызым миңа
Әйткәнче үк сизгән идем), әйе, шуннан,
Белгәнемне дәфтәр кебек эчтә саклап
Йә булмаса бу гыйшыкка читтән карап
Дәшми торсам, сез үзегез яки сезнең
Биредәге асыл затлы бикәгез дә
Минем хакта ни уйлаган булыр иде?
Юк, мин эшне кызу тоттым, кызыма да
Болай әйттем: лорд Гамлет ул — принц кеше, —
Ул синең йолдызыңа буйсынмаган[1].
Моннан ары бетсен бу эш, дидем; аңа
Очрама, аннан бүләк-мазар алма,
Арада кеше йөртмә, диеп куйдым.
Мин кушканча итте кызым. Шуннан Гамлет
Гыйшкы кабул ителмәгәч, кыскасы шул,
Кинәт авыр уйга төшеп, моңга баткан.
Аннан юньләп ашамый да, эчми башлап,
Йокыдан калган, аннан хәле киткән,
Аннан хәтере таркауланган, шулай итеп
Бара торгач, хәзер безнең һәммәбезне
Борчыган шул шашкынлыкка килеп төшкән.

Король

Син дә моны шуннан диеп уйлыйсыңмы?

Королева

Шулай кебек тия.

Полони

Шулай булмаганны
Берәр вакыт, киресенчә, «бу шулай» дип
Әйткәнем бармы — шуны белер идем.

Король

Исемдә юк.

Полони

Шулай булып чыкмаса бу,
*(үзенең башына һәм иңсәсенә күрсәтеп)*
Моны моннан алып ташлагыз. Килсен генә
Миңа җае, хаклык дигән нәрсәне мин
Җирнең тишегендә булсын — эзләп табам.

Король

Моның дөреслеген ничек белеп була?

Полони

Ул монда галерея буйлап кайчан
Сәгатьләр буе йөри, беләсездер.

Королева

Әйе, йөри.

Полони

Нәкъ шул вакыт мин кызымны
Аның янына җибәрим. Минем белән
Шушы палас артына сез яшеренеп
Аларның очрашуын күзәтерсез.
Әгәр дә ул кызга гыйшык тотмый икән,
Шашуы да шуның өчен түгел икән,
Минем урыным дәүләт киңәшендә түгел,
Әнә йортта ат камытлау, арба майлау.

Король

Ярый, сынап карарбыз без.

Королева

Күрәмсең, ул
Укый-укый килә. Нинди уйчан, мескен.

Полони

Китебрәк торыгызчы икегез дә.
Мин янына барыйм.

Король, Королева һәм сарай хадимнәре китәләр. Гамлет китап укый-укый керә.

Рөхсәт итсәгезче.
Принц Гамлет, хәлләр ничек?

Гамлет

Ярый, шөкер.

Полони

Сез мине беләсез бит, принц?

Гамлет

Бик яхшы беләм. Сез — балык сатучы[1].

Полони

Юк, принц.
Гамлет. Ул чагында мин сезнең шундый ук туры кеше булуыгызны телим.

Полони

Туры дисез, принц?
Гамлет. Әйе, әфәндем, туры кеше булырга, дим. Чөнки бит ул, бу дөньяның гадәтенчә, ун меңләгән кешедән берәү генә табыла.

Полони

Бу бик дөрес, әфәндем.
Гамлет. Әгәр дә кояш үзенең нурлары белән сасыган эт үләксәсен иркәләп сөеп, анда кортлар ярата торган булса, — кызың бар бит әле синең?

Полони

Бар, принц.
Гамлет. Аңа кояшта йөрергә ирек бирмә. Корсакка узу — изге эш, ләкин мондый изгелек синең кызыңа төшмәсен. Кара аны, дус.
Полони. Моның белән ни әйтмәкче буласыз? *(Читкә.)* Һаман минем кызга бора. Башта үзе мине танымады; балык сатучы, ди; ычкынган бу, ерак ычкынган. Дөрес тә шул, гыйшык яшь вакытны минем дә авызны шактый гына өшеткән иде. Менә бөтенләй моның кебек инде. Тукта, мин аның белән яңадан сөйләшеп карыйм. Сез ни укыйсыз, принц?

Гамлет

Сүзләр, сүзләр, сүзләр.

Полони

Нәрсә турында соң, принц?

Гамлет

Кемнәр турында дисеңме?

Полони

Юк, мин сезнең укыганыгыз нәрсә турында, дим.
Гамлет. Яла турында, әфәндем. Чөнки монда бер наян кеше әйтә, картларның сакалы ак, йөзләре җыерылган була, ди; күзләреннән сөтлегән кебек куе сыекча сыгылып чыга, ди; аларның бер акыллары да калмаган, шуның өстенә тагы тез асты шөрепләре дә бөтенләй бушаган була, ди. Гәрчә мин үзем боларның барысына да бик тирән, бик нык ышансам да, ләкин бу нәрсәләр турында мондагы кебек итеп язуны килештермим, сэр. Чөнки син үзең дә кысла шикелле артың белән алга йөри алсаң, минем шикелле үк карт булыр идең, сэр.
Полони *(читкә)*. Юләр булса да, төпле сөйли әле. Мондагы җиләстән китеп торырга уйламыйсызмы?

Гамлет

Кабергәме?
Полони. Хәер, шул, анда чыннан да болай җиләс булмас. *(Читкә.)* Кайчагында җаваплары нинди мәгънәле бит әле үзенең! Ярый әле баш җитмәгән җирдә күп вакытта юләрлек алдыра. Тукта, мин аны калдырып китим дә хәзер үк аның белән кызымны очратырга бер әмәл уйлап табыйм. Асыл зат принц, мин сезне калдырып китү шәрәфенә ирешергә рөхсәтегезне сорый аламмы?
Гамлет. Шуннан да артык үзем теләп аерыла торган бернәрсә дә сорый алмассың, — гомеремнән башка, гомеремнән башка, гомеремнән башка.

Полони

Сау калуыгызны телим, принц.

Гамлет

Менә бер сөмсез, карт тилеләр!

Розенкранц белән Гилденстерн керәләр.

Полони

Сез принц Гамлетны эзлисезме? Менә ул.

Розенкранц
*(Полонига)*

Рәхмәт яусын сезгә, сэр.

Полони китә.

Гилденстерн

Бөек принц!

Розенкранц

Кадерле принц!

Гамлет. Сөекле дускайларым! Йә, нихәл син, Гилденстерн? Әй, Розенкранц! Йә, туганнар, икегез дә ни хәлдә генә соң?

Розенкранц

Җирнең гади генә бала-чагалары кебек.

Гилденстерн. Бик үк бәхетле булмау белән бәхетле; без бит бәхет кызының калфагындагы күк төймә түгел[1] .

Гамлет

Ләкин аның башмак олтаны да түгел?

Розенкранц

Ансы да, монсы да түгел, принц.

Гамлет. Димәк ки, сез бәхет кызының биле тирәсендә яки аның мәрхәмәтенең кендегендә?

Гилденстерн

Дөрестән дә, без аның белән әдәп тирәсендә генә.

Гамлет. Итәгенең әдеп[1] тирәсендә? Аһ, бик дөрес шул, бәхет кызы бик әдәплеләрдән түгел. Ни яңалыклар?

Розенкранц. Яңа берни дә юк, принц. Дөньяның сафлана төшүен генә әйтмәсәк.

Гамлет. Алай булса, кыямәт якын икән; ләкин сезнең бу хәбәрегез дөрес түгел. Сездән төпчебрәк сорарга рөхсәт итегез әле. Йә, әйтегез сез, ул бәхет кызы каршында ни гаебегез булды да, нигә ул сезне шушы төрмәгә җибәрде әле, дускайларым?

Гилденстерн

Төрмәгә дисез, принц?

Гамлет

Дания — төрмә.

Розенкранц

Алайса, бөтен дөнья төрмә.

Гамлет. Аның да менә дигәне. Кат-кат бүлмәле; дөм караңгы базлары, камералары бар. Дания — шуның да иң начары.

Розенкранц

Без алай дип уйламыйбыз, принц.

Гамлет. Алайса, ул сезгә төрмә түгел. Чөнки үзалдына бернәрсә дә яхшы да, яман да булмый, бары тик фикер генә аны андый-мондый ясый. Минем өчен ул төрмә.

Розенкранц. Алайса, сезнең шөһрәт чыгарасы килү хисегез аны шундый ясый; ул сезнең таләпләрегез өчен таррак.

Гамлет. Ярабби, мин чикләвек кабыгы эченә дә сыяр, анда да үземне чиксез дөньялар патшасы итеп санар идем, тик шул яман төшләрне генә күрмәсәм!

Гилденстерн. Ул — шул шөһрәт чыгарасы килү төшләре. Чөнки шөһрәт эзләүнең төбе үзе дә төшнең күләгәсе генә.

Гамлет

Төш үзе дә күләгә генә.

Розенкранц. Дөрес. Шөһрәт сөю шундый һава кебек тәнсез, төссез бер әйбер, мин дә аны күләгәнең күләгәсе дип кенә саныйм.

Гамлет. Алай булса, җыен түбәнлек безнең чын гәүдәбез булып тора да, безнең патшалар белән шөһрәтле кешеләр шул хәерчелекнең күләгәсе булып торалар. Әллә һавага чыгабызмы? Дөресен генә әйтим, минем ул хәтле баш эшләми.

Розенкранц белән Гилденстерн

Без сезнең хезмәтегезгә әзер.

Гамлет. Андый нәрсә юк, мин сезне башка хезмәтчеләрем белән тиңлисем килми. Чөнки, сезгә туры кеше булып кына әйтсәм, алар миңа бик дорфа хезмәт күрсәтәләр. Ярый, без дуслыкның такыр юлыннан барыйк әле. Сез Эльсинорда нишлисез?

Розенкранц. Шул, сезне күрәсебез килде, принц. Башка берни юк.

Гамлет. Минем кебек хәерче кеше рәхмәткә дә ярлы. Алай да мин сезгә рәхмәт, дим. Хәер, кадерле дуслар, минем рәхмәтләрем ярты тиен дә тормый. Сезне чакыртып китерделәрме әллә үз теләгегез беләнме? Ирекле визиттыр бит? Ягез, минем белән самими булыгыз әле. Йә соң, сөйләгез инде.

Гилденстерн. Без ни дип әйтергә тиеш соң, принц?

Гамлет. Ни булса да барыбер, тик шул сорауга гына җавап булсын. Сезне чакыртып китергәннәр, күзләрегез дә шуны әйтеп тора кебек. Сезнең үз-үзегезне әдәпле тоткан булуыгыз да моны яшерә алмый. Беләм, сезне Король хәзрәтләре белән Королева бире чакырткан.

Розенкранц

Нинди максат белән, принц?

Гамлет. Ансын сез миңа әйтергә тиешсез. Ләкин безнең һәммә булган иптәшлегебез хакына, безнең яшьлек татулыгыбыз хакына, безнең какшамас дуслык мәхәббәте хакына, адәм табып әйтә алган тагын да кыйммәтлерәк нәрсәләр хакына үтенеп әйтәм, минем белән ачыктан-ачык булыгыз: сезне чакыртып алдырдылармы, юкмы?

Розенкранц
*(Гилденстернга акрын)*

Син ни дисең?

Гамлет *(читкә)*. Тимә, хәзер күзегездән күреп торам. Мине яратсагыз, яшермәгез.

Гилденстерн

Принц, без чакырылып килдек.

Гамлет. Ни өчен икәнен үзем әйтеп бирим дә, минем әйтеп куюым сезне дә аңлатма биреп торудан коткарыр, аннан, сезнең Король белән Королевага булган турылыгыгызга да бер кимчелек тә килмәс. Соңгы вакытларда нигәдер, үзем дә белмим, мин бөтен шатлыгымны югалттым; гадәттәге шөгыльләремне ташладым; кәефем чыннан да шундый начар, гаҗәп рәвештә яратылган бу дөнья, бу җир йөзе миңа кысыр бер таш кыя кебек күренә; бу күксел һава чатыры, бу искиткеч җәелгән күк йөзе, бу — алтын утлар кандиле белән бизәлгән мәһабәтле гөмбәз — бар да миңа тынчу, зарарлы пар-бу томаны булып кына күренә. Кеше дигәнең үзе табигатьнең нинди шәп могҗизасы! Акылы нинди камил! Сәләтләренең чиге юк! Кыяфәте белән дә, хәрәкәте белән дә нинди мәгънәле, нинди искиткеч! Мөгамәләсендә — фәрештә шикелле! Идеясе белән Алла шикелле! Бөтен галәмнең гүзәллеге бит! Бөтен яратылышның таҗы! Ләкин бу балчык әвәләмәсе минем өчен нәрсә? Ирләр дә минем күңелемә ятмый. Хатын-кызы да шулай ук. Гәрчә сез, елмаюыгызга караганда, монсыннан шикләнсәгез дә.

Розенкранц. Андый нәрсә һич башыма да килмәде, принц!

Гамлет. Ирләр күңелемә ятмый дигәндә ни өчен көлдегез соң, алай булгач?

Розенкранц. Мин шуны уйладым, принц, адәм балалары күңелегезгә ятмый торган булгач, ул чагында артистлар сезнең тарафтан шактый салкын каршы алыначак икән. Без юлда аларны узып үттек, җитмәсә тагы, алар сезгә хезмәтләрен тәкъдим итү өчен монда килеп яткан булалар.

Гамлет. Корольне уйнаучыга — хуш килдең. Король хәзрәтләре миннән тиешле бүләген алыр; гайрәтле рыцарьга да кылыч белән калкан табылачак; гашыйк та бер дә юкка гына уф ормас; комик үз ролен ахырынача исән-сау гына уйнап чыгар; мәзәкче хәтта йөткерә-йөткерә үпкәсе гырылдап беткән кешеләрне дә көлдерер; героиняга үз хисләрен иркен әйтергә берәү дә комачауламас; хәер, сөйләгәндә, аның ак шигыре аксаса да ярый. Нинди артистлар соң?

Розенкранц. Шул теге, сездә булып та, сез бик яратып калган артистлар — шәһәр трагиклары.

Гамлет. Нишләп соң алар гастрольдә гизеп йөриләр? Бер урында гына эшләсәләр, аларга атказану кесә ягыннан да яхшырак булыр иде бит.

Розенкранц. Миңа калса, соңгы вакыйгалардан соң аларга шәһәрдә уйнау тыелган булса кирәк.

Гамлет. Ничек икән, алар һаман мин шәһәрдә күргәндәге кебек дан тоталар микән? Тамашачылар шулай ук йөри микән?

Розенкранц

Юк, дөресен әйткәндә, алай ук йөрмиләр хәзер.

Гамлет

Нигә икән? Әллә бик тынчый башлаганнармы?

Розенкранц. Юк, алар үз эшләрен һаман шулай тырышып алып барган булалар да соң... Ләкин анда, сэр, җыен бала-чага, кечкенә чебиләр оялаган[1]. Аларга, тиешеннән артык көчәнеп акырган өчен, котырып кул чабалар. Хәзер алар модада. Гомуми театрларны *(хәзер аларны шулай атыйлар)* шундый тиргиләр, кулына кылыч тоткан кешеләр дә, каз каурыйларыннан куркып, анда йөрмиләр.

Гамлет. Ул нинди бала-чага? Кем аларны асрый? Кем аларга түли? Нәрсә, алар тавышлары җитлеккәнче генә бу һөнәр белән шөгыльләнмәкче булалармыни? Гадәттәгечә артист яшенә җиткәндә *(башка чаралары булмагач, әлбәттә, алар ул яшькә җитәчәкләр),* ул чагында алар бу төсле үзләренең барыр юлларын кисеп, үзләреннән декламация сөйләттергән өчен безгә начарлык эшләдегез дип авторларны сүкмәсләрме соң?

Розенкранц. Дөресен әйткәндә, ике яктан да шау-шу аз булмады. Халык та аларны ызгыштыруны гөнаһка санамый. Булды вакытлар, әгәр дә репликада шагыйрь белән артистлар йодрык сугышына барып җитмәсәләр, пьеса җыем бирми иде.

Гамлет

Мөмкинме бу хәл?

Гилденстерн

Һәй, баш ярулар да җитәрлек булды.

Гамлет

Балалар җиңеп чыктымы?

Гилденстерн. Әйе, алар, принц. Геркулесны җилкәсендәге җир шары-ние белән бергә[1] җиңделәр.

Гамлет. Бу бик гаҗәп эш түгел. Минем агам да Дания короле ич. Атам заманында аны үчекләргә әзер торган кешеләр хәзер аның кечкенә рәсеме өчен егерме, кырык, илле, хәтта йөзәр алтын түлиләр. Шайтан алгыры, әгәр дә философия моңа ирешә алса, монда нәрсәдер, табигатьтән өстен бер әйбер бар бит.

Сәхнә артында быргы тавышлары.

Гилденстерн

Менә артистлар.

Гамлет. Джентльменнар, Эльсинорга килеп яхшы иттегез бит әле. Йә, бирегез кулларыгызны; ачык чырай белән каршылау — йола. Миңа да сезнең белән мөмкин хәтле ачык булырга рөхсәт итегез. Югыйсә минем артистлар белән мөгамәләм сезгә минем сезне кабул итүемнән дә үзрәк булып тоелмасын. Хуш килдегез; ләкин минем эти-агам белән әни-апам ялгыша.

Гилденстерн

Нәрсәдә, кадерле принцым?

Гамлет. Мин тик бары төньяк җиле белән генә шашкан кеше. Әмма көньяк җиле искәндә, мин челәнне карчыгадан аера беләм.

Полони керә.

Полони

Сәлам сезгә, джентльменнар.

Гамлет. Тыңлагызчы, Гилденстерн, сез дә тыңлагыз, — колак саен бер тыңлаучы; сез күргән бу зур бәбәй әле булса биләүсәдән чыкканы юк.

Розенкранц. Бәлки, ул икенче кат бәбәйлеккә кайткандыр; әйтәләр ич, карт кеше ике кат бала, диләр.

Гамлет. Алдан ук пәйгамбәрлек итеп әйтәм: мөгаен, ул миңа артистлар килгәнен әйтергә килә. Карап та торыгыз. — Дөрес әйтәсең, сэр, дүшәмбе көн иртә белән; чынлап та шулай.

Полони. Милорд, мин сезгә яңа хәбәр әйтмәкче булам.

Гамлет. Милорд, мин сезгә яңа хәбәр әйтмәкче булам: Росций[1] борынгы Римда артист булган...

Полони

Артистлар килде, принц.

Гамлет

Кыт-кыт-кытыйк, кыт-кыт-кытыйк.

Полони

Валлаhи әгәр.

Гамлет

«Һәрберсе бер ишәк менеп?»[2]

Полони. Дөньяда беренче артистлар; ул трагедия уйнарга кирәкме, ул — комедияме, ул тарихи булганынмы, җырлы кәмитме, тарихлы-трагедиялесенме, траги-кәмитле-тарихи-музыкаль пьесалар кирәкме, бер ярлыкка да сыймаган сәхнәләрме, берни белән дә чикләнмәгән поэмалар дисеңме — бөтенесенә дә. Боларга Сенекаң[3] берни дә түгел, Плавттың[4] чүп тә түгел. Язылган рольләрне дә, язылмаганнарын уйнауда да боларның тиңе юк.

Гамлет. Әй Зөлкәфил галәйһиссәлам, бәни Исраил каүменең судиясе[5], нинди казнаң бар иде бит, ә?

Полони

Зөлкәфилнең казнасы булганмыни? Нинди?

Гамлет

Ниндиме?

«Аның булган гүзәл бер кыз баласы,

Яраткандыр аны бик нык атасы».

Полони

*(читкә)*

Һаман минем кыз турында бит бу.

Гамлет

Дөрес әйтмиммени, карт Зөлкәфил?

Полони. Әгәр сез мине Зөлкәфил дисәгез, бик туры килә минем чамадан тыш яраткан кызым да бар, принц.

Гамлет

Юк, моннан бу нәтиҗә килеп чыкмый.

Полони

Ул чагында нәрсә килеп чыга, принц?

Гамлет

Нәрсәме?

«Аңа бу хәл Ходай биргән бәладер».

Аръягын үзең беләсең:

«Бу хәлгә һәрбер адәм мөбтәладер».

Бу мөнәҗәтнең беренче юллары сиңа калган юлларын үзе әйтеп бирер. Чөнки, әнә күрәсеңме, минем сүземне бүлдерүчеләр килә.

Дүрт-биш артист керәләр.

Хуш килдегез, сәнгать осталары! Барыгыз да рәхим итегез. Мин сезне исән-сау күрүемә бик шатмын. Төкле аягыгыз белән, дускайлар! Аhа, минем карт дускай? Мин сине соңгы күргәнемнән бирле битеңне ничек йон баскан; әллә син Даниягә минем морҗаны томалар өчен бу сакалың белән килдеңме? Һу, минем яшь героиням, ханым әфәнде[1] ! Мәрьям ана белән ант итеп әйтәм, сез, ханым, мин сезне соңгы мәртәбә күргәнемнән бирле, күккә бер башмак үкчәсе биеклеге якыная төшкәнсез. Алладан сорыйм, тавышыгыз тишек алтын тәңкә кебек тыкырдый күрмәсен. Әфәнделәр, барыгыз да рәхим итегез. Француз карчыгачылары кебек, әйберне күрү белән эләктереп, чөеп алыйк: ягез әле, нинди дә булса берәр монологтан. Әйдә, үз һөнәреңдә зәукың бар икәнен бер күрсәтеп җибәр әле. Йә әле, бер ялкынлы монологыңны!

Беренче артист

Кайсы монологны, хөрмәтле принц?

Гамлет. Син бервакыт миңа бер монолог сөйләгән идең; ләкин ул сәхнәләрдә сөйләнгән нәрсә түгел; яки сөйләнгән булса да, бердән артык булмас. Чөнки хәтеремдә, пьесасы күпләргә ошамаган иде; күпләр өчен ул дуңгызга сәйлән тагу белән бер иде, ләкин ул минем төшенүемчә, шулай ук мондый нәрсәләрдә миннән дә яхшырак төшенүчеләр фикеренчә, менә дигән пьеса иде, сәхнәләре яхшы бүлен-

гән, үзе гади, үзе сәнгатьчә оста язылган пьеса иде. Әле дә хәтеремдә, кемдер әйтте: мәгънәсен тәмләндерим дип, шигырен тозламаган бу; теленә килгәндә, язучысын төче теллелектә гаепләрлек бернәрсә дә юк, диде. Моны ул яхшы алым дип, ару, ягымлы метод дип, коры бизәге генә түгел, үзе матур дип тапты. Мин аның бигрәк тә бер монологын яраттым; ул Энейның Дидонга сөйләгән хикәясе[1] иде. Бигрәк тә аның — Приамның үтерелүе турында сөйләгән урыны. Әгәр дә ул синең исеңдә калган булса, шул юлдан башлап җибәр. Хәзер, хәзер.

«Гыйркан җанварыдай ярсыган Пир»[2].
Юк, ул алай түгел, Пир белән башлана:
«Ярсыган Пир, ялган атның корсагында
Үзен яшереп килгән төнне, кораллары
Аның явыз уеннан да һәм шул төннең
Үзеннән дә кара иде. Ул аларның
Куркынычлы кара төсен тагын да бер
Дәһшәтлерәк яңа төскә алыштырды:
Баштанаяк ата-ана, угыллар һәм
Кызларның каннарына манчылды да
Җирәнгеч тоташ кызыл төскә керде.
Ул каннар шәһәр халкы ничек һәлак
Ителгәнне куркынычлы яктыртучы
Урам янгыннары белән куырылып
Кибеп көйде. Шул кызу ут, шул ачудан
Кайнап көеп, камыр кебек канга катып,
Җәһәннәмдәй ике күмер күзе белән
Карт Приамны эзли иде ярсыган Пир.
Шуннан дәвам иттер.
Полони. Валлаһи, принц, шәп чыкты. Шундый юралышлы итеп, көчле хис белән укыдыгыз.

Беренче артист

Менә шунда грекларга каршы торып
Маташкан Приамны ул килеп тапты.
Приамның иске кылычы үз кулына
Карышып, төшкән килеш күтәрелми
Тора иде. Шундый тиңсез сугыш өчен
Карт Приамга ташланды Пир. Бар көченә
Бер кизәнде һәм кылычның шул сызгырган
Җиленә үк хәлсез патша авып китте.
Дөрләп янып торган аның сарае да,
Карт Приамның егылуын сизгән кебек,
Шул уңайга ишелеп төшеп гөрселдәве
Пирны, бердән, чиркәндереп җибәрде дә
Зур гәүдәле карт Приамның дерелдәгән
Башына төшәм дигән чакта гына,
Кылычы аның буш һавада туңган кебек
Туктап калды. Рәсемнәрдә язылган бер
Үтерүче шикелле, Пир, гамәл белән
Ихтыяры арасында икеләнеп,
Нишләргә дә белми калды. Ләкин безнең
Һәммәбез дә бик еш кына күргән бер хәл:
Давыл булыр алдыннан, бар күкләр тынып,
Болытлар да кузгалмыйча, җил басылып,
Астагы җир үлем кебек тынып калгач,
Кинәт шунда каяндыр бер яшен атып,
Һаваларны ярып, күкрәп җибәргәндәй,
Бер мизгел, тик бер мизгел, шулай тынып
Калган Пир да күзен ачып исенә килгәч,
Үзенә каныгудан, канлы кылычы
Карт Приамга шундый китереп бер сукты кем,
Хәтта Циклоп[1] чүкече дә Марс өчен
Мәңге сынмас тимер кием чүкегәндә
Шундый авыр төшмәгәндер.

Оял, оял, бәхет дигән син фахишә!
Әй аллалар, бүген сенатыгыз белән
Ул бәхетне үз тәхтеннән куыгыз да
Тәгәрмәче, тугымнарын ватып ташлап,
Көпчәгенең тешен кырып, күгегездән
Җәһәннәмгә, җен төбенә ыргытыгыз!

Полони

Бу артык озын.

Гамлет. Ансын синең сакалың белән бергә парикмахерда кыскартырлар. Дәвам ит, зинһар; аңа бию такмагы белән бозык анекдотлар гына кирәк. Башкасы бар да аны йоклата; дәвам ит, Гекубага җит.

Беренче артист

Тик кем, кемнәр күрсен патша хатынын, аһ,
Ялангач кыяфәттә... ярым шәрә.

Гамлет

Ялангач патшабикә?

Полони

Монысы шәп; «ярым шәрә патшабикә» — әйбәт.

Беренче артист

Яше белән янгыннарны күмәр кебек,
Яланаяк анда-монда ул ташлана.
Элек алтын таҗлар белән бизәкләнгән
Маңгаена чүпрәк сарган. Мантиясе
Урынына, куркуыннан кулга эләккән
Җәймә белән ул үзенең арык, ябык
Һәм күп бала тудырудан төшкән билен
Аннан-моннан кораштырган. Бу хәлендә
Аны хәзер кем күрсә дә, бәхет нинди
Хыянәтче икәнлеген ачы зәһәр
Теле белән бар дөньяга кычкырачак.
Әгәр шушы патша хатын күз алдында
Ире мәетен мәсхәрәләп, кылычы белән
Пирның ничек тураклавын аллалар да
Күктән карап күрсә һәм бу хатынның да
Ничек ачы аһ оруын ишетсәләр,
Бу дөньяның хәлләреннән һичбер нәрсә
Тәңреләрне борчымавы хак булса да,
Күкләрнең дә утлы күзе юешләнер,
Аллалар да бер ярсуга төшәр иде.

Полони. Карагыз, ничек төсләре үзгәрде. Күзләрендә яшьләр. Үтенәм, артык кирәкми.

Гамлет. Әйбәт; син миңа тиздән калганын сөйләп бирерсең. Мәрхәмәтле лорд җәнапләре, сез артистларны яхшы гына урнаштыру ягын карагыз. Ишетәмсез, аларны яхшы карасыннар; алар бит бүгенге көннең чагылышы һәм заманыбызның тарихи рупоры. Алардан исән чагыңда яман тәнкыйть ишетүгә караганда, сезгә үлгәч кабер ташыгызга «әшәке» дип язып куюлары яхшырак.

Полони. Принц, мин аларны исемнәренә карап урнаштырырмын.

Гамлет. Шайтан алгыры адәм, яхшырак итеп урнаштыр! Әгәр һәркем белән исеменә күрә генә эш итсә, кем генә камчыдан котылыр иде икән? Алар белән сез үз исемегезгә һәм намусыгызга торырлык итеп эш итегез. Алар ничаклы исемсезрәк булсалар, сезнең яхшылыгыгыз шулхәтле исемле булыр. Алып барыгыз аларны.

Полони

Әйдәгез, әфәнделәр.

Гамлет. Аның артыннан барыгыз, дусларым; иртәгә без уен күрсәтербез.

Беренче артисттан башка артистлар Полони белән китәләр.

Карале, иске дус, сез «Гонзагоның үтерелү»ен уйный алмыйсызмы?

Беренче артист

Уйнап була, принц.

Гамлет. Без аны иртәгә кичкә карар идек. Әгәр дә кирәк булып, аңа бер унике яки уналты юллык монолог язып кертсәм, сез өйрәнә алырсыз бит?

Беренче артист

Була, принц.

Гамлет. Бик шәп. Шул лордның артыннан бар. Ләкин кара, аны үчекләмә.

Беренче артист китә.

Ягез, кадерле дусларым, миңа сездән кичкә кадәр аерылып торырга туры килә. Эльсинорга хуш килдегез.

Розенкранц

Яхшы, принц җәнапләре.

Гамлет

Тапшырдык, хуш.

Розенкранц белән Гилденстерн китәләр.

Ахырында мин дә ялгыз.
Ах, нинди бер юк кеше мин, кол кеше мин.
Оят түгелме соң миңа? Шул артист та
Шагыйрь язган бер хис, ялган бер дәрт белән
Хыялына җанын шундый буйсындыра,
Йөзе шуннан агарына, күзендә яшь,
Чыраенда зур шашкынлык, тавышы тетри,
Һәр гамәле хыялына җавап бирә.
Нәрсә өчен шулар бар да? Шул Гекуба
Өченме, йә?
Бик ул хәтле яшь түгәргә аңа нәрсә
Гекуба да, ул кем әле Гекубага?
Әгәр аңа тилмерергә минекедәй
Сәбәп булса, ул нишләмәс иде икән?
Яше белән бар сәхнәне күмәр иде,
Күкрәп чыккан монологы бөтен залның
Колакларын ярыр иде, гаеплене
Акылыннан шашырса ул, гаепсезне
Сискәндерер, наданнарны ярсытыр һәм
Публиканың күзен-башын айкар иде.
Ә мин,
Өшән, мәҗнүн, булыр-булмас кысыр дөлдел,
Эшлексез бер җебегән авыз, — бар сәбәпне
Юкка сылтап, хәтта сүз дә әйтми торам.
Ул гынамы? Тәхте белән мәмләкәте
Һәм кадерле гомере шундый явызларча
Таланган шул Король хакын аклап-яклап,
Бер сүз дәшми торам. Мин кем, куркак мәллә?
Йә, миңа кем: «Син битсез», — дип әйтә алыр?
Башымны бәреп ватар, сакалымны
Йолкып атар үз йөземә? Борыным өзәр?
«Ялганчы» дигән пычак кебек үткен
Сүзе белән кадар минем бугазыма?
Миңа каршы кем соң моны эшли алыр?
Һа!
Мөгаен, мин аны да күтәрәчәк!
Шулай булмый, мин күгәрчен йөрәк ич бер;
Бу хурлыктан ачынырга үт юк миндә.

Югыйсә бит мин бу этнең үләксәсен
Тилгәннәргә күптән биргән булыр идем.
Аһ, уйнашчы, сатлык, явыз, яман ерткыч.
Аһ, үч! Кару!
Мин дә яхшы ишәк! Йә, күр, мин мин булып,
Үтерелгән үз атамның углы булып,
Оҗмах белән тәмуг мине үч алырга
Чакыра торып, батыр булыр урында мин,
Фахишә күк, буш сүз белән күңел басып,
Табак-савыт юучыдай сүгенәм монда.
Тфү, ваклык! Кузгал, мием! Эшкә ябыш!
Һмм... Ишеткәнем бар югыйсә, җинаятьче
Кешеләр театрны караганда,
Оста уен тәэсиреннән шундый тирән
Сискәнгән вакытлары була, хәтта
Җинаятен үзе әйтеп ташлый, имеш[1] .
Үтерүче дәшмәсә дә, йөз ымнары
Тоттырачак. Кушыйм да мин артистларга,
Әйдә алар агам Король күз алдында
Атамның үтерелүе шикелле бер
Нәрсә уйнап ташласыннар. Мин Корольнең
Күзләреннән күз дә алмам, шундый җитез
Күзәтермен, чак кына тик бер селкенсен,
Нишләремне мин белермен. Мин күргән рух
Бәлки әле шайтан гына булуы бар,
Шайтан изге сыйфатта да күренә ала.
Аннан тагын, бик ихтимал, минем шундый
Җегәрсез, боек икәнемне күргәч,
Мондый җанга хөкем йөртү җиңел дип, ул
Мине юри һәлакәткә сөйрәве дә.
Миңа хәзер тагын ныграк дәлил кирәк.
Уйнатыйм мин бер драма, шул ау белән
Корольнең вөҗданын да тотармын һәм.

Китә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сарайда бер бүлмә.
Король, Королева, Полони, Офелия, Розенкранц һәм Гилденстерн керәләр.

Король

Берничек тә белә алмыйсызмыни соң сез,
Ни өчен тилелеккә салына ул?
Нилектән аның җаны шундый дорфа,
Фетнәчел һәм хәтәр төстә шашынган соң?

Розенкранц

Шашкынлыгын ул үзе дә әйтә, ләкин
Нилектән — сәбәпләрен һичбер ачмый.

Гилденстерн

Без чынлап та аңа нәрсә булганлыгын
Үзеннән әйттерергә теләдекме —
Юләрлеккә салына да кулдан тая.

Королева

Ул сезне яхшы кабул иттеме соң?

Розенкранц

Зур илтифат белән.

Гилденстерн

Әмма ләкин үзен
Көч белән үз кулында тотып кына.

Розенкранц

Сорауларны саран бирде, әмма безнең
Сорауларга җавапны бик юмарт бирде.

Королева

Аның күңлен табу өчен ул-бу чара
Күрмәдегез?

Розенкранц

Ханым, шулай туры килде:
Без юлда артистларны куып җиттек;
Без аңа шуны әйткәч, ул моңа бик
Куанган төсле булды. Алар монда;
Ялгышмасам, бүген кич үк алар аның
Алдында уйнарга да тиеш бугай.

Полони

Бу дөрес. Минем аша ул сезнең дә
Затыгызны уен карарга чакыра.

Король

Чын күңелемнән риза. Миңа аның шундый
Шат булуын ишетү үзе бик куаныч.
Джентльменнар, моннан соң да аның зәүкын
Сез шул якка юнәлтегез.

Розенкранц

Яхшы, милорд.

Розенкранц һәм Гилденстерн китәләр.

Король

Кадерле Гертрудам, син дә безне
Калдырып тор. Гамлет белән Офелия
Шушы залда туры килеп очрашсыннар
Өчен, без аны бире чакырттырдык.
Кыз атасы белән икәү без шушында,
Үзебез күренмичә күреп торып,
Аларның чын хәлләрен беләчәкбез.
Гамлетның үзен тотышына карап,
Мәхәббәтме аны шулай йә башкамы
Газаплавын белеп булыр.

Королева

Мин буйсынам.
Инде сиңа теләгем шул, Офелия,
Гамлетның шашуына синең назлы
Гүзәллегең генә сәбәп булсын иде.
Синең яхшы сыйфатларың аны тагы
Элекке эзгә салсын, һәр икегез
Өчен дә абруй булсын диеп торам.

Офелия

Амин, бикәм.

Королева китә.

Полони

Офелия, син шунда йөр.
Падишаһ, сез әйткәнчә, яшеренәбез.
*(Офелиягә.)*
Үзеңнең ялгызлыгың аклау өчен
Шул китапны укыган бул. Безнең гөнаһ
Күбрәк шунда, һәм һәркем дә аны белә, —
Изгелеккә салынып[1], без кайчагында
Шайтанны да шикәр сибеп йоттырабыз.

Король

Һай, бик дөрес бу сүз! *(Читкә.)* Аның сүзе ничек
Вөҗданымны әрнеттереп әче чага.
Купшы сүзләр белән өрткән зур гөнаһым
Уйнашчы хатыннарның буяу белән
Матурлаган йөзеннән дә ямьсезрәк.

Полони

Ишетәм, килә; яшереник, чыгыйк, милорд.

Король белән Полони китәләр. Гамлет керә.

Гамлет

Яшәргәме, үләргәме, — менә нидә
Мәсьәлә. Йә, кайсысы яхшырак соң:
Явыз язмыш укларына баш июме,
Әллә, кулга корал тотып, бу җәфалар
Диңгезенә көрәш ачып, чик куюмы?
Үлү — йоклау. Артык һични. Барлык йөрәк
Газапларың, тәнең дучар булган мең-мең
Җәфаларың шул бер йокың белән бетте
Диеп уйлау — көтеп алган чик түгелме?
Үлү — йоклау; йоклау, бәлки, төш күрүдер!
Шик тә шунда. Чери торган бу гәүдәдән
Аерылганда, үлем исреклеге белән,
Без нинди төш күрәчәкбез, — менә нәрсә
Безнең кулны тотып тора; менә нәрсә
Һаман бездән гомер йөген сөйрәттерә.
Шул булмаса, кем соң түзеп торыр иде
Замананың мыскылына, камчысына;
Башлыкларның изүенә; өстеннәрнең
Үз өстеңнән көлүенә, мәхәббәтең
Кире кагылу газабына; властьларның
Ятсызлыгы, гаделлекнең соңлавына;
Эш күрсәткән кешеләрнең җыен рәтсез
Кешеләрнең типкесендә йөрүенә;
Шул тормыштан үз-үзеңне пычак белән
Бер кадауда котылып булгач, нәрсә тота?
Әлегәчә анда киткән бер юлчы да
Әйләнеп кайтмый торган ул билгесез
Дөньяның нәрсәседер куркытмаса,
Ул билгесез җиргә качып котылудан
Бер күнеккән михнәтләргә түзгән яхшы
Дигән курку ихтыярны какшатмаса,
Маңгай тирен түгеп, кем соң, аһ-ваһ килеп,
Шушы хәтле тормыш йөген сөйрәр иде?
Менә вөҗдан ничек безнең барыбызны да

Куркак ясый. Менә ничек нык карарлы
Булуның да алсу гөле күп уйлаудан
Уңып шиңә. Һәм башлаган зур эшләр дә
Шул уйлардан эш димәслек хәлгә килә. —
Акрын, тукта! Назлы Офелиям?
Догаларың укыганда, мин гөнаһлы
Бәндәңне дә телеңә ал.

Офелия

Асыл принц.
Затыгызның бу көннәрдә кәефе ничек?

Гамлет

Сезгә иелеп рәхмәт укыйм: шәп, шәп, бик шәп.

Офелия

Принц, миндә сездән алган бүләкләр бар,
Күптән-күптән кире бирим диеп йөрим,
Үтенәм сездән хәзер, кире алыгызчы.

Гамлет

Минме? Мин һич сезгә бүләк биргәнем юк.

Офелия

Асыл затым, яхшы беләм, сез бирдегез,
Сез шундый татлы сүзләр белән бергә
Бирдегез ки, бу нәрсәләр минем өчен
Икеләтә кыйммәтрәк. Аларның хуш
Исләре бетте, кире алыгызчы.
Бүләкне бирүченең күңеле бизгәч,
Бүләгенең безнең өчен кыйммәте юк.
Менә алар, принц.

Гамлет

Һа, һа! Сез саф кызмы?

Офелия

Ай, принц!

Гамлет

Син матурмы?

Офелия

Җәнабегез ни әйтмәкче була?

Гамлет. Шуны: әгәр син саф та, матур да булсаң, синең кызлык сафлыгыңның матурлыгың белән эше булмаска кирәк иде.

Офелия. Матурлык соң үзе кызлык сафлыгыннан башка тагын нәрсә белән татурак була алсын, принц?

Гамлет. Әйе, бу дөрес; чөнки кызлык сафлыгының көче матурлыкны да үзе шикелле саф иткәнче, матурлыкның көче кызлык сафлыгын да бозып өлгерер. Элегрәк бу парадокс иде, ләкин безнең заман моны исбат итте. Мин сезне бер сөйгән идем.

Офелия. Шулай шул, принц, сез миңа шулай дип ышанырга сылтау биргән идегез.

Гамлет. Син миңа ышанырга тиеш түгел идең. Безнең ише карт агачка яхшылыкның бөресен син күпме генә ялгама, барыбер бездә элекке тәме бетми аның. Мин сине сөймәдем.

Офелия. Шуның саен мин ныграк алданганмын.

Гамлет. Монастырьга кит; нәрсәгә сиңа бу гөнаһлы адәм балаларын үрчетергә? Мин үземне намуслы кешегә саныйм санавын да, алай да әле анам мине тапмаган гына булса, яхшырак булыр иде дип, кайбер нәрсәләр өчен үземне үзем битәрли алам. Мин бик тәкәббер, үч алучан, шөһрәт сөючән; шулчаклы гөнаһ эшләргә бара алам, уйлап бетерергә уй да җитмәс, тасвир итәргә хыял да ирешмәс, эшләп бетерергә гомер дә җитмәс. Йә, нәрсәгә соң минем кебек егетләргә күк белән җир арасында сөй-

рәлергә? Без барыбыз да киселеп чыккан мутлар; безнең беребезгә дә ышанма син. Монастырьга кит. Синең әтиең кайда?

Офелия. Өйдә, принц.

Гамлет. Артыннан ишеген дә бикләп куйсыннар. Юләр сатса, үз өеннән башка җирдә сатмасын. Сау бул!

Офелия
*(читкә)*

Аһ, мәрхәмәт ит син аңа, җиде кат күк!

Гамлет. Әгәр дә син кияүгә чыксаң, мин сиңа менә нинди нәләтләремне бирнә итеп бирәм: син теләсәң, боздан да сафрак, кардан да аграк бул, барыбер син гайбәттән котылмассың! Кит син монастырьга, кит, сау бул. Яки сиңа кияүгә чыгу бик кирәк икән инде — юләргә чык. Чөнки акыллы кешеләр бит сез аларны нинди гыйфриткә әйләндерүегезне бик яхшы беләләр. Монастырьга кит; тизрәк кит. Сау бул.

Офелия
*(читкә)*

Әй, күк көчләре, терелтегез аны.

Гамлет. Сезнең художниклык турында да мин җитәрлек ишеттем; Алла сезгә бер йөз биргән, сез үзегезгә икенче йөз ясыйсыз; сез сикеренгәләп йөрисез, кыланасыз, пышылдыйсыз; Алланың мәхлукларыннан көләсез; сез үзегезнең азуыгызны балалыкка салынып каплыйсыз. Йә, бар, миңа шул җиткән; мине шулар юләр ясаган. Әйтәм бит, кирәкми безгә моннан соң өйләнүләр; моңа хәтле өйләнешкәннәре, берсеннән башкасы, барысы да тора бирсеннәр; калганнары булганнарынча калсыннар. Монастырьга кит.

Китә.

Офелия

Аһ, нинди затлы акыл һәлак булды!
Түрәлекнең, хакимлекнең һәм гаскәрнең
Күзе, теле, кылычы һәлак; чәчәк аткан
Илнең өмет һәм чәчәге; зәвык белү
Мисалы, манер белү өлгесе һәм
Бөтен үрнәк алучыга көзге кеше
Тәмам-тәмам һәлак булды. Мин бичара,
Иң бәхетсез, кызганыч кыз, аның бал күк
Татлы сүзен, аның антын ишеткән мин,
Күреп торам хәзер ничек шундый төпле
Бер акылның, патшаларча зур акылның
Чатнаган кыңгырау күк зыңгыравын,
Күреп торам шундый япь-яшь гөлдәй йөзе
Шашкынлыктан каралганын, бозылганын.
Ни үкенеч, аны элек күргән булу
Өстенә шушы хәлен күреп тору.

Король белән Полони кире кайталар.

Король

Мәхәббәтме? Юк, шашуы аннан түгел;
Сөйләгән сүзләрендә бик бәйләнеш
Булмаса да, тилелек күк әйбер дә юк.
Җанында нәрсәдер бар, шуннан аны
Бу меланхолия баса; мин шул нәрсә
Куркыныч тудырмагай иде, димен.
Аннан котылу өчен мин дә менә мондый
Тиз генә бер кискен чара кабул итәм:
Әйдә, безнең салымнарны юллау өчен,
Бик тиз генә китсенче ул Англиягә;
Киң диңгезләр, яңа илләр, бәлки, аның
Җанында кайнап яткан нәрсәләрне,

Аның шундый башын ваткан, үзлегеннән
Чыгарган нәрсәләрне таркатыр да
Көйгә килер. Ни уйлыйсың син бу хакта?

Полони

Яхшы булыр. Алай да мин әле һаман
Кайгысының төп сәбәбе тибәрелгән
Мәхәббәттә дип ышанам. Йә, ничек соң,
Офелия? Принц Гамлет ни әйткәнне
Син безгә әйтеп тормасаң да ярый.
Без барын да ишетеп тордык. *(Корольгә.)* Яхшы, милорд,
Әйткәнегезчә эшләгез. Ләкин әгәр
Мәслихәт булса, кичке уеннан соң
Анасы Королева аулак җиргә
Аны алып чын кайгысын сорашсынчы.
Турыдан-туры сөйләшсен, нык, коры тотсын;
Миңа да, әле рөхсәт булган кебек,
Аларны качып тыңлау рөхсәт булсын.
Шул да телен ачтыралмый икән, әнә
Җибәрегез Англиягә, яки аны
Яптырып куегыз сез, хәер, тагын
Хикмәт сезгә кайсын кушар.

Король

Әйе, дөрес;
Зурлар шашына икән, кирәк күзәтергә.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сарайда бер зал.
Гамлет белән ике-өч артист керәләр.

Гамлет. Монологны, зинһар өчен, мин сиңа күрсәткәнчә, телеңне бутамыйча гына сөйлә. Әгәр син аны, артистларыгызның күбесе кебек, корыга бакырып кына чыгасың икән — шигырьләремне урамда кычкырган кырыктартмачы сөйләве яхшырак. Кулларыңны һавада бик бутама; барын да җай гына, тигез генә эшлә. Хисләрнең агымында, хәтта, әйтер идем, давылында да, син аны нәфисләндерерлек бер чаманы табарга, шуны тотып барырга тиешсең. Мин кайчагында шуны күрәм; башына ялбыр парик кигән, дөя хәтле бер олан чыга да үзенең хисләрен йон урынына йолкырга тотына, күрәм, шулай җенләнеп ул күбесенчә шул аңлаешсыз пантомималар белән шул бакырынудан башка берни дә аңламаган галерканың колагын тондыра, шуны ишеткәндә, минем саруларым кайный. Термагантның[1] үзеннән уздырырга көчәнүче мондый егетне мин рәхәтләнеп тунар идем. Бу Һерод[2] патшаның үзеннән дә гарибрәк. Үтенәм синнән, моны куй.

Беренче артист

Җәнабегез тыныч булсын.

Гамлет. Сүз җебен бик бушатып та җибәрмә, күңел күзең сиңа гел юл күрсәтеп барсын; гамәлне — сүз белән, сүзне гамәл белән яраштыр; бигрәк тә шунысын кара: табигый гадилектән чыгып китә күрмә. Чөнки һәрбер арттырып җибәрү уенның уенлыгына каршы килә; уенның максаты бит, электә булган кебек, хәзердә дә табигать каршында көзге тотып тору шикелле бер эш булды һәм булып тора. Яхшылыкны үзенең төп сызыкларында алып күрсәт, яманлыкны да үз кыяфәтендә; һәрбер чорның, һәр заманның гәүдәләнешен үз формасы, үз тамгасы белән. Инде болай чамасыннан арттырып җибәрүләр яки чамасына җиткерә алмаулар надан кешеләрне көлдерсә дә, сәнгатьне танып белүчеләрне әрнетмичә мөмкин түгел. Ә мондый кешеләрнең берсенең генә сүзе дә тегеләрнең бөтен театрыннан өстен торырга тиеш икәнен үзең дә беләсең. О, бар артистлар, мин аларның уйнаганнарын күрдем, ничек макталуларын да ишеттем, хәтта бик нык та макталалар, ләкин, сүзем көфер китмәсен, ни аларның сөйләүләре христианнар теленчә түгел, ни йөрешләре христианча да, мәҗүсләрчә дә, гомумән бер кешеләрчә дә түгел, шулхәтле ватылалар, шулхәтле улап сөйлиләр, алар адәм баласына шулхәтле ямьсез итеп ия-

реп кылангач, мин, болар әллә табигатьнең берәр кендекчеләре тарафыннан гына ясалды микән, бигрәк начар ясалганнар бит, дип уйларга мәҗбүр булдым.

Беренче артист. Без бу нәрсәләрдән шактый арынганбыз дип өмет итәм, принц.

Гамлет. Аһ, сез моннан бөтенләйгә арыныгыз. Аннан, анда мәзәкче ролен уйнаучыларыгызга әйтегез — роленнән артыгын әйтмәсеннәр; чөнки алар арасында шундыйлар да бар: нәкъ пьесаның төп урынына игътибарны юнәлтергә кирәк вакытта гына, берничә бушбаш тамашачыны көлдерәбез дигән булып, үзләре көләргә тотыналар. Әшәкелек бу. Бу бары тик болай кыланган мәзәкченең мескеннәрчә шөһрәт сөюен генә күрсәтә. Барыгыз, әзерләнегез.

Артистлар китәләр.
Полони, Розенкранц һәм Гилденстерн керәләр.

Йә, ничек, әфәндем хәзрәтләре, Король үзе бу тамашаны карарга булдымы, юкмы?

Полони

Королева да. Хәзер үк, диләр алар.

Гамлет

Әйтегез, артистлар тизрәк булсыннар.

Полони китә.

Сез дә икәүләп аларны тизләтергә булышмыйсызмы?

Розенкранц белән Гилденстерн

Без ике куллап әзер, принц.

Розенкранц белән Гилденстерн китәләр.

Гамлет

Һәй, һәй! Горатсио!

Горатсио керә.

Горатсио

Монда, принц. Сезнең хезмәтегездә мин.

Гамлет

Очраткан кешеләрем арасында
Син аларның иң турысы, Горатсио.

Горатсио

О, нәрсә сез, принц...

Гамлет

Мине алдаша дип
Уйлый күрмә. Синнән миңа ни табыш бар?
Карныңны тук, өстеңне дә бөтен иткән
Киң күңелеңнән башка синдә ни байлык бар?
Ярлыны нәрсәгә дип юмаларга?
Әйдә әнә төче телләр коры көяз
Алларында ялмансыннар, каеш тезләр
Табышлырак майлы җирдә сыгылсыннар.
Ишетәмсең? Күңлем кеше аера белеп
Сайлый белә башлаганнан бирле җаным
Сиңа ятты. Син бит шундый: үз башыңнан
Барсын кичереп, үзең берни күрмәгәндәй,
Язмышның ачысын да, төчесен дә
Бердәй күреп, рәхмәт укып каршылаучан.
Берәүнең акылы белән каны шулай
Тату икән — менә инде ул бәхетле.
Язмыш аны сыбызгыдай үз көенә
Сызгырталмас. Тап син миңа бер дәрткә дә
Уралмаган бер кешене, мин дә аны
Сине кочкан кебек йөрәгемә, юк-юк,

Йөрәгемнең йөрәгенә кочар идем.
Монсы җитәр. Хәзер Король каршысында
Уен биреләчәк. Анда, минем сиңа
Әйткәнемчә, әтиемнең үтерелүен
Сурәтләгән бер сәхнә бар. Үтенәм синнән,
Шул барганда, бар көчеңнән минем агам
Артыннан күзәт әле. Әгәр дә ул,
Кайбер сүзне ишеткәндә, яшерен гаебен
Сиздермәсә, димәк ки, без синең белән
Җәһәннәм кунагын тик күргән булып
Чыгабыз, һәм минем шикле хыялларым
Янартау тишеге кук кара була.
Бик нык күзәт. Минем күзләр бөтенләйгә
Гел төбәлгән булыр аның йөзләренә;
Соңыннан без, үзебезнең күргәннәрне
Чагыштырып, килербез бер нәтиҗәгә.

Горатсио

Яхшы, принц. Уен барган чагында ул
Чыраенда бездән әгәр берәр нәрсә
Яшереп калса, анысы өчен мин түләрмен.

Гамлет

Алар килә. Мин дә юләр булам хәзер.
Үзеңә урын ал син.

Дания маршы. Быргычылар, Король, Королева, Полони, Офелия, Розенкранц, Гилденстерн, сарай хадимнәре, факеллар күтәргән
сакчылар белән бергә керәләр.

Король

Энекәшебез Гамлетның кәефе ничек?

Гамлет. Бик шәп, кояштыр әгәр, яшәмим, торам; хамелеон[1] кебек, һава ашап симерәм, җил ашап күбенәм. Печкән әтәчне дә шулай симертә алмассыз.

Король. Бу җавабың миңа кагылмый, Гамлет; бу сүзләр минеке түгел.

Гамлет. Әйе, инде минеке дә түгел. *(Полонига.)* Милорд, сез, университет сәхнәсендә[2] бер уйнаган идем, дисез?

Полони. Уйнадым, принцкаем, мин яхшы артистка санала идем.

Гамлет. Кем булып уйнадыгыз?

Полони. Мин Юлий Цезарь[3] булып уйнадым; мине Капитольдә[4] чәнчеп үтерделәр, — Брут үтерде мине.

Гамлет. О, шушы хәтле капитал бозауны борып үтерде, диегез! Артистлар әзерме?

Розенкранц

Әйе, принц, алар сезнең боерыкны гына көтәләр.

Королева

Бире килче, газизем Гамлет, утырчы яныма.

Гамлет

Юк, кадерле анам, монда көчлерәк магнит тарта.

Полони
*(Корольгә акрын)*

А-һа! Сизәсезме?

Гамлет

Туташ, тезегезгә ятып торсам, булырмы?

Офелиянең аяк очына ята.

Офелия
Юк, принцкаем.

Гамлет

Мин башымны тезегезгә куйсам диюем.

Офелия

Ярый, принц.

Гамлет

Мин сезгә әдәпсез сүз әйттем дип уйлыйсызмы?

Офелия

Мин берни дә уйламыйм, принцкаем.

Гамлет

Кызлар тезе арасында ятуны уйлау күңелле уй ич.

Офелия

Сез ни сөйлисез, принц?

Гамлет

Һични.

Офелия

Сез шат, принцкаем.

Гамлет

Кем, минме?

Офелия

Әйе, принцкаем.

Гамлет. Ай Алла, мин сезнең күңелегезне ачучы гына. Шат та булмагач, кешегә нишләргә генә соң? Кара син минем әнине, нинди шат карый ул; ике сәгать элек кенә этием үлеп тә.

Офелия. Юк, принц, аңа инде ике тапкыр ике ай булып үтте.

Гамлет. Шулчаклы үткән?! Алайса, шайтан кара киенеп йөресен, мин кеш туннар кия башлыйм. Әй, күкләр! Ике ай элек үлеп тә әле булса онытылмый торсын! Болай булса, бөек кешеләрнең истәлекләре үзләреннән ярты елга соңгарак калып яшәр дигән өмет бар. Ләкин, Мәрьям ана белән ант итеп әйтәм, моның өчен ул чиркәү салдырырга тиешле; шулай итмәсә, теге бер агач ат кебек, онытылып куюы бар, аның да кабер ташына «Ни үкенеч, ни үкенеч! Агач ат онытылды»1 дип язылган бит.

Быргычылар уйный. Пантомима башлана. Бер-берсенә гашыйк булган Король белән Королева керә; Королева — аны, ул да Королеваны кочаклый. Королева тезләнеп аңа ишарәләр белән үзенең гыйшкын белдерә; Король аны торгызып, аның муенына башын ия; аннан чәчәкләр белән бизәлгән урынга ята; Королева аның йоклавын күргәч тә, ялгызын калдырып китә; шуннан бер егет керә. Корольнең таҗын салдырып ала, таҗны үбә. Корольнең колагына агу сала да чыгып китә. Королева кире кайта. Корольне үлгән килеш тапкач, үрсәләнгән була; Агулаучы, бер сүз дә дәшми торган ике-өч кеше белән яңадан кереп, Королева белән кайгырышкан булып күренә. Мәетнең гәүдәсе чыгарыла. Агулаучы Королевага бүләкләр тәкъдим итә; Королева башта икеләнгән, яхшысынмаган кебек итенә, ләкин ахырында аның
мәхәббәтенә баш ия.
Китәләр.

Офелия

Нәрсә аңлата бу, принц?

Гамлет

Бу поскын малэчо1 — явыз эш дигәнне аңлата.

Офелия

Әллә бу тамаша драманың эчтәлеген күрсәттеме?

Пролог керә.

Гамлет. Без аны шушы егеттән белербез; артистлар сер саклый белмиләр: алар барысын да быкылдыйлар.

Офелия. Ул безгә әле уйналганны да әйтеп бирерме?

Гамлет. Әйе, һәм сез аңа нинди генә тамаша күрсәтмәгез, анысын да әйтер; сез күрсәтергә оялмасагыз, ул аның мәгънәсен әйтеп бирергә оялмый инде.

Офелия. Сез усал, сез усал; мин уенны карап барачакмын.

Пролог

Безгә һәм фаҗигабезгә
Илтифат итеп сез дә
Түзеп карагыз безгә.

Китә.

Гамлет. Нәрсә бу, прологмы әллә йөзек кашына язылган шигырьме[2] ?

Офелия

Бик кыска бу, принц.

Гамлет

Хатын-кыз мәхәббәте кебек.

Король булып уйнаучы

Мәхәббәт безнең йөрәктә
Кабынган көннән бирле,
Кулларга никах чылбыры
Тагылган көннән бирле,
Көн арбасы күк өстендә
Җирне-суны тирәләп,
Ел артыннан еллар сызды
Инде утыз түгәрәк.
Ел тәүлеге унике ай
Нур алмашып, ялтырап,
Җир тирәли йөреп үтте
Унике утыз кабат[1] .

Королева булып уйнаучы

Ай белән көн әйдә тагын
Туа бирсен шулхәтле,
Күңелебездә сүнмәс безнең
Анда да сөю дәрте.
Тик шунсы вай, ни гомер син
Хәлсез, авыру ятасың,
Төсең китте, мескенкәем,
Юанычтан качасың.
Синең өчен куркамын шул,
Мин генә куркыйм ләкин;
Падишаһым, моңа карап,
Һич кенә борчылма син.
Чөнки хатын-кыз сөюе
Куркуына тиң килә,
Йә бөтенләй сөйми сине,
Йә чамадан тыш сөя.
Сине ничек сөюемнең
Билгесе шушы инде;
Синең өчен күпме курыксам,
Шулкадәр сөям сине.
Кайда сөю көчле булса,
Анда курку көчлерәк,
Кайда курку-шигең артса,
Шулкадәр үк көчле дәрт.

Король булып уйнаучы

Сөеклем, ләкин шуны бел,
Калдырам сине тиздән,
Көч-дәрманым китә миннән;
Сүнәм, аерылам синнән.

Син яшәрсең наз эчендә
Якты дөньяда калып,
Хөрмәт күреп, ихтимал ки,
Башка бер иргә барып,
Рәхәт-рәхәт көн итәрсең...

Королева булып уйнаучы

Аh, җитәр, куй, җаным бул,
Андый сөю сөю түгел,
Йөрәккә хыянәт ул.
Икенчегә чыксам әгәр,
Нәләт яусын башыма.
Кем беренче ирен суя —
Шул икенчегә чыга.
Икенче кат иргә чыгу
Ул зур мәшәкать түгел,
Ул тик исәп-хисап кына,
Әмма мәхәббәт түгел.
Икенче ир минем белән
Үбешсә ятагымда,
Беренче ирем үләр ич
Икенче кат тагын да.

Гамлет
*(читкә)*

Әрем! Әрем!

Король булып уйнаучы

Әйткән сүзең йөрәгемә
Хактыр кебек тоела,
Безнең карарыбыз ләкин
Күбрәк карарсыз була.
Кешеләрнең нияте дә
Нәкъ хәтерләре кебек,
Башта көчле булып туа,
Тиз бетә ләкин җебеп.
Ботагында чакта җимеш
Саклана сусыл килеш,
Ләкин пешкәч, үз-үзеннән
Өзелеп төшәр, имеш.
Бурыч итеп өскә алган
Вәгъдәләрне һәммәбез
Җиңел генә онытабыз
Түгелме үтәргә без?
Кызу мәлдә вәгъдә бирү
Безгә җиңел булса да,
Кызу белән бергә сүнеп
Вәгъдә сүзе буш кала.
Шатлык белән кайгы бездә
Көчле булса никадәр,
Берсен-берсе тиз басарга
Тиеш алар шулкадәр.
Кайда бәлеш, кайда туй,
Анда сагыш, уй китә,
Шатлык елый, кайгы көлә,
Берсен берсе юк итә.
Дөнья фани үзгәрүчән,
Нәрсәсе гаҗәп аның?
Мәхәббәт тә үзгәрә ич,
Бәхет үзгәргән саен.
Кайсы кайсысына карый?
Шуны кем белгән икән:

Сөю бәхеттән киләме,
Бәхет сөюдән микән?
Түрә түрәлектән төшсә,
Качып бетә дуслары,
Ярлы дәрәҗәгә менсә,
Дус та була дошманы.
Шулай итеп сөю һаман
Бәхет артыннан чаба,
Дуска мохтаҗ түгел кеше
Үзенә дус күп таба.
Мохтаҗ кеше барса әгәр
Куштан дусты янына,
Дустын әйләндергән булыр
Үзенең дошманына.
Кайтып әйтсәм, бәхет белән
Иркебез арасында
Мәңге бетмәс дошманлыклар
Өзелми бара шунда.
Шуның белән алданабыз
Теләкләребездә гел,
Уй безнеке, нәтиҗәсе
Генә безнеке түгел.
Син дә чыкмамын дисең дә
Икенче иргә бер дә,
Беренче ирең үлүгә,
Уең да үләр бергә.

Королева булып уйнаучы

Җирдән азык күрмим әгәр,
Күктән күрмим нур йөзен,
Көндез шөгыль күрмим әгәр,
Төнлә күрмим ял йөзен,
Өметләрем бушка түнсен,
Калыйм шундый бәлагә,
Ашсыз-сусыз тоткын булып
Башым черсен төрмәдә,
Шатлык йөзен боза торган
Күпме бәла-каза бар
Төшсен миңа, барлык якты
Уйларымны кырсыннар,
Нәләт яусын бу башыма
Һәр ике дөньясында —
Бер тол калгач, яңадан да
Мин иргә чыксам шунда!
Гамлет. Әгәр дә бу хатын антын бозса, нәрсә булып чыгар?

Король булып уйнаучы

Коточкыч ант. Инде мине
Калдырчы син ялгызым.
Хәл-дәрманым китә бара,
Аруымнан көн озын
Йокы белән арынмаммы?

Йоклый.

Королева булып уйнаучы

Йокла, җаның кинәнсен.
Гомердә дә безнең башка
Бәла-каза килмәсен.

Китә.

Гамлет

Ханым, бу пьеса ошыймы сезгә?
Королева. Королева вәгъдәне күбрәк бирә шикелле, минемчә.

Гамлет

О, ул үз сүзендә торыр, мөгаен.

Король

Син эчтәлеген белмисеңме?
Монда берәр мәсхәрә юкмы?
Гамлет. Юк, юк; алар юри генә итенәләр бит; агулау да юри; бер мәсхәрә дә юк.

Король

Драмасы ничек атала?
Гамлет. «Тычкан тәбесе»[1]. Кызыкмы? Читләтеп әйтелгән мәгънәдә. Бу драма Венада булган бер үтерешнең тасвиры; Король Гонзаго исемле булган; хатыны — Бабтиста; хәзер күрерсез: бик зур мутлашу, алдашу бара монда. Хәер, барсын. Җәнабегез белән безнең вөҗданыбыз таза булгач, безгә ни? Корчаңгы алаша әйдә үзалдына тик ышкына бирсен, аннан безнең аркабыз ачытмас.

Луциан керә.

Монсы Луциан дигән кеше. Корольнең энесе.
Офелия. Сез трагедиядә суфлерлык вазифасын бик шәп үтисез икән, принц.
Гамлет. Әгәр дә мин сезнең ничек курчаклар биеткәнегезне күрә алсам, сезнең белән егетегез арасында да суфлер була алыр идем.
Офелия. Сез үткен телле, принц, үткен телле.
Гамлет. Минем үткенлек беткәнче, сезгә бераз ыңгырашырга туры килер.
Офелия. Ничаклы яхшы булса, шуның саен начар.
Гамлет. Сез дә үзегезгә шулай кияү табарга тиешсез. Йә, башла, үтерүче. Ташла шул әшәке шамакайлануыңны да башла. Йә: «Карылдаган козгын: үч ал, дип кычкыра»[1].

Луциан

Күңел куркак, кулым оста, агу — хак,
Вакыт җайлы, һичкем күрми, бик аулак.
Әй, агу, син төн гөленнән тамгансың,
Һекатадан[2] өч кат ләгънәт алгансың;
Хәзер бөтен бозгыч көчең көч булсын,
Сап-сау кеше шул минутта юк булсын!

Йоклаучының колагына агу сала.

Гамлет. Ул, аның патшалыгын эләктерү өчен, аны бакчада агулый; исеме Гонзаго аның; бу чын вакыйга, саф итальян телендә язылган; менә хәзер сез үтерүченең ничек Гонзаго хатыны алдында мәхәббәт казанырга тырышуын күрерсез.

Офелия
Король тора.

Гамлет

Нәрсә? Коры пистоннан курыктымы әллә?

Королева

Сиңа ни булды, Король?

Полони

Уенны туктатырга!

Король

Миңа бераз яктыртыгыз әле, киттек!

Барысы бергә

Утлар, утлар, утлар!

Гамлет белән Горатсиодан башкалар бары да китәләр.

Гамлет

Яраланган болан шыңшый бирсен[3],
Исән калган болан бер уйнар,
Берәү йоклаганда, берәү уяу,
Шулай зыр-зыр бара дөньялар.

Әгәр дә минем язмышым, төрек язмышы шикелле, үземә каршы әйләнә икән, мине башымдагы шушы каурый урманнары[4] белән, шушы ерык башмакларымдагы бер пар кызыл тасмаларым белән артистлар труппасына алырлар иде бит, әфәндем, ә?

Горатсио

Ярты паекка.

Гамлет

Юк, мин бөтенгә, дим.
Бик беләсең килсә, Дамон кода,
Гөрләп торган шушы тәхеттә
Элек Зевс хөкем сөргән иде,
Хәзер хөкем сөрә бер тавис.

Горатсио

Сез рифмага бетерә алган булыр идегез.

Гамлет. Әй җаным Горатсио, мин ул өрәкнең сүзләрен мең алтын биреп алыр идем. Йә, сизденме син?

Горатсио

Бик яхшы сиздем, принц.

Гамлет

Агулау турында сүз барганда дамы?

Горатсио

Мин аны бик нык күзәтеп тордым.

Гамлет

Ха-ха! Бирегез миңа музыка! Кая курайчылар?
Король ошатмады уенны, шәт,
Ошатмасын, аның шунсы да шәп!
Һәй, музыка, бирегә!

Розенкранц белән Гилденстерн керәләр.

Гилденстерн. Принц җәнапләре, миңа берәр сүз әйтергә генә рөхсәт итегезче.

Гамлет

Теләсәгез, бөтен тарихны сөйләп чыгыгыз, әфәндем.

Гилденстерн

Король, әфәндем...

Гамлет

Әйе, әфәндем, аңа ни булды?

Гилденстерн

Бик кәефсез хәлдә үз бүлмәсенә кереп китте.

Гамлет

Эчкәннәнме, әфәндем?

Гилденстерн

Юк, принц, үте кабарганнан булуы хаграк.

Гамлет. Сез бу хакта аның докторына хәбәр итсәгез, эшегез төплерәк булыр иде; чөнки әгәр дә бит аның эчен тазартырга мин тотынсам, аның ярсыган үте тагын ярсый төшәр иде.

Гилденстерн. Принц җәнапләре, телегезне бераз тәртипкә китерсәгез лә, минем сүземнән ул хәтле читкә китмәсәгез лә.

Гамлет

Мин тыңлыйм, сөйли бирегез, әфәндем...

Гилденстерн. Королева, сезнең анагыз, бик каты борчылып, мине сезгә җибәрде.

Гамлет

Бик хуш килдегез.

Гилденстерн. Юк, принц, бу нәзакәт күрсәтүегез чын ихластан түгел. Әгәр сез, мәрхәмәт итеп, юньле җавап кайтарсагыз, мин әниегезнең кушканын үтим, юк икән — бигайбә; шуның белән эшемне бетердем дә киттем.

Гамлет

Әфәндем, мин булдыра алмыйм.

Гилденстерн

Нәрсәне, принц?

Гамлет. Сезгә юньле җавап бирүне; ләкин бирә алганча җавабым сезнең хезмәтегезгә әзер яки, үзегез әйтмешли, анам хезмәтенә; шуның өчен монысы җитте, эшкә килик; минем анам, дисез бит сез.

Розенкранц. Менә шул, ул әйтә: сезнең холкыгыз аны бик зур аптырашка, хәйранга калдырган.

Гамлет. Кара син нинди шаккатарлык угыл икән ләбаса, үз анасын хәйранга калдырган булгач! Бәлки, бу хәйран артыннан берәр вәйран да юкмы? Сөйләгез.

Розенкранц. Ул йокыга китәр алдыннан сезнең белән үз бүлмәсендә сөйләшергә тели.

Гамлет. Буйсындык, тели икән, безгә ун мәртәбә анабыз булсын. Тагын миңа берәр эшегез бармы?

Розенкранц

Принц, сез кайчандыр мине ярата идегез.

Гамлет *(үзенең кулларын күрсәтеп).* Шушы караклар һәм кармакларым белән ант итәм[1], мин һаман да шулай.

Розенкранц. Принц җәнапләре, бу борчылуыгызның сәбәбе нәрсәдә соң? Сез хәсрәтегезне үз дустыгыз белән бүлешмәвегез белән үзегезгә аннан котылу юлын гына биклисез бит.

Гамлет. Әфәндем, минем бөтен юлым бикле.

Розенкранц. Ничек алай булсын ди, Король сезгә үзе Данияне мирас итеп калдырам дип торганда?

Гамлет. Әйе, әфәндем, «түз, атым, түз...»[1] — хәер, бу мәкаль чак кына искерә төшкән шул.

Артистлар курайлар белән кире керәләр.

Ах, курайлармы, берсен бирегезче. Сезнең миңа аулак сүзегез бармы? Сез нәрсә, мине тозакка кертергә куган кебек, һаман минем тирәмдә җилпенәсез.

Гилденстерн. О, принц, мин йөкләмәмне үтәүдә бик тырыш булган кебек, яратуымда да бәйләнчек кеше.

Гамлет. Ничектер мин моны яхшы аңлап җиткермим. Шушы курайда уйнап җибәрегезче!

Гилденстерн

Уйный белмим, принц.

Гамлет

Үтенәм сездән.

Гилденстерн

Ышаныгыз, миннән булмый.

Гамлет

Зинһар өчен!

Гилденстерн

Мин аны тота да белмим, милорд.

Гамлет. Ялганлап торудан да җиңел ул; бармакларыгыз белән шул тишекләргә, аннан баш бармагыгыз белән монда басасыз, авызыгыз белән өрәсез дә, аннан бик шәп тавышлар чыгар. Күрәсезме, менә ул басамыклары.

Гилденстерн. Ләкин моннан бер генә көй дә чыгара алмыйм; минем моңа сәләтем юк.

Гамлет. Менә күрәсезме, сез миннән нинди юк нәрсә ясамакчы буласыз! Сез минем өстә уйнап карамакчы булдыгыз; минем телләргә дә баса белә икәнегезне күрсәтмәкче булдыгыз; минем серләремне йөрәк төбеннән йолкып алмакчы булдыгыз; сез миннән, иң түбәннән алып иң югарысына чаклы, бө-

тен авазларны чыгармакчы булдыгыз; менә бу кечкенә курайда бик күп төрле көй, бик моңлы авазлар бар, шулай да сез аны сөйләтә алмыйсыз. Шайтан алгыры, сез нәрсә, минем белән уйнау шушы курайда уйнаудан да җиңел дип уйлыйсызмы? Мине теләсәгез нинди уен коралы дип атагыз, ләкин сез мине көйдән чыгарсагыз да, миннән көй чыгара алмассыз.

Полони кире кайта.

Рәхмәт төшсен сезгә, әфәндем.
Полони. Принц, Королева сезнең белән сөйләшергә тели; шушы ук минутта.

Гамлет

Күрәсезме әнә теге болытны, бөтенләй дөя кебек.

Полони

Валлаһи гына, чынлап та дөя кебек.

Гамлет

Минемчә, ул көзәнгә охшаган.

Полони

Әйе шул, аркасы көзәннеке кебек.

Гамлет

Яки китныкы кебек.

Полони

Бөтенләй китныкы.
Гамлет. Ярый, хәзер үк анам янына барырмын. *(Читкә.)* Алар мине ахмаклыкның түшәменә менгереп җиткерәчәкләр. Хәзер барырмын.

Полони

Шулай дип әйтермен дә.

Гамлет

«Хәзер» дип әйтү җиңел. Калдырыгыз мине, дусларым.

Гамлеттан башкалар бары да китәләр.

Хәзер нәкъ сихри җиде төн уртасы,
Авызларын ачып гүрләр бу дөньяга
Җәһәннәмнең зәхмәт җилен өргән чагы.
Кайнар кан эчә алыр идем хәзер,
Шундый эш эшли алыр идем ки мин —
Кояш үзе дер калтырап төшәр иде;
Хәзер анам янына. Чү, аһ син, йөрәк!
Үз табигатеңне җуйма; бу күкрәккә
Нерон[1] җаны һич тә кереп утырмасын.
Рәхимсез булсам булыйм, ерткыч булмам;
Телем аңа хәнҗәр булыр, кулым булмас.
Телем, күңелем, булыгыз сез икейөзле;
Сүзләрем аңа ачы яра салсын,
Кулым шуны, әй йөрәгем, расламасын!

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сарайда бер бүлмә. Король, Розенкранц һәм Гилденстерн керәләр.

Король

Ошамый миңа ул һич. Үзебезне
Аның ахмак көйсезлеге кулына да
Тапшырырга риза түгел. Шуңар әзер
Торыгыз, хәзер сезне мин илчелек
Кәгазьләре белән тәэмин итим дә, ул
Сезнең белән бергә Англиягә китәр;

Аның юләрлеге белән сәгать саен
Башыбызга янап торган куркынычлы
Бәлаләрне дәрәҗәбез күтәрә алмый.

Гилденстерн

Без җыенабыз. Сез падиша хәзрәтенең
Мәрхәмәте белән ашап-яшәп килгән
Күп кенә кешеләрне бәлаләрдән
Саклап калу һәм кайгырту — изге бурыч.

Розенкранц

Һәм һәркем дә үз миенең, тимер кебек
Ныклыгы белән, үзен һәммә төрле
Бәла-каза, фетнәләрдән саклау тиеш,
Бигрәк тә исәнлеге бик күпләрнең
Тормышына сәбәп булган сездәй Король.
Патша үлсә, үзе генә үлеп калмый,
Өермә күк, якындагы һәммәсен дә
Үзенә тартып ала; биек тауның
Башындагы зур көпчәк күк, аның озын
Тешләренә ун меңнәрчә вак нәрсәләр
Ябышып әйләнәләр; ул аудымы —
Ябышкан валчыкларның иң вагы да
Бу куркыныч тәгәрәүдә бергә була.
Патша һич тә бәла күрми ялгыз гына,
Елаш бөтен иле белән уртак була.

Король

Сорыйм сездән, юлга бик тиз җыеныгыз;
Бу хәтәрне тиз богаулыйк, югыйсә ул
Артык иркен йөри.

Розенкранц белән Гилденстерн

Бик тиз тотарбыз без.

Розенкранц белән Гилденстерн китәләр. Полони керә.

Полони

Милорд, ул үз әнисенең бүлмәсенә
Китте хәзер. Бар сүзен дә ишетер өчен
Теге палас артында мин качып торам.
Әлбәттә, Королева аны тетәр.
Үзегез әйттегез бит, — һәм хикмәтле
Сүз әйттегез, — ана күңеле һәрвакытта
Бала яклы булган өчен, анда тагын
Тыңлар өчен өстәмә бер шаһит кирәк,
Тик тыңласын, дидегез бит. Хуш, падишаһ,
Сез йокларга ятканчы, мин борылып килеп,
Белгәнемне сөйләп бирим.

Король

Рәхмәт, дустым.

Полони китә.

Аһ, җирәнгеч бу гөнаһым. Сөремнәре
Күккә җитә: нәләтләрнең иң борынгы,
Иң шомлысы төшкән аңа — туган үтерү!
Гыйбадәт тә кылып булмый; ихтыярым
Хәтлүк көчле мәелем дә бар — юк, кылалмыйм,
Нинди көчле теләктән дә гаебем көчле.
Берьюлы ике эшкә тотынучы

Кеше кебек мин, кайсыннан башларга да
Белми, ташлыйм икесен дә. Әгәр дә бу
Нәләтле кулым минем баштанаяк
Туган каны белән катып калган икән,
Аны соң кардан да ак юу өчен
Күкнең рәхмәт яңгырлары җитмәсмени?
Рәхмәте нәрсәгә соң хезмәт итә,
Гөнаһлы җан сыенырга ярамагач?
Ике баштан түгелмени дога көче:
Берсе алгы гөнаһлардан тыелу булса,
Икенчесе — булганыннан ярлыкану.
Оедым күккә. Үткәндәге гөнаһ өчен.
Ләкин миңа нинди дога ярдәм итәр?
— «Ярлыка шомлы үтерүемне» дип?
Юк, ярамый, мине шундый үтерүгә
Илткән нәрсә — тадж, дәрәҗәм, Королевам.
Үземдә бит. Җинаятьнең әйберләре
Кулда булып, кеше гафу ителәме?
Бу гөнаһлы җир йөзендә чын хаклыкны
Учына алтын тоткан ялган җиңә;
Гаебең өчен акча түләп, закон сатып
Алу җиңел, әмма теге дөньяда юк,
Алай түгел, боргаланып булмый анда.
Эшләр анда бар булганча алга килә.
Гаебебез белән йөзгә-йөз торырга
Тиешбез. Шулай булгач, нәрсә кала?
Тәүбә итү? Тәүбә барсын йолып ала.
Ләкин тәүбә капкасы да берәү өчен
Ябык булса, нишли ала? Нинди шомлык!
Әй, үлемдәй кара күкрәк! Әй, пычракка
Бата барган минем җаным! Фирештәләр!
Коткарыгыз! Ярдәм, ярдәм! Иел, тезем!
Таш йөрәгем, яңа туган яшь баланың
Бәгыреннән дә йомшара төш! Бәлки әле,
Эш төзәлер.

Артка китеп тезләнә. Гамлет керә.

Гамлет

Хәзер аны үтерә алам. Гыйбадәттә.
Кизәндемме — оҗмахка ук туры китәр.
Шуның белән тынам мин дә. Тукта, уйлыйк:
Шулаймы бу? Әтиемне шушы явыз
Үтерсен дә, шуңа каршы мин, атамның
Ялгыз углы, ул явызның җанын күккә
Җибәрәмме? Бу бит аңа бүләк бирү,
Үч кайтару түгел. Ләкин минем атам
Баштанаяк гөнаһларга баткан чакта,
Хыянәтле үлем белән бу үтергән.
Аның хәле анда ничек. Алла белә,
Тик безнең уйлый алган кадәренчә,
Хәле авыр. Инде хәзер бу игелексез
Арынып гөнаһыннан, мәңгелеккә
Китәргә торган гына чакта, аны
Үтерсәм, кайтырмы соң минем үчем?
Юк.
Кылычым, кынына кер, бел үзеңнең
Моннан шомлы һөҗүм өчен кирәгеңне.
Ул исереп аунаганда, ярсыганда,
Яки фәхеш кылган чакта, сүгенгәндә,

Яки карта уйнаганда, ни дә булса
Берәр яман эш өстендә чәнеч аны!
Шундый чәнеч — үкчәләре күккә тибеп
Җибәрсен дә, барыр җире җәһәннәмнән
Караңгырак җаны белән утка төшсен!
Анам көтә. Ярый. Калган гомереңә мин
Бераз вакыт бирәм, котылу түгел ләкин.

Китә.

Король

Сүзләрем күккә китә, уем — җирдә;
Коры сүзләр күккә ашмый һич тә бер дә.

Китә.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Королева бүлмәсе. Королева белән Полони керәләр.

Полони

Хәзер килә. Сез катырак сөйләшегез.
Әйтегез — теле адәм күтәргесез
Әчелеген; аңа булган куркынычлы
Ачуны сез үз гәүдәгез белән каплап
Арада тора икәнегезне. Мин
Бирегә качам. Зинһар, сез катырак.

Гамлет
*(тыштан)*

Анам, анам, анам!

Королева

Сезне ышандырам,
Минем өчен курыкмагыз сез; йә, барыгыз,
Ишетәм, килә.

Полони палас артына кача.
Гамлет керә.

Гамлет

Ягез, анам, ни бар?

Королева

Гамлет,
Синең атаң синнән бик нык җәберсенгән.

Гамлет

Минем атам синнән бик нык җәбер күргән,
Анакаем.

Королева

Килче, зинһар, бу җавабың
Ахмак җавап.

Гамлет

Куйчы, зинһар, бу соравың
Бозык сорау.

Королева

Йә, бу нәрсә инде, Гамлет?

Гамлет

Эш нәрсәдә?

Королева

Мин кем сиңа, оныттыңмы?

Гамлет

Юк, ант итәм — менә тәре, алай түгел.
Син — падишабикә, ирең туганының
Хатынысың һәм, аһ, шунысы үкенечкә,
Син анамсың.

Королева

Алай булгач, синең белән
Бүтәннәр сөйләшсеннәр.

Гамлет

Юк, кил әле,
Утыр әле; урыныңнан һич кузгалма да;
Җаныңдагы бар сереңне мин үзеңә
Көзгедәге кебек күрсәтмичә торып,
Китмәссең дә.

Королева

Нишләмәкче буласың син?
Әллә мине үтермәкче буласыңмы?
Ярдәм, ярдәм итегез, һәй!

Полони
*(палас артыннан)*

Нәрсә бу, һәй?!
Ярдәм, ярдәм, ярдәм!

Гамлет
*(кылычын чыгарып)*

Бу ни? Күсеме шул?
Үлде, алтын куеп әйтәм, үлде.

Палас аркылы чәнчә.

Полони
*(палас артында)*

Аһ, мине
Үтерделәр.

Үлә.

Королева

Аһ, ни шомлык! Нишләдең син?

Гамлет

Юк, мин белмим, Корольме бу?

Королева

Аһ, бу ниткән
Юләрчә эш, зур канлы эш!

Гамлет

Зур канлы эш!
Шулкадәрле әшәке эш бу, анакай,
Корольне үтереп тә энесенә
Иргә чыгу кебек.

Королева

Ничек Корольне үтереп?

Гамлет

Әйе, ханым, шулай әйттем.

Паласны күтәрә төшеп, Полонины күрә.

Әй, тыкшынган,
Әрсез, мескен син мәзәкче, хуш, бәхил бул!
Кизәнгән идем ләкин зуррак тузга.
Бик артык куштанлансаң, шулай чыга.
*(Королевага.)*
Акрын, шулай кулларыңны өзгәләмә.
Йөрәгең тырнак үтмәс кабык белән
Капланмаса йә начарга күнегүдән
Инде сизмәс бер металлга әйләнмәсә,
Утыр, синең йөрәгеңне мин өзгәлим.

Королева

Аһ, бу кайгым! Телең белән миңа шулай
Куркынычлы янар өчен мин соң нинди
Эш эшләгән?

Гамлет

Нинди эшме? Бу эшеңнән
Әдәпнең сихри алсу йөзе шиңде,
Турылыкның исеме ялган булып калды,
Саф сөюнең йөзендәге алсу чәчәк
Кутырга әйләнде дә1, никах анты
Картада уйнаучының антыннан да
Ялганрак бернәрсәгә әйләнде. Аһ,
Нинди эшме? Бу эшеңнән никах дигән
Изге йола буш, коры сүз булып калды.
Бу эшең турысында уйлаганда,
Гарасат мәйданында торган кебек,
Күкләрнең йөзе яна, җирнең каты,
Какшамас тау-ташлары каралдылар.

Королева

Вай хәлләрем! Ул турыда әйткәнче үк
Шундый каты күкрәрлек эш — ул нинди эш?

Гамлет

Бире кара бу рәсемгә, монсына да;
Кара-каршы ике туган басып тора.
Кара монсын, нинди гүзәл, якты чырай;
Аполлондай чәче бөдрә, маңгае нәкъ
Зевсныкы; күз каравы — Марсныкы;
Боерыр өчен яратылган; буй-сыннары
Болыттан ашып чыккан тау өстенә
Күкләрдән илче булып килеп төшкән
Меркуридай мәһабәтле. Бу дөньяга
Кешенең иң яхшы, шәп бер үрнәген
Бирер өчен, һәрбер Тәңре үзеннән бер
Сыйфат бирсә, алар бар да шушы йөздә
Урнашкан. Шушы синең ирең иде,
Хәзер кара бу егетне. Яңа ирең.
Башакка төшкән кара кисәү кебек,
Үз туганын кисүче. Һа! Күзләрең соң
Бармы синең? Шундый гүзәл тау башыннан
Шундый сазга төшеп черү? Аһ, күзләрең

Бармы синең? Мәхәббәт дип атар идең,
Синең яшьтә инде алай кан кайнамый,
Кеше инде исен-һушын җыйган була;
Ләкин нинди акыл шундый тәүге ирдән
Монысына китәргә соң риза булсын?
Син тере бит, тойгыларың бардыр бит соң?
Тик, мөгаен, ул тойгылар зәгыйфьләнгән,
Югыйсә ахмак та бит моны сизәр.
Саташкан хәлендә дә кешенең бит
Хисләрендә шушындый зур аерманы
Күрерлек кадәр генә бер як кала.
Нинди шайтан, сине шулай адаштырып,
Синең белән сукыр тәкә уйнады соң?
Тими күрү, күрми капшау, капшамый һәм
Күрми ишетү, барысыннан тыш иснәп белү,
Гади хиснең хәтта зәгыйфь кисәге дә
Бу кадәрле ахмакланмас.
Аһ, ни оят! Аз гына да кызармыйсың?
Әй син, купкан тәмуг, әгәр бу карчыкның
Канын шулай кабындыра алган булсаң,
Ул чагында яшьнең кайнар оят хисе
Үз утында балавыз шәм кебек эресен.
Шул бозга да шундый кызу ут кабынгач,
Шәһвәт шулай ихтыярны алыштыргач,
Яшьлек дәрте үз-үзеннән таша икән,
Аны инде оят дип тә атарга юк.

Королева

Аһ, Гамлет, җитәр, тукта, күзләремне
Син минем нәкъ бәгыремә төбәлдердең,
Анда шундый кара таплар күрәмен ки, —
Мин аларны ни белән дә юа алмыйм.

Гамлет

Юк, соң ничек, сөрсеп беткән, майга каткан
Бер түшәктә сасы тиргә батып яшәү,
Пычрак бер абзарда ышкынгалап,
Бакылдашып күңел ачу.

Королева

Аһ, куй, җитәр.
Сүзләрең колагыма хәнҗәр кебек
Кадалалар! Гамлет, кызган.

Гамлет

Башкисәр, кол;
Үтерүче; башта булган үз ireңнең
Йөздән бер өлешенә тормый торган
Явыз бер җан, шамакайлар падишасы,
Патшалыкны һәм властьны эләктерүче,
Киштәдән алтын таҗны урлап алып
Куенына яшерүче, әрсез карак!

Королева

Җитәр!

Гамлет

Корамадан теккән чүпрәк король[1].

[1] Өрәк керә.

Коткарыгыз мине, канат астыгызга
Алыгыз, әй, фирештәләр! Ни кушасың,
Әй мәһабәт, азамат ир!

Королева

Аһ, ул шашкан!

Гамлет

Әллә вакытым әрәм итеп,
Ул дәһшәтле боерыгыңны әле булса
Җиренә җиткерергә акрынлаган
Улыңны шелтәләргә килдеңме син?
Аһ, сөйлә.

Өрәк

Онытма. Бу килүем тик
Үтмәсләнгән ихтыярың көчең синең
Үткерләү өчен. Ләкин, күрәсеңдер,
Әниеңнең чын куркуга төшкәнлеген;
Тор син аның белән аның җан көрәше
Арасында. Көчсезрәк кешеләрдә
Хыял көчле. Аның белән сөйләш, Гамлет.

Гамлет

Хәлең ничек, ханым?

Королева

Сиңа ни булды, аһ?
Бушлыкка күзләреңне юнәлттең дә
Гәүдәсез һава белән сөйләштең син.
Күзләреңдә рухың шундый кыргый карый;
Гауга белән уятылган гаскәр кебек,
Чәчләрең тере төсле үрә торды.
Әй газизем, ярсуыңның кызуын син
Салкын сабыр суы белән бөрке дә бас.
Син нәрсә күрәсең, әйт!

Гамлет

Аны, аны!
Кара, ничек күзе томса, хәрәкәтсез!
Үз хәлләрен ул сөйләсә, хәтта таш та
Аның өчен йомшар иде. Аһ, карама
Миңа шулай. Йә кайгылы бу карашың
Куркынычлы ниятемнең көчен җуяр.
Шуның белән мин эшләргә тиеш эш тә
Кан урынына күз яшь белән бетүе бар.

Королева

Моны кемгә сөйлисең син?

Гамлет

Әнә анда
Син берни дә күрмисеңме?

Королева

Һичберни дә.
Бар нәрсәне күрәм ләкин.

Гамлет

Бернәрсә дә
Ишетмәдең дәме?

Королева

Бары икебезнең
Тавышын гына.

Гамлет

Әнә анда кара, әнә
Кара, ничек китеп бара. Минем атам!
Нәкъ тере чагындагы кыяфәттә.
Кара, әнә атлап чыкты бусагадан.

Өрәк китә.

Королева

Бу тик синең үз миеңнең уйламышы;
Мондый төпсез хыяллар гел аймылышу,
Саташудан килеп чыга.

Гамлет

Саташумы?
Минем йөрәк тибешем нәкъ синеке күк,
Тигез, анык, бик сау тибә, юк, саташмыйм;
Кайтарып сора миннән, мин яңадан
Сүзгә-сүз кабатлармын әйткәнемне,
Саташкан кеше аны сөйли алмас.
Мәрхәмәт хакы өчен сорыйм, анам,
Бу сүзләрне үз хурлыгың сөйләтмичә,
Саташуым сөйләтә дип, үзеңне син
Бал-май белән алдама һич, ул бал-майлар
Кутырны өстән генә бераз каплар,
Әмма эчтән яшерен эрен үз тирәсен
Һаман ашап җәеләчәк. Йөрәгеңне
Ач Ходайга, бөтен булган эшләреңнән
Син тәүбә ит, булачактан тагын саклан,
Туфракны бакыра белән ашлый күрмә,
Ул куерак булып үсәр. Кичер минем
Яхшылыкка әйткән сүзне. Чөнки безнең
Кабахәт, сасы, тынчу бу заманда,
Яхшылык яманлыкка тезен чүгеп,
Үз ярдәме өчен гафу сорау тиеш.

Королева

О, Гамлет, йөрәгемне телдең минем
Син икегә.

Гамлет

Ә син аның шакшы ягын
Читкә ат та яхшы ягы белән яшә.
Хәерле төн. Ләкин агам ятагына
Бармыйсың. Оятың юк икән синең,
Ичмасам, оятлыдай булып кылан.
Гадәт дигән шайтан безнең үзебезне
Нәфсебезгә күнектереп бетерсә дә,
Кайвакыт ул бик ятышлы бер киемгә
Күнектергән кебек, безне яхшы эшкә
Өйрәткәндә, фирештә дә булып куя.
Бүгенгә син тыелып тор, икенче кат
Тыелу да сиңа җиңелрәк булыр.
Аның киләсесе тагын җиңелрәк.
Күнегү ул табигатьне — холыкны да
Үзгәртә ала, һәм искиткеч көче белән

Шайтанны да җиңеп, хәтта аны куып
Чыгарала. Тагын бер кат хәерле төн.
Изгелеккә кайтсаң, миңа фатиха бир.
Инде бу лорд.
*(Полонига күрсәтеп.)*
Бик үкенәм бу эшемә.
Күрәсең, язмыш шулай аның кулы
Белән — мине, минем кулым белән аны —
Бер-беребезне җәзаларга хөкем иткән.
Үзем җирлим аны, үлеменә җавап
Мин бирермен. Шулай, тагын хәерле төн.
Шәфкатемнән генә шундый мин рәхимсез
Булырга тиешлемен. Эшнең башы
Яман, әле алда булыр иң яманы[1].
Тагын бер сүз миңа, ханым.

Королева

Мин нишләргә
Тиеш?

Гамлет

Һич тә мин әйткәнчә эшләмәскә:
Күбенгән патшаң сине әйдә тагын
Түшәгенә өстерәсен, яңагыңны
Чеметкәләп, и тычканым, дип яратсын,
Муеныңны мәлгунь бармаклары белән
Кытыклап, сине пычрак үбү белән
Үпкән өчен аңа барсын сөйләрсең дә,
Мине чынлап тилермичә, юри генә
Тиле булып кылана дип такылдарсың.
Шәп бит моны аңа сөйләү. Шундый гүзәл,
Акыллы Королева ничек инде
Бу кадәрле зур эшләрне шул гөберле
Бакадан, шул уйнашчы мәчедән, шул
Ярканаттан яшереп калсын? Килешәме?
Кем шулай әйтми калсын? Юк, хәзер үк
Акылыңа ачу итеп кәрзин ал да
Мен чарлакка, очыр бөтен кошларыңны,
Аннан үзең, әкияттәге маймыл кебек,
Сынар өчен, шул кәрзингә кереп утыр,
Шуның белән очам диеп бер талпын да
Муенын сындыр[2]!

Королева

Бел син ләкин, әгәр сүзләр
Сулыш булса һәм сулыш та гомер булса,
Синең әйткән сүзләреңне тыным белән
Әйтергә минем гомрем җитмәс.

Гамлет

Миңа
Англиягә китәргә. Беләмсең син
Моны?

Королева

Аһ, мин онытып торам; карар шулай.

Гамлет

Хатлар инде мөһерләнгән. Ике зәһәр

Еланнан да ышанычлы ике дустым
Ул хатларны илтә бара һәм тозакка
Юллар әрчеп мине шунда илтәчәкләр.
Ярый, булсын. Җиргә мина салган кеше
Үз минасы белән шартлап күккә очса,
Шунда кызык. Мин аларның казыганына
Караганда, үз минамны берәр аршын
Тирәнгәрәк салырмын да, алар аннан
Айга хәтле чәчрәп китәр. Ике хәйлә
Бер-берсенә маңгай белән маңгай килеп
Бәрелүнең үзендә бар бер тәм аның.
Тотынырга вакыт моңа. Бу мәетне
Ераккарак мин болдырга сөйрәп илтим.
Хәерле төн, анам. Ләкин алай да бу
Түрә хәзер чыннан да бик җитди, тыныч.
Тере чакта такылдык бер наян иде.
Йә, акыллым, эшне бетерик синең белән,
Юлың анда табан; анам, хәерле төн.

Икесе ике якка чыгалар. Гамлет Полонины сөйрәп алып китә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сарайда бер бүлмә.
Король, Королева, Розенкранц һәм Гилденстерн керәләр.

Король

Юкка гына офтанмыйлар; болай тирән
Сулавыңның мәгънәсе ни, төшендерче,
Без аңларга тиеш аны. Кайда углың?

Королева

Калдырып торыгызчы беразга сез
Икебезне.

Розенкранц белән Гилденстерн китәләр.

Падишаһым, бу төнне мин
Ниләр, ниләр кичермәдем.

Король

Барын да әйт,
Гертруда, Гамлет ни хәл?

Королева

Давыл белән
Чарпылышкан диңгез кебек, ярсу бит ул.
Шашкын хәлдә, үзен-үзе белешмәстән,
Паласның артында ул бер кыштырдау
Ишетү белән, кылычын суырып, күсе-күсе,
Дип кычкырып ташланды да анда посып,
Тыңлап торган мескен картны үзе күрми
Үтерде дә куйды.

Король

Гөнаһ шомлык икән!
Әгәр анда карт урынында без утырсак,
Безгә дә шул булыр иде. Менә шулай
Иркендә йөрүләре аның хәзер
Безгә дә, үзеңә дә, һәммәбезгә
Бик куркыныч. Йә, бу канлы явыз эшкә
Ни дип җавап бирик, аны хәзер безгә
Аударырлар; ни өчен, дип, ул шашканны
Аерым тотмый, нәрсә карап торганнар, дип,
Аның өчен хәзер безне гаепләрләр.
Ләкин без, аны шундый яратканга,
Аңа нәрсә тиешлеген аңламадык.
Яман чирен яшергән кеше кебек
Яшердек тә, менә хәзер ул тирәнгә,
Эчкә китте. Кая китте хәзер үзе?

Королева

Ул каядыр аның мәетен сөйрәп китте.
Ләкин аның шашкынлыгы руда белән
Аралаш алтын кебек, саф, гаепсез.
Кылган эше өчен үзе елап-үкенеп
Бетә алмый.

Король

Аһ, Гертруда, кызу тотыйк.
Өлгермәс кояш тауга иңәргә дә,
Ул корабта киткән булыр; бу четерекле
Эшне без корольләрчә оста итеп
Сылап-сыйпап йомшатырга тиешбез, һәй,
Гилденстерн!

Розенкранц белән Гилденстерн кире керәләр.

Дускайларым, сез икегез
Булышыгыз, анда Гамлет исәрләнеп
Полонины үтергән дә, Королева
Бүлмәсеннән сөйрәп аны, белмим кая,
Чыгып киткән. Тиз Гамлетны табып, җайлап,
Мәетне алып барыгыз часовняга.

Розенкранц белән Гилденстерн китәләр.

Әйдә, Гертруда, акыллырак дус-ишләрне
Җыйыйк та үзебезнең карарларны
Белдерик һәм бу вакытсыз хәл турында
Уйлашыйк. Нәкъ атылган җиргә тигән
Ядрә кебек, бу Җир шарын тишеп чыгып
Иясенә тия торган пыш-пыш сүзләр,
Шулай итсәк, бәлки, безгә тими үтәр.
Аһ, китикче, күңелемне шик, курку басты.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сарайда икенче бер бүлмә. Гамлет керә.

Гамлет. Ышанычлы яшерелде.
Розенкранц белән Гилденстерн *(тыштан).* Гамлет! Гамлет!
Гамлет. Ниткән тавыш?! Кем Гамлетны чакыра? Чү, монда киләләр.

Розенкранц белән Гилденстерн керәләр.

Розенкранц. Мәетне кая илттегез, принц?

Гамлет. Балчык белән укмаштырдым. Ул аның затыннан.

Розенкранц. Әйтегез, кайда ул? Безгә аны часовняга илтергә кирәк.

Гамлет. Моңа ышанмагыз.

Розенкранц. Нәрсәгә ышанмаска?

Гамлет. Мин сезнең серегезне саклый алып та үземнекен саклый алмавыма. Аннан соң, һәрбер мунча мунчаласы сораган сүзгә Корольнең углы ни өчен дип әле җавап биреп торырга тиеш?

Розенкранц. Сез мине мунчалага санайсызмыни, принц?

Гамлет. Әйе, әфәндем; Корольнең мәрхәмәтен, бүләк-санакларын, боерыкларын үзенә эчеп-суырып торучы мунчала. Ләкин мондый сарай йомышчылары Корольгә иң шәп хезмәтне актыктан гына күрсәтәләр. Ул аларны, чикләвек ашаган маймыл кебек, башта уртында тота; иң соңыннан гына йота. Сезнең суырганнарыгыз аңа кирәк булдымы — ул сезне сыгып ташлый да, сез, мунчалалар, тагын коп-коры.

Розенкранц. Мин сезне аңламыйм, принц.

Гамлет. Анысы миңа шатлык: аңгыра колакка шаян сүз батмый.

Розенкранц. Принц, сез безгә аның гәүдәсе кайда икәнен әйтергә, үзегез безнең белән Король янына барырга тиешсез.

Гамлет. Мәет Король янында, ләкин Король мәет янында түгел. Король бит ул берни...

Гилденстерн. «Ни», принц?

Гамлет. Берни, алып барыгыз мине аңа. Йөгер, төлке, йөгер, чык; ку артыннан, куып тот[1]!

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сарайда икенче бер бүлмә.
Сарай хадимнәре һәм Король керәләр.

Король

Үзен эзләп китерергә, мәетне дә
Табарга куштым. Әмма нинди хәтәр
Бу кешенең үз иркендә йөрүләре.
Ләкин аңа каты закон йөртергә дә
Ярамый. Башы белән яратмыйча,
Тик күз белән яратучы кара халык
Аны яклый. Андый чакта халык бары
Җәза даулый, әмма ләкин эш нәрсәдә,
Күп тикшереп тормый ансын. Эшне шома
Йөртү өчен, аның моннан китүен без
Эш өчен китү итеп күрсәтербез.
Каты чирне бары каты чара гына
Төзәтә алса ала яки һични.

Розенкранц керә.

Йә, ни анда? Нәрсә булды?

Розенкранц

Ул мәетне
Кая илткән, таба алмадык, милорд.

Король
Үзе
Кайда соң ул?

Розенкранц

Тышта, монда гына, милорд,
Сак астында, сезнең әмерегезне көтә.

Король
Китерелсен.

Розенкранц

Һәй, Гилденстерн! Керт принцны.

Гамлет белән Гилденстерн керәләр.

Король

Хуш, Гамлет, Полони кайда?

Гамлет

Кичке аш янында.

Король

«Кичке аш янында!» Кайда?

Гамлет. Үзе ашаган җирдә түгел, үзе ашалган җирдә. Ниндидер бер өер политик кортлар хәзер генә аңа ябыштылар[1]. Корт ул — ашау дигәндә, чын-чын император. Без үзебез туклану өчен терлек-туарны симертәбез, ә үзебезне кортлар симертү өчен тукландырабыз. Симез патшаң да, ябык хәерчең дә корт өчен бары тик азык төре генә; ике тәлинкә, ләкин бер үк өстәлгә. Соңы шушы.

Король

Вай безнең хәлебез, вай!

Гамлет. Адәм баласын кара, корольне ашаган корт белән балык тота да аннан шул кортны ашаган балыкны ашый.

Король

Моның белән ни әйтмәкче буласың?

Гамлет. Берни дә. Мин сезгә корольнең ничек хәерче эчәгендә сәяхәт итә алганын гына күрсәтәсем килә.

Король

Кайда Полони?

Гамлет. Күктә; аннан эзләттереп карагыз; әгәр илчегез аны аннан да таба алмаса, икенче җирдән үзегез табыгыз. Алай да сез аны бер ай эчендә эзләп таба алмасагыз, баскычтан галлереягә менгәндә, ул сезнең борыныгызга бәрер.

Король
*(сарай хадимнәренең кайберләренә)*

Барыгыз, аны шуннан эзләгез.

Гамлет

Курыкмагыз, ул сезне көтәр.

Сарай хадимнәре китәләр.

Король

Гамлет, синең бу эшләгән зур эшеңә
Чын күңелдән борчылганга, сине саклап
Калу өчен, бик тиз сине хәзер моннан
Озатырга тиешлебез. Җыен юлга.
Кораб әзер, җил дә арткан. Команда да
Англиягә китү өчен сине көтә.

Гамлет

Англиягә?

Король

Әйе, Гамлет.

Гамлет

Бик шәп. Король,
Шулай
Безнең уйны алдан белгән кебек әйттең.

Гамлет. Мин аларны белгән җәбраил белән эш итәм. Ярый, киттек Англиягә! Сау бул, кадерле анам.

Король

Сине сөйгән атаң, Гамлет.

Гамлет. Анам; ата-ана — ир белән хатын; ир белән хатын — икесе бер тән; шулай булгач — анам! Киттек Англиягә!

Китә.

Король

Артыннан һич калмагыз, тиз корабка!
Юанмагыз, бүген төннүк киткән булсын!
Юлга тизрәк! Бар да язган шушы хатта,
Мөһерләнгән. Үтенәм сездән, ашыгыгыз!

Розенкранц белән Гилденстерн китәләр.

Әгәр син, әй Англия, минем сиңа
Кылыч аша дуслыгымны кыйммәт күрсәң,
Даниянең кылычыннан алган яраң
Әле синдә бетәшмәгән булса һаман,
Һәм син әле бездән куркып, чүгеп торсаң,
Падишаңның бу әмерен дә читләтмәссең.
Гамлетны һич тоткарсыз үтерергә дип,
Ачык әйттек бу боерыкта. Англиям,
Үтә шуны. Каннарымны бизгәк кебек
Кайната ул; коткар мине бу ялкыннан.
Әлегә ул исән икән, һичбер вакыт
Миңа күрү насыйп түгел шатлык-бәхет.

Китә.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Даниядә бер дала.
Фортинбрас, Капитан һәм солдатлар марш атлап керәләр.

Фортинбрас

Бар, Капитан, Даниянең короленә
Миннән сәлам тапшыр һәм әйт: җирегездән
Гаскәр белән үтү өчен Фортинбрас
Сездән рөхсәт сорый, диген. Очрау урынын
Беләсең син. Әйт шунсын да: әгәр дә без
Король заты шәрифенә кирәк булсак,
Чакыру белән без янына ашыгырбыз.

Капитан

Әйтермен, принц.

Фортинбрас

Алга, акрын атлап!

Фортинбрас белән солдатлар китәләр.
Гамлет, Розенкранц, Гилденстерн һәм башкалар керәләр.

Гамлет

Әйтегез, сэр, болар кемнең гаскәрләре?

Капитан

Норвегиянекеләр, сэр.

Гамлет
Кая сәфәр?
Әйтә аламсыз?

Капитан

Польша җирләренә табан.

Гамлет

Башлыклары кем аларның?

Капитан

Карт корольнең
Кардәше — Фортинбрас.

Гамлет

Сез Польшаның
Төп үзенә йә чигенә барасызмы?

Капитан

Алдалашмый дөресен әйтсәм, без кечкенә
Исеме бар да җисеме юк бер җир кисәген
Яулап алырга барабыз. Биш акча да
Бирмәс идем мин ул җиргә. Әнә аны
Сатсалар да, Польша белән Норвегия
Өчен ул җир шуннан артык тормас иде.

Гамлет

Алай булгач, сугышып та тормас Польша
Аның өчен.

Капитан

Анда инде алар гаскәр
Китерткәннәр.

Гамлет

Ике меңләп солдат белән
Егерме мең алтын акча — шундый бер юк
Мәсьәләне хәл итә алмый; менә шулай
Тын елларда эчкә җыйган шеш тулышып
Сытыла да, күтелмәгән үлем килә.
Рәхмәт сезгә, сэр.

Капитан

Тапшырдык Аллага, сэр.

Китә.

Розенкранц

Рәхим итеп, принц, сез дә юнәләмсез?

Гамлет

Артыгыздан җитәм, бара торыгыз сез.

Гамлеттан башкалар бары да китәләр.

Бар да мине үз-үземә фаш итә һәм
Бар да мине үч алырга ашыктыра.
Дөньяда кешенең иң төп теләге
Әгәр бары ашау белән йокы булса,
Ул чагында нәрсә кеше? Хайван гына.
Безне шулай үткән белән киләчәккә
Баш йөртерлек киң уй белән яратучы
Мөгаен дә, бу акылны безнең башка
Тиккә ятып тутыксын дип бирмәгәндер?
Эш нидә соң? Хайван кебек онытумы бу?
Эшнең вак-төяген төрле яктан
Төпчеп уйлап шөгыльләнү гадәтеме,
*(Ул уйда да бер уеңа өч шик булсын!)*

Нәрсә, белмим, — ләкин минем шушы эшкә
Кулда сәбәп, иркем, көчем, чарам булгач,
Нигә һаман үз-үземә: «Мин бу эшне
Эшләргә тиешмен», — дип тукып яшим?
Бөтен җирдә моңа мисал: шул гаскәрнең
Шундый авыр көчен, санын алып кара;
Шушы йомшак принц аны алып бара;
Җаны гаҗәп шөһрәт эзләү белән ташып,
Билгесез язмышына алдан көлеп,
Үлемле һәм фани булган кешеләрне
Йә бәхеткә, йә үлемгә дучар иткән
Эшен алсаң, шалкан кабыгына тормый.
Чын бөеклек — бушка гайрәт ору түгел,
Әмма ләкин эш намуска терәлгәндә,
Бер уч салам өчен дә син сугыш инде.
Мин соң ничек? Атам минем үтерелгән,
Каным кайный, шул көемә аягөсте
Йокымсырап, егерме мең шул гаскәрнең
Күренеп торган гүр авызына баруларын
Оялмыйча карап торам; алар анда
Коры данга, буш хыялга корал булып,
Үзләренә әйләнерлек, хәтта үлгән
Солдатларын күмәрлек тә урыны юк бер
Җир кисәген алыр өчен, кроватька
Йокларга барган кебек, рәхәтләнеп
Каберләренә баралар. Әй син, акылым,
Моннан ары йә кан булсын уйлаганың,
Йә дөньяда булганыңнан булмаганың!

Китә.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Эльсинор. Сарайда бер бүлмә.
Королева, Горатсио һәм Джентльмен керәләр.

Королева

Ул кыз белән мин сөйләшмәс идем.

Джентльмен

Ул бик
Үзсүзләнә, тәмам шашкан; кызганмыйча
Мөмкин түгел аны.

Королева

Нәрсә кирәк аңа?

Джентльмен

Һаман ул — әтием, ди; бу дөньяны
Ялганчы, ди, уфтана ул, үз күкрәген
Төя-төя юк-бар өчен кызып бара.
Тел төбе аңлашылмый, тик ул сүзләр
Корамасы уйланырга мәҗбүр итә.
Берәүләр ул сүзләрне юрыйлар да
Үзләренә кирәк мәгънә чыгаралар;
Хәрәкәте, күзе белән ымлаулары
Аңлашылып җитмәсә дә, әмма ләкин
Бу ымнарда коточкыч бер шомлы әйбер
Яшерелгән дип уйлый кала кайберәүләр.

Горатсио

Аны алдан күреп кую яхшы булыр.

Дошманнарның башына ул хәтәр уйлар
Салуы бар.

Королева

Ярый, керсен.

Джентльмен китә.

*(Читкә.)*
Үз җанында
Бер гөнаһың булгач, шундый юк нәрсә дә
Алдан шундый шомлы әйбер булып күренә.
Җинаять дигән нәрсә шундый шикчел —
Фаш булудан куркып үзен фаш иттерә.

Джентльмен белән Офелия әйләнеп керәләр.

Офелия

Даниянең данлы Королевасы кайда?

Королева

Йә, ни хәл соң, Офелия!

Офелия
*(җырлый)*

Кайда ярың, әй, чибәр кыз?
Ярым хаҗ юлларында,
Таяк тоткан, яланаяк,
Сай кәвеш аягында.

Королева

Аһ, акыллым, бу җырыңның мәгънәсе ни?

Офелия

Ни дисез? Юк, сез тыңлагыз әле, үтенәм.
*(Җырлый.)*
Ул үлгән, кайтмас ул, леди,
Ул үлгән, кайтмас;
Аяк очы яшел чирәм,
Баш очында таш.
А! Аһ!

Королева

Йә, йә, Офелия.

Офелия

Тыңлагызчы.
*(Җырлый.)*
Өсте карлы таудай ап-ак кәфен.

Король керә.

Королева

Нинди хәлләр, карагызчы монда, милорд.

Офелия
*(җырлый)*

Ята күмелеп гөлләргә;
Аны яр-дуслары елавы да
Озатмады гүрләргә.

Король

Хәлең ничек, сөйкемле кыз?

Офелия. Рәхмәт, Алла ярлыкасын үзегезне! Ябалакны икмәкче кызы булган, диләр. Ярабби, без үзебезнең кем икәнебезне беләбез, ләкин кем була алган булыр идек — ансы билгесез. Хөрмәтегез Алладан кайтсын.

Король
*(читкә)*

Атасы турында сөйләнә.

Офелия. Зинһар, бу хакта сөйләшмик әле; ләкин сездән моның ни икәнен сорасалар, болай диегез. *(Җырлый.)*

Иртәгә Валентин көне[1],
Мин дә таң нуры белән
Валентина булыр өчен
Тәрәзәсенә киләм.
Торды да егет киенде,
Берьялгыз кызык түгел;
Кыз кереп кунды да кайтты,
Ләкин кыз булып түгел.

Король

Гүзәл Офелия!

Офелия. Хәзер, бер дә валлаһисыз гына, ахырын җырлап бетерәм. *(Җырлый.)*

Гайса-Мәрьямнәрдер антым,
Фу, ояттыр бу әгәр.
Сез, егетләр, бар да шундый,
Әй хурлык та шулкадәр.
Башта миңа син сүз бирдең,
Хатыным итәм, дидең!»
Аның җавабы:
«Башта бергә йокламасаң,
Вәгъдәмне үтәр идем».

Король

Күптәнме ул шулай?

Офелия. Бар да яхшыга булыр дип торам әле. Сабырлы булырга кирәк. Ләкин мин аны салкын кабергә салуларын уйласам, еламыйча булдыра алмыйм. Менә абыем бу турыда белер әле; яхшы киңәшегез өчен сезгә рәхмәт. Каретамны китерегез!.. Хәерле төн, ханымнар, хәерле төн, кадерле ханымнар; хәерле төн, хәерле төн!

Китә.

Король

Артыннан бар, бик нык кара, үтенәм синнән.

Горатсио китә.

Һай зур хәсрәт нинди зәһәр. Атасының
Үлеменнән туган бу хәл. Әй, Гертруда,
Бел син, бәла килгән чакта ул берәмләп
Килми сиңа, батман-батман белән килә:
Иң элек атасының үтерелүе,
Аннан — углың китү; ә ул, башсыз нәрсә,
Үзен илдән сөрдерүгә үзе сәбәп;
Болгана монда халык; Полониның
Үлеме турында күп имеш-мимеш,
Яман сүзләр йөри, аны шулай яшерен
Күмүебез белән ахмак эш эшләдек;
Офелия җуйды, мескен, газиз башын,
Якты акылын; шул акылдан башка без ни?
Коры курчак яки ерткыч хайван гына.
Ахырында, болардан да зуррагы,
Агасы Лаэрт шуның өстәвенә
Яшерен генә кайтып төште Франциядән;

Өеннән чыкмый ята, шиккә батып;
Атасының бу үлеме турысында
Пышылдыклар аның шикле колагына
Агулы сүзләр сөйләп өркетәләр.
Дәлилләр аз, шулай булгач, бөтен эшкә
Гаепне безнең өскә аударырга
Һичшиксез пышын-пышын сүзләр китәр.
Болар барысы, аһ Гертруда, картечь белән
Бәргән кебек миңа үлем белән яный.

Тышта тавышлар.

Королева

Йа Ходаем, нинди тавыш?

Король

Кайда ишек
Сакчыларым? Сакласыннар ишекләрне.

Джентльмен керә.

Ул ни анда?

Джентльмен

Коткарыгыз үзегезне,
Милорд; әгәр диңгез ярдан ташып чыкса,
Иңкел җирне ул да шулай тиз капламас,
Яшь Лаэрт бер гаугачы төркем белән
Шулай сезнең сакчыларны басып керде.
Толпа аны үзенә баш итеп таный;
Әйтерсең лә дөнья бүген башланган кук,
Бар тәртипкә нигез булган иске гадәт —
Йолаларны онытканнар; белгәннәре:
«Без сайлыйбыз, Лаэрт хәзер безнең король!»
Бүрекләр, куллар, телләр шуны раслый:
«Лаэрт безгә король, Лаэрт — король!» — диләр.

Королева

Хата эзгә төшеп алар ничек улый;
Ялгыштыгыз, әй Дания этләре, сез!

Тышта тавышлар.

Король

Ишекләрне җимерделәр.

Коралланган хәлдә Лаэрт керә; артында даниялеләр.

Лаэрт

Кайда Король?
Әфәнделәр, анда чыгып торсагызчы.

Даниялеләр

Юк, керәбез.

Лаэрт

Көтегезче мине анда.

Даниялеләр

Ярый, яхшы.

Ишек артына чыгалар.

Лаэрт

Рәхмәт сезгә, нык саклагыз
Шул ишекне. Ерткыч король, табып китер

Әтиемне.

Королева

Син тынычлан, яхшы егет.

Лаэрт

Бер генә тамчы каным тыныч булса,
Мин табылдык малай булыйм, атам миңа
Ата түгел, анамның да саф йөзенә
Уйнашчы дигән тамга салган булсын!

Король

Гигантларча баш күтәреп килүеңнең[1]
Сәбәбе нәрсә, Лаэрт? — Керсен, тимә,
Гертруда; безнең өчен куркынма син,
Патшаның башы Хода ышыгында;
Хыянәт, бу ышыкны күрү белән,
Ниятеннән туктап калыр хәрәкәтсез.
Әйт, Лаэрт, нидән болай син ярсыган?
Калдыр аны син, Гертруда, — сөйлә, адәм.

Лаэрт

Кайда минем атам?

Король

Үлде.

Королева

Ләкин аның
Кулыннан түгел.

Король

Аңа ирек бир син,
Сорашсын теләгәнчә.

Лаэрт

Ничек үлде?
Мин үземне ишәкләргә иш иттермәм.
Тәмугка китсен сиңа буйсынуым!
Кап-кара шайтаннарга анттыр әгәр,
Олаксын баз төбенә әдәп саклау!
Чәчрим шунда — үземнекен итәчәкмен!
Ике дөньяң икесе дә берни тормый,
Теләсә ни булса булсын, — ләкин атам
Үлеме өчен үчем алмый тынмам.

Король

Кем сине тотып тора?

Лаэрт

Иркем генә;
Дөньяда башка берни туктаталмый;
Аз гына бер эш белән күп нәрсәгә
Ирешүнең дә юлын беләм.

Король

Яхшы, Лаэрт,
Атаңның үлемендә дөрес эшне
Беләсең килә икән, аның өчен
Карта уенындагы кебек, чухор ясап,
Дошманны да, дустыңны да бергә өеп,
Отканны да, отылганны бергә кыйнау
Кирәкмени?

Лаэрт

Юк, тик атам дошманнарын.

Король

Беләсең килә, димәк, аларны син?

Лаэрт

Әйе; аның дусларын мин, кочак ачып,
Пеликан кошы кебек, шәфкатемнән
Алар өчен каным коеп үләргә дә
Әзер.

Король

Хәзер син атаңның тугры угылы
Һәм затлы рыцарь булып сүзең әйттең. —
Атаңның үлемендә мин гаепсез,
Аның өчен ачы, тирән кайгыруым,
Көн нуры күзләреңә төшкән кебек,
Синең дә миләреңә үтеп керсен.

Даниялеләр
*(тыштан)*
Кертегез аны.

Лаэрт

Бу ни? Нинди тавыш?

Офелия кире кайта.

Аһ, ялкыным, куыр минем миләремне!
Әй, күз яшем, җитмеш кәррә ачы бул да
Яндыр ике күземне дә. Анттыр әгәр,
Синең шашкынлыгың өчен мин шундый үч
Алырмын, бизмән ягы авыр тартыр.
Әй, кадерле умырзаям, сеңлем минем,
Әй, сөйкемле Офелия! Әй, Ярабби,
Шулай ук соң кыз баланың акылы да
Карт кешенең гомере кебек фанимыни?
Мәхәббәтнең төбе — җанны фида итү;
Менә ул да, үз атасын ятратканга,
Аның өчен газиз башын бүләк иткән.

Офелия
*(җырлый)*

Йөзе ачык килеш гүргә ятты,
Һәлли генәм, һәлли һәлиләм;
Һәм каберенә ачы яшьләр акты —
Сау бул, җанкисәккәем.

Лаэрт

Үз акылында булып әгәр үч алырга
Чакырсаң да, җанны болай кузгатмассың!

Офелия. Сез җырга болай дип кушылыгыз: «Базлардан ыргып, идәндә биеп; әйлән, орчыгым, әйлән сынмыйча». Бу бер үз хуҗасының кызын урлаган приказчик булган.

Лаэрт

Монда саташу гына түгел, нәрсәдер бар.

Офелия. Менә сезгә бөтнек белән күгәрчен күзе; менә сезгә әрем; ул бик әче — үкенү кебек; менә сезгә колмак белән тилебәрән; а, сез әремне аерым билге итеп кадап йөртергә тиешсез[1]. Менә монсы чалма чәчәк, мин сезгә бераз умырзаялар да биргән булыр идем дә, ләкин алар, әтием үлгәч, бар да шиңделәр шул. Аны яхшы үлем белән үлгән, диләр. *(Җырлый.)*

Минем яраткан Робиным барсыннан чибәр.

Лаэрт

Уй-кайгыны, йөдәүне һәм җәһәннәмнең
Үзен дә ул гүзәллеккә әйләндерә.

Офелия
*(җырлый)*

Ул яңадан кайтмасмыни?
Ул яңадан кайтмасмыни?
Юк, юк, ул вафат;
Син дә тор нәүбәт;
Яңадан кайтмас.
Ак сакалы кардан аграк,
Чәче җитеннән дә чалрак;
Ул киткән, кайтмас;
Артыннан без дә елашмыйк,
Җаны ял тапмас!
Барлык христианнарның җаны өчен дә Алладан сорыйм. Алла сезгә хәерлесен кылсын.

Чыга.

Лаэрт

Күрәмсез сез, Ярабби!

Король

Син, Лаэрт, тукта,
Кайгыңны бүлешергә миңа таян.
Инде мине бу ханымнан мәхрүм итсәң,
Иң акыллы дусларыңны сайлап ал да
Сине-мине тыңлап, алар хөкем итсен.
Бу эшкә турыдан-туры яки читләп
Алар безне катышкан дип таба икән,
Кан хакына без патшалык таҗыбызны,
Башыбызны бар нәрсәбез белән кушып
Бүләк иттек сиңа; инде тапмый икән,
Син дә безгә үз сабырыңны бүләк итеп
Бирергә күн; без дә бергә синең белән
Каруыңны кайтарырга булышырбыз.

Лаэрт

Шулай, ләкин аның нидән үлүен һәм
Корал, кылыч, герб белән, йә башкача
Рыцарьлык йолалары белән аның
Күмелмичә, болай яшерен күмелүе
Дөнья ярып чакырып, җавап сорап тора,
Мин дә моңа җавап таләп итәчәкмен.

Король

Һәм таләп ит. Җинаятьнең башы кайда,
Балта шунда төшәр. Чыгыйк әле анда.

Китәләр.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Горатсио белән Хезмәткәр керәләр.

Горатсио

Минем белән кем сөйләшмәкче була?

Хезмәткәр

Матрослар, сэр, алар сезгә хат китердек, диләр.

Горатсио

Керсеннәр.

Хезмәткәр чыга.

Белмим, миңа дөньяның кем кай җиреннән
Хат җибәрер, принц Гамлет җибәрмәсә?

Матрослар керәләр.

Беренче матрос

Алла ярдәмчегез булсын, әфәндем.

Горатсио

Сезгә дә.

Беренче матрос. Ул теләсә яудыра, әфәндем. Әгәр дә, миңа әйткәннәренчә, сезнең исемегез Горатсио булса, менә сезгә хат, әфәндем, бу — Англиягә киткән бер илчедән.

Горатсио *(укый).* «Горатсио, шушы хатны укыгач та, бу матросларга король янына керергә мөмкинлек бир; боларда аңа дигән хатлар бар. Без диңгез өстендә ике көн дә бармадык, артыбыздан бик шәп коралланган пиратлар кудылар. Җилкәннәребез кечкенә булганлыктан, безгә дә, ирексез рәвештә, үз батырлыгыбызга таянырга калды. Кылыч белән кисешкәндә, мин алар корабына сикердем, нәкъ шул чакны алар безнең корабтан аерылып киттеләр дә, мин аларга ялгыз башым әсир төштем, алар минем белән шәфкатьле юлбасарларча эш иттеләр; алар үз эшләрен беләләр, мин дә аларга яхшылык белән кайтарырга тиешмен. Минем җибәргән хатларны ничек тә король кулына тапшырт, аннан үзең, үлемнән качкан кебек, бар тизлек белән минем яныма ашык. Колагыңа гына әйтәсе бер-ике сүзем бар, син аны ишеткәндә телсез калырсың; ләкин ул сүзләр, үзләренең мәгънәләренә караганда, бик җиңел сүзләр. Бу юньле матрослар сине минем яныма алып килерләр. Розенкранц белән Гилденстерн Англиягә сәфәрләрен дәвам итәләр; алар турында сиңа сөйлисе сүзләрем күп. Сау бул. Үзең белгәнчә — Гамлетың».

Әйдәгез, сез ул хатларны тапшырырсыз;
Аннан сезгә ул хатларны бирүчегә
Мине илтеп тапшырырга ашыгырсыз.

Чыга.

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сарайда башка бер бүлмә.
Король белән Лаэрт керәләр.

Король

Хөрмәтле этиеңне үтерүче
Миңа да хас[1] икәнлеген белгәч, хәзер
Мин акландым булса кирәк синең алда;
Син дә мине дустың итеп үз күңелеңә
Алырга тиешлесең.

Лаэрт

Шулай күренә;
Тик, әйтегез, ни өчен сез шулкадәрле
Җәзага лаек булган җинаятьле
Бу эшләрне бер җәзасыз калдырдыгыз?
Бигрәк тә сезнең тирән акылыгыз һәм
Иминлек моны сезгә кушып торгач?

Король

Аһ, бу махсус ике сәбәп аркасында.
Синең өчен алар, бәлки, юк сылтаудыр,
Ләкин алар минем өчен бик мөһимнәр.
Иң элек углы өчен анасының
Өзелеп тору хәтлесен ал; миңа килсәк,
Бәхеткәме әллә гөнаһ шомлыгына
Каршымы, җаным-тәнем Гертрудага
Шундый нык бәйләнгән ки, бер мәрәдә[2]
Әйләнүче йолдыз кебек, аннан һич тә
Аерылалмыйм. Инде хәзер эшне ачык

Суд алдына куялмауга тагын сәбәп —
Гамлетны киң халыкның яратуы.
Бу ярату — аның гаебен юып-аклап,
Агачны таш ясаган чишмә кебек,
Аның хәтта богавын да изге нәрсә
Ясавы бар. Мондый көчле җилгә каршы
Атар өчен, минем уклар бик җиңел шул:
Алар, бәлки, мин төзәгән җиргә китми,
Үз кулыма кире кайтып тияр иде.

Лаэрт

Лаеклы әткәемнән яздым шулай;
Өметсезлек яшь сеңлемне һәлак итте,
Югалганны кайта мактау мөмкин булса,
Камиллеге аның бөтен гасырларга
Ирешелмәслек нәрсә булып торыр иде.
Ләкин минем үчем кайтыр.

Король

Алдан алып
Бик борчылма. Бик ул хәтле мине көчсез,
Йомшакка санама син; хәвеф-хәтәр
Сакалымны тарта икән — аны юкка
Санамам; үзең дә син ишетерсең,
Атагызны мин яраттым, үземне дә
Яратам мин; шулай булгач, өмет итәм,
Үзең хәзер шуннан чыгып эш итәрсең.

Хат тотып Хәбәрче керә.

Нәрсә анда? Нинди хәбәр?

Хәбәрче

Хатлар, милорд,
Гамлеттан; монысы җәнабыгыз өчен,
Монысы Королева өчен.

Король

Гамлеттан? Кем
Аларны китерүче?

Хәбәрче

Диңгезчеләр,
Диләр, милорд; мин аларны күрмәдем дә;
Клавдио тапшырырга бирде миңа,
Ул аларны китерүчеләрдән алган.

Король

Сиңа укыйм, тыңла, Лаэрт. Калдыр безне.

Хәбәрче чыга.

*(Укый.)* «Бөек җәнап! Сезгә мәгълүм булсын, мине ялангач хәлдә сезнең корольлекнең җиренә китереп төшерделәр. Иртәгә сезнең мөбарәк күзләрегезне күрү шәрәфенә ирешүгә рөхсәтегезне сорыйм; һәм шунда, башта сездән гафу үтенеп, үземнең шулай кинәт кенә һәм бик сәер генә кайтып килүемнең сәбәбен мәгълүм итәрмен. Гамлет».

Бу ни дигән сүз? Барысы да кайтты микән?
Йә бу ялган булып, монда ул-бу юкмы?

Лаэрт

Кулын таныйсызмы?

Король

Кулы Гамлетныкы.
«Ялангач» ди. Монда аска төшереп әйтә:
«Ялгызмын» ди. Миңа киңәш бирә аламсың?

Лаэрт

Мин дә моны төшенә алмый торам, Король.
Ярый, кайтсын. Тиздән аның үз йөзенә
«Моны син эшләдең!» дип әйтүемне
Уйлау минем йөрәгемә дәрман кертә.

Король

Шулай булса, Лаэрт, шулай булыр микән?
Ә башкача ничек булсын? Минем сине
Җитәкләвемне телимсең?

Лаэрт

Әйе, милорд,
Ләкин мине килешергә кыстамагыз.

Король

Эш тик шунда — синең җаның тынгы тапсын.
Ул диңгездән куркып әгәр кире кайтса
Һәм юлына китәргә дә уйламаса,
Мин аңа хәзер генә миндә туган
Бер уйны башкарырга кушачакмын,
Ул аннан котылалмас, һәлак булыр.
Үлеменә һичбер гайбәт җиле исмәс,
Әнисе дә хәтта монда этлек сизмәс,
Бу очраклы бер хәл, дияр.

Лаэрт

Сез бу эшне
Мәгъкуль күреп, мин дә сезгә корал булу
Мөмкин икән — җитәкләгез мине, милорд.

Король

Шулай мәгъкуль. Син киткәннән бирле монда,
Гамлетның күз алдында, синең күркәм
Һөнәрләрең турында сүз аз булмады;
Шулардай аны бигрәк көнләштергән
Берсе булды һәм, минемчә, кечкенәсе.

Лаэрт

Нинди һөнәр соң ул, милорд?

Король

Ул егетләр
Бүрке өчен бизәк кенә, ләкин кирәк.
Картларга вәкарь биргән, саулык биргән
Постау туннар ничек булса, яшьләр өчен
Җилбердек чәч, ачкан изү, җилбәгәйлек
Шулкадәр үк хас нәрсә бит. Ике айлар
Элек монда килде Норман казагы бер.
Мин үзем французларны сугышларда
Күргән кеше, алар атта шәп йөриләр,
Бу егет әмма ләкин бу һөнәрдә
Бер сихерче дип әйтсәң дә була иде.
Ияренә төп шикелле утыра да
Атыннан шундый эшләр эшләтә кем, —

Әйтерсең ул шушы гаҗәп хайван белән
Бер җан, бер тән булып үскән. Ул күрсәткән
Җитезлекне, егетлекне мин һичвакыт
Уема да китерә алмаган булыр идем.

Лаэрт

Норман казагымы?

Король
Норман.

Лаэрт

Башым белән
Ант итәм, ул — Ламонд!

Король

Әйе, нәкъ ул үзе.

Лаэрт

Мин аны яхшы беләм; ул чынлап та
Күргергә ямь, бөтен илләр өчен бизәк.

Король

Сине ул бер һөнәрдә үзеннән дә
Өстен саный икәнлеген әйтеп бирде.
Бигрәк тә син кылыч уены уйнаганда
Үзеңне якларга бик оста икән.
— Әгәр дә, — ди, — синең берәү-берәү белән
Җиңешкәнне карап торсаң, тамаша! — ди;
Безнең Норман казаклары синең белән
Кизәнешкә чыктылармы — күз язалар,
Исәпләрен ялгышалар, — дип ант итте.
Аның бу мактаулары Гамлетның, сэр,
Көнчелеген шулкадәрле кабартты ки,
Бөтен уе — син тиз микән кайтырсың да,
Ул да шунда синең белән көч сынашыр.
Хәзер шуннан килеп чыга...

Лаэрт
Нәрсә чыга,
Милорд?

Король

Лаэрт, сиңа атаң кыйммәтме иде
Яки синең, сурәттәге кайгы кебек,
Йөзең генә кайгырамы?

Лаэрт

Нәрсә өчен
Мондый сорау бирүегез?

Король

Атаңны син
Яраткансың, беләм, әмма шунсын беләм,
Ярату ул вакытына карап йөри;
Чаткысын да, ялкынын да заман ничек
Сүндергәнен эштә күреп сынап киләм.
Мәхәббәт ялкынының үзендә үк
Көйрәк кебек бернәрсә бар, аның утын
Шул көйрәге сүрелдерә; бернәрсә дә
Һаман гел-гел үсеп тормый, аша китсә,
Һәлак була; теләк барда эш үтәп кал,
Теләк тә бит саегучан; дөньядагы

Телләр, куллар, ихтималлар күпме булса,
Теләккә дә шулкадәрле комачау күп.
Калган эш — бушка гына «уф!» дию күк;
Уф дию ул, җиңеләйтсә дә, җанны ала.
Эшкә килик: Гамлет кайта, атаң углы
Икәнеңне сүздә генә түгел, эштә
Күрсәтергә син нишләмәк буласың, йә?

Лаэрт

Чиркәүдә очратсам да суям аны.

Король

Атаңны үтерүчене саклап калыр
Изге җир юк, үч алу ул чикне белми.
Син инде, ул чагында, менә нәрсә:
Үз өеңнән чыкма, Лаэрт. Синең чыкмый
Ятканыңны Гамлет кайткач үзе белер.
Без монда аңа сине бик нык мактап,
Теге Норман синең хакта әйткәннәрне
Икеләтә арттырып, без һөнәреңне
Тиңсез итеп күрсәтербез. Аннан соң
Башларыгыз өчен бәя билгеләп, без
Икегезне бергә китереп очратырбыз.
Ул — гамьсез, кия, күңелле, хәйлә белми,
Кылычларны сайлаганда карап тормас,
Син сиздерми, җиңел генә, кылычларның
Кайралганын сайлап кына алырсың да
Җитез чәнчеп атаң үчен кайтарырсың.

Лаэрт

Булды, риза; өстәвенә ул кылычның
Очын әле мин майлармын бер май белән.
Ничектер мин багучыдан бер май сатып
Алган идем; шундый зәһәр бер агу ул —
Аны сөрткән үткер пычак бер-берәүнең
Тәненә чак кына бер тиеп китсен,
Дөньяда ай астында төнлә үскән
Ни шифалы үләннәр бар — ул кешене
Үлемнән һичберсе дә коткара алмас.
Кылыч очын шул зәһәргә манармын мин.
Чак кына бер эләктердемме — ул үләчәк.

Король

Моны тагын төптән уйлыйк. Безнең эшкә
Бу чаралар вакыт белән мач киләме?
Эш чыкмаслык булып, әгәр шушы эштә
Безнең мәкер ачыла икән, ул чагында
Тотынганнан тотынмавың хәерлерәк:
Монсы барып чыкмый икән, алмашына
Икенче бер хәйләне дә әзер тоту
Кирәк безгә. Тукта, уйлап карыймчы мин.
Болай итсәк: сезнең уен өчен дип без
Тантаналы касә тотарбыз ич? Таптым!
Уенның кызуында, сез сусагач, —
Моның өчен син һөҗүмне кызу алып бар, —
Ул эчәргә сорар, шушы ихтималга
Аның өчен мин бер касә әзерләрмен,
Тик бер генә йотым йотсын, ул агулы
Ярасыннан котылса да, без максатка
Ирешербез. Ләкин тукта, нинди тавыш?

Королева керә.

Нихәл, Королевам?!

Королева

Тагын кайгы, кайгы,
Берсе артлы икенчесе; Лаэрт, сезнең
Сеңлегез суга баткан.

Лаэрт

Баткан? Кайда?

Королева

Агымсуның нәкъ өстенә иелеп торган
Бар бер тирәк, аның көмеш яфраклары
Дулкыннарга карап тора; Офелия
Шунда килгән, кулларында бау-бау чәчкә,
Кычытканнар, казаяклар, чалмабашлар.
Аннан тагы бар бит ут күк кызыл чәчкә,
Көтүчеләр атый ямьсез исем белән,
Ләкин безнең мондагы карт кызларыбыз
Аны мәет бармагы дип атап йөртә, —
Шул чәчкәләр бәйләмен ул шул тирәккә
Элеп, аны бизәмәкче булган, ахры;
Шуннан шул, ботагына элгән чакта,
Ул сынган да, үзе дә, шул чәчкәләрне
Тоткан килеш, агымсуга төшеп киткән.
Күлмәкләре җәелеп, ул су өстендә
Су кызыдай агып киткән. Үзе шунда
Бер хәтәр дә сизмәгәндәй, гүя суда
Яшәр өчен яратылган бер җан кебек,
Өзек-өзек иске җырлар җырлап барган.
Бу хәл озак бармаган тик, аның юеш
Киемнәре авыраеп, бичараны
Дулкыннардан упкыннарга, моңлы көйдән
Аны үлем кочагына алып киткән.

Лаэрт

Аһ, шуннан ул батканмыни?

Королева

Әйе, баткан.

Лаэрт

Син суларга гарык булдың, мескен сеңлем;
Сине тагы күз яшемә батырмыйм дип
Тыелам, ләкин шулай да шул елау безгә
Шулкадәр хас, күпме генә оялсак та,
Табигать үзенекен итә һаман
Һәм бездәге хатын-кызча йомшаклык та
Шул яшь белән бергә бездән агып китә.
Сау булыгыз, патша. Хәзер утлы сүзләр
Бөркер иде авызым; аны шушы ахмак
Күз яшьләрем буды.

Чыга.

Король

Калмыйк, атла, Гертруда;
Ярсуын мин аның көчкә-көчкә җиңдем,
Куркам ләкин ул яңадан кабынмасын.

Барыйк, калмыйк.

Чыгалар.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Каберлек.
Көрәк-китмәннәр күтәргән ике кабер казучы керә.

Беренче казучы. Соң, үзен-үзе үтереп котылмакчы булган кешене дин кушканча күмәргә ярыймыни?

Икенче казучы. Ярый дип әйтәм ич мин сиңа. Шуңа күрә дә җәтрәк каберен казуыңны бел. Мәетен караганнар инде, дин кушканча күмәрлек итеп тапканнар.

Беренче казучы. Ничек алай табалар ди алар! Ул үзен-үзе һөҗүмнән яклау өчен батып үлмәгән ич.

Икенче казучы. Шулай тапканнар, күрәсең.

Беренче казучы. Ул чагында ул үзен яклау өчен үзенә-үзе һөҗүм иткән булып чыга. Бүтәнчә була алмый. Менә аның законы ничек: әгәр дә мин үз иркем белән суга батсам, бу инде бер эшнең булганлыгын исбат итә. Һәрбер эш өч кисәктән тора: эш үзе бар, аңа ниятләнү бар, аны үтәү бар; шуннан сиңа хөкем: ул үз ирке белән баткан.

Икенче казучы. Юк, син тыңла әле, әфәндем, кабер казучы.

Беренче казучы. Әйтеп бетерергә бир. Менә монда су диик, әйбәт; менә монда — кеше, бик әйбәт. Әгәр дә кеше шул суга килеп, исеңдә тот — үзе килеп, батса, димәккем, ул теләсә дә, теләмәсә дә суга килгән була; әмма ләкин су аңа килеп аны батырса, ул чагында ул үзе батмаган була; шуннан сиңа хөкем: кем дә кем үз үлемендә үзе гаепле булмаса, ул үз гомерен үзе кыскартмаган була.

Икенче казучы. Шундый да закон бармыни?

Беренче казучы. Бар шул: җинаять законы.

Икенче казучы. Дөресен генә әйтимме? Әгәр дә ул аристократ кызы булмаса, аны дин кушканча күмеп тормаслар иде.

Беренче казучы. Нәкъ өстенә бастың. Шунысы да эчне кыра шул аның: бу әфәнделәр үзләрен батырсалар да, ассалар да, калган дин кардәшләренә караганда, моңа властьлары күбрәк. Бир әле минем көрәкне. Бел син: бакча казучы, җир казучы, аннан кабер казучыдан да борынгырак нәселле аристократлар юк, алар атабыз Адәм һөнәрен дәвам иттерәләр.

Икенче казучы. Атабыз Адәм аристократ булганмыни?

Беренче казучы. Иң башлап кулына корал тотучы — ул.

Икенче казучы. Аның коралы булмаган да.

Беренче казучы. Син нәрсә, мәҗүсме әллә? Аятьтә язганны ничек аңлыйсың син? Аятьтә әйткән бит: «Адәм казыды» дигән; бер коралсыз казый алыр идеме соң ул? Менә мин сиңа тагын бер сорау бирим, әгәр син дөрес җавап бирә алмасаң, тәүбә ит.

Икенче казучы. Әйдә бир.

Беренче казучы. Кем дөньяда таш остасына, кораб остасына яки балта остасына караганда да ныграк итеп әйбер ясый?

Икенче казучы. Кемме? Дар агачы ясаучы; ник дисәң — аның ясаганы меңнәрчә кешенең гомеренә җитә.

Беренче казучы. Миңа синең җавабың ошый, валлаһи; дар агачы яхшы нәрсә ул. Ләкин кемгә яхшы? Начар кешегә яхшы. Ә менә син дар агачын чиркәүдән дә нык ка чыгарып начар иттең; шуннан сиңа хөкем: дар агачы сиңа яхшы булып чыкты. Яле, яңадан әйтеп кара.

Икенче казучы. Кем дөньяда таш остасына, кораб остасына яки балта остасына караганда да ныграк нәрсә ясый дигәнеңнеме?

Беренче казучы. Әйе, миңа шуны әйтеп бир дә юлыңда бул.

Икенче казучы. Яхшы, хәзер әйтәм.

Беренче казучы. Йә, әйт.

Икенче казучы. Менә әйтә алмаганымны әйтәм.

Ерактанрак Гамлет белән Горатсио киләләр.

Беренче казучы. Башыңны да ватма ул хакта; чөнки аңгыра ишәкне күпме генә кыйнама, адымын тизләтми ул. Әгәр сиңа шул сорауны тагын да бирсәләр, син әйт, кабер казучы, диген; аның ясаган бинасы гарасат купканчы торачак. Барчы, кабакка барып, миңа бер шешә аракы китерче.

Икенче казучы чыга.

Беренче казучы
*(казый да җырлый)*

Яшь чагымда сөйгәндә лә сөйгәндә,
Сөю иң шәп эш дип сөйдем мин;
Гомерем зая, аһ, үткәрүне, уһ,
Иң күңелле эш дип белдем мин.

Гамлет. Әллә бу олан үзенең нишләгәнен дә сизмиме? Кабер казыганда җырламаса...

Горатсио. Күнеккән ул; шул нәрсә аны эшенә тыныч карарга өйрәткән.

Гамлет. Гел шулай була; кул аз хезмәт иткән саен, сизүе нечкәрәк була.

Беренче казучы
*(җырлый)*

Ләкин картлык килде поса-поса,
Карак кебек мине эләктерде.
Алып китте мине, күзем ачсам,
Мин белмәгән якка китерде.

Баш сөяген чыгарып ыргыта.

Гамлет. Бу баш сөягенең теле булган, кайчандыр ул җырлый алган; ә бу, туңбаш мужик, ничек аны атып бәрә. Әйтерсең бу сиңа беренче башлап кеше үтергән Кабилнең ияге! Хәзер шушы ишәк аны теләсә нишләтә алган бу баш Алланың үзен алдарга куәте җиткән бер политикның башы булырга мөмкин бит. Шулай түгелме?

Горатсио. Ихтимал, принц.

Гамлет. Яки берәр сарай хезмәткәренең «Хәерле иртәләр, әфәндем! Кәефләрегез ничек, гаять тә гыйззәтле вә хөрмәтле әфәндем!» диюче яки бу фәлән бер әфәнденең менгән атын мактап, шуның каршысына берәр нәрсә өмет итүче берәр фәләневнең башы булырга да мөмкин бит? Шулай түгелме?

Горатсио. Әйе, принц.

Гамлет. Соң шулай, әлбәттә. Ә хәзер инде бу — кортбикә ханымныкы; кимерелгән; каберче көрәге аның иякләрен җимерә; матур алмашыныш бу; шуны тагын безгә үз күзебез белән дә күреп ятарга кодрәтебездән килсә иде! Шулай ук соң бу сөяк кәкмәшә белән шар урынына сугылып йөрер өчен генә шулкадәр нәзек тәрбияләр күреп үсәргә тиеш булганмыни? Моны уйлагач кына да минем сөякләрем бүзли башлый.

Беренче казучы
*(җырлый)*

Һай китмән, китмән, кабер көрәге,
Җиңсез күлмәк — кабер күлмәге,
Аһ, бу шәп казылган кабердә
Кунак табар җайлы кунар җир.

Икенче баш сөяген чыгарып ыргыта.

Гамлет. Менә тагын берсе; нигә әле син аны берәр юрист башы түгелдер дисең? Кайда соң хәзер аның хөкем статьялары, хәйләләре, закон йөртүләре, чокчынулары, утыртулары? Нигә соң ул хәзер бу туң мужиктан үзенә пычрак көрәк белән суктырып тора да нигә бу мыскыллары өчен ул аны хөкемгә тартмый? Һм-м! Ихтимал, бу тәти егет үзенең заманында, авыр шартлар белән арендага җир биреп, шуңа икешәр кешене кәфил итеп, төрле салым, штрафлар белән эш иткән зур бер алпавыт булгандыр. Шулай ук соң аның үз җирләреннән алган бөтен табышы шул үз башына бер уч пычрак балчык чәпәтер өчен генә булды микәнни? Аның үзен икешәр катлы шартнамәләр белән тәэмин иттерүләре бүген аңа шул ике кәгазь буйлыгы да җир тәэмин итә алмаслармыни? Аның аренда кәгазьләре, белмим, үзе яткан бу тартмага гына сыяр иде микән? Инде шул кәгазьләрнең хуҗасына бары шушы тартма гына тигән?

Горатсио. Бар тигән нәрсә шул, принц.

Гамлет. Пергамент кәгазен тәкә тиресеннән ясыйлар бит.

Горатсио. Әйе, принц, аннары бозау тиресеннән дә.

Гамлет. Шуннан тәэминат эзләүче кешеләр үзләре дә тәкә белән бозаулар. Мин бу олан белән сөйләшеп карыйм. Әй, мут, кем кабере бу?

Беренче казучы

Минеке, сэр.

*(Җырлый.)*

Аһ, бу шәп казылган кабердә

Кунак табар җайлы кунар җир.

Гамлет. Кабер эчендә көенчә дә ялган сөйләп торгач, синеке буласы хак ансы.

Беренче казучы. Сез, әфәндем, аның тышында, ә мин эчендә булгач, ул минеке. Шулай булгач, мин ялганламыйм.

Гамлет. Менә шул минеке диюең ялган инде. Каберне бит тере кеше өчен түгел, үлек өчен казыйлар.

Беренче казучы. Алай ялган булса, бу, әфәндем, тере ялган. Ул тота да миннән сезгә сикерә.

Гамлет. Нинди ир заты өчен моны казыйсың?

Беренче казучы. Бернинди ир өчен дә түгел, сэр.

Гамлет. Ул чагында — нинди хатын-кыз өчен?

Беренче казучы. Хатын-кыз өчен дә түгел.

Гамлет. Кемне күмәргә тиешләр соң?

Беренче казучы. Дөньяда чагында хатын-кыз булып яшәгән бер кешене, сэр, ләкин ул, Алла рәхмәт итсен, хәзер инде мәет.

Гамлет. Кара ничек дөрес суктыра бу наян! Моның белән саграк сөйләшергә кирәк, югыйсә ул үзенең кинаяле сүзләре белән безнең дә морҗаны ябар. Валлаһи, Горатсио, мин бу өч ел эчендә шуны күрәм, барысы да хәзер телгә шундый чарланды, мужикның аяк очы әфәнделәрнең үкчәсенә басып, сөяле чыкканчы сыдыра. Күптәнме кабер казыйсың син?

Беренче казучы. Елның көннәреннән бер көнендә — мәрхүм Король Гамлетның Фортинбрасны җиңгән көненнән алып казыйм.

Гамлет. Күптәнме соң ул эшкә?

Беренче казучы. Сез үзегез әйтеп бирә алмыйсызмы? Моны һәрбер тиле әйтеп бирер. Нәкъ шул көнне Гамлет дөньяга килде; әлеге акылыннан шашып Англиягә җибәрелгән бар ич бер?

Гамлет. Менә ничек! Ни өчен аны Англиягә җибәргәннәр икән соң?

Беренче казучы. Шул, акылдан шашкан өчен. Анда ул исен җыяр; хәер, анда исен җыймаса да, кирәге шулхәтле.

Гамлет. Нигә?

Беренче казучы. Англиядә — анда аны сизәләрмени? Анда бит бар да аның үз іше, акылдан шашкан халык.

Гамлет. Ничегрәк шашкан икән соң ул?

Беренче казучы. Бик сәер генә диләр үзен.

Гамлет. Ничек инде ул «сәер»?

Беренче казучы. Тоткан да шашкан, билләһи.

Гамлет. Юк, шашу нинди җирлектә килеп чыккан?

Беренче казучы. Менә шушы Дания җирлегендә инде. Мин дә шул җирдә малай чактан бирле кабер казыйм бит, кеше булгач та; менә инде утыз ел.

Гамлет. Кеше җирдә ни гомер черемичә ята?

Беренче казучы. Ничек әйтим, анысы инде кешенең үлгәнче черемәгән булуына карап. Хәзерге көнне шундый тере мәетләр китте — үзенең җеназасына да көчкә генә килеп җитә. Шундый булмаса, сигез-тугыз еллап ята болай. Тире иләүче, әлбәттә, тугыз ел ята.

Гамлет. Ни өчен ул башкалардан озаграк ята соң?

Беренче казучы. Ни өчен булсын, һөнәре шундый, әфәндем, аның эшендә үзенең тиресе шулкадәр иләнгән була — аңа тиз генә су үтми. Ә су дигәнең, беләсегез килсә, мәетеңне черетергә дигәндә, беренче маһир инде; менә тагын баш сөяге. Җирдә нәкъ егерме өч ел яткан бу.

Гамлет. Кемнеке ул?

Беренче казучы. Иң мут, иң шаталак кеше иде бу олан. Кемнеке булыр дип уйлыйсыз?

Гамлет. Юк, мин белә алмыйм.

Беренче казучы. Сөяген үләт себергере, шамакай! Бермәлне ул, беләсезме, бер шешә кызыл аракыны тотты да минем башыма койды! Шушы баш сөяге! Бу, әфәндем, король мәзәкчесе Йорик башыныкы.

Гамлет. Шушымы?

Беренче казучы. Нәкъ шушы.

Гамлет. Яле, күрим. *(Баш сөяген ала.)* Вай, бичарам Йорик, вай! Мин белә идем аны, Горатсио. Ифрат дәрәҗәдә сүзгә җор кеше иде, юкны уйлап чыгарырга — ул иде. Мине бер мең мәртәбәләр генә аркасына атландырып йөрткәндер. Ә хәзер моны уйласам гына да күңелләрем укшый, җаннарым әйкала. Менә монда аның мине үпкән иреннәре булган бит; белмим, мин аны ничә мәртәбәләр генә үпкәнмендер. Кая соң хәзер синең ул шуклыкларың, шатлыктан сикеренүләрең, җырларың? Корольнең табындашларын көлдереп үтерә торган көлке кыланышларың? Ичмасам, үзеңнең тешсез авызыңнан кө-

ләрлек кенә бер тешле сүзең дә калмадымыни хәзер? Салындымы шыр иягең? Бар, хәзер берәр ханымның бүлмәсенә барып кер дә аңа әйт инде, иннекне битеңә ике илле итеп яксаң да, барыбер актыгында менә шушы кыяфәткә керерсең, диген; бар, шуның белән үзен көлдереп кара! Горатсио, син миңа бер нәрсәне әйт әле.

Горатсио. Нәрсәне, принц?

Гамлет. Александр Македонскийны да, гүргә кергәч, шушындый кыяфәткә кергәндер дип уйлыйсыңмы син?

Горатсио. Нәкъ шушындый.

Гамлет. Аннан да шундый ук ис килгәнме? Фу! *(Баш сөяген җиргә төшерә.)*

Горатсио. Бөтенләй шундый ис, принц.

Гамлет. Бара торгач, шушындый түбән утильгә әйләнәбез икән, Горатсио. Ни өчен әле без данлы Александрның мөбарәк тәннәре иң ахырында мичкә бөкесенә әйләнеп калгандыр дип уйлый алмыйбыз?

Горатсио. Ул кадәресе бигрәк әкәмәтчә уйлау булыр иде.

Гамлет. Юк, дөрестән дә. Без бик тыйнак рәвештә генә аның эзеннән барып, менә болай ихтимал йөртә алабыз: Александр үлгән; Александр тузанга әйләнгән; ә тузан ул — җир; җирдән без балчык алабыз; ә ни өчен без аннан ясалган балчык бөке белән сыра мичкәсен тыга алмыйбыз?

Бөек Цезарь үлде, чергән тәне,
Бәлки, хәзер ярык каплыйдыр
Җирне дер селкеткән ир кулы, аһ,
Кыш җиленнән безне саклыйдыр.
Акрын, ләкин китә төшик, Король килә.

Җеназа процессиясе белән поплар һ.б. керә. Офелия гәүдәсе артыннан Король,
Королева, сарай хадимнәре керәләр.

Королева, сарай халкы... Кемне күмү?
Нинди шыксыз йола белән? Димәк, мәет
Аптыраудан үз-үзенә кулын салган?
Данлылардан, ахры. Читтән карыйк әле.

Горатсио белән бер якка ышыкланалар.

Лаэрт

Әйтегез, тагын нинди йола үтик?

Гамлет

Бу — Лаэрт; булган егет. Кара.

Лаэрт
Тагын
Нинди йола үтик?

Беренче поп

Аны җирләү өчен
Без кулдан килгән кадәр рөхсәт бирдек.
Үлемендә шик зур, әгәр өстән боерык
Безнең чиркәү кагыйдәсен үзгәртмәсә,
Ул арусыз җирдә, сурлар өрелгәнчә
Шулай яткан булыр иде; җеназалар
Уку түгел, аңа төрле кирпеч-ташлар
Ыргытылган булыр иде. Аның өсте
Хәзер сафлык төсе — гөлләр белән балкый,
Кыңгыраулар сугыла, зурлап озату бу.

Лаэрт

Алайса, артык берни тиеш түгел!

Беренче поп

Берни тиеш түгел; аны әгәр дә без
Үз үлеме белән үлгән кебек күреп
Җырлап күмсәк, дин йоласын мыскыл иткән
Булыр идек.
Лаэрт

Иңдерегез аны җиргә.
Гаепсез, гүзәл тәннәреннән аның
Миләүшәләр чәчкә атсын. Тыңла мине,
Рәхимсез поп, син тәмугта үрле-кырлы
Сикергәндә, минем сеңлем оҗмахларда —
Күктә булыр...

Гамлет

Ничек? Гүзәл Офелия?

Королева
*(чәчкәләр сибеп)*

Гүзәлгә гүзәл гөлләр, кил, бәхил бул!
Киленем булмассыңмы диеп сине
Гамлетыма көткән идем; әй, матур кыз,
Гөлләр белән кабереңне түгел, синең никах
Ятагыңны бизәрмен дип көткән идем.

Лаэрт

Аһ, сине якты акылын, исләреннән
Явызларча мәхрүм иткән мәлгунь җанның
Башына җитмеш җиде бәла төшсен иде!
Туфрагын ыргытмагыз, соң мәртәбә
Кулларыма кочыйм аны, хәзер инде
Күмегез мәет белән мин — терене,
Өегез шундый туфрак, — ул борынгы
Фели тавы яки күккә тигән Олимп
Тавыннан да биегрәк булып ашсын!

Гамлет
*(алга чыгып)*

Кем ул шундый үз хәсрәтен зурлап әйткән?
Кемнең ачы аһ-зарлары йолдызларга
Кадәр җитеп, аларны да шаккатырып
Юлларыннан туктатырга көче җитә?
Данияле Гамлет — мин ул!

Кабер эченә сикереп төшә.

Лаэрт

Җәһәннәмгә
Китсен җаның!

Буышалар.

Гамлет

Изге түгел синең догаң.
Үтенәм, җибәр минем бугазымны.
Аннан соң, мин алай бик тиз кабынучан
Булмасам да, ләкин миндә нindидер бер
Хәтәрлек бар, саклanганың яхшы аннан.
Ал кулыңны.

Король

Аерыгыз!

Королева

Гамлет, Гамлет!

Барысы бергә

Әфәнделәр!

Горатсио

Милорд, принц, борчылмагыз!

Сарай хадимнәре аларны аералар, алар кабер өстенә килеп чыгалар.

Гамлет

Шулай, ләкин керфекләрем керфегемә
Кагылудан туктаганчы, бу эш өчен
Аның белән сугышудан туктамам мин.

Королева

Ул нинди эш, углым?

Гамлет

Офелияне мин
Сөйдем; аның кырык меңләп туганнары
Булса да, сөюләрен бергә җыйсаң,
Минекенә җитмәс иде. Ул кыз өчен
Нәрсә эшли алыр идең?

Король

Ах, шашкан ул
Лаэрт.

Королева

Алла хакы өчен, кызган аны.

Гамлет

Юк, әйт миңа, күрсәт, нәләт, нишләр идең?
Үксер идең йә ач торыр, сугышыр идең?
Җәфаланыр, Нил елгасын төбенәчә
Эчәр идең, крокодилны ашар идең?
Мин дә шуны булдыра алам. Шыңшыргамы
Килдең бире, миңа булган ачуыңнан
Каберенәме сикереп төштең? Аның белән
Тере килеш күмеләсеңме? Синең кебек
Мин дә әзер. Таулар диеп әйткән булдың,
Әнә безгә миллион гектар җир өйсеннәр,
Туфрагыбыз күккә җитеп көнгә көйсен.
Осса тавы торып калсын сөял хәтле,
Юк, әгәр син мактанасың икән, мин дә
Синең хәтле мактана алам.

Королева

Шашыну бу;
Ярсуы озак бармас, басылыр да
Аннары ул, йомыркадан яңа чыккан
Бәбкәләрен иркәләгән күгәрчендәй,
Тыйнак кына булып калыр.

Гамлет

Әйтегез, сэр,
Минем белән ник сез болай эш итәсез?
Мин яратып килдем сезне һаман. Хәер,
Геркулес, тели икән, җир җимерер,
Мәче мырлар, эт тә һаман йөри бирер.

Чыга.

Король

Горатсио, сорыйм синнән, бар артыннан.

Горатсио чыга.

*(Лаэртка.)*
Онытма кичә әйткән сүзне, чыда;

Без эшне тиз соңына җиткерербез.
Гертруда, бар, углың саксыз йөремәсен,
Бергәрәк бул. *(Лаэртка.)* Бу кабергә тере һәйкәл
Утыртсак, тынычлыкка без дә тиздән
Ирешербез, хәзер түзем кирәк бездән.

Чыгалар.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сарайда бер зал. Гамлет белән Горатсио керәләр.

Гамлет

Ул турыда җитәр, күчик икенчегә:
Бөтен булган эшне яхшы хәтерлимсең?

Горатсио

Ничек хәтерләмим, принц!

Гамлет

Сэр, шуннан соң
Йөрәгемдә шундый көрәш купты минем,
Йокым качты, богауланган фетнәчедән
Яманрак хәлдә тойдым үз-үземне;
Кинәттән... аһ, яшәсен шул — «кинәттән»лек,
Кайчагында тирән акыл аптыраган
Эштә шушы «кинәттән»лек ярдәм итә,
Акыл башта бер төрлегә план корса,
Тәкъдир башка төрле очлый.

Горатсио
Ул булгалый.

Гамлет

Әйе. Шуннан аркама мин бушлатымны
Салып кына каютамнан чыктым шулай.
Үзләрен караңгыдан, капшый торгач,
Эзләп таптым. Пакетларын эләктердем дә
Үз бүлмәмә кире кайттым. Шундый каты
Кыюландым, курку дигән нәрсә әдәп
Белми бит ул, — тоттым ачтым хөкүмәтнең
Яшерен хатын! Нәрсә күрәм, Горатсио,
Аһ, патшаның хыянәте! Язган фәрман:
Китерелгән башта бик күп дәлил; шуннан
Дания һәм Англия дәүләтенең
Интересын күздә тотып, шуңа каршы
Торучы куркынычлы бүкәй итеп
Мине, ха-ха, мине хәтта дию итеп
Күрсәткән дә, шушы хатны уку белән
Мине тотып, бер минут та кичекмәстән,
Балта чарлап алырга да вакыт бирми,
Башым чабып ташланырга тиеш, дигән.

Горатсио
Мөмкинме бу?

Гамлет

Менә ул хат; буш вакытыңда
Укы. Шуннан, йә, беләсең киләме, мин
Нишләдем?

Горатсио
Үтенәм сездән.

Гамлет
Шулай итеп,

Мин хыянәт ятьмәсенә эләккән булгач,
Эшемә тотынганчук, зиһнем инде
Уйный башлап, үзе тапты чарасын да:
Утырдым да мин икенче фәрман яздым;
Матур итеп яздым; элек чакны безнең
Түрәләр кебек ачык язуны мин
Оят санап, бу һөнәрне ташларга дип
Күп тырыштым, ләкин хәзер ул миңа бик
Зур хезмәт күрсәтте, сэр. Йә, беләсең
Киләме, мин нәрсә яздым?

Горатсио

Әйе, принцым.

Гамлет

Корольнең үтенгәне сезгә шушы:
Әгәр дә Англия хөкемдары
Аның туры бер вассалы булса һаман,
Әгәр дә арадагы дуслык хисе
Хөрмә кебек чәчкә атып торса һаман,
Әгәр дә бу дуслыкның башакларын
Бәйләр өчен дөнья үзе тасма булса,
Әгәр дә... тагын шундый бик күп мөһим
«Әгәр»дән соң, шушы хатны юлыгып алып
Укыгач та, азын-күбен уйлап тормый,
Кичекмәстән, тапшыручы илчеләрне
Иман әйтергә дә бирми, шундук тотып
Үтерергә куша.

Горатсио

Нинди печать белән?

Гамлет

Аһ, монда да миңа бәхтем ярдәм итте:
Әтинең печатен мин үз янымда
Йөртә идем. Ул Дания дәүләтенең
Печате белән бер үк төсле. Хатны,
Кулым куеп, тегеседәй печатьләдем,
Аннан аны, сиздермичә, элеккесе
Урынына илтеп салдым. Иртә белән
Пиратлар белән сугыш булды безнең.
Калган ягы сиңа мәгълүм.

Горатсио
Алай булса,
Гилденстерн, Розенкранц икесе дә
Хәзер анда сәфәр итте?

Гамлет
Ә нишләргә?
Үзләре теләп алар шул хезмәткә
Алынган кеше булгач? Алар минем
Вөҗданыма кагылмыйлар. Үзләренең
Кирәксезгә куштанланып йөрүләре
Нәтиҗәсе. Зур куәтле ике дошман
Пычакка-пычак килеп бер-берсенә
Кизәнгәндә, ике пычак арасына
Тыгылучы вак кешеләр хәле хәтәр.

Горатсио

Нинди Король диген моны!

Гамлет

Йә, син ничек
Уйлыйсың, әтиемнең башын ашап,
Әниемне рисвай иткән бу кешенең,
Сайланачак урыным белән өметемнең
Арасына килеп кергән бу кешенең,
Башымны ашар өчен үземә дә
Шундый явыз кармак салган шул кешенең
Хәзер шушы кулым белән эшен бетерү
Турыдан-туры минем бурычым түгелме соң?
Моннан соң тәнебезне шул кутырдан
Ашату үзе шомлык түгелме соң?

Горатсио

Эшнең ничек беткәнлеген анда аңа
Хәбәр итәр Англия бик тиз ара.

Гамлет

Тиз итсә дә, бу «ара» бит минем кулда.
Адәм гомере — «эһ» дигәнче; тик шунсына
Бик кайгырам, Горатсио, мин Лаэртның
Алдында үз-үземне оныттым шул.
Үземнең язмышымның борылышында
Күрәм аның язмышының чагылышын.
Аның белән килешим, дим; ләкин аның
Мактанчык, масаючан кайгыруы
Җенләндерә мине.

Горатсио

Акрын, кем ул килә?

Озрик керә.

Озрик. Заты галиегезнең Даниягә исән-сау әйләнеп кайтуы белән!

Гамлет. Гаять тәшәккер итәм, сэр. *(Горатсиога акрын.)* Бу чикерткәне беләмсең син?

Горатсио *(Гамлетка акрын)*. Юк, принцым.

Гамлет *(Горатсиога акрын)*. Бәхетең, алайса. Аны белү — үзе кимчелек. Аның җир-суы күп, уңышлы җирләр. Ләкин хайван хайваннарга баш булдымы — абзарын патша түр башына ук китереп кора. Бу — аңгыра тартар, ләкин, әйткәнемчә, пычрак сазлар алпавыты.

Озрик. Принц хәзрәтләре, заты галиегезнең әгәр дә вакыты булса, мин сезгә Король хәзрәтләренең кайбер сүзләрен тапшырыр идем.

Гамлет. Әфәндем, мин моны күңелемнең иң нечкә җире белән бирелеп тыңлыйм. Эшләпәгезне үз урынында куллансагыз ла ул баш өчен.

Озрик. Җәнабе галиегезгә зур рәхмәт. Бик эссе шул.

Гамлет. Юк, миңа ышансагыз ла, бик каты салкын. Җиле төньяктан.

Озрик. Чыннан да, бик каты салкын, милорд.

Гамлет. Шулай булса да, мин әйтер идем, минем гәүдәм өчен бу гаять дәрәҗәдә эссе, бик бөркү.

Озрик. Ифрат дәрәҗәдә, милорд. Шундый бөркү, гүяки ничек әйтергә дә белмим. Шулай исә дә, Король хәзрәтләренең боерыгы буенча, сезгә белдереп куярга җөрьәт итәмен ки, ул сезнең башыгыз өчен бик зур сумма куеп пари тота, милорд.

Гамлет. Зинһар өчен, онытмасагыз ла. *(Аны эшләпәсен кияргә мәҗбүр итә.)*

Озрик. Юк, валлаһи, миңа болай да җайлы, валлаһи. Сэр, монда яңарак кына сарайга Лаэрт килде; әгәр дә ышансагыз, менә җитмеш җиде төрле камиллек иясе; ул мөгамәләсенең нәзеклеге, ул кыяфәтләре; башыннан аягына хәтле чын рыцарь! Бәясен җиткереп кенә, уенсыз әйтсәм, ул инде аристократлыкның картасы да, календаре да. Сез анда рыцарь теләгән һәммә сыйфатларның бөтен таблицасын табарсыз.

Гамлет. Әфәндем, сезнең билгеләвегез аның сыйфатларына бер генә кимчелек тә китерми; дөрес, аның сыйфатларын инвентарь шикелле санау белән генә аның камиллеккә бу хәтле тиз ашуы артыннан сөйрәлеп җитү мөмкин түгел, бу тик хәтернең арифметикасын гына чуалта икәнен дә беләм, вә ләкин шулай булса да, аны чын мактау йөзеннән мин шуны да өстәп әйтә аламын ки, аның җаны гаять дәрәҗәдә асыл сорттан; ә инде аның камиллекләре шул дәрәҗәдә кыйммәтле вә шул дәрәҗәдә сирәк нәрсәләр ки, турысын гына әйткәндә, дөньяда аның бер охшашы булса, ул да үзенең көзгесе булыр, әмма инде бичара рәвештә аңа иярүчеләр бары тик аның коры күләгәсе генә булып калырлар.

Озрик. Заты галиегез аның турында бер дә хатасыз сөйли.

Гамлет. Хуш, шуннан соң да нәрсә калды, сэр? Ни өчен соң без ул әфәндекәйне үзебезнең тупас сулышларыбыз белән тончыктырабыз?

Озрик. Сэр?

Горатсио. Аңлашылмыймыни? Гадирәк телдә сез аны, әлбәттә, аңлар идегез, сэр!

Гамлет. Ул әфәндене телгә алуыгызның хикмәте ни?

Озрик. Лаэртнымы?

Горатсио *(Гамлетка акрын)*. Янчыгы бушады, бөтен алтын сүзләрен тотып бетерде, ахры.

Гамлет. Әйе, Лаэртны, сэр.

Озрик. Уйлыйм ки, сез белә торгансыздыр...

Гамлет. Телим ки, сез аны белә күрсәгез лә. Хәер, чынын гына әйткәндә, сезнең аны белүегез миңа әллә ни хөрмәт китерми. Шуннан, сэр?

Озрик. Уйлыйм ки, сез Лаэртның нинди камиллекләргә ия булуын белә торгансыздыр?

Гамлет. Шулай булса да, мин, аның белән тиң камиллек дәгъва итү булмасын өчен, моны беләм дип әйтергә кыя алмыйм. Икенче кешене камил белү бит үзеңне камил белү дигән сүз.

Озрик. Мин аның корал тота белүен әйтмәкче булам, сэр; гомуми фикергә караганда, бу һөнәрдә аның тиңдәше юк.

Гамлет. Кораллары нәрсәләр соң?

Озрик. Пычак та хәнҗәр.

Гамлет. Ике коралы булды. Хуш, тагын?

Озрик. Король, сэр, аның каршына алты бәрбәр аты[1] куеп бәхәсләште, Лаэрт шуңа каршы, минем ишетүемчә, сигез француз пычагы белән хәнҗәрләр куйган; бөтен мичәүләре белән бергә, димәк ки, бил каешы, кыннары, таккыч баулары — бар да шунда керә. Шулардан өчәүсе, валлаһи, гаять тә нечкә зәвык белән эшләнгән, саплары гаять тә нәфис; таккычлары гаять дәрәҗәдә купшы һәм бик күңелле әкәмәтләр.

Гамлет. Сез «мичәүләре белән» дип нине атыйсыз?

Горатсио *(Гамлетка акрын)*. Уйлаган гына идем сезгә тагын искәрмә ясарга туры килер дип.

Озрик. Мичәү, сэр, шул хәнҗәр баулары, каеш тарткычлар инде.

Гамлет. Әгәр дә без билебезгә кылыч урынына туп арбалары тага торган булсак, бу әйткәннәрегез, бәлки, туры да килер иде. Ярый, шуңа хәтле алар бәйләвеч кенә булып торсын, ди, шуннан? Шулай итеп, алты бәрбәр аты каршысына алты француз пычагы, аннан өч пар гаять тә нечкә зәвык белән эшләнгән бәйләвеч, таккычлар булды; Даниянекенә каршы куелган француз әйбере шул икән. Нәрсә өчен куела соң бу әйберләр?

Озрик. Король, сэр, шуңа кул суга, сэр: Лаэрт унике мәртәбә кизәнгәндә, сезгә өчтән дә артык тидерә алмас, ди; Лаэрт уникедән тугызын тидерергә итә; әгәр дә заты галиегез мәрхәмәт итеп җавап бирсә, моны хәзер үк сынап карарга мөмкин булачак.

Гамлет. Әгәр дә мин «юк» дип кенә җавап бирсәм?

Озрик. Юк, мин — әгәр дә сез ярышны кабул иттем, дип җавап бирсәгез димәкче булам.

Гамлет. Сэр, мин монда залда йөрим; Король хәзрәтләренә кирәк булса, бу минем гадәттәге ял вакытым, хәнҗәрләр китерелсен; әгәр дә ул егеткә бик кирәк булып, Король дә үз ниятендә тора икән, мин, булдыра алсам, аның өчен бәхәсне отармын, булмый икән — мин чәнчелү хурлыгыннан башка үземә бернәрсә дә алмам.

Озрик. Нәкъ үзегез әйткәнчә итеп сүзләрегезне тапшыра аламындыр?

Гамлет. Шул рухта, сэр, анда үзегез булдыра алган хәтле бизәкләрсез.

Озрик. Заты галиегезгә чын ихласым белән тапшырылам.

Гамлет. Сезнең, бәндәгез...

Озрик чыга.

Үзен-үзе алдан ук тапшырып куеп яхшы итә бу. Югыйсә башка беркем дә аны тәкъдим итмәс иде.

Горатсио. Күкәйдән чыгып җитмәгән, кабыгы башында килеш чапты китте бу тәкәрлек[1].

Гамлет. Ул сөт имә башлаганчы ук, анасының күкрәгенә комплиментлар әйтмичә, авызына имчәк алмаган. Шушы кеше, тагын шуның хәтле генә сикерә алган бер ише халык — менә кемнәр безнең заманыбызның шаккаткач кешеләре; хәлбуки заманның рухы дигәннән алар бары тик тышкы манерны гына кабул иткәннәр; бу ниндидер күбек боткасы, шуның ярдәме белән алар иң ахмак, көчәнеп чыгарылган тәгъбирләр әйтәләр; ә син сынар өчен генә бер өр — куыклар шундук шартлар.

Лорд керә.

Лорд. Принц, Король хәзрәтләре сезгә сәлам тапшыру өчен яшь Озрикны җибәргән иде, ул кайтып сезнең аны залда көтә икәнегезне хәбәр итте. Инде ул белергә җибәрде, сез Лаэрт белән җиңешергә дигән уйда торасызмы яки кичектерергә уйлыйсызмы?

Гамлет. Мин үз ниятләремдә нык торам, ул ниятләр Корольнең теләгенә туры килә; ул әйтсә — мин әзер; хәзерме, башка вакыттамы, тик хәзерге шикелле мәелем генә булсын.

Лорд. Король, Королева белән бар да бергә монда төшәләр хәзер.

Гамлет. Хәерле сәгатьтә.

Лорд. Королева сездән, уенны башлаудан элек, Лаэрт белән ничек тә йомшаграк булуыгызны сорый.

Гамлет

Ул миңа яхшы киңәш бирә.

Лорд чыга.

Горатсио. Сез бәхәсне оттырасыз, принц.

Гамлет. Уйламыйм. Ул Франциягә киткәннән бирле мин һаман күнектем бит. Бәхәснең тигезсез булуы минем файдага. Мин отачакмын, ләкин болар бар да ничек минем эчемне пошыра икәнен син күз алдыңа китерә алмыйсың. Хәер, ансы юк нәрсә.

Горатсио. Ай-һай, принц...

Гамлет. Ансы ахмаклык аның, шуның белән бергә ул алдан сизенү кебек бернәрсә, хатын-кызны булса, бәлки, туктатыр да иде.

Горатсио. Әгәр бер эшкә күңелегез тартмаса, шул сизенүгә колак салыгыз. Мин каршыларына барыйм да, сезнең теләгегез юклыгын әйтеп, килүләрен туктатыйм.

Гамлет. Һичкайчан да. Безне бертөрле сизенү дә шикләндерми. Язмыштан тыш чыпчык та егылып төшми. Хәзер буласы — соңыннан булмый, соңыннан булмаска икән — хәзер була; хәзер булмаска икән — соңыннан бер буласы. Әзер тору — бөтен хикмәт тә шунда гына. Үзенең нәрсәдән аерылачагын беркем дә белми икән, аңардан иртә аерылды ни, соң ни, барыбер түгелмени? Ни булса, шул булыр.

Король, Королева, Лаэрт һәм лордлар, Озрик һәм башка хезмәткәрләр хәнҗәрләр һәм сугыш бияләйләре күтәреп керәләр; өстәл һәм аның өстендә эчемлек
савытлары.

Король

Кил, Гамлет, кил, кабул ит минем аша
Шушы кулны.
*(Лаэртның кулын Гамлет кулы белән тоташтыра.)*

Гамлет

Кичерегез рәнҗеткәнем
Өчен сезне, ләкин, рыцарь буларак, сез
Кичерегез мине. Чөнки бу затларның
Барына да мәгълүм, аннан үзегез дә
Ишеткәнсез булыр минем нинди авыр
Зәхмәт белән авыруымны. Сезнең намус,
Хисегезгә шулкадәрле каты тигән
Мөгамәләм, мин биредә игълан итәм,
Шашкынлыктан туган эш ул. Кем, Гамлетмы
Лаэртны җәберләүче? Һич ул түгел;
Бер җаны ике булып, әгәр Гамлет,
Үзен үзе белешмәстән, шул хәлендә
Лаэртны җәберләгән икән, бу эш
Гамлет эше түгел; моны тана Гамлет.
Кем гаепле? — шашкынлыгы. Димәк, Гамлет
Үзе дә җәберләнгән кешеләрдән.
Гамлетка, бичарага, үзенең үк
Шашкынлыгы дошман аңа. Шушы мәҗлес
Алдында миндә һичбер явыз ният
Булмавын игълан итәм, сез дә мине
Өй аркылы ук атып та, үзе белми
Туганын яралаган кеше итеп
Карагыз да киң күңелдән кичерегез.

Лаэрт

Ихтимал, күңелем минем мондый хәлдә
Үч алырга чакырырга тиештер дә,

Алай да мин моңа риза булам. Ләкин
Намуска килгән чакта, ул башка эш.
Анда аның үз законы, һәм әлегә
Намусның каты хөкемен хәл итүдә
Сыналган карт хакимнәрдән кем дә булса
Берсе торып, бу килешү минем өскә
Тап булып төшми диеп әйтми икән. —
Мин әлегә ул турыда килешә алмыйм.
Шуңа хәтле сез күрсәткән мәхәббәтне
Тик мәхәббәт итеп кенә кабул итәм
Һәм шуңа тугры калам.

Гамлет

Мин моңа шат,
Синең белән туры, гадел, туганнарча
Бергә-бер кылыч уенына чыгам.
Башладык, кайда кылыч?

Лаэрт

Миңа берсен.

Гамлет

Теләр идем, минем ипсезлегем, Лаэрт,
Сезнең файдагызга булып төшсен иде.
Минем янда сезнең данлы һөнәрегез
Караңгыда янып торган йолдызлардан
Ныграк янсын.

Лаэрт

Көләсез сез, принц.

Гамлет

Һич тә;
Кисәргә кулым бирәм.

Король

Кылыч тоттыр
Кулларына, Озрик, ә син, Гамлет туган,
Бәхәс нидән икәнлеген беләсең бит?

Гамлет

Әйе, милорд; әмма ләкин сез бәяне
Көчсез якка зур куйгансыз.

Король

Мин ансыннан
Курыкмыйм, миңа икегез дә бик билгеле.
Ул бик оста, ләкин шашкын.

Лаэрт

Икенчесен
Күрсәтегез, бу бик авыр.

Гамлет

Миңа таман.
Озынлыгы бар да берме?

Озрик

Әйе, принц.

Алар сугышка әзерләнәләр.

Король

Шәраб, шәраб өстәлләргә! Әгәр Гамлет
Беренче йә икенче кат һөҗүм итсә,
Йә өченче кизәнүне кире какса,
Коймадагы барлык туптан ут ачылсын,
Гамлетның сулышы киң, озын булсын
Өчен король касә күтәрәчәк һәм ул
Даниянең дүрт короле мирас итеп
Таҗына тага килгән җәүһәрдән дә
Кыйммәтлерәк асылташны касәсендә
Эретәчәк. Китерелсен касәләрең,
Король — Гамлет өчен эчә дигән сүзне
Барабаннар быргыларга, быргылар да
Тупчыларга, туплар — күккә, күкләр җиргә
Хәбәр итсен. Йә, башлагыз, хөкемчеләр,
Нык күз белән күзәтегез.

Гамлет

Башладык, сэр.

Лаэрт
Ягез, принц.

Сугышалар.

Гамлет

Бер.

Лаэрт

Юк.

Гамлет

Хөкем!

Озрик

Тию булды —
Һәм бик дөрес тию булды.

Лаэрт

Яхшы, тагын!

Король

Тукталыгыз, эчик. Гамлет, бу асылташ
Синеке булды. Синең саулыгыңа.

Быргылар, тыштан — туп тавышлары.

Бирегез аңа касә.

Гамлет

Башта сугышыйм.
Куегыз читкә, — ягез.

Сугышалар.

Тагын тиде.
Йә, ни дисез?

Лаэрт

Тиде, тиде, икърар итәм.

Король

Углыбыз җиңеп чыга.

Королева

Тәнгә калын,

Шуңа күрә тыны кыса. Менә минем
Кулъяулыгым, маңгаең сөрт; Королева —
Мин синең уңышың өчен эчәм, Гамлет.

Гамлет

Рәхмәт, анам.

Король

Эчмә, Гертруда!

Королева

Бик эчәсем
Килә минем, үтенәм, кичерегез, Король.

Король
*(читкә)*

Ул касәдә агу иде. Инде эш — соң!

Гамлет

Эчәргә минем әле форсатым юк,
Соңрак, әни.

Королева

Бирче, сөртим йөзеңне, кил.

Лаэрт

Падишаһым, хәзер чәнчәм аны.

Король

Ай-һай.

Лаэрт
*(читкә)*

Вөҗданыма каршы барып булса да, мин...

Гамлет

Ягез, Лаэрт, өченче кат. Шаяртмыйча;
Сорыйм, бөтен көчегезгә ташланыгыз.
Куркам, мине иркәлисез түгелме сез?

Лаэрт

Шулай димсез? Ягез, әйдә.

Сугышалар.

Озрик

Икесе дә
Бушка сукты.

Лаэрт

Менә сиңа алай булса!

Лаэрт Гамлетны яралый; алар сугыш кызуында кылычларын алмашалар да Гамлет
Лаэртны яралый.

Король

Аерырга! Үз-үзләрен белми алар.

Гамлет

Юк, тагын! Йә!

Королева ава.

Озрик

Һай, карагыз, Королева

Нишләде?

Горатсио

Икесе дә кан эчендә.
Хәлләр ничек, принц?

Озрик

Лаэрт, нәрсә булды?

Лаэрт

Үз авына үзе эләккән тәлләтәвеч
Хәле миндә, Озрик; үз хыянәтемә
Бик таман торырлык мин җәза таптым.

Гамлет

Королевага ни булды?

Король

Кан күрүгә
Һушыннан язды.

Королева

Юк, юк; шәраб, шәраб!
Әй Гамлетым, шәраб белән агуландым.

Үлә.

Гамлет

Аһ, явызлык! Һәй, бикләгез ишекләрне!
Хыянәт! Тиз эзләгез, башы кемдә?

Лаэрт ава.

Лаэрт

Ул биредә, Гамлет. Гамлет, син үтерелдең.
Коткарачак дару сине дөньяда юк;
Ярты сәгать гомерең калды; хыянәтле
Корал синең үз кулыңда, ул чарланган,
Агуланган; үзем кылган яман мәкерем
Үз башыма кире кайтты; күр син мине,
Яңадан мәңге тормас хәлдә ятам.
Анаң синең агуланды; аһ, юк хәлең,
Король, Король, ул гаепле һәммәсенә.

Гамлет

Кылыч та агулымы? Алай булса,
Бар син, агу, үз урыныңа кайт!

Корольне чәнчә.

Барысы бергә

Хыянәт,
Хыянәт!

Король

Аһ, булышыгыз миңа, дуслар.
Мин тик яраландым гына.

Гамлет

Мә, уйнашчы,
Үтерүче, мәлгунь Король, төбенәчә
Эч шәрабың! Асылташың эчендәме?
Әниемнең артыннан бар!

Король үлә.

Лаэрт
Үзенә кайтты
Үзе әзерләгән агу. Бер-беребезне
Бәхилләшик, асыл егет Гамлет, синең
Үлемең минем өскә, минем белән
Атамның үлеме дә сиңа төшмәс.

Үлә.

Гамлет

Тәңре сине ярлыкасын; мин дә синең
Артыңнан барам; үләм, Горатсио.
Бәхетсез анам, миннән бәхил бул! Сез
Бу хәлләрне күреп, тетрәп калучылар,
Булса иде минем дәрман, бу рәхимсез
Үлем мине бугазымнан бумасае,
Аһ, мин сезгә сөйләр идем. Хәер... үләм,
Горатсио. Син каласың, минем хакта
Белмәгән кешеләргә булган эшнең
Чын дөресен син сөйләрсең.

Горатсио

Бу — һич булмас,
Мин Дания кешесенә караганда
Борынгы Рим кешесерәк; монда бераз
Эчемлек калган әле.

Гамлет
Син ир булсаң,
Бир миңа ул касәне. Калдыр, китер,
Йә Хода! Горатсио, әгәр минем
Бөтен серем беленмичә калса шулай,
Миннән нинди начар исем калыр иде.
Әгәр син кайчан булса мине дә бер
Дус итеп йөрәгеңдә йөрткән булсаң,
Беразга бу ниятеңнән син кайтып тор.
Минем бу тарихымны сөйләр өчен,
Мәшәкатьле бу дөньяда бераз тын ал.

Еракта марш һәм тышта атыш тавышлары.

Нинди атыш анда?

Озрик

Ул — яшь Фортинбрас,
Польшадан җиңеп кайтып килешендә
Англия илчеләрен туплар атып
Сәламли ул.

Гамлет

Аһ, үләм мин, Горатсио;
Көчле агу бар җанымны басып алды.
Англиядән монда хәбәр алынганчы,
Мин булмам. Ләкин алдан әйтеп куям. —
Фортинбрас файдасына булыр сайлау;
Минем дә соңгы тавышым аңа булсын.
Бу эшләрнең барысы ничек булганлыгын
Эресен-вагын аңа сөйлә. Бетү, тынлык.

Үлә.

Горатсио

Тынды бөек йөрәк. Тыныч йокла, принц.

Фирештәләр тирбәтсеннәр көйләп синең
Бу йокыңны! Барабаннар тавышы һаман
Нишләп бире якыная?

Тышта марш.
Фортинбрас һәм Англия илчеләре барабаннар, байраклар һәм сарай хадимнәре белән керәләр.

Фортинбрас

Бу ни күренеш?

Горатсио

Ни эзлисез? Бер тамаша яки дәһшәт
Дисәгез — алар менә — каршыгызда.

Фортинбрас

Нинди кырылыш! Аһ, син, үлем, канлы кулың
Белән син шулкадәрле принцларны
Бер сугуда корбан итеп, җир астыңда
Нинди зур туй әзерлисең, әйт, тәкәббер?

Беренче илче

Нинди шом бу? Англиядән хәбәр белән
Без дә килеп җитешә алмадык. Аның әмере
Буенча, Гилденстерн, Розенкранц —
Икесе дә үтерелгәнен ишетергә
Тиеш булган кеше — үзе хиссез, мәет.
Кем безгә рәхмәт дияр?

Горатсио

Тик ул түгел,
Рәхмәт дия алса да ул, әйтмәс иде.
Чөнки ул беркайчан да бу икәүнең
Үлемнәрен теләмәде. Тик сез инде
Берегез Англиядән, берегез Польша
Сәфәреннән мондый канлы хәл өстенә
Килеп кергәч, мәетләр дә барыгызның
Күз алдына салынсыннар, калку җиргә.
Бу эшләрнең ничек килеп чыкканлыгын
Белмәүче кешеләр, сез сүз әйтергә
Миңа бирегез. Сөйлим сезгә гадәттән тыш
Канлы, кыргый бу эшләрне, судсыз хөкем,
Уйланмаган үтерешләр, хәйлә-мәкер,
Чарасыздан үтерү һәм көчләүләрне;
Ниһаять, явыз эшкә явызларның
Үз башлары белән ничек түләүләрен —
Барсын — сезгә ишетергә туры килер,
Бу эшләрнең чын дөресен мин сөйләрмен.

Фортинбрас

Ашыгабыз ишетергә, җыелсыннар
Асыл затлар зур мәҗлескә, кайгы белән
Бергә мин дә үз бәхтемә ия булыйм.
Бу дәүләткә күптән минем үз хакым бар,
Мин дә хәзер, шул форсаттан файдаланып,
Шул турыда игълан итим.

Горатсио

Бу хакта да
Аның авызы белән әйтү — миңа насыйп;
Аның тавышы башкаларны сезгә тартыр.
Тик хәзер үк моңа башлыйк; кешеләрнең

Акылы-зиһене кызган чакта, башбаштаклык
Чуалыш һәм зур фетнәләр кузгалмасын.

Фортинбрас

Күтәрсен Гамлет мәетен дүрт капитан,
Аны хәрби кеше итеп калку җиргә.
Әгәр аңа тәхет тоту насыйп булса,
Мөгаен, ул бөек король булыр иде.
Җеназасы хәрбиләрчә йола белән,
Гаскәри музыкалар белән бергә
Мактап, данлап озатылсын. Мәетләрне
Алыгыз. Мондый күренеш сугыш кыры
Өчен ярый, ләкин монда ул килешми.
Юнәлегез, туп атсыннар гаскәриләр.

Матәм маршы. Мәетләрне алып чыгалар, аннан туп тавышлары ишетелә.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Венециянең бер урамы. Родриго белән Яго керәләр.

Родриго

Юк, Яго, юк! Ышанмыйм мин сиңа!
Хәзинәмне үз байлыгың кебек
Файдалана торып, шушы хәлне
Алдан белеп миңа әйтмәгәнсең!

Яго

Шайтан алган, тукта, диләр сиңа!
Син бит тыңларга да теләмисең.
Бу хәл төшкә генә кергән булса да,
Мин үземне сиңа теләгәнчә
Мыскылларга ирек куяр идем.

Родриго

Син маврны дошман күрәм дия идең.

Яго

Әгәр ялганласам, йөземә төкер.
Затлы өч әфәнде мине монда
Аның лейтенанты итү өчен
Бик нык тырыштылар. Үз бәямне
Мин бик яхшы беләм, ул урынга
Мин һәр яктан лаек кеше идем.
Әмма үз-үзенә исе киткән
Кара гарәп моңа каршы булды.
Башта хәрби сүзләр катыштырып,
Сафсаталар сатып, сузып килде;
Ә соңыннан кире какты мине,
Имеш, «Мин лейтенант таптым инде».
Ә кем соң ул тапкан лейтенанты?
Флоренциянең бер хисапчысы,
Фахишәгә исе киткән гашыйк,
Яу кырына аяк та басмаган,
Сугыш тәртипләрен хатыннардан
Артык белми торган шыр мактанчык
Ниндидер Кассио! Ул сугышны,
Сенаттагы гади түрә кебек,

Китаплардан укып кына белә.
Тәҗрибә юк. Әмма лыгырдарга,
Шапрынырга дисәң, — о, ул оста —
Менә ул егетнең бар һөнәре.
Шуңа карамастан ул ярады.
Ә мин, Отеллоның күз алдында
Родос һәм Кипрда, тагын башка
Мәҗүс һәм христиан илләрендә
Бик зур батырлыклар күрсәтсәм дә,
Гади саннар белән эш итүче
Хисапчыдан түбән торып калдым;
Ул — лейтенант, ә мин — кичер, Раббым!
Мин — маврның гади поручигы!

Родриго

Ә мин аңа палач булыр идем.

Яго

Соң нишлисең? Тәртип шундый бездә,
Кода-кодагыйлык хөкем сөрә.
Кем аксөяк, кемнең дус-ише күп,
Тик шундыйлар гына хөрмәт күрә.
Элеккечә беренченең урынын
Икенчегә бирү тәртибе юк.
Шулай булгач, үзең уйлап кара,
Миңа соң маврны яратырга,
Аны саф йөрәктән олыларга,
Әйт, бармы соң тик бер генә сәбәп?

Родриго

Алайса, ник аңа хезмәт итәсең?

Яго

Тыныч бул син!.. Аңа хезмәт итеп
Мин үземә хезмәт итәм. Кинәт
Һәркем түрә булып бетми бит ул.
Түрәләр дә бездән гомер буе
Рәхәт күреп таралмыйлар. Дөрес,
Хуҗасына зур ихтирам белән
Билен бөгеп, тугры хезмәт иткән,
Җирәндергеч лакейлыгын сөеп,
Ишәк сыман, бары тамак ялына
Эшләп йөргән кабахәтләр дә бар,
Андыйларны картайгач та куалар.
Ул намуслы ахмак бәндәләрне
Таяк белән тотып ярырга иде!
Ләкин бар башкалар, — ул кешеләр
Тыштан тугры хезмәт иткән булып
Үзләренә файда итеп йөриләр;
Иткән хезмәтләре аркасында
Хуҗаларына да ярый беләләр,
Үз эшләрен дә гел алга сөрәләр,
Кесәләре байлык белән тулгач,
Алар үзләренчә яши башлыйлар.
Айдашларның акылы таза була.
Үзем дә мин менә шундыйлардан.
Әйе, әйе, синьор, әгәр дә мин
Мавр булсам, Яго булмас идем.
Синең исемең Родриго булуы
Дөрес булган кебек, бу да дөрес.
Аңа хезмәт итү белән мин тик

Үземә хезмәт итәм. Хода шаһит,
Бурыч та юк монда, ярату да —
Ялган тугрылыгым уйларымны
Каплап тора торган пәрдә генә.
Әгәр тышкы хәрәкәтем белән
Чын йөземне, яшерен уйларымны
Ачып салсам, бу эш — йөрәгемне
Уч төбенә салып, каргаларга
Азык итү белән бер булмасмы?
Юк, мин тыштан күренгәнчә түгел.

Родриго

Нинди бәхетле ул калын ирен!
Бөтен җирдә тик ул җиңеп чыга...

Яго

Кыз атасын тизрәк уятыгыз,
Хәзер артларыннан куа китсен.
Агулагыз аның тынычлыгын!
Бөтен шәһәр ишетерлек итеп
Каты кычкырыгыз! Отеллоның,
Кызның яманатын таратыгыз,
Кызның бөтен кардәш-ыруларын
Аңа каршы аякландырыгыз!
Ләззәтләнү өчен кара гарәп
Бәхет бишегенә менгән икән,
Син чебеннәр белән йөдәт аны.
Ул үзенә тиңсез бәхет тапты,
Ә син аңа шундый агу җибәр,
Бәхетенең нуры сүнеп калсын.

Родриго

Кыз атасы шушы өйдә тора,
Хәзер бар тавыштан сөрән салам.

Яго

Әйе, әйе, көчегез җиткән кадәр
Каты кычкырыгыз; шәһәр халкы
Гамьсез йоклап яткан кара төндә
Кинәт шәһәр өстен көчле ялкын
Каплап алгандагы кебек әче,
Ямьсез тавыш белән акырыгыз!

Родриго

Әй, әй! Брабанцио! Синьор Брабанцио!

Яго

Синьор, уяныгыз! Әй! Караклар!
Караклар бар! Сандыкларыгызны,
Кызыгызны, өегезне саклагыз!
Әй! Караклар!

Тәрәзәдән Брабанцио күренә.

Брабанцио

Нинди гауга монда?
Нинди тавыш? Ни бар, нәрсә булган?

Родриго

Синьор, барыгыз да өйдәмесез?

Яго

Өегезнең ишекләре биклеме?

Брабанцио

Нәрсә кирәк сезгә? Ник төпчисез?

Яго

Шуңа, синьор, сезне таладылар.
Тиз булыгыз, әйдә, киенегез!
Сезнең йөрәгегез телгәләнде,
Ярты җаныгызны югалттыгыз.
Әйе, менә хәзер, шул сәгатьтә,
Шул минутта сөмсез кара тәкә
Ак бәрәнегезне харап итә.
Тиз булыгыз, синьор! Чаң сугыгыз,
Бөтен шәһәр халкын уятыгыз,
Юкса җен бабасы булачаксыз.
Тиз булыгыз!

Брабанцио

Сез шаштыгыз мәллә?

Родриго

Синьор, минем тавышым сезгә танышмы?

Брабанцио

Сез кем соң?

Родриго

Мин Родриго.

Брабанцио

Бәдбәхет!
Өем тирәсендә буталма, дип
Әйттем бит мин сиңа. Мин кызымны
Сиңа бирергә дип үстермәдем.
Ә син күбенгәнче тыгынып, эчеп-исереп,
Оялмыйча тагын килеп җиткәнсең.
Ансы гына җитми, акырып-бакырып
Кеше борчыйсың.

Родриго

Аһ, синьор, синьор!..

Брабанцио

Ләкин шуны онытма: көчемне,
Дәрәҗәмне беләсең, мин сине
Тиз айнытырмын.

Родриго

Хөрмәтле синьор,
Тыныч кына тыңлагыз!

Брабанцио

Ни өчен
«Таладылар сезне» дип кычкырасыз?
Венеция бит бу, минем өем
Шәһәр читендәге утар түгел.

Родриго

Аһ, хөрмәтле синьор, ышаныгыз,
Бүген сезгә ихлас саф күңелдән
Ярдәм итү өчен килгән идем!

Яго. Шайтан алсын сезне, синьор! Сез, әгәр дә иблис кушса, Аллага гыйбадәт кылудан да баш тартырга торучылардан икәнсез. Без сезгә яхшылык итәргә дип килгән идек, ә сез безне алдакчыларга исәплисез. Ахры, сез үз кызыгызның гарәп айгыры белән кушылуын, алардан туган балаларның тирә-юнегездә кешнәп йөрүләрен телисездер.

Брабанцио

Монысы нинди мөртәт адәм тагын?
Яго. Мин, синьор, нәкъ шушы минутта кызыгыз белән маврның, бер-беренә ябышып, ике аркалы әкәмәт бер хайван кыяфәтенә керүләрен әйтү өчен килгән кешемен.

Брабанцио

Син — кабахәт!

Яго

Ә сез, синьор, сенатор.

Брабанцио

Моның өчен миңа җавап бирерсең,
Родриго, мин сине яхшы таныйм.

Родриго

Мин барысы өчен җавап бирәм.
Ләкин, синьор, шуны сез әйтегез:
Җаныгыздай күргән кызыгызга
Шундый ямьсез, шомлы кара төндә,
Сатлык ялчы-көймәчедән башка,
Һич сакчысыз-нисез япа-ялгыз
Мавр ятагына юнәлергә
Сез үзегез рөхсәт иттегезме?
Азгын кара гарәп кочагына
Сезнең рөхсәт белән кердеме ул?
Әгәр алай булса, әлбәттә, без
Әдәпсезлек кылдык, мыскылладык.
Әгәр инде киресенчә булса,
Безне әрләвегез һич урынсыз.
Бөтен әдәп кануннарын онытып
Сездәй картны мыскыл итү өчен
Килгән икән бу дип уйламагыз.
Әгәр дә бу эшне кызыгызга
Сез үзегез рөхсәт итмәсәгез, —
Кабат әйтәм, — ул зур гөнаһ кылды:
Ул үзенең бурычын, үткер гаклын,
Намусын, матурлыгын һәм язмышын,
Һәркем тарафыннан чит күрелгән
Йортсыз-җирсез, котсыз килмешәккә
Корбан итте. Менә озакламый
Моны үз күзегез белән күрерсез
Һәм хәзер сез аны өегезнең
Берәр бүлмәсеннән табалсагыз,
Алдашуым, мыскыллавым өчен
Мине хөкем кулына тапшырыгыз!

Брабанцио

Ут! Ут яндырыгыз, шәм бирегез!
Тиз хезмәтчеләрне уятыгыз!
Шомлы бер төш күргән идем бүген,
Юкка түгел икән... Бу турыда
Уйлау гына да, аһ, нинди авыр!..
Мин ут сорыйм сездән, ут бирегез!

Тәрәзәдән югала.

Яго

Йә, хушыгыз! Мин китәргә тиеш.
Яхшы түгел, үз түрәмә каршы
Шаһит булу килешеп бетмәс миңа;
Китим, юкса шаһит булам моңа.
Мин бик яхшы беләм, сенат аны
Урыныннан төшерүгә бармас,
Бик күп булса — җиңел шелтә бирер:
Алда торган Кипр сугышы өчен
Ул сенатка бик, бик кирәк кеше.
Сенат аны башка беркем белән
Алыштыралмый, һәм шуның өчен
Аны үлеп дошман күрсәм дә мин,
Каршысында дуслык һәм мәхәббәт
Әләмнәрен күтәрергә мәҗбүрмен.
Ләкин бу тик коры әләм генә.
Ә сез, Отеллоны табу өчен,
Кыз атасын тизрәк «Арсенал»га
Җибәрегез, мавр белән бергә
Мин дә анда булырмын. Хушыгыз.

Китә.
Өйдән Брабанцио һәм факеллар тоткан хезмәтчеләр чыгалар.

Брабанцио

Барысы да дөрес! Кызым өйдә юк!
Хәзер инде миңа бу дөньяда
Әче хәсрәт кенә торып кала.
Родриго, син кайда күрдең аны?
Һай бәхетсез бала! Мавр беләнме?
Нинди ата хәзер сине балам дияр?
Минем кыз икәнен кайдан белдең?
Аһ, башыма гына килгән булсачы!..
Сөйлә тизрәк: сиңа ул ни диде?..
Әй, тагын да утлар китерегез!
Бөтен кардәшләрне уятыгыз!
Родриго, әйт, ничек уйлыйсың син,
Никахлашып өлгерделәр микән?

Родриго

Өлгергәннәр булса кирәк.

Брабанцио

Раббым!
Ничек өйдән чыгып китә алган?
Бу бит... бу бит канга хыянәт итү!
Әй, аталар, моннан соң беркайчан да
Сез кызларыгызга ышанмагыз:
Тыштан гына алар саф күренә.
Әллә чынлап та саф кызлык намусын,
Яшь күңелне бозык юлга тартып
Адаштыра торган сихер бармы?
Мондый шомлы хәлләр турысында
Укыганың бармы синең, Родриго?

Родриго

Әлбәттә бар, синьор.

Брабанцио

Абзыйны
Чакырыгыз. Аһ, ни өчен, Родриго,
Сиңа гына бирмәдем мин аны!
Кызны эзәрләргә, тиз булыгыз!
Берничәгез — моннан, берничәгез
Теге яктан урап китәрсез... Тик
Кайдан, кай җирләрдән эзлик икән?
Хәзер алар кайда булыр, Родриго?

Родриго

Табармын дип уйлыйм. Тик иң элек
Берникадәр гаскәр чакырыгыз,
Үзегез дә миңа иярегез.

Брабанцио

Тиз алып бар! Әйдә! Мин һәр өйгә
Керермен һәм миңа буйсынучы
Кешеләрнең барсын уятырмын.
Әй, коралланыгыз! Тиз булыгыз!
Төнге сакчыларны чакырыгыз!
Киттек, киттек! Бу хезмәтең өчен
Мин буш итмәм сине, Родриго!

Китәләр.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук шәһәрдә икенче урам. Отелло, Яго һәм кулларына факеллар тоткан хезмәтчеләр керәләр.

Яго

Сугышларда кеше үтерсәм дә,
Үз иркемнән кеше үтерүне
Намуссызлык итеп саныймын мин —
Күңлем йомшак минем. Әмма бүген
Ярсуымнан әллә ничә тапкыр
Кылычымны кыннан суырып алып
Корсагына батырмакчы булдым.

Отелло

Әле ярый батырмагансың.

Яго

Соң нишлим мин? Мактана бит! Сезне
Шундый пычрак сүзләр белән хурлый,
Сабырлыгым җуеп, чак-чак кына
Җанын җәһәннәмгә җибәрмәдем.
Шулай да, әйтегез әле, сез соң
Ул кыз белән никахланыштыгызмы?
Тик, әфәндем, шуны онытмагыз:
Сенаторны монда һәркем сөя,
Монда аның һәрбер әйткән сүзе
Дож[1] сүзеннән өстенрәк йөри.
Ул аертыр сезне йә булмаса,
Дәрәҗәсен файдаланып, сездән
Закон көче белән үчен алыр.

Отелло

Котыра бирсен әйдә теләгәнчә.
Илгә иткән тугры хезмәтләрем
Аның үч ялкынын сүндерергә
Ярдәм итәр миңа. Өстәвенә, —

Әгәр нәсел белән мактануны
Кирәк итеп тапсам, — мин үземнең
Патша нәселеннән икәнемне
Әйтермен һәм тиңсез бу бәхеткә
Хаклы булуымны исбат итәрмен.
Шуны бел, Яго: Дездемонаны
Яратмасам әгәр, диңгез төбендәге
Бар байлыкны җыеп бирсәләр дә,
Йортсыз-җирсез азат тормышымнан
Аерылырга риза булмас идем.
Кара әле, нинди утлар анда?

Яго

Кызның атасы бу, Брабанцио,
Дус-ишләре белән монда килә.
Сезгә моннан китәргә иде, синьор.

Отелло

Юк, беркая китмим, киресенчә,
Килеп табуларын телимен мин.
Иткән хезмәтләрем, тоткан урыным,
Керсез күңелем мине аклый алыр.
Тукта, алармы соң?

Яго

Юк, Янус[2] белән ант итеп әйтәм,
Алар түгел.

Отелло

Дож хезмәтчеләре.
Яннарында минем лейтенантым.
Хәерле кич, дуслар! Йә, ни хәбәр?

Кассио

Дождан сәлам сезгә, генералым.
Хөрмәтле дож, сезне һич кичекми
Килеп җитсен, диде.

Отелло

Нигә икән?
Белмәдегезме?

Кассио

Мин шуны гына
Белеп калдым: мөһим эш хакында
Кипр утравыннан хәбәр килгән.
Бүген төнлә флоттан бер-бер артлы
Уникеме чапкын килеп китте.
Сенаторлар анда киңәш өчен
Ашыгып дож янына җыйналдылар.
Кабаланып сезне эзләттеләр,
Өегездә очратмагач, сенат,
Сезне тизрәк эзләп табу өчен,
Төрле якка кешеләр тараттырды.

Отелло

Килеп табуыгыз әйбәт булды.
Туктагыз, мин хәзер монда кереп
Бер-ике сүз генә әйтеп чыгам,
Аннан бергә китәрбез.

Китә.

Кассио
Яго, әйтче,
Монда аның нинди йомышы бар?

Яго

Коры җирдә генә йөри торган
Бер көймәне басып алды бүген[1].
Әгәр аны закон хаклы тапса,
Ул иреште тиңсез зур бәхеткә.

Кассио

Мин аңламыйм.

Яго
Ул өйләнде.

Кассио
Кемгә?
Улмы...

Отелло керә.

Яго

Киттекме, генерал?

Отелло
Киттек.

Кассио

Менә сезне эзләп тагы да бер
Отряд килеп җитте.

Яго

Кыз атасы —
Брабанцио! Синьор, сакланыгыз!

Брабанцио, Родриго һәм факеллар тоткан кораллы сакчылар керәләр.

Отелло

Тукта! Бу кем?

Родриго

Синьор, менә үзе.

Брабанцио

Тотыгыз шул юлбасарны!

Һәр ике як кылычларын суырып ала.

Яго

Бу сезме,
Родриго? Мин булышырга әзер.

Отелло

Кылычларны яшерегез, дуслар,
Тутыгырлар юкса төнге чыктан.
Мәрхәмәтле синьор, картлыгыгыз
Корал көчегездән кодрәтлерәк.

Брабанцио

Аһ, әшәке карак! Әйт тизрәк,
Кая куйдың минем кызкаемны?
Сихерләгәнсең син аны, мәлгунь!
Сихер җебең белән урамасаң,
Шундый гүзәл, сабыр, тәрбияле,
Никах сүзенә нәфрәт белән карап,

Венециянең иң гүзәл һәм бай
Егетләрен кире каккан кызның —
Әнә шундый кызның, дим мин сиңа! —
Ил көлдереп, өйдән качып китеп,
Кешеләрдә сөю хисе түгел,
Фәкать курку хисе тудыра торган
Котсыз кара тәнле бер мәхлукның
Кочагына яшеренүе мөмкинмени?
Әйткән сүзем әгәр хак булмаса:
Бөтен дөнья хөкем итсен мине.
Аны син иң пычрак һәм кабахәт
Сихер белән үзеңә караткансың.
Гакыл ихтыярын җуя торган
Әллә нинди зәһәр агу биреп
Аның саф яшьлеген һәлак иткәнсең.
Мин бу эшне куям тикшерергә.
Хәер, бу эш болай да бик ачык,
Күзгә күренеп тора. Шуның өчен
Сине — закон тыйган әллә нинди пычрак
Сихер эше белән маташучы
Ләгыйнь алдакчыны — мин хәзер үк
Кулга алам. Әй, алыгыз үзен!
Әгәр карышырга җөрьәт итсә,
Бик иркәләп маташмагыз!..

Отелло

Әй, дусларым, сабыр! Шулай ук сез дә,
Тугры хезмәтчеләр, тыелыгыз.
Әгәр хәзер, менә бу урында
Минем эш кан кою булса иде,
Ышаныгыз миңа, мин бу эшне
Суфлер ярдәменнән башка да
Үти алыр идем. Бу эшемә
Җавап бирү өчен сезнең белән
Хәзер кая барыйм мин?

Брабанцио

Төрмәгә!
Закон һәм суд чакырганга кадәр
Син төрмәдә утырырга тиеш!

Отелло

Мин буйсынып сезнең әмерегезгә
Хәзер сезнең арттан китеп барсам,
Дожның әмерен ничек итеп үтәрмен?
Дәүләт эше белән үзенә чакырып
Ул җибәргән миңа илчеләрен.

Бер офицер

Аның сүзе дөрес, синьор сенатор:
Дож сенатта. Киңәшмәгә чакырып
Сезгә дә бер кеше җибәрделәр.

Брабанцио

Ничек? Дож сенатта? Төнлә белән?
Киттек алайса. Алып барыгыз
Минем арттан. Минем эшем дә бит
Бик ул кадәр кечкенә эш түгел.
Дож үзе дә, сенатор кардәшләр дә
Бу хурлыкны үзләренә төшкән

Хурлык итеп исәпләргә тиеш.
Ирек бирсәк мондый бозыклыкка,
Безнең эш башына шакшы коллар,
Мәҗүсиләр менеп утырырлар.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук шәһәрдә сенат залы. Өстәл янында Дож һәм сенаторлар утыралар. Алар артында офицерлар.

Дож

Хәбәрләр бер-берсенә охшамыйлар,
Шуңа күрә ышануы кыен.

I сенатор

Әйе, дөрес, каршылыклар байтак,
Минем хатта — йөз дә җиде кораб.

Дож

Миңа йөз дә кырык диеп язалар.

II сенатор

Миңа ике йөз дип. Сан ягыннан
Бер-берсенә охшамыйлар, әлбәттә.
Төрле җирдән килгән хәбәрләрдә
Мондый каршылыклар һәрчак була.
Ләкин бу алынган хәбәрләрдән
Шунсы ачык мәгълүм: төрек флоты
Кипр утравына таба йөзә.

Дож

Фикер йөртү өчен шунсы җиткән.
Эш ул кораб саннарында түгел,
Төп мәсьәлә ачык һәм мин аны
Дөрес диеп табам; бу куркыныч.

Матрос
*(сәхнә артыннан)*

Әй, әй! Җибәрегез!

I офицер

Флоттан чапкын.

Матрос керә.

Дож

Ни бар, сөйлә!

Матрос

Төрек флоты хәзер
Родос утравына таба йөзә.
Синьор Анжеллодан бу хәбәрне
Тиз сенатка җиткерергә дигән
Әмер булды миңа.

Дож

Тагын да үзгәреш.

I сенатор

Моның һич булуы мөмкин түгел.
Бу тик хәйлә: безнең игътибарны

Үзләреннән читкә бормак булалар.
Төптәнрәк уйлап карасак без,
Кипр утравының төрекләргә
Родос утравына караганда
Әһәмиятлерәк икәнлеген
Күрербез: һәм төрекләргә аны
Басып алуы да җиңелрәк —
Кипр ныгытылмаган. Төрекләрне
Алай беркатлы дип уйламагыз;
Җиңел һәм файдалы эшне ташлап,
Һич мәгънәсез бу куркыныч эшкә
Тотынмаслар алар.

Дож

Әлбәттә,
Алар игътибарын тарткан утрау
Родос түгел.

I офицер

Тагын чапкын килде.

Чапкын керә.

Чапкын

Затлы һәм хөрмәтле әфәнделәр,
Төрекләрнең хәрби кораблары
Родос утравына җиткән чакта,
Башка бер флотка кушылдылар.

I сенатор

Менә шуны көткән идем дә мин.
Ничә кораб?

Чапкын

Утыз; хәзер алар
Кире борылдылар һәм туп-туры
Кипр утравына таба йөзәләр.
Ышанычлы, батыр хезмәтчегез
Синьор Монтано бу яңалыкны
Сезгә тапшырырга әмер бирде,
Һәм ул сездән түбәнчелек белән
Моңа ышануыгызны сорый.

Дож

Инде шик калмады — төрек флоты
Кипр утравына һөҗүм итә.
Марк Лючезе бүген шәһәрдәме?

I сенатор

Флоренциядә ул.

Дож

Хат языгыз,
Чапкын җибәрегез, кайтып җитсен.

I сенатор

Менә безнең батыр мавр белән
Брабанцио да килеп җитте.

Брабанцио, Отелло, Яго, Родриго һәм офицерлар керәләр.

Дож

Батыр Отелло, сез хәзер безгә
Илебезнең хас дошманы булган
Төрекләргә каршы көрәш өчен
Кирәксез... *(Брабанциога.)* Ә, сезне күрми торам, —
Сәлам сезгә, синьор. Бүген сезнең
Киңәшегез, ярдәмегез кирәк.

Брабанцио

Миңа сезнең ярдәмегез кирәк,
Хөрмәтле дож, кичерегез, зинһар,
Бүген мине җылы түшәгемнән
Кузгалырга мәҗбүр иткән сәбәп
Бик зур әһәмияткә ия булган
Әлеге хәбәр диеп уйламагыз.
Бүген мине борчый торган нәрсә
Уртак кайгы түгел, хөрмәтле Дож.
Шәхси кайгым ташкын булып ага,
Һәм ул минем башымдагы булган
Башка кайгыларны канлап алды.

Дож

Йә, ни бар соң, синьор? Нәрсә булды?

Брабанцио

Кызым, кызым...

Дож

Нәрсә, үлде мәллә?

Брабанцио

Әйе, минем өчен ул юк хәзер!
Урладылар аны, алдадылар,
Явыз мәлгуньнәрнең сихре белән
Агуланып һәлак булды балам.
Шул каһәрле сихер, башындагы
Гакылын алып, күзен капламаса,
Минем кызым шундый куркынычлы
Бозык юлга кереп китмәс иде.

Дож

Андый пычрак, шакшы юллар белән
Сездән кызыгызны, ә кызыгыздан
Гакылын тартып алган явыз бәндә —
Ул кем генә булса да, барыбер —
Канлы закон кенәгәсен ачып,
Анда күрсәтелгән җәзаларның
Иң катысын үзегез сайлап алырсыз.
Ул эшлексез туган улым булса да,
Мин сүземнән кайтмам.

Брабанцио

Чын күңелдән
Рәхмәт сезгә. Ул гаепле кеше —
Дәүләт эше белән сез чакырткан
Менә бу мавр.

Дож һәм сенаторлар

Моны ишетү авыр.

Дож
*(Отеллога)*

Үзегезне аклау өчен
Сез ни әйтерсез?

Брабанцио

Мин әйткән сүзне
Дөресләүдән башка ул ни әйтсен?

Отелло

Затлы һәм хөрмәтле сенаторлар,
Минем мәрхәмәтле хакимнәрем!
Картның кызын алып китүем — хак:
Шулай ук ул кызга өйләнүем дә
Ялган түгел. Минем җинаятем
Фәкать шуннан тора. Минем сүзләр
Тупас булыр, бизәп, матур итеп
Сөйли алмам, аңа осталык юк.
Чөнки җиде яшьтән, кулларымның
Тәүге көчен сизгән көннән алып,
(Рәхәт үткән соңгы тугыз айлык
Тыныч тормышымны санамасам),
Шушы көнгә кадәр яу кырыннан,
Солдат палаткаларыннан башка
Берни күргәнем юк. Һәм дөньяда
Була торган бөтен хәл-әхвәлдән
Мин тик сугыш-кырылыш, канлы яулар
Турысында гына сөйли алам.
Шуңа күрә бүген мин үземне
Яклап сөйли торган бу сүземдә
Гаебемне йомшарталмам. Шулай да
Хәзер сезнең рөхсәтегез белән,
Безнең арадагы мәхәббәтнең
Ничек туып, ничек үскәнлеген,
Матур сүзләр белән бизәмичә,
Гади генә итеп сөйләп бирәм.
Нинди ырым, агу, сихер белән
Картның кызын үземә каратуым
Мәгълүм булыр — мин бит сезнең алда
Әнә шуның өчен гаепләнәм.

Брабанцио

Шундый саф, әдәпле, итагатьле,
Хәтта үзенең хәрәкәтләреннән
Кызаручы юаш бер кыз бала, —
Тотсын да, холкына, яшьлегенә,
Туган иле, халкы гадәтенә
Капма-каршы барып, затсызланып,
Моңа кадәр карарга да курыккан
Бер кешегә гашыйк булсын, имеш!
Юк, юк, фәкать гакылы зәгыйфьләнгән
Яки тәмам шашкан кеше генә
Табигатьнең һичбер канунына
Сыймый торган аның бу эшенә
Табигый эш бу дип карый алыр.
Таза гакыл сыйдыралмый моны,
Моңа сихер эше диеп кенә
Карап була. Әнә шуның өчен
Кабат әйтәм сезгә: ул үзенең

Шушы максатына ирешү өчен,
Махсус әзерләнгән әллә нинди
Гакыл җуйгыч зәһәр агу биреп,
Кыз баланың зиһенен томалаган.

Дож

Болай сөйләү генә әле эшнең
Сез әйткәнчә булуын исбат итми,
Коры шиккә генә нигезләнгән
Фикер бит бу — әле бу фикерне
Гаепләүгә нигез була алырлык
Дәлил белән ныгытырга кирәк.

I сенатор

Йә, әйтегез әле безгә, Отелло,
Ул яшь кызның күңелен аулау өчен,
Чынлап та, шул закон тыя торган
Көчләү чараларын кулландыгызмы?
Әллә, киресенчә, бу максатка
Күңелләрне бергә бәйли торган
Җылы сүзләр аша ирештегезме?

Отелло

Мин үтенәм сездән, үзен чакырып,
Мәшһүр гостиница «Арсенал»га
Кеше җибәрегез. Килсен дә ул,
Атасының каршысында, сезгә
Минем хакта барын сөйләп бирсен.
Әгәр аның сүзләреннән соң да
Мин гаепле булып калсам, ул чак
Мине үзегез биргән дәрәҗәдән,
Ышанычтан мәхрүм итеп кенә
Калмассыз; хак, гадел хөкемегез
Хәтта җанымны да тартып алыр.

Дож

Хәзер үк Дездемона артыннан
Кеше җибәрегез.

Отелло
*(Ягога)*

Алып бар, дус,
Син бит аның кайдалыгын беләсең.

Яго берничә офицер белән чыгып китә.

Ә мин монда, алар килеп җиткәнче,
Хода каршысында саф күңелдән
Гөнаһымны икърар иткән кебек,
Сезгә шушы тиңсез гүзәл кызның
Мәхәббәтен ничек биләвемне,
Һәм ул кызның минем мәхәббәтне
Ничек кабул иткәнлеген сөйлим.

Дож

Сөйлә, Отелло, без сине тыңлыйбыз.

Отелло

Аның карт атасы мине сөя иде,
Еш-еш кына өенә чакыра иде.

Минем тормыш белән кызыксына,
Баштан үткән төрле вакыйгалар,
Канлы сугыш, яулар турысында
Сөйләвемне сорый иде миннән.
Һәм мин шунда малайлыктан башлап
Шушы көнгә кадәр гомеремдә
Күргән, белгәнемне сөйли идем.
Коры җир өстендә, диңгезләрдә
Күреп үткән газап-михнәтләрне,
Кайчандыр бер үлем чокырына
Төшә язып көчкә котылуымны,
Кансыз дошманнарга әсир булуым
Һәм коллыкка сатылуымны,
Аннан соң иреккә чыгуымны
Сөйләдем мин. Шуннан соң мин аңа
Сәяхәттә йөргән чакта күргән
Мәгарәләр, төпсез зур чокырлар,
Иген үсми торган киң далалар,
Стенадай текә таш кыялар,
Түбәләре күккә тигән таулар
Турысында, аннан тагын
Берсен-берсе тотып ашый торган
Вәхшиләрне — башларына караганда
Иңбашлары югарырак булган
Антропофагларны күрүемне
Сөйләдем мин аңа. Ә Дездемона
Моны бик бирелеп тыңлый иде.
Кайчак аңа, берәр йомыш белән,
Безнең яннан чыгып китәкләргә
Туры килә иде; һәм ул шунда
Тизрәк эшен бетереп керә иде дә
Тагын йотылып тыңлый башлый иде.
Моны сизгәч, мин бер җаен табып
Дездемона белән очрашкач,
Моңача ул тик кисәкләп кенә
Тыңлый алган әлеге хикәямне
Тагын яңабаштан сөйләвемне
Үтенергә мәҗбүр иттем. Шуннан
Мин яңадан башлап алып киттем.
Яшьлегемдә күргән михнәтләрне
Сөйләгәндә аның күзләрендә
Яшьләр күрдем, сүзем тәмамлангач,
Мине тирән көрсенүләр белән
Бүләкләде, һәм ант итеп миңа,
Боларның барсы да шундый гаҗәп,
Нәкъ могҗиза кебек, сокландыргыч,
Шул ук вакыт күңелгә бик авыр,
Әйтеп бетергесез әче булуын
Һәм үзенең бу хикәяләрне
Артык ишетергә теләмәвен
Әйтеп үтте. Ләкин шул ук вакыт,
— Хак Тәңренең минем үземне дә
Синдәй батыр итеп яратуын
Чын күңелдән теләр идем! — диде.
Аннан ул хикәям өчен миңа
Рәхмәт әйтте, һәм иптәшләремнән
Аңа гашыйк берәү табыла калса,
Һәм ул аңа әлеге мин сөйләгән
Хикәяне сөйли торган булса,
Аны сөячәген әйтеп куйды.

Аның бу уратып әйткән сүзен
Мин аңладым, әлбәттә, һәм шунда ук
Йөрәгемне ачтым аңа. Мине ул
Күргән газапларым өчен сөйде,
Ә мин аны шушы газапларны
Уртаклашкан өчен сөйдем. Менә
Мин кулланган бөтен сихер шунда.
Әнә үзе килә, сөйләп бирсен.

Дездемона, Яго һәм офицерлар керәләр.

Дож

Бу хикәя минем кызымның да
Башын әйләндерер иде. Брабанцио,
Үткән эшне кире борып булмый,
Килешергә туры килер сезгә.
Кеше сугышырга чыккан чакта
Сынык булса да бер корал тота,
Болай коры йодрык белән чыкмый.

Брабанцио

Үтенәмен, кызымны да тыңлагыз:
Әгәр минем кызым бу гаепнең
Тик яртысын гына үзенә алса да,
Бу егетне битәрләвем өчен
Афәт төшсен минем карт башыма!
Якынрак кил, сөекле бала!
Монда утыручы синьорлардан
Күбрәк син кемне тыңларга тиеш?

Дездемона

Затлы атам, монда бурычымның
Мин икегә аерылганын күрәм:
Тормыш һәм тәрбиям — гыйлемем өчен
Мин бурычлы сезгә. Бу тәрбия
Сезгә буйсынырга куша миңа.
Монда сез баш миңа, мин — кызыгыз.
Ә менә бу минем ирем. Әти,
Газиз әнкәм туган атасыннан
Аерылып сезгә чыкканнан соң,
Ничек ул буйсынган булса сезгә,
Миңа да нәкъ шулай Отеллога
Буйсынырга рөхсәт итсәгезче!

Брабанцио

Ярый, рәхмәт төшсен! Сүзем бетте.
Инде дәүләт эшләренә күчик.
Аһ, бу минем туган кызым булганчы,
Асрарга алган кызым булса,
Җиңелрәк булыр иде миңа!
Йә, мавр, кил бире. Әгәр дә син
Үзеңнеке итеп өлгермәгән булсаң,
Бөтен көчем белән синең кулдан
Тартып алыр кызымны мин бүген
Ихлас күңелемнән сиңа бирәм.
*(Дездемонага.)* Якын кил, кадерлем,
Әле ярый минем башка кызым юк.
Юкса качуыңа үч итеп мин
Кансыз бер тиранга әверелеп,
Аңа богау салыр идем... Ярый,
Сүзем бетте минем, хөрмәтле дож.

Дож

Сезнең исемегездән әйткән сыман
Мин дә бер сүз әйтим, минем сүзем
Гашыйкларга сезнең гафуыгызга
Ирешү өчен, бәлки, баскыч булыр.
Котылырлык чара калмаганда,
Соңгы өмет сүнү белән бергә,
Кайгы-хәсрәт югалырга тиеш.
Үтеп киткән кайгы өчен елау —
Үз башыңа яңа кайгы теләү.
Әйберләрен урлатучы кеше,
Югалтуга көлеп карый алса,
Әле ул каракны берникадәр
Откан була. Әмма югалтуы өчен
Файдасызга уфылдаган кеше
Үзенекен үзе урлый.

Брабанцио

Алайса,
Без Кипрны төрекләргә бирик,
Ә үзебез шаркылдашып көлик.
Бәла килмәгәндә үз башыңа
Акыл бирү җиңел юлдашыңа.
Зур бәлагә дучар булган адәм
Нинди файда тапсын буш сүзләрдән?
Ул сүз дәва булса кайгысына,
Агу була аның ярасына.
Сүз сүз инде. Әле һичбер кемнән
Ишеткән юк минем буш сүз белән
Төзәлгәнен йөрәк ярасының.
Түбәнчелек белән сорыйм сездән,
Күчик, зинһар, дәүләт эшләренә.

Дож. Көчле коралланган төрекләр Кипрга таба йөзәләр. Ул җирләрне дошман һөҗүменнән саклау чаралары башка кешеләрдән бигрәк сезгә билгеле, Отелло. Гәрчә безнең анда яхшы ук игътибарлы кешебез булса да, безнең җәмәгатьчелек фикере бар өметне сезгә баглый. Шуның өчен сезгә яңа якты бәхетегезне бу давыллы сәфәр белән берникадәр караңгыландырырга туры килер.

Отелло

Затлы һәм хөрмәтле сенаторлар,
Дошманнарга каршы яуга чыгу —
Бу эш минем гадәтемә кергән.
Яу кырының тимер, таш ятагын
Мамык түшәк итеп хис итәргә
Мин күнеккәнмен, һәм дөресен әйтим,
Кыенлыклар белән көрәшүдән
Әллә нинди ләззәт, шатлык табам.
Һәм мин төрекләргә каршы булган
Бу походка әзер, сенаторлар.
Шуның өчен, түбәнчелек белән
Мин үтенәм сездән: хатыным өчен
Җайлы торак, хезмәтчеләр кирәк —
Аның затлы нәселенә лаек
Яшәү ихтыяҗын үтәү өчен
Кирәк булган бөтен нәрсәләрне
Әзерләргә рөхсәт бирсәгезче.

Дож

Әгәр дә сез каршы килмәсәгез,
Ул үзенең атасында торыр.

Брабанцио

Юк, мин риза түгел.

Отелло

Һәм мин дә.

Дездемона

Мин дә.
Әткәемнең күз алдында булып,
Һәрчак аның ачуын китерергә,
Аны ярсытырга теләмим мин.
Хөрмәтле дож, минем үтенечемә
Тирән ихлас белән колак салып,
Тәҗрибәсез кызга аталарча
Ярдәм кулыгызны сузсагызчы.

Дож

Сез ни телисез соң, Дездемона?

Дездемона

Мин маврны һәрчак бергә булу,
Бергә яшәү өчен сөйдем; моны
Мин ачыктан-ачык, һич курыкмыйча,
Язмыш давылына каршы барып,
Аңа чыгуым белән исбат иттем.
Минем күңелемне Отеллоның
Бөек сыйфатлары буйсындырды.
Мин карадым аның пакь күңеленә
Һәм йөзенең ак икәнен күрдем.
Данга илткән батырлыкларына
Язмышымны, күңелемне багышладым.
Шулай булгач, ул сугышка китеп,
Мин, тынычлык сөйгән күбәләктәй,
Монда торып кала торган булсам,
Ул чагында бит мин Отеллоның,
Минем күңелемне буйсындырган,
Аны сөйдерергә мәҗбүр иткән,
Куркынычлар, батырлыклар белән
Сугарылган, җил-давыллы гомерен
Уртаклашу-бүлешү бәхетеннән
Үз-үземне мәхрүм иткән булам.
Сөеклемнән аерылып тору —
Бу бик авыр булыр минем өчен.
Бирегез рөхсәт, мин дә бергә китим.

Отелло

Сенаторлар, тавыш бирегез, зинһар,
Үтенәм сездән, аның бу теләген
Кире какмагызчы. Хода шаһит,
Азгын күңел теләгенә бирелеп
Аның кайнар яшьлек дәрте белән
Үзем ләззәтләнү өчен түгел,
Бәлки, аның күңеле мәшәкатьтән,
Борчылудан азат булсын өчен,
Мин үтенәм сездән, сенаторлар.
Ләкин, сезне Алла саклый күрсен,
Минем хакта «аннан аерылалмый,
Мөһим эшкә зарар китерер» дигән
Уй килмәсен башыгызга. Юк, юк!

Әгәр дә уенчак, шаян гыйшык
Минем күзләремне томаласа,
Татлы гыйшык ләззәтенә чумып,
Ихтыярым җуеп, уйларымны,
Бурычымны оныта торган булсам, —
Ул чак минем сугыш шлемымнан
Хатын-кызлар чүлмәк ясасыннар,
Намусыма хурлык, оят төшсен!

Дож

Китәргәме аңа, калыргамы,
Бу мәсьәлә сезнең ихтыярда;
Ә безнең эш ашыгуны сорый.
Сузу, кичектерү һич ярамый.
Бүген китәрсез.

Дездемона

Ә? Бүген төнлә?

Дож

Бүген төнлә.

Отелло

Мин шат.

Дож

Иртә белән без нәкъ сәгать унда
Җыйналырбыз тагын менә монда.
Отелло, офицерларыгыздан
Берәвесен монда калдырыгыз;
Ул офицер безнең боерыкларны,
Сезгә тиеш булган кәгазьләрне
Алып барыр.

Отелло

Рөхсәтегез булса,
Поручик Ягоны калдырырмын,
Ул — намуслы, ышанычлы кеше.
Хатынымны алып бару бурычын да
Аңа тапшырам мин. Җибәргә
Кирәк тапкан бөтен нәрсәгезне
Ул җиткерер миңа.

Дож

Шулай булсын.
Ә хәзер мин сезнең һәммәгезгә
Хәерле төн телим.
*(Брабанциога.)*
Йә, хөрмәтле синьор,
Адәм күңлендәге гүзәл сыйфат
Чын матурлык булып балкый, диләр.
Киявегез сезнең саф күңелле,
Димәк, кара булса да ул матур.

I сенатор

Сау булыгыз, батыр мавр,
Саклагыз Дездемонаны бәлаләрдән.

Брабанцио

Кара аны, мавр, яхшы кара:
Ул алдады үзенең карт атасын,
Мөгаен, ул алдар сине дә.

Дож, сенаторлар һәм офицерлар чыгып китәләр.

Отелло

Юк, мин аның күңеле сафлыгына
Җаным белән ант итәргә әзер!
Саф күңелле Яго, хатынымны
Сиңа калдырам мин. Хатыныңа әйт,
Ул Дездемонага хезмәт итсен.
Ә соңыннан, берәр җаен табып,
Һәр икесен анда алып барырсың.
Киттек, Дездемона.
Мәхәббәт һәм башка мәшәкатькә
Тик бер генә сәгать вакыт калды,
Без вакытка буйсынырга тиеш.

Дездемона белән чыгып китәләр.

Родриго

Яго!

Яго

Ни бар, изге җанлы кеше?

Родриго

Беләсеңме, мин хәзер нишләргә уйлыйм?

Яго

Кайтып йокларсың дип уйлыйм.

Родриго

Мин хәзер барам да суга ташланам.

Яго. Моны эшләсәң, мин сине яратмый башлармын. Нигә кирәге бар ул суга ташлануның, ахмак бәндә?

Родриго. Тормыш газап булганда, яшәү — үзе ахмаклык. Үлем безнең яралы күңелне дәвалый икән, без үләргә тиешбез.

Яго. Фу, нинди буш сүз! Мин инде егерме сигез елдан бирле дөньяда яшим. Һәм, файданы зарардан аера башлаган көннән алып, үз файдасын төпле рәвештә аңлаган бер генә кешене дә күргәнем юк әле. Юк, ниндидер бер фахишәгә булган мәхәббәттән суга ташланганчы, мин үземнең кешелегемне маймыллыкка алмаштырырга риза булырмын.

Родриго. Миңа нишләргә соң? Яшермим, бу кадәр гашыйк булуым үземә дә оят. Ләкин гыйшкымны җиңәрлек көчем юк минем!

Яго. Көчең юк? Буш сүз! Безнең андый яки мондый булуыбыз үзебездән. Безнең тәнебез — бакча, ихтыярыбыз — шул бакчаның тәрбиячесе. Без ул бакчада кычыткан үрчетәбезме, салат, иссоп, тмин шикелле яшелчәләр утыртабызмы, бер генә төрле үлән үстерәбезме, әллә бик күп төрле үләннәр белән бизибезме, ул бакчаны ташларга телибезме, әллә, булмаса, зур игътибар белән карарга-тәрбияләргә телибезме, — моңа кирәкле көч һәм власть безнең үз ихтыярыбызда. Әгәр дә хисләребезне тигезләүгә хезмәт итүче акыл бизмәнебез булмаса иде, каныбыздагы кызулык, күңелебездәге бозыклык безне бөтенләй ахмаклыкка алып барыр иде. Ләкин безнең котырган дәртләребез, хайвани теләкләребез, һичбер авызлыкланмаган айгырлыгыбызны суыта-киметә торган гакылыбыз бар. Менә шуның өчен дә мин теге синең мәхәббәт дип атаган нәрсәңне күңелеңә ябышып үскән кирәксез бер ботак дип карыйм.

Родриго. Моның булуы мөмкин түгел.

Яго. Әйе, әйе, бу — каныңның авызлыкланмаган бозык теләкләр белән кайнавы. Йә, җитәр, ир бул! Суга ташланырга!.. Суга син әнә мәчене, күзе ачылмаган эт балаларын ташла. Мин үземне синең дустың дип игълан иттем, һәм, дөресен әйтим, мин сиңа иң нык дуслык баулары белән бәйләнгәнмен. Минем синең өчен бүгенге кебек кирәкле булганым юк иде әле. Син янчыгыңа акча тутыр да сугышка кит. Ясалма сакал ябыштырып йөзеңне үзгәрт. Ләкин кабат әйтәм, янчыгыңа күп итеп акча тутыр. Дездемонаның маврны озак сөюе мөмкин түгел. Шулай ук ул да Дездемонаны озак сөя алмас. Бу мәхәббәт бик тиз кабынды, сүнүе дә аның бик тиз булыр. Ләкин янчыгыңа акча салырга онытма! Маврларның

күңеле тиз үзгәрүчән була... Янчыгыңа бик күп итеп акча тутыр. Бүген аңа бал кебек тәмле тоелган нәрсә тиз көннән әремнән дә әчерәк булыр. Дездемона әле бөтенләй яшь, ул да озакламый үзгәрер. Маврның кара тәненнән туйгач, үзенең ни дәрәҗәдә ялгышканын ул аңлар. Әйе, аңа икенче берәү кирәк булыр, шиксез, кирәк булыр, — менә шуның өчен син янчыгыңа акча тутыр. Әгәр дә инде син үзүзеңне һәлак итми булдыра алмыйсың икән, моның өчен суга ташлануга караганда һәйбәтрәк чара эзләп тап. Акчаны булдыра алган кадәр күбрәк җыйна. Әгәр дә шушы килмешәк вәхшинең һәм хәйләкәр Венеция кызының ялган изгелекләре, бернигә дә ярамаган черек антлары минем акылымны һәм бөтен җәһәннәм көчләрен җиңеп кенә китмәсәләр, Дездемона синеке булыр. Тик акча гына җыйна. Нинди буш сүз: суга ташланырга! Ул бит бернинди максатка да алып бармый. Теләгәнеңә ирешә алмый суга ташлануга караганда, рәхәтлекнең тәмен татыганнан соң, асылыну яхшырак!

Родриго. Әгәр дә мин синең киңәшеңне тотсам, максатыма ирешергә ярдәм итәрсеңме соң?

Яго. Минем турыда син тыныч бул... Хәзер, бар, акча тап. Мин сиңа һәрвакыт әйтә килдем һәм хәзер дә әйтәм: мин маврны үлеп дошман күрәм. Сәбәпләре бик күп аның, ул сәбәпләр синдә дә җитәрлек. Үч алу өчен без берләшик. Әгәр дә син аңа мөгез куя алсаң, бу синең өчен — куаныч, минем өчен юаныч булыр. Вакыт карынында тиз көннән дөньяга киләчәк андый вакыйгалар бик күп. Йә, бар, акча тап! Иртәгә без бу турыда иркенләп сөйләшербез. Сау булып тор!

Родриго

Иртәгә без кайда очрашырбыз?

Яго

Миндә.

Родриго

Мин иртәрәк барырмын.

Яго

Йә, хуш. Ләкин хәтереңдә тот, Родриго...

Родриго

Нәрсәне?
Яго. Үлем турында яңадан бер генә сүз дә әйтәсе булма. Ишеттеңме?
Родриго. Юк, мин хәзер икенче кеше! Киттем. Җирләремне, утарларымны сатам.

Яго

Бар. Ләкин кара, акчаны күп җыйна.

Родриго китә.

Һәрчак менә шундый ахмаклардан
Мин үземнең янчыгымны тутырам.
Моннан һичбер файда күренмәсә,
Бары кызык өчен шундый юньсез
Ахмак ишәк белән ләчтит сатып,
Гакылымны, кыйммәт вакытымны
Юкка әрәм итәр идемме мин!
Бу үземне хурлау булыр иде.
Мин маврны үлеп дошман күрәм.
Аны, минем түшәгемә ятып,
Мин эшлисе эшне эшләгән дип
Сөйлиләр. Бу сүзләр дөрестерме,
Ялгандырмы, мин белмимен. Ләкин
Бу хәл имеш-мимеш кенә булса да,
Мин чын итеп исәплимен аны.
Миңа ул ышана. Бу бик әйбәт,
Ниятемне очлап чыгу өчен,
Бу тагын да уңайлырак булыр.
Яшь Кассио чибәр, сылу егет...
Менә шуны ничектер... Мин аның
Урынын алып, ә соңыннан үзен үк
Планымның таянычы итсәм,

Ике яклап файда булыр иде!
Ләкин моны ничек эшләргә соң?
Бераз баш ватарга туры килер.
Эшне, бераз вакыт үткәннән соң,
Отеллоның колагына: «Бу Кассио
Синең хатын белән бик дус икән», — дип
Пышылдаудан башлап җибәргәндә,
Начар булмас. Егет төскә матур,
Кеше белән бик ягымлы, ачык,
Әйтерсең лә хатын-кызлар күңелен
Аулау өчен генә яратылган.
Ул егеттән көнләштерү берни түгел.
Ә маврның күңеле шундый садә,
Тыштан изге күренә белүчене
Саф күңелле кеше диеп белә.
Аны, ишәк җитәкләгән кебек,
Танавыннан тагып йөртү җиңел.
Булды бу! Төн белән шайтан бергәләшеп
Бу мин чәчкән дәһшәт орлыгыннан
Коточыргыч җимеш үстерерләр.

Китә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кипр утравының диңгез буендагы бер шәһәре. Монтано белән ике офицер керәләр.

Монтано

Диңгез уртасында берәр нәрсә
Күренмиме?

I офицер

Юк, бернәрсә күренми.
Котыра дулкын. Ерак күк читеннән,
Ичмасам, бер җилкән күрсәң икән!

Монтано

Бу давылдан бүген җир өстендә
Калын таш диварлар дерелдәде.
Бу коточкыч давыл диңгездә дә
Шулкадәре көчле булган булса,
Дулкын тауларының ишелүенә
Нинди генә имән кораблар да
Чыдый алмас. Нинди хәбәр ишетербез?

II офицер

Төрек флотының һәлакәтен.
Яр читләрен ап-ак күбек баскан.
Карагыз: ачулы зур дулкыннар
Шундый айкалалар, тамчылары
Болытларга кадәр чәчрәп менә;
Көчле давыл таудай дулкыннарның
Бөдрә чал ялларын йолкып алып
Җидегән йолдызына кадәр чөя,
Әйтерсең ул котып сакчыларын[1]

Сүндерергә тели суга манчып.
Дулкыннарның болай котыруын
Һичбер вакыт күргәнем юк минем.

Монтано

Портка гына кереп сыенмаса,
Төрек флоты хәзер су төбендә.
Бу давылда ничек исән калсын?

III офицер керә.

III офицер

Әфәнделәр, хәбәр, яңа хәбәр!
Сугыш бетте. Шашкын давыл
Төрекләрне тәмам тар-мар иткән.
Димәк, планнары юкка чыккан.
Венециянең бер зур корабы
Төрек флотының һәлакәтен,
Күп өлеше су төбенә китеп
Харап булганлыгын күреп торган.

Монтано

Дөресме бу?

III офицер

Менә әле генә
Безнең портка «Верона» исемле
Кораб килеп керде. Ул корабта
Батыр Отеллоның лейтенанты
Микаэль Кассио килде.

Отелло

Әле юлда. Кипр утравына
Ул хөкемдар итеп билгеләнгән.

Монтано

Моңа мин шат: аннан лаеклырак
Хөкемдарны табу мөмкин түгел.

III офицер

Ләкин Кассио төрек флотының
Һәлак булуына шатланса да,
Яшерә алмый үзенең борчылуын,
Коткар, Раббым, Отеллоны дип, ул
Һаман теләк тели. Давыл купкач,
Аерылганнар алар бер-берсеннән.

Монтано

Сакла аны, Раббым, һәлакәттән!
Мин бит Отеллоның кул астында
Хезмәт иткән идем. О, ул оста,
Менә дигән гаскәр башлыгы ул.
Портка барыйк, күрик ул корабны.
Текәп аннан күзне еракларга,
Без күзәтик, диңгез киңлегендә
Отеллоны алып килә торган
Кораб күренмиме?

III офицер

Әйдә киттек!
Һәрбер минут кыйммәт — чөнки аның

Менә-менә килеп җитүе бар.

Кассио керә.

Кассио

Сәлам сезгә, Кипр утравының
Батыр сакчылары. Отеллоны
Болай хөрмәт итүегез өчен
Рәхмәт сезгә. Раббым! Отеллоны
Һәлакәттән сакла. Котырынган
Диңгез уртасында югалттым мин аны.

Монтано

Ничек соң, корабы нык идеме?

Кассио

Корабы нык. Койрыкчысы да шәп,
Менә дигән тәҗрибәле кеше.
Шуңа күрә аның сау-сәламәт
Килеп җитүенә мин ышанам.

Сәхнә артында тавыш.

«Кораб! Кораб!»

Кассио

Анда нинди шау-шу?

IV офицер керә.

IV офицер

Шәһәр бушап калды, бөтен халык
Яр буена тулды, бар да бердән
«Кораб, кораб» диләр.

Кассио

Сизеп торам,
Бу — хөкемдар.

Туп тавышы ишетелә.

II офицер

Кораб салют бирә,
Дуслар килә дигән сүз бу!

Кассио

Синьор,
Рәхим итеп, барып кем икәнен
Белегез дә миңа хәбәр итәрсез.

II офицер

Киттем.

Китә.

Монтано

Лейтенант, әйтегезче, генерал
Өйләнмәдеме?

Кассио

Өйләнде, кызның
Менә дигәненә — ул бәхетле.
Кызның чибәрлеген тасвирларга
Тел сәләтсез, каләм көчсез;

Табигатьнең тиңсез бизәге ул.

II офицер керә.

Кассио

Йә, ни бар? Кем килгән?

II офицер

Ниндидер Яго,
Генералның順 поручигы.

Кассио

Кара!
Ничек тиз һәм бәла-казаларга
Очрамыйча килеп җитә алган!
Корабларга бәла китерүче
Көчле давыл, шашкын, ярсу диңгез,
Кыя ташлар, сай җирдәге комнар, —
Әйтерсең лә яшь Дездемонаның
Гүзәллеген күргәч, аның юлы
Тыныч, куркынычсыз булсын өчен
Шомлы холыкларын үзгәрткәннәр.

Монтано

Нинди хатын соң ул Дездемона?

Кассио

Безнең генералның генералы.
Аны монда алып килү бурычы
Поручик Ягога тапшырылган иде,
Алар без көткәнгә караганда
Төгәл сигез көнгә алдан килде.
Бөек Тәңре, сакла Отеллоны!
Көчле тының белән өр җилкәнгә,
Ул корабы белән монда туктап
Бу утрауның халкын шатландырсын,
Тизрәк яшь Дездемонасын кочсын,
Сүнгән күңелебезгә ут кабызсын,
Шомлануčы Кипр утравына
Бәхет һәм тынычлык алып килсен.
О, күрегез менә!

Дездемона, Эмилия, Яго, Родриго һәм хезмәтчеләр керәләр.

Корабның
Тиңсез хәзинәсе җиргә төште.
Кипр утравының егетләре,
Каршысына килеп тезләнегез!
Пакь күңелдән сәлам сезгә, синьора!
Хак Тәңренең бөек мәрхәмәте
Сезне төрле яктан урап алсын!

Дездемона

Чын күңелемнән рәхмәт. Йә, Кассио,
Ирем турысында ни әйтәсез?

Кассио

Ул сәламәт, тиздән килеп җитәр.

Дездемона

Аһ, мин куркам!.. Ничек аерылдыгыз?

Кассио

Безнең аерылуга диңгез белән
Күкнең тартышуы сәбәп булды.
Тукта! Анда тавыш: «Җилкән», — диләр.

Сәхнә артыннан тавыш: «Җилкән! Җилкән!» Туп тавышлары яңгырый.

II офицер

Туп тавышы. Бу — крепостька салют.
Димәк, тагын дуслар килә.

Кассио
*(икенче офицерга)*

Барып бел.

Офицер китә.

А, саумысыз, поручик?
*(Эмилиягә.)*
Синьора, саумысыз?
*(Аны үбә.)*
Гафу ит, Яго,
Бу фигылем өчен син ачуланма.
Нишлим соң, тәрбиям шундый инде,
Кешеләргә хөрмәт күрсәткәндә,
Мин үземне шулай иркен тотам.

Яго

Әгәр дә ул сине ирене белән,
Һәр көн мине әче теле белән
Сыйлагандай сыйлый торган булса,
Син бөтенләй хәлдән таяр идең.

Дездемона

Юк, ул андый әче телле түгел.

Яго

Кирәгеннән артык әче телле.
Мин түшәккә яткач һәр көн сизәм.
Сезнең алдыгызда ул тел яшерә,
Үзе эчтән мине тиргәп тора.

Эмилия

Һич урынсыз синең бу сүзләрең.

Яго

Әлбәттә! Сез кеше арасында
Менә дигән сокландыргыч сурәт,
Кунак бүлмәсендә — сез кыңгырау,
Аш-су бүлмәсендә — азгын песи,
Кешене тиргәгәндә — сез изгеләр,
Үзегез тиргәлгәндә — шүрәлеләр;
Хуҗалыкта юньсез, ә түшәктә
Чын-чын хуҗа.

Дездемона

Фу, нинди әдәпсез,
Гайбәт төенчеге!

Яго

Дөресе шулай,
Ялганласам, төрек булыйм. Сез, таң аткач,
Юкны бушка төяү өчен торасыз,
Кич җитүгә, эш эшләргә ятасыз.

Эмилия

Мактау сүзен көтмим дә мин синнән.

Яго

Әйтмим дә мин аны.

Дездемона

Ул бурычны
Мин йөкләсәм? — Макта мине дисәм?

Яго

О, хөрмәтле синьора, булдыралмыйм;
Тик яманлый гына беләм бит мин,
Булмый.

Дездемона

Шулай да бер көчең сынап кара...
Портка кем дә булса китмәдеме?

Яго

Китте, синьора.

Дездемона

Күңелсез миңа,
Шат күренгән булып үз-үземне
Алдыйм гына. Йә, әйт, ничегрәк
Мактар идең мине?

Яго

Фикерләрем,
Постау кисәгенә сылап куйган
Кошлар аулый торган җилем төсле,
Башыма ябышканнар, тартып алсам,
Мием ябышып чыга. Әһә, булды —
Иҗат газаплары үтеп китте,
Илһамымның җимеше пешеп җитте.

Матур кызның акылы булса,
Ике яклап файда аңа:
Матурлыгы — зур хәзинә,
Акылы шуннан файдалана.

Дездемона

Шәп мактадың! Әгәр дә ул хатын
Бик акыллы, ләкин ямьсез булса?

Яго

Бик акыллы, ләкин үзе
Кара булса, ул барыбер
Сары чәчле, чибәр генә
Бер егетне иләштерер.

Дездемона

Монысы тегесеннән дә әшәкерәк.

Эмилия

Матур булып, үзе ахмак булса?

Яго

Матур булгач, аңа нәрсә?
Акылга бик исе китә!
Аңа бала булдырырга
Ахмаклыгы ярдәм итә.

Дездемона. Сөрсеп беткән бу такмаклар кабактагы исерекләрне көлдерергә генә ярый. Әгәр ямьсез дә, ахмак та булса, ул хатынга нинди мактау җыры җырларсың?

Яго

Акыллы һәм гүзәлләрдән
Артта калмас ул барыбер,
Алар кылган гөнаһларның
Барысын да эшли белер.

Дездемона. Нинди ахмаклык! Иң начарны иң шәп итеп мактыйсың. Йә, әйт әле, мактауга чынчыннан лаеклы, гүзәл сыйфатлары белән гайбәтнең үзен телсез калдыра торган хатынны ничегрәк мактар идең?

Яго

Чибәр, ләкин тыйнак булса;
Тапкыр, ләкин телен тыйса;
Байлык белән масаймаса;
Нәфесенә кол булмаса;
Акылын җуймый ярсуыннан.
Тыела белсә үч алудан;
Күңеле азып, җуеп акылын
Алмашмаса треска башын
Лосось балык койрыгына;
Кызыгып матурлыгына
Ияргәндә егет-җилән
Мавыкмаса алар белән;
Менә, ичмасам, шәп хатын бу,
Дөньяда әгәр андый булса...

Дездемона

Йә, ул нәрсәгә лаек була?

Яго

Бала-чага имезергә,
Иренә сыра китерергә.

Дездемона. Фу, нинди әдәпсез! Ирең булса да син аны тыңлама, Эмилия! Йә, әйт әле, Кассио, ул үзенең бу сүзләре белән әдәпсезлеккә һәм азгынлыкка өйрәтә түгелме?

Кассио. Ул сүзгә тупас, ләкин әйбәт солдат. Сез аны вәгазьче итеп түгел, солдат итеп яратыгыз.

Яго *(читкә).* Ул Дездемонаның кулын тота! Әйбәт! Пышылдашыгыз! Пышылдашыгыз! Кассио — зур чебен, әлбәттә, ләкин аны бик нечкә пәрәвез белән дә аулап була. Елмай әйдә, елмай! Мин сине шушы ягымлылыгың белән аулармын. *(Кычкырып.)* Бик дөрес әйтәсез, чыннан да шулай. *(Читкә.)* Бу фокусларың аркасында лейтенантлыгыңнан колак кагасыңны белсәң, нәзакәтлек күрсәткән булып, бармак очларыңны бу кадәр еш үпмәс идең. Бик әйбәт, менә дигән итеп үбәсең, бик нәзакәтле чыга. Бармак очларын тагын иренена китерде. И, бармакларың клизма трубкасына әйләнгере!

Сәхнә артында быргы тавышы.

Яго. Әнә мавр да килеп җитте! Мин аның быргы тавышын таныйм.

Кассио

Әйе, бу ул.

Дездемона

Әйдә, каршы барыйк.

Кассио

Әнә үзе килә.

Хадимнәре белән Отелло керә.

Отелло

О, син, батыр дустым!

Дездемона

Бәгърем, Отеллом!

Отелло

Миннән алда килеп җитүеңә
Хәйран калам. О, шатлыгым, бәхетем!
Һәрбер көчле давыл азагында
Шундый бәхет килә торган булса,
Үкерсен җил, шомлы тавышы белән
Ул уятсын үлем-газраилне,
Киң диңгездә йөзгән зур кораблар
Олимп тавы кебек дулкыннарның
Түбәсенә менсен йомычкадай,
Аннан тагын шул ук тизлек белән
Төпсез зур упкынга барып төшсен.
Менә хәзер миңа үлем килсә,
Аны зур бәхеткә санар идем —
Чөнки күңелем тулы шундый шатлык,
Киләчәктә мондый зур шатлыкны
Күрә алмам диеп куркам.

Дездемона

А, юк!
Киресенчә, Хода ярдәмендә,
Гомер үткән саен бу мәхәббәт
Арта гына барыр.

Отелло
Фәрештәләр
«Амин» дигән чакка туры килсен!
Аһ, күңелемә тулган шатлыгымны
Мин сүз белән генә аңлата алмам.
Менә монда килеп тыгылды ул.
Чиксез рәхәт миңа!

Дездемонаны үбә.

Менә, менә!
Арабызда низаг туса да, без аны
Менә шулай *(үбә),* шулай тәмамларбыз.

Яго
*(читкә)*

Әлегә кәефегез шәп,
Музыкагыз көйле, матур яңгырый.
Ләкин мин ант итәм намусым белән,
Көйле бу музыкагызның моңын
Бозу өчен, мин кылларыгызны
Бушатырмын.

Отелло

Әйдәгез замокка...
Тәбрик итәм, дуслар, шатлык белән:
Сугыш бетте, төрек флоты батты.
Ничек икән монда, иске дуслар
Ничек яши икән? Сине, иркәм,
Бик зур шатлык белән каршыларлар:
Монда мине яраталар иде.
О, сөеклем! Шатлыгымнан исереп,
Кирәгеннән артык сөйлим бүген.

Үтенәм синнән, Яго, портка барып
Минем әйберләрне алып кайтсаңчы.
Аннан капитанны чакыр миңа,
Әйбәт егет, батырлыгы өчен
Бүләкләргә телимен мин аны.

Отелло, Дездемона һәм хезмәтчеләр чыгып китәләр.

Яго *(хезмәтчеләрнең берсенә).* Бар, мине портта көтеп тор. *(Родригога.)* Йә, Родриго, әгәр дә синең йөрәгеңдә батырлык дигән нәрсә чынлап та булса, — мәхәббәт тойгысы тумыштан куркак кешеләргә дә батырлык бирә, диләр бит, — тыңла мине. Бүген төнгә лейтенант замок сакчыларына башлык итеп билгеләнде. Иң элек мин сиңа шуны әйтергә тиешмен: Дездемона ул егеткә бөтен күңеле белән гашыйк булган.

Родриго. Кассиогамы? Юк, моның булуы мөмкин түгел!

Яго. Телеңне тешлә дә тыңла мине. Беләсең бит, маврга ул бөтен күңеле белән гашыйк булды. Ни өчен диген? — Мавр аны шапырынулары, хыялый әкиятләре белән сихерләде. Коры әкияткә генә нигезләнгән бу мәхәббәт озакка барыр дип уйлыйсыңмы? Ул кадәр беркатлы булма! Кызның күзләренә азык кирәк. Һәрвакыт кап-кара шайтанга карап тору аңа бик күңелле дип уйлыйсыңмыни? Гыйшык ләззәтен татып туйганнан соң, аңа сүнеп калган дәртен яңадан кабызып җибәрү өчен мөлаем йөз, яшьлек гүзәллеге, хәрәкәттә җитезлек, мөлаемлык кирәк — маврда боларның берсе дә юк. Димәк, Дездемона, күңеле теләгән бу сыйфатларны маврда таба алмагач, үзен алданган итеп хис итәр. Маврдан күңеле бизәр, тора-бара аннан җирәнә башлар һәм ахырында аның күңелендә маврга карата нәфрәт уяныр. Моны аңа табигать үзе өйрәтер һәм башка берәүне эзләргә мәҗбүр итәр. Шулай булгач, үзең уйлап кара, аның каршында бу бәхеткә ирешә алырлык Кассиодан башка тагын кем бар? Ул сүзгә оста, яшерен хисләренә бирелеп хайвани теләгенә ирешү өчен, нәзакәтле һәм кешелекле булып күренә белә. Монда инде аның белән беркем дә тиңләшә алмый! Беркем дә! Күңеле бик азгын, үзе бик мут, форсаттан файдалана белә; юньле сыйфатлардан бөтенләй мәхрүм булуына карамастан, ул үзен менә дигән кеше итеп күрсәтә ала. Шайтан шикелле мут! Өстәвенә искиткеч матур, үзе яшь, — кыскасы, тәҗрибәсез кызның башын әйләндерү өчен бөтен мөмкинлекләре бар. Бик әшәке, бозык егет! Дездемона исә аңа авышып та өлгерде инде.

Родриго. Моңа мин ышана алмыйм. Дездемона әдәпле хатын.

Яго. Чәнчелеп китсәнә шул әдәплелегең белән! Ул эчә торган шәраб шул ук йөзем җимешеннән түгелмени? Ул әдәпле булса, бервакытта да маврны яратмас иде. Әдәпле, имеш! Азгын шайтан ул! Күрешкәндә Кассионың кулын кытыклавын күрмәдеңмени? Йә, күрмәдеңмени?

Родриго. Күрүен күрдем, ләкин бу гади күрешү, аңа ихтирам күрсәтү генә иде.

Яго. Юк, ант итеп әйтәм, Родриго, бу — азгынлык. Әдәпсез уйлар, бозык эшләрнең шомлы башлангычы бу. Иреннәре шулкадәр якынайды, сулышлары белән үбешеп тордылар алар. Әшәке ният бу, Родриго! Бер-бере белән бу кадәр якынайгач инде, озакламый тәннәре тәнгә кушылып, төп эшкә тотынырлар... Юк, Родриго, син инде миңа үз өстеңнән җитәкчелек итәргә рөхсәт ит. Сине бит Венециядән монда мин алып килдем. Бүген төнлә сакчылар арасында бул. Мин сине билгеләтергә тырышырмын. Кассио сине белми. Мин сездән ерак булмам. Ничек тә Кассионы ачуландырырга тырыш: кычкырып сөйләшепме, аның әмерләреннән көлепме... яки башка берәр юл беләнме, кыскасы, җаена карап эш итәрсең.

Родриго. Яхшы.

Яго. Кассио кызу табигатьле кеше, ачуландырсаң, үз-үзен белми. Ихтимал, ул сиңа салып та җибәрер. Син аны әнә шул хәлгә җиткерергә тырыш. Ә мин шул кечкенә генә вакыйганы күпертеп, зур бер бунт итеп күрсәтермен. Бунтны туктату өчен, Кассионы урыныннан алып ташлау кирәк булыр. Шулай итеп, синең теләкләреңнең тиз көндә үтәлүенә киң юл ачылыр. Юлыбызга аркылы торган киртәне алып ташласак, безгә комачаулардлык кеше калмый.

Родриго. Ярый. Җае туры килсә, мин моны эшләрмен.

Яго. Ә мин туры килүенә ышанам. Соңыннан крепостька кил. Мин хәзер портка, маврның әйберләрен алырга китәм. Хуш.

Родриго

Хуш.

Китә.

Яго

Кассионың Дездемонаны сөюенә
Мин ышанам. Шулай ук һәм аның да
Кассионы сөюе бик табигый.

Ә мавр — гәрчә мин ул маврны
Бөтен күңелем белән дошман күрсәм дә,
Дөресен әйтү кирәк, ул намуслы,
Көчле сөя ала торган кеше.
Әйбәт, менә дигән ир булырлык.
Ул хатынны үзем дә мин сөям;
Ул кадәр үк шашып түгел, әлбәттә,
Чөнки минем бу мәхәббәтемдә, —
Бәлки, кичермәслек гөнаһтыр бу, —
Отеллога үч тойгысы ята.
Азгын мавр минем түшәгемә
Бик күп мәртәбәләр менгән дигән
Шик бар миндә! Менә шушы шигем
Агу булып ага тамырларда,
Күңлем әрни минем, бәгърем көя.
Азгын мавр миңа хатыным өчен
Хатыны белән түләмичә торып,
Мәңге тапмам дәва әрнүемә.
Алай булмый икән, йөрәгенә
Мин көнчелек уты ягармын,
Ул көнчелек дигән аждаһаны
Акыл көче генә җиңә алмас.
Бу эш әйбәт барып чыксын өчен,
Кассионы файдаланырмын мин.
Тик бу эшкә теге юньсез адәм —
Венеция эте, ахмак Родриго
Комачаулык китерүе мөмкин.
Хәер, мин ул этне, киек кош артыннан
Артык кызу чабалмасын өчен,
Чылбыр белән кулда тотып барырмын.
Кассиога ярдәм иткән булырмын.
Ә маврга аны мин коточкыч
Шакшы кеше итеп күрсәтермен.
Миңа калса — төнге калфагымны
Кассио да кигәләгән бугай.
Эшне шулай алып барырмын мин,
Чиксез зур осталык белән үзен
Ахмак карт ишәккә әйләндереп,
Гамьсез тынычлыктан шаштыруга
Илтеп җиткерүем өчен, мавр
Рәхмәт укыр миңа, бүләк бирер.
Әле болар коры хыял гына,
Очына кадәр уйланмаган әле.
Ләкин хәйлә тәмам пешеп җитеп
Үтәлгәнгә кадәр яшерен була!

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урам. Кулына игълан тоткан Герольд керә. Аңа бер төркем халык ияргән.

Герольд *(укый).* Батыр генералыбыз Отелло төрек флотының һәлакәте турындагы шатлыклы хәбәр мөнәсәбәте белән зур бәйрәм үткәрелүен, бөтен утрау халкының, тантаналы рәвештә утлар яндырып, уен-көлке, биюләр оештыруын, кыскасы, һәркемнең күңеле теләгәнчә бәйрәм итүен тели. Генерал Отелло бу тантана белән бергә үзенең никах бәйрәмен дә үткәрә, һәм бу хәбәрне бөтен утрауга белдерергә кушты. Сарайның бүлмәләре ачык, ул бүлмәләрдә һәркем хәзерге сәгать биштән алып төнге унбергә кадәр күңел ача ала. Бөек Тәңре Кипр утравына һәм безнең затлы генералыбызга үзенең рәхмәтен иңдерсен.

Китә.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Замок эчендә зал.
Отелло, Дездемона, Кассио һәм хезмәтчеләр керәләр.

Отелло

Микаэль, син төнге каравылга
Күз-колак бул. Күңел ачкан чакта да
Тыйнак һәм сак булу кирәклекне
Онытырга һич кенә дә ярамый.

Кассио

Мин Ягога боерык бирдем инде.
Шуңа карамастан мин һәммәсен
Үзем күзәтәчәкмен.

Отелло

Яго ул
Бик намуслы кеше. Йә, хуш, Микаэль,
Хәерле төн. Иртән иртәрәк кил,
Минем синең белән сөйләшәсем бар.
Киттек, бәгърем. Төгәлләнгәч эшең,
Мөмкин хәзер бәхетеңнең җимешен
Авыз итәргә. Хәерле төн сезгә.

Отелло, Дездемона һәм хезмәтчеләр китәләр.
Яго керә.

Кассио. Ә, Яго! Килүең әйбәт булды. Каравылга китәргә вакыт.

Яго. Иртә әле, лейтенант. Сәгать ун да тулмаган. Генерал бит сөекле Дездемонасын сагынганга күрә генә бүген безне болай иртә җибәрде. Моның өчен аны гаепләп тә булмый: аның бит әле сөеклесе белән бер кич тә кунганы юк. Ә хатыны бит Юпитер сокланырлык.

Кассио. Әйе, искиткеч гүзәл хатын!

Яго. Өстәвенә ут кебек дәртле.

Кассио.Әйе, гаҗәп гүзәл, искиткеч хатын.

Яго. Ә күзләре нинди! Яшерен сөйләшик дип чакырып торалар.

Кассио. Әйе. Шуның белән бергә әдәпле күзләр.

Яго. Сөйләшкән чагында сөешергә чакырып тора.

Кассио. Әйе. Дөресен әйтергә кирәк, ул хатын — гүзәлләрнең гүзәле!

Яго. Бик дөрес. Инде никахлары хәерле булсын!.. Миндә, лейтенант, сезнең өчен әзерләнгән бик әйбәт шәраб бар. Монда, якында гына, Кипр егетләре дә җыйналган. Алар кара Отеллоның сәламәтлегенә берәр бокал күтәрергә телиләр.

Кассио. Бүген түгел, сөекле Яго. Шәраб минем башыма бик тиз китә. Шуңа күрә күңел ачу өчен икенче берәр нәрсә уйлап табар идең.

Яго. Якын дуслар бит алар. Берәр генә бокал, артык түгел.

Кассио. Мин бүген бер бокал эчкән идем инде, аны да су белән катыштырып кына. Күрәсең, ул да нык кына тәэсир иткән. Юк, мин үземнең йомшаклыгымны беләм, ул йомшаклыкны тагы бер кабат сынап карарга батырчылык итә алмыйм.

Яго. Бу төн бит күңел ачу төне. Моны бит үзебезнең егетләр тели...

Кассио. Кайда соң алар?

Яго. Монда, күрше бүлмәдә. Сез аларны бирегә чакырыгыз.

Кассио. Яхшы. Ләкин һич кенә дә күңелем тартмый.

Китә.

Яго

Айнып өлгермәгән бу егеткә
Тагын да бер бокал эчереп булса,
Җитте миңа; ул кәпрәер, кызар,
Хатынымның этеннән дә болай
Ярсуланып, усалланып китәр.
Теге ахмак, гыйшкы зәхмәтеннән
Эчми исереп йөргән җүләр Родриго,
Яшь Дездемонаның саулыгына
Бик мул итеп салып та өлгергән.

Ул да бүген каравылга чыга.
Шулай ук бу Кипр утравының
Ярсу табигатьле өч-дүрт егетен дә
Әйбәт кенә итеп сыйлап алдым.
Алар үзләренең намусы өчен,
Кипр утравының даны өчен
Җан бирергә әзер. Бүген алар да
Төнге каравылга чыга. Инде
Кассионы әйбәт кенә сыйлап,
Шушы исерекбашлар арасында
Бу утрауның халкын мыскылларлык
Берәр нәрсә эшләтәсе калды.
Менә алар! О, бу ниятемнең
Бик аз гына өлеше барып чыкса да,
Җилкәнемә буйсынучан кораб
Алга очар дулкыннарны ярып!

Кассио, Монтано һәм берничә Кипр офицеры керәләр.

Кассио. Алла белән ант итеп әйтәм, алар мине сыйлап та өлгерделәр.

Монтано. Нәрсә инде, сөйләп торырлыкмыни? Бер бокал бит, ул да уймак кадәр генә. Солдат намусы белән ант итеп әйтәм, артык түгел.

Яго

Әй, тагын да шәраб китерегез!
*(Җырлый.)*
Чәкәшсен бокаллар, чеңләсен,
Чәкәшеп серләшсен-сөйләшсен!
Солдат та — кеше;
Ул яши бер генә!
Эчсен дә күңелен күтәрсен!
Әй, хезмәтчеләр, шәраб китерегез!

Кассио

Әйбәт җыр, шайтан алгыры!

Яго. Мин аны Англиядә өйрәнгән идем. Аһ, менә анда, ичмасам, эчә беләләр! Даниялеләр, немецлар, юан корсаклы голландиялеләр эчүгә килгәндә инглизләр каршында чүп кенә!

Кассио. Инглизләр дә оста эчәмени?

Яго. О, әйтерең бармы! Данияле бераз эчсә, аяктан егыла, немец үлек кебек тәгәрәп ята, голландияле коса, ә инглиз әле бу вакытта бөтенләй аек була.

Кассио. Генералыбыз саулыгына!

Монтано. Аның саулыгына мин дә эчәм, лейтенант... Сездән калышмыйм.

Яго

Аһ, гүзәл Англия!
*(Җырлый.)*
Король Стефан данлы булган,
Илле тиенгә ыштан теккән,
Ә соңыннан, кыйбатсынып,
Тегүчене тотып сүккән.
Король Стефан — зур каһарман!
Ә син — йолкыш, өтек, надан.
Ул да исраф харам, дигән,
Ябынып йөргән ертык җилән.
Әй, тагын да шәраб китерегез!

Кассио. Бу җыр тегесеннән дә шәбрәк.

Яго. Тагы бер кат тыңларга теләмисезме?

Кассио. Юк, бернәрсәне кат-кат тыңлаучыны мин урынына лаексыз дип саныйм... Хәер, һәркем өстеннән хөкем йөртүче Алла бар. Берәүләрне ул ярлыкар, берәүләрне һәлак итәр.

Яго. Бик дөрес әйтәсез, сөекле лейтенант.

Кассио. Ә минем мәсьәләгә килгәндә, генералның яки башка берәр затлы кешенең кәефен кыру нияте белән әйтмим, — мин җәннәткә керермен дип өмет итәм.

Яго. Мин дә үз турымда шулай уйлыйм, лейтенант.

Кассио. Шулай, ләкин әйтергә рөхсәт итегез, сез җәннәткә миннән алда керә алмыйсыз. Лейтенант җәннәткә поручиктан алда керергә тиеш. Йә, җитәр... Эшкә тотынырга вакыт! Раббым, кичер безнең гөнаһларыбызны! Синьорлар, эшкә! Сез мине, синьорлар, исерек дип уйламагыз. Менә бу минем поручигым — уң кулым, ә бу — минем сул кулым. Мин исерек түгел. Мин аякларымда нык басып торам, әйткән сүзләрем дә дөрес минем.

Барысы да. Әйе, бик әйбәт.

Кассио. Әһә! Әйбәт шул, үзегез үк әйтеп бирдегез! Димәк, мине исерек дип уйларга хакыгыз юк...

Китә.

Монтано. Мәйданга чыгыйк, синьорлар! Каравыл куярга киттек.

Яго

Күрдегезме безнең лейтенантны?
Нинди кыяфәттә чыгып китте?
Батырлыгы белән ул Цезарьга
Тиңләшерлек. Шушы зәхмәтеннән
Бизә алса, бөтен гаскәр белән
Җитәкчелек итә алыр иде.
Батырлыгы белән йомшаклыгы,
Көн белән төн кебек, бер-берсенә
Капма-каршы көрәш алып бара.
Мин кызганам аны. Менә хәзер —
Чыгырыннан чыккан вакытында —
Отеллоның аңа ышанычы
Кипр утравына берәр төрле
Бәла китермәгәе дип куркам.

Монтано

Мондый чагы аның еш буламы?

Яго

Йокы алдыннан ул һәрвакыт шулай.
Шәраб эчеп, исереп тирбәлмәсә,
Тәүлек буе йоклый алмый, мескен.

Монтано

Алай булгач, аны генералга
Әйтү кирәк, бәлки, ул белмидер?
Йә булмаса күңеле хушлыгыннан,
Аның яхшы ягын гына күреп,
Начар якларына күз салмыйдыр.
Шулай түгелме? Ә?

Родриго керә.

Яго

Родриго, синме?
Нигә килдең монда? Бар, тиз йөгер!
Лейтенантның артыннан бар, тиз бул!

Родриго китә.

Монтано

Отеллоның лейтенантлык кебек
Мөһим вазифаны шушындый зур
Кимчелекле кешегә тапшыруы
Бик кызганыч. Намусым моны
Отеллога белдерергә куша.

Яго

Әйе. Ләкин бөтен бер Кипрны
Бирсәләр дә, моңа мин алынмам.
Кассионы үлеп яратам мин.
Бу зәхмәттән аны йолу өчен
Әллә ниләр эшләр идем. Бу ни?
Нинди шау-шу анда?

Сәхнә артында тавыш.

Родриго

Ярдәм! Ярдәм!

Родриго йөгереп керә. Аның артыннан Кассио куып килә.

Кассио

Ах, эшлексез! Юньсез!

Монтано

Чү, лейтенант,
Нәрсә булды?

Кассио

Мине хезмәт тәртибенә
Өйрәтмәкче була! Ах, кабахәт!
Бутылкага бөтереп тыгам хәзер!

Родриго

Минеме? Ә?

Кассио

Ах, эшлексез! Әле
Акыл сатып торасыңмы?

Монтано

Сабыр!
Туктагыз, лейтенант, кулыгызга
Алай ук бирмәгез ирек! Сабыр.

Кассио

Җибәр мине, җибәр! Юкса синең дә
Тешләреңне сугып җимерәм хәзер.

Монтано

Күрәм, сез исерек.

Кассио

Минме исерек?

Монтано

Әйе, сез исерек!

Кылычларын суырып алып, сугыша башлыйлар.

Яго
*(Родригога әкрен)*

Йөгер тизрәк.
Сөрән сал, ярдәмгә халык чакыр!

Родриго китә.

Ах, лейтенант, синьор, зинһар, туктагыз!
Сабыр, дим, Кассио! Синьор Монтано!
Әй, синьорлар! Ярдәм, ярдәм итегез!..
Каравылчыларын әйтер идем!

Чаң сугалар.

Әй, кем ул чаң суга? Шайтан, тукта!
Бөтен кала халкын уятасың!..
Әй, лейтенант, сабыр, дим, гомерлек
Мәсхәрәгә каласыз бит. Туктагыз!

Хезмәтчеләре белән Отелло керә.

Отелло

Нинди шау-шу монда? Нәрсә булды?

Монтано

Ярам тирән, каным агып бетә,
Миңа үлем килә, — ул да үлсен!
*(Кассиога ташлана.)*

Отелло

Җаннарыгыз газиз булса, туктагыз!

Яго

Сабыр, дим, лейтенант! Синьор Монтано!
Бурычыгызны, кайдалыгыгызны
Оныттыгыз мәллә? Әй, синьорлар!
Айныгыз — генерал каршыгызда!
Җитәр, дим! Ичмасам, оялыгыз!

Отелло

Акылыгыздамы сез? Нинди гауга?
Нидән чыкты? Хода әмерен бозып,
Бер-береңә кылыч күтәрергә
Без төрекләр мәллә? Туктагыз!
Христианлык намусы кыйммәт булса,
Туктатыгыз хәзер бу сугышны!
Кем дә кем ярсуын тыя алмый,
Димәк, аңа җаны газиз түгел.
Кем кузгала — хәзер үлем аңа!
Бу коточкыч чаңны туктатырга!
Шомландыра ул бар утрау халкын.
Нәрсә булды монда? Тугры Яго,
Синең йөзең мәет йөзе кебек,
Сөйлә хәзер, кем башлады? Көтәм.

Яго

Мин белмимен, әле генә
Менә дигән якын дуслар идек.
Яңа өйләнешкән гашыйклар күк,
Тату гына утыра идек. Кинәт
Әйтерсең койрыклы йолдыз төшеп
Барысының акылын алды, шундук
Кылычларын суырып чыгардылар.
Канлы сугыш китте. Бу ызгышның
Нидән башланганын әйтә алмыйм.
Аһ, нигә мин берәр данлы яуда
Аякларым югалтмадым икән?
Килмәс идем монда, мондый эшкә
Шаһит булып җавап бирмәс идем!

Отелло

Ничек син, Микаэль, бурычың онытып
Сабырлыгың җуйдың?

Кассио

Аһ, генерал,
Кичерегез, сөйли алмыймын мин...

Отелло

Ә сез, затлы Монтано, һәрвакыт
Әдәплелек белән мактaлдыгыз.
Сабырлыгыгызга ил сокланды,
Илнең агалары исемегезне
Һәрчак хөрмәт белән телгә алды.
Шундый данны, ихтирамны җуеп,
Данлы исмегезгә тап төшереп,
Төнге юлбасарга әверелергә
Сезне нәрсә мәҗбүр итте? Сөйләгез!

Монтано

Батыр Отелло, мин яраландым,
Каты яраландым, минем хәлем юк...
Күрәсез бит, көчкә-көчкә сулыйм.
Мин белгәнне менә поручик Яго
Барысын да сөйләп бирер сезгә.
Ә мин шуны беләм: үз-үзеңне
Яклау җинаятькә саналмаса,
Өскә туры һөҗүм килгән чакта
Кылыч алу гөнаһ саналмаса,
Бүген мин бер гөнаһ эшләмәдем.

Отелло

Мин ант итеп әйтәм, каным кыза,
Көчле ярсу акылымны каплап
Мине үз кулына алмак була.
Бер кузгалсам хәзер, кул күтәрсәм,
Иң шәбегез минем ярсуыма
Корбан булыр. Бу әшәке җәнҗал
Кайдан чыкты? Кем башлады моны?
Ул эшлексез, кан кардәшем булса да,
Шәфкать булмас миннән — гафу итмәм.
Бу ни? Хәрби шәһәр уртасында,
Әле кешеләрнең коты очып
Торган бервакытта, өй эчендә
Җәнҗал куптарырга! Ә? Җитмәсә,
Төнлә, каравылда! Бу коточкыч!
Әйт, Яго, кем? Кем башлады моны?

Монтано

Кара аны, дуслык хисенә бирелеп
Яки ара бозылудан куркып,
Дөреслеккә ни дә булса кушсаң
Йә киметсәң, — солдат түгел син, Яго.

Яго

Хурлама син мине. Кассионы
Хурлый торган начар сүз әйткәнче,
Телем кистерергә риза булырмын.
Ләкин мин ышанам, туры сүзем
Аңа зарар итмәс. Эш, генерал,
Болай булды: Монтано белән икәү
Без сөйләшеп тора идек шунда.
Кинәт шулчак ниндидер бер адәм:
«Ярдәм, ярдәм!» — диеп йөгереп керә,
Ә Кассио, кылыч айкый-айкый,

Аны куып килә. Синьор Монтано
Кассионы каты ярсуыннан
Тыймак булып аның юлын бүлде,
Ә мин, халык уянудан куркып, —
Нәтиҗәдә шулай килеп чыкты да, —
Сөрән салып чапкан ул адәмне
Куа киттем. Ләкин ул бик җитез,
Йөгерек булып чыкты — тоталмадым.
Шуннан инде ашыгып монда чаптым.
Чөнки монда кылыч чыңгылдавын,
Кассионың, моңа кадәр һичбер
Ишетмәгән каты сүзләр белән
Әче сүгенүен ишетеп калдым.
Мин килгәндә, менә сез күргәнчә,
Ярсып-ярсып сугышалар иде.
Менә шуны гына әйтә алам.
Ләкин кеше һәрвакытта кеше,
Һәр кешенең ярсып китүе мөмкин.
Монтанога кылыч күтәрүдә
Кассионың гаебе, әлбәттә, бар;
Ләкин нишлисең бит, ярсыганда,
Якын дустыңны да тотып ярасың.
Шуңа мин ышанам: Кассионы
Теге сөрән салып чапкан адәм
Шундый каты ярсытырлык итеп
Мыскыл иткән. Ул тик шуңа күрә генә
Сабырлыгын җуйган.

Отелло

Беләм мин, Яго,
Кассиога булган дуслыгыңа
Бирелеп китеп, күңлең йомшаклыктан,
Аның гаебен йомшартырга телисең.
*(Кассиога.)*
Мин, Кассио, сине бик яратам,
Шулай да син шушы көннән башлап
Лейтенантым түгел.

Хезмәтчеләре белән Дездемона керә.

Отелло

Әнә карагыз,
Сөеклемне дә сез уяттыгыз.
*(Кассиога.)*
Башкаларга үрнәк булсын өчен,
Сиңа шундый каты җәза бирәм.

Дездемона

Нәрсә булды, бәгърем?

Отелло

Болай гына. Инде бетте.
Әйдә киттек, иркәм.
Сезнең җәрәхәтегезгә, Монтано,
Үзем хирург булырмын. Алыгыз.

Монтаноны алып китәләр.

Син, Яго, шәһәрне әйләнеп чык,
Бу әшәке җәнҗал таушын ишетеп
Борчылучы шәһәр кешеләрен
Тынычландыр. Киттек, Дездемона,
Солдат гомере менә шулай үтә:

Һәр тавышка йокың бүлеп чыгасың.

Яго белән Кассиодан башкалар китәләр.

Яго. Йә, ничек? Нык яраландыгызмы, лейтенант?

Кассио. Шундый яраландым, хәзер миңа бернинди хирург та ярдәм итә алмас.

Яго. Ул ни дигән сүз? Алла ярдәм бирер әле.

Кассио. Данлы исемем, данлы исемем, данлы исемем!.. Аһ, мин данлы исемемне югалттым. Рухымның мәңге үлмәс өлешен, намусымны югалттым мин, миндә хәзер хайванлык кына торып калды. Данлы исемем, Яго, данлы исемем!..

Яго. Ә мин тагын берәр җирегез яраланганмы дип торам. Исем югалтуга караганда яралanудан күбрәк зарар килүе мөмкин. Данлы исем бит ул коры сүз генә. Күп вакытта аны бер дә юкка бирәләр, һәм юк кына сәбәп аркасында тартып та алалар. Җитәр, кайгырмагыз! Генералның мәрхәмәтен кайтару өчен бик күп юллар бар. Ул бит сезне урыныгыздан ачулы минутында төшереп куйды. Ачудан да бигрәк, тәртип кагыйдәсе таләп иткән өчен. Кайчагында бит, усал арысланны куркыту өчен, гаепсез этне тотып кыйныйлар. Яхшылап үтенсәгез, ул сезгә мәрхәмәтен тагын да күрсәтер.

Кассио. Шушындый генерал каршына барып, аңа шундый ярты акыл, исерекбаш, әдәпсез офицерны тәкъдим иткәнче, мин аның үземә нәфрәт күзе белән каравын артыграк күрермен! Эчеп исерергә дә тутый кош сыман сөйләнергә, тавыш чыгарырга, әтәчләнеп сүгенергә, үз күләгәң алдында әллә кем булып шапырынырга! Әй син, шәрабның күзгә күренми торган рухы, әлегә кадәр синең исемең булмаса, Иблис дип атасыннар сине!

Яго. Сез соң, кылыч болгап, кем артыннан йөгердегез? Ни эшләде соң ул?

Кассио. Белмим.

Яго. Шулай мөмкинме инде?

Кассио. Хәтеремдә бик күп вакыйгалар бутала, ләкин берсен дә ачык итеп хәтерләмим. Тавыш чыкты; ни сәбәптән чыкты — белә алмыйм. Ярабби! Ни өчен кешеләр акылларын урлый торган явыз дошманны авызларына алалар икән? Нигә без кәеф-сафа вакытында, хозурланып рәхәтлек җимешен татыганда, хайванга әйләнәбез икән?

Яго. Йә, куегыз! Сез хәзер бөтенләй аек. Ничек болай бик тиз айныдыгыз?

Кассио. Шәраб шайтаны үзенең урынын котырыну шайтанына бирде. Бер әшәкелек икенчесен ияртеп килеп, мине үз-үземнән җирәнергә мәҗбүр итте.

Яго. Куегыз. Сез үзегезне артык каты хөкем итәсез. Әлбәттә, вакытын, урынын, бу илнең хәзерге шартларын исәпкә алып караганда, мин бу хәлнең бөтенләй булмавын теләр идем. Ләкин булган икән инде, хәзер сез аны үз файдагызга хезмәт иттерү ягын карагыз.

Кассио. Урынымны кайтарып бирүен үтенсәм, син эчкече дияр. Гидра шикелле әллә ничә авызлы булсам да, аның бу сүзен ишеткәч, мин телсез калырмын. Башта акыллы булып та, кинәт кенә ахмакка әйләнеп, аннан инде бөтенләй хайванга әверел, имеш! Аһ, нинди мәгънәсезлек! Һәрбер артык бокал каһәрле, эчендә аның шайтан зәһәре!

Яго. Әйбәт шәраб — әйбәт куллана белүчеләр өчен менә дигән нәрсә ул. Юкка хурламагыз аны. Сез миңа шуны әйтегез: минем сезне яратуыма ышанасызмы, сөекле лейтенант?

Кассио. Ышанганга күрә менә эчеп исердем дә.

Яго. Башкалар кебек үк кайчак сезнең дә эчеп исерүегез мөмкин. Хәзер инде нишләргә икәнен мин сезгә өйрәтим. Хәзер бит бездә генерал хатыны генерал. Моны мин шуның өчен әйтәм, Отелло хәзер бөтен игътибарын аның гүзәллеге белән ләззәтләнүгә биргән. Сез Дездемонага барып, дәрәҗәгезне кайтаруга ярдәм итүен сорап, йөдәтеп бетерегез үзен... Ә ул шундый ачык, юмарт, киң күңелле бер хатын ки, берәүнең үтенечен артыгы белән үтәп чыкмаса, аны үзе өчен зур кимчелек итеп саный.

Кассио. Киңәшең әйбәт.

Яго. Чын күңелдән яратканга күрә, сезгә яхшылык телим мин.

Кассио. Мин моңа ихлас күңелемнән ышанам. Иртәгә үк киң күңелле Дездемонага барып, аның ярдәмен сорармын. Болай да барып чыкмаса, мин үземнең бәхетемне бөтенләй югалганга исәпләрмен.

Яго. Барып чыгар. Йә, хәерле кич, лейтенант, миңа каравылга китәргә кирәк.

Кассио. Хәерле төн, намуслы Яго.

Китә.

Яго

Йә инде, кем генә минем хакта
Кабахәтлек эшли бу дип әйтер!
Минем биргән киңәш шундый әйбәт,
Өстәвенә ихлас, саф күңелдән
Отеллога якынаю өчен
Иң дөрес юл. Бит Дездемонаны

Мондый изге эшкә күндерүдән дә
Җиңел эш юк. Аның күңеле нечкә,
Табигатьнең үзе кебек юмарт ул.
Ул маврны теләсә нишләтә ала.
Ә мавр Дездемонасы өчен
Хәтта иманыннан, җәннәтеннән
Ваз кичәргә әзер, һәм Дездемона,
Аның йомшаклыгын файдаланып,
Ни теләсә, шуны эшли ала;
Җимергәнне шундук кире төзи,
Тели икән, җимереп ташлый ала.
Шулай булгач, Кассиога шундый
Бәхет ишегенә илтә торган
Туры юл күрсәтәм икән, мине
Кабахәт дип атау ярыймыни?
Иблис ләгыйнь олы гөнаһларның
Иң олысын эшләмәкче булса,
Ул гөнаһның тышкы кыяфәтен
Изге пәрдә белән каплап ала.
Мин һәм аны шулай итеп эшләрмен.
Бу намуслы ахмак, ярдәм сорап,
Яшь Дездемонага барган чакта,
Ә Дездемона Кассио өчен
Иренә ялынганда, мин маврның
Колагына: сезнең хатыныгызның
Бу яшь егет өчен ялынуында
Бозык теләк ятмый микән, диярмен.
Һәм бу ялыну арта барган саен,
Хатынына аның ышанычы
Һаман кимегәннән-кими барыр.
Шулай итеп, мин Дездемонаның
Ап-ак эшен кара дегет итәрмен,
Ә изгелегеннән ятьмә үреп,
Мин аларны шушы ятьмәм белән
Урап алырмын.

Родриго керә.

Йә, ни бар, Родриго?

Родриго. Ни булсын, менә шул бар: мин бу ауда аучы эт булып түгел, бәлки, өрүче эт булып кына катнаштым. Акчам бетеп килә. Бүген төнлә мине ярыйсы гына кыйнадылар да. Миңа калса, бу эшнең нәтиҗәсе шул булыр, — күргән газапларыма каршы берникадәр гыйбрәт алып, бер тиен акчасыз, бар-лы-юклы акылым белән Венециягә кайтып китәрмен.

Яго

Ахмак та соң бу түземсез халык!
Нинди җәрәхәтне кинәт кенә
Төзәтергә мөмкин? Үзеңә мәгълүм,
Сихер-тылсым көче белән түгел,
Акыл көче белән эш итәбез.
Ә акылның вакыт кануныннан
Чыгып китәлмавы сиңа мәгълүм.
Эшләр начар барамыни? Йә? Кассио
Сиңа бер мәртәбә суккан икән,
Шуның белән аны урыныннан
Бәреп төшерергә син өлгердең.
Кинәт үсә торган үсемлек юк.
Ләкин иртә чәчәк аткан агач
Иртә җимеш бирә. Син тынычлан һәм көт.
Әнә алсу таң да сызылып килә.
Мондый эшләр белән мавыкканда,

Бәхет-шатлык җимешен татыганда,
Вакыт үткәнлеген сизмисең дә.
Бар өеңә, якын киләчәктә
Зуррак эш мәгълүм булыр сиңа.

Родриго китә.

Инде алда ике нәрсә тора:
Ипләп хатынымны котыртырга;
Кассиога ярдәм итүен сорап,
Ул Дездемонага барсын хәзер.
Үзем шул арада Отеллоны
Кая булса читкә алып китеп,
Кассио Дездемона янына кергәч тә,
Икәүләшеп кайтып төшү кирәк.
Әйе, бу юл дөрес булыр — әйбәт!
Тизрәк эшкә тотынырга кирәк.

Китә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Замок алды. Кассио һәм музыкантлар керәләр.

Кассио

Әфәнделәр, менә шунда уйнагыз,
Хезмәтегез өчен түләрмен мин.
Кыска гына бер көй уйнагыз да
Генералга тәбрик белдерегез[1] .

Музыка.
Мәзәкче егет килеп чыга.

Мәзәкче егет. Нәрсә бу, әфәнделәр, сезнең музыка коралларыгыз Неапольдә булдылармы әллә? Ниндидер тыңкышлык бар үзләрендә.

I музыкант. Ничек инде ул?

Мәзәкче егет. Әйтегез әле, зинһар, сезнең бу музыка коралларыгыз өреп уйный торганмы?

I музыкант. Әйе, өреп уйный торган.

Мәзәкче егет. Алайса, аларның урыны койрык астында булырга тиеш.

I музыкант. Ничек инде ул койрык астында?

Мәзәкче егет. Шулай. Мин белгән өреп уйный торган музыка коралларының бик күбесе койрык астына урнашкан. Кыскасы, менә сезгә акча, әфәнделәр! Генерал музыкагызны шулкадәр яратты, зинһар, туктатсыннар, акыртмасыннар, ди.

I музыкант. Ярар, әфәндем, артык уйнамабыз.

Мәзәкче егет. Бәлки, сезнең берәр төрле ишетелми торган музыкагыз бардыр? Андые булса, әйдә, рәхим итегез. Ләкин монысын генерал яратмады.

I музыкант. Андый музыкабыз юк шул.

Мәзәкче егет. Ул чагында быргыларыгызны капчыкларыгызга тыгыгыз да үкчәгезне күтәрегез, төтен булып таралыгыз.

Музыкантлар китәләр.

Кассио. Тыңла әле, сөекле дустым...

Мәзәкче егет. Сөекле дустыгыз тыңламый сезне, мин тыңлыйм.

Кассио. Ташла әле шул такмазаларыңны. Менә сиңа кечкенә генә бер алтын. Генерал хатынына хезмәт итүче ханым әгәр дә торган булса, әйт аңа: Кассио дигән кешенең сезгә әйтәсе сүзе бар, диген. Шул йомышны үтәрсеңме?

Мәзәкче егет. Ханым торды, синьор. Әгәр дә ул мин китү белән бирегә килеп чыкса, димәк, мин сезнең йомышыгызны үтәгән булам.

Кассио. Зинһар, шулай ит.

Мәзәкче егет китә. Яго керә.

Яго, шәп булды —
Бик вакытлы очрадыгыз.

Яго

Әллә сез ятмадыгыз да?

Кассио

Кайчан ятыйм,
Таң сызылгач кына аерылдык бит.
Хатынызгызны чакырырга куштым,
Мине ул Дездемона янына
Алып кермәсме дим.

Яго

Хәзер менә
Сезнең янга чыгарам мин аны,
Үзем Отеллоны кая булса
Алып китү ягын карыйм — сезгә
Сөйләшергә аулаграк булсын.
Кассио. Чын күңелемнән рәхмәт.

Яго китә.

Мин гомеремдә Флоренциядә дә моның кебек саф күңелле кеше күргәнем юк.
Эмилия керә.

Эмилия

Исәнмесез, сөекле лейтенант.
Кайгыгызны уртаклашам; ләкин
Озакламый эшегез рәтләнәчәк.
Әле генералның хатыны белән
Сөйләшкәнен ишетеп тордым. Синьора
Сезне шундый яклый! Мавр әйтә,
Сез җәрәхәтләгән теге кеше
Кипр утравында бик атаклы,
Нәселе ягыннан да бик затлы, ди.
Шуңа күрә сезне урыныгыздан
Алмый ярамый, ди. Ләкин үзе
Сезне чын күңелдән яратканын,
Берәр җае килеп чыгу белән
Шундук кире алачагын әйтте.

Кассио

Мөмкин булса, үтенер идем сездән —
Хәзер мин Дездемонаны күреп,
Фәкать аның үзе белән генә
Берәр минут сөйләшмәкче идем —
Безне очраштыра алмассызмы?

Эмилия

Рәхим итегез, керегез. Анда сез
Күңелегездә булган серегезне
Бик иркенләп сөйләп бирә алырсыз.

Кассио

Мин бурычлы сезнең каршыгызда.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Замокта бер бүлмә. Отелло, Яго һәм офицерлар керәләр.

Отелло

Син бу хатны капитанга тапшыр,
Ул сенатка хатым белән бергә
Минем сәламемне ирештерсен.
Мин крепостька китәм, анда барырсың.

Яго

Әмерегезне үтәрмен, генерал.

Отелло

Әфәнделәр, без ныгытмаларны
Барып карыйк.

Офицерлар

Боерыгыз, синьор.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Замок алдында бакча.
Дездемона, Кассио, Эмилия керәләр.

Дездемона

Сез, Кассио, ышаныгыз миңа,
Сезгә ярдәм итү өчен
Бөтен көчем белән тырышачакмын.

Эмилия

Шулай итә күрегез инде, синьора!
Бу вакыйга минем иремне дә
Бик борчыды. Шулкадәр уфтана,
Әйтерсең лә шушы бәхетсезлек
Үз башына төшкән.

Дездемона

Ул намуслы,
Саф күңелле кеше... Сез, Кассио,
Борчылмагыз, зинһар, ирем белән
Сезнең арадагы дуслык җебен
Үзем ялгармын.

Кассио

О, синьора,
Башыма нинди генә бәла төшсә дә,
Мәрхәмәтегезне һич онытмам.
Мәңге тугры хадимегез булырмын.

Дездемона

Рәхмәт, Отеллоны сез яратасыз,
Аның белән бит сез күптән таныш,
Һәм ул сезне озак читтә тотмас,
Хәзер аның сезне читләтүе
Тик сәясәт кушкан өчен генә.

Кассио

Мин ышанам сезгә, синьора, тик
Сәясәтнең тирән тамырланып,
Бик озакка сузылуы мөмкин.
Үзем аннан читтә булгач, урыным

Башка бер кешегә бирелеп куйгач,
Минем тирән дуслык тойгыларын,
Тугры хезмәтемне — барысын да
Ул онытыр.

Дездемона

Зинһар, борчылмагыз!
Менә Эмилия алдында әйтәм,
Урыныгызны кире алырсыз, дим.
Вәгъдә — иман, аны үтәрмен мин.
Отеллоның һич янынннан китмәм,
Тынгы бирмәм аңа, йокы бирмәм,
Тәмам теңкәсенә тиеп бетәрмен.
Нинди генә эшкә тотынмасын,
Сезнең исемегезне телгә алырмын.
Сез тынычланыгыз, борчылмагыз,
Яклаучыгыз сезнең үлсә үләр,
Ләкин алган эшен үтәп чыгар.

Эмилия

Синьора, ирегез кайтып килә.

Кассио

Алайса, хушыгыз, китим инде.

Дездемона

Юк, китмәгез сез, үз алдыгызда
Сөйләшәм мин хәзер аның белән.

Кассио

Юк, юк, бүген түгел. Китәм мин, хуш;
Бүген минем кәефем шундый начар,
Үз файдама һичбер сүз әйталмам.

Дездемона

Ярый алайса, ихтыярыгыз.

Кассио китә. Кулына кәгазь тоткан Отелло белән Яго керәләр.

Яго

А! Менә бу инде миңа ошамый.

Отелло

Ә? Ни дидең син, Яго?

Яго

Юк, болай...
Әгәр дә мин әйтәм... Хәер, белмим.

Отелло

Минем хатын белән саубуллашып
Киткән кеше кем? Кассио түгелме?

Яго

Кем? Кассио? Юк, генерал, булмас!
Әгәр дә ул булса, сезне күргәч,
Карак кебек болай качмас иде.

Отелло

Минемчә, ул.

Дездемона

Ни бар, иркәм Отелло?
Әле генә ярдәм сорап килгән
Берәү белән сөйләштем мин монда;
Синең ачуыңа дучар булган ул.

Отелло

Кем соң ул?

Дездемона

Кассио, лейтенантың.
Бәгърем, әгәр дә син мине сөйсәң,
Сүзем сиңа тәэсир итә алса, —
Кичер аны һәм хәзер үк килеш.
Инде ул да сине яратмаса,
Һәм бу эшне ялгышудан түгел,
Явыз ният белән кылган булса, —
Димәк, саф күңелле кешеләрне
Таный алмыйм мин. Үтенәм синнән,
Кайтар аны, зинһар, үз урнына!

Отелло

Әле киткән кеше ул идеме?

Дездемона

Әйе. Бик кайгыра мескенкәем.
Хәсрәтенең ярты авырлыгын
Миңа ташлап китте, хәзер инде
Аның өчен мин дә газапланам.
Бәгърем, кайтар аны үз урнына.

Отелло

Юк, соңыннан, җаным, хәзер түгел.

Дездемона

Кайчан? Тизме?

Отелло

Мөмкинчелек тугач.

Дездемона

Бүген кичкәме?

Отелло

Юк, бүген түгел.

Дездемона

Иртәгәме?

Отелло

Мин иртәгә өйдә булмыйм.
Крепостька китәм, мөһим эш бар,
Ашны да мин анда гына ашармын.

Дездемона

Алай булса, берсекөнгә иртән,
Яки кичен, яки сишәмбе көн,
Анда да булмаса, чәршәмбе көн.
Йә, әйт инде, кайчан? Вакытын әйт,
Ләкин, зинһар, өч көннән дә артык
Интектермә, бик пошына мескен.
Гаебе дә бит нәрсә генә инде!
Сугыш вакытында үрнәк өчен,

Кемнең кемлегенә карамастан,
Каты хөкем кирәк дисәләр дә, —
Шундый кечкенә бер гаеп өчен
Чакырып алып тиргәү җитәр иде.
Кайчан килсен соң ул? Йә, әйт инде!
Мин аптырыйм. Әгәр дә син шулай
Миңа килсәң? Синең теләгеңә
Каршы килә алыр идем микән?
Сүз Кассио турысында бара!
Миңа гашыйк булып йөргән чакта,
Син бит аңа бөтен серләреңне
Яшермичә сөйли идең. Хәтта
Димләргә дә бит син аңа куштың.
Кайчагында шулай синең хакта
Начаррак бер сүз ычкындырсам,
Ярсып яклый иде. О, Кассио!
Хәзер сине гафу иттерү өчен
Күпме интегергә туры килә!
Аны синең алда аклар өчен,
Артыграгын да эшләр идем.

Отелло

Йә, йә, җитәр, җитәр. Әйт Кассиога,
Үзе кайчан тели, шунда килсен.
Күңлеңдәге һичбер теләгеңне
Кире кагалмыйм мин, җитми көчем.

Дездемона

Бу эш белән миңа зур яхшылык
Эшләдем дип уйлый күрмә тагын.
Бу бит минем сиңа, перчатка ки,
Тәмле ашлар аша, йә булмаса
Җылы итеп киен, дигәнем күк,
Синең үз файдаңа әйтелгән сүз.
Әгәр дә мин ничек сөюеңне
Сынамакчы булсам, синең алга
Мондый гына таләп куймам, аны
Үтәп чыгу бик үк җиңел булмас.

Отелло

Һичбер теләгеңне кире какмам,
Хәзер син дә минем теләгемә
Каршы килмә, мине ялгыз калдыр.

Дездемона

Каршы киләмме соң! Хуш, газизем.

Отелло

Хуш, фәрештәм. Тиздән синең янга
Керермен мин.

Дездемона

Киттек, Эмилия.
*(Отеллога.)*
Күңелең ничек тели, шулай эшлә —
Мин һич каршы килмәм.

Дездемона белән Эмилия чыгып китәләр.

Отелло

Ах, син наян!
Бөтен күңелем белән яратмасам,

Җаным җәһәннәмгә китсен минем,
Синнән күңелем бизсә, бар дөньямның
Асты өскә килсен!

Яго

Генералым!

Отелло

Ни әйтергә телисең, Яго?

Яго

Мин
Шуны гына сорамакчы идем,
Синьорага өйләнмәстән элек,
Сезнең аңа булган гыйшкыгызны
Микаэль Кассио белә идеме?

Отелло

Әйе, барысын да белә иде.
Бу сорауны нигә бирдең әле?

Яго

Болай гына. Бер фикерне генә
Ачыкларга иде.

Отелло

Нинди фикер?

Яго

Мин аларны бер-берсе белән
Таныштыр дип уйламаган идем.

Отелло

Таныш, күптән таныш. Хәтта безнең
Арабызда йөрде.

Яго

Чынлап әйтәсезме?

Отелло

Әйе, чынлап... Сиңа нәрсә булды?
Моннан нинди мәгънә чыгарасың?
Әллә ул намуссызмы?

Яго

Намуслы.

Отелло

Әйе, ул намуслы.

Яго

Миңа калса...

Отелло

Әйт, ни уйлыйсың?

Яго

Ни уйлыйммы?

Отелло

«Ни уйлыйммы?»
Күк белән ант итәм, һәр тавышка
Җавап бирә торган урман кебек,

Ул кабатлый минем сүзләремне.
Әйтерсең лә аның күңелендә
Коточыргыч яшерен серләр ята.
Әйт, ни уйлыйсың син? Кассионың
Минем хатын белән исәнләшеп
Китеп барганлыгын күреп алдың да
«Ошамый бу миңа» дидең. Нигә?
Нәрсә ошамый? Әйт! Аннан тагын
Ул һәрвакыт безнең арабызда
Йөрде дигәч, син аптырап калдың да
«Чынлап әйтәсезме?» диеп куйдың.
Аннан, башыңа килгән шомлы уйны
Яшерергә теләгәндәй, кинәт
Кашларыңны җыерып, тынып калдың.
Мине саф күңелдән хөрмәт итсәң,
Сөйлә ул уеңны!

Яго

Минем сезне
Ничек хөрмәт итүемне беләсез.

Отелло

Әйе, беләм. Әнә шуның өчен,
Тугрылыгың, саф күңеллелегең,
Үлчәмичә сүз сөйләмәвеңне
Белгән өчен, синең ярты-йорты
Бу сүзләрең мине шомландыра.
Күңеле бозык кеше авызыннан
Мондый сүзне һәрчак ишетеп була.
Саф күңелле кеше мондый сүзне
Бер дә юкка гына ычкындырмый,
Димәк, ул уй аның эченә сыймый.
Ялкынланып тышка ташып чыга.

Яго

Кассионың күңеле сафлыгына
Ант итәргә әзер.

Отелло

Мин дә шулай.

Яго

Кеше тыштан саф күренә икән,
Эчтән дә ул саф булырга тиеш.
Күңеле бозык икән, саф күңелле,
Пакь намуслы булып күренмәсен.

Отелло

Дөрес, тыштан саф күренә икән,
Эчтән дә ул саф булырга тиеш.

Яго

Менә шуның өчен Кассионы
Саф күңелле диеп уйлыймын мин.

Отелло

Юк, юк, монда нәрсәдер бар. Зинһар,
Уйларыңны, боргаламый гына,
Ачык итеп сөйлә. Әгәр дә ул
Әшәке уй булса, тартынмыйча,
Начар сүзләр белән сөйлә миңа.

Яго

Аһ, генерал, кичерегез, зинһар,
Әлбәттә, мин сезгә буйсынырга
Бурычлымын. Ләкин колларны да
Мәҗбүр итү мөмкин булмый торган
Эшләр була. Күңелемдәге уйны
Сөйләтергә телисез сез. Әгәр дә
Минем уем әшәке уй булса?
Пычрак булмый купшы сарайда дип
Әйтә алабызмы? Пакь күңелдә
Тугры һәм саф уйлар белән бергә
Әллә нинди шикле уйлар булуы
Мөмкин түгелмени, генералым?

Отелло

Син дустыңның мәсхәрәләнгәнен
Белә торып, аннан уйларыңны
Яшерәсең икән, бу — хыянәт.

Яго

Аһ, генерал, бәлки, минем уем
Ялгыш уйдыр. Минем табигатем
Шундый инде: һәрнәрсәдән
Әшәкелек эзләп тик йөрим мин.
Шундый юк-бар шикләнүләр белән
Әллә ниләр эшләп беткәнем бар.
Шуның өчен мин үтенәм сездән,
Нигезе нык булмаган сүзләремә
Илтифат итмәгез, һич дәлилсез,
Минем коры шикләремә карап,
Тынычлыгыгызны югалтмагыз.
Акылым, бурычым, саф намусым,
Тынычлыгыгызны боза торган
Уйларымны сезгә фаш итүдән
Тыя мине.

Отелло

Бу ни дигән сүз, Яго?

Яго

Генералым, хатын-кыз өчен дә,
Ир өчен дә керсез исем — намус
Иң кадерле, иң мөкатдәс нәрсә.
Берәү минем акча янчыгымны
Урлый икән, әле бу югалту
Ул кадәр үк зур югалту түгел.
Бүген миндә ул, иртәгә анда,
Элек тә ул меңнәр кулыннан үткән.
Әгәр инде минем намусымны
Урласалар, бусы инде башка...
Дөрес, аның белән баемый ул,
Ләкин мине тәмам ул бөлдерә.

Отелло

Хода шаһит, синең бу уеңны
Мин барыбер белермен.

Яго

Юк, синьор,
Йөрәгемне тартып алсагыз да,
Барыбер аны сезгә әйтмәс идем.

Отелло

Әһә! Менә ничек!

Яго

Аһ, генерал,
Зинһар, көнчелектән сакланыгыз,
Ул ямь-яшел күзле юха елан
Мәсхәрәләп көлә корбаныннан.
Хыянәтче хатынын ташлый алган
Мөгезле ир мең кат бәхетле ир.
Шиккә чумып, көнләү ялкынында
Көя-көя, хатынын ташлый алмый,
Акылыннан шашып сөйгән иргә
Алла түзем бирсен.

Отелло

О, коточкыч!

Яго

Үзенең язмышыннан риза булып
Яши торган ярлы, минемчә — бай;
Ләкин бар байлыгым югалтам дип
Тетрәп тора торган черегән бай,
Кышкы шәрә ялан кебек, ярлы.
Раббым, үзең сакла көнчелектән!

Отелло

Тукта! Бу сүзләрне син ни өчен
Сөйләдең соң әле? Әллә мине
Көнчелектән көеп, җаны сыкрап,
Көн-төн газапланыр дисеңме син?
Яңа ай туган саен өр-яңа шик
Туа башлар дисең мәллә миндә?
Юк, Яго, мин андыйлардан түгел.
Күңелемне андый вак, җирәнгеч
Шикләнүләр белән тутыру кебек
Түбәнлеккә төшәм икән, ул чак
Аңгыра сарык итеп сана мине.
Хатыныгыз матур, киенергә,
Кеше арасында күренергә
Бик ярата, үзен иркен тота,
Матур җырлый, бии, уйный-көлә,
Сүзгә тапкыр диләр икән, әйдә
Сөйләсеннәр, моңа мин көнләшмәм.
Күңеле саф булгач, бу сыйфатлар
Аны фәкать матурлата гына.
Хатын-кызны кызыктыра торган
Сыйфатларым азлыгына да мин
Бер дә борчылмыйм, чөнки ул
Мине сайлаганда күзле иде.
Юк, Яго, юк, миңа күрү кирәк,
Күреп шикләнергә һәм ул шикне
Дәлил табып дөресләргә кирәк.
Дөресләнсә, икеләнеп тормам,
Гыйшкымны да, көнләү тойгымны да
Төбе-тамры белән йолкып ташлармын.

Яго

Моңа мин шат. Инде болай булгач,
Сезне ничек хөрмәт итүемне
Ачыграк итеп күрсәтергә

Батырчылык итәм. Тартынмыйча,
Бурычым кушкан сүзне әйтәм сезгә.
Әлегә менә диеп күрсәтерлек
Дәлилләрем юклыгын юк. Шулай да
Киңәшем шул сезгә: хатыныгызны
Бик нык күзәтегез. Бигрәк тә
Ул Кассио белән булган чакта.
Көнчелеккә бирелеп сукыраймагыз,
Шулай ук аларның сафлыгына да
Бик үк ышанмагыз; саф күңелле,
Пакь намуслы ирнең сукыраюын
Теләмим мин, — шуңа күрә әйтәм,
Зур игътибар белән күзәтегез!
Венеция хатыннарын беләм мин!
Ирләреннән яшерен этлекләрен
Тик Алладан гына яшермиләр.
Ул халыкның күңел сафлыгы бит
Гөнаһлардан пакь булуда түгел,
Аны оста итеп яшерүдә.

Отелло

Шулай уйлыйсыңмы?

Яго
Сезгә чыгып,
Алдады бит үзенең карт атасын!
Хәтта сезнең күз карашыгыздан
Дер-дер тетрәп, куркып йөргән булды,
Үзе шул ук вакыт сезне сөйгән.

Отелло

Әйе, әйе, синең сүзең дөрес.

Яго

Шулай булгач үзегез уйлап карагыз,
Әле япь-яшь, ә нинди хәйләкәр!
Атасының күзен шундый оста
Томалады, теге бичара карт,
Кызының фигылен башына сыйдыралмыйча,
Сезне сихерче дип гаепләде...
Мин бик ерак кереп киттем бугай...
Сезне артык яратуым өчен
Зинһар, мине кичерегез, синьор.

Отелло

Мин мәңге бурычлы синең алда.

Яго

Минем сүзләр сезне борчый, ахры.

Отелло

А, юк!.. Һич юк...

Яго

Мин борчудан куркам.
Хәер, минем бу сөйләгән сүзләр
Сезне чын күңелдән яраткanга
Сөйләнүе аңлашылса кирәк.
Сез борчыласыз, генерал... Зинһар,
Минем сүзләремнең әһәмиятен
Артык тирәнәйтеп җибәрмәгез.
Бу шик кенә бит.

Отелло

Мин тирәнәйтмим.

Яго

Әгәр андый нәрсә була калса,
Сүзем белән үзем теләмәгән
Бик зур әшәкелек эшләдем мин.
Кассио бит минем якын дустым...
Аһ, генерал, күрәм, сез борчыласыз!

Отелло

Юк, берни юк. Болай гына... Юк, Яго,
Шуны беләм мин: Дездемонаның
Бозык кыз булуы мөмкин түгел.

Яго

Ходай озын гомер бирсен аңа,
Ә сез аңа мәңге ышаныгыз.

Отелло

Ә бит кайчагында кешеләрнең
Кайнар хистән күзе томаланып...

Яго

Әнә шул шул! Бөтен эш тә шунда!
Батырчылык итеп ачык әйтим,
Иле, заты, нәселе, каны белән
Үзенә якын булган егетләрнең
Тәкъдимнәрен кире какканлыгын
Үзегез беләсез бит. Табигатьтә
Һәркем үз тиңенә омтылучан.
Кайчагында бу табигый тойгы
Бозылып китеп, кеше тәм, ләззәтне
Әллә кайдан эзли. Бу бозыклык...
Кичерегез, зинһар, бу сүзләрне
Мин Дездемонага төбәп әйтмим.
Шулай да мин сезнең өчен куркам:
Беркөн килеп, сезне үз иленең
Егетләре белән чагыштырып,
Алдандым, дип үкенмәгәе дим.

Отелло

Йә, хуш! Әгәр тагын ни дә булса
Сизә-нитә калсаң, миңа белдер,
Хатыныңа әйт, ул күз-колак булсын.
Йә, бар.

Яго

Сау булыгыз.

Чыгарга юнәлә.

Отелло

Ник өйләндем?
Бу намуслы, саф күңелле егет
Бар белгәнен сөйләп бетермәде.

Яго

Әйләнеп килеп.

Мин үтенәм сездән, генералым,
Зинһар, көнчелеккә бирелмәгез.

Вакыт үтәр, бар да ачыкланыр.
Әгәр теләсәгез, Кассионы
Үз урнына кайтарыгыз. Болай
Ул хезмәтен әйбәт алып барды.
Ләкин бераз сабыр итеп тору
Зарар итмәс, чөнки читтә тотып
Күңлеңдәге уен, теләкләрен
Ачыграк итеп белә алырсыз.
Аннан тагын шуны хәтерләгез:
Әгәр хатыныгыз аның өчен
Бик ялынып сорый икән, димәк,
Алар арасында ни булса бар.
Ләкин әлегә минем сүзләремә
Бик үк таянмагыз, зинһар, мин бит
Бик вак нәрсәдән дә шикләнүчән.
Шуның өчен бу сүзләргә карап
Хатыныгызны, зинһар, борчымагыз.

Отелло

Үз-үземне тота алырмын мин.

Яго

Сәламәтлек теләп башым иям.

Китә.

Отелло

Саф күңелле егет! Өстәвенә
Нинди тирән акыл. Кешеләрнең
Күңелендәге уен ничек белә!
О, лачыным, әгәр дә син мине
Үзсенмәсәң, сиңа бәйләнгән бау
Нечкә йөрәк кылларымнан торса да,
Барыбер өзәрмен мин аны, әйдә,
Күңелең кайда тели, шунда юнәл...
Тәнем кара минем — сәбәп шунда,
Татлы телле тәти егетләр күк
Купшы матур сүзләр сөйли белмим.
Бәлки, инде яшем үтеп барадыр?
Хатыным юк хәзер, мин алдандым.
Хәзер миңа бердәнбер юаныч —
Нәфрәт. Менә ул каһәрле никах,
Менә кайда аның әче каһәре:
Хатын-кызның үзен безгә бирә,
Күңелен, тойгыларын буйсындырмый.
Аһ! Йөрәгем белән өзелеп сөйгән
Бернәрсәмнең бик аз өлешеннән
Чит берәүне ләззәтләндергәнче,
Бака булып туып, җир астында
Сасы иснәп яшәү артыграк.
Менә үзе килә, Дездемонам,
Әгәр синең күңелең саф булмаса,
Хода үз-үзеннән көлгән була.
Шулай да, юк, ышанмыйм мин моңа.

Дездемона белән Эмилия керәләр.

Дездемона

Бу ни эшең инде, җаным Отелло!
Бу утрауның затлы халыклары —
Кунакларың анда җыелып бетте.
Аш куелды, алар сине көтә.

Отелло
Мин гаепле.

Дездемона

Тавышың зәгыйфьләнгән,
Әллә авырыйсыңмы?

Отелло

Болай гына,
Баш авырта.

Дездемона

Төнлә йокламадың,
Шуңадыр ул. Килче, кысып бәйлим.
Бер сәгатьтән берни калмас, бетәр.

Отелло

Куй, яулыгың бик кечкенә синең.

Яулыгын тартып ала, ул идәнгә төшә.

Үтәр әле. Әйдә минем белән.

Отелло белән Дездемона китәләр.

Эмилия

Менә, шөкер, яулык минем кулда.
Бу маврдан аңа тәүге бүләк.
Минем җүләр ирем ни өчендер
Шул яулыкны миңа, урлап бир, дип,
Йөз кат ялынгандыр. Дездемона
Бу яулыкны һич кулыннан төшерми,
Ул сөйләшә аның белән, үбә.
Бу яулыкны аңа Отеллосы
Кабреңәчә сакла дигән икән.
Чү, үрнәген күчереп кенә алыйм да
Шундый яулык чиктерергә бирим.
Ул яулыкны мин Ягога бирермен.
Нигә кирәктер ул аңа, белмим,
Мин тик аның назлы теләген үтим.

Яго керә.

Яго

Япа-ялгыз монда нишләп йөрисең?

Эмилия

Йә, чәпчемә. Миндә синең өчен
Бернәрсә бар.

Яго

Ул бернәрсәң миңа күптән таныш.

Эмилия

Тукта, чү! Син ни турында сөйлисең?

Яго

Ахмак хатынымны сөйлим.

Эмилия

Алай.
Яулык өчен миңа нәрсә бирәсең?

Яго

Нинди яулык?

Эмилия

Нинди яулык? Отелло
Синьорага бүләк иткән яулык.
Син ничәме тапкыр миңа урла дип...

Яго

Урладыңмы?

Эмилия

Юк, урламадым.
Төшеп калды, ә мин аны алдым.
Менә.

Яго

Син хәзинә, хатын гына түгел.
Йә, бир әле монда.

Эмилия

Иң элек әйт,
Сиңа нигә кирәк ул? Ни өчен
Һаман урла дип теңкәмә тидең?

Яго

Анда синең ни эшең бар?
*(Яулыкны тартып ала.)*

Эмилия

Әгәр
Артык зур кирәге булмаса, бир.
Аның югалганын сизеп калса,
Акылыннан шашар мескен синьорам.

Яго

Ә син аңа мин белмимен, диген.
Миңа кирәк ул... Йә, бар, кит моннан.

Эмилия китә.

Моны мин Кассио бүлмәсендә
Төшереп калдырырмын — һәм ул табар.
Һава төсле җиңел шундый бер чүп,
Көнләштерү драмасы өчен
Изге әфсен булып хезмәт итәр.
Бераз агу салынды бит инде.
Шик бит үзенең табигате белән
Шул ук агу. Башта көчсез, тәме дә
Беленер-беленмәслек кенә була.
Канга кереп алса, күкерт сыман,
Дөрләп яна башлый... Әнә үзе.
Минем уем дөрес түгелмени?
Хәзер инде мәк тә, мандрагора да,
Йоклатучы барлык дарулар да
Кичәге йокыңны кайтаралмас.

Отелло керә.

Отелло

О! Хыянәт! Мине алдау! Мине!

Яго

Ни булды, генерал? Йә, куегыз,
Онытыгыз инде.

Отелло

Кит яньмнан!
Мине син җәзага дучар иттең.
Мин ант итәм, шиккә чумып йөргәнче,
Чынлап алдануың артыграк.

Яго

Йә, тынычланыгыз инде, синьор.

Отелло

Хатынымның бозыклыгын белү
Нигә кирәк иде миңа? Нигә?
Мин күрмәдем, уйламадым аны,
Әче газабын да татымадым;
Йокым тыныч, күңелем ачык иде.
Әлегә кадәр аның иренендә
Кассио үпкән эзне күрми идем.
Кеше талануын белми торса,
Һич таланган итеп сизми үзен.

Яго

Бу сүзләрне тыңлау авыр миңа.

Отелло

Бөтен бер полк, полкның һәр солдаты
Аны үзенеке итеп бетсә дә,
Әгәр дә белмәсәм шул хурлыкны,
Мин бәхетле бәндә булыр идем.
Хәзер инде барысы да бетте.
Сау бул, тынычлыгым, якты бәхетем,
Сау булыгыз, батыр гаскәрләрем,
Шөһрәт сөю хисен батырлыкка
Әйләндерә торган бөек көрәш,
Сугыш яланнары, сау булыгыз!
Сау бул, ярсу атым, күңелләрне
Ашкындыра торган дәртле быргы,
Барабаннар тавышы, флейта моңы,
Данлы байрак, җиңү тантанасы!
Сау булыгыз, Зевс тавышы белән
Үкерүче шомлы, авыр туплар!
Отеллоның барыр юлы бетте.

Яго

Мөмкинме бу?

Отелло

Явыз! Дәлил табып,
Хатынымның бозыклыгын исбат ит!
*(Бугазыннан ала.)*
Җаным белән мин ант итеп әйтәм,
Минем ачуыма дучар булганчы,
Эт булуың артык булыр иде.

Яго

Менә кая кадәр килеп җитте!

Отелло

Күрсәт миңа; булмый икән, исбат ит.
Шундый дәлил китер, сүзләреңдә
Энә очы кадәр шик калмасын.
Юкса — үлем.

Яго

Газиз генералым!

Отелло

Әгәр саф хатынга яла ягып,
Ялаң белән минем йөрәгемне
Телем-телем теләә торган булсаң,
Динеңнән яз, ваз кич вөжданыңнан
Һәм атлаган саен явызлык кыл,
Синең эшне күреп күк еласын,
Дәһшәтеңнән җир тетрәсен, ләкин
Нинди генә явызлыклар кылсаң да,
Зур җәзага лаек булу өчен
Моннан да зур гөнаһ эшли алмассың.

Яго

Кичер мине, Раббым! Кешеме сез?
Сездә шәфкать дигән нәрсә бармы?
Моннан соң мин хадим түгел сезгә.
Ахмак! Менә җимеше тугрылыкның!
Син ялганчы! Әй син, шакшы дөнья!
Күр, күр менә, тугры, саф күңелле
Кеше булу нинди куркынычлы!
Сабагыгыз өчен рәхмәт сезгә,
Дуслык җәбер чыганагы булгач,
Мин дус булмам хәзер һичбер кемгә.

Отелло

Тукта, сабыр. Бәлки, тугрысыңдыр.

Яго

Акыллы булырга теләр идем,
Тугрылыкның нинди файдасы бар?

Отелло

Мин ант итәм бөтен дөнья белән,
Бер карасам, хатыным бик саф кебек,
Бер карасам, хыянәтче кебек,
Синең сүзең дә бер дөрес кебек,
Бер карасам, ялган яла кебек.
Дәлил кирәк миңа, дәлил кирәк.
Хатынымның йөзе, Диананың
Нурлы йөзе кебек, ап-ак иде,
Хәзер инде, минем тәнем кебек,
Ул каралды. Аһ, пычаклар, баулар,
Ут һәм агу, тагын җир йөзендә
Үч алырлык нинди чаралар бар?
Мондый хыянәткә мин түзалмам,
Тизрәк, тизрәк дәлил китер миңа!

Яго

Көнчелектән ничек өзгәләнәсез.
Мин үкенәм инде сөйләвемә.
Дәлил китерүне телисезме?

Отелло

Телимме? Юк, таләп итәм, таләп!

Яго

Мөмкин. Тик ничек күрсәтим икән?
Сезгә соң мин нинди дәлил әйтим?

Ә бәлки, эшләрен эшләгәндә,
Өсләренә барып чыгу кирәктер?

Отелло

Үлем! Ләгънәт!.. О!..

Яго

Тик белмим,
Сез аларны андый кыяфәттә
Очрата алырсызмы? Ай-һай!
Яшерен эшлиләр бит алар аны,
Белсә дә шул, түшәк кенә белә.
Нишлим соң мин? Нинди җавап бирим?
Сезгә нинди дәлил китерим мин?
Кәҗә, маймыл, бүре, этләр кебек,
Дәртләреннән оятларын онытып
Китмәс инде алар, сакланырлар.
Андый дәлил беркем китерә алмас,
Без аларны яткан җирләрендә
Барып тоталмыйбыз. Әгәр сезне
Хаклык ишегенә илтә торган
Дәлилләрем канәгатьләндерсә,
Андыйларны китерә алам.

Отелло

Китер,
Аның хыянәтен исбат иткән
Нинди булса җанлы дәлил китер.

Яго

Мондый эшне мин һич яратмыйм. Ләкин
Ни хәл итим, ахмак намуслылык,
Сезгә булган дуслык аркасында
Бу кадәре тирән кергәч инде,
Дәвам итми булмый. Берчак шулай
Без Кассио белән бер түшәктә
Ята идек. Тешем сызлаганга,
Төн буена йоклый алмый яттым.
Шундый йомшак кешеләр бар, алар
Өндә уйлап йөргән яшерен уйны
Йокы аралаш сөйлиләр. Кассио да
Шундый кеше. Шунда ул саташып:
«Сак булыйк без, бәгырем, о, Дездемона,
Белмәсеннәр безнең гыйшкыбызны!» —
Диеп, минем кулны кысып тотты.
«Җаным, бәгырем» дигән була миңа,
Әй тотынды мине бу үбәргә!
Иреннәрне өзәме дип торам.
Миңа бөтен тәне белән кысылып
Үбә, елый. «Сине кара гарәп
Кочагына аткан бу язмышка
Ләгънәт төшсен!» — дип кычкырды.

Отелло
Бу коточкыч!

Яго

Соң, төш кенә бит бу.

Отелло

Әйе, бу төш, ләкин төш булса да,
Өндә булган яшерен эшне ачып,

Коточкыч шик сала ул күңелгә.

Яго

Өстәвенә ачык ук булмаган
Башка дәлилләрне ачыклый ул.

Отелло

Мин өзгәлим хәзер ул хатынны.

Яго

Чү, акылыгызны югалтмагыз.
Без бит әле берни күрә алмадык.
Бәлки, аның һичбер гаебе юктыр?
Шуны сез әйтегез: хатыныгызда
Җиләк төшерелгән кулъяулыгы
Күргәнегез бар идеме?

Отелло

Яулык?
Аңа минем тәүге бүләгем ул.

Яго

Ансын белми идем. Кассиода
Нәкъ шул төсле яулык күреп калдым.
Битен сөртеп алды, мөгаен, ул
Сезнең хатыныгызның кулъяулыгы.

Отелло

Әгәр дә ул булса...

Яго

Ул яулыкмы,
Башкамы, тик сезнең хатыныгызның
Яулыгы ул. Тагын да бер дәлил.

Отелло

Аһ, ни өчен соң ул кабахәтнең
Җаны кырык мең түгел? Бер җан бик аз.
Үчем канмас минем бер җан белән.
Хәзер күрәм, барысы да дөрес.
Күр, Яго, күр, саф мәхәббәтемне
Мин һавага өрәм — ул юк хәзер!
Әй кара үч, төпсез җәһәннәмнән
Җир өстенә үрлә! Син, мәхәббәт,
Тәхетең һәм таҗыңны кара көчкә бир!
Елан угы белән тулган күкрәк,
Киерел әйдә!

Яго

Чү, тынычланыгыз!

Отелло

Кан, Яго, кан!

Яго

Туктагыз, чү!
Бәлки әле, бу фикердән кайтырсыз.

Отелло

Юк, Яго, юк! Беркайчан да кайтмам!
Понт суының бозлы дулкыннары,
Кире борылуны белмиенчә,
Һаман алга, алга, Пропонтидка,

Геллеспондка ургылганы кебек,
Минем канлы бу ниятем һаман
Алга агар, кире юлны белмәс.
Мәхәббәткә кайтып ул сүрелмәс.
Канлы үчкә йотылып кына сүнәр ул!
Мәрмәр күккә карап мин ант итәм,
Бөтен ихлас күңелем белән әйтәм,
Сүзләремнән кире кайтмам.

Яго

Туктагыз.

Тезләнә.

Әй сез, күктә янган пакь йолдызлар,
Шаһит булыгыз, Яго бар акылын,
Кулын һәм йөрәген, бөтен көчен
Мыскылланган Отеллоның үчен
Алу хезмәтенә багышлый ул.
Ул тик миңа әмер генә бирсен,
Нинди генә канлы әмер булса да,
Саф, мөкатдәс бурычым итеп үтәрмен.

Отелло

Дуслык белән биргән бу антыңны
Күпертелгән сүзләр белән түгел,
Саф йөрәгем белән кабул итәм,
Һәм хәзер үк аннан файдаланам:
Өч көннән соң миңа син Кассио
Инде яшәми дип хәбәр китер.

Яго

Бу үтәлер. Дустым үлгән булыр.
Ләкин хатыныгыз тере калсын.

Отелло

Ләгънәт ул хыянәтчегә, ләгънәт!
Әйдә хәзер киттек минем белән,
Гүзәл кыяфәтле ул шайтанны
Тизрәк һәлак итү турысында
Фикер йөртергә кирәк миңа.
Син бүгеннән минем лейтенантым.

Яго

Мәңге сезнең тугры хезмәтчегез.

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Дездемона, Эмилия һәм Мәзәкче егет керәләр.

Дездемона. Әйтче, сөеклем, лейтенант Кассио кайда туктады икән?

Мәзәкче егет. Әйтә алмыйм, синьора, нигә дисәгез, сүзем ялган булыр.

Дездемона. Ничек алай?

Мәзәкче егет. Солдат бит ул. Ә солдатлар алар туктап тормыйлар, гел алга баралар. Туктатырга азапланучының кирәген бирәләр.

Дездемона. Такмазаларыңны куеп тор. Әйт, кайда тора ул?

Мәзәкче егет. Фәлән өйдә тора дисәм, ялганлыйм бит мин.

Дездемона. Ничек алай?

Мәзәкче егет. Чөнки мин аның кайда торганын белмим. Анда яки тегендә тора ул дисәм, сүзем ялган булыр да үз башыма бәла алырмын.

Дездемона. Аның кайда торганлыгын кешеләрдән сорап белә аласыңмы?

Мәзәкче егет. Хәзер юлда очраган һәрбер кешегә, дин сабагы өйрәтүче кебек, сораулар яудырам һәм алардан җаваплар таләп итәм.

Дездемона. Эзләп тап та син аны монда җибәр. Әйт аңа, мин иремне аның ягына аудардым, эше рәтләнер дип өмет итәм.

Мәзәкче егет. Бу эшне башкарып чыгарга акылым җитәр дип уйлыйм. Шуңа күрә тырышып карыйм булмаса.

Китә.

Дездемона

Яулыгымны кайда төшердем икән, Эмилия?

Эмилия

Белмим, синьора.

Дездемона

Аны югалтканчы, алтын белән
Тулы янчыгымны югалтырга
Риза булыр идем. Болай Отеллом
Ышана да миңа ышануын,
Түбән кешеләрдә була торган
Көнчелектән өстен аның күңеле,
Ләкин моннан шикләнүе мөмкин.

Эмилия

Көнче түгелме ул?

Дездемона

Кем? Улмы? Юк.
Ватанының эссе кояшында
Янып беткән аның ул тойгысы.

Эмилия

Әнә кайтып килә.

Дездемона
Кассионы
Үз урнына кире кайтартмыйча,
Һич тынгылык бирмим мин аңарга.

Отелло керә.

Дездемона

Кәефең ничек, җаным?

Отелло

Хәзер әйбәт. *(Читкә.)*
Аһ, тойгыны яшерү нинди авыр.
Синең кәефең ничек соң, Дездемона?

Дездемона

Минем әйбәт.

Отелло

Бир кулыңны. Кулың
Нинди дымлы.

Дездемона

Ник ул коры булсын?
Кайгы-хәсрәт белән таныш түгел,
Картлык корытмаган.

Отелло

Бу — дәртлелек,
Ялкын һәм юмартлык галәмәте.
А! Ул нинди эссе, нинди дымлы!

Мондый кулга ирек бик зарарлы;
Хуҗасының хисен дилбегәләп,
Дәртле күңелен руза, гыйбадәткә,
Изгелеккә юнәлтергә кирәк.
Юкса ул күңелгә бик сөйкемле
Яшь кенә бер шайтан оялаган —
Ул бик дәртле, хискә бирелүчән,
Тыелырга яратмый ул. — Әйе,
Әйбәт кул һәм үзе шундый юмарт.

Дездемона

Сүзең дөрес, җаным! Мәңгелеккә
Йөрәгемне сиңа бирде бит ул.

Отелло

Әйе, юмарт! Элек заманнарда
Кул һәм йөрәк бергә бирелә иде,
Хәзер коры кулны гына бирәләр.

Дездемона

Сүзләреңне аңламыйм. Йә, ташла,
Шуны әйт син миңа: биргән вәгъдәң
Кайчан үтәләчәк?

Отелло

Нинди вәгъдә?

Дездемона

Синең белән сөйләшергә килсен дип,
Кассиога кеше җибәрдем мин.

Отелло

Бүген миңа бик нык томау төшкән,
Бирче яулыгыңны.

Дездемона

Менә ул, мә.

Отелло

Юк, мин бүләк иткән яулыкны бир.

Дездемона

Ул янымда юк.

Отелло

Юк?

Дездемона

Әйе, монда юк.

Отелло

Бик кызганыч. Аны әниемә
Чегән кызы бүләк итеп биргән.
Ул күрәзә булган, кешеләрнең
Күңелендәге бар уйларын белгән.
Әниемә яулык биргән чакта
Болай дигән: «Яныңда йөрт моны,
Бу яныңда чакта, ирең сине
Сөяр; әгәр дә югалтсаң яки
Берәрсенә бүләк итеп бирсәң,
Ирең сине ташлап китәр», — дигән.
Үлгән чакта әни ул яулыкны,

Кәләшеңә бүләк итәрсең, дип,
Миңа бирде. Шулай иттем дә мин.
Күз караңдай сакла бүләгемне,
Кемгә булса бирсәң йә югалтсаң,
Башкаеңа тиңсез бәла килер.

Дездемона

Мөмкинме бу?

Отелло

Әйе. Ул тылсымлы яулык.
Җирдә ике йөз ел гомер сөргән
Изге хатын изге уйлар белән
Яшәгәндә чиккән ул яулыкны.
Җебен изге кортлар эрләгәннәр,
Ул җепләрне гафиф яшь кызларның
Йөрәк каны белән буяганнар.

Дездемона

Дөресме бу?

Отелло

Дөрес. Шуның өчен
Сакла.

Дездемона

Әгәр дә бу дөрес булса,
Ул яулыкны бөтенләй күрмәвем
Артыграк булыр иде.

Отелло

Ә! Ничек?

Дездемона

Тавышың нинди шомлы!

Отелло

Әйт, югалттың?
Юкка чыктымы? Әйт тизрәк!

Дездемона

Раббым!

Отелло

Кайда ул? Әйт!

Дездемона

Югалмады. Ләкин...

Отелло

Әһә!

Дездемона

Кабат әйтәм, югалмады.

Отелло

Бир яулыкны, күрсәт!

Дездемона

Күрсәтә алам.
Ләкин теләмим. Мин күреп торам,
Сүзне икенчегә бормак буласың.
Рөхсәт ит, Кассио килсен монда.

Отелло

Бир яулыкны, күңелем нидер сизә.

Дездемона

Куйчы, зинһар!.. Аннан әйбәт кеше
Беркайдан да эзләп табалмассың.

Отелло

Яулык!

Дездемона

Ялынып сорыйм, Кассио
Турысында сөйләшикче, зинһар.

Отелло

Яулык!

Дездемона

Ул үзенең бөтен бәхетен
Синең дуслыгыңа нигезләде.
Зур куркынычларны аның белән
Бергә татыдыгыз.

Отелло

Яулык!

Дездемона

Ышан,
Бу хөкемең синең гадел түгел.

Отелло

Кит янымнан!

Чыгып китә.

Эмилия

Көнче түгелмени?

Дездемона

Мондый чагын күргәнем юк иде.
Ул яулыкта, ахры, чын-чыннан да
Тылсым бардыр. Аны югалтуым
Минем өчен нинди бәхетсезлек!

Эмилия

Ирне бер ел, ике елда гына
Белеп булмый. Ирләр — ашказаны,
Ә без — азык. Комсызланып ашыйлар,
Туйганнан соң, косып ташлыйлар.
Әнә ирем белән Кассио килә.

Яго белән Кассио керәләр.

Яго

Башка юл юк. Моны тик ул гына
Рәтли ала. Ә, менә ул үзе дә.
Бик бәхетле икәнсең. Бар, сора.

Дездемона

Йә, ни бар, Кассио дустым? Сөйлә.

Кассио

Һаман шул үтенеч инде, синьора.
Тагын да үтенәм, мине яклап,
Саф йөрәгем белән хөрмәт иткән
Шул кешемнең мәрхәмәтен, зинһар,
Кире кайтарыгыз. Сабырым бетте,
Артык көтә алмыйм. Әгәр инде
Кылган хатам артык олы булып,
Электәге тугры хезмәтләрем,
Хатам өчен әрнеп үкенүем,
Киләчәктә болай хаталанмам
Диеп биргән вәгъдәм — һичберсе дә
Аклый алмый икән гаебемне,
Әйтсен миңа туры. Ул чагында
Язмышыма башым иярмен дә
Бәхетемне башка юлдан эзләрмен.

Дездемона

О Кассио, саф күңелле дустым,
Тырышудан хәзер һич файда юк.
Ул элекке түгел хәзер. Әгәр
Йөзе дә үзгәрсә күңеле кебек,
Мин һич таный алмас идем аны.
Синең өчен мин ялынган кебек,
Минем өчен бөтен фәрештәләр
Ялынсыннар иде. Туры сөйләп
Ачуын гына китердем мин аның.
Бераз сабыр итү кирәк булыр —
Кулдан килгән кадәр тырышырмын.
Шуның белән канәгатьләнегез.

Яго

Ачуландымы генерал?

Эмилия

Нигәдер борчылып чыгып китте.

Яго

Ничек? Ачуланды дисезме? Мин
Туп ядрәсе сафтан солдатларын
Кырган чакта күргәнем бар аны.
Үз янында торган туган энесен
Җен шикелле очып барган ядрә
Кисәкләргә өзгәләде... Ә ул
Чырай да сытмады. Шушы кеше
Ачуландымы? Бу юкка түгел,
Бик зур сәбәп бардыр. Барып белим.

Дездемона

Барып белче, зинһар.

Яго китә.

Нинди булса
Бер хәл бардыр. Бәлки, Венециядән
Берәр төрле начар хәбәр алгандыр.
Ә бәлки, Кипрда нинди булса
Бер хыянәт ачылгандыр. Бу хәл
Аның якты акылын томалыйдыр.
Кешеләр бит зур эш белән борчылсалар,
Вак нәрсәдән үч алучан булалар.
Бу һәрвакыт шулай. Бармактагы
Бер кечкенә яра бөтен тәнне

Сызландыра. Аннан шунсы да бар:
Ирләр Алла түгел, гомер буе
Кияү булып йөргән көндәгедәй
Илтифатлы булып бета лмыйлар.
Бик нык әрлә мине, Эмилия,
Командирдан зарланган яшь солдат кебек
Эшнең төбен аңламыйча, мин иремне
Каты мөгамәлә итә диеп
Гаепләдем. Ләкин шаһитларым
Минем уйны дөресләмәделәр:
Гаепләвем минем һич урынсыз.

Эмилия

Хода кушып, борчылуга сәбәп
Көнләшү булмыйча, берәр төрле
Дәүләт эше генә була күрсен.

Дездемона

Раббым! Алай көнләштерә торган
Берни эшләгәнем юк бит минем.

Эмилия

Бу сүз көнчеләргә җавап түгел.
Көнләшүгә сәбәп кирәк түгел.
Көнче кеше сәбәп булган өчен
Көнләшми бит. Ул көнләшә фәкать
Табигате көнче булган өчен.
Көнчелек ул, нәкъ аждаһа кебек,
Ул үзеннән-үзе буазлана
Һәм үзеннән-үзе туа, үсә.

Дездемона

Раббым, үзең сакла Отеллоны
Андый аждаһадан.

Эмилия

Амин, синьора.

Дездемона

Мин артыннан китәм. Сез, Кассио,
Монда калып көтеп торсагызчы.
Әгәр дә ул тынычланган булса,
Бурычымны үтәп чыгу өчен,
Бөтен көчем белән тырышырмын.

Дездемона белән Эмилия чыгып китәләр.
Бианка керә.

Бианка

А, Кассио, дустым!

Кассио

А, сөеклем!
Кәефең ничек? Нигә килдең монда?
Сиңа китеп бара идем, бәгърем.

Бианка

Ә мин сиңа диеп бара идем.
Атна буе килгәнең юк. Җиде көн,
Җиде төн син килми йөри аласың.
Нәкъ йөз алтмыш сигез сәгать бит бу!
Сөеклеңнән башка үткәрелгән

Һәрбер сәгать йөз дә алтмыш тапкыр
Озынрак булып тоела бит ул.
Аны санау, аһ, никадәр авыр!

Кассио

Кичер мине, бәгърем, бу арада
Мөһим эшләр белән мәшгуль идем.
Иркәм, миңа менә шуның төсле
Яулык чигеп бирә алмассыңмы?
*(Яулык бирә.)*

Бианка

Кайдан алдың моны? Яңа дустың
Бүләк итеп биргән яулыкмы бу?
Менә син ни өчен килми йөргәнсең!
Әйбәт, иркәм, әйбәт!

Кассио

Йә, йә, җитәр!
Бу шигеңне шайтан битенә бәр,
Ул пышылдый сиңа бу уйларны.
Көнлисең? Бу яулык башка берәр
Сөяркәмнең ядкаре дип уйлыйсың?
Юк, Бианка, ант итәм.

Бианка

Соң, кемнеке?

Кассио

Үзем дә белмимен, бәгърем, моны
Мин бүлмәмнән таптым. Бик ошаттым.
Хуҗасына кайтарганга кадәр,
(Кайтарырга туры килер, мөгаен),
Шуның төсле яулык чигеп бирсәңче.
Мә, ал да кит моннан.

Бианка

Китим? Нигә?

Кассио

Мин бит генералны көтеп торам.
Яхшы булмас, әгәр дә ул мине
Хатын-кыз янында очыратса.
Үзем дә мин моны һич теләмим.

Бианка

Нигә алай?

Кассио

Сөймәгәнем өчен
Түгел инде.

Бианка

Артык сөйгән өченме?
Ярый, әйдә әзрәк озат мине...
Кайчан куна киләсең?

Кассио

Озатам.
Ләкин ерак баралмыйм, сөеклем,
Генералны көтәм. Тиздән күрешербез.

Бианка

Нишлисең бит, ансына да рәхмәт,

Башыңа төшкәч, буйсынасың инде.

Китәләр.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кипр. Замок алды. Отелло белән Яго керәләр.

Яго

Һаман шулай уйлыйсызмы?

Отелло
Шулай.
Яго

Яшерен бер үбүдән нәрсә була?

Отелло

Яшерен үбү — зур җинаять.

Яго
Яки
Дус егете белән, шәрә килеш,
Гөнаһ кылмый гына яткан икән...

Отелло

Шәрә килеш гөнаһ кылмый яту!
Бу — күз буяу шайтан каршысында!
Һичбер бозык уйсыз андый эшне
Кылган кешеләрне җен котырта,
Алар мыскыл итә Хак Тәңрене.

Яго

Олы эш юк икән — гөнаһ та юк.
Аннан хатыныма бүләк итеп
Яулык бирәм икән...

Отелло
Йә, йә, шуннан?
Яго

Яулык аның милке була, аны
Ул теләсә кемгә бирә ала.

Отелло

Намусы да аның милке, аны да
Кемгә тели, шуңа бирә аламы?

Яго

Намус нәрсә? Күзгә күренми ул.
Саф намуслы булып күренүче
Бик күпләрдә намус бөтенләй юк.
Әмма яулык...

Отелло

О, ант итеп әйтәм,
Мин шатланып онытыр идем аны,
Ләкин син хәтергә төшерәсең.
Кешеләрен үләт кырып киткән
Йорт өстендә очкан козгын кебек,

Хәтерем күген каплый шушы яулык.
Кассиода күрдем дисеңме әле?

Яго

Күрсәм нәрсә булган?

Отелло

Аһ, Яго, бу начар!

Яго

Кассиодан сезне хурлый торган
Андый-мондый сүзләр ишетәм икән,
Моңа карап нигә борчылырга?
Бит дөньяда түбән табигатьле
Андый юньсез халык тулып ята.
Күңел куеп йөргән хатыннарын,
Бертуктамый ялынып йөреп яки
Оста итеп күңел кылын чиртеп,
Үзләренә таба аударсалар,
Шуны сөйләмичә түзалмыйлар.

Отелло

Сиңа берәр нәрсә әйтте мәллә?

Яго

Әйтте, ләкин андый юк-бар сүздән
Антлар итеп тануы да мөмкин.

Отелло

Соң, ни диде?

Яго

Улмы?.. Ләкин белмим,
Ничегрәк итеп әйтим икән?
Мин, ди, аның белән...

Отелло

Йә?

Яго

Яттым, ди.

Отелло

Янындамы?

Яго

Янындамы анда, өстендәме,
Ничек теләсәгез, шулай аңлагыз.

Отелло. Аның белән яткан!.. Аның белән! Аһ, бу нинди кабахәтлек! Яулык!.. Үз теле белән сөйләп йөрүе. Яулык! Барын да сөйләтергә дә асарга!.. Юк, иң элек асарга, аннан сөйләтергә!.. Бөтен тәнем дер-дер калтырый... ярсуым акылымны җиңеп бара, юкка түгел бу. Фу! Борыннар, колаклар, иреннәр! Мөмкинме бу? Үз теле белән сөйләп биргән!.. Яулык!.. Аһ, Иблис!.. *(Һуштан язып егыла.)*

Яго

Эшлә, агуым, эшлә үз эшеңне!
Ышанучан ахмак бәндәләрне
Менә шулай аулыйлар! Һич керсез,
Пакь күңелле, тугры хатыннарны
Шулай пычраталар... Аһ, генерал,
Синьор Отелло! Ни булды сезгә?

Кассио керә.

Ә, Кассио!

Кассио

Ни бар? Нәрсә булды?

Яго

Менә өянәге тотты. Инде
Икенче кат. Кичә дә егылды.

Кассио

Чигәсен у.

Яго

Юк, юк, кирәкми һич.
Өянәге тоткан чакта борчыма.
Авызыннан күбекләре килер,
Шашып котырына башлар... Тукта,
Кыймылдады. Сез китегез моннан.
Һушына килә хәзер. Моннан китәр ул,
Аннан соң килегез, сезнең белән
Мөһим эш хакында сөйләшәсем бар.

Кассио китә.

Ничек, синьор, маңгаегыз саумы?

Отелло

Көләсең син миннән?

Яго

Көләм? Сездән?
Ходa шаһит. Мин тик сезнең
Әче бу язмышыгызны ирләрчә
Күтәрүегезне генә телим.

Отелло

Мөгезле ир — ерткыч ул, аждаһа.

Яго

Андый аждаһалар шәһәр тулы,
Елмаешып, тыныч кына яшиләр.

Отелло

Үзе әйттеме?

Яго

Ах, ир булыгыз!
Сакал үсеп җиткән һәрбер кеше,
Хатын арбасына җигелү белән,
Шул ук хурлык йөген тарта башлый.
Ышаныгыз, миллионлаган ирләр
Һәр кич саен әллә кемнәр яткан
Түшәкләргә кайтып яталар, һәм
Бу түшәккә тик мин генә ятам дип
Антлар итәләр. Сез алай түгел,
Сезнең хәлегез аннан әйбәтрәк.
Йә, әйтегез, әгәр дә ир кеше
Азып, себерелеп йөргән хатынын,
Фәрештәдәй пакь дип уйлап, аны
Саф мәхәббәт белән иркәләсә,
Бу хәл җәһәннәмнең — Газазилнең
Әче мәсхәрәсе булмасмыни?
Белү әйбәтрәк, белгәч инде

Хатынымны нишләтергә беләм мин.

Отелло

Син акыллы...

Яго

Хәзер яшеренегез.
Зур түземлек белән күзәтегез.
Әле кайгыгыздан шашып китеп
Җирдә егылып яткан чагыгызда,
Микаэль Кассио булды монда.
Сезнең болай егылуыгызга
Матуррак сәбәп эзләп табып,
Кире борып җибәрдем мин аны.
Тиздән монда сөйләшергә килә,
Мин чакырдым аны. Сез яшеренеп
Күзәтегез: аның чыраенда
Мәсхәрәле көлү, нәфрәтләнү,
Кәпрәю билгеләре күрерсез.
Хатыныгыз белән кайвакытта,
Кайда, ничә тапкыр эш иткәнен.
Тагын киләчәктә ничә тапкыр
Бергә булачагын — барысын да
Яңабаштан, кабат сөйләтәчәкмен.
Кабат әйтәм, аның хәрәкәтен
Күзәтегез, ләкин сабыр, сабыр!
Юкса күрәм, артык шашып китеп,
Ирлек сыйфатларыгызны җуясыз.

Отелло

Сабыр булырмын мин — ишетәмсең, Яго?
Минем сабырлыкка син шаккатарсың.
Тик соңыннан синең янга мин, Яго,
Кансыз ерткыч булып килеп басармын.

Яго

Килсәгез ни — ул да яман булмас,
Тик шунысы: һәрнәрсәнең вакыты бар.
Хәзер сезгә яшеренергә кирәк.

Отелло читкә китә.

Аның белән Бианка хакында
Мин сөйләшермен. Ул шундый хатын,
Азык, кием өчен гүзәллеген
Кем очрый, шуңа сатып йөри.
Кассионы сөя. Андый азгын,
Бозык хатыннарның язмышы бер:
Бик күпләрне алдап, азагында
Кемнең булса тозагына төшә.
Ә Кассио, аның турысында
Сүз кузгатсаң, үлә язып көлә.
Менә үзе.

Кассио керә.

Егет бер елмайса,
Тәмам акылыннан шашар Отелло.
Яшь егетнең елмаюы, сүзе,
Хәрәкәте, сукыр көнче өчен
Әллә нинди мәгънә аңлатачак.
Йә, лейтенант, эшләр ничек бара?

Кассио

Начар. Өстәвенә, мыскыл иткән кебек,
Җуйган титулымны телгә аласың.
Ансыз да мин ярым үлек кеше.

Яго

Сез Дездемонадан үтенегез,
Мөгаен, эшегез барып чыгар.
*(Әкрен.)*
Бу эш Бианка кулында булса,
Сезнең теләк тиз үтәлер иде.

Кассио

Шул бичара искә төшкән чакта
Көлми чыдый алмыйм.

Отелло
*(читкә)*

Көлә, көлә!

Яго

Шушы кадәр ирләр яратучы
Хатын күргәнем юк әле минем.

Кассио

Бичаракай, чынлап та ул мине
Сөя бугай.

Отелло
*(читкә)*

Юк, яшерми. Үзе
Һаман көлә.

Яго

Шуны сез әйтегез...
*(Колагына нидер әйтә.)*

Отелло
*(читкә)*

Сөйләтергә тели... әйбәт, әйбәт!

Яго

Сезнең хакта, миңа өйләнә, дип
Сөйләп йөри икән!

Кассио

Ха-ха-ха-ха!

Отелло
*(читкә)*

Син шатланасың, Рим егете, шатланасың!

Кассио. Мин аңа өйләнәм? Урам кызына? Зинһар, кызган мине, акылымны ихтирам ит, шөкер әле, ул кадәр үк ахмак түгелмен! Ха-ха-ха!

Отелло *(читкә)*. Шулай, шулай, шулай! Откан кешеләр һәрвакыт көләләр.

Яго. Чынлап та, сезнең хакта аңа өйләнә дигән хәбәр йөри.

Кассио. Чынлап сөйлисеңме?

Яго. Юкны сөйли торган булсам, чәнчелеп китим.

Отелло *(читкә)*. Мине бөтенләй исәптән чыгардыгыз. Яхшы!

Кассио. Ул үзе, ахмак маймыл, шундый хәбәр тарата. Мин вәгъдә иткәнгә түгел, үзенең яратуына таянып, миңа чыгам дип уйлый.

Отелло *(читкә).* Яго миңа ымлый. Димәк, ул сөйли башлый.

Кассио. Һәрвакыт арттан ияреп йөри. Моннан берничә көн элек яр буенда венециялеләр белән сөйләшеп тора идем. Кинәт әллә кайдан килеп чыкты да, шашкан кеше кебек, менә шулай муеныма килеп асылынды.

Отелло *(читкә).* «О, кадерлем Кассио!» дип кычкырган. Хәрәкәтләреннән шулай аңлашыла.

Кассио. Ул сарыла миңа, үзе елый, әллә кая өстери, йолыккалый. Ха-ха-ха!

Отелло *(читкә).* Хәзер инде үзен ничек итеп йокы бүлмәмә алып керүе турында сөйли.

Кассио. Юк, болай ярамый. Аның белән исәпне өзәргә кирәк.

Яго. Әнә үзе килә!

Кассио. Менә көзән! Исле май сөртенгән көзән!

Бианка керә.

Йә, әйт әле, нигә болай минем артымнан ияреп йөрисең?

Бианка. Шайтан иярсен сиңа! Миңа биргән бу яулыгың нинди яулык? Ә мин, җүләр, нигә алдым соң әле? Ул миннән шундый ук яулык чиктерергә тели. Ә үзе бүлмәсеннән табылган шушы әшәке чүпрәкнең кемнеке икәнен дә белмим дигән була! Шулай итеп, мин нindидер бер кәнтәй тарафыннан аңа бүләк ителгән яулыкның бизәген күчереп утырыйм, имеш! Мә, ал, кәнтәеңә илтеп бир! Миңа дисә, әллә кемнән ал, ләкин мин аның бизәген күчереп утырырга теләмим.

Кассио. Сиңа ни булды, җаным Бианка? Ни булды сиңа?

Отелло *(читкә)*. Күк белән ант итеп әйтәм, бу, мөгаен, минем яулык!

Бианка. Теләгең булса, бүген миңа кичке ашка килеп чык. Теләмисең икән, икенче берәр вакытта, үзең теләгәч килерсең.

Китә.

Яго. Артыннан бар, артыннан!

Кассио. Чынлап та, барырга кирәк. Юкса урам уртасында сүгенә башлар.

Яго. Кичке ашны сез аңарда ашыйсызмы?

Кассио. Шулай итәрмен, ахры.

Яго. Ул чагында, бәлки, мин дә барып чыгармын. Сезнең белән сөйләшәсе сүзем бар минем.

Кассио. Рәхим итегез. Килерсезме?

Яго. Хушыгыз. Барып чыгармын.

Кассио китә.

Отелло. Ничек үтерим мин аны, Яго!

Яго. Сиздегезме, үзенең кабахәтлеге белән ничек мактана?

Отелло. О, Яго!

Яго. Яулыкны күрдегезме?

Отелло. Ул минем яулык идеме?

Яго. Кулларымны кисәргә бирәм, сезнеке. Теге җилкуар хатынны ничек хөрмәт иткәнен күрдегезме инде — сезнең хатыныгызны, дим. Дездемона аңа яулык бүләк иткән, ә ул аны үзенең шушы себеркесенә биргән.

Отелло. Мин бу азгын егетне тугыз елда тугыз тапкыр үтерер идем. Гүзәл хатын! Сылу хатын! Сөйкемле хатын!

Яго. Юк, сезгә моны онытырга кирәк.

Отелло. Аһ, чәнчелеп китсен, череп бетсен, бүген кичен үк җәһәннәм кисәвенә әйләнсен! Юк ул хатынга дөньяда яшәү — юк! Йөрәгем ташка әйләнде: мин сугам йөрәгемә, ләкин кулым гына авырта. Аһ, дөньяда аннан да гүзәл җан иясе юк иде! Ул император хатыны булып, аңа да әмерләр биреп тора алыр иде!

Яго. Аннан сезгә нинди мәгънә?

Отелло. Чәнчелеп китсен! Мин тик гүзәл сыйфатлары турында гына әйтәм. Матур итеп чигә белә, нинди оста итеп музыкада уйный. О, ул үзенең моңлы җыры белән тупас аюны да эретер иде. Нинди тирән акыл үзендә, нинди тапкырлык!..

Яго. Бу аның гаебен тагын да арттыра төшә.

Отелло. Мең тапкыр, мең тапкыр арттыра. Өстәвенә нинди ягымлы!

Яго. Әйе, кирәгеннән артык ягымлы.

Отелло. Дөрес, син хаклы, шулай да, кызганыч, Яго! О, Яго. Кызганыч, Яго, кызганыч!

Яго. Хатыныгызның азгынлыгына шулкадәр гашыйк булгач, ирек бирегез аңа, әйдә йөри бирсен. Үз күңелегезгә авыр булмаса, анда бер кешенең дә эше юк.

Отелло. Мин аны кисәкләргә тураклыйм... Миңа мөгез куярга[1] !

Яго. Әйе, бу аның тарафыннан зур әдәпсезлек.

Отелло. Җитмәсә, минем офицерым белән!

Яго. Монысы инде тагын да әшәкерәк.

Отелло. Агу тап миңа, Яго, бүген кичкә үк! Аның гүзәллекләре минем карарымны какшатмасын өчен сөйләшеп, аңлашып та тормам... Бүген кичкә үк, Яго.

Яго. Агу белән үтермәгез. Сезне мыскыл иткән түшәктә буып үтерегез.

Отелло. Әйбәт, әйбәт! Мондый гадел хөкем миңа ошый. Шәп булыр!

Яго. Ә Кассионы миңа тапшырыгыз. Эшнең дәвамын бүген төн уртасында ишетерсез.

Отелло. Әйбәт!

Быргы тавышы.

Бу ни? Нинди быргы тавышы?

Яго

Венециядән бер хәбәр килгәндер.
Ә Лодовико бу, дож илчесе.
Әнә сезнең хатыныгыз белән
Монда киләләр.

Лодовико, Дездемона һәм хезмәтчеләр керәләр.

Лодовико

Генерал, сәлам сезгә.

Отелло

Чын күңлемнән рәхмәт сезгә.

Лодовико

Хөрмәтле дож, барлык сенаторлар
Сәлам тапшырдылар.
*(Пакет бирә.)*

Отелло

Алар әмерен
Миңа җиткерүче бу кәгазьне
Саф күңелдән үбәм.
*(Пакетны ачып укый.)*

Дездемона

Нинди хәбәр
Китердегез, сөекле Лодовико?

Яго

Сезне монда күрүемә бик шатмын,
Килүегез белән тәбрик итәм.

Лодовико

Рәхмәт. Ә Кассио ничек яши?

Яго

Яши, синьор.

Дездемона

Ирем белән аның арасында
Бераз күңелсезлек чыгып тора.
Хәер, сезнең ярдәмегез белән
Ул төзәлер.

Отелло

Шулай уйлыйсыңмы?

Дездемона

Ә? Ни дидең, бәгърем?

Отелло

*(укый)*

«Бу әмерне
Сез үзегез теләгәндә үтәрсез».

Лодовико

Синә түгел, ул хат белән мәшгуль.
Димәк, алар бераз бозылыштылар?

Дездемона

Әйе, үкенечкә каршы шулай.
Мин аларны килештерү өчен
Әллә ниләр эшләр идем, чөнки
Бик яратам бит мин Кассионы.

Отелло

Ут, җәһәннәм!

Дездемона

Син ни дидең, иркәм?

Отелло

Син акылыңдамы?

Дездемона

Ул ачулана.

Лодовико

Аны хат борчыгандыр. Бу хатта,
Әгәр ялгышмасам, сенат аңа,
Хакимлекне Кассиога биреп,
Венециягә кайтырга куша.

Дездемона

Моңа мин шат.

Отелло

Син шат?

Дездемона

Нәрсә, бәгърем?

Отелло

Шуңа «мин шат», син акылыңнан шашкансың!

Дездемона

Отеллом, ни дигән сүз бу?

Отелло

Иблис!

Кулындагы төргән кәгазе белән суга.

Дездемона

Нинди гаебем бар?

Лодовико

Генерал, әгәр дә,
Шушы хәлне күзем белән күрдем, дип
Венеция халкына ант итсәм дә,
Ышанмаслар иде. Монысы чиктән тыш.
Гафу үтенегез, елый ул.

Отелло

О!

Иблис, Иблис! Хатын-кыз яшеннән
Җир авырга кала торган булса,
Һәрбер тамчысыннан бер аждаһа
Туар иде. Бар, күземнән югал!

Дездемона

Монда калып сине ярсытырга
Теләмим.

Китә.

Лодовико

Ул нинди буйсынучан.
Ах, генерал, кире чакырыгыз.

Отелло

Синьора!

Дездемона

Ни кирәк, иркәм?

Отелло

Әнә
Синьор сезгә нидер әйтмәк була.

Лодовико

Кем? Мин?

Отелло

Әйе, сез бит теләдегез
Кире борылуын. О, ул борыла,
Китә, кире борыла, тагын китә,
Тагын борылып килә, ул булдыра.
Елый — күз-яшь түгә. Буйсынучан,
Сез әйткәнчә, бик-бик буйсынучан.
Ела, ела!.. Хатны укып чыктым...
Нинди оста газаплана белә!..
Әмер шулай: мин кайтырга тиеш...
Бар, кит моннан, бар, соңыннан чакырырмын!
Сенат боерыгын үтәрмен мин,
Венециягә кайтырмын... Бар, югал!

Дездемона китә.

Эшне мин Кассиога тапшырырмын.
Бүген, синьор, миңа кичке ашка
Рәхим итәрсез. Чын күңелемнән
Мин шатландым сезне күрүемә.
Кәҗә тәкәләре һәм маймыллар!

Китә.

Лодовико

Бу нинди эш? Безнең сенатыбыз
Бөтен гүзәллекнең үрнәге дип
Атап йөртә торган гарәп шушымы?
Һичбер хискә җиңелмәслек рухы,
Кайгы-хәсрәт, язмыш укларына
Бирешмәгән көчле ихтыяры
Шулмы аның?

Яго

Ул үзгәрде хәзер.

Лодовико

Акыл ягы ничек икән аның?
Мие ничек, зәгыйфьләнмәгәнме?

Яго

Бары шунда инде. Гаепләргә
Батырчылык италмыйм мин. Фәкать
Ничек яратылган, шулай калсын дип,
Теләк кенә тели алам Хактан.

Лодовико

Хатыныңа сугу! Мөмкинме бу?

Яго

Шәп эш түгел, әлбәттә, ләкин мин
Моннан зуррагы булмасын дип
Теләр идем.

Лодовико

Ничек, ул һәрвакыт
Үзен шулай тотамы? Бәлки, ул
Хат укыгач, артык ярсып китеп,
Белешмичә суккандыр.

Яго
Әй, синьор,
Күргән, белгәнемне сөйләп бирсәм,
Бик зур намуссызлык булыр иде.
Күзәтегез, сез үзегез күрерсез:
Эше, холкы минем сүздән башка да
Барысын да сезгә ачып салыр.

Лодовико

Аның турындагы фикеремне
Үзгәртүе миңа нинди авыр.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Замок эчендә бүлмә.
Отелло белән Эмилия керәләр.

Отелло

Димәк, сез берни дә күрмәдегез?

Эмилия

Юк, күрмәдем. Андый шикләнерлек
Сүз дә ишетмәдем.

Отелло

Кассио белән
Очрашканын күргәнсең бит.

Эмилия

Күрдем.
Ләкин мин аларның һәрбер сүзен
Ишетеп тордым. Андый гаепләрлек
Эш күрмәдем.

Отелло

Бәлки, ара-тирә
Пышылдашып сөйләшкәннәрдер?

Эмилия

Юк.

Отелло

Сине берәр төрле йомыш белән
Җибәрмәделәрме?

Эмилия

Юк, беркайчан.

Отелло

Перчатка, веер, маска алырга дип?

Эмилия

Юк, генерал.

Отелло
Гаҗәп.

Эмилия
Синьораның
Күңеле саф. Аның сафлыгына
Җаным белән ант итәргә әзер.
Әгәр хатыныгыз турында сез
Башка төрле фикер йөртсәгез,
Чыгарыгыз аны башыгыздан,
Күңлегезне юкка борчымагыз.
Мондый шикне сезнең күңлегезгә
Берәр явыз урнаштырган булса,
Ул эшлексез, юха елан кебек,
Хода ләгънәтенә дучар булсын!
Инде синьора да саф булмаса,
Димәк, бәхетле ир юк дөньяда;
Димәк, хатыннарның иң сафы да
Яла кебек пычрак булып чыга.

Отелло

Чакыр үзен.

Эмилия чыга.

Нинди оста сөйли!
Хәер, сөяркәләр кавыштырып
Йөри торган һәрбер гади димче
Шулай оста итеп сөйли ала.
О, хәйләкәр. О, мәкерле мәхлук!
Иң әшәке серләр сандыгының
Йозак һәм ачкычы. Шул, тезләнеп,
Дога укып тора — үзем күрдем.

Дездемона белән Эмилия керәләр.

Дездемона

Нәрсә тели миннән хөкемдарым?

Отелло

Монда кил, сөеклем.

Дездемона

Ни бар?

Отелло

Күзләремә кара, туры кара.

Дездемона

Сүзләреңнең серен аңлый алмыйм.

Отелло
*(Эмилиягә)*

Хәзер инде үз эшеңә тотын,
Ишек төбен сакла, гашыйкларны
Ялгыз калдыр. Берәр кеше килсә,
Тамак кырып яки тавыш биреп,
Безгә белдер. Мондый вакытларда
Ничек эш итәргә беләсең бит.
Йә, бар!

Эмилия китә.

Дездемона

Аңлат, зинһар, мин ялварам,
Мәгънәсе ни шомлы сүзләреңнең?
Күрәм фәкать синең ярсуыңны,
Ләкин серен аның аңлый алмыйм.

Отелло

Йә, әйт, син кем?

Дездемона

Тугры, саф хатының.

Отелло

Ант ит: шушы ялган антың белән
Җәһәннәмгә ташла үз-үзеңне.
Юкса, нурлы, саф йөзеңне күреп,
Зобанилар кыймас тотынырга.
Гаебеңне үстер икеләтә:
Ант ит, мин саф, диген.

Дездемона

Хода шаһит!

Отелло

Ходa синең җәһәннәмдәй кара,
Мәкерле җан икәнеңә шаһит.

Дездемона

Гөнаһым ни? Кемне алдадым мин?

Отелло

О, Дездемона, кит, кит, кит!

Дездемона

Раббым!
Нинди шомлы бу көн! Аһ, син елыйсың?
Мин сәбәпчемени бу яшьләргә?
Бәлки, сине моннан кайтаруны
Әтиемнән күрә торгансыңдыр.
Ләкин монда мин гаепсез, сиңа
Ул чит булган кебек, миңа да чит,
Мин дә мәхрүм ата шәфкатеннән.

Отелло

Әгәр дә күк, җимереп бар шатлыгым,
Баш өстемә михнәт, кайгы-хәсрәт,

Иксез-чиксез әче хурлыкларын
Көчле яңгыр кебек коеп түксә,
Мине муеннан мохтаҗлыкка күмеп,
Бөтен өметемне тар-мар итсә, —
Әле күңелемнең бер читендә
Мин сабырлык таба алыр идем.
Ләкин мине җансыз һәйкәл итеп,
Ил алдына бастырсалар, һәркем,
Салкын нәфрәт күзе белән карап,
Миңа бармак төртеп көлсә, — а юк,
Аңа да мин түзә алыр идем.
Ләкин монда — рухым җәннәтендә —
Минем рухым өчен урын бетсә,
Миңа яшәү көче бирә торган
Хәят чишмәм мәңге корып кипсә
Яки, сасы күлгә әверелеп,
Нәҗес хәшәрәтләр ояласа!..
О! Бу чакта инде син, сабырлык,
Ал мөлаем йөзле, нурлы күзле
Фәрештәдәй кыяфәтең җуеп,
Коточыргыч зобанига әйлән!

Дездемона

Шулай да әле минем сафлыгыма
Ышанасыңдыр дип өмет итәм.

Отелло

О, ышанам! Ит базарындагы
Шакшы чебеннәрнең сафлыгына
Ышанган күк. О, зәһәрле, ләкин
Гаҗәп матур, тәмле исең белән
Агулаучы чәчкә, бу дөньяга
Бөтенләй тумаган булсаң әгәр,
Артыграк булыр иде.

Дездемона

Раббым!
Үзем белми торган гөнаһым ни?

Отелло

Бу гаҗәеп матур ап-ак кәгазь,
Шушы кадәр гүзәл китап нигә?
«Бозык хатын» диеп язар өченме?
«Гөнаһым ни?» Аһ, син урам кызы!
Әгәр дә мин синең эшләреңне
Хәзер сиңа сөйләмәкче булсам,
Йөзем эссе мичкә әверелеп,
Бар әдәбем көлгә дүнәр иде.
«Гөнаһым ни?» Синең эшне күреп,
Күк үзенең борынын каплый бит; ай
Йөзен чыта; хәтта ни очраса,
Шуны үбеп үткән әдәпсез җил дә,
Сиңа кагылмыйм дип, җирәнүдән
Тирән мәгарәгә кереп поса!
«Гөнаһым ни?», имеш! Аһ, уйнашчы!

Дездемона

Мине юкка мыскыл итүеңне
Хода күреп тора.

Отелло

Азгын түгелме син?

Дездемона

Азгын түгел. Бөек Хода белән
Мин ант итәм, сафлыгым хак минем!
Ире өчен үзен чит куллардан,
Чит кочактан саклый торган хатын
Азгын саналмаса, синең хатының
Азгын түгел.

Отелло

Синме азгын түгел?

Дездемона

Юк, юк! Мин ант итәм җаным белән!

Отелло

Мөмкинме бу?

Дездемона

Раббым, Раббым, шәфкать!

Отелло

Гафу ит алайса, мин бит сине
Отеллога иргә чыгып алган
Венециянең бер бозык кызы дип
Белгән идем.
*(Тавышын күтәрә төшеп.)*
Әй син, җәһәннәмнең
Ишек саклаучысы!

Эмилия керә.

Әйе, син, син!
Без бетердек. Мә хезмәтең өчен.
Ач ишекне һәм бу серне сакла.

Китә.

Эмилия

Раббым, ул ни эшләмәкче була?
Синьора, ни булды сезгә? Синьора?

Дездемона

Мин төш күрәм кебек.

Эмилия

Соң, ни булды?

Дездемона

Кемгә?
Эмилия

Соң, билгеле инде, әфәндемә.

Дездемона

Кем соң ул әфәндең?

Эмилия

Соң, шул инде,
Сезнең әфәндегез, минем хуҗам,
Мин ирегез турысында әйтәм.

Дездемона

Юк, юк минем ирем! Эмилия,
Сөйләшмә син, зинһар, минем белән.
Фәкать әче күз-яшь белән генә
Җавап бирә алыр идем, ләкин
Елый алмыйм хәзер. Бүген төнгә
Никах түшәк япмамны җәй, онытма.
Ә хәзер Ягоны чакыр монда.

Эмилия

Менә бәла.

Чыгып китә.

Дездемона

Нинди сүзләр әйтте?
Аны мондый шиккә төшерерлек
Нинди генә гөнаһ кылдым соң мин?

Эмилия белән Яго керәләр.

Яго

Ни боерасыз? Ни булды сезгә?

Дездемона

Ничек диеп әйтергә дә белмим.
Бала тәрбияли торган кеше
Яшь балага җәза биргәндә дә
Җиңел җәза бирә. Мине дә ул
Бераз шелтәләсә, җитәр иде,
Дөресен әйтсәм, мин бит әле бала.

Яго

Соң ни булды?

Эмилия

Ах, Яго, генерал
Синьораны шундый мыскыл итте,
Шундый ямьсез кушаматлар такты,
Ул кушаматларны саф йөрәкле
Һичбер кеше күтәрә алмас иде.

Дездемона

Әйтче, ул исемне күтәрергә
Тиешме мин?

Яго

Нинди исем соң ул?

Дездемона

Әле генә ирем таккан исем.

Эмилия

Ул «уйнашчы» диде хатынына,
Гомере буе эчеп айнымаган
Теләнче дә үзенең сөяркәсен
Мондый сүзләр белән сүкмәс иде.

Яго

Соң ни өчен?

Дездемона

Белмим. Бары шуны беләм,
Мин андый әшәке хатын түгел.

Яго

Йә, тынычланыгыз, еламагыз.
Нинди шомлы бу көн!

Эмилия

Шуның өченме
Менә дигән затлы кешеләрнең
Тәкъдимнәрен кире кагып килде?
Уйнашчы дип сүгелер өченмени
Карт атасын, якын дус-ишләрен,
Газиз туган илен ташлап китте?
Моны ишетеп, еламый кем түзәр?

Дездемона

Күрәсең, язмышым шундый карадыр.

Яго

Ничек оялмый ул! Бу ахмаклык
Кайдан килгән аңа?

Дездемона

Хода белсен.

Эмилия

Бу гайбәтне адәм җирәндергеч,
Эшлексез бер юньсез, ялагай кол,
Тугры булган булып, яхшатланып,
Дәрәҗәгә менү уе белән
Таратмаган булса, тотсыннар да
Дарга асып үтерсеннәр мине!

Яго

Куй, дөньяда андый кешеләр юк.
Булуы да мөмкин түгел.

Дездемона

Әгәр дә
Була икән, Ходa ярлыкасын.

Эмилия

Юк, юк, дар агачы ярлыкасын!
Сөякләре җәһәннәмдә янсын!
Нинди исем! Бозык хатын, имеш!
Ул кем белән йөрде? Кайда? Ничек?
Кайвакытта? Юк, маврны, мөгаен,
Ниндидер бер явыз, эшкә иңмәгән,
Җирәндергеч, юньсез, битсез адәм
Алдалаган. Раббым! Андыйларны
Фаш итмәссеңмени? Саф намуслы
Гадел кешеләрнең кулларына
Камчы тоттыр. Шул кабахәтләрне,
Шәрә чишендереп, чыбыркылап
Көнчыгыштан көнбатышка куып,
Бөтен дөнья буйлап мәсхәрәләп йөртсеннәр.

Яго

Әй син, әкренрәк.

Эмилия

Ләгънәт аңа! Син дә, шуның кебек

Бер кабахәт сүзеннән акылың җуеп,
Мине Отеллодан көнләп йөрдең.

Яго

Шаштың мәллә? Бар, кит моннан.

Дездемона
Ах, Яго,
Киңәш бир, иремнең мәхәббәтен
Ничек итеп кире кайтарырга?
Саф күңелле дустым, бар син аңа!
Ходa шаһит, аның мәхәббәтен
Ни сәбәптән югалтканлыгымны
Үзем дә белмим. Тезләнгән килеш
Мин ант итеп әйтәм сиңа, әгәр дә
Аның мәхәббәтен кайчан булса
Сүзем, эшем белән, уем белән
Мыскыл иткән булсам, йә булмаса
Башка берәр төрле ир кешене
Күз карашым белән иркәләсәм,
Аның сүзен тыңлап ләззәтләнсәм,
Яки башка берәр тойгым аша
Аңа күңел салган булсам икән!
Мине мәсхәрәләп үз яныннан
Куып җибәрүгә карамастан,
Аны һаман электәге кебек
Бөтен күңлем белән яратмасам,
Тар-мар килсен бөтен тынычлыгым,
Һәм күңлемә минем ул тынычлык
Мәңге урнашмасын! Ачу көчле,
Аның ачуы миннән яшәү көчен
Тамыры белән йолкып ташлый ала.
Ләкин ул да минем күңлемдәге
Мәхәббәтне тартып ала алмас.
Бозык хатын! Бу исемне ишетү
Нинди авыр миңа! Бу кабахәт,
Әшәке сүз мине җирәндерә!
Бар дөньяны миңа бирсәләр дә,
Бу исемгә лаек эшкә мәңге
Риза булмам.

Яго
Йә, тынычланыгыз.
Бу ярсуы аның бер минутлык,
Ул борчылган дәүләт эше белән,
Хәзер шуның үчен сездән ала.

Дездемона

Шулай гына булса иде!

Яго

Шулай,
Ышаныгыз минем сүзләремә.

Быргы тавышы.

Әнә быргы кичке ашка чакыра.
Сезне Венеция кешеләре
Көтә анда. Барыгыз, еламагыз,
Бар да элеккечә әйбәт булыр.

Дездемона белән Эмилия китәләр. Родриго керә.

Яго. Йә, ни бар, Родриго?

Родриго. Миңа калса, син минем белән бик намуссыз кыланасың.

Яго. Нигә алай дисең?

Родриго. Көн саен өр-яңа хәйлә табасың. Миңа калса, син, мине максатыма якынлаштыру урынына, хәтта өметләремнән дә читләштерә генә барасың. Моңа мин артык түзә алмыйм, үземнең ахмаклыгым аркасында моңа кадәр күргән газапларым өчен, белмим, сине гафу итәргәме, әллә юкмы?

Яго. Тыңла әле мине, Родриго.

Родриго. Мин сине бик күп тыңладым инде, Яго, синең сүзең белән эшең арасында бернинди дә бәйләнеш юк.

Яго. Син мине бөтенләй урынсыз гаеплисең.

Родриго. Бик урынлы гаеплим. Мин бөтен байлыгымны тотып бетердем. Дездемонага дип сиңа биргән бриллиантларымның яртысы гына да хәтта монашканы аздырырга җитәр иде. Ә син: «Дездемона аларны алды, һәм тиз көндә кавышу вәгъдә итте», — дип сөйләгән булдың. Ә минем шушы көнгә кадәр ул кавышу дигән нәрсәне күрә алганым юк.

Яго. Яхшы, яхшы, дәвам ит!

Родриго. «Яхшы, яхшы, дәвам ит», имеш! Юк, мин дәвам итә алмыйм, һәм бу яхшы да түгел. Ант итеп әйтәм, син кабахәтләрчә кыланасың. Мин хәзер төшенә башладым, син мине алдап йөртәсең.

Яго. Бик әйбәт!

Родриго. Ә мин әйтәм, бер дә әйбәт түгел! Дездемона белән мин үзем сөйләшәм. Әгәр дә ул минем бриллиантларымны кайтарып бирсә, мин, аның артыннан йөрүемне туктатып, законга каршы эшләрем өчен үкенермен. Әгәр дә бирмәсә, белеп тор, Яго, аның өчен җавапны мин синнән таләп итәрмен.

Яго. Сөйләп беттеңме?

Родриго. Беттем. Һәм эшләргә уйламаган бер генә сүз дә әйтмәдем.

Яго. Менә хәзер мин синдә характер барлыгын күрәм. Һәм синең хактагы фикеремне шушы минуттан башлап үзгәртәм. Бир кулыңны, Родриго. Синең миннән шикләнүең бик урынлы, әлбәттә, ләкин, ант итеп әйтәм, синең өчен мин чын күңелдән тырыштым.

Родриго. Сизелми.

Яго. Дөрес, сизелми. Әнә шуңа күрә синең шикләнүең дә бөтенләй үк нигезсез түгел. Ләкин, Родриго, әгәр дә синдә мин тагын да зуррак итеп күрергә теләгән сыйфатлар: кыюлык, егетлек һәм батырлык чынлап та булса, бүген кичкә үк күрсәт миңа аларны. Шуннан соң инде киләсе төнгә дә Дездемона синеке булмаса, мине хыянәтчегә исәпләп, дөньядан сөрерсең һәм минем өчен күңелең теләгән җәзаны уйлап чыгарырсың.

Родриго. Нинди эш соң ул? Акылга сыярлыкмы? Башкарып чыгу өчен уңайлымы?

Яго. Венециядән Отеллоның урынын Кассио кабул итсен дигән хәбәр алынды.

Родриго. Чынлапмы? Димәк, Отелло белән Дездемона Венециягә кайтып китәчәк?

Яго. О юк! Әгәр Отеллоны юлдан туктатырлык берәр вакыйга килеп тумаса, ул үзенең сөеклесе гүзәл Дездемона белән Мавританиягә китәчәк. Моны булдырмау өчен, Кассионы читкә алып ыргытудан башка чараның булуы да мөмкин түгел.

Родриго. Ягъни ничек инде ул читкә алып ташларга?

Яго. Отелло урынын алырга яраксыз итәргә, ягъни башын сугып ярырга.

Родриго. Һәм бу эшне миннән эшләтергә уйлыймсың?

Яго. Әйе. Әгәр дә үзеңә файда итәргә, дошманыңнан үч алырга теләсәң, син моны эшләргә тиешсең. Ул бүген кичке ашны сөяркәсендә ашый. Мин дә анда булам. Үзенең шундый хөрмәтле урынга билгеләнүен ул белми әле. Әгәр аның өенә кайтуын көтеп торырга теләсәң, — мин моны төнге унике белән бер арасына туры китерергә тырышырмын, — син аны теләсәң нишләтә аласың. Сиңа ярдәм итү өчен, мин шул тирәдә булырмын, аңа безнең икебез белән эш итәргә туры килер. Йә, нигә бу кадәр шаккаттың? Әйдә киттек, юлда мин сиңа аны үтерүнең ни дәрәҗәдә кирәклеген шундый итеп исбат итәрмен ки, бу эшне син үзеңнең бурычың итеп санарсың. Кичке аш вакыты җитте, озакламый караңгы төшәр. Эшкә!

Родриго. Шулай да мин синнән моның өчен тагын да төплерәк дәлилләр теләр идем.

Яго. Теләгең үтәлер.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Замок эчендә бүлмә.
Отелло, Лодовико, Дездемона, Эмилия һәм хезмәтчеләр керәләр.

Лодовико

Зинһар, борчылмагыз, синьор, кирәкми,
Озатмагыз.

Отелло

О, зарар юк. Миңа
Бераз йөреп кайту файда гына.

Лодовико

Хәерле төн, синьора, хушыгыз.
Хөрмәтегез өчен бик зур рәхмәт.

Дездемона

Зарыгып көтеп алган кунак бит сез.

Отелло

Киттек, әфәнделәр. Ә... Дездемона...

Дездемона

Нәрсә, иркәм?

Отелло

Хәзер үк ят. Мин тиз
Кайтырмын. Ә Эмилияне җибәр.
Онытма.

Дездемона

Син теләгәнчә булыр.

Отелло, Лодовико һәм хезмәтчеләр чыгып китәләр.

Эмилия

Йә, ничек? Хәзер ул, миңа калса,
Берникадәр йомшый төшкән кебек.

Дездемона

Озакламам, мин тиз кайтырмын, син
Хәзер үк ят, диде. Сине бүген
Моннан чыгарырга кушты.

Эмилия

Мине?

Дездемона

Әйе. Миңа шулай әмер итте.
Шуның өчен төнге күлмәгемне
Китер дә, бар, сау бул, Эмилия,
Ярсымасын инде, ачуландырмыйк.

Эмилия

Сезнең аны мәңге күрмәвегез
Артыграк булыр иде.

Дездемона

А юк,
Аны мин шулкадәр өзелеп сөям,
Ачуы да аның, ярсуы да
Шундый якын һәм ягымлы миңа.

Эмилия

Теге түшәк япмагызны җәйдем.

Дездемона

Ах, барыбер! Без ниндиен ахмак!

Синнән элек үлә-нитә калсам,
Шул япмамнан миңа кәфен тегәрсең.

Эмилия

Юкны сөйләмәгез.

Дездемона

Әнкәемә
Варвара исемле бер асрау кыз
Хезмәт итеп торды. Ул кемнедер
Сөя иде. Сөяркәсе аны
Ташлап киткән. Мескен ул һәрвакыт
Моңлы «Бөдрә тал»ны җырлый иде.
Бу борынгы зарлы-моңлы җырда
Аның үз хәсрәте яңгырый иде.
Шушы җырны җырлый-җырлый үлде дә.
Менә шул җыр бүген кич буена
Һич башымнан чыкмый. Бичара кыз
Варварадай, башны түбән иеп,
Һаман җырлап утырасым килә.
Тиз бул инде.

Эмилия

Төнге күлмәгеңне
Китеримме?

Дездемона

Юк. Элек чәчемне сүт.
Бу Лодовико сөйкемле егет.

Эмилия

Гаҗәп сылу.

Дездемона

Матур итеп сөйли.

Эмилия. Мин Венециядәге бер хатынны беләм. Шул хатын, аның белән бер үбешү өчен, яланаяклап Палестинага кадәр барыр идем, ди.

Дездемона
*(җырлый)*

Хөрмә агачы төбенә сөялгән!
Җырлагыз бөдрә тал җырын!
Авыр кайгыдан башкае иелгән,
Җырлагыз бөдрә тал җырын.
Моның кабатлый, чылтырый саф чишмә,
Җырлагыз бөдрә тал җырын.
Тама яшьләре салкын таш өстенә...
Ал боларны...
Җырлагыз бөдрә тал җырын...
Тиз бул инде, хәзер кайтып җитәр.

Венок үрерләр миңа тал-тирәктән...
Әрләмәгез, ник ташладың, дип аны...

Юк, монысы җырның ахырында...
Кемдер шакый түгелме?

Эмилия

Юк, бу — җил.

Дездемона

*(җырлый)*

Нигә ташладың, дигәч, ул ни диде?
Җырлагыз яшел тал җырын.
Йөрим-себереләм, син дә бар, йөр, диде!..

Йә, бар. Тыныч йокы. Бүген минем
Әллә нигә күзем кычытып тора,
Еларгадыр.

Эмилия

Юкны сөйләмәгез.

Дездемона

Шулай диләр бит. Әй ирләр, ирләр!
Йә, әйт әле, зинһар, Эмилия,
Үзенең ирен шулай оятсызларча
Алдалаучы битсез хатын-кызлар
Чынлап та бармыни?

Эмилия

О! Булмыйча!
Дөнья тулы.

Дездемона

Йә, әйт: әгәр сиңа
Бар дөньяны бирәм дип әйтсәләр,
Шундый эшкә күңелең барыр идеме?

Эмилия

Синең бармас идемени?

Дездемона

Һич, һич!
Якты кояш нуры шаһит!

Эмилия

Соң бит
Кояш нуры төшеп торган чакта,
Мин дә аңа риза булмас идем.
Ул эш караңгыда ипле була.

Дездемона

Бар дөньяны бирәм дип әйтсәләр,
Шуны эшләр идеңме син?

Эмилия

Дөнья!
Шул кечкенә гөнаһ өчен — дөнья!
Бу бик кыйбат түләү була.

Дездемона

Сөйләмә.
Бу гөнаһны эшли алмас идең.

Эмилия. Ә мин әйтәм, эшләр идем. Ләкин шома итеп, бөтенләй эшләмәгән кебек итеп. Әлбәттә, мин йөзек, күлмәк, итәк яки баш киеме шикелле чүп-чарга гына риза булмас идем. Ләкин бөтен дөньяны бирсәләр! Кем генә үзенең иренә мөгез куюдан тартынып торыр икән, әгәр дә аны шул эш аркылы, әйтик, тәхеткә менгереп булса? Мин батырчылык итәр идем. Ә соңыннан, гөнаһымнан арыну өчен, тәүбә итәр идем.

Дездемона. Юк, бөтен дөньяны бирсәләр дә, мин андый түбәнлеккә бармас идем.

Эмилия. Түбәнлек бит ул дөньяда гына түбәнлек. Хезмәтең бәрабәренә бөтен дөньяны кулыңа аласың икән, синең түбәнлегең үз дөньяң эчендә була. Үз дөньяң эчендәге начарлыкны яхшылыкка әйләндереп җибәрү кыенмыни?

Дездемона

Юк, дөньяда андый хатыннарның
Булуына мин һич ышанмыймын.

Эмилия

Бар, дистәләп. У! Шундый күп алар,
Бергә җыйсаң, бөтен дөнья тулыр.
Хатыннарның болай бозылуына
Һәрвакытта ирләр сәбәпчеләр.
Бурычларын ялкауланып үтәп,
Безгә тиеш булган рәхәтлекне
Башка хатыннарга илтеп бирәләр.
Йә булмаса, тиктомалдан көнләп,
Юкка бимазалыйлар йә кыйныйлар.
Йә, котырып китеп, үчлек белән
Безнең расходыбызны киметәләр.
Ачу дигән нәрсә бездә дә бар,
Юашбыз без, ләкин үч тойгысы
Безнең өчен дә чит тойгы түгел.
Бөтен ирләр белеп торсын, безнең дә
Күрү, сизү, иснәү тойгыбыз бар,
Әче белән төчене без дә аерабыз.
Әйтче, ни өчен соң безне ирләр
Башка хатыннарга алмаштыралар?
Кәефләнү өчен? Әйе, шулай!
Алар канын дәрт кайната? Әлбәттә,
Нәфес колы булып азып китәләр.
Андый дәрт һәм хисләр, комсыз нәфес
Бездә дә бар ласа! Шулай булгач,
Ирләр безнең белән тиешенчә
Эш итсеннәр. Юкса белсен алар,
Андый бозыклыкны без аларның
Үзләреннән үрнәк алып эшлибез!

Дездемона

Хуш! Хуш!.. Тәңрем, бозыклыкны күреп
Үзем бозылырга түгел, ничек итеп
Аннан арынырга өйрәт мине!

Китәләр.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урам.
Яго белән Родриго керәләр.

Яго

Менә монда, колонна артына
Яшеренеп тор. Хәзер килеп җитә ул.
Кылычыңны чыгар — әзер торсын.
Һөҗүм иткән чакта җәһәт маташ,
Бернәрсәдән дә курыкма, мин монда —

Мөмкин кадәр якынрак булырмын.
Хәтереңдә тот: безгә бүген монда
Яки отыш, яки зур һәлакәт.
Шуның өчен, булдыра алган кадәр
Тырыш, батыр бул.

Родриго

Син якынрак тор,
Юкса минем каушап калуым бар.

Яго

Мин беркая китмәм. Батыррак бул.
Чыгар кылычыңны.

Читкә китә.

Родриго

Һичбер эшкә
Тотынырга исәбем юк иде,
Ләкин аның дәлилләре көчле.
Ярый, җирдә берәү кимрәк булыр,
Алга, кылычым, — ул үләргә тиеш!

Колонна артына яшеренә.

Яго

Кабарттым бит ачуын җилкенчәкнең,
Ул ярсыды — үзен-үзе белми.
Әйдә, теләсә генә нәрсә булсын,
Ул Кассионы үтерсә дә, Кассио
Аны үтерсә дә яки алар
Бер-берсен үтерешсәләр дә,
Ничек булса да мин отам монда.
Әгәр исән торып калса Родриго,
Ул Дездемонага бүләккә дип
Миңа биргән барлык алтыннарын
Һәм бриллиантларын таләп итәр.
Юк, юк, моңа юл куярга ярамый.
Әгәр дә Кассио исән калса,
Аның тормышының матурлыгы
Мине шыксыз итә, гарипләтә.
Өстәвенә тагын аңа Отелло
Мин сөйләгәннәрне әйтүе бар.
Ул чагында минем эшем харап!
Юк, юк, бүген ул үләргә тиеш.
Әһә, әнә үзе килә.

Родриго

Бу — ул,
Аның аяк тавышын таныймын мин.
Үл, кабахәт!

Кассиога һөҗүм итә.

Кассио

Әгәр минем
Эчке тимер киемем сез уйлаганча
Начаррак булган булса, әлбәттә,
Бәлки, мин үлгән дә булыр идем.
Хәзер инде синекен сынап карыйк.

Родригоны яралый.

Родриго

Аһ, мин үлдем.

Яго, Кассионың артыннан килеп, аның аягын яралый да чыгып йөгерә.

Кассио

Яраландым мин... Әй,
Ярдәм, ярдәм! Үтереш монда, үтереш!

Отелло керә.

Отелло

Бу Кассио тавышы.
Тугры Яго вәгъдәсендә торган.

Родриго

Нинди кабахәтлек эшләдем мин!

Отелло

Сүзең дөрес.

Кассио

Ярдәм! Хирург! Ут бирегез!

Отелло

Шик юк, бу — ул! О Яго, син батыр,
Саф күңелле егет! Син дустыңның
Мыскылланган саф хисләре өчен
Нинди әйбәт итеп үч алгансың;
Миңа бик зур үрнәк күрсәттең син.
Йә, уйнашчы, сөйгән егетең үлде,
Инде нәүбәт сиңа — хәзер барам.
Инде синең сихри карашларың
Миңа артык тәэсир италмаслар.
Уйнаш белән пычратылган түшәгеңне
Мордар каның белән юам хәзер.

Китә.
Лодовико белән Грациано керәләр.

Кассио

Сакчы да юк, узгынчылар да юк!
Ярдәм, ярдәм! Үтереш монда, үтереш!

Грациано

Берәр бәхетсезлек булса кирәк;
Ишетәсеңме, тавышы үзәк өзгеч.

Кассио

Әй, әй, ярдәм!

Родриго

Аһ, кабахәт адәм!

Лодовико

Чү, ыңгырашты. Әнә тагын берәү.
Төн караңгы, берни күреп булмый.
Берәр төрле хәйлә түгелме бу?
Халык җыйналганчы ашык-пошык
Анда бару акылсызлык булыр.

Родриго

Беркем дә юкмыни? Каным агып бетә...

Яго керә.

Лодовико

Әнә, ишетәсезме? Чү...

Грациано

Күлмәктән,
Кулына факел тоткан берәү килә.

Яго

Кем ул? Үтереш дип кем кычкыра?

Лодовико

Без белмибез.

Яго

Әле кычкырганны
Ишетмәдегезме?

Кассио

Монда, монда!
Ходай өчен ярдәм күрсәтегез.

Яго

Нәрсә булды монда?

Грациано

Миңа калса,
Отеллода хезмәт иткән егет бу.

Лодовико

Чынлап та шул, теге батыр егет.

Яго

Кем ул ярдәм сорый? Кем ыңгыраша?

Кассио

Бу синме, Яго? Аһ, яраландым мин.
Харап булдым. Ярдәм ит, кил, коткар!

Яго

Ах, лейтенант! Нинди кабахәтләр
Эшләде бу эшне?

Кассио

Миңа калса,
Берсе монда — миннән ерак түгел,
Хәрәкәтсез ята.

Яго

У, кабахәт!
*(Лодовико һәм Грацианога.)*
Әй, кем анда, ярдәм итегез миңа!

Родриго

Аһ, аһ! Ярдәм!

Кассио

Менә, менә берсе!

Яго

Ах, кабахәт адәм! У, юлбасар!

Родригоны чәнчә.

Родриго

А, Яго, эт! Ләгънәт төшсен сиңа!

Яго

Караңгыда кеше үтерергә!
Кая калганнары? Бөтен шәһәр
Кабер кебек тынган... Әй, кешеләр!
Сез кем анда? Яхшы кешеләрме,
Әллә усаллармы?

Лодовико

Ничек телисең,
Шулай аңла.

Яго

Синьор, сез — Лодовико?

Лодовико

Әйе, мин, әфәндем.

Яго
Кичерегез.
Монда кабахәтләр тарафыннан
Яраланган Кассио ята.

Грациано

Кем? Кассио?

Яго

Хәлең ничек, туган?

Кассио
Аяк, аяк!
Үткер кылыч сөягемә җитте.

Яго

Аһ, бәдбәхет! Раббым, үзең ярдәм бир!
Әфәнделәр, яктыртыгыз әле...
Тукта, күлмәгемне ертып бәйлим.

Бианка керә.

Бианка

Нәрсә булды монда? Кем кычкырды?

Яго

Кем кычкырды!

Бианка

О Кассио, кадерлем,
Җаным, бәгърем! О Кассио, Кассио, Кассио!

Яго

Кит, себерке! Аһ, кем эше бу? Кассио,
Кемнән булса шикләнмисезме?

Кассио

Юк.

Грациано

Сезне мондый хәлдә очырату
Бик күңелсез. Мин бит әле генә

Сезне эзләргә дип чыккан идем.

Яго

Бирегез чүпрәк, бәйлик. — Менә шулай.
Аһ, носилка булса иде хәзер,
Ипләп кенә алып китәр идек.

Бианка

Аһ!
Һуштан язды! О Кассио, Кассио, Кассио!

Яго

Әфәнделәр, монда, минем уемча,
Бу эшәке кызның да катнашы бар.
Сабыр ит, Кассио. Әй, факел бир,
Карыйкчы, кем ята икән?.. Раббым!
Бу бит минем якын дустым Родриго...
Юк... Ул, ул... Ярабби! Якташ, Родриго!

Грациано

Ничек? Венеция кешесеме?

Яго

Әйе. Сезгә таныш иде мәллә?

Грациано

Таныш кынамы соң!

Яго

Аһ, сезме бу,
Хөрмәтле Грациано? Белмәдем,
Кичерегез, зинһар. Хәер, минем
Сезгә булган илтифатсызлыгым
Канлы бу вакыйга аркасында
Икәнлеге аңлашылса кирәк.

Грациано

Сезне күрүемә бик шатмын мин.

Яго

Йә, Кассио, кәефегез ничек?
Аһ, носилка булса иде менә!

Грациано

Родригомы?

Яго

Әйе, ул, ул, синьор.

Носилка алып керәләр.

Әһә, носилка да булды. Әйбәт.
Әфәнделәр саклык белән генә
Яралыны алып сез китегез.
Ә мин хирург чакырырга барам.
*(Бианкага.)*
Сез, туташкай, кыланмагыз юкка.
*(Кассиога.)*
Әйтче, монда үлеп яткан егет
Минем якын дустым иде. Сез соң
Аның белән нигә ызгыштыгыз?

Кассио

Ызгышмадык. Кемлеген дә белмим.

Яго
*(Бианкага)*

Әһә! Ник бу кадәр төсең китте? —
Алып китегез тизрәк.

Родриго белән Кассионы алып чыгып китәләр.

Әй, синьорлар! —
Әһә, агарындың? Күрәсезме?
Күзләреннән нинди дәһшәт аңкый.
Куркуыңның серен без тиз белербез.
Карагыз, җентекләбрәк карагыз!
Ә җинаять дигән нәрсә телсез дә
Сөйли ала ул.

Эмилия керә.

Эмилия

Ни булды монда?
Ә, Яго.
Әйт, нәрсә булды?

Яго
Родриго
Төнге караңгыда, әллә нинди
Бозык яшьләр белән бергәләшеп,
Кассиога һөҗүм иткән.
Иптәшләре качып өлгергәннәр.
Кассио бик каты яраланган,
Ә Родриго үлеп ята.

Эмилия
Раббым!
О Кассио, мескенкәем!

Яго
Менә ул
Азгынлыкның җимеше... Үтенәм, Эмилия,
Барып бел: Кассио бүген кичке ашка
Кайда барган?
*(Бианкага.)*
Әһә, калтырыйсыз!

Бианка

Кичке ашны миндә ашады ул.
Ләкин хәзер минем калтыравым
Аның өчен түгел.

Яго
Синдәмени?
Алай булса, әйдә минем арттан.

Эмилия

Тфү, себерке!

Бианка

Мин себерке түгел,
Минем биткә пычрак ыргытучы
Синең кебек үк саф хатынмын мин.

Эмилия

Минем кебек дисең? Тфү, әшәке!

Яго

Әфәнделәр, барып белик, Кассионың
Җәрәхәтен бәйләделәр микән?
*(Бианкага.)*
Киттек, туташ, анда баргач, сөйләрсең.
Эмилия, бар, крепостька йөгер,
Монда булган хәлне Отеллога
Һәм Дездемонага сөйлә. Киттек!
О бу төн! Йә мине максатыма
Яки һәлакәткә алып бара!

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Йокы бүлмәсе.
Дездемона түшәктә йоклап ята. Өстәлдә шәм яна.
Отелло керә.

Отелло

Сәбәп монда, сәбәп йөрәгемдә.
Әйтмим аны сезгә, пакь йолдызлар,
Ләкин сәбәбем бар. Мин кан түкмәм,
Кардан да ак, мәрмәр кебек шома
Бу саф тәнне чәнчеп яраларга
Теләмим мин. Ләкин ул үләргә тиеш.
Юкса башкаларны да ул алдар.
Менә шәмне өреп сүндерергә дә
Аннан соң... Ә, шәмне сүндерергә?
Әгәр дә сүндерәм икән сине,
Юлым яктыртучы утлы хадим,
Кирәксәң бит сине мин яңадан
Кабызалам.
*(Дездемонага карап.)*
Синең нурың сүнгәч,
Табигатьнең тиңсез нәфис гөле,
Сине яңадан җанландыра торган
Ялкынны мин таба алырмынмы?
Кызыл гөлне сабагыннан өзгәч,
Аңа яшәү көче бирә алмам,
Сабагында чакта хуш исеннән
Исереп калыймчы.
*(Үбә.)*
О нинди татлы сулыш!
Хаклык үзе сине күргәннән соң
Гадел кылычын сындыргалап ташлар.
Тагын, тагын... Үлгәч тә шундый бул!
Үтергәннән соң, яңадан сөярмен.
Тагын, соңгы тапкыр! Аһ, бу үбү
Нинди татлы, шомлы! Елыймын мин,
Бу күз яше нинди куркынычлы!
Минем кайгым — Тәңре кайгысыдай;
Ул да шулай кайчак иң сөекле
Мәхлугына ләгънәт яудырырга,
Аны җәзаларга мәҗбүр була...
А... Уянды...

Дездемона

Кем бар монда?
Отелло, синме бу?

Отелло

Мин, Дездемона.

Дездемона

Нигә син ятмыйсың, иркәм?

Отелло

Бүген кич
Гыйбадәтең кылдыңмы, Дездемона?

Дездемона

Әйе, кылдым.

Отелло

Хода кичермәгән
Берәр төрле гөнаһ исеңә төшсә,
Тизрәк тәүбә итеп саф күңелдән,
Ярлыкавын сора Хак Тәңредән.

Дездемона

Мәгънәсе ни, иркәм, бу сүзләрнең?

Отелло

Тәүбә ит, дим, ләкин кыскарак тот,
Ә мин монда көтеп, йөреп торам.
Рухың белән әҗәл каршыларга
Тәмам әзер булып бетми торып
Үтерергә теләмим, — юк,
Мин рухыңны синең үтермим.

Дездемона

Аһ... син үлем турысында сөйлисең?

Отелло

Әйе, үлем турысында.

Дездемона

Раббым!
Коткар мине!

Отелло

Амин.

Дездемона

«Амин» дидең, —
Димәк, мине үтермисең син?

Отелло

Һм!

Дездемона

Шулай да мин синнән куркам, Отелло;
Ул коточкыч йөгрек күзләреңнән
Дәһшәт аңкып тора. Гөнаһым юк,
Курку өчен һичбер сәбәп тә юк,
Ләкин куркам, әллә нигә куркам.

Отелло

Гөнаһларың турысында уйла.

Дездемона

Гөнаһым шул — сиңа мәхәббәтем.

Отелло

Әнә шуның өчен бүген үләсең.

Дездемона

Мәхәббәткә каршы — үлем? Бу бит
Табигатьнең канунына сыймый.
Син нинди куркыныч, Отелло! О,
Нигә алай иреннәрең тешлисең?
Әллә нинди ярсу, канлы ярсу
Бөтен тәннәреңне дерелдәтә.
Хәерлегә түгел бу хәл. Шулай да
Мин ышанам әле, мин ышанам,
Бу коточкыч яшен мине сукмас.

Отелло

Җитәр, эндәшмә!

Дездемона

Эндәшмәм. Тик әйт,
Нәрсә булды?

Отелло

Минем иң кадерле,
Теге сиңа биргән яулыгымны
Кассиога бүләк итеп биргәнсең.

Дездемона

Юк, ант итеп әйтәм җаным белән!
Чакырт хәзер, сора!..

Отелло
О сөеклем,
Саклан, ялган ант бирүдән саклан:
Син бит үлем түшәгендә ятасың.

Дездемона

Раббым! Хәзер үтермисеңдер бит?

Отелло
Хәзер,
Шуның өчен гөнаһыңнан тәүбә ит.
Чөнки антлар итә-итә тансаң да,
Карарымны син үзгәртә алмассың,
Карарымнан бәгърем телгәләнсә дә,
Үтәрмен мин аны һәм син үләрсең.

Дездемона

Кызган мине, Раббым!

Отелло

Амин.

Дездемона

Син дә,
Син дә кызган мине. Мин беркайчан
Синең намусыңнан көлгәнем юк.
Җирдә яши торган һәр кешене
Ходай ничек яратырга кушса,
Кассионы фәкать шулай гына
Яраттым мин. Аңа һичбер нәрсә
Бүләк иткәнем юк.

Отелло

Хода шаһит,
Яулыгымны үз күзләрем белән
Мин кулында аның күреп калдым.
О мәкерле хатын, ялганлавың
Йөрәгемне ташка әйләндерә.
Алга куйган изге ниятемне
Син җинаять диеп исәпләргә
Мәҗбүр итәсең. Мин яулыгымны
Кассиода күрдем.

Дездемона

Табып алгандыр.
Минем биргәнем юк! Чакырт хәзер:
Дөресен әйтеп бирсен, намусы булса.

Отелло

Әйтте инде дөресен.

Дездемона

Нәрсә әйтте?

Отелло

Синең белән бергә йоклаганын.

Дездемона

Минем белән йоклаганын?

Отелло

Әйе.

Дездемона

Моны ул кабатлый алмас.

Отелло

Әлбәттә.
Чөнки авызы томаланды инде,
Тугры Яго вәгъдәсендә торды.

Дездемона

Аһ, куркуым юкка түгел икән!
Үлгәнме ул?

Отелло

Әгәр ул явызның
Чәч бөртеге саен җаны булса,
Чәчләренең һәрбер бөртегеннән
Канлы үчемне мин алыр идем.

Дездемона

Аһ! Алданган ул! Мин харап булдым!

Отелло

Аһ, уйнашчы! Аһ, җирәнгеч мәхлук!
Әле минем алда аның өчен
Син еларга батырчылык итәмсең?

Дездемона

Куып чыгар, тик үтермә генә!

Отелло

Үлем уйнашчыга!

Дездемона

Аһ, ичмасам,
Шушы төнне генә яшәп калыйм!

Отелло

Карышасыңмы?

Дездемона

Ярты гына сәгать!

Отелло

Юк, юк, кичектерелми бу карар.

Дездемона

Мин гыйбадәт кылам.

Отелло

Соңга калдың.
*(Буа.)*

Эмилия
*(сәхнә артыннан)*

Синьор! Синьор! Тиз ачыгыз! Тизрәк!

Отелло

Нинди шау-шу анда? — Тере әле, тере!
А, мин кансыз, ләкин күңелемдә
Шәфкать дигән нәрсә дә бар: сине
Озак газапларга теләмим мин.
Менә шулай, шулай!

Эмилия

Синьор! Синьор!

Отелло

Кем бар анда?

Эмилия

Синьор, минем сезгә
Кичектерми әйтә торган сүзем бар.

Отелло

Эмилия? Хәзер ачам. — Үлде. —
Мөгаен, Кассио турысында
Хәбәр итү өчен килгәндер ул.
Шау-шу көчле булды... — Үлде, селкенми,
Кабер кебек тынды. — Кертимме, юкмы?
Әгәр кертсәм, җайсыз булмас микән? —
Чү, селкенде бугай! Юк, юк, хәрәкәтсез.
Соң нишләргә? Монда килеп кергәч,
Хатыным белән сөйләшергә тотыныр...
Хатыным белән! Нинди хатыным белән?
Хатыным юк минем. Нинди авыр!
Күтәргесез авыр, шомлы минут!
Хәзер миңа кояш һәм ай сүнеп,
Кара тапка әйләнерләр кебек.
Бу коточкыч авыр вакыйгадан
Җирнең асты өскә килер төсле...

Эмилия

*(сәхнә артыннан)*

Синьор, синьор, мин үтенәм сездән,
Зинһар, тиз булыгыз.

Отелло

А, онытканмын.
Кер, кер, Эмилия! Тукта, хәзер...
Чыбылдыкны гына тартып куям.

Ишекне ача.
Эмилия керә.

Отелло

Йә, ни бар? Ни өчен килдең монда?

Эмилия

Аһ, генерал, анда кабахәтләрчә
Кеше үтерделәр.

Отелло

Ә? Хәзерме?

Эмилия
Әйе.
Отелло

Моңа ай гаепле. Җиргә
Кирәгеннән артык якынайды,
Әнә шуңа кешеләр котырдылар.

Эмилия

Кассио үтергән. Нindидер бер
Венеция кешесен. Исеме Родриго.

Отелло

Ничек? Родригоны үтергәннәр?
Ә Кассио? Аны дамы үтергәннәр?

Эмилия

Юк, Кассио исән калган.

Отелло

Исән?..
Алай булса, әле үтереш юк,
Канлы үч тойгысы һаман үсә!

Дездемона

Аһ, гаепсез, һич гаепсез үләм!

Эмилия

Кем ыңгыраша?

Отелло

Ә? Ыңгыраша? Кая?

Эмилия

Раббым! Раббым! Бу синьора тавышы.
Кем бар анда? Әй, тиз! Ярдәм, ярдәм!
Аһ, сөекле синьора! Дездемона!
Әйтегезче миңа ни дә булса!

Дездемона

Мин гаепсез үләм.

Эмилия

Кем ул, кем ул
Сезне үтерүче?

Дездемона

Беркем түгел... Үзем...
Хуш! Сөекле ирем Отеллога
Соңгы сәламемне тапшыр. Бәхил бул.

Үлә.

Отелло

Кем үтерде икән?

Эмилия

Аһ, кем белсен!

Отелло

Шулай да, ишеткәнсеңдер, ул бит
Мин үтерде дип әйтмәде.

Эмилия

Әйе,
Аның сүзен дөресләми хәлем юк.

Отелло

Алайса, ул шул ялганы белән
Утлы җәһәннәмгә төшеп китте:
Мин үтердем аны.

Эмилия

Алай булгач, Ул — фәрештә, ә син — Иблис ләгыйнь.

Отелло

Туры юлдан язды, уйнашчыга
Әйләнде ул.

Эмилия

Ялган! Яла ягасың —
Иблис ләгыйнь син!

Отелло

Ул елга кебек
Ышанычсыз иде.

Эмилия

Ә син — ялкын,
Уйлап-нитеп тормыйсың, яндырасың!
Ул фәрештәдәй пакь, тугры иде!

Отелло

Кассио белән бер түшәккә яткан.
Әнә ирең әйтер. Әгәр дә мин
Шундый эшкә һич дәлилсез-нисез
Батырчылык итсәм, ул чак мине
Төпсез җәһәннәмгә ыргытырга
Кирәк булыр иде. Бу эшләрнең
Барысын да синең ирең белә.

Эмилия

Минем ирем?

Отелло

Әйе, синең ирең.

Эмилия

Дездемона үзенең никахына
Хыянәт иткәнлеген беләме ул?

Отелло

Әйе, хатынымның Кассио белән
Бер түшәктә ятканлыгын белә.
Әгәр дә ул тугры булган булса,
Җирен, күген асылташтан корган
Яңа дөнья китереп утыртсыннар, —
Аңа да мин алмаштырмас идем.

Эмилия

Минем ирем?

Отелло

Әйе, моны миңа
Башлап әйтүче ул. Ул намуслы,
Һәр бозыклык-пычраклыкка каршы
Нәфрәт кайный аның саф күңелендә.

Эмилия

Минем ирем?

Отелло

Нәрсә мыгыр-мыгыр
Бер үк сүзне һаман кабатлыйсың?
Әйе, синең ирең.

Эмилия

Аһ, бәхетсез синьора,
Пычрак мәкер синең саф тойгыңнан
Ничек көлгән! Аңа хыянәтче
Исемен таккан кеше минем иремме?

Отелло

Әйе, ул, ул, синең ирең! Син нәрсә,
Миңгерәүләндең мәллә? Минем дустым,
Синең ирең, саф күңелле Яго.

Эмилия

Әгәр дә ул моны әйткән булса,
Пычрак җаны җәһәннәмгә китсен.
Кабахәтләрчә ул ялганлаган!
Бу саф хатын зур ялгышлык белән
Сайлап алган кара, шакшы ирен
Артык кайнар итеп сөя иде.

Отелло
Аһ!
Эмилия

Теләгән кабахәтлегеңне эшлә,
Ләкин моннан зурын эшли алмассың.
Кылган эшең Хода каршысында
Никадәре пычрак, түбән булса,
Үзең дә син хатының каршысында
Шулкадәр үк түбән һәм кабахәт.

Отелло

Җитәр, эндәшмә, телеңне тыйсаң,
Үзең өчен әйбәтрәк булыр.

Эмилия

Мин күтәрә алыр газапларның
Яртысын да эшли алмыйсың син.
Аh, кабахәт! Аh, аңгыра, башсыз,
Шакшы юләр! Әйбәт эш эшләгәнсең!
Мин кылычыңнан синең куркып тормам.
Егерме кат үтер мине, ләкин
Бу эшеңне синең фаш итәм мин.
Әй, әй! Ярдәм, ярдәм! Монда үтереш!
Мавр үзенең хатынын һәлак итте!

Монтано, Грациано, Яго һәм башкалар керәләр.

Монтано

Нинди тавыш монда? Ни бар, синьор?

Эмилия

Ә, Яго, син! Әйбәт егет икәнсең!
Кешеләр монда үз куллары белән
Кылган җинаятьләрендә сине,
Сине гаеплиләр.

Грациано

Ни бар монда?

Эмилия

Син, Яго, ир булсаң әгәр, хәзер
Ерт битлеген шушы кабахәтнең:
Хатынына яла ягу гаебен
Синең өскә ташлый ул. Мин беләм:
Андый эшкә күңелең бармас синең,
Син андый намуссыз кеше түгел.
Әйт тизрәк, йөрәгем чыгып бара.

Яго

Мин уйлаганымны әйттем аңа.
Ә ул аны булуы мөмкин диеп,
Хәтта дөрес диеп тапты.

Эмилия

Синьора
Иренә хыянәт иткән дигән сүзне
Син әйттеңме?

Яго

Әйе, мин. Мин әйттем.

Эмилия

Син алдагансың, алдагансың,
Кабахәтләрчә алдагансың!
Мин ант итеп әйтәм, яла яккансың!
Ирен Кассиога алмаштырган?
Кассиога диденме син?

Яго

Әйе, Кассиога дидем. Ә син телең тый.

Эмилия

Юк, тыялмыйм. Мин сөйләргә тиеш.
Явыз кулдан үтерелгән синьора
Ята монда.

Барысы да

Раббым, коткар!

Эмилия

Бу җинаять —
Синең пычрак гайбәтеңнең җимеше.

Отелло

Сез аптырамагыз, әфәнделәр,
Дөрес бу, чын хаклык аның сүзләрендә.

Грациано

Бу коточкыч хаклык!

Монтано

Коточкыч эш!

Эмилия

Пычрак, пычрак эш! Уйлаган саен
Һаман ачыклана гына бара.
Башыма килгән иде... Аһ, коточкыч!
Хәзер соң шул! Авыр хәсрәтемнән
Үз-үземне үтерергә әзер!
О, пычраклык, нинди әшәкелек!

Яго

Нәрсә булды сиңа? Шаштың мәллә?
Бар, кайт өйгә.

Эмилия

О синьорлар! Зинһар,
Рөхсәт итегез, барысын сөйләп бирәм...
Мин бурычлы аңа буйсынырга,
Ләкин хәзер түгел. Моннан соң, Яго,
Бәлки, мин бөтенләй кайтмам инде...

Отелло
*(түшәккә ташлана)*

О-о-о-о!

Эмилия

Ауна әйдә, үкер,
Тиңсез сафлыкны син һәлак иттең!

Отелло
*(күтәрелеп)*

А юк, аның шакшы күңеле
Бозыклыклар белән тулы иде.
*(Грацианога.)*
Сезне мин аз беләм, абзый, менә
Сезнең кардәшегез ята монда.
Шушы куллар кисте аның сулышын.

Грациано

Аһ, бичара сеңлем! Әтиеңнең
Бу дөньяда булмавына мин шатмын.
Синең никах аның йөрәгенә
Шомлы үлем җәрәхәтен салды
Һәм ул картның гомер җебен кисте.

Әгәр тере булса, моны ишетеп
Акылын җуяр, тәмам шашар иде.
Әче ләгънәтләрен чәчә-чәчә,
Рухын шайтаннардан саклый торган
Пакь фәрештәләрне читкә качырып,
Җанын җәһәннәмгә салыр иде.

Отелло

Аның Кассио белән йөз, мең тапкыр
Пычрак бәйләнештә булганлыгын
Яго белә. Моны Кассио үзе дә
Әйтеп бирде. Аңа ядкарь итеп
Минем тәүге бүләгемне биргән,
Кайнар мәхәббәтем истәлеген
Оялмыйча бүләк иткән аңа.
Ефәк яулык ул, әткәем аны
Әнкәемә бүләк иткән булган.

Эмилия

А-аһ, күк көчләре! Раббым!

Яго

Эндәшмә!

Эмилия

Юк, юк! Барысын да сөйләп бирәм.
Миңа эндәшмәскә? Юлындагы
Барлык киртәләрне җимереп искән
Җил шикелле иркен сөйләрмен мин:
Фәрештәләр, кешеләр, җен-пәриләр,
Бергәләшеп, барсы беравыздан
Әллә ниләр белән янасыннар, —
Мин барыбер сөйләрмен.

Яго

Акылыңа кил!
Бар, кит өйгә.

Эмилия

Юк, китмим.

Яго Эмилиягә ташлана.

Грациано

Чү, оял!
Хатын-кызга кылыч күтәрәсең!

Эмилия

Ах, син, ахмак мавр! Ул яулыкны,
Төшеп калган җирдән табып алып,
Мин иремә илтеп биргән идем.
Чөнки ирем, шуңа исе китеп,
Зинһар, шул яулыкны урлап бир, дип
Ялына, ялына буыныма төште.

Яго

Ух, җирәнгеч мәхлук!

Эмилия

Кассиога
Яулык бирәме соң ул! Юк! Аны,
Табып алып, мин иремә бирдем.

Яго

Алдыйсың, бәдбәхет!

Эмилия

Алдамыйм, юк,
Мин ант итеп әйтәм, әфәнделәр,
Алдамыйм мин!.. Аһ, аңгыра! Хәер,
Мондый ахмак адәм шушы кадәр
Гүзәл хатын кадерен беләмени?

Отелло

Нигә сукмый яшен! Әллә коры
Яшьнәү өчен генә яратылганмы?
Аһ, кабахәт!

Ягога ташлана. Яго, Эмилияне кылычы белән яралап, чыгып йөгерә.

Грациано

Карагыз, чайкала,
Авып бара. Хатынын үтерде ул!

Эмилия

Әйе, әйе... Инде синьорама
Якынрак илтеп салыгызчы.

Грациано

Качты ул, хатынын үтереп качты.

Монтано

Әшәке эт!.. Алчы бу кылычны,
Моны мин маврдан алдым. Хәзер
Чыгып ишек төбенә басыгыз да
Чыгармагыз. Буйсынмый башласа,
Атарсыз. Мин теге эшлексезне,
Явыз юлбасарны куа киттем.

Монтано һәм Грациано китәләр.

Отелло

О, мин нинди хәлгә төштем хәзер...
Нindидер бер малай кулымдагы
Кылычымны тартып алды! Хәер,
Намусың киткәч, кадерең каламыни!
Хәзер минем өчен бар да бетте.

Эмилия

Күгәрченем, синең теге җырың
Менә нәрсә хәбәр иткән икән!
Тыңлый алсаң тыңла: аккош булып,
«Бөдрә тал»ны җырлап үләм хәзер.
*(Җырлый.)*
Җырлагыз «Бөдрә тал» җырын.
Ул саф хатын иде, кансыз мавр!
Сине ничек өзелеп сөя иде...
Аһ, Ходаның мине ярлыкавы да,
Әйткән сүзем кебек, хак булса иде...
Чын хаклыкны сөйләдем мин... Хәзер...
Үләм инде... Үләм...

Үлә.

Отелло

Минем монда
Тагын да бер коралым бар әле,

Испанлылар кылычы, бозлы суда
Чыныктырган кылыч. Ә, менә ул.
Абзый, җибәр әле мине, чыгыйм.

Грациано
*(ишек артыннан)*

Ул ниятең бик кыйбатка төшәр.
Син коралсыз. Шулай булгач, буйсын,
Карышма.

Отелло

Кер алайса, сөйләшик.
Юкса куркып тормам мин, коралсыз да
Ташлана алырмын.

Грациано керә.

Грациано

Йә, нәрсә кирәк?

Отелло

Кара, минем кулда шундый кылыч,
Мондый кылыч белән һичбер солдат
Билен бизи алганы юк әле.
Бар иде вакытлар, шушы кулым
Шул кечкенә генә кылыч белән
Моннан хәтәррәк киртәләрне
Җимереп үтеп, юллар сала идем...
Ләкин... нигә юкка мактанырга?
Кем соң кача алган язмышыннан?
Ул вакытлар үтте, курыкма миннән,
Кылыч тоткан килеш басып торсам да.
Юлым бетте, очына килеп җиттем,
Төшерәм инде хәзер җилкәннәрне...
Чикмә алай артка, курыкма юкка,
Төрт син Отеллоның күкрәгенә
Нечкә камыш белән — үзе чигенер ул...
Кая барсын соң ул хәзер Отелло?
*(Дездемона гәүдәсенә карап.)*
О бичара, син ничек үзгәргәнсең!
Йөзең ап-ак, нәкъ күлмәгең төсле.
Мәхшәр көнне, Хода каршысында
Очырашкач, синең бер карашың
Минем җанны җәһәннәмгә ташлар,
Зобанилар аны тотып алыр...
Салкын, салкын хәзер синең тәнең,
Сафлыгыңдай тыныч!.. А, син явыз!
Зобанилар, тиз килегез монда,
Бу фәрештә тирәсеннән мине
Куып җибәрегез! Өерегез,
Өермәгә урап күтәрегез!
Күкерт ялкынында көйдерегез,
Сыек ут эченә чумдырыгыз.
Аһ, Дездемона, син җансыз, җансыз!
Аһ, Дездемона! О!

Лодовико, Монтано, носилкага салынган Кассио, офицерлар керәләр. Алар арасында куллары артка бәйләнгән Яго.

Лодовико

Кайда ул акылсыз
Һәм бәхетсез кеше?

Отелло

Элегрәк Отелло дип йөртелгән кешеме?
Монда.

Лодовико

Кайда теге юха елан?
Монда китерегез кабахәтне.

Отелло

Карыймын мин аның аякларын,
Ләкин күрә алмыйм тоякларын[1] .
Хәер, ялгандыр ул, әкияттер ул,
Әгәр чыннан да син шайтан булсаң,
Сине мин барыбер үтерә алмам.

Ягоны яралый.

Лодовико

Кылычын ал.

Яго

Яраландым, ләкин
Мин үлмәдем әле.

Отелло

Моңа мин шат,
Синең яшәвеңне телимен мин,
Минем уйлавымча, үлем — бәхет.

Лодовико

Отелло, син, кайчандыр каһарман,
Бүген шушы явыз бәдбәхетнең
Мәкеренә корбан булган Отелло,
Кем дип атыйм сине?

Отелло

Теләсәгез ничек.
Әгәр исем тагу кирәк булса,
Саф намуслы үтерүче дип атагыз.
Чөнки бу һич усаллыктан түгел,
Бәлки, пакь намусым кушканлыктан.

Лодовико

Бу шакшы җан кылган эшләренең
Байтак өлешен әйтеп бирде инде.
Аның белән бергә Кассионы
Үтерергә теләвегез дөресме?

Отелло

Дөрес.

Кассио

Газиз генералым, минем сезгә
Һичбер явызлыгым тигәне юк.

Отелло

Мин ышанам һәм үтенәм сездән,
Зинһар өчен, мине кичерегез.
Барсы өчен шушы ярым шайтан
Җавап бирсен сезгә. Җан-тәнемне
Бу коточкыч ләгънәт бауларына
Нинди ният белән ураганын
Әйтеп бирсен.

Яго

Төпчеп маташмагыз.
Нәрсә беләсез, белегез шуны,
Моннан соң мин авызымны да ачмыйм.

Лодовико

Тәүбә итү өчен дә ачмыйсыңмы?

Грациано

Җәзалагач, телең ачылыр.

Отелло
Әйе!
Һичбер кем ул эшне синдәй булдыралмас.

Лодовико

Инде, синьор, аңлатыйм мин сезгә,
Бу серләрне әле сез белмисез:
Бүген үтерелгән Родригоның
Кесәсеннән ике хат табылды.
Ул хатларның берсе Кассионы
Үтерү турысында; бу бурычны
Родриго үтәргә тиеш булган.

Отелло
О бәдбәхет!

Кассио

Тик мәҗүси генә
Бу кабахәтлекне эшли алыр.

Лодовико

Икенче хат шелтә белән тулы.
Родриго ул хатны бу мәлгуньгә
Җибәрергә әзерләгән булган,
Ләкин Яго, Родригога барып,
Аның күңелен тапкан булса кирәк.

Отелло

Кассио, әйт әле: хатынымның
Кулъяулыгы сиңа кайдан килде?

Кассио

Аны мин бүлмәмнән табып алдым,
Ә Яго ул кулъяулыкны анда
Явыз бер уй белән ташлаганын,
Һәм ул уе барып чыкканлыгын
Менә әле генә үзе әйтте.

Отелло

Аһ! Мин ахмак, ахмак, ахмак!

Кассио

Шул ук хатта Родриго Ягоны
Үзен каравылда минем белән
Ызгышырга котыртуы өчен
(Мине урынымнан, дәрәҗәмнән
Мәхрүм иткән әлеге җәнҗал өчен)
Әче итеп әрли. Һәм ахырында
Без үлгәнгә исәпләгән Родриго,
Һушына килеп, бүген минем белән
Сугышырга котыртучы кеше
Шул ук Яго икәнлеген әйтте,
Аның үзен дә Яго үтергән.

Лодовико

Отелло, сез хәзер моннан чыгып,
Безнең арттан иярергә тиешсез.
Сездән власть алына, урыныгызга
Кипр утравының башы итеп
Кассио билгеләнә — әмер шулай.
Ә инде бу кабахәткә килсәк,
Мәрхәмәтсез акыл уйлап тапкан
Нинди генә каты җәзалар бар —
Барысын да, барысын да татыр ул.
Сезнең кылган җинаятегезне
Без сенатка хәбәр иткәнче, сез
Бездә әсир булып каласыз...
Йә, алып барыгыз минем арттан.

Отелло

Туктагыз! Бер-ике генә сүзем бар.
Илгә мин күп кенә хезмәт иттем,
Моны һәркем белә... Ләкин хәзер
Минем сүзем ул турыда түгел.
Сездән фәкать шуны гына сорыйм:
Бу бәхетсезлекләр турысында
Сез сенатка язган чагыгызда,
Мин асылда нинди кеше булсам,
Шундый итеп күрсәтегез мине.
Кылган гаебемне киметмәгез,
Шул ук вакыт аны арттырмагыз да.
Сез языгыз: Отелло, диегез,
Артык көчле итеп, җаны-тәне белән,
Хәтта акылыннан шашып сөйде.
Табигате белән көнче түгел,
Ләкин бер көнләшсә, көнчелекнең
Иген-чиген белми иде, диегез.
Илендәге бөтен байлыгыннан
Мең кат кыйммәт энҗе кулына төшкәч,
Хакын белми суга атып бәргән
Ахмак һиндлы төсле торып калдым;
Мәңге яшь чыкмаган күзләремнән,
Гарәбстан сәхраларындагы
Агачлардан сыгылып чыга торган
Бәлзәм кебек кайнар яшьләр ага,
Моны да языгыз, һәм ахырында
Тагын шуны өстәгез: кайчандыр
Хәләп шәһәрендә чалма кигән
Усал бер төрекнең ярсый-ярсый
Венеция кешесен кыйнаганын
Һәм сенатны хурлаганын күргәч,
Сөннәтләнгән этне, кабахәтне,
Бугазыннан эләктереп алдым да
Суйдым үзен — менә шулай итеп...

Суела.

Лодовико

Канлы эшнең канлы нәтиҗәсе.

Грациано

Монда хәзер сүзнең файдасы юк.

Отелло
*(Дездемона гәүдәсе янына егыла)*

Үбеп үтердем мин, үбеп үлим дә.

Үлә.

Кассио

Менә шуннан курыккан идем дә мин,
Ул бит бөек рухлы кеше иде,
Ләкин коралсыз дип белгән идем.

Лодовико

Спарта эте, син ачлыктан,
Үләт зәхмәтеннән, океаннан
Дәһшәтлерәк! Кара бу түшәккә,
Күр коточкыч эшләреңнең җимешен!
Аһ, бу күренеш — агу, карап булмый;
Яп пәрдәне. Сез, Грациано, мавrга
Варис булганлыктан, монда калып,
Аның милкен кабул итәрсез.
Сез, Кассио — илнең хөкемдары,
Бу явызны хөкем итү бурычы
Сезнең өскә төшә; көнен-вакытын,
Урынын билгеләгез; һәм җәзаның
Мөмкин кадәр катырагын сайлагыз!
Ә мин кайтып китәм туган илгә,
Бу аяныч, авыр вакыйганы
Ил хакимнәренә белдерергә.

Китәләр.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Венеция. Урам. Саланио, Саларино  һәм Антонио керәләр.

Антонио

Белмим, нигә бу кадәре эчем поша.
Моңа сез дә борчыласыз, күреп торам.
Нинди хис бу? Кайдан килде? Ни сәбәптән?
Һич кенә дә аңлый алмыйм. Шуңадырмы
Үз-үземне белмим, әллә нишләдем мин.

Саларино

Чөнки сезнең күңелегез океанда,
Җилкәннәрен киереп йөзгән корабларда.
Ул кораблар, океаннарның банкиры кук,
Вак сәүдәгәр кешеләргә илтифатсыз,
Һаман алга йөзә киереп җилкәннәрен.

Саланио

Әгәр дә мин бар малымны корабларга
Төяп шулай тәвәккәлләп озаткан булсам,
Уем-күңелем фәкать шунда булыр иде.
Минут саен үлән йолкып, җилнең кайдан
Искәнлеген гел тикшереп торыр идем.
Малым һәлак булыр диеп хәвефләнеп,
Ихтыярсыз хәсрәткә чумар идем.

Саларино

Кайнар ашны өреп-өреп суытканда,
Тәлинкәдә дулкын күреп, киң океанда
Давыл купкандыр дип куркып тетрәр идем.
Ком сәгатен күргән чакта, корабымның
Комга утырып кыйшаюын, мачтасының,
Суга иелеп, үзенең каберен үпкәнлеген
Күз алдыма китереп котым алыныр иде.
Чиркәүнең таш стенасын күргән чакта,
Таш кыялар килер иде күз алдыма!
Корабымның ташка бәрелеп ватылуын,
Кофеларым, борычларым чәчелүен,
Ефәгемнең дулкыннарга уралуын —
Бар малымның суга батып югалуын
Уйлый-уйлый тәмам шашмас идемме мин?
Сөйләмәгез, Антонио, күреп торам:
Малларыңны уйлап шулай борчыласың.

Антонио

Ышаныгыз, юк, дим. Мин бит малларымны
Бер корабка төяп, бер тарафка гына
Озатмадым. Аннан сәүдә әйләнеше
Бу елгы ел белән генә чикләнми бит.
Ышаныгыз, малым өчен борчылмыйм мин.

Саларино

Алай булса, гыйшкың төшкән берәрсенә.

Антонио
Юк ла!..

Саларино

Юкмы? Беркемне сөймисең дәме?
Алай булгач, кәефең юкка күңелсез син.
Болай булса, «Кайгым юкка күңелем шат» дип
Көлүең дә мөмкин икән әле синең!
Икейөзле Янус белән ант итәм мин,
Табигатьтә гаҗәп кызык кешеләр була;
Кайберләре, сорнай уйнаганны ишетеп,
Хихылдаучы тутый коштай, бер дә юктан
Шырык-шырык көлеп тора һич туктаусыз;
Кайберләре, киресенчә, һаман чытык,
Нестор үзе шаркылдарлык мәзәккә дә
Исе китми — елмаеп та карамый ул.

Бассанио, Грациано һәм Лоренцо керәләр.

Саланио

Менә затлы кардәшегез Бассанио,
Лоренцо һәм Грациано монда килә.
Сау бул. Алар килгәч, кәефең күтәрелер.

Саларино

Күңлең ачыйм дип яныңда калмакчы идем,
Ләкин күрәм, кадерлерәк кешеләр килә.

Антонио

Минем өчен барыгыз да кадерле сез.
Күреп торам: эшегез бар; әнә шуңа,
Җае чыккач, китеп калыйм дисез инде.

Саларино

Сәлам сезгә, синьорлар!

Бассанио

Сәлам, дуслар!
Кайчан күңел ачабыз соң бергәләшеп?
Кайчан? Никтер күзгә-башка күренмисез.

Саларино

Буш вакытны бүлешергә без әзербез.

Саларино белән Саланио китәләр.

Лоренцо
*(Бассаниога)*

Синьор, Антониону очраттыгыз.
Шулай булгач, без китәбез. Сөйләшегез.
Ләкин төшке ашка бергә җыйналабыз.
Онытмагыз.

Бассанио

Мин барырмын.

Грациано

Ни өчендер
Кәефегез юк сезнең, синьор Антонио.
Шулкадәре бирелеп дөнья куасызмы?
Артык тырышып тапкан маллар югала, ди.
Шулкадәре үзгәргәнсез!

Антонио

Дөнья бит ул
Сәхнә кебек, Грациано.
Анда һәркем үз ролендә. Минем ролем
Хәсрәтле шул.

Грациано

Мин мәзәкче булыр идем!
Күп көлүдән җыерчыклар бассын битне.
Кайгы йотып бәгърем бозга әйләнгәнче,
Аракыдан бавырым көйсен — анысы шәбрәк.
Тамырларда яшь кан уйнап торган чакта
Нигә картаерга, ташка әйләнергә?
Аягүрә йокла! Юкка мыгырданып
Сарыга сабыш, имеш! Тыңла әле, Антонио,
Яратам мин сине, ратканга әйтәм:
Шундый юньсез кешеләр бар — йөзләре нәкъ
Бака үләне каплаган су шикелле
Хәрәкәтсез. Ай-һай затлы, төпле кеше,
Дип әйтсеннәр өчен шулай кукраялар.
Эх, Антонио дустым! Ә бит шундыйларны
Дәшми-тынмый утырганы өчен генә
Бик зур акыл иясе дер дип уйлыйлар.
Әгәр сүзгә керешеп китсә, ташка үлчим,
Лыгырдап җыен тузга язмаганны,
Сине эчтән сүгенергә мәҗбүр итә.
Ярый, җитте, калып торсын бу әңгәмә.
Зинһар, дустым, хәсрәт кармагыңны салып,
Шул мәсхәрә балыкны каптырма инде!..
Киттек, Лоренцо. Хуш, әлегә сау булып тор!
Вәгаземне мин аштан соң тәмамлармын.

Лоренцо

Төшке ашка кадәр сезне калдырабыз...
Мин дә дәшмим, «акыллы баш» булам хәзер —
Грациано сүз әйтергә ирек бирми.

Грациано

Әйе,
Минем белән бер-ике ел бергә торсаң,
Үз тавышыңны бөтенләйгә онытырсың.

Антонио

Ә мин, синең лыгырдауны тыңлый-тыңлый,
Үзем дә лыгырдыкка әйләнермен.

Грациано

Бик шәп булыр. Дәшми тору эшмени ул!
Какларга дип элгән сыер теле белән
Оялчан кызга гына килешә ул.

Грациано белән Лоренцо китәләр.

Антонио

Бу сүзләрнең мәгънәсе ни?

Бассанио. Грациано кебек лыгырдыкны бөтен Венецияне бетереп эзләсәң дә табалмассың. Аның сүзләренең мәгънәсе ике тубал кибәк эченә буталган ике бөртек бодай кебек. Эзли-эзли күзең тона, тапкач, нигә шундый чүпне эзләп вакыт әрәм иттем дип үкенәсең.

Антонио

Әйе, бәлки, шулайдыр да... Йә, әйт инде,
Нинди кызга табынырга барасың син?
Бүген әйтәм, дигән идең.

Бассанио

Антонио,
Кесәмдәге байлыгымны санамыйча,
Купшыланып яшәвемне һәм шуңарга
Эштән чыгып бөлүемне син беләсең.
Купшы тормыш бетте дип мин һич пошынмыйм.
Күңелемне борчыган уй тик бер генә:
Хисапсыз күп типтерүләр аркасында
Иңнәремә кунаклаган бурычлардан
Ничек итеп намусымны тапламыйча
Котылырга?
Антонио,
Барыннан да күбрәк сиңа бурычлы мин.
Иң күп акча бирүче дустым ул син.
Шул дуслыкка таянып мин, хәзер сиңа
Күңлемдә саклап йөргән планымны —
Бурычлардан котылу юлын сөйләп бирәм.

Антонио

Барсын да сөйлә, дустым Бассанио,
Күплеңдәге планнарың үзең кебек
Саф булсалар,
Янчыгым да
Һәм үзем дә хезмәтеңә әзер, дустым.

Бассанио

Шәкерт чакта аткан угым юкка чыкса,
Шул тарафка тагын бер ук ата идем,
Ә соңыннан икесен дә таба идем.
Сабыйлыктан үрнәк алдым һәм шуңарга
Планым да сабыйларча күренер, бәлки.
Сиңа минем бурычым күп. Биргән акчаң
Мин исрафчы кулына кереп юкка чыкты.

Синең өчен югалды ул, аткан уктай.
Тәвәккәлләп тагын бер ук атсаң әгәр,
Бәлки, барып икесен дә табар идем.
Булмый икән, икенчесен кайтарырмын,
Беренчесе миндә бурыч булып калыр.

Антонио

Мине яхшы беләсең син. Шулай булгач,
Нигә читләп күңелемә юл эзлисең?
Мине борчый дуслыгыма шик тотуың,
Мине бөлдерүең мең кат җиңелрәк.
Әйт, нишләргә? Кулларымнан килгән эшнең
Барын да мин эшлим, дустым, синең өчен.
Йә, әйтсәнә!

Бассанио

Бельмонтта шундый кыз бар:
Бик зур мирас калган аңа атасыннан.
Үзе матур, күңле дә саф, бервакытны
Сирпеп карап сәлам күндерде ул миңа.
Исеме — Порция. Брут хатыныннан,
Данлы Катон кызыннан ул һич ким түгел.
Аның хакын бөтен дөнья халкы белә,
Дүрт яктан да, кызның кулын сорарга дип,
Төрле илләрдән яучылар явып тора.
Гаҗәеп кыз! Чәче кояш нуры төсле,
Әкияттәге алтын сарык йоны кебек
Җем-җем итә.
Бельмонт хәзер Колхидага әверелде,
Бер генә Язон килми хәзер анда.
Аһ, әгәр дә мөмкин булса, Антонио,
Мин дә алар белән ярышып карар идем.
Җиңеп өстен чыгарыма ышанам мин.

Антонио

Син беләсең, бар байлыгым диңгездә бит.
Акчам да юк һәм сатарлык товар да юк...
Бар син, ычкын: Венеция шәһәреннән
Ышанып бурыч бирердәй кешене тап.
Сине Порцияңә шәпләп озатыр өчен
Җәһәннәмнән булса да табып бирәм...
Син дә, мин дә — икәүләшеп эзлик әйдә.
Монда минем абруем зур, шуңа күрә
Мин шикләнмим, табабыз без ул акчаны.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бельмонт. Порция йортында бер бүлмә. Порция белән Нерисса керәләр.

Порция. Дөресен әйтәм, Нерисса, бу зур дөнья мин кечкенә кешене тәмам алҗытты.

Нерисса. Бәхетегез урынына бәхетсезлек килсә дә шулай булыр иде, кадерле синьорам. Чамасыз күп ашаган кеше дә ач кеше кебек үк газаплана ич. Шуңа күрә бәхетнең үлчәүлерәк булганы яхшы. Кирәгеннән артып китсә, чәчне агарта ул, таманрак булса, гомерне озайта.

Порция. Үгетең матур, матур итеп әйтә дә белдең.

Нерисса. Ул тормышка ашса, тагы да шәбрәк булыр иде.

Порция. Һәр белгәнеңне тормышта җиңел кулланып булса, фәкыйрь йортлар патша сараена әйләнер иде. Үз кагыйдәсе буенча яши алучы — җирдә иң бәхетле кеше. Менә мин егерме кешегә бер дигән кагыйдәләр өйрәтә алсам да, үзем шул егерменең берсе булсам, үз кагыйдәм буенча барыбер яши алмас идем. Сабыр акыл күңелгә законнар билгели, ә житез күңел ул законнарны сикереп үтә. Яшьлек — дуамал куян бит ул, акыл куйган киртәләрдән сикереп чыга. Ләкин бу сүзләр миңа кияү сайларга яр-

дәм итә алмыйлар... Әй, бичара! «Сайларга» дигән булам бит әле! Күңелем теләгәнне сайлый алмыйм, теләмәгәнне кире кага алмыйм. Мәрхүм әткәй әмеренә генә буйсына минем ихтыярым. Рәхимсезлек түгелме бу, Нерисса? Сайларга да, кире кагарга да хакың булмасын, имеш!

Нерисса. Әтиегез яхшы кеше иде. Андый саф күңелле кешегә үлем түшәгендә изге уйлар килә. Шуңа күрә аның күңеленә килгән уй сезгә бәхет китерер. Сезгә кияү булачак кеше әтиегез калдырган өч тартманың берсен сайларга тиеш: алтынынмы, көмешенме, әллә кургаштан ясалганынмы? Ышаныгыз, сезне чын күңелдән яраткан егет, һичшиксез, әтиегез уйлаган тартманың кирәклесен сайлап алыр да сезне кәләш итәр. Әйтегез әле, бүген килгән егетләр арасында күңелегезгә ошаганы бармы?

Порция. Зинһар, исемнәре белән әйт. Һәркайсына карата үз фикеремне белдерермен. Ошау-ошамавын үзең шуннан аңларсың.

Нерисса. Беренчесе Неаполь патшасының улы.

Порция. Уф, ат җене кагылган җан бит ул. Һаман аты турында сөйли. Әйтүенә караганда, аның төп сәләте — ат дагалау! Сөекле әнкәсе берәр тимерче белән чуалгандыр, мөгаен.

Нерисса. Пфальцграф турында ни әйтәсез?

Порция. Анысы һаман каш җыеруын гына белә. Янәсе: «Миңа чыкмыйсыз икән — ихтыярыгыз». Иң кызыклы нәрсәне дә елмаймыйча тыңлый. Яшь чагында шундый чытык булгач, картайгач, елак философка әйләнер ул. Мондыйларга чыкканчы, шыр ялангач скелетка чыгуың артык. Коткара күр, Раббым, икесеннән дә.

Нерисса Француз алпавыты Ле-Боне әфәнде турында ни әйтәсез?

Порция. Ходай Тәгалә ир итеп яраткач, ир булсын иде инде ул. Кешедән көлү гөнаһ икәнен дә беләм. Ләкин бу кеше?! Ташка үлчим! Имеш, аның аты Неаполь кешесенекеннән шәбрәк. Каш җыеруга килгәндә, Пфальцграфтан да уздырып җибәрә. Шундый көнче, үз күләгәсенә үзе һөҗүм итәргә тора. Әгәр дә ул миңа нәфрәт күзе белән карaса, мин гафу итәр идем шикелле. Чөнки ул мине шашып сөйсә дә, минем күңелем аңа барыбер ятмас иде.

Нерисса. Яшь инглиз бароны Фоконбридж әфәндегә карата ни әйтәсез?

Порция. Беләсең ич, аның үзе хакында да, сүзе хакында да берни дә әйтә алмыйм. Чөнки без берберебезне аңламыйбыз. Латинча сөйләшми ул, французча белми, итальянча аңламый. Ә мин инглиз теленнән бөтенләй мәхрүм. Кыяфәте белән менә дигән егет. Ләкин андый телсез таш сын белән кем генә сөйләшә алыр икән? Кигән киемнәре дә әллә нинди: миңа калса, ул камзулын Италиядән алган, чамасыз киң ыштанын — Франциядән, эшләпәсен — Германиядән, кыланышларын бөтен җир йөзеннән җыйган.

Нерисса. Аның күршесе Шотландия лорды турында ни әйтәсез?

Порция. Күңелендә күршелек хисе гаҗәеп көчле: инглиздән яңак төбенә алган бурычны җае чыгу белән мул итеп түләргә ант иткән. Француз аңа ярдәм күрсәтәчәк, имеш.

Нерисса. Саксония герцогы кардәше — яшь немецка ничек карыйсыз?

Порция. Иртән, аек чагында, җирәнгеч була, көндез, исергәч, тагын да әшәкеләнә. Һәйбәт минутларында кешедән түбән, әшәкеләнгәч, хайваннан чак кына өстен була. Нинди генә хәлгә калсам да, аннан котылырга тырышырмын.

Нерисса. Әгәр дә ул тартманы дөрес сайласа? Сез бит аның белән никахланырга тиеш буласыз. Әтиегез боерыгыннан баш тартмыйсыздыр бит?

Порция. Ул бәладән мине коткарыр өчен, зинһар, бер буш тартма кертеп, өстенә бер стакан аракы куй. Эчендә Иблис утырса да, аракысына кызыгып, мөгаен, шул тартманы сайлар ул. Әллә ниләр эшләрмен, Нерисса, ләкин андый кешегә чыкмам.

Нерисса. Карыкмагыз, синьора. Бу егетләрнең берсе дә сезгә өйләнмәс. Миңа әйттеләр инде: тартмалар сайламыйча гына килешеп булмаса, алар сезне артык борчымаска, өйләренә кайтып китәргә карар кылганнар.

Порция. Юк, Нерисса, әти васыяте буенча кияүгә чыга алмасам, Сивилла яшенә җитсәм дә, барыбер Дианадай кыз булып калачакмын. Шулай да бу егетләрнең китүенә мин бик шат. Бик әйбәт иткәннәр. Юлларына ак җәймә!

Нерисса. Хәтерлисезме, синьора, әтиегез исән чакта Венециядән бер яшь егет килгән иде. Үзе укымышлы, үзе офицер, маркиз Монферра белән иде ул.

Порция. Әйе, әйе. Бассанио. Исеме шулай иде бугай.

Нерисса. Шулай, синьора. Мин күргән егетләр арасында иң әйбәте, сезгә иң лаеклысы әнә шул иде.

Порция. Мин аны яхшы хәтерлим. Синең мактавыңа ул чыннан да лаеклы.

Хезмәтче керә.

Ни булды? Ни хәбәр бар?

Хезмәтче. Анда чит илләрдән килгән дүрт егет сезне эзләп йөриләр, синьора. Саубуллашырга телиләр. Өстәвенә бишенче егеттән чапкын килеп төште. Марокко патшасы улыннан: «Әфәндем кичкә килеп җитә», — ди.

Порция. Аһ, бу бишенче егетне күрү дүртесе белән саубуллашу шикелле хозур булса, аның килүенә ихлас күңелдән шат мин. Киттек, Нерисса, син әйдә алдан бар. Берсен озатып өлгермисең, икенчесе шакый капканы!

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Венеция. Мәйдан.
Бассанио һәм Шейлок керәләр.

Шейлок. Өч мең алтын дисезме? Яхшы.

Бассанио. Әйе, синьор. Өч айлык срок белән.

Шейлок. Өч айлык срок белән? Яхшы.

Бассанио. Кабатлап әйтәм: түләүне Антонио үз өстенә ала.

Шейлок. Вексельне Антонио бирә? Яхшы.

Бассанио. Миңа ярдәм итә аласызмы? Бурычка бирәсезме? Җавабыгызны ишетергә мөмкинме?

Шейлок. Өч мең алтын, өч айлык срок белән, Антонио векселенә ышаныпмы?

Бассанио. Җавабыгыз?

Шейлок. Антонио — әйбәт кеше.

Бассанио. Аламалыгын ишеткәнегез юктыр, әлбәттә.

Шейлок. А, юк, юк, юк! Минем «әйбәт кеше» дигәнем «байлыгы бар» дигән мәгънәне аңлата. Шулай да аның байлыгына ышанып булмый. Бер корабы Триполи ягына китеп бара, икенчесе — Һиндстанга. Риальтода яңа гына ишетеп калдым әле: өченче корабы Мексикага юнәлгән, дүртенчесе Англиягә китеп бара. Калган кораблары бөтен дөньяга сибелгән. Кораблар бит алар — такта гына. Матрослары — кешеләр генә! Дөньяда җир күселәре дә, су күселәре дә бар, караклар да җитәрлек. Җирдә дә бар алар, суда да бар — пиратларны әйтәм. Шуның өстенә төрле куркынычлар — афәтләр, җил-давыллар, таш кыялар очрый. Ләкин шуңа карамастан ул хәлле кеше... Өч мең алтын... Миңа калса, аның векселенә ышанырга була шикелле.

Бассанио. Әлбәттә, була.

Шейлок. Ышану өчен уйларга кирәк әле. Антонио белән сөйләшергә мөмкинме соң?

Бассанио. Бәлки, безгә ашка килерсез?

Шейлок. Ашка? Дуңгыз исе иснәргә? Эченә җеннәр оялаган хайван итен ашарга? Мин сезгә мал сатам, үзегездән сатып алам, кирәк чакта сөйләшәм, сез йөргән юлдан йөрим. Әмма ләкин сезнең белән бер табында ашамыйм, эчмим, сезнең белән гыйбадәт кылмыйм. Риальтода нинди яңалыклар бар? Кем килә бу?

Антонио керә.

Бассанио

Әнә синьор Антонио үзе килә.

Шейлок
*(үзалдына)*

Күр син әнә, чын исрафчы кебек купшы.
Җенем сөйми христиан булганы өчен,
Аннан бигрәк, процентсыз акча өләшеп,
Безгә килер табышларны киметүе өчен.
Ух! Әгәр дә кулларыма килеп эләксә,
Борынгыдан килгән үчне алыр идем.
Безнең изге халыкны ул дошман күрә.
Сәүдәгәрләр алдында мине хурлый,
Кәсебемне минем, хәләл табышымны
Хәрам ди ул. Ростовщиклык ди, мыскыллый.
Шушы хурлауларын гафу итсәм әгәр,
Бөтен нәсел-нәсәбемә нәләт яусын!

Бассанио

Йә, ни дисез, Шейлок?

Шейлок

Шуны уйлап торам,
Кулымда, дим, акчам күпме икән.

Исәбемдә ялгышмасам, хәзер генә
Өч мең алтын чыгарып бирә алмам.
Хәер, миңа милләттәшем, бай яһүд карт
Тубал дустым биреп торыр. Чү, туктагыз,
Ничә айлык срок белән?
*(Антониога.)*
Сәлам, синьор,
Әле генә сезне сөйләп тора идек.

Антонио

Мин бурычка акча бирсәм, процент алмыйм,
Үзем алганда да процент түләмим.
Җан дустыма ярдәмләшү ниятеннән
Ул тәртипне бүген бозам.
*(Бассаниога.)*
Күпме акча кирәклеген беләме ул?

Шейлок

Әйе, беләм, өч мең алтын.

Антонио

Срок — өч ай.

Шейлок

Аһ, анысын онытканмын. Әйе, шулай,
Срок өч ай, дидегез сез. Вексель сездән.
Уйлап карыйк. Чү, туктагыз! Процентны
Алмыйм да, түләмим дә, дидегез бугай?

Антонио

Беркайчан да түләмәдем, алмадым да.

Шейлок

Изге Якуб әнисенең ярдәмендә
Лаванга көтүче булып кергәч...
Ибраһимнан соң өченче пәйгамбәр ул...

Антонио

Ник бутыйсыз монда Якуб пәйгамбәрне?
Әллә ул да процент белән эш йөрткәнме?

Шейлок
Юк,
Процент түгел... Процент дип булмый аны...
Беләсезме нишләгән ул? Лаван белән
Сөйләшкәндә, шундый бер шарт куйган Якуб:
«Туачак бәрәннәрнең чуарларын
Хезмәт хакы итеп үземә алам», — дигән.
Көз көне дәрт кузгалып, сарыкларда
Тәкәләр белән кушылыр вакыт җиткәч,
Бу хәйләкәр, таяклар кисеп алып,
Кайрыларын юынгалап чуарлаган.
Тәкә белән кушылган һәр сарыкның
Күз алдына чуар таяк китереп салган.
Шулай итеп, көтүдәге сарыкларның
Барысының да бәрәннәре чуар булган,
Һәм барысы да Якубка эләккән алар.
Менә сиңа баю юлы — изге юл ул.
Урламыйча килә торган һәрбер табыш
Хәләл була. Пәйгамбәрдән калган йола!

Антонио

Якубка сукыр бәхет ярдәм иткән,
Аның ихтыярындагы эш түгел бу,
Тәкъдир эше, барысы да Хак Тәңредән.
Шуны сөйләп процентны яклыйсыңмы?
Акчаларың сарык белән тәкәмени?

Шейлок

Белмим. Ләкин алар миндә бик тиз үрчи,
Тагын шунысын әйтим, синьор...

Антонио

Бассанио, күр:
Иблис тә, үзенең эшен аклар өчен,
Китаплардан изге язу эзләп таба.
Язуларга таянучы бозык күңел —
Сөйкемле, көләч йөзле явыз җәллад
Яки эче чергән җиләк-җимеш бит ул.
Аһ, бу ялган! Тышкы яктан нинди матур!

Шейлок

Өч мең алтын! Зур акча ул... Өч айгамы?..
Еллык проценты күпме соң?

Антонио

Ничек, Шейлок,
Шулай итеп бирергә булдыңмы?

Шейлок

Синьор Антонио, күп тапкыр Риальтода
Үз алтыным, үз процентым өчен мине
Эткә тиңләп хурладыгыз. Мин күтәрдем,
Җилкәләрем җыерып кына җавап бирдем —
Безнең халык шундый сабыр, чыдам бит ул.
Кабахәт дип, котырган дип үкердегез,
Минем яһүд җиләнемә төкердегез.
Ни өчен бит!
Үз малымнан үзем файдаланган өчен.
Инде күрәм, хәзер сезгә кирәгем бар.
Ни хәл итмәк кирәк? Миңа килдегез дә:
«Безгә акча кирәк иде, Шейлок», — дисез.
Сез бит бу! Сез! Минем биткә төкерүче,
Өегезнең болдырыннан карт Шейлокны
Эт урынына типкәләп төшерүче!
Сезгә акча кирәк хәзер! Мин ни диим?
«Эттә нинди акча булсын» дип әйтимме?
«Кайдан алып бирсен өч мең алтынны ул»
Дииммени? Әллә башны түбән иеп,
Кол шикелле дер-дер тетрәп каршыгызда,
Күңлегезне табу өчен, куштанланып:
«Синьоркаем, чәршәмбе көн рәхим итеп
Минем битемә төкердегез. Фәлән көнне
Болдырдан типкәләп төшердегез,
Аннан эт дип хурладыгыз. Шуның өчен
Менә акча бирәм сезгә» дииммени?

Антонио

Мин хәзер дә сине эт дип атар идем,
Битеңә төкереп, типкәләп ташлар идем.
Тик мин әйтәм: әгәр акча бирәм дисәң,
Дустыма дип бирмә. Монда нинди дуслык?
Акчаны син дошманыма бирәм дип бир.

Әгәр бөлә-нитә калсам, рәхәтләнеп
Түләтерсең.

Шейлок

Кара ничек кыздыгыз сез!
Сезгә дус булырга телим, үз булырга,
Сездән күргән җәберләрне онытырга!
Шуның өчен ярдәм итмәк булам сезгә,
Процент өчен ярты тиен дә түләтмичә.
Ә сез мине тыңларга да теләмисез.
Бу тәкъдимне явызлык дип буламы соң?

Бассанио

Киресенчә, бу изгелек булыр иде.

Шейлок

Менә шушы изгелекне күрсәтим дим.
Бергәләшеп нотариуска барыйк хәзер,
Шунда вексель язарсыз һәм мәзәк өчен
Шундый шарт куярбыз язып: әгәр дә сез
Вексельдә күрсәтелгән бурычыгызны
Фәлән көнне миңа түли алмасагыз,
Тәнегездән бер кадак ит кистерәсез.
Шунысын да күрсәтәбез: мин ул итне
Кайсы җирдән телим, шуннан кисеп алам.

Антонио

Бик шәп булыр. Ул вексельгә мин кул куям;
Шунысын да әйтәм: яһүд шәфкатьле, дим.

Бассанио

Минем өчен шундый вексель?! Юк, бирмисең!

Антонио

Курыкма, дустым, өч ай срок бик зур бит ул.
Ике айдан минем кулга моннан ун кат
Артыграк акча керә. Шулай булгач,
Төгәл бер ай әле артып кала безнең.

Шейлок

Йә, Ибраһим, изге ата! Менә бит ул!
Христианнар барысы да шундый алар,
Үзләренең күңелләре бозык булгач,
Башкалардан шикләнмичә калалмыйлар.
Соң, уйлагыз: ярый, түли алмады ди.
Ул бер кадак иттән миңа нинди файда?
Адәм ите өстәвенә... кемгә кирәк?
Ул бәягә тормый да ул, файдасыз да.
Сыер, сарык, кәҗә ите булса икән.
Чын дусларча ярдәм итим дигән идем.
Шуңар риза икән — алсын; булмаса — хуш!
Дуслык өчен миңа җәбер күрсәтмәгез.

Антонио

Ярый, Шейлок, векселеңә мин кул куям.

Шейлок

Нотариуста очрашырбыз. Хәзер барып
Шул әкәмәт вексельне сез әзерләгез.
Ә мин өч мең алтын җыеп алып килим,
Өйгә дә күз салып чыгыйм. Үтә гамьсез

Хезмәтчемә генә ташлап киткән идем.
Яныгызга бик тиз килеп җитәрмен мин.

Антонио

Бар, шәфкатьле яһүд.

Шейлок китә.

Күңеле йомшардымы?
Димәк, яһүд христиан диненә күчә.

Бассанио

Мондыйларның йомшак сүзе, ай-һай, хәтәр.

Антонио

Киттек. Хәтәр уйларыңны ташла йолкып.
Утыз көнгә алдан кайта корабларым.

Китәләр.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бельмонт. Порция өенең бүлмәсе.
Сакчыларын иярткән Марокко шаһзадәсе, Порция, Нерисса һәм хезмәтчеләр керәләр.

Марокко шаһзадәсе

Тәне кара дип син мине кире какма:
Эссе кояш мине шулай киендергән,
Аңа күрше торам, шунда үскәнмен мин.
Бозларын кояш эретә алмаган
Төньякның иң ак кешесен чакырып китер;
Сине сөю хакына без икебез дә
Тиребезне кисеп-ярып күрсәтербез:
Кайсыбызның кызылрак икән каны?
Шунысын да әйтим, минем йөзне күргәч,
Иң гайрәтле батырның да коты чыга.
Әмма гыйшкым белән мин ант итеп әйтәм:
Илемдәге кызлар мине яраталар.
Тәнем төсен үзгәртергә мин һич күнмәм,
Күнсәм дә, тик синең күңел хисләреңне
Белү өчен генә күнә алырмын бу
Хилаф эшкә, әй күңелемнең падишаһы!

Порция

Сайлаганда мин күзләрем киңәшенә
Карап кына эш итмим бит,
Минем язмыш лотерея уены күк,
Үзем теләп сайларга юк ихтыярым.
Әйткәнемчә, әтием куйган шул шартларны
Төгәл үтәүчегә генә чыга алам!
Юкса сезне, әй шаһзадә, һич кенә дә
Әлегәчә күргән чибәр егетләрдән
Ким санамыйм.

Марокко шаһзадәсе

Анысына бик зур рәхмәт.

Тартмаларың янына илт, бәхетем сыныйм.
Мин ант итәм данлы солтан Сөләйманны
Өч кат җиңеп чыккан, Иран шаһзадәсен
Һәм Суфины һәлак иткән кылыч белән,
Син гүзәлне үземнеке итәр өчен
Иң гайрәтле батыр белән алышырга,
Имеп яткан күмәк аю балаларын
Аналары имиеннән аерырга,
Ач бәгырьле арысланны үчекләргә
Әзермен мин. Тик, аһ! Әгәр, көч сынашып,
Геркулес һәм Лихас кузна уйнасалар,
Хезмәтченең көчсез кулы җайлы бәреп,
Баһадирны җиңүе мөмкин түгелмени?
Мин дә шулай, сукыр язмыш аркасында,
Бәхетемне оттырып иң лаексызга,
Хәсрәтемнән үлүем бар.

Порция

Хәзер сезгә
Йә сайлаудан баш тартырга, яки алдан
Ант итәргә кирәк. Әгәр оттырсагыз,
Беркайчан да бер хатын-кыз каршында да
Яңа никах турында сүз кузгатмаска.
Уйлагыз.

Марокко шаһзадәсе

Мин риза! Әйдә, җитәкләгез.

Порция

Иң элек гыйбадәткә. Аннан — ашка.
Аннан инде бәхетегезне сынарсыз.

Марокко шаһзадәсе

Язмыш! Миңа ярдәм итәсең син
Яки, каргап, мине ярдан этәсең син!

Музыка. Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Венеция. Урам. Ланчелот керә.

Ланчелот. Һич шикләнмим: намусым миңа хуҗамны ташлап китәргә рөхсәт итәчәк. Шайтан ләгыйнь, кабыргама төртә-төртә, әй котырта, әй котырта: «Гоббо, Ланчелот Гоббо, саф күңелле Ланчелот», — ди. Яки: «Саф күңелле Гоббо, саф күңелле Ланчелот Гоббо», — дип эндәшә. Ул миңа: «Аякларыңа ирек бир, ялтырат табаныңны, кач тизрәк моннан», — ди. Әмма вөҗданым: «Юк, тукта, намуслы Ланчелот! Тукта, намуслы Гоббо», — ди яки, башта әйткәнемчә: «Тукта, намуслы Ланчелот Гоббо, аякларыңа ирек бирмә, ялтыратма табаныңны», — ди. Ярый, әмма шайтан һаман туктамый. Әйберләремне җыярга куша. «Чыгып кит!» — ди шайтан. «Марш!» — ди шайтан. «Алла хакы өчен тәвәккәллә дә йөгер», — ди. Ярый. Әмма ләкин вөҗданым күңелемнең муенына асылына да әйтә: «Намуслы дустым Ланчелот, син бит намуслы ата баласы», — ди. Дөресрәге, намуслы ана баласы дияргә кирәк иде. Чөнки, дөресен генә әйтсәм, әткәйнең намус ягы чамалы... Күңеле бик азгын... Ярый. Вөҗданым әйтә: «Ланчелот, кузгалма!» — ди. «Кузгал!» — ди шайтан. «Тик тор!» — ди вөҗданым. Шуннан инде мин аңа: «Вөҗдан гынам! Киңәшең бик әйбәт», — диярга мәҗбүр булам. Менә бит ул: вөҗданымны тыңласам, хуҗамнан китмәскә кирәк. Ә ул, минем хуҗам, әстәгъфирулла тәүбә, Иблискә охшаган, суйган да каплаган. Димәк, аннан качар өчен миңа шайтан киңәшен тыңларга кирәк. Ә ул, миңа киңәш бирүче шайтан, чын иблиснең үзе. Шулай булгач, минем вөҗданым — яһүдтә калырга өндәүче вөҗданым — үтә шәфкатьсез булып чыга түгелме? Димәк, шайтанның киңәше чын дусларча... Болайга киткәч, шайтан әфәнде, сине тыңлыйм инде мин. Аякларым синең ихтыярда, үкчәләрне ялтыратам булып чыга.

Гоббо карт керә. Кулында кәрзин.

Гоббо. Яшь синьор, әйтегез әле, яһүд әфәнденең өенә ничегрәк барырга?

Ланчелот. Ярабби! Әткәй бит бу. Үз улын танымагач, күзләре начар гына түгел, бөтенләй сукыр булып чыга лабаса. Шаяртыйм әле үзен.

Гоббо. Хөрмәтле яшь синьор, әйтегез, зинһар, яһүд әфәндегә ничегрәк барырга?

Ланчелот. Беренче борылышта уңга китәргә, аннан алдагысында — сулга. Инде борылышның үзенә барып җиткәч, уңга да, сулга да борылмыйча, яһүднең өенә туп-туры барып керергә кирәк.

Гоббо. Ярабби, юлны табуы җиңел булмас. Әйтмәссез микән, аның хезмәтчесе Ланчелот дигән егет хәзер аңарда торамы, юкмы?

Ланчелот. Яшь синьор Ланчелотны әйтәсезме? *(Читкә.)* Туктагыз, шундый бер галәмәт китереп чыгарыйм әле... Яшь синьор Ланчелотны әйтәсезме?

Гоббо. Нинди синьор булсын, әфәндем. Ярлы кеше баласы ул. Аның атасы намуслы, ләкин бик ярлы кеше. Аллаһы Тәгалә ярдәмендә сау-сәламәт йөри әлегә.

Ланчелот. Атасы кем генә булмасын, без яшь синьор Ланчелот турында сөйләшәбез.

Гоббо. Җәнабыгызга таныш булган гади Ланчелот турында.

Ланчелот. Зинһар, дим, карт, ялынып сорыйм, сез соң кем турында сөйлисез? Яшь синьор Ланчелот турындамы?

Гоббо. Гади Ланчелот турында, әфәндем.

Ланчелот. Әйе шул, синьор Ланчелот турында. Ләкин сез, әткәй генәм, синьор Ланчелот турында сүз куертмагыз — ул үлде, ачыграк әйтсәк, теге дөньяга китте.

Гоббо. Ярабби Ходаем, үзең кичер! Ул бала бит минем картлык көнемдә бердәнбер таяныр таягым иде ләбаса!

Ланчелот. Мин шулай таякка охшыйм микәнни? Күсәккә? Утын агачына, терәүгә? Сез мине танымыйсызмыни, әткәй?

Гоббо. Аһ, танымыйм шул, синьор. Зинһар, дим, дөресен генә әйтегез: минем балам, авыр туфрагы җиңел булсын, тереме, үлеме?

Ланчелот. Мине чынлап та танымыйсызмыни, әткәй?

Гоббо. Аһ, гөнаһ шомлыгы, сукырайдым дисәм дә, ялгыш булмас, танымыйм шул.

Ланчелот. Күзләрегез күрсә дә, сез мине танымас идегез: үз баласын таныр өчен ата кешенең акылы булырга тиеш. Ярый, карт, улыгыз турында мин сезгә барын сөйлим хәзер. *(Тезләнә.)* Кичер мине, әткәй, хаклык барыбер беленер. Улыңның мәетен озак яшереп булмас. Кемнең кем улы икәнен яшереп булса да, вакыты җиткәч, ачылыр ул.

Гоббо. Торыгыз, синьор, торыгыз, зинһар. Сезнең Ланчелот булуыгыз, минем улым булуыгыз мөмкин түгел.

Ланчелот. Шаяру урынсыз. Мин — Ланчелот. Синен малаең идем, хәзер дә синең улың, киләчәктә дә синең балаң булырмын.

Гоббо. Сез улым булганга ышана алмыйм.

Ланчелот. Менә ул ягын белмим инде. Ләкин мин Ланчелот, яһүд хезмәтчесе. Чын күңелдән ышанып әйтәм: сезнең хатыныгыз Марджери минем әнием була.

Гоббо. Әйе шул, аның исеме Марджери... Әгәр син Ланчелот икән, чынлап син минем улым буласың. *(Җилкәсенә төшкән чәчен тотып.)* Ярабби! Алланың рәхмәте төшкере! Нинди сакал үстергәнсең! Алаша койрыгыннан да куерак.

Ланчелот. Алайса, алашаның койрыгы сыегайган. Юкса соңгы тапкыр күргәндә, аның койрыгы минем сакалдан куерак иде.

Гоббо. Ярабби! Ничек үзгәргәнсең. Хуҗаң белән тату яшисезме? Мин аңа күчтәнәч алып килгән идем. Арагыз ничек?

Ланчелот. Зарар юк, ярыйсы. Ләкин мин аннан качарга булдым. Эштән чыккан саран ул, аңа бүләк бирергәме? Бау бир син аңа, асылынсын. Мин аңарда хезмәт итеп ачтан интегәм. Кабыргаларым кул белән санарлык. Синең килүеңә мин шат. Күчтәнәчеңне синьор Бассаниога бир. Хезмәтчеләренә менә дигән киемнәр тектерә икән ул. Аңа урнаша алсам, качам, җәһәннәмгә ычкынам. Менә ул бәхет! Әнә үзе килә. Каршысына чык, эти! Юкса яһүдтә хезмәт итә-итә үземнең дә яһүдкә әйләнүем бар.

Леонардо һәм башка хезмәтчеләр белән Бассанио керә.

Бассанио. Бу эшне син булдыра аласың. Җәһәтрәк бул. Кичке аш сәгать биштән дә соңга калмасын. Бу хатларны хәзер үк җибәр. Хезмәтчеләр тиешенчә киенсеннәр. Грацианога әйт, миңа кереп чыксын.

Хезмәтчеләрнең берсе китә.

Ланчелот. Туп-туры каршысына чык, әткәй!

Гоббо. Ходай ярлыкасын үзегезне, синьор.

Бассанио. Рәхмәт. Миндә берәр йомышыгыз бармы әллә?

Гоббо. Менә, синьор, минем улым, бичара егет...

Ланчелот. Бичара егет түгел, синьор, бай яһүднең хезмәтчесе. Минем теләгем... менә эткәй аңлатып бирер...

Гоббо. Ул, синьор гынам, төнлә төшләрендә...

Ланчелот. Әйе, мин яһүдтә хезмәт итәм. Әмма бөтен теләгем... энә эткәй аңлатып бирер...

Гоббо. Турысын әйткәндә, әфәндем, хуҗасы белән бик тату яши димәс идем мин...

Ланчелот. Кыскасы шул: дөресен әйтергә кирәк, яһүд мине бик җәберли. Шуңа күрә... энә эти карт сезгә аңлатып бирер...

Гоббо. Менә монда кыздырылган күгәрченнәр... Батырчылык итеп сезгә тәкъдим итәм. Шунда берьюлы гозеремне дә әйтим инде...

Ланчелот. Озын сүзнең кыскасы: минем үтенечем шул... Менә бу намуслы карт сезгә аңлатып бирер... Ул үзе карт кына, ярлы гына булса да, миңа эти кеше ләбаса.

Бассанио. Берегез генә сөйләгез, ни кирәк сезгә?

Ланчелот. Сезгә хезмәт итәр идем, синьор.

Гоббо. Үтенечебезнең бөтен асылы шул.

Бассанио

Сине беләм мин, үтәрмен теләгеңне.
Бүген генә хуҗаң сине бик мактады.
Әгәр дә син, бай яһүднең йортын ташлап,
Бер ярлыга хезмәткә яллануны
Өскә үрләү дип санасаң, теләгеңә ирештең син.

Ланчелот. Шейлок белән сезнең арадагы аерманы борынгы мәкаль бик әйбәт аңлата: «Аңарда — акча, сездә — җан рәхәте».

Бассанио

Әйбәт әйттең.
Хәзер кайтып хуҗаң белән саубуллаш та
Аннан миңа рәхим ит.
*(Хезмәтчесенә.)*
Ливреянең
Иң матурын, иң пөхтәсен бир син аңа.

Ланчелот. Киттек, эткәй. Урын тапмыйммы соң мин? Телем бар лабаса! Бер дигән! Учымны гына кара син: бөтен илне бетереп эзләсәң дә, мондый учны табалмассың. Шушы учым белән изге китапка таянып ант итеп әйтә алам: мин бәхетле булырмын! Менә кара тормыш юлымны, *(Кулын күрсәтә.)* Хатын-кыз әллә ни күп түгел анда, унбиш кенә. Унбиш хатын күпмени ул ир кешегә? Тукта, тукта, алардан тыш унбер тол хатын, тугыз кыз бар икән әле — алары инде бер кешегә таман гына. Өстәвенә өч тапкыр суга батам, бәхетемә өчесендә дә котылам. Аннан ниндидер бер түшәктә әҗәл белән очрашам икән әле — монысы аның очраклы хәл. Фарт дигәнең хатын-кыз булса, котылырмын дип уйлыйм — мондый эшләрдә алар бик тапкыр була. Киттек, эткәй. Шейлок белән мин күз ачып йомганчы саубуллашырмын.

Ланчелот һәм Гоббо карт китәләр.

Бассанио

Леонардо, эшне сузма, зинһар;
Бөтен кирәк нәрсәләрне сатып ал да
Тизрәк кайт. Мин иң якын дусларымны
Сыйламакчы булам бүген. Тиз бул! Ашык.

Леонардо

Бар көчемне салып тырышырмын.

Грациано керә.

Грациано

Хуҗаң кайда?

Леонардо

Әнә тегендә ул.

Чыгып китә.

Грациано

Синьор Бассанио...

Бассанио

Грациано!

Грациано

Йомышым бар иде...

Бассанио

Алдан ук әйтәм, үтәлер.
Грациано. Үтәмәү мөмкин дә түгел. Мин сезнең белән Бельмонтка барырга тиеш.

Бассанио

Ярый, киттек әйдә. Ләкин тыңла:
Син бик дорфа, кызу, телең артык тупас.
Дөрес, холкың үзеңә килешеп тора.
Аның өчен без дә сине әрләмибез.
Ләкин читтә, ят кешеләр арасында
Тупас булып күренүең бик ихтимал.
Шуңа күрә холкыңны син бераз үзгәрт.
Юкса синең дуамаллык аркасында
Минем хакта әллә нинди фикер туып,
Бар өметем юкка чыгып куюы бар.

Грациано

Тыңла, синьор. Сезгә мин сүз бирәм:
Анда баргач, әүлияга әйләнәм мин;
Беренчедән, сүгенүне сирәгәйтәм.
Икенчедән, сөйләшкәндә суфи булам.
Тик йөрермен изге китап тотып кына,
Мыштым гына, ирнем кыймылдатып кына;
Гыйбадәт вакытында мин күзләремне
Эшләпәнең кыры белән капланмын да:
«Амин, амин», — дип торырмын. Кайберәүләр,
Әбиләре күңеленә ошар өчен,
Нәкъ тәүфыйклы песи кебек йөриләр бит.
Мин дә шулар күк булырмын. Биргән вәгъдәм
Үтәмәсәм, миңа мәңге ышанмассың.

Бассанио

Ярый, бик шәп.

Грациано

Бүгенге кич исәпләнми.
Ниләр генә кылансам да,
Гаепләмә.

Бассанио

Гаепләсәм,
Бик күңелсез булыр иде. Киресенчә,
Мөмкин кадәр шаянрак бул син бүген.
Дуслар килә бүген күңел ачарга дип.
Ярый, минем эшләрем бар. Сау булып тор.

Грациано

Мин дә китәм. Лоренцога керәсем бар.
Тагын башка дусларны да күрәсем бар.
Барыбыз да кичкә сезгә җыйналабыз.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук. Шейлок өенең бер бүлмәсе. Джессика һәм Ланчелот керәләр.

Джессика

Әтидән китүең бик кызганыч.
Безнең өй бит тәмуг. Ә син — шаян шайтан.
Минем хәсрәтемне гел син тарата идең.
Нишлисең бит. Ярый, сау бул, хәерле юл!..
Менә сиңа алтын тәңкә. Аһ, Ланчелот,
Бассаниода кичке мәҗлес вакытында
Лоренцоны күрерсең син. Шушы хатны
Бир син аңа, яшереп кенә. Ярый, сау бул.
Сөйләшкәнне әти сизеп калмасын тик.

Ланчелот. Сау булыгыз. Күз яшьләрем телемне бәйли, сөйли алмыйм. Гүзәлләрнең гүзәле мәҗүс кызы! Күңелләрне сихерләүче яһүдә! Берәр христиан егете сезнең өчен диненнән язмаса, бар өметем юкка чыксын!.. Йә, сау булыгыз... Бу күз яшьләре егетлегемне тәмам чылатты лабаса. Сау булыгыз!

Китә.

Джессика

Исән бул, Ланчелот дустым!
Аһ, нинди зур гөнаһ! Үз атаңның
Туган кызы булудан оял, имеш!
Кан ягыннан гына ата бит ул миңа,
Күңеле белән бөтенләй ят. Аһ, Лоренцо!
Вәгъдәң үтәр булсаң әгәр, бу ызгышны
Ташлыйм да мин сиңа хәләл хатын булам,
Христиан диненә күчәм бүгеннән үк.

Китә.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук. Урам.
Грациано, Лоренцо, Саларино һәм Саланио керәләр.

Лоренцо

Әйе, шулай! Табыннан торабыз да
Сиздермичә генә чыгып югалабыз.
Безгә барып киенәбез дә иплэп кенә
Кире кайтып урныбызга утырабыз.
Бер сәгатьтә барысына өлгерәбез.

Грациано

Безнең әле бернәрсә дә әзер түгел.

Саларино

Факелчылар ялларга да өлгермәдек.

Саланио

Болай әшер-өшер генә барып чыкмый.
Андый эшнең булуыннан булмавы артык.

Лоренцо

Сәгать дүртне сукты, безнең әле
Ике сәгать вакытыбыз бар.

Кулына хат тоткан Ланчелот керә.

Ни бар, дускай?
Ланчелот. Шушы хатны ачып карасагыз, ни барын үзегез күрерсез.

Лоренцо

Бу кулны таныйм мин... Язуы нинди матур.
Куллары да язган хаты кебек ап-ак.

Грациано

Гыйшык хаты?

Ланчелот

Сау булыгыз, синьор.

Лоренцо

Кая барасың?
Ланчелот. Кая булсын? Элекке хуҗам Шейлокка барам, синьор, яңа хуҗам аны кунакка чакырды.

Лоренцо

Менә сиңа. Джессиканың үзенә генә
Яшерен әйт: килә, диген. Йә, бар, тизрәк.

Ланчелот китә.

Без дә тизрәк маскарадка әзерләник.
Минем факелчым бар инде.

Саларино
Әйдә, киттек.

Саланио

Мин дә китәм.

Лоренцо

Бер сәгатьтән барыбыз да
Грациано өендә очрашабыз.

Саларино

Яхшы.

Саланио һәм Саларино китәләр.

Грациано

Бу хат Джессикадан булды бугай?

Лоренцо

Әйе, минем синнән яшерен серем юк.
Хатында ул бүген үзен өйдән
Ничек алып китәргә икәнлеген,
Күпме алтын, асылташлар әзерләвен,
Үзе өчен паж киеме хәстәрләвен
Яза миңа.
Әйе, яһүд, җәннәткә керсә дә, тик
Гүзәл кызы аркасында гына керер.
Бәхетсезлек килсә дә бу гүзәл кызга,
Атасы яһүд булганы өчен генә
Килер инде... Әйдә хәзер минем белән,
Хатны юлда укырсың. Джессика бүген
Үзе миңа факелчы булып бара.

Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук. Вакыйга Шейлок өе алдында. Шейлок, Ланчелот керәләр.

Шейлок

Ярый, яхшы. Күрерсең үз күзең белән.

Бассанио белән минем арадагы
Аерманы тиз күрерсең... Әй, Джессика!
Син аңарда миндәгедәй тыгыналмассың.
Әй, Джессика! Гыр-гыр килеп йокларга да,
Миндәгечә киенергә дә туры килмәс.
Кайда соң син, әй, Джессика!

Ланчелот
Әй, Джессика!
Шейлок. Чү, кем сиңа кычкырырга кушты? Минме?
Ланчелот. Үзегез бит кушканны гына эшли дип сүгәсез.

Джессика керә.

Джессика

Сез чакырдыгызмы? Нәрсә кирәк?

Шейлок

Кызым, мине мәҗлескә чакырдылар.
Менә ачкычлар. Барыргамы, әллә юкмы?
Дус күргәнгә чакырмый ул. Шуның белән
Юмаларга тели. Ярый. Барыйм әле.
Исрафчыга үч итеп күп ашармын.
Әйдә, түли бирсен. Ә син, балакаем,
Өйне яхшы кара. Әллә бармыйм микән?
Әллә нинди күңелсезлек булыр кебек,
Төшемдә капчык-капчык алтын күрдем.

Ланчелот. Зинһар, дим, синьор, барудан баш тартмагыз. Ният барып чыкмаса, яшь хуҗам бик борчылыр.

Шейлок. Мин дә шулай ук.

Ланчелот. Алар анда сүз куештылар. Баргач та маскарадка тап булырсыз дип, мин сезгә алдан әйтеп тормыйм инде.

Шейлок

Маскарад? Джессика, яхшылап тыңла:
Ишегең биклә. Барабаннар тавышына,
Кәкре-бөкре быргылар чинавына
Исең китеп, тәрәзәгә асылынма.
Битләрен буяп чыккан шыр дивана
Христианнар өеренә бик акайма.
Өйнең барлык ишекләрен-тишекләрен
Томалап куй. Ахмакларның шау-шулары
Минем затлы өй түремә керә алмасын.
Изге Якуб таягы белән ант итәм мин,
Һич кенә дә сыйланасым килми бүген.
Ярый, барыйм. Бар, әйт, хәзер килә, диген.

Ланчелот

Киттем, синьор! Сез, туташ, тәрәзәгә шулай да күз салыгыз.
Анда чибәр христиан егете йөрер,
Яһүд кызы ул егетне бик хуп күрер.

Китә.

Шейлок
Ни диде ул кяфер?

Джессика

Исән булыгыз, диде.

Шейлок
Болай әйбәт үзе;
Ләкин бик күп ашый, бирән. Эшкә дисәң,
Әйтерсең лә әкәм-төкәм — чак сөйрәлә.

Көн буена йоклап ята мәче кебек.
Соры кортка урыным юк умартада,
Мин бит аны шуңа бирәм яшь хуҗага.
Исрафчының миннән алган акчаларын
Туздырышсын. Ә син, кызым, бар, өйгә кер!
Бәлки, кире әйләнеп үк кайтырмын мин.
Мин әйткәнчә эшлә: кер дә эчтән биклән.
«Саклаганның сагы ятар», — дигәннәр бит,
Хәстәрле кешеләрнең бер мәкале бу.

Китә.

Джессика

Хуш, исән бул! Сыныйм бүген язмышымны —
Мин атамны югалтам, ә син — кызыңны.

Китә.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Шунда ук.
Битләренә маскалар кигән Грациано белән Саларино керәләр.

Грациано

Лоренцо шул урында көтәргә кушты.

Саларино

Билгеләнгән сәгать үтте.

Грациано

Ник соңлады икән?
Гашыйкларның сәгате бит җитез була.

Саларино

О! Мәхәббәт күгәрчене шундый бит ул:
Иске антны үтәүгә караганда,
Ун мәртәбә тизрәк оча яңа ярга.

Грациано

Әйе шул. Һәрвакыт шулай була бит ул.
Кем омтыла табынга, тамак туйгач?
Нинди генә ярсу ат та, зур юл үткәч,
Кайтыр юлда шактый сүрелә, юашлана.
Кадере кими; кулга төшерүдән бигрәк,
Аны эзләү күп мәртәбә күңеллерәк.
Корабны ал! Ил портыннан киткән чакта,
Көяз егет күк бизәнә, купшылана;
Юлда аны шаян җилләр иркәлиләр.
Әмма кире кайткан чакта танып булмый.
Азып-тузып, юлдан язып йөри торгач,
Тәмам өтелеп, атасына кире кайткан
Тәүфыйксыз яшь егетне хәтерләтә:
Кабыргалар бәрелеп-сугылып ямьшәйгәннәр,
Җилкәннәре җилләр белән сугыша-сугыша
Тетелеп беткән!

Саларино

Әнә үзе, Лоренцобыз.
Әңгәмәне хәзергә ташлап торыйк.

Лоренцо керә.

Лоренцо

Соңлавымны, дусларым, кичерегез.
Мин гаепле түгел, эшем бик күп булды.

Кыз урларга чыккан чакта үзегезгә дә
Нәкъ шулай ук булышырмын. Йә, килегез.
Каенатам яһүд менә шунда тора, —
Кем бар анда?

Тәрәзәдә ирләр киемендә Джессика күренә.

Джессика

Син кем? Зинһар, эндәшсәнә.
Тавышыңнан танысам да, кемлегеңне
Тикшеримче.

Лоренцо

Лоренцо мин, сөйгән ярың!

Джессика

Лоренцо шул! Сөйгән ярым. Әйе, дөрес.
Бүтән кемне сөям соң мин шулкадәре?
Тик шунысы: кем белә соң, синнән башка
Минем сиңа яр булганны?

Лоренцо

Син үзең һәм
Хак Тәгалә шаһит моңа.

Джессика

Тот тартманы. Моны тотсаң, хур булмассың.
Әле ярый төн караңгы — күрә алмыйсың.
Өстемдәге киемемнән оялам мин.
Гыйшык күзе сукыр, диләр. Гашыйклар бит
Үзләренең җүләрлеген күрә алмый.
Өстемдәге киемемне күрсә әгәр,
Кызарыр иде хәтта Купидон да.

Лоренцо

Төш, факелчым булырсың бүген минем.

Джессика

Хурлыгымны кешеләргә фаш итимме?
Ансыз да фаш булдым инде. Һәркем күрер.
Ә бит миңа яшеренергә кирәк, җаным.

Лоренцо

Өстеңдәге менә дигән малай киеме
Яшергән бик әйбәт итеп, бәгырькәем.
Йә, чык инде. Озакламый таң беленә.
Бассанио кичке ашка дәште безне.

Джессика

Ишекләрне биклим башта. Кирәк кадәр
Алтын тутырыйм, аннан сезнең янга чыгам.

Югала.

Грациано

Бүрегем белән ант итәмен, бу чибәр кыз
Чын мәҗүси, әмма яһүд кызы түгел!

Лоренцо

Өзелеп сөям бу мөлаем сылу кызны.
Миңа калса, зирәк тә ул, акыллы да,
Күзләрем алдамаса, чибәр дә ул.
Үзе исбат итүенчә, тугры да ул.

Мондый зирәк, батыр, чибәр, тугры кызга
Мәхәббәтем мәңге сүнмәс йөрәгемдә.

Джессика чыга.

Ә, чыктыңмы? Ягез, дуслар, әйдә киттек.
Маскалылар анда безне күптән көтә.

Лоренцо, Джессика һәм Саларино китәләр. Антонио керә.

Антонио

Кем бар монда?

Грациано

Синьор Антонио!

Антонио

Нигә болай көттерәсез, Грациано?
Башкалары кая? Тугыз тулды!
Анда сезне дуслар көтә. Мәҗлес булмый.
Җил уңайга искән чакта, Бассанио
Корабында тизрәк сәфәр чыкмак була.
Егермеләп кеше эзләп йөри сезне.

Грациано

Моңа мин шат! Киң океанда алга карап,
Җилкәннәрен киереп очар безнең кораб.

Китәләр.

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бельмонт. Порция өенең бер бүлмәсе. Музыка.
Порция, Марокко шаһзадәсе һәм аның сакчылары керәләр.

Порция

Тарт чаршауны. Ачып җибәр тартмаларны,
Күрсәт затлы шаһзадәгә. Йә, сайлагыз!

Марокко шаһзадәсе

Беренчесе — алтын тартма. Ни дип язган?
«Син табарсың моннан күпләр теләгәнне».
Икенчесе — көмеш тартма. «Мине алсаң,
Үз бәяңә лаек нәрсә табарсың син».
Өченчесе — кургаш тартма. Нәрсә дигән?
«Мине алсаң, бар нәрсәңне жуюың бар».
Кайсын сайлап алсам, дөрес булыр икән?

Порция

Тартмаларның берсендә — минем рәсемем.
Рәсемлесен сайлый алсаң, мин — синеке.

Марокко шаһзадәсе

Уйларымны әүлия җитәкләсен.
Язуларны тагын бер кат укып чыгыйм.
Кургаш ни ди?
«Мине алсаң, бар нәрсәңне жуюың бар».
Бар нәрсәмне жуярга? Ә! Ни хакына?
Кургаш өчен бар нәрсәңнән кул селтәргә!
Бик зур табыш өмет иткән чакта гына
Тәвәккәлләп бар байлыкны салып була.
Алтын акыл затсыз малга кызыкмый ул.
Кургаш өчен бар байлыкны куялмыйм мин.
Саф чәчәктәй көмеш ни ди? «Мине алсаң,
Үз бәяңә лаек нәрсә табарсың син».

Чү, шаһзадә, үз бәяңне,
Учыңа салып, ипләп кенә үлчәп кара.
Үз уеңча бәяң, бәлки, бик зур булыр,
Ләкин ул «зур бәя» шундый сылу кызның
Тиңсез кулына торырлыкмы?.. Үз бәяңне
Урынсызга арзанайту — зур ахмаклык.
Бәям күпме?.. Ләкин мин бу кызга лаек,
Нәселем затлы, байлыкларым һәм тәрбиям,
Саф күңелем белән, барыннан да бигрәк
Мәхәббәтем белән лаек мин бу кызга.
Әллә шуны сайлыйм микән тәвәккәлләп?
Алтын тартма язуын да укыйм әле.
«Син табарсың моннан күпләр теләгәнне»,
Әлбәттә, кыз монда. Аны һәркем тели,
Төрле илдән бар да аңа омтылалар,
Ашкыналар изге кулын үбәргә дип.
Кыз янына килүче шаһзадәләр
Эзсез-юлсыз Гиркания далаларын,
Иксез-чиксез Гарәбстан сахраларын
Кисеп үтә торгач, анда юл салынды,
Җил-давылда ярсып-ярсып үкерүче,
Шашып китеп, зәңгәр күккә түкерүче
Океаннар да туктаталмый ул халыкны.
Кызның йөзен күрү өчен ул гашыйклар
Диңгезләрне күлдәй күреп йөзеп чыга:
Тартмаларның берсендә аның рәсеме.
Кургашында микәнни? ...Юк. Болай уйлау
Бик зур әдәпсезлек булыр. Мөмкинме соң?
Шундый матур кыз рәсеменә кургаш кәфен!
Чорнадылар микән әллә көмеш белән?
Алтыннан ун мәртәбәгә арзан бит ул.
Алай уйлау гөнаһ булыр. Кем соң инде
Энҗенең иң кыйбатлысын алтыннан да
Арзан металл белән бизи оялмыйча?
Инглизләр суккан алтын акчаларда
Фәрештә сурәте бар. Ул сурәтне,
Тышкы якта булгач, күрә һәрбер кеше.
Әмма минем фәрештәмне күреп булмый,
Эчтә ята — шушы алтын тартмада ул.
Бирегез ачкыч, ни булса да, шуны сайлыйм!

Порция

Менә... Әгәр минем рәсемем анда булса,
Мин сезнеке.

Марокко шаһзадәсе
*(алтын тартманы ача)*

Аһ!.. Җәһәннәм! Нәрсә соң бу?
Баш сөяге! Күз куышы эчендә ул
Нинди кәгазь? Тукта, укып карыйк.
«Һәрбер ялтыраган алтын түгел» —
Акыллылар шулай дигәннәр.
Фәкать мине күрер өчен генә
Җанын җуйды бик күп адәмнәр...
Алтын кабердә дә корт була.
Акылың булса азрак башыңда,
Яшьләй кортка азык булырга
Килеп капмас идең син монда.
Кайда алып килде саф алтын —
Зәмһәрирдәй кабер сап-салкын!

Эзләгәнең таптың, хуш инде».
Әйе, юкка түктем көчемне.
Өмет бетте! Йөрәгемдә сүнде ялкын.
Җаннарыма, тәннәремә үрли салкын.
*(Порциягә)*
Кичер. Миңа чиксез авыр. Тизрәк китим,
Калалмыйм, отылдым мин, ни хәл итим?

Китә.

Порция

Уф, коткардың Раббым Ходай!
Яп чаршауны. Сайласыннар иде шулай
Мондыйларның барысы да.

Китәләр.

СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Венеция. Урам.
Саларино белән Саланио керәләр.

Саларино.

Бассанионың корабка утырганын
Үзем күрдем.
Грациано белән китте.
Өзеп әйтәм: анда Лоренцо юк иде.

Саланио

Яһүд гауга салып Дожны уятты,
Бассанионың корабын тентергә, ди.

Саларино

Соңга калды: кораб инде күптән китте.
Дожга шундук хәбәр килде: Лоренцоның
Яһүд кызы белән икәү бер көймәгә
Утырганын берәү ярдан күреп калган.
Антонио да: «Корабта юк алар», — диде.

Саланио

Кешенең бу кадәре котыруын,
Мондый шашкын хисләр белән дулавын
Күргәнем юк иде үз гомеремдә.
Яһүд эттәй улый:
«Аһ, кызым!.. Аһ, алтыннарым!.. Аһ, кызкаем!
Христиан белән качты! Юкка чыкты
Христианнардан җыйган алтыннарым!
Кайда гадел хөкем?! Кызым бер янчык... түгел,
Ике янчык пичәтләнгән алтынымны
Урлап качты! Асылташлар! Иң кыйбатлы
Ике бриллиантым! Кызым урлап киткән!
Әй, хакимнәр, табыгыз эзләп кызкаемны!
Асылташым, алтыннарым аңарда бит!..»

Саларино

Венециядәге барлык малай-шалай:
«Асылташым! Абау, кызым! Алтыннарым!» —
Дип кычкырып, аның арттан йөгерәләр.

Саланио

Антонио түләү көнен соңлатмасын,
Юкса бөтен үчне аннан алачак ул.

Саларино

Антонио дигәннән, кичә генә
Бер француздан шундый хәбәр ишеттем мин;

Франция белән Англия арасында
Безнең илнең кораблары баткан, имеш.
Кыйммәтле йөк төягән кораблар, ди.
Кинәт кенә Антонио искә төште:
Аһ, аныкы булмагае ул кораблар?!.

Саланио

Бу хәбәрне Антониога җиткерергә иде,
Ипләп кенә ләкин, җайлап кына.

Саларино

Аннан да яхшы кеше юк дөньяда.
Бассаниоңы озатканын карап тордым.
Бассанио тиз кайтырга вәгъдә бирә.
Ә ул: «Юк, — ди, — минем өчен эшләреңне
Ашык-пошык эшләмә, Бассанио, — ди. —
Җиңү белән алар тәмамлансыннар, — ди. —
Яһүдигә язып биргән әлеге вексель
Синең гашыйк күңелеңне борчымасын.
Тыныч бул; зиһенеңне, уйларыңны
Кызны үзеңә каратырга юнәлт син», — ди.
Күзләренә яшьләр тулды, йөзен яшереп,
Читкә борылып Бассаниога кулын сузды.
Алар шулай хушлаштылар.

Саланио
Минемчә, ул
Бассанио өчен генә яши төсле.
Әйдә, аңар барыйк, күңелен биләп алган
Шомлы уйларыннан арындырыйк.

Саларино

Киттек.
Китәләр.

ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Бельмонт. Порция өенең бер бүлмәсе. Нерисса һәм хезмәтчеләр керәләр.

Нерисса

Тарт чаршауны, тизрәк ачып җибәр.
Арагон патшасының улы килде.
Ант итте ул. Хәзер сайлый башлар.

Музыка. Арагон шаһзадәсе, Порция һәм сакчылар керәләр.

Порция

Менә монда, шаһзадә, өч тартма бар.
Сайлавыгыз туры килсә,
Без хәзер үк никах белән кавышабыз!
Булмый икән, һичбер сүзсез һәм карусыз
Өегезгә кайтып китәсез, шаһзадә.

Арагон шаһзадәсе

Өч төрле шарт үтәргә дип мин ант иттем:
Беренчедән, кай тартманы сайлавымны
Һичбер кемгә белдермәскә. Икенчедән,
Синнән бүтән һичбер кәләш эзләмәскә,
Һәм, ниһаять, сайлавымда ялгышсам мин,
Шундук чыгып, үз өемә кайтып китәм.

Порция

Мин лаексыз кеше өчен, тәвәккәлләп,
Һәркайсы ант итә килеп.

Арагон шаһзадәсе

Мин барын да үтим хәзер. Әй син, бәхет!
Кил, ярдәм ит! Алтын, көмеш, затсыз кургаш!
«Мине алсаң, бар нәрсәңне җуюың бар».
Әгәр дә син матуррак булсаң, бәлки,
Тәвәккәлләр идем. Алтын тартма ни ди?
«Син табарсың моннан күпләр теләгәнне».
Ничек «күпләр»? Күпләр бит ул — затсыз халык.
Тышкы якны гына күрә — күзгә ышана,
Эчке якны һич кенә ул күрә алмый.
Шәрә ярга оялаучы карлыгачтай,
Җил-давылны, яңгырларны уйламый ул.
Юк, мин күпләр теләгәнне сайлый алмыйм.
Һич охшыйсым килми затсыз ахмакларга,
Буталасым килми кара халык белән.
Син ни дисең, көмеш тартма? «Мине алсаң,
Үз бәяңә лаек нәрсә табарсың син».
Шәп әйтелгән! Язмышны кем алдый ала?
Һичбер бәяң булмый торып, ничек инде
Хөрмәт өмет итмәк кирәк? Юк, лаексыз
Беркайчан да хөрмәт таҗын кия алмас!
Аһ, әгәр дә данлы исем, дәрәҗәләр
Түбәнлекләр, шакшы юллар белән түгел,
Хезмәткә хөрмәт йөзеннән бирелсәләр,
Билен бөккән күпләр балкып йөрер иде,
Мескен булмас иде, боерык бирер иде...
Чү! Сайлауга күчик инде. «Мине алсаң,
Үз бәяңә лаек нәрсә табарсың син».
Үзем нигә лаек булсам, шуны алам.
Кая ачкыч? Бер сыныймчы бәхетемне.

Көмеш тартманы ача.

Порция
*(үзалдына)*

Юкка гына акыл саттың, табышың — чүп.

Арагон шаһзадәсе

Ни күрәм мин? Әллә нинди бер шамакай
Миңа кәгазь сузып тора! Тукта, укыйк.
Порциягә һич кенә дә охшамый бу,
Бөтенләй ят минем якты өметемә дә!
«Үз бәяңә лаек нәрсә табарсың син».
Шундый котсыз шамакайга лаекмы мин?
Шулмы миңа лаек бүләк? Шәбрәгенә
Торырлык кыйммәтем юкмыни соң?

Порция

Гаепле һәм судьяны сез бутамагыз,
Ул кешеләр бер-беренә капма-каршы.

Арагон шаһзадәсе

Ни язган соң монда? Әйдә укып карыйк.
«Җиде үлчә, бер кис, диләр.
Ә син җиңел җайладың.
Шуңа мине сайладың.
Шәүлә куып гомерең үтте...
Отканың да — күләгә.
Килде-китте шыр дивана
Шулай килеп эләгә.
Көмешләргә күмелгән
Тиленәр күп синсез дә.
Кемгә генә өйләнсә дә,

Акыл кермәс юньсезгә.
Үз йөземне күрим дисәң,
Миңа гына син кара.
Бар кит инде, бичара».
Чыгып китмәсәм вакытында,
Көлкегә калуым бар.
Мисез башым берәү иде,
Инде икәү булдылар.
Сөйләмәм хур булуымны
Һичбер адәм затына.
*(Кызга.)*
Тап төшермәм антыма.

Китә.

Порция

Көйде көя күбәләге
Эләгеп шәм утына.
Аһ, бу акыл ияләре, диваналар.
Берәр нәрсә сайларга туры килсә,
Акыллары аркасында хур булалар.

Нерисса

Ил телендә шундый мәкаль яшәп килә:
«Хатын алу — муенга бау салу», — диләр.

Порция

Яп пәрдәне, киттек, Нерисса.

Хезмәтче керә.

Хезмәтче

Синьора кайда?

Порция

Биредә. Нәрсә кирәк?

Хезмәтче

Венеция шәһәреннән бер яшь егет
Ашыгыч хәбәр белән килде әле генә:
«Озакламый хуҗам үзе булачак», — ди.
Аннан сезгә кайнар сәлам алып килгән,
Сәламе һәм җылы сүзләренә кушып
Кыйммәтле бүләкләр дә җибәргән ул.
Күргәнем юк иде гыйшык илчесенең
Бу кадәре ягымлысын, сөйкемлесен.
Юмарт җәйнең киләчәген хәбәр иткән
Апрельдән дә мөлаем бу. Хуҗасының
Сезгә булган гыйшкын шундый итеп сөйли...

Порция

Ярый, җитте. Юкса күрәм, ул егетне
Кан карендәш, туган итеп势 тануың бар,
Мактавында чыгып киттең чик-чамадан.
Әйдә киттек, Нерисса, әллә нигә
Апрель ае кебек гүзәл һәм мөлаем
Бу илчене бик күрәсем килә минем.

Нерисса

Әй Ходаем! Килеп төшкән бу яшь егет
Бассанионың йомышчысы булсын иде.

Китәләр.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Венеция. Урам.
Саланио белән Саларино керәләр.

Саланио. Риальтода нинди яңалыклар бар?

Саларино. Нәрсә булсын! Һаман шул инде. Антонионың кыйммәтле товар төягән корабы тар бугазга кереп баткан, диләр. Гудвин комлыгы — шулай дип йөртәләр бугай — бик хәтәр урын. Су төбендәге комга терәлеп бик күп зур кораблар һәлак булган анда. Гайбәт ханым әкияте генә булмаса, бу бик начар хәбәр.

Саланио. Ә мин моның гайбәт ханым әкияте булуын телим. «Өченче ирем дә үлде», — дип, конфет чәйни-чәйни елаучы фахишә сүзе кебек, ялган булып чыксын иде бу хәбәр. Ләкин, ары-бире боргаламый гына, чынын гына әйтсәк, бу хәбәр, әлбәттә, дөрес хәбәр. Изге күңелле Антонио, намуслы Антонио... Аһ, бу исем янына куярга лаеклы сүз табып булса иде!..

Саларино. Ярый, сүзеңне бетер инде, җитте.

Саланио. Шуның белән бетте, Антонионың корабы су төбенә китте.

Саларино. Аңа килгән бәла шуның белән бетсен иде инде.

Саланио. Телемне шайтан тотмас борын «амин» дип калыйм. Әнә яһүд кыяфәтле шайтан үзе килә.

Шейлок керә.

Нихәл, Шейлок? Сәүдәгәрләр дөньясында ни яңалыклар бар?

Шейлок. Беләсез бит инде, — ул хәбәрне сездән дә яхшырак белүче юк, — кызым качты!

Саларино. Бик дөрес. Очты! Хәтта аңа канатлар тегеп бирүчене беләм мин. Кызың әнә шул канатлар ярдәмендә очып китте дә.

Саланио. Кошка канатлар үскәнен Шейлок үзе дә күрде. Ул чорда алар барысы да ата-аналар оясыннан очып китәләр — табигатьләре шундый аларның.

Шейлок. Ләгънәт төшсен аңа!

Саларино. Судьясы шайтан булса, төшмичә чарасы юк.

Шейлок. Үз каным бит, үземә каршы ничек котыра.

Саланио. Ах син, карт үләксә! Бу яшьтә кан котыра димени?!

Шейлок. Юк ла, кызымны әйтәм — үз каным үземә каршы!

Саланио. Аның белән сезнең арагызда аерма бик зур. Берегез кара таш булса, икенчегез — фил сөяге. Каннарыгыз да гади кызыл шәраб белән рейнвейн шәрабы. Син безгә шуны әйт: Антонионың корабы батканмы, юкмы?

Шейлок. Анысы да минем башка тимер таяк! Банкрот ул, исрафчы. Сәүдәгәрләргә күренерлеге калмады. Теләнче! Ә үзе ул базарда әллә кем булып йөри. Хәзер әнә үз векселе турында уйласын. Мине һаман ростовщик, тереләй тунаучы дип сүгә иде. Христианча ярдәм итәм дип, һичбер процентсыз акчалар биргән була иде. Үз векселе турында уйласын.

Саларино. Вакытында түли алмаса, итен кисеп алмассың бит. Аннан сиңа ни файда?

Шейлок. Кармакка куеп балык тотар өчен! Файдасы булмаса да, үчем кайтыр, ичмасам. Ул мине хурлады, кулыма керәчәк ярты миллионнан мәхрүм итте. Югалтуларымнан көлде. Табышларымны хәрам дип мыскыллады. Халкымны хурлады, планнарымны җимерде, дусларымны биздерде, дошманнарымны котыртты. Нигә болай кылана соң ул? Яһүд булганым өченме? Яһүднең күзе чыкканмыни? Яһүднең куллары, эчке әгъзалары, хис-дәртләре, теләкләре юкмыни? Шул ук ашны ашамыймыни ул? Шул ук коралдан яраланмыймы, шул ук авырудан чирләмиме, шул ук дару белән дәваланмыймы, кышкы салкыннан яки җәйге эсседән, христиан кебек үк, туңмыймы, тирләмиме ул? Тиребез киселсә, кан чыкмыймы бездән? Кытыклаганда көлмибезме? Агулаганда үлмибезме? Әгәр дә безне мыскыл итсәләр, без үч алырга тиеш түгелмени? Һәрьяктан сезгә охшыйбыз икән, бу яктан да сезгә охшыйсыбыз килә. Әгәр дә яһүд христианны җәберләсә, христианның тыйнаклыгы аңа нишләргә куша? Үч алырга. Әгәр дә христиан яһүдне җәберләсә, христиан үрнәге буенча ул нишләргә тиеш була? Шулай ук үч алырга. Сез безне кабахәтлеккә өйрәтәсез икән, мин аны эшлим инде. Бу эштә мин өйрәтүчеләрнең үзләреннән уздырачакмын.

Хезмәтче керә.

Хезмәтче. Синьорлар, минем хуҗам синьор Антонио хәзер өйдә. Ул сезнең икегез белән дә сөйләшергә тели.

Саларино. Ә без аны эзләп йөрибез.

Тубал керә.

Саланио. Әнә шул ук токымның тагын бер кешесе килә. Иблис үзе, яһүдкә әверелеп, яннарына килеп басмаса, боларга охшаган өченче кешене таба алмассың.

Саларино, Саланио һәм хезмәтче чыгып китәләр.

Шейлок. Йә, нихәл, Тубал? Генуяда нинди яңалыклар бар? Кызымны тапмадыңмы?

Тубал. Аның хакында күп җирдә ишеттем, әмма таба алмадым.

Шейлок. Алай икән. Алай, алай! Димәк, Франкфуртта ике мең алтын түләп алган бриллиант юкка чыкты. Моңарчы безнең нәселгә каһәрнең бу кадәр катысы төшмәгән иде әле. Мондый зур хәсрәтне моңарчы беркайчан да татыганым юк иде. Бер бриллиантта ике мең алтын, өстәвенә иң кыйммәтле асылташлар да ычкынды. Шушы бриллиантларымны колакларына киеп, кызым күз алдымда үлеп ятса, артыграк булыр иде. Аяк астыма күмсеннәр иде үзен, алтыннарымны табутына салсыннар иде... Алтыннар турында да ишетелмиме? Әлбәттә! Эзләү өчен генә дә күпме чыкты! Аһ, каһәр суккыры! Зыян өстенә зыян... Карак фәлән кадере чәлдерде. Аны эзләү фәлән хакка төште. Әмма эзләүдән канәгатьләнү, үч кану дигәннең эзе дә күренми. Минем башыма төшкән мондый афәт дөньяда юктыр! Шулкадәр иңрим, шулкадәр яшь түгәм, бер Ходай үзе белә минем хәлне!

Тубал. Бәхетсезлек дигәнең башкаларга да юлыга. Әнә Антонио. Генуядан ишетеп кайттым...

Шейлок. Нәрсә? Нәрсә? Бәхетсезлек? Бәхетсезлек дисеңме?

Тубал. Триполидан кайтып килгән корабы һәлак булган.

Шейлок. Аллага шөкер! Аллага шөкер! Чынмы бу? Чынмы?

Тубал. Кораб һәлакәтеннән котылып исән калган берничә матрос белән сөйләштем мин.

Шейлок. Рәхмәт яусын үзеңә, саф күңелле Тубал! Яхшы хәбәрләр китердең. Яхшы! Ха-ха! Кайда дисең әле? Генуяда дисеңме?

Тубал. Кызыгыз Генуяда бер кичтә сиксән алтын исраф иткән дип ишеттем.

Шейлок. Бәгыремә хәнҗәр кадыйсың ич! Ул алтыннарымны бүтән күрә алмам мин. Берьюлы сиксән алтын! Сиксән алтын!

Тубал. Минем белән Венециягә Атнонионың берничә кредиторы килде. «Антонио һичшиксез банкротка чыгачак», — ди алар.

Шейлок. Моңа мин шат! Эшен бетерәм мин аның! Башын ашыйм! Моңа мин бик шат!

Тубал. Шуларның берсе йөзек күрсәтте миңа. Кызыгыздан маймылга алмаштырып алган.

Шейлок. Каһәр генә суксын! Син җәзалыйсың мине, Тубал! Минем йөзегем ул, фирүзә кашлы. Миңа аны егет чагымда Лия бүләк иткән иде. Ул йөзекне мин, маймыллар тулы урман бирсәләр дә, ычкындырмас идем кулдан.

Тубал. Антонио харап булды. Монысы хак.

Шейлок. Анысы дөрес, бик дөрес!.. Бар, Тубал, алдан ук приставны сатып ал. Түләү срогына ике атна калгач, ул шәһәрдән чыгып, кая да булса китсен. Антонио бурычны вакытында түләмәсә, мин аның йөрәген уеп алам. Пристав Венециядә юк чакта теләсә ни эшли алам мин. Бар, тиз бул, Тубал! Синагогада очрашырбыз; бар, сөекле Тубал.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бельмонт. Порция өенең бер бүлмәсе. Бассанио, Порция, Грациано, Нерисса
һәм хезмәтчеләр керәләр.

Порция

Ашыкмагыз, көтегез ике-өч көн,
Бәхетегезне сынарга өлгерерсез.
Ялгышсагыз, бөтенләйгә җуям сезне.
Ашыкмагыз. Гыйшык димим, күңелемдә
Нindидер хис югалтмаска куша сезне.
Билгеле, әгәр ул хис нәфрәт булса,
Мондый киңәш бирмәс идем. Шулай да мин
Аңлатырга телим сезгә (гәрчә кызга
Сүз сөйләүдән дәшмәү шәбрәк саналса да).
Әйтим инде: бәхетегезне сынаганчы,
Бер-ике ай шунда тотар идем сезне.
Ничек сайлау кирәклеген әйтә алмыйм...

Әйтсәм, антны бозган булам. Юк, юк, әйтмим...
Әгәр дә сез ялгышсагыз? Ул чак нигә
Гөнаһ кылмадым икән дип үкенермен.
Аһ, каһәрле күзләр! Мине сихерләде,
Икегә бүлде: ике кисәк булдым хәзер.
Берсе — сезгә, берсе — сезгә... юк ла, үземә...
Үземә дисәм дә, ул — сезгә, барысы — сезгә.
Аһ бу язмыш, киртә куя арабызга.
Мин сезнеке, ләкин сезгә була алмыйм...
Ялгышсагыз, сезгә була алмасам мин,
Сез язмышны ләгънәтләгез, мине түгел.
Бик күп сөйлим. Вакыт әкрен узсын иде.
Сайлау вакытын озаккарак сузасы иде.

Бассанио

Сайлыйм инде! Юкса миңа болай яшәү —
Үзе җәза!

Порция

Ничек җәза? Йә, әйтегез,
Ни чагыла гыйшкыгызда, хыянәтме?

Бассанио

Хыянәт юк. Күңелемә шик урнашкан.
Бәхетемә ышанырга ирек бирми.
Боз белән ут дуслашса да, минем гыйшкым
Хыянәт белән мәңге дуслашалмас.

Порция

Җәзалаудан куркып сөйләмисез микән?
Андый чакта әлләниләр әйтә кеше.

Бассанио

Бирегез миңа яшәү — барысын сөйләп бирәм.

Порция

Сөйләгез дә яшәгез.

Бассанио

«Һәм сөегез».
Менә минем сөйләр сүзем. Палачкаем
Ничек җавап бирергә үзе өйрәтә!
Мондый җәза — татлы җәза, җан рәхәте!
Җибәрегез тартмаларга — язмышыма.

Порция

Йә, килегез!

Тартмаларны каплаган пәрдәне ача.

Тартмаларның берсендә — мин,
Әгәр мине яратсагыз, табалырсыз.
Нерисса, сез читкәрәк китегез бераз,
Сайлаганда музыка да уйнап торсын.
Ялгыша икән, аккош кебек, саубуллашып,
Ул җыр белән китсен моннан бөтенләйгә.
Чагыштыру төгәлрәк булсын өчен
Шунсын да әйтим: минем кайнар күз яшьләрем,
Дулкын булып, аккош мәетен кочакласын.
Әгәр отса... ул моң ничек яңгырар дисең?
Яңа гына таҗ киюче падишаһны
Тәхеткә менү белән котлар ул моң.
Яшь кияүне никахка чакыра торган
Тантаналы илаһи җыр булып яңгырар.

Әнә килә, күркәмлектә Трояны
Корбан таләп итүче аждаһадан
Коткарган яшь Геркулестан һич ким түгел;
Мәхәббәте белән аннан бик күп өстен,
Мин бичара корбан төсле аждаһага.
Читтәгеләр — аждаһадан коткарганны
Күзәтүче, елый-елый шешенеп беткән
Кызлар кебек, миңа ни буласын көтә.
Килче, килче, Геркулесым!
Син яшәсәң, мин дә яшим. Бу сугышта
Синнән бигрәк үзем куркам.

Бассанио тартмаларны караганда җыр яңгырый.

**Җыр**

Акылдамы туа гыйшык,
Йөрәктәме? Ничек итеп
Бу дөньяга килә соң ул?
Нинди сөтне имә соң ул?
Әйтче, зинһар,
Әйтче, зинһар.
Гыйшык элек күздә туа,
Елмаюдан ул тук була.
Бишегендә үк юк була,
һәм ул гүргә керә шуннан,
Матәм яңгырый:
— Дин-даң, дин-даң!

Барысы бергә

Дин-даң, дин-даң,
Дин-даң, дин-даң!

Бассанио

Тышкы кабык эчке якны күрсәтми ул.
Тәти бизәк бик еш алдый бу дөньяда.
Әнә судта адвокатлар, матур сөйләп,
Күренеп торган җинаятьне каплап кала.
Диндә дә нәкъ шулай бит ул, җаен белсәң,
Иң әшәке, иң кабахәт бозыклыкны
Изге итеп күрсәтергә табыла фәтва.
Тыштан изге күренмәгән шакшылык юк.
Комнан ишкән баскычка тиң куркаклар бар.
Сакалының муллыгына караганда,
Геркулестай йә Марстай мәһабәт ул.
Әмма баксаң, куян кебек куркак үзе.
Башкаларны шомландыру өчен генә,
Йөзләрендә ирләр төсе йөртә алар.
Матурлыкны карагыз сез — аны да бит
Үлчәү белән үлчәп сатып алып була.
Шуңа күрә бу дөньяда
Башка сыймас хәлләр була. Зиннәтләре
Авырларның акыллары җиңел була.
Тыштан чибәр күренүче хатын-кызның
Бөдрә чәчен алып кара. Күп вакытта
Ул бөдрәләр бүтән баштан күчкән була,
Баш иясе күптән гүргә төшкән була.
Сары алтын безгә хаклык булып күренә.
Даһи акыл ияләрен алдар өчен,
Хәйләкәр заманыбыз шуңа төренә.
Әй син, күзне чагылдырган сары алтын,
Мидас ашамлыгы, сине сайлый алмыйм.
Син дә миңа кирәк түгел, кулдан-кулга
Тәңкә булып күчеп йөргән тонык көмеш.

Әмма сине, гади кургаш, әйткән сүзең
Янау булып күренсә дә, өстен саныйм.
Матур сүздән бигрәк синең гадилегең,
Фәкыйрьлегең күпне сөйли — сине сайлыйм.
Бәхет китер миңа, кургаш!

Порция

Ничек соң бу?
Шик һәм курку, өметсезлек, көнләү хисе
Кинәт кенә юкка чыкты. Чү, мәхәббәт!
Куанычлы хисләреңне авызлыкла.
Шатлык яшең-яңгырыңны туктат бераз.
Аһ, мәхәббәт! Бәхетле мин хәзер чиксез,
Бу шатлыкны күтәрә алмам дип куркам мин!

Бассанио

Кургаш тартманы ача.

Аһ, ни күрәм?! Синең рәсемең! Нурлы йөзең!
Моны нинди илаһи көч иҗат иткән?
Аһ, күзләре! Кыймылдый күк. Үз күзләрем
Хәрәкәтләнгәнгә шулай тоела микән?
Иреннәре ярым ачык. Татлы сулыш
Аерган аларны бер-береннән.
Ә чәчләре! Бу художник, үрмәкүчтәй,
Күңелләрне чебен кебек аулар өчен,
Алтын чәчтән пәрәвез үреп куйган.
Ә күзләре!
Ничек иҗат итә алган сукыраймыйча?
Миңа калса, моның берсен төшергәндә,
Художникның ике күзен югалтуы
Һәм рәсемне бетермәве мөмкин иде.
Минем хәзер әйткән сүзләр бу рәсемне
Мактау өчен никадәре зәгыйфь булса,
Рәсем үзе табигатьнең асылыннан
Шулкадәр үк зәгыйфь, ярлы. Менә кәгазь...
Язмышымны хәл итәчәк сүзләр шунда.
«Кызыкмадың тышкы ямьгә,
Ямьнең чынын теләгәнгә.
Өлешеңә чыккан көмешең,
Гыйшкың дөрли иде кем өчен?
Бу ярны тиң юлдаш иткән өчен,
Дөнья җәннәтенә кердең син,
Күңелеңдәге янган хисләреңне
Сөеклеңә үбеп белдер син!»
Изге әмер! Матур сүзләр! Синьора, кил,
Бу әмерне ахырынача үтим инде.

Порцияне үбә.

Шулай ике көрәшченең берсе, җиңгәч,
Каушап кала кинәт алкыш ишетелгәч.
Җиңүенә ышанса да, аптырый ул.
«Кайсыбызга соң бу алкыш?» — дип сорый ул.
Мин дә шулай сиңа карыйм. Барсын аңлыйм,
Син кул куеп беркетмичә, ышаналмыйм.

Порция

Сез күрәсез мине, синьор Бассанио,
Мин гади кыз. Әмма сезнең өчен

Алтмыш тапкыр кыйммәтлерәк булыр идем.
Тәкәбберлек өчен түгел.
Сезнең алда шәбрәк булып күренер өчен,
Йөз мәртәбә чибәррәк, зиһенлерәк,
Ягымлырак һәм баерак булса идем.
Әмма минем бар кыйммәтем бик кечкенә:
Гади бер кыз, белемем юк. Тик шуңа шат:
Карт түгел мин, белмәгәнне өйрәнә алам.
Барыннан да бигрәк шуңа бәхетле мин:
Тыйнак күңелем, акылым сиңа тапшырыла.
Буйсынам мин сиңа — күңелем патшасына!
Үзем дә һәм бар нәрсәм дә синеке хәзер.
Бу көнгәчә сараема ия идем,
Хезмәтчеләремә хаклы хуҗа идем,
Үз-үземә патша идем. Әмма бүген
Сараем да, хезмәтчеләр дә, үзем дә —
Барыбыз да синеке без, падишаһым!
Шушы йөзек белән бергә барысын бирәм.
Бу йөзектән аерылсаң яки җуйсаң,
Берәрсенә йә бүләккә биреп куйсаң,
Күңелемдәге мәхәббәтне сүндерерсең
Һәм үзеңне гаепләргә юл бирерсең.

Бассанио

Сез, синьора, мине телдән калдырдыгыз,
Дөпелдәгән йөрәгем генә җавап бирә.
Сөекле падишаһның җылы сүзен
Ишетеп күңелләре канатлангач,
Шатлыкларын аңлатырга сүз табалмый
Аптыраган халык төсле булдым инде;
Күңлемдәге бар хисләрем, бергә кушылып,
Чиксез шатлык давылына әверелде,
Әмма үзем шуны һич тә аңлаталмыйм.
Әгәр бу йөзектән аерылсам,
Гомерем дә бетәр минем. Ул чагында
Бассанио дөньяда юк дип белерсез.

Нерисса

Синьора һәм синьор, хәзер инде
Теләгегез үтәлгәнне күреп торган
Безгә дә сүз әйтергә рөхсәт итегез:
Тигез бәхет бирсен Ходай үзегезгә!

Грациано

Синьор Бассанио, сөекле синьорабыз,
Телим сезгә үз күңелегез теләгәнне,
Чөнки артык мин берни дә өсти алмыйм!
Берегезгә берегез биргән вәгъдәләрне
Тантаналы никах белән беркеткәндә,
Рөхсәт итегез, никахланыйм мин дә шулчак.

Бассанио

Чын күңелдән рөхсәт, әгәр кәләш тапсаң.

Грациано

Бик зур рәхмәт. Миңа кәләш сез таптыгыз.
Минем күзләр сезнекедәй җитез, синьор.
Сез бикәсен күргәнсез, мин — хезмәтчесен...
Сезнең кебек мин дә гашыйк булып йөрдем,
Сезнең күк мин дә сузарга һич яратмыйм.
Сезнең язмыш кебек минем язмышым да

Шул ук тартма эчендә яткан икән.
Сөеклемне куып йөреп тирләп беттем.
Аңа антлар итә-итә тамак кипте,
Һәм, ниһаять, кызның күңелен яулый алдым,
Ризалыгын бирде, ләкин бер шарт белән,
Бикә, диде, сезнең белән никахлашса.

Порция

Дөресме бу, Нерисса?

Нерисса

Дөрес, бикәм.
Сезнең рөхсәт кенә кирәк.

Бассанио
*(Грацианога)*

Син дә чынлап сөйлисеңме?

Грациано

Әйе, синьор!

Бассанио

Сезнең туегыз бизәр безнең мәҗлесне дә.

Грациано

Әйдә бәхәсләшик. Кайсыбызда
Алдан малай туса — шуңарга мең алтын!

Нерисса

Барын да картага салабызмы?

Грациано

Барын да картага салсаң, башыңны җуюың бар.
Кемнәр соң бу килә монда? Лоренцо бит,
Мөлаем яһүд кызы белән бергә.
Тегесе кем? Иске дускай Салерио.

Лоренцо, Джессика, Венеция йомышчысы Салерио керәләр.

Бассанио

Лоренцо, Салерио, хуш киләсез... —
Кинәт хуҗа булдым бугай мин бу йортка. —
Рөхсәт ит, фәрештәм, якташларны
Һәм дусларны кунак итеп каршыларга.

Порция

Аларның килүенә мин дә бик шат.

Лоренцо

Рәхмәт сезгә, синьора.
*(Бассаниога.)*
Башта минем
Сезнең янга килү уе һич юк иде.
Юлга чыккач, Салерионы очраттым.
Ә ул мине, ай-ваема карамыйча,
Бирегә алып килде.

Салерио

Әйе. Кирәк өчен алып килдем. —
Сезгә синьор Антониодан кайнар сәлам.

Бассаниога хат бирә.

Бассанио

Хатны ачмас борын сорыйм әле: дустым ничек яши?

Салерио

Күңел җәрәхәтен искә алмаганда,
Авыру түгел, шулай ук ул сау да түгел.
Хатны ачкач, барысы аңлашылыр.

Бассанио хатны укый.

Грациано

Нерисса, чит ил кызына ягымлы бул,
Бир кулыңны, Салерио.
Венеция шәһәрендә ни хәлләр бар?
Зур сәүдәгәр Антонио ничек яши?
Безнең уңыш аны чиксез куандырыр.
Без, Язоннар кебек, җиңеп чыктык монда —
Алтын тире — безнең кулда.

Салерио

Ул югалткан алтыннарны тап идегез.

Порция

Хатта начар хәбәр бардыр — төсе качты,
Дусты үлде микән әллә? Ир кешене
Башка нәрсә үзгәртә алмас бу кадәре.
Ул агара бара һаман! Бассанио!
Мин бит синең ярты җаның. Шулай булгач,
Хатка язган хәбәрләрне миңа да әйт.

Бассанио

Аһ, сөеклем! Бу кадәре хәтәр сүзләр
Беркайчан да язылган булмагандыр.
Мәхәббәтем аңлатканда, мин бит сиңа
Бар байлыгымны үземдә дигән идем.
Мин бу сүзне чын күңелдән әйттем сиңа,
Әлбәттә, бу дөрес. Ләкин хәзер күрәм,
Үземне иң фәкыйрь итеп күрсәтсәм дә,
Синең алда мин мактанган булып калам.
Фәкыйрьдән дә фәкыйрьрәк дигән булсам,
Дөресрәк булыр иде. Акча өчен
Мин үземне җан дустыма,
Ә дустымны дошманына заклад салдым.
Менә аның язган хаты. Ә бу кәгазь
Җан дустымның тәне гүя. Һәрбер сүзе —
Авыр яра, ялалардан каннар тама. —
Дөресме бу, Салерио? Корабларның
Барысы да һәлак булды микәнни соң?
Триполидан, бәрбәрләрдән, Мексикадан,
Һиндстаннан, Англиядән, Лиссабоннан
Кайта торган корабларның барысы да
Ташка бәрелеп ватылганмы? Берәүсе дә
Котылып исән калмаганмы?

Салерио

Юк, берсе дә.
Аннан шунсы да бар: хәзер Антонио
Акчасын бирә алса да, алмый яһүд.
Үтә явыз, бу кадәре мәрхәмәтсез,
Кешене юк итәргә әзер торган
Адәм кыяфәтенә кергән ерткычны һич
Күргәнем юк.
Дожның саруын кайната ул:

Көн-төн шунда. «Әгәр дә суд
Таләбемне кире какса, — ди ул аңа, —
Республика абруена тап төшә», — ди.
Сенаторлар, сәүдәгәрләр, Дож үзе дә:
«Ниятеңнән кайт», — дип, бик нык үгетлиләр.
Ләкин кая! Күнәме соң? Ул һаман да
Үзенекен тукый: «Кайда гаделлек?» — ди.

Джессика

Минем алда ант итте ул — ишетеп тордым —
Якташлары Тубал һәм Хус килгән иде.
«Акчаны, — ди, — егерме кат артык итеп
Китерсә дә, кабул итеп барыбер алмыйм,
Антонионың итен артык күрәм мин», — ди.
Әгәр закон, югары суд һәм хөкүмәт
Яклашмаса, Антонионың эше харап.

Порция

Ул бичара синең якын дустыңмы, әйт?

Бассанио

Иң-иң якын дустым. Менә дигән кеше.
Армый-талмый изгелекләр эшли һаман.
Бөтен Италияне бетереп эзләсәң дә,
Күңелендә борынгы римлыларның
Рухи көчен шундый итеп чагылдырган
Бүтән кешене син барыбер табалмыйсың.

Порция

Яһүдкә ул күпме тиеш?

Бассанио

Минем өчен өч мең алтын алган иде.

Порция

Шул гынамы?
Бар, алты мең итеп түлә,
Вексельне ал... унике мең бир, кирәксә.
Унсигез мең итеп түлә. Тиз бул ләкин...
Шундый якын, дус кешенең синең өчен
Чәчләренең бөртеге дә коелмасын.
Без чиркәүгә кереп башта никахланыйк,
Аннан туры Венеция шәһәренә,
Дустыңны коткарырга, тиз бул, ашык!
Күңелеңне шомлы уйлар борчыганда,
Яр куенында тыныч ятып буламы соң?
Алтын бирәм. Ул бурычны егерме кат
Кайтарырлык итеп түлә. Аннан монда
Кайтыгыз сез алып якын дустыгызны.
Без Нерисса белән монда икәүләшеп
Сезне кызлар һәм толлар булып көтәрбез.
Әйдә ашык, туй көнендә китәсең син,
Йөзең ачык булсын. Дуслар очраганда
Чытык чырай күрсәтмә син берсенә дә.
Йә, дустыңның хатын укып күрсәт миңа.

Бассанио *(укый)*. «Сөекле Бассанио, корабларымның барысы да һәлак булды. Кредиторларым рәхимсез, хәлем бик начар. Яһүдкә биргән векселемнең срогы чыкты. Бурычны вексельгә язылган шарт буенча түләгәч, мин исән калмам инде. Шуңа күрә арадагы исәп-хисапны беткән саныйбыз. Минем тик бер генә теләгем бар: үлем алдыннан сине күрәсем килә. Үз мөмкинлегеңнән чыгып эш ит. Кирәк тапсаң, кайт. Булмый икән, хатым сине борчымасын».

Порция

Бар, сөеклем! Эшеңне ташла да кит!

Бассанио

Иркәм, синнән рөхсәт икән — китәм, китәм!
Өйләнеп кайтканчы мин һич ял итмәм.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Венеция. Урам.
Шейлок, Саларино, Антонио һәм төрмә сакчысы керәләр.

Шейлок

Син, төрмәче, яхшы кара! Мәрхәмәт юк.
Бушлай бурыч өләшүче дивана бу!
Яхшы кара.

Антонио

Тыңласана, Шейлок.

Шейлок

Минем вексель! Аңа каршы бер сүз әйтмә.
Язылганча түләтергә мин ант иттем.
Бер дә юкка мине эт дип хурладың син.
Әйе, мин эт! Саклан минем тешләремнән!
Дож, һичшиксез, гадел булыр... Әй, төрмәче!
Мин аптырыйм сиңа, үтә томана син;
Ул сорый дип, урамнарда йөретәсең.

Антонио

Зинһар, мине тыңласана...

Шейлок

Минем вексель! Тыңламыйм бер сүзеңне дә.
Язылганча түлисең син, бетте-китте.
Юк, мин андый ахмак түгел, җебеп төшмәм,
Христианнар ялына дип аһ-вах килмәм.
Тыңламыйм! Юк! Язылганча түләттерәм!

Китә.

Саларино

Нинди кансыз! Бу кадәре явыз этне
Күргәнем юк иде минем.

Антонио

Китә бирсен!
Мәгънәсезгә шуңа ялынып торыйммыни.
Миңа үлем тели бит ул. Ник икәнен
Ачык беләм. Аның тозагына төшкән
Бик күпләрне коткардым мин. Шуңа мине
Дошман күрә.

Саларино

Мин ышанам, Дож юл куймас,
Мондый шартны үтәргә ул ирек бирмәс.

Антонио

Дож законны боза алмый. Законда бит
Чит ил халкы өчен махсус хокуклар бар.
Аны бозсаң, башка илләр каршысында
Безнең дәүләт ышанычсыз булып кала.

Ә бит безнең сәүдәбез дә, файдабыз да
Бөтен илләр белән бәйле. Шулай булгач,
Сүзне туктат... Югалтулар, кайгы-хәсрәт
Шулкадәре изде мине, ул кансызга
Минем тәндә бер кадак ит табылыр микән.
Әйдә киттек! Ходай кушып, Бассанио
Тизрәк кайтып керсен иде. Аның бурычын
Ничек итеп түләгәнне күрсен иде.
Калган ягы, ни булса да, барыбер миңа.

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бельмонт. Порция өенең бер бүлмәсе. Порция, Нерисса, Лоренцо, Джессика һәм Бальтазар керәләр.

Лоренцо

Синьора, мин күзегезгә карап әйтәм:
Чын дуслыкның нинди изге хис икәнен
Сез аңлыйсыз тирән итеп, бөтен яктан.
Изге дуслык бурычын үтәү хакына сез
Никах көнне өзелеп сөйгән ярыгыз белән
Аерылышу газабын кичерәсез.
Әгәр дә сез ул кешенең кем икәнен,
Күңелендәге хисләренең гүзәллеген,
Ирегезне ничек якын күргәнлеген
Белсәгез, аһ, синьора, күңелегездә
Горурлык хисе тагы үсәр иде.

Порция

Җае килеп ярдәм кулы сузган өчен
Үкенергә бер дә туры килгәне юк.
Бу юлы да үкенмәм мин. Бит гадәттә
Дуслык йөген бергә тартып, гомерләрен
Бергә үткәргән кешеләрнең йөзләре дә,
Гореф-гадәт, эшләре дә, рухлары да
Бер-беренә бик нык охшый; һәм мин уйлыйм,
Антонио да, иремнең җан дусты булгач,
Нәкъ шундый ук кешедер дип.
Үземә якын кешенең рухын-җанын
Явыз шайтан тырнагыннан йолар өчен
Бик кечкенә хезмәт бит бу... Ярый, җитте,
Мактануга охшап китте... Йә, Лоренцо,
Ирем кайтканчыга чаклы хуҗалыкны,
Йорт-җиремне — барысын сиңа тапшырам мин.
Күңелемнән шундый нәзер әйткән идем:
Ирләребез кайтканчы, Нерисса белән
Икәү генә калып, бөтен вакытымны
Гыйбадәттә үткәрермен дигән идем.
Безнең өйдән
Нәкъ ике миль ераклыкта монастырь бар.
Шунда барып торырбыз без. Зинһар өчен,
Баш тартмагыз.

Лоренцо

Ни кушсагыз да, синьора,
Рәхәтләнеп үтим барысын.

Порция

Бу теләкне хезмәтчеләр бар да белә,

Алар сезгә, Джессика белән икегезгә,
Мине тыңлаган шикелле буйсынырлар.
Сау булыгыз. Озакламый күрешербез.

Лоренцо

Якты уйлар җитәкләсен. Хәерле юл!

Джессика

Шатлык тулсын күңелегезгә.

Порция

Бик зур рәхмәт,
Үзегезгә дә шуны телим. Хуш, Джессика.

Джессика һәм Лоренцо чыгып китәләр.

Йә, Бальтазар, син һәрвакыт тугры идең,
Намуслы идең, моннан соң да шулай ук бул.
Ал бу хатны. Падуяга ашык тизрәк.
Мөмкин кадәр тизләт адымың! Абзыкайның —
Мәшһүр доктор Белларионың үз кулына
Илтеп тапшыр. Ул хат бирер. Кием бирер.
Син шуларны бик тиз генә су буена —
Венеция паромына китереп җиткер.
Күп сөйләнмә. Тиз бул. Шунда көтәрмен мин.

Бальтазар

Мөмкин кадәр тиз йөрергә тырышырмын.

Китә.

Порция

Киттек, Нерисса. Бер план уйладым мин,
Аны син белмисең әле... Аларны без
Алданрак күрә алырбыз.

Нерисса

Алар безне күрерләрме?

Порция
О! Күрерләр!
Ләкин шундый киемнәрдә булабыз ки,
Күргәч, бездә һич булмаган нәрсәне дә
Бар диярләр. Бәхәсләшә алам хәтта!
Әгәр дә без ирләр киеме киеп алсак,
Күрерсең, мин менә дигән малай булам.
Кылычны мин йөртәм синнән әйбәтрәк.
Малай тавышын ир тавышына үзгәртә алам.
Үземнең вак адымнарны эреләтәм.
Дуэльләрдә сугыштым дип шапырынырмын;
Хатын-кызлар артымнан калмый, диеп,
Мин ташлаган кызлар сарыга сабыштылар,
Кайберләре үлде, диеп очыртырмын;
Нишлим, монда мин гаепсез; тик шулай да
Кызганам үзләрен, дип көрсенермен.
Егермеләп шундый тузга язмаганны
Лыгырдасам, — мине мәктәп тәмамлаган
Малай икән дип барысы да ышанырлар.
Нәкъ шушындый мактанчыклар сөйли торган
Шаккатыргыч мәзәкләр бар, аларны да
Ходка җибәрергә була бик әйбәтләп!

Нерисса

Ирләр булып барабызмы?

Порция

Фу, мәгънәсез. Нинди сорау бирәсең син?
Берәрсенең тыңлавы бар. Әйдә киттек.
Барысын да аңлатырмын бәйнә-бәйнә.
Парк янында карета көтә безне,
Ашык тизрәк, Нерисса, вакыт бик тар,
Бүген безнең егерме миль барасы бар.

Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук. Бакча.
Ланчелот һәм Джессика керәләр.

Ланчелот. Шулай инде ул. Аталарның гөнаһлары балаларга төшә. Шуңа күрә, валлаһи дип әйтәм, сезнең өчен бик куркам мин. Һәрвакыт күңелемдәген ачыктан-ачык әйтә килдем. Хәзер дә дөресен сөйлим: гомерлек тәмуг сезгә. Монда инде бер генә өмет кала... Ләкин ул өмет тә тегенди-мондый гына, уйнаштан туган бала кебек.

Джессика. Нинди өмет соң ул?

Ланчелот. Бәлки, шуңар өметләнеп булыр иде... Әйтик, сезнең дөньяга килүегезгә атагызның бернинди дә катнашы юк. Сез яһүд кызы да түгел...

Джессика. Чыннан да, уйнаштан туган өмет бу. Ул чагында минем өскә әнкәй гөнаһы төшәргә тиеш була.

Ланчелот. Әнә шуңа күрә әйтәм дә, әтиегез ягыннанмы, әниегез ягыннанмы — барыбер сезгә гомерлек тәмуг. Котылуы авыр булачак.

Джессика. Ирем коткарыр әле, мине ул христиан ясады ич.

Ланчелот. Дөресен әйткәндә, моның өчен аны мактап булмый. Христианнар ансыз да җитәрлек, тамаклары да тук. Һәркемне болай христиан ясый башласалар, дуңгыз итенең кыйбатлануы ихтимал. Барыбыз да дуңгыз ашый башласак, бер калҗа ит күрергә тилмерерсең.

Джессика. Син әйткәннәрнең барын да иремә сөйләрмен, Ланчелот. Әнә үзе дә килә.

Лоренцо керә.

Лоренцо. Почмак саен хатыным белән болай пышылдасаң, иялләшә башлармын мин, Ланчелот.

Джессика. Сиңа монда куркырлык нәрсә юк, Лоренцо. Без Ланчелот белән килешә алмыйбыз әле. Ул әйтә, сиңа, ди, теге дөньяда бернинди шәфкать булмаячак, ди. Мин яһүд кызы, янәсе. Сине дә гаепли, республиканың алама гражданины, ди. Яһүдләрне христианга әйләндереп, дуңгыз итен кыйбатлата, ди.

Лоренцо. Республика каршында минем гаебем синеке кадәр үк түгел. Син анда негр кызын юанайткансың, гарәп кызы синнән авырга калган бит, юньсез.

Ланчелот. Анысы әле хәзергә күренми... Ярый, шулай да булсын ди. Моңа ул үзе гаепле, шундый ягымлы итеп карамасын...

Лоренцо. Һәрбер җүләр сүз уйната белә. Озакламый дәшми утыручыларны — сүз остасы дип, күп сөйләүчеләрне попугай дип йөртәчәкләр... Бар, әйт, төшке ашка барысы да әзер булсын.

Ланчелот. Барысы да әзер, синьор, барысының да аппетиты ачылган.

Лоренцо. Ярабби Ходаем, бу нинди тел бистәсе. Алайса, аш әзерләргә куш.

Ланчелот. Анысы да әзер, синьор. Табын җәясе генә бар.

Лоренцо. Җәй алайса.

Ланчелот. Җәеп салмасам да белгәнсез бит әле... Гарәп кызын дим.

Лоренцо. Тагын телеңә салынасың. Бөтен сүз байлыгыңны берьюлы тотып бетерергә уйлыйсыңмы әллә? Тыңла менә, гади сүзне гади генә итеп аңла. Иптәшләреӊ янына кер дә табын әзерләргә куш, аш куйсыннар, без тиздән керәбез.

Ланчелот. Табыны да әзерләнер, ашы да куелыр — монысы безнең эш. Әмма ашарга керү яки кермәү — анысы сезнең ихтыярда.

Китә.

Лоренцо

Аһ син, акыл! Никадәре лыгырдады!

Җыен тозсыз сүзләр җыйган зиһененә.
Хәер, моннан күп мәртәбә өстен торган
Шундый ахмак абзыйлар да бар бит әле.
Алар да бит бер үткен сүз әйтү өчен
Мәгънәдән читкә чыгып йөгерәләр...
Йә, Джессика, кәефең ничек? Әйтче, иркәм,
Бассанионың кәләшен ошаттыңмы соң?

Джессика

Гаҗәеп кыз! Хәзер синьор Бассанио
Әйбәт итеп көн итәргә тиеш була.
Шундый гүзәл кызга ия булды,
Дөньяда ук җәннәткә иреште ул.
Әгәр шуны аңламаса ул дивана,
Моннан соң һич насыйп булмас җәннәт аңа,
Аннан да шәп кыз табылмас бу дөньяда.

Лоренцо

Кешеләрнең иң әйбәте: ирләрдән — мин,
Кызлардан — ул.

Джессика

Минем фикеремне белү
Һич тә зыян итмәс иде.

Лоренцо

Сорармын. Тик башта ашап алыйк әле.

Джессика

Юк, син хәзер сора.
Аппетитым бар чагында әйтеп калыйм.

Лоренцо

Аппетитың бар чагында ашап кал син.
Бу сүзләрне аш янында сөйләшербез.
Мин дә аны әйбәтрәк сеңдерермен.

Джессика

Чыда гына, бирәм хәзер кирәгеңне!

Китәләр.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Венеция. Суд залы.
Дож, сенаторлар, Антонио, Бассанио, Грациано, Салерио һәм башкалар керәләр.

Дож

Антонио мондамы соң?

Антонио

Әйе, монда, җәнабе гали.

Дож

Бик кызганыч синең хәлең.
Дошманың таш кебек каты.
Мәрхәмәтсез, миһербансыз, үтә кансыз,
Шәфкать дигән нәрсәнең юк әсәре дә.

Антонио

Мин ишеттем, җәнабе гали, аның күңелен
Йомшартырга тырышкансыз. Нишлисең бит,
Шулкадәре кире икән, законыбыз
Мине аннан аралый алмый икән.
Бер генә юл: аның кыргый ярсуына
Сабырлыгым белән җавап бирермен мин.
Таянып күңелемдәге тынычлыкка,
Аның җәберен, ерткычлыгын күтәрермен.

Дож

Барыгыз, Шейлокны чакырыгыз.

Салерио

Әнә ишек төбендә ул, җәнабе гали.

Шейлок керә.

Дож

Юл бирегез, каршыбызга килеп бассын.
Шейлок, мин дә, башкалар да болай уйлый:
Син бит эшнең ахырына җиткәнче генә
Кансыз булып күренергә тырышасың.
Аннан, кинәт шәфкатеңне игълан итеп,
Безне тагын ныграк хәйран итәрсең син.
Менә хәзер бу бичара сәүдәгәрнең
Бер кадак итен таләп итсәң дә син,
Аны алмау гына түгел, шәфкать итеп
Хәтта ярты бурычын да кичерерсең.
Чөнки күреп торасың бит үзең дә син
Нинди каза-афәтләргә тарыды ул.
Падишадай сәүдәгәр тәмам бөлде.
Таш күңел дә йомшарыр мондый хәлгә.
Шейлок, синнән ипле җавап көтәбез без.

Шейлок

Аңлаттым бит инде сезгә, җәнабе гали:
Вексельдә язылганча түләтәм мин.
Изге шимбә көнне мин ант иттем, дидем.
Бу дәгъваны әгәр кире каксагыз сез,
Венеция законнарын, сәүдә иркен,
Хокукларны таптыйсыз сез. Ни сәбәптән
Бу үләксә итен өч мең алтыннан да
Артык күрә дип сорарсыз. Җавап бирмим.
Бирәм икән, әйтәм. Минем зәүкым шундый.
Нәрсә, җавап түгелме бу? Йорт-җиремне
Күсе-тычкан басып алса, мин шуларны
Кырып бетерү өчен өч мең алтын тотсам,
Ни диярсез? Нәрсә, җавап түгелме бу?
Берәү, дуңгыз башын күрсә, укшый башлый.
Берәү, мәче күреп калса, шашып китә.
Берәү, сорнай уйнаганны ишетеп калса,
Бәвелен тота алмый башлый. Табигать бу.
Адәмнең бар хисләренә хуҗа булып,
Йә мәхәббәт яки нәфрәт кузгата ул.
Менә сезгә минем җавап. Дуңгыз башын,
Һич гаепсез мәчене һәм сорнай тавышын
Шулкадәре яратмауны, ул халыкның
Үзләре газапланган өчен генә
Башкаларны газаплау хурлыгына
Төшкәнлеген аңлатып булмаган кебек,
Мин дә мондый файдасыз дәгъва белән

Гадел хөкем каршысына килүемне
Аңлаталмыйм, аңлатырга теләмим дә.
Шуны гына әйтәм сезгә: Антонионы
Җенем сөйми минем, үлеп дошман күрәм.
Нәрсә, җавап түгелме бу?

Бассанио

Юк, ерткыч, юк,
Кансызлыкны аклый алмый мондый җавап!

Шейлок

Акланырга уйламыйм да!

Бассанио
Яратмаган
Һәр кешене үтерергә дигәнмени?

Шейлок

Хак дошманын кем үтерми?

Бассанио
Бер сүз өчен
Кинәт кенә дошман күреп буламыни?

Шейлок

Кара елан икенче кат чаксын, димәк?

Антонио

Зинһар өчен, бәхәсләшмә яһүд белән,
Куйчы, зинһар. Бу бит яр буена басып,
Ярга сукма дип дулкынга ялынган күк,
Ник сарыкның бәрәнен ашадың дип,
Бүрене оялтырга тырышу бит бу.
Җил-давылда чайкалучы наратларга
«Тын гына тор, селкенмә» дип буламыни?
Яһүд күңлен йомшартырга уйлама да,
Аннан каты бернәрсә юк бу дөньяда!
Зинһар, юкка ялынмагыз, көч түкмәгез,
Яһүднең бар таләбенә юл куегыз.

Бассанио

Өч урынына мин алты мең бирәм.

Шейлок

Һәр алтының алтышарга бүлгәләнеп,
Һәр кисәге бер алтынга әйләнсә дә,
Барыбер алмыйм. Куйган шартны үтәсен ул.

Дож

Үзең шундый кансыз булгач,
Нинди шәфкать көтәсең син?

Шейлок
Законнан тыш
Бер эшем юк. Ни өчен мин судтан куркыйм?
Барыгызның сатып алган коллары бар,
Сез аларны ишәк, качыр, эт урынына
Шакшы эшләргә куасыз һәр көн саен.
Ник куасыз? Акча түләп алгангамы?
Әгәр дә мин: «Бирегез ирек ул колларга,
Өйләнсеннәр сездән туган яшь кызларга,
Сезнекедәй түшәкләрдә йокласыннар,
Сездәй тәмле ашасыннар», — дисәм әгәр,

«Ул коллар бит — минем милкем», — диячәксез.
Мин дә әйтәм: «Бер кадак ит — минем милкем,
Зур акчага сатып алдым мин ул итне.
Ул минеке, таләп итәм». Әгәр дә суд
Кире какса, хурлык сезнең законнарга!
Чүп тә тормый, димәк, сезнең ул законнар.
Җавап көтәм, буламы ул гадел хөкем?

Дож

Шушы эшне тикшерергә дип чакырткан
Мәшһүр доктор Белларио килмәгәнгә,
Утырышны кичектерү ягында мин.

Салерио

Җәнабе гали, менә монда Падуядан,
Доктордан хат алып килгән берәү көтә.

Дож

Монда керсен. Хатны миңа тапшырыгыз.

Бассанио

Антонио, рухыңны син һич төшермә,
Үз канымны, үз җанымны бирсәм бирәм,
Әмма синнән бер тамчы кан түктермәм мин.

Антонио

Көтүдә иң кабахәт сарык бит мин.
Мине әҗәл көтеп тора. Агачтагы
Зәгыйфь җимеш элегрәк төшә җиргә.
Мин җан бирим. Ә син яшә, Бассанио,
Васыятем шул: каберемә таш куярсың.

Адвокат сәркатибе киеменнән Нерисса керә.

Дож

Падуядан килдегезме?
Сезне доктор Белларио җибәрдеме?

Нерисса

Әйе, җәнабе гали, сезгә сәлам әйтте.

Аңа хат бирә.

Бассанио
*(Шейлокка)*

Тырышып-тырышып нигә пычак кайрыйсың син?

Шейлок

Банкроттан бурычым кисеп алыр өчен.

Грациано

Янама син пычагыңны кунычыңа,
Таш бәгъреңә янап кына үткерлә син.
Явызлыгың синең палач балтасыннан
Үткенрәк. Ялынуга да йомшамый ул.

Шейлок

Синең акылың җитми аңа, энекәшем.

Грациано

Каһәр генә төшсен сиңа, рәхимсез эт!
Табигатькә хурлык өчен тугансың син.
Иманым какшый башлый сине күргәч,
Мин ышана башлыйм хәтта Пифагорга:

«Хайван жаны кешегә күчә», — ди ул.
Бу әшәке жаның сиңа кешеләрне
Ашаганы өчен асып үтерелгән
Бүредән күчкән! Баудан качып, әнкәеңнең
Кабахәт карынына барып кергән;
Аннан сиңа тигән ул жан; әйе, шулай:
Бүре жаны, комсыз, кансыз, кабахәт жан!

Шейлок

Вексельдәге пичәтне син сүгенү белән
Бозалмассың. Бик акырма, үпкәң шартлар.
Акылыңа ямау салдыр, энекәшем.
Юкса тәмам рәте киткән. — Мин суд көтәм.

Дож

Белларио ниндидер бер зур гыйлемле
Яшь юристны тәкъдим итә. Кайда соң ул?

Нерисса

Монда, ерак түгел. Җавап көтә сездән.
Ничек, кабул итәсезме?

Дож

Бик шатланып. —
Каршылагыз үзен чыгып берәрегез.
Тиешенчә хөрмәтләп алып керегез.
Шул арада хатны укыйк.

Сәркатип *(укый)*. «Мәгълүм булсын, җәнабе гали, сездән хат килгәндә мин авырып ята идем. Чапкыныгыз килеп төшкән сәгатьтә миндә Римнан килгән яшь юрист утыра иде. Исеме Бальтазар. Мин аны сездән килгән эш белән таныштырдым. Үзем бара алмау сәбәпле, аны җибәрәм. Минем фикеремне ул сезгә җиткерер. Үтенәм сездән, аны сез, яшьлегенә карап, тиешле хөрмәттән мәхрүм итмәгез. Үз гомеремдә мондый акыллы яшь егетне күргәнем юк иде. Мин аны җәнабегезгә тапшырам. Егет минем бу фикеремне эше белән аклар».

Дож

Белларионың язганын ишеттегезме?

Порция керә. Ул хокуклар докторы киеменнән.

Менә доктор шулдыр инде, — кулыгызны!

Исәнләшә.

Белларио тәкъдим иткән егет сезме?

Порция

Әйе, җәнабе гали.

Дож

Яхшы, утырыгыз.
Бүген тикшерелә торган эш белән сез
Танышмы?

Порция

Бик җентекләп карап чыктым.
Сәүдәгәр кем? Яһүд кайсы?

Дож

Антонио, Шейлок карт, килегез бире.

Порция

Сез Шейлокмы?

Шейлок

Әйе, Шейлок минем исемем.

Порция

Суд каршына гаҗәп дәгъва куйгансыз сез.
Тик шулай да Венеция законнары
Дәгъваның мондыен да кире какмый.
*(Антониога.)*
Ә ул мондый дәгъвага хаклымы соң?

Антонио

Шулай ди ул.

Порция

Вексельне сез бирдегезме?

Антонио
Әйе.

Порция

Шейлок шәфкать күрсәтергә тиеш иде.

Шейлок

Тиеш дисез? Мине соң кем мәҗбүр итә?

Порция

Шәфкать өчен мәҗбүр итү кирәкмени?
Җиргә яуган җылы яңгыр шикелле ул.
Игелеген тоя аның һәр ике як:
Бирүче дә, алучы да. Шифалы ул.
Көчлеләрнең иң көчле коралы ул;
Патша өчен ул таҗдан да күркәмрәк.
Падишалык гөрзие ул — вакытлы көч,
Мәһабәтлек һәм ихтирам билгесе ул.
Падишаның гөрзие җир тетрәтә.
Әмма шәфкать гөрзи ише генә түгел,
Падишалар күңеленә падиша ул.
Шәфкать бит ул Алланың да төп сыйфаты.
Закон шәфкать аралашкан чакта гына
Җир хакиме илаһи бер көчкә охшый.
Әгәр закон шәфкатьтән читтәрәк торса,
Беребез дә исән калмас. Гыйбадәттә
Ходайдан һаман шәфкать сорыйбыз бит.
Мин дә бүген йомшартырга телим сине.
Әгәр дә син таләп итсәң, безнең закон
Сәүдәгәргә каты хөкем чыгарачак.

Шейлок

Минем эшем үз башыма! Мин законча
Гадел хөкем таләп итәм. Түләсен ул.

Порция

Ә ул сиңа акча түли алмыймыни?

Бассанио

Ала. Менә суд каршында ике хакын
Тәкъдим иттем. Аз дип тапса, ун мәртәбә
Арттырырга вәгъдә итәм. Кулым белән,
Башым, җаным белән мин ант итеп әйтәм,
Моны да аз дисә инде, ул чак, димәк,
Явызлыкның хакыйкатьне таптавы бу.
Зинһар өчен, власть көчен кулланыгыз.
Хаклык өчен, кечкенә бер гөнаһ кылып,
Бу Иблиснең таләбенә чик куегыз.

Порция

Юк, ярамый! Безнең илдә власть көче
Куелган законнарны үзгәртә алмый.
Бу бик начар үрнәк булыр. Килеп керер
Республика эшләренә зур хаталар.
Юк, ярамый.

Шейлок

Аһ, Даниил!
Даниил хөкем итә монда! Нинди зирәк!
Яшь булса да зур хөрмәткә лаек хаким.

Порция

Бирегезче, векселегезне карыйм әле.

Шейлок

Менә ул, хөрмәтле хаким, менә.

Порция

Сиңа, Шейлок, өч хакын түлиләр ич.

Шейлок

Ә соң антым? Антым ничек? Ант иттем ич.
Шуның өчен җаным харап булсынмыни?
Юк, юк, бөтен Венецияне бирсәләр дә...

Порция

Вексельнең срогы чыккан. Димәк, Шейлок
Безнең закон нигезендә сәүдәгәрдән
Бер кадак ит таләп итә: мөмкин кадәр
Йөрәгенә якынрак җирдән кисеп... —
Шәфкатьле бул! Төгәл өч хак түләсен дә,
Мин вексельне ертып ташлыйм.

Шейлок

Анда язган
Бурычларын төгәл түләп бетерсен ул.
Күрәм мин, яшь булсагыз да, законны сез
Шәп беләсез. Карарыгыз гадел сезнең.
Шул үзегез яклый торган закон хакына
Сорыйм сездән, тизрәк карар чыгарыгыз.
Мин ант итәм җаным белән, бернинди тел
Күндералмый мине. Көтәм. Түләсен ул.

Антонио

Чын күңелдән сорыйм судтан,
Тизрәк карар чыгарылсын.

Порция

Алайса, шул,
Карар болай: күкрәгең ач, киссен әйдә.

Шейлок

Аһ, искиткеч хаким! Нинди зирәк егет!

Порция

Законның хәрефе дә, мәгънәсе дә
Бу вексельдә күрсәтелгән һәрбер шартны
Тулысынча үтәргә куша безгә.

Шейлок

Шулай, дөрес. Син бик гадел, зирәк хаким.
Синең акылың үз яшеңнән бик күп олы.

Порция

Ач күкрәгең.

Шейлок

Әйе, дөрес, күкрәгеннән.
Вексельдә нәкъ шулай дигән,
«Йөрәгенә якын җирдән» дип язылган.

Порция

Әйе, шулай. Ә соң үлчәү бармы монда?
Ит үлчәргә.

Шейлок

Менә үзем алып килдем.

Порция

Хирургны үзең ялла,
Кан югалтып үлмәсен ул.

Шейлок

Вексельдә ул хакта язганмы соң?

Порция

Язмаса соң, шәфкать шулай куша безгә.

Шейлок

Юк, кирәкмәс. Вексельдә бит андый шарт юк.

Порция

Йә, сәүдәгәр, сезнең нинди сүзегез бар?

Антонио

Сүзем бик аз. Мин үлемгә әзерләндем.
Бир кулыңны, Бассанио, кичер мине.
Минем өчен һәлак булды дип кайгырма.
Язмыш миңа уйлаганнан шәфкатьлерәк.
Ә бит күпләр, байлыкларын югалткач та,
Шактый озак газап чигеп көн итәләр.
Ябыгып күзләре төпкә бата,
Сулган йөзен җыерчыклар каплап ала.
Акрынлап изә торган бу газаптан
Котылырга ярдәм итә миңа язмыш.
Хатыныңа миннән сәлам; сөйлә аңа
Гомеремне ничек тәмам итүемне,
Сине ничек сөюемне — барсын сөйлә!
Шул сүзеңнән ул аңласын иде чынлап:
Бассанионың булганмы чын дусты, юкмы?
Һич кайгырма җан дустымны җуям диеп.
Бурычыңны түләү өчен мин үкенмим.
Пычагын тирәнгәрәк тыкса яһүд,
Бурычыңны түләрмен мин йөрәгем белән.

Бассанио

Антонио! Җандай күргән кыз алдым мин.
Тик җаным да, хатыным да, бар дөньям да
Миңа синең гомереңнән өстен түгел.
Коткарыр өчен сине бу шайтаннан
Барын-барын корбан итәр идем, дустым.

Порция

Бу сүзләрне хатыныгыз ишетеп калса,

Өегездә каты җәнҗал кубар иде.

Грациано

Мин дә сөям хатынымны. Әмма бүген
Аның җаны, тәненнән аерылып,
Күккә менеп югалуын теләр идем.
Анда ул җан, ялынып берәр фәрештәгә,
Бу кабахәт этнең таштай каты бәгърен
Бераз гына йомшарттырмас иде микән?!

Нерисса

Ярый хатының ишетми бу сүзләрне,
Юкса синең кирәгеңне бирер иде.

Шейлок
*(үзалдына)*

Әнә бит ул христиан кияүләре!
Ә бит минем кызым бар... Аһ, әгәр дә ул
Христианга чыкмыйча, юл басучы
Варрава токымына килен булса,
Җиңелрәк булыр иде минем өчен.
Вакыт үтә. Ә соң карар кайчан чыгар?

Порция

Сәүдәгәрдән бер кадак ит тиеш сиңа.
Карар да һәм закон да нәкъ шулай куша.

Шейлок

Гадел хаким!

Порция

Итне кисеп ал син аның күкрәгеннән.
Закон да, суд карары да шулай куша.

Шейлок

Хаким — гадел! Хөкем чыкты! Йә, әзерлән!

Порция

Чү, сабыр ит бераз гына. Бетмәде әле;
Вексельдә бит кан турында бер сүз дә юк.
Ачык әйткән: «бер кадак ит» дигән анда.
Үзеңә тиясе итне ал син кисеп.
Әмма шунысы: кискән чакта бер тамчы кан
Тамызсаң да, безнең закон нигезендә,
Бөтен малың күчә дәүләт казнасына.

Грациано

Гадел хаким. Ишет, яһүд! Нинди зирәк!

Шейлок

Шундый закон бармы?

Порция

Менә үзең кара.
Син бит гадел хөкем таләп итәм дисең.
Карарны без чыгарабыз төгәл итеп.

Грациано

Зирәк! Зирәк! Яһүд, ишет! Галим — хаким.

Шейлок

Өч хак итеп түләгез дә эше бетте.
Христиан азат!

Бассанио

Менә акча.

Порция

Тукта, сабыр; яһүд гадел хөкем сорый.
Ашыкмагыз, тик ит кенә тиеш аңа.

Грациано

Әһә, яһүд! Аһ, искиткеч гадел хаким!

Порция

Йә, әзерлән ит кисәргә. Әмма җиргә
Кан түгәсе булма. Кара: бер кадактан
Арттырма да, ким дә кисмә; шул үлчәүдән
Скрупулның егерменче өлешенең
Егермедән бере кадәр генә артык
Йә ким булса, үлчәү теле кыл кадәре
Берәр якка аусын гына — үлем сиңа,
Бөтен милкең республика кулына күчә.

Грациано

О, Даниил! Яһүд, ишет! Даниил бит ул! —
Менә килеп каптың инде, әшәке җан!

Порция

Ник дәшмисең, Шейлок? Әйдә ал бурычыңны!

Шейлок

Акчаларым түләгез дә чыгып китәм.

Бассанио

Акчаларны әзерләдем — мә, ал тизрәк.

Порция
Ул бит
Суд каршында акчалардан кул селтәде.
Вексельдә язылганча түләтә ул.

Грациано

Аһ, Даниил! Өр-яңа Даниил бит бу! —
Рәхмәт, яһүд, бик әйбәт сүз табып бирдең.

Шейлок

Капиталны алалмыйча каламмыни?

Порция

Син нибары бер кадак ит алаласың.
Тәвәккәлләп кисеп ал, йә.

Шейлок

Ул чагында алсын аны шайтан гына,
Эш калмады миңа монда.

Порция
Тукта, яһүд!
Судның сиңа дәгъвасы бар. Венециядә
Закон шундый: әгәр дә чит ил кешесе
Республика гражданы тормышына,

Туп-турымы, читләтепме һөҗүм кылса, —
Аның милке урталайга бүленә дә,
Яртысы — җәберләнгән гражданинга,
Яртысы республика кулына күчә;
Ә тормышы Дож иркенә тапшырыла.
Ә син хәзер шундый хәлдә, туп-туры да,
Читләтеп тә гражданинның тормышына
Һөҗүм иттең. Шуның белән син үзеңне,
Әйткәнемчә, шундый авыр хәлгә куйдың.
Егыл Дожның аягына — гафу сора.

Грациано

Рөхсәт алып, үзең генә асылын инде,
Бар малыңнан колак кактың, шуңа күрә
Хөкүмәт үз исәбенә асар сине.

Дож

Холкыбызның төрлелеген күрсен дип, мин
Сораганчук бүләк итәм тормышыңны.
Байлыгыңның бер яртысы — Антониога,
Бер яртысы республикабызга күчә.
Тәүбә итсәң, штраф белән котылырсың.

Порция

Республика штраф белән чикләнсә дә,
Антонио өлешенә кагылмый бу.

Шейлок

Алыгыз малымны да, җанымны да,
Кичермәгез. Таянычым тартып алгач,
Малымны да алыгыз сез.
Тереклегем нигезен ваткач,
Җанымны да алыгыз сез.

Порция

Антонио аңа шәфкать күрсәтерме?

Грациано

Аңа бушлай бау бирә ул. Шуннан артык
Нәрсә бирсен?

Антонио

Әгәр дә сез, җәнабы гали,
Ярты милкең штрафка алмашсагыз,
Үз өлешем турында мин болай уйлыйм:
Шейлок миңа «Үзе үлгәч, ул байлыкны
Гүзәл кызын урлап киткән яшь егеткә
Бирергә» дип васыятьнамә язсын хәзер.
Өстәвенә мин күрсәткән шәфкать өчен
Христиан динен хәзер кабул итсен;
Аннан тагын Шейлок, үзе үлгәннән соң,
Калган милкен кызы белән киявенә
Бирергә дип, суд каршында васыять кылсын.

Дож

Шулай булсын, васыять кылсын; кылмый икән,
«Кичерергә» дигән карар үзгәрәчәк.

Порция

Бу хөкемгә син ризамы? Йә әйт, Шейлок!

Шейлок

Риза.

Порция

Сәркатип, васыятьнамә яз.

Шейлок

Китәргә рөхсәт итегез. Кәефем начар.
Кәгазьләрне җибәрерсез, —
Кул куярмын.

Дож

Рөхсәт. Кара, вәгъдәң үтә.

Грациано

Ике шаһит бирелә сиңа чукынырга;
Әгәр дә мин судья булсам, тагын унны
Өстәр идем; алар сине бик әйбәтләп
Дарга гына озатырлар иде шундук,
Коендырып, чукындырып тормас иде.

Шейлок китә.

Дож
*(Порциягә)*

Төшке ашка миңа рәхим итегез.

Порция

Кичерегез, җәнабы гали, бүген төнлә
Падуяда булырга тиеш мин.
Хәзер миңа юлга чыгар вакыт җитте.

Дож

Вакытыгыз булмау бик кызганыч.
Антонио, синьорны бүләкләгез,
Сез бурычлы хәзер аңа.

Дож үзенең иярченнәре белән чыгып китә.

Бассанио

Хөрмәтле синьор! Сезнең гаҗәеп саф
Зиһенегез мине дә һәм дустымны да
Зур бәладән йолып алды, шуның өчен
Яһүдкә дип билгеләнгән акчаларны
Риза булып, рәхим итеп алсагыз ла.

Антонио

Моннан тыш та мәңге түләп бетермәслек
Бурыч торып кала әле минем өстә.

Порция

Сезнең шатлык минем өчен иң зур бүләк!
Коткаруым белән чиксез бәхетле мин.
Шуннан артык берни өмет итмәдем мин.
Очрашканда танышлыкны онытмагыз.
Бәхет, шатлык телим сезгә. Сау булыгыз!

Бассанио

Синьоркаем, уемнан мин кире кайтмыйм.
Истәлеккә ни дә булса алыгыз, зинһар:
Түләү итеп түгел, дуслык төсе итеп.
Баш тартмагыз, зинһар, мине кичерегез.

Порция

Бу кадәре сорагач, мин карыша алмыйм.

*(Антониога.)*
Истәлеккә сездән перчаткалар алам.
*(Бассаниога.)*
Ә сез дуслык төсе итеп шул йөзекне...
Кулыгызны яшерәмсез? Башка нәрсә
Кирәкми дә. Яратсагыз, шуны бирегез.

Бассанио

Синьор... бу бит... берни түгел... бер чүп кенә!
Мондый нәрсә бүләк итү оят миңа.

Порция

Шуннан башка миңа берни кирәк түгел.

Бассанио

Кыйммәтле бу минем үзем өчен генә.
Әмма сезнең өчен, махсус игълан куеп,
Венециянең иң затлы йөзеген табам.

Порция

Күреп торам, юмартлыгың телдә генә.
Теләнергә үзегез мине өйрәттегез;
Хәзер инде, күрәм, миндәй теләнчегә
Ничек җавап кайтарырга өйрәтәсез.

Бассанио

Синьор, моны миңа хатыным бүләк итте.
Мин ант иттем. Бу йөзекне беркайчан да,
Беркемгә дә бирмәскә һәм югалтмаска.

Порция

Хатыныгыз, шашкан җан булмаса әгәр,
Бу йөзекнең миңа нинди хезмәт өчен
Бирелгәнен белгәч, сезгә ачуланмас.
Нишлисең бит? Ярый инде, сау булыгыз.

Порция белән Нерисса чыгып китәләр.

Антонио

Бассанио, бир син аңа йөзегеңне.
Аның мине коткаруы, мәхәббәте
Хатыныңның әмереннән өстенрәк.

Бассанио

Грациано, йөгер тизрәк, куып җитеп
Бир йөзекне! Күндерә алсаң, Антонионың
Өенә чакыр. Бар, тизрәк бул, ашык, дускай.

Грациано китә.

Әйдә киттек, безнең юл да шул якка ич:
Иртә белән иртүк торып, икәүләшеп,
Үзебез дә Бельмонтка без юнәләбез.
Киттек, Антонио.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук. Урам.
Порция һәм Нерисса керәләр, алар шул ук киемнәрдә.

Порция

Яһүд өен эзләп тап та кәгазьне бир.

Кулын куйсын. Бүген, төнлә юлга чыгып,
Кияүләрдән элегрәк кайтып җитик.
Лоренцоны бу кәгазь бик куандырыр.

Грациано керә.

Грациано

Менә булды. Куып җиттем үзегезне.
Бассанио дустым бераз уйланды да
Йөзекне сезгә бирергә карар кылды.
Аннан сезне төшке ашка
Бик үтенеп чакырды ул.

Порция

Анысы булмый. Ә йөзеген алам. Рәхмәт.
Сезгә шундый үтенеч бар: зинһар өчен,
Шейлок өен күрсәтегез сәркатипкә.

Грациано

Бик шатланып!

Нерисса

Синьор, бер сүзем бар.
*(Порциягә.)*
Киявемнең йөзеген алып булыр микән?
Саклыйм, дип ант иткән иде. Сыныйм әле.

Порция
*(Нериссага.)*

Һу, аласың. Ант итсеннәр әле бергә,
Йөзекне ирләргә бирдек, диеп.
*(Кычкырып.)*
Тиз бул! Кайда көтәсемне беләсең ич.

Нерисса
*(Грацианога)*

Әйдә киттек, миңа юлны күрсәтерсез.

Китәләр.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бельмонт. Порциянең өенә алып бара торган аллея.
Лоренцо белән Джессика керәләр.

Лоренцо

Ай яктысы нинди якты... Шундый төндә
Яфракларын кыштырдатмый, какмый гына
Агачларны йомшак җилләр сыйпаганда,
Гашыйк Троил, менеп шәһәр коймасына,
Күңеле белән сөеклесе Крессиданың
Туган җиренә очкандыр.

Джессика

Нәкъ шундый төндә,
Физба чыклы болын буйлап килгән чакта,
Арыслан күләгәсен күреп алгач,
Йөгергән кинәт куркып...

Лоренцо
Шундый төндә
Дидона кыз, киң диңгезнең ярына басып,
Кулындагы тал чыбыгы белән изәп,
Сөеклесен чакырган Карфагенга.

Джессика

Шундый төндә Медея кыз карт Эзонны
Яшәртергә шифалы үлән җыйган.

Лоренцо

Шундый төндә Джессика, атасының
Йортын ташлап, үтә азгын дусты белән
Бельмонтка качып киткән.

Джессика

Шундый төндә
Яшь Лоренцо аңа гыйшык игълан иткән,
Ант итеп, кызның күңелен урлап киткән;
Әмма аның анты чеп-чи ялган икән.

Лоренцо

Шундый төндә Джессика — мөлаем кыз —
Бик җәберләгән сөеклесен, яла яккан;
Ә шулай да егет аны гафу иткән.

Джессика

Әгәр дә без икәү генә булсак монда,
Төннәрнең бик күп төрлесен табар идем.
Аяк тавышы ишетәм мин.

Стефано керә.

Лоренцо

Төн тынлыгын бозып, кем ул килә?

Стефано
Дустыгыз бу!

Лоренцо

Дус дисезме? Әйт, нинди дус?
Исемең ничек, дускай?

Стефано
Стефано!
Хәбәр алып килдем сезгә. Минем бикәм
Тан алдыннан Бельмонтка кайтып җитә.
Хәзер анда крест янында тезләнеп, ул,
Изге никах бәхет, шатлык китерсен дип,
Теләк тели.

Лоренцо
Янында кем?

Стефано
Изге монах,
Хезмәтче кыз Нерисса да аның белән.
Әйтегезче, хуҗабыз кайтмадымы?

Лоренцо

Юк, кайтмады. Хәбәре дә килгәне юк.
Әйдә киттек, Джессика! Икәүләшеп,
Өй хуҗасы Порцияне
Тантаналы каршыларга әзерләник.

Ланчелот керә.

Ланчелот

Әлә-лә-лә, һай, һай, һай! Ә-лә-лә!

Лоренцо

Кем ул анда?

Ланчелот

Әлә-лә-лә, Лоренцо әфәндене күрмәдегезме?
Лоренцо әфәндене?

Лоренцо

Акырмасана, мин монда.

Ланчелот

Һә-лә-лә, кайда, кайда?

Лоренцо

Монда.
Ланчелот. Әйтегез аңа, хуҗаның чапкыны килде. Хуҗа үзе дә таң атканчы кайтып җитәчәк.

Китә.

Лоренцо

Киттек, җаным! Анда көтеп утырырбыз.
Хәер, безгә өйгә керү нигә кирәк?
Стефано, әйтче, зинһар, анда кереп,
Хуҗагызның тиздән кайтып җитәчәген.
Музыкантлар бакчага чыксыннар хәзер.

Стефано китә.

Нинди тынлык. Сибелә тауга ай нурлары!
Утырып торыйк — музыканың серле моңын
Тыңлыйк бергә. Сихерле төн тынлыгында
Бигрәк тә саф булып яңгырый бит ул.
Утыр, иркәм. Күрче, бөтен күк йөзенә
Җемелдәгән алтын шарлар сибелгәннәр.
Аларның иң кечесе дә җем-җем итеп
Балкыганда җырлый анда. Аның җыры
Нурлы күзле фәрештәләр хорына кушыла.
Яши ул моң үлемсезләр күңелендә.
Тик әлегә,
Җаныбызны фани дөнья тузаннары
Каплаганга, без ул моңны ишетмибез.

Музыкантлар керәләр.

Гимн уйнап уятыгыз Диананы!
Дәртле моңнар ишетелсен бикәгезгә.
Музыкагыз аны өйгә ашкындырсын.

Музыка.

Джессика

Моңлы җырдан күңелем тула.

Лоренцо

Җаның белән тыңлаганга шулай.
Күз алдыңа китер кыргый көтүләрне
Яки бер дә җигелмәгән атлар өерен.
Тамырларда яшь кан уйнап торганлыктан,
Котырынып чаба, сикерә, кешни алар;
Ләкин шунда кемдер быргы уйнап куйса

Яки башка музыканы ишетсәләр,
Барысы да кинәт кенә тынып кала!
Сихерле музыка тәэсирендә
Кырыс күзләр мөлдериләр, моңланалар.
Юккамыни дәртле Орфей музыкасы
Урман, елга, таш-тауларны сихерләгән.
Һичбер хиссез, тупас, дорфа күңелләр дә
Музыкадан эриләр һәм йомшаралар.
Күңелендә моң әсәре чагылмаган,
Музыкадан тәэсирләнми торган кеше
Хәйлә, мәкер, явызлыкка, хыянәткә
Тиз бирелә. Андыйларның җаны төндәй,
Хисләре нәкъ Эреб кебек дөм караңгы...
Һич ышанма андыйларга, тыңла җырны.

Порция белән Нерисса күренәләр.

Порция

Күрәсеңме, залда ут бар. Шәм яктысы,
Кечкенә шәм нуры сузыла еракларга!
Изге эш тә балкый шулай нурлар сибеп
Кап-караңгы явыз җаннар дөньясында.

Нерисса

Айлы төндә шәм яктысы күренми дә.

Порция

Данның да бит кечкенәсе зуры янында
Күренмәслек дәрәҗәдә тоныклана.
Баскакның да даны балкый,
Фәкать патша юкта гына.
Ә соңыннан, патша килгәч,
Диңгезгә койган елга суы кебек,
Аның бөтен күркәмлеге юкка чыга.
Музыканы ишетәсеңме?

Нерисса

Синьора, бу үзегезнең оркестр ич.

Порция

Үз урнында әйбәт була һәрбер нәрсә,
Төнлә белән бу музыка көндезгедән
Моңлырак та, серлерәк тә тоела миңа.

Нерисса

Төн тынлыгы шулай итә.

Порция

Болай булгач, каркылдаучы каргалар да
Тургайдан ким сайрамыйлар булып чыга.
Без бит көндезен аларны тыңламыйбыз.
Сандугач та
Казлар кыйгаклашкан вакытта сайраса,
Бытбылдыктан артык күрмәс идек аны.
Һәрбер нәрсә үз вакытында әйбәт була,
Тик шунда ул тиешенчә бәя ала.
Җитте! Ай Эндимион белән йоклый,
Уяныrга теләми ул!

Музыка туктый.

Лоренцо

Ялгышмасам, Порция тавышы бит бу.

Порция

Сукыр кеше кәккүкне таныган күк,
Мине ямьсез тавышымнан
Таныды ул.

Лоренцо

А, синьора, әйдә, рәхим итегез.

Порция

Ирләребез өчен дога кылдык,
Хак Тәгалә кабул иткәндер дип уйлыйм.
Кайттылармы?

Лоренцо

Юк бит әле, бикә генәм,
Әле генә чапкын килде, икесе дә
Кайталар, ди.

Порция

Нерисса, бар әйт анда,
Ирләр юкта безнең өйдән киткәнлекне
Хезмәтчеләр ычкындырып куймасыннар.
Сез дә, Лоренцо! Джессика, сез дә ләм-мим!

Быргы тавышы.

Лоренцо

Ирегез кайта, быргы тавышы ишетелде.
Курыкмагыз, синьора, без шым булырбыз.

Порция

Төне нинди! Сүрәнрәк көн шикелле,
Кояшны болыт кына каплаган күк.

Бассанио, Антонио, Грациано һәм хезмәтчеләр керәләр.

Бассанио

Көләч кояш антиподлар ягына күчкәч,
Син күренсәң, яңадан көн балкый бездә.

Порция

Балкып кына калсам ярый, пешермәсәм.
Хатынның утына пешсә, ир кешегә
Шәп булмый бит. Бассанио пешмәсен, дим.
Хәер, анысы бездән түгел, Хак тәкъдире!..
Рәхим ит, бәгырькәем, үз өеңә.

Бассанио

Рәхмәт, синьора, каршы ал дустымны да.
*(Таныштыра.)*
Антонио. Аңа чиксез бурычлы мин.

Порция

Әйе, аңа бөтен яктан бурычлы сез.
Чөнки сезнең бурычны ул нәрсә белән
Түләргә сүз биргәнен мин ишеттем.

Антонио

Бирәчәген тулысынча түләде ул.

Порция

Синьор, сезне күрүемә чиксез шат мин.

Грациано
*(Нериссага)*

Ай белән ант итәм, гадел сөйләмисең.
Валлаһи, дим, сәркатипкә бүләк иттем.

Порция

Әрләшә дә башладыгыз, нәрсә булды?

Грациано

Бүләк итеп биргән алтын балдак өчен,
Бер чүп өчен! Пычакларга языла торган
Өтек бер шигыре дә бар иде шунда:
«Ярат мине, мәңге миннән аерылма».

Нерисса

Шигыренә дә, хакына да кагылма син.
Йөзек биргән чакта миңа ант иттеңме?
Гомерем буе саклармын дип, кабергә дә
Йөзек белән кумәрләр диеп әйттеңме?
Минем өчен булмаса да, ичмасам, шул
Яңгыравыклы антың өчен саклар идең.
Сәркатипкә? Юк-юк. Ходай күреп тора:
Мәңге мыек үсми торган сәркатип ул.

Грациано

Олыгайгач үсәр әле.

Нерисса

Әйе,үсәр,
Әгәр ул кыз ир кешегә әверелсә.

Грациано

Кулым корсын әгәр аны кызга бирсә,
Япь-яшь малай, менә синең буе гына.
Шулкадәре ялынды ул. Бүләк ит, дип
Буыныма төште. Бирми котыла алмадым.

Порция

Дөресен әйтим, синең гаебең бик зур монда.
Кәләшеңнең иң беренче бүләгеннән
Ничек алай җиңел генә аерылдың син?
Син ант итеп кигәнсең ич ул йөзекне,
Антың белән үз тәнеңә беркеткәнсең,
Тәнеңнең ул кисәгенә әверелгән.
Мин дә йөзек бүләк иттем киявемә.
Бүләгемнән аерылмаска ант итте ул!
Әнә үзе! Мин ант итеп әйтәм сиңа,
Бөтен дөньяның байлыгын бирсәләр дә,
Бармагыннан салмаячак ул йөзекне.
Дөресен әйтим, Грациано, хатыныңның
Йөрәгенә авыр яра салгансың син.
Әгәр мине шундый хәлгә куйса ирем,
Акылымнан шашар идем.

Бассанио
*(үзалдына)*

Сул кулымны

Чабып өзсәм, ичмасам, йөзекне дә
Шунда җуйдым дияр идем.

Грациано

Бассанио да йөзеген бүләк итте.
Хезмәте өчен аны юрист сорап алды.
Бик шәп юрист, ул бүләккә лаек юрист.
Сәркатибе минекенә ябырылды.
Икесе дә, башка бүләк алмыйбыз дип,
Безнең шушы йөзекләргә ябыштылар.

Порция

Нинди йөзек бүләк итте ул юристка?
Минекен түгелдер ич?

Бассанио

Гаебемә
Ялган өстим дисәм, хәзер танар идем.
Күрәсең ич, бармагымда йөзегем юк.

Порция

Тугрылык юк, димәк, синең йөрәгеңдә.
Хода шаһит: йөзегемне тапмый торып,
Сиңа хатын була алмыйм.

Нерисса

Әйе, дөрес!
Йөзегемне күрми торып, мин дә сиңа
Хатын булмыйм.

Бассанио

Аһ, әгәр дә
Белсәң кемгә биргәнемне ул йөзекне
Һәм кем өчен биргәнемне ул йөзекне,
Нәрсә өчен биргәнемне ул йөзекне,
Һич бирәсем килмәгәнне ул йөзекне,
Белсәң әгәр соравын тик шул йөзекне,
Ачуың йомшарыр иде.

Порция

Белсәң нинди кыйммәтлеген ул йөзекнең,
Нәрсә өчен бирелгәнен ул йөзекнең,
Намусың итеп тойган булсаң ул йөзекне,
Беркайчан да бирмәс идең ул йөзекне.
Әгәр аны җандай күреп, әһәмиятен
Чын күңелдән исбат итсәң, һичбер кем дә
Аны синең бармагыңнан салдырырга
Батырчылык итмәс иде. Нериссаның
Сүзе дөрес. Мин дә шулай уйлыйм хәзер:
Йөзегемне кыз кешегә биргәнсең син.

Бассанио

Кызга түгел. Намусым белән, җаным белән
Ант итәм мин: яшь юристта минем йөзек.
Тәкъдим иткән акчаларны алмады ул.
Йөзегемне сорады, ә мин бирмәдем.
Ул үпкәләп чыгып китте. Уйлап кара,
Җан дустымны һәлакәттән коткаручы
Кешенең кәефен кырдым. Ни дип әйтим,
Артыннан җибәрергә мәҗбүр булдым.
Оялдым мин, әдәпсезлек эшләдем дип,

Игелексез булып намусым таптадым дип.
Кичер мине! Әгәр үзең шунда булсаң,
Йөзегеңне, бармагымнан суырып алып,
Юристка син үзең биргән булыр идең.

Порция

Йөзегемне бармагына кигән булгач,
Сакларга ант иткән ярым биргән булгач,
Өйгә якын җибәрмәгез ул юристны.
Юмартлыкта ярым белән ярышам хәзер.
Юрист миннән ни сораса, шуны бирәм.
Бәлки, нәфсен сузар минем ул үземә,
Ярым белән уртак никах түшәгенә.
Карышмам мин аның һичбер теләгенә.
Төнлә белән ялгызымны калдырмассың,
Нәкъ Аргустай, мең күз белән сагаларсың.
Ялгыз калсам, ант итәм мин намусым белән
(Намусым әле үземнеке), юристны мин
Түшәгемә алып ятам, «эһ» тә димим.

Нерисса

Ә мин әлеге сәркатипне. Уйлап кара,
Ничек минем ялгызымны калдырасың?

Грациано

Ярый, ләкин минем күзгә чалынмасын,
Каләмен сындырам мин ул юньсезнең.

Антонио

Мондый җәнҗал чыгуына мин сәбәпче.

Порция

Борчылмагыз, сез кадерле кунак безгә.

Бассанио

Кичер, бәгърем, ихтыярсыз гөнаһ кылдым.
Мин ант итәм дусларымның каршысында
Үз шәүләмне чагылдырган күзләреңнең
Нуры белән...

Порция

Ишетәсезме? Күзләремдә
Ике шәүлә күрә. Димәк, икейөзле...
Ике йөзең белән ант ит, ышанырмын!

Бассанио

Тукта инде, тыңласана. Кичер, зинһар,
Җаным белән ант итәм мин, моннан соң һич
Антым бозмам.

Антонио

Ирегезнең бәхете өчен
Мин тәнемне заклад салдым. Әгәр дә шул
Йөзегегезне алган юрист якламаса,
Беткән идем. Хәзер инде мин җанымны
Заклад салып әйтәм сезгә, моннан соң ул
Биргән антын мәңге бозмас.

Порция

Аның өчен ант итәсез?

Ул чагында бу йөзекне
Бирегез аңа, монысын инде сакласын ул.

Йөзекне Антониога бирә.

Антонио
*(йөзекне Бассаниога тапшырып)*

Бассанио, ал. Күз нурыңдай сакла моны.

Бассанио

Раббым! Бу бит юристка биргән йөзек!

Порция

Юрист миңа бирде. Кичер, Бассанио,
Бүген төнлә аның белән йокладым мин.

Нерисса

Син дә мине кичер, бәгърем Грациано.
Сәркатип тә менә шушы йөзек өчен
Бүген төнлә минем янда кунып чыкты.

Грациано

Ат кермәгән күперне кем төзәттерә?
Җен суккыры, кияү булып өлгермәстән,
Маңгайларны мөгез белән бизәделәр.

Порция

Ташлагыз бу тупас сүзне.
Барыгыз да шаккаттыгыз. Менә язу.
Вакыт барда бер укырсыз. Падуядан
Белларио җибәргән хат! Укыгач та
Юристыгыз Порция, сәркатибе
Нерисса икәнлеген сез аңларсыз.
Лоренцо әйтер: сез китүгә, без дә киттек.
Әле менә яңа гына кайтып кердек,
Әле өйдә булган да юк... Антонио,
Көтелмәгән хәбәр алып кайттым сезгә.
Шушы хатны укыгыз. Өч корабыгыз
Кыйммәтле йөк белән кире кайтып кергән.
Бу кәгазьнең миңа ничек эләккәнен
Әйтеп тормыйм үзегезгә.

Антонио

Тәнем ойый!

Бассанио

Ул юрист син идеңмени?
Ничек соң мин танымадым?

Грациано

Миңа
Мөгез куйган сәркатип син идеңмени?

Нерисса

Әйе. Ләкин ир кешегә әверелмәсәм,
Гомеремдә сиңа мөгез куялмам мин.

Бассанио

Гүзәл юрист, минем белән йоклыйсың син,
Мин югында йокларсың хатыным белән.

Антонио

Гүзәл ханым, җанымны да коткардыгыз,
Тормышымның нигезен дә кайтардыгыз:
Корабларым чынында да исән икән!

Порция

Лоренцо, кил!
Сәркатиптә сиңа да бер сөенеч бар.

Нерисса

Аның өчен синнән берни түләтми ул.
Менә сезнең исемегезгә рәсми кәгазь,
Кәләшеңә һәм үзеңә. Шейлок үлгәч,
Аның бөтен мал-мөлкәте сезгә күчә.

Лоренцо

Ачлыктан интегүче мескеннәргә
Күктән ярма яудырдыгыз.

Порция

Таң беленә.
Ләкин, сизәм, эшнең ничек булганлыгын
Тулы итеп беләсегез килә сезнең.
Әйдә өйгә, анда кергәч сорашырсыз,
Барысын да бәйнә-бәйнә аңлатырбыз.

Грациано

Мин хәзер үк соравымның бирәм берсен,
Нерисса һич кичекмичә җавап бирсен:
Хәзер ятсак, ике сәгать җитәр микән,
Иртәгәсе бөтен төнне көтә микән?
Бүгенге таң соңгарып атса иде,
Иркәм белән бик озак ятсам иде.
Искә төшсә, җаным тетри шомлы уйдан:
Хатыным йөзеген бүтән мәңге җуймам!

Китәләр.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Герцог сараеның бер бүлмәсе.
Герцог, Эскал, сарай хадимнәре керәләр.

Герцог

Эскал!
Эскал

Әйе, хөкемдарым.

Герцог

Хөкем сөрү тәртипләрен хәзер сезгә
Сөйләп тору артык булыр, чөнки сездә
Тәҗрибә зур, бу эшләрдә белемегез
Мин бирәсе киңәшләрдән тирәнрәк.
Хәзер аны эштә файдалану өчен,
Кулыгызга хакимлекне бирү кирәк.
Халкыбызның рухын, илнең законнарын
Сездән дә шәп белүчене хәтерләмим.

Өстегезгә йөкләтелгән бурычларның
Барсы да менә монда күрсәтелгән.
*(Кәгазь бирә.)*
Анжелоны чакырыгыз.

Хадимнәрнең берсе китә.

Әйтегезче,
Минем вазифаны үти алыр бит ул?
Үз урныма Анжелоны сайладым мин,
Мин югында ил хакиме булып торыр.
Җәзаны да, шәфкатьне дә эченә алган
Гадел закон аның кулына бирелә хәзер.
Сез ни дисез?

Эскал

Безнең Вена шәһәрендә
Андый ышанычка лаек тик Анжело.

Герцог

Әйе, әнә үзе килә!

Анжело керә.

Анжело

Минем иркем
Һәрчак сезнең ихтыярда, җәнаб гали,
Әмерегезне көтәм.

Герцог

Синең табигатең
Шундый күркәм, күзәтүче һәрбер кеше
Күңелеңдәге ачык күрә ала;
Тик шуны бел, синең гүзәл сыйфатларың
Үзең өчен генә түгел. Ходай безне
Шәмдәй итеп файдалана.
Шәм бит үзе өчен янмый, син беләсең,
Яшерен генә яткан сәләт — юк сәләт ул.
Безгә акыл бөек максат өчен бирелә.
Табигать, ул көчен юкка исраф итми,
Биргән икән — син игелек күрсәт аңа,
Процент түлә!.. Хәер, бу сүз нигә кирәк?
Үзе акыл өйрәтердәй кешегә мин
Киңәш биргән булып вакыт әрәм итәм.
Әйтер сүзем шул, Анжело:
Мин югында мине алмаштырасың син,
Вена шәһәрендә хәзер һәммәсе дә —
Үлеме дә, шәфкате дә синең кулда.
Гәрчә Эскал өлкәнрәк булса да, мин
Аны сиңа ярдәмче итеп билгеләдем.
Менә рәсми кәгазь.

Бирә.

Анжело

Хөкемдарым,
Металлны сез башта ныклап тикшерегез,
Сезнең сынны коярга ул ярарлыкмы?

Герцог

Син карышма,
Бөтен ягын уйлап сине сайладык без.
Кил, кабул ит хакимлекне, эшем ашыгыч.
Кичекмәстән хәл итәсе эшләр кала —

Алар синең өскә төшә. Вакыт барда
Хат язармын, син дә хәбәр җибәреп тор.
Йә, хушыгыз. Йөкләтелгән вазифаны
Уңыш белән үтәрсез дип өмет итәм.

Анжело
Хөкемдар,
Бераз гына озата барыйм сезне.

Герцог

Юк, кирәкмәс, эшем ашыгыч, һич шикләнмә:
Дәрәҗәң һәм көчең белән син тиң миңа,
Законнарны көчәйтсәң дә, йомшартсаң да
Киң иркең бар. Бир кулыңны. Яшерен китәм.
Халкыбызны яратсам да, һәр очракта
Күренәсем килми аңа. Гәрчә аның
Шатлануы, ихтирамы чын булса да,
Һич яратмыйм купшылыкны, шау-шуларны.
Шуннан ләззәт табып йөргән кешеләрне дә
Акыллы дип саный алмыйм. Йә, хушыгыз.

Анжело

Хәерле юл. Хак Тәгалә юлдаш булсын.

Эскал

Исән йөреп, сау кайтыгыз.

Герцог

Рәхмәт сезгә.
Йә, хушыгыз.
Китә.

Эскал

Граф, әгәр рөхсәт булса,
Сезнең белән сөйләшергә теләгем бар.
Вазифамның асылын белү кирәк миңа.
Күп бурычлар йөкләнде бит минем өскә,
Әмма аңлап бетерә алмыйм һәммәсен дә.

Анжело

Мин дә шулай, әйдә хәзер минем белән,
Без икәүләп тикшерик ул бурычларны.

Эскал
Киттек.
Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урам.
Луцио белән ике дворян керәләр.

Луцио. Безнең Герцог һәм башка герцоглар патша белән килешә алмасалар, берләшеп патшага каршы баш күтәрәчәкләр.

I дворян. Илаһым, Ходаем! Ачлык патшадан кала барлык патшалар белән дә килешеп яшәргә язсын.

II дворян. Амин.

Луцио. Син, теге кәсепкә чыкканда, ун васыятьнең берсен сызып ташлаучы диңгез карагын хәтерләтәсең.

II дворян. «Урламаска» дигәненме?

Луцио. Әйе, нәкъ шунысын.

I дворян. Әйе шул, ул васыять бит каракка кәсебен ташларга куша. Шулай ук безнең солдатлар арасында да «тату яшәргә» дигән васыятьне яратучы кеше табылмас.

II дворян. Мин әле бер солдатның да татулыкны яратмыйм дигәнен ишеткәнем юк.

Луцио. Каян ишетәсең аны! Синең дога укыган җирдә булганың бармы соң?

II дворян. Бар, кимендә унике тапкыр булдым мин анда.

I дворян. Алайса әйт, ничек язылган ул догалык, шигырь беләнме, нәсер беләнме?

II дворян. Шигырь белән дә, нәсер белән дә, төрле телләрдә тыңладым мин ул доганы.

I дворян. Төрле диннәрдә инде алай булгач?

Луцио. Нигә? Нинди генә диндә булса да, дога дога инде ул, ә син менә нинди генә дога укысаң да, барыбер бозыклыктан айный алмыйсың.

I дворян. Без икебез дә берочтан.

Луцио. Дөрес. Бер үк хәтфәдән киселгән; тик син шуның кырыеннан кисеп ташланган тасма.

I дворян. Әйе шул, син хәтфә булсаң да, аның кыршылып, йоны коелып беткәне. Кыршылган хәтфә булганчы, тасма булуым артыграк, аңладыңмы?

Луцио. Аңладым. Син кыркылып ташланган чүп, алай да синең саулыкка берне эчәм, тик син эчкән касәдән түгел.

I дворян. Нәрсә булды соң әле бу, үз өстемә сөйләп авызымны гына пешердеммени?

II дворян. Ярый, икенче тапкыр өреп кабарсың.

Луцио. Карагыз, кара, әнә кем килә. Ләззәт хәзинәсе үзе.

I дворян. Әйе, ләззәт хәзинәсе. Аның йортында эләктергән авырулар миңа бик кыйбатка төште.

II дворян. Күпмегә?

Луцио. Үзең уйлап бел.

II дворян. Елына өч мең доллар.

I дворян. Әйе, шуның өстенә тагын...

Луцио. Француз авыруы.

I дворян. Әллә нинди авырулар тагасың син миңа. Дөрес түгел, мин сау-сәламәт. Типсәм тимер өзәм.

Луцио. Әйе, тибәсең син, типтерәсең, типтерә-типтерә миеңне киптереп бетергәнсең.

Таушалган ханым керә.

I дворян. Ә! Исәнме-саумы? Бүген кай җирегез сызлый?

Таушалган ханым. Ярый, ярый, әнә сезнең ишеләрнең биш меңенә торырлык егетне төрмәгә алып киттеләр.

II дворян. Кемне?

Таушалган ханым. Кемне, кемне... Клавдионы, Клавдио әфәндене.

I дворян. Клавдионы? Төрмәгә? Булмас.

Таушалган ханым. Булды шул. Алып киткәннәрен үз күзем белән күрдем. Анысы-анысы, өч көннән башын да кисәчәкләр.

Луцио. Бу шаяра торган эш түгел, һич ышанасым килми, дөресме бу?

Таушалган ханым. Дөрес кенәме? Джульетта туташка бала ясаган — шуның өчен гаеплиләр.

Луцио. Дөрестер, мөгаен, моннан ике сәгать элек минем белән күрешергә тиеш иде — килмәде. Ә ул вәгъдәсез егет түгел.

II дворян. Әйе, бу хәбәр баягы сүзгә дә бик туры килә.

I дворян. Бигрәк тә яңа чыккан указга туры килә.

Луцио. Әйдәгез, барып белик әле.

Луцио, ике дворян китәләр.

Таушалган ханым. Менә бит нинди хәлләр, кайсын сугышка, кайсын больницага, кайсын дар агачына, кайсын сөргенгә сөрәләр. Болай барса — эш харап, миңа килердәй егет тә калмас.

Мәзәкче керә.

Йә, ничек, берәр яңалык ишетмәдеңме?

Мәзәкче. Төрмәгә алып киттеләр.

Таушалган ханым. Нәрсә эшләгән соң ул?

Мәзәкче. Бер кызны әмәлләгән.

Таушалган ханым. Гаебе ни, дим?

Мәзәкче. Кеше күленнән балык сөзгән.

Таушалган ханым. Джульетта туташка бала ясаган. Шуның өчен гаеплиләрме?

Мәзәкче. Кызны хатын ясаган, балалы да иткән. Яңа указ турында ишетмәдегезмени?

Таушалган ханым. Нинди указ ул, сөеклем?

Мәзәкче. Шәһәр читендәге фәхешханәләрне бетерәләр.

Таушалган ханым. Ә шәһәрдәгеләрен?

Мәзәкче. Орлыкка калдыралар. Аларын да бетермәкче булганнар да, ниндидер бер акыллы түрә каршы килгән.

Таушалган ханым. Шәһәр читендәгеләрен барын да бетерәләрме?

Мәзәкче. Берсен дә калдырмыйлар, апакай гынам.

Таушалган ханым. Менә бит ул хөкүмәт үзгәрсә! Хәзер нишләргә инде миңа?

Мәзәкче. Борчылмагыз, яхшы адвокатка килүчеләр өзелми; адресыгызны алмаштырсагыз да, һөнәрегез үзгәрми ич. Мин исә нәкъ элеккечә сезнең йомышчыгыз булып калам. Курыкмагыз, сезне җәберләмәсләр. Бу эштә сезнең, Аллага шөкер, кешелеккә хезмәт итә-итә тешләрегез коелып бетте.

Таушалган ханым. Нишлисең бит инде, сөеклем. Әйдә киттек.

Мәзәкче. Әнә Клавдио әфәндене төрмәгә алып баралар. Джульетта туташ белән икесен бергә.

Төрмәче, Клавдио, Джульетта һәм сакчылар керәләр.

Клавдио. Нигә болай шәһәр буйлап йөретәсең? Син төрмәгә озатырга тиеш мине.

Төрмәче. Нишлим соң мин, үз иркемнән йөретмим бит. Граф Анжело шундый боерык бирде миңа.

Клавдио

Хаким... Әлеге ярым алла... Нинди каты
Җәзалый ул безне, үзе теләгәнчә!
Шулай инде, тели икән гафу итә,
Теләмәсә — башны кисә. Закон шулай!

Луцио белән ике дворян керәләр.

Луцио

Аһ, Клавдио, син богаулы! Ни өчен бу?

Клавдио

Артык иркен булган өчен, сөекле дус.
Шулай бит ул, күп тыгынсаң, ач йөрисең,
Артык иркен булсаң әгәр — богау, төрмә.
Комсызланып агу эчкән күселәр күк,
Татлы гөнаһ чишмәсенә омтылабыз,
Нәфсебезгә баш булалмый хур булабыз.

Луцио. Әгәр дә мин, кулга алынгач, шулай матур итеп сөйли белсәм, шунда ук кредиторларымны чакыртыр идем. Шулай да мин тәүфыйклы булып төрмәдә утыруга караганда, иректә йөреп, бозыклык эшләүне артыграк күрәм. Нинди җинаять эшләдең соң әле син, Клавдио?

Клавдио. Аның исемен әйтү үзе бер җинаять.

Луцио. Әллә кеше үтердеңме?

Клавдио. А, юк!

Луцио. Уйнаш иттеңме әллә?

Клавдио. Әйдә, шулай булсын.

Төрмәче. Йә, әфәндем, вакыт җитте.

Клавдио. Сабыр ит, дус. Луцио, бер йомышым бар.

Луцио

Йөз булса да үтим, сиңа файдам тисә.
Уйнаш иткән өчен генә кулга алсыннарчы!

Клавдио

Без Джульетта белән икәү вәгъдәләшкән.
Ләкин туйны көтеп тормый кушылдык без.
Син беләсең аны, минем хатыным ул,
Фәкать рәсми никах кына җитми безгә.
Рәсмиләштермәвебезнең сәбәбе шул:
Джульеттаның бирнәләрен кардәшләре
Сандыклардан чыгарырга теләмиләр.
Без аларның ризалыгын алгангача

Бәйләнешне фаш итмәскә булган идек.
Ләкин безнең сөешүләрнең яшерен сере
Джульеттада артыграк зурайды шул.

Луцио

Авыры бармы?

Клавдио

Кызганычка каршы, бар шул.
Ә бу безнең Герцог урынын алган кеше...
Дәрәҗәгә менгәч шулай сукырайдымы?
Илне әллә аргамак дип белә микән?
Авызлыклап, шпорларын кадый-кадый,
Теләсә кая борып йөртү осталыгын
Бар галәмгә күрсәтмәкче була микән?
Хакимнәргә кансызлык хас булгангамы,
Әллә үзе үтә кансыз булгангамы,
Тутыгып беткән кылычлар күк, унтугыз ел
Кулланылмый яткан иске законнарның
Барсын җыеп алган. Хәзер инде,
Миңа каршы кулланып шул законнарны,
Каты куллы хаким булып танылмакчы,
Шөһрәт өчен эшли бит ул бу эшләрне.

Луцио. Чыннан да шулайдыр. Синең башың хәзер гашыйк кыз сулышы гына кагылса да тәгәрәп төшәргә тора. Герцогка кеше җибәр, шәфкать сора.

Клавдио

Җибәрдем дә, бер җирдән дә тапмаганнар.
Хәзер миңа, дустым, зинһар, син ярдәм ит.
Туган сеңлем монастырьга керде бүген,
Әлегә ул багышланып өлгермәгән.
Аңа барып минем хәлне сөйләп бир син.
Әйт син аңа: Анжелога барсын, зинһар,
Аның күңелен йомшартырга чара тапсын,
Хәзер минем бар ышаныч сеңелкәштә.
Яшьлек бит ул һичбер сүзсез булганда да
Ышандыра белә, көчле тәэсир итә.
Минем сеңлем акыллы да, талантлы да,
Теләсә, ул зирәк акылы, сүзе белән
Һәр кешене үз ягына аудара ала.

Луцио. Ходай ярдәм бирсен аңа. Синең хәлгә төшкән барлык кешеләргә шатлык китерсен, сиңа тагын да яшәү ләззәтен татырга насыйп итсен, юкса, шушы гыйшык-мыйшык уены аркасында җаның-ны жуйсаң, минем өчен бик күңелсез булыр. Ярый алайса, мин сеңлең янына киттем.

Клавдио. Рәхмәт сиңа, дустым.

Луцио. Ике сәгатьтән соң нәтиҗәсе мәгълүм булыр.

Клавдио *(Төрмәчегә)*. Әйдә киттек!

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Монастырь.
Герцог белән Фома ата керәләр.

Герцог

А юк, изге ата, алай уйлама син:
Тимер кием кигән кеше йөрәгенә
Гыйшык угы кагыла алмый. Монастырьда
Яшеренергә урын сорыйм икән сездән,
Моңа сәбәп кайнар яшьлек уты түгел,
Монда минем бик мөһим бер максатым бар.

Фома ата

Нинди максат ул, әйтегез.

Герцог
Беләсез ич,
Электән үк ялгызлыкны яратам мин.
Дәртле яшьлек, уен-көлке хөкем сөргән
Кәеф-сафа мәҗлесенә исем китми.
Хакимлекне Анжелога тапшырдым мин —
Ул таләпчән, тотанаклы, каты куллы.
Хәзер мине ул Польшада диеп белә,
Шундый хәбәр тараттым мин бөтен илгә —
Һәммәсе дә мине читтә дип уйлыйлар.
Нигә болай эшләдең дип сорыйсыңмы?

Фома ата

Әйе, сорыйм.

Герцог

Бездә каты законнар бар,
Халык өчен ул бик кирәк, ярсу атны
Авызлыксыз тыю мөмкин булмаган күк,
Халыкны да законсыз һич тыеп булмый.
Картаеп эштән чыккан арыслан күк,
Унсигез ел тик яттылар ул законнар.
Кайбер ата, иркә улын шүрләтим дип,
Бәйләм-бәйләм пеше чыбык алып кайта.
Суктырмый ул, фәкать яный: тора-бара
Курыкмый һич аннан бала, көлә генә.
Кулланылмый яткан безнең законнар да
Акрынлап көчен җуя, сүнә-бетә.
Кирәгеннән артык ирек — йөгәнсезлек,
Гадел судны утырта ул төп башына.
Нәни бала кыйный үзенең имезүчесен,
Әдәп-хая, әхлак, тәртип юкка чыга.

Фома ата

Ләкин ул тик яткан гадел законнарны
Эшкә кушу сезнең кулда бит, хөкемдар.
Анжелога тапшыруга караганда,
Моны үзегез эшләсәгез, күп мәртәбә
Хәтәррәк күренер иде ул законнар.

Герцог

Артык хәтәр булуы бар. Гаебем шул —
Халыкка киң ирек бирдем. Әлегәчә
Кешеләргә күп нәрсәләр рөхсәт иттем —
Җәза бирмәү — рөхсәт итү дигән сүз ул.
Хәзер инде шуның өчен мин үзем үк
Җәзаласам — бу явызлык булып күренер.
Шуңа күрә
Бу эшләрне Анжелога тапшырдым мин.
Әйдә минем исемнән ул җәзаласын,
Ә мин тел-теш, шелтәләрдән читтә калам.
Шул ук вакыт әледән-әле, яшерен генә,
Монах киеме киеп, халык арасына
Чыгып йөреп, аның эшен тикшерәм мин.
Миңа кием бирегез, зинһар, ил каршында
Монах булып күренү өчен, үз-үземне
Ничек тоту тәртибенә өйрәтегез.
Монда тагы башка төрле максат та бар,
Тик анысын мин соңыннан аңлатырмын.

Асылын әйтим: граф Анжело тотанаклы,
Һичбер төрле сүз тидереп булмый аңа.
Әйтерсең лә дәрт кайнамый йөрәгендә,
Әйтерсең лә тәм дә тоймый, икмәкнең ул
Таштан тәмле икәнлеген гүя белми.
Менә күрик, хаким булгач нишләр икән?
Һаман шулай гөнаһ кылмый саф йөрерме,
Үзгәрерме?
Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хатын-кыз монастыре.
Франциска белән Изабелла керәләр.

Изабелла

Монашкалар өчен хокук шул гынамы?

Франциска

Безнең тәртип сиңа кырыс тоеламы әллә?

Изабелла

Һич юк. Шуннан артыгын теләмим дә.
Киресенчә, изге Клара тәртибенең
Тагы да катырак булуын теләр идем.

Луцио
*(тыштан)*
Сәлам сезгә!

Изабелла

Кем бар анда?

Франциска
Ниндидер ир.
Изабелла, бар, сора, ни кирәк аңа?
Сиңа ярый аның белән сөйләшергә,
Ә миңа — юк, син өйрәнчек, ирекле син.
Монахлыкка багышлангач, ир-ат белән
Фәкать остаз каршысында сөйләшәсең,
Анда да әле йөзең-күзең каплап кына.
Йөзең ачык була икән — эндәшмисең...
Тагын чакыра! Зинһар, җавап бир үзенә.

Китә.

Изабелла

Сәламәтлек телим сезгә! Нәрсә кирәк?

Луцио керә.

Луцио

Сәлам, кызкай, әгәр дә сез кыз булсагыз —
Күрер күзгә үзегез болай кыз шикелле.
Изабелла дигән кызны күрер идем.
Монастырьда өйрәнчек ул, яңа кергән,
Клавдио бичараның сеңлесе ул.

Изабелла

Бичараның? Әйтегез, ник бичара ул?
Мин булам ул Изабелла — аның сеңеле.

Луцио

Мөлаем кыз! Абыегыздан сәлам сезгә.
Озын итеп сөйләп тормыйм, ул төрмәдә.

Изабелла

Аһ, нинди зур хәсрәт. Зинһар, әйт, ни өчен?

Луцио

Ни өчен дип... Әгәр дә мин судья булсам,
Ул эш өчен бүләкләгән булыр идем.
Сөйгәненә бәби бүләк итте бит ул.

Изабелла

Ай әфәндем, шаярмагыз.

Луцио
Һич шаярмыйм.
Кызлар белән уен-көлке, мәзәк сөйләп
Шаярырга яратсам да, сезнең белән
Булдыралмыйм, минем өчен сез изге кыз;
Әрвах бит сез, чын әүлия, изге кыз дип
Чын күңелдән сөйләшәм мин сезнең белән.

Изабелла

Миннән көлеп сез Алланы хурлыйсыз бит.

Луцио

Һич хурламыйм, кыскача тик чынын әйтим:
Абыең сөйгән кызы белән кочаклашкан,
Беләсез ич, ашагач та симерәләр,
Җиргә сипкән орлыктан мул иген үсә.
Шәп сөрелгән, чәчелгән кыз түтәлендә
Менә дигән гүзәл җимеш үсеп килә.

Изабелла

Авыры бармы... Джульетта туганымның?

Луцио
Туганымның?

Изабелла

Туганым дип йөртә идем.
Бер мәктәптә укыганда дуслаштык без,
Бер-беребезгә туганым дип эндәшә идек.

Луцио
Әйе, шул кыз.

Изабелла

Соң, өйләнсен алай булгач.

Луцио

Бөтен хикмәт шунда: безнең Герцогыбыз
Кинәт кенә әллә кайда китеп барды;
Бик күпләргә, шул исәптән миңа да ул
Хәрби эшләр, дәрәҗәләр вәгъдә итте.
Әмма дәүләт эшен белгән халык әйтә:
Аның уе бөтенләй дә башка, диләр.
Үз урнына Анжелоны куеп китте.
Ә бит аның йөрәге туң, тамырында бозлы су бит
Кан урнына, үз гомерендә
Кайнар хиснең ни икәнен белгәне юк.
Күңелендә ниндидер дәрт сизсә, шундук
Эшкә чумып, руза тотып сүндерә ул.
Карт арыслан янындагы күселәр күк,
Гадел закон тирәсендә һич куркусыз
Яшәп килгән гадәтләрне бетерү өчен,

Каты закон табып алган. Синең абыең
Гөнаһы өчен җаны белән саубуллаша.
Аны шундук кулга алырга боерды ул.
Башкаларга шомлы гыйбрәт булсын өчен,
Абыеңа шул законны кулланмакчы.
Әгәр дә сез Анжелоның каты күңелен
Йомшартырга берәр җаен тапмасагыз,
Аның бүтән өмете юк. Абыегыз
Сезгә шуны җиткерергә кушты миңа.

Изабелла

Ничек? Аны җәзаларга телиме ул?

Луцио

Абыегызны үлемгә ул хөкем итте,
Аның башын кисәргә дигән боерык
Инде төрмә башлыгына тапшырылган.

Изабелла

Аһ, мин аңа ярдәм итә аламмы соң?

Луцио

Көчегезне сынап карагыз.

Изабелла

Аһ, кайда?
Минем нинди көчем булсын? Ай-һай, белмим.

Луцио

Шик хыянәт итә безгә күп вакытта,
Җиңүгә ирешергә мөмкин чакта
Кулны бәйли, хәрәкәттән тыя безне.
Тиз булыгыз, Анжелога йөгерегез,
Мөлаем кыз сораганда, ир кешенең
Алладан да юмартрак булганлыгын
Үзе татып белсен әле. Әгәр дә кыз
Тезен чүксә, күз-яшь түксә, анда, бәлки,
Кыз теләге — үз теләге булып китәр.

Изабелла

Тырышып карыйм!

Луцио

Тиз булыгыз.

Изабелла
Хәзер китәм,
Остазыма гына кереп белдерәм дә
Йөгерәм. Рәхмәт. Сәлам күндер абыема.
Бүген кичкә, төн җиткәнче,
Сөйләшүнең нәтиҗәсен белдерермен.

Луцио
Сау булыгыз.

Изабелла

Чын күңелдән рәхмәт сезгә!

Китәләр.
ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Анжело өенең бүлмәсе.
Анжело, Эскал, Судья, Төрмәче, Полиция һәм сакчылар керәләр.

Анжело

Законны без, бакчаларга куела торган
Карачкыдай, хәрәкәтсез тоталмыйбыз,
Әрсез кошлар, тиз арада күнегеп китеп,
Карачкының түбәсенә менеп куна.

Эскал

Анысы шулай, ләкин кансыз булу нигә?
Мин коткарып калыр идем ул егетне.
Атасын да яхшы беләм: бик инсафлы,
Күркәм кеше иде, мәрхүм... уйлагызчы.
Гәрчә сезне бик әхлаклы, тотанаклы
Кеше итеп белсәм дә, мин сорар идем:
Кайчан булса, ничектер бер җае чыгып,
Урны ипле туры килеп, көчле теләк —
Ихтыярга буйсынмаслык дәрт кузгалса,
Әйтегезче, зинһар, әлеге егет кылган
Гөнаһтан сез тыела алыр идегезме?
Шулай ук сез беркайчан да шул законга
Хилаф эшне кылганыгыз юкмыни соң?

Анжело

Ымсыну — бер, гөнаһ кылу — икенче эш.
Дөрес, хөкем итүчеләр төркемендә
Гаепләнүчедән бик күп гөнаһлырак
Кешеләр дә булуы мөмкин. Закон бит ул
Күренеп торган гаепләргә җәза бирә.
Каракны карак хөкем итә икән,
Аннан нинди зарар? Без бит җирдә яткан
Бриллиантны күрсәк кенә иеләбез,
Күренмәсә, аны таптап үтәбез ич!
Минем гөнаһ кылуым да ихтимал дип,
Аның гаебен йомшартырга тырышмагыз.
Әгәр дә мин, аны хөкем иткән кеше,
Нәкъ шундый ук гөнаһ кылсам, үз хөкемем
Үз башыма җитсен! Ул үләргә тиеш.

Эскал

Хуп, сезнеңчә булсын әйдә.

Анжело

Кайда төрмә башлыгы?

Төрмәче

Мин монда, синьор.

Анжело

Иртән сәгать нәкъ тугызда, соңламыйча,
Клавдионың башы тиеш киселергә.
Бүген аңа руханины чакырыгыз,
Тәүбә иттерсен, үлемгә әзерләсен.

Төрмәче китә.

Эскал

Кичер аны, Раббым, кичер барыбызны да.
Кайберәүләр гөнаһ эшләп күтәрелә,
Кайберәүләр харап була саф булганга.

Берәү чиксез күп явызлык эшләсә дә
Исән кала.
Берәү исә бөтенләй юк гаеп өчен
Башын сала.

Терсәк, Сакчылар, Күбек һәм Мәзәкче керәләр.

Терсәк. Монда кертегез үзләрен! Җәмгыятьнең юньле генә кешеләре юньсезлек эшләүдән бушамагач, белмим инде, нәрсә генә булып чыгадыр бу закон дигәннәре. Монда кертегез!

Анжело. Бу нәрсә тагын, кем син, нәрсә бар?

Терсәк. Рөхсәт итсәгез, әфәндем, сезнең каршыгызда Герцог җәнабларының тәртип саклаучысы. Мине монда Терсәк дип йөртәләр. Законга таянып эшләүче мин, әфәндем. Менә каршыгызга эштән чыккан эшлеклеләрне китердем.

Анжело. Эшлеклеләр? Нинди эшем кешеләре? Эшлексезләр түгелме?

Терсәк. Рөхсәт итсәгез, әфәндем, кем икәнлекләрен үзем дә рәтләп белмим. Шунысы гына миңа көн кебек ачык, үтә чыккан кабахәтләр алар. Бернинди һөнәрләре — профанацияләре юк. Профанациясез нинди христиан инде ул?

Эскал. Менә әйтте ичмасам! Бигрәк галим икән бу тәртип саклаучы.

Анжело. Эш турында сөйләшик, кемнәр соң болар? Үзеңне Терсәк дип йөртәләр дидең бугай. Йә, ник дәшмисең син, Терсәк, сөйлә!

Мәзәкче. Ул сөйли алмый, әфәндем, ертык терсәк бит ул, ямау салырга кирәк.

Анжело. Ә син кем?

Терсәк. Улмы, әфәндем? Шайтан ялчысы, уйнашчылар кавыштыручы. Бик әшәке бер хатында хезмәт итә. Ул хатынның шәһәр читендә фәхешханәсе бар иде — бетерделәр. Хәзер әнә шәһәр уртасында мунча ачып җибәргән, диләр. Анысы да бик шикле урын. Анда да шул элекке кәсебен алып бара шикелле.

Эскал. Син моны каян беләсең?

Терсәк. Хатыным әйтте, әфәндем, ул каһәр суккан эт тә кеше инде, ялган сүзнең хас дошманы.

Эскал. Ничек, хатыныңмы?

Терсәк. Әйе, әфәндем, ул, Аллага шөкер, намуслы хатын.

Эскал. Алайса, нигә син аны каһәр суккан дисең?

Терсәк. Чөнки без икебез дә каһәр суккан эт кешеләр, ялган сүзне үлеп яратмыйбыз. Сез аңа миңа ышанган кебек ышаныгыз. Ул әшәке хатынның мунча дигәне фәхешханә булып чыкмаса, чәнчелеп китим.

Эскал. Нигә бу кадәр кистереп әйтәсең, каян белдең?

Терсәк. Ничек инде, әфәндем, хатынымнан белдем. Әгәр дә минем хатыным табигате белән себерке булмаса иде, анда аны бик тиз бозыклыкка, фахишәлеккә өйрәтерләр иде.

Эскал. Теге хатын аркасындамы?

Терсәк. Әйе, әлеге шул Таушалган ханым аркасында. Ләкин минем хатын менә бу егетнең битенә лач иттереп төкергән дә шуның белән эш тә беткән.

Мәзәкче. Рөхсәт итсәгез, әфәндем, андый хәл булмады.

Терсәк *(Анжело белән Эскалны күрсәтеп)*. Алайса исбат ит менә шушы кабахәтләр алдында, намуслы егет, йә әле, исбат ит!

Эскал. Ишетәсезме, ничек бутый ул сүзләрне.

Мәзәкче. Әфәндем, аның хатыны безгә корсаклы көйгә килде — пешкән караҗимеш кирәк булган аңа. Ә бездә нибары ике бөртек караҗимеш табылды. Тәлинкәдә яталар иде. Тәлинкәсе шундый, өч тиенлек кенә үзе — чынлап әйтәм, андый тәлинкәне күргәнегез бардыр, әфәндем. Әлбәттә, кытай чынаягы түгел инде ул, шулай да менә дигән тәлинкә.

Эскал. Ташла әле шул тәлинкәңне, сүз тәлинкә турында бармый.

Мәзәкче. Дөрес, әфәндем, тәлинкәнең монда һичбер катнашы юк, дөрес әйтәсез, эшнең асылына күчик. Терсәк әфәнденең хатыны, әле әйткәнемчә, тегеләй-болай иде, корсаклы бит инде, караҗимеш теләгән, теләсәң каян тап та бир син аңа. Ә бездә, әле әйткәнемчә, нибары ике бөртек караҗимеш торып калган. Чөнки, Күбек әфәнде — менә каршыгызда тора ул — барын да тыгынып бетергән. Җимешнең хакын, әле әйткәнемчә, тулысынча түләде ул, мул итеп түләде. Чөнки, хәтерлисезме, Күбек әфәнде, сезгә кайтарып бирергә минем вак акчам да җитмәде.

Күбек. Әйе шул, җитмәде, бик дөрес.

Мәзәкче. Менә күрәсез! Нәкъ шул чакта сез әлеге караҗимешнең төшен ватып ашап тора идегез.

Күбек. Әйе, шулай, бик дөрес.

Мәзәкче. Менә күрәсез! Шунда мин сезгә әйттем дә әле — фәлән кеше, дидем, чукынса да сәламәтләнә алмый, дидем, нинди авырудан икәнен беләсез инде.

Күбек. Дөрес, бик дөрес.

Мәзәкче. Менә күрәсез!

Эскал. Син эчпошыргыч ахмак. Эш турында сөйләшик. Терсәкнең хатынын нишләттегез, ул нидән зарлана? Кайчан шуның төбенә төшеп җитәбез?

Мәзәкче. Анын төбенә җитеп булмый, әфәндем.

Эскал. Анысын әйтмим лә!

Мәзәкче. Хәер, бик тырышсагыз, әфәндем, ихтимал, төбенә дә җитәрсез. Түбәнчелек белән үтенәм сездән, менә Күбек әфәндегә карагыз әле, еллык килере сиксән алтын. Күптән түгел генә атасы үлде, изгеләр бәйрәме көнне. Дөрес бит, Күбек әфәнде, изгеләр бәйрәме көнне бит?

Күбек. Бәйрәм алдыннан, кич белән.

Мәзәкче. Менә күрәсез, хаклык һәрвакыт кычкырып тора ул, әфәндем. Ә бу әфәнде нәкъ шул чакта йомшак мендәрдә тәбәнәк урындыкта утыра иде, «Йөзем тәлгәше» дип йөртелә торган бүлмәдә, үзегезнең ярата торган урыныгызда. Дөрес бит, әфәндем, яратасыз бит сез ул урынны?

Күбек

Дөрес, яратам, кыш көне анда җылы була.

Мәзәкче

Менә күрәсез, хаклык үзенекен итә ул.

Анжело

Бу әңгәмә, Рәсәйдәге кышкы төн күк,
Һаман сузыла, иге-чиге күренми һич...
Мин китәм, син ахырынача тыңлап бетер,
Барысын да яткырып суктырырга
Сылтавын табарсың дип өмет итәм.
Эскал.Табармын дип уйлыйм, граф. Сау булыгыз.

Анжело китә.

Зинһар, дим, соңгы тапкыр: Терсәкнең хатынын нишләттегез?

Мәзәкче. Соңгы тапкыр, дисезме, әфәндем? Соңгы тапкыр без аны берни дә эшләтмәдек.

Терсәк. Түбәнчелек белән үтенәм, әфәндем, зинһар, дим, бу кешенең үзеннән сорагыз әле, ни эшләде икән ул минем хатын белән?

Мәзәкче. Түбәнчелек белән үтенәм, әфәндем, миннән сорагыз!

Эскал. Әйт алайса, бу кеше Терсәкнең хатынын ни эшләтте?

Мәзәкче. Ни эшләтсен инде! Зинһар, дим, әфәндем, бу кешенең йөзенә карагыз. Ә сез, Күбек әфәнде, аңа карагыз, мин моны сезгә яхшылык теләп әйтәм... Әфәндем, карадыгызмы?

Эскал. Йә, карадым.

Мәзәкче. Зинһар, дим, җентекләбрәк карагыз.

Эскал. Карадым, йә, шуннан?

Мәзәкче. Аның йөзендә нинди дә булса әшәкелек күрәсезме?

Эскал. Юк шикелле!

Мәзәкче. Ә мин ант итеп әйтәм, аның бөтен әшәкелеге дә шул йөзендә генә, ә сез аны да әшәкелек дип санамыйсыз. Шулай булгач, менә үзегез әйтегез инде, әфәндем, бу кеше Терсәкнең хатынына начарлык эшли аламы соң?

Эскал. Ул дөрес әйтә. Моңа син ни дисең, Терсәк әфәнде?

Терсәк. Рөхсәт итсәгез, әфәндем, беренчедән, ул йорт бик шикле йорт, икенчедән, менә бу егет тә бик шикле, өченчедән, аның хуҗасы — әлеге хатын да бик шикле.

Мәзәкче. Эш алайга китсә, аның үз хатыны барыбыздан да шиклерәк.

Терсәк. Нәрсә, нәрсә? Ялганлыйсың син, кабахәт, ялганлыйсың, телеңә тилчә чыккыры! Минем хатыным шикелле булырга, теге?! Андый мәсхәрәгә калганы юк әле. Ир белән дә, хатын белән дә, бала белән дә — Аллага шөкер.

Мәзәкче. Аның белән никахка кадәр үк торгансың дип үзеңнән дә шикләнгәннәр.

Эскал. Кем тапкыррак соң монда, гаепләүчеме, әллә гаепләнүчеме?

Терсәк. Ах син, явыз, ах син, кабахәт! Ах син, намуссыз Ганнибал, әгәр дә мәгәр никахка кадәр үк хатынымнан яки үземнән бер генә кеше шикләнгән булса да, мине Герцогның тәртип сакчысы итеп санамагыз. Исбат ит, явыз Ганнибал, юкса мин сине яла ягуда гаепләп судка бирәм.

Эскал. Әгәр дә ул синең колак төбеңә берне тондырса, яла якты дип гаепли аласыңмы?

Терсәк. Ах, кадалып киткере, булмый икән шул. Киңәшегез өчен рәхмәт, әфәндем. Алайса, бу явыз кабахәтне сез нишләтергә боерасыз?

Эскал. Беләсеңме, син бит аңардан бозыклык эшли дип шикләнәсең, шуны исбат итәргә телисең икән инде, үз иркенә куй да шым гына күзәт.

Терсәк. Киңәшегез өчен рәхмәт, әфәндем. Менә эләктеңме, кабахәт? Үз иркеңә куям мин сине, белдеңме, үз иркеңә!

Эскал. Сез кайда тудыгыз, дускай?

Күбек. Вена шәһәрендә, әфәндем.

Эскал. Алай. Еллык килерегез чыннан да сиксән алтынмы?

Күбек. Әйе, әфәндем, әгәр дә рөхсәтегез булса.

Эскал. Алай. Ә син, чибәр егет, нинди кәсеп белән көн итәсең?

Мәзәкче. Йомышчы мин... Кунакларга шәраб ташыйм. Ярлы тол хатында хезмәт итәм.

Эскал. Хуҗаңның исеме ничек?

Мәзәкче. Таушалган ханым дип йөртәләр.

Эскал. Бер генә ире булганмы, әллә берничәме?

Мәзәкче. Тугыз ире булган, әфәндем, тугызынчысыннан таушалып калган.

Эскал. Тугыз? Якынрак килегез, Күбек әфәнде. Шәраб ташучы белән дус булырга киңәш бирмәс идем. Алар сезне тиз арада савып бетерерләр, ә сез аларны дар агачына озатырсыз. Барыгыз, моннан соң ил теленә керәсе булмагыз.

Күбек. Рәхмәт, әфәндем. Мин бит кабакка үзем кермим, кешеләр алып керә.

Эскал. Ярый, җитте, хушыгыз.

Күбек чыга.

Монда рәхим ит, йомышчы әфәнде, исемең ничек?

Мәзәкче. Помпей.

Эскал. Фамилияң?

Мәзәкче. Койрык асты дип йөртәләр.

Эскал. Әйе, исемең үзеңә бик туры килә икән. Кәсебең дә койрык тирәсендә. Шәраб ташыган булып, бозыклыкка димләп, уйнашчылар кавыштырып йөрисең. Шулай бит? Дөресен әйт, үзең өчен яхшырак булыр.

Мәзәкче. Дөресен, дисезме, әфәндем? Мин ярлы кеше, минем дә бит яшисем килә.

Эскал. Ничек яшисең килә, Помпей? Бозыклыкка димләп, уйнашчылар кавыштырыпмы? Бу кәсеп турында син ни уйлыйсың, законга сыямы бу кәсеп?

Мәзәкче. Сыйдырсаң, сыя инде.

Эскал. Закон сыйдырмый, Помпей. Вена шәһәрендә аңа юл кую бетте.

Мәзәкче. Шәһәрнең барлык егетләрен дә печтерәсезмени?

Эскал. Юк, Помпей.

Мәзәкче. Ул чагында инде, әфәндем, бездән башка аларның эше пешми, уйнашчы ирләр белән фахишәләргә каршы чара күрсәгез, кавыштыручылардан куркырга туры килмәс.

Эскал. Чарасы күрелер. Анысы өчен кайгырма, тотылган һәрбер уйнашчы йә дарга асыла, йә башы киселә.

Мәзәкче. Шуның өчен генә башлар кисә башласагыз, ун елдан бер баш та калмас, каян туры килсә, шуннан яңа башлар китертергә туры килер. Әгәр дә бу закон ун ел яши алса, менә әйтте диярсез, мин сезгә өч тиенгә Вена шәһәрендәге иң һәйбәт йортны алып бирәм, шул көнгә кадәр яши алсагыз, менә Помпей әйткән иде диярсез...

Эскал. Рәхмәт, сөекле Помпей. Киләчәктән хәбәр бирүең өчен бүләк рәвешендә тыңла: моннан соң синең өстеңнән миңа беркем килеп сөйләмәсен, хезмәт итә торган йортыңнан киткән бул. Юкса мин сине, бөек Помпейны Цезарь куган кебек, чатырыңа куып кертермен дә үзем сиңа хәтәр Цезарь булырмын. Гади итеп әйтсәк, ыштаныңны салдырып камчы белән ярдырырмын. Ә хәзергә, Помпей, сау булып тор.

Мәзәкче. Киңәшегез өчен рәхмәт, әфәндем. Ләкин тыңлармынмы аны, юкмы — анысын инде нәфсем иркенә тапшырам.

Мине камчыларга? Юк, юк!
Камчылагыз җирән чаптарны.
Батыр егет сөйгән кәсебен
Камчылаудан куркып ташлармы?

Китә.

Эскал. Инде сез килегез, Терсәк әфәнде, рәхим итегез, тәртип башлыгы. Күптән хезмәт итәсезме бу урында?

Терсәк. Җиде ел ярым.

Эскал. Вазифагызны үтәүдән күрдем инде, бу эштә сез яңа кеше түгел. Җиде ел, дисезме?

Терсәк. Җиде ел ярым, әфәндем.

Эскал. Бу вакыт эчендә күпме җәфа чиккәнсез, күпме көч түккәнсездер. Сезне юкка газаплыйлар. Урамыгызда сездән башка кеше юкмыни соң?

Терсәк. Кешеләр бар ла ул, әфәндем, тик дөресен әйтергә кирәк, бу эшнең рәтен белүчеләр аз. Аларны сайлап куюлары була, бөтен эшне шатлана-шатлана миңа йөклиләр. Шулай итеп, аз гына түләү хакына аларны мин алмаштырам. Барысы өчен дә үзем эшлим.

Эскал. Иртәгә миңа сәләтлерәк алты-җиде кешенең исемлеген кертегез.

Терсәк. Өегезгәме?

Эскал. Әйе, өемә. Хушыгыз.

Терсәк китә.

Сәгать ничә?

Судья. Төгәл унбер булды.

Эскал. Төшке ашны әйдә бергә ашыйк.

Судья. Рәхмәт.

Эскал

Клавдионың язмышы бик борчый мине,
Ләкин ярдәм итеп булмый берничек тә.

Судья

Граф Анжело бигрәк инде каты кеше.

Эскал

Хәер, ансыз булмый да шул. Кайчагында
Шәфкать дигәнең дә шәфкать булып чыкмый,
Яңа гаеп эшләнүгә сәбәп була.
Шулай да бик кызганыч бу Клавдио!..
Һич кенә дә ярдәм итеп булмый. Киттек!

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук. Икенче бүлмә.
Төрмәче белән Хезмәтче керәләр.

Хезмәтче

Эше бар шул әле, тиздән монда чыгар.
Сез килгәнне хәзер кереп әйтәм.

Төрмәче
Зинһар.

Хезмәтче китә.

Сорыйм әле, бәлки, күңеле йомшап куяр.
Мескен егет... Бу гөнаһ ни... Гөнаһмыни?
Төштә күргән кебек кенә кылган бит ул.
Бу эштә һәркем гөнаһлы — карты, яше,
Фәкать шуның өчен кеше үлсен, имеш!

Анжело керә.

Анжело

Нәрсә кирәк?

Төрмәче

Клавдионың башын иртән кисәргәме?

Анжело

Әйтмәдемме? Сиңа боерык бирмәдемме?
Бу мәгънәсез сорау нигә кирәк булды?

Төрмәче

Ашыгудан куркам. Әгәр рөхсәт булса,
Әйтер идем: гаеплене җәзалагач
Хакимнәрнең үкенгәнен күргәнем бар.

Анжело

Ансын инде миңа калдыр, эшеңне бел,
Булмый икән, рәхим итеп урының бушат,
Син булмаудан эш тукталмас.

Төрмәче

Кичерегез.
Джульеттаны нишләтергә? Газаплана,
Озакламый ул бит бала тудырачак.

Анжело

Җайлы җиргә урнаштыр, ләкин тизрәк.

Хезмәтче керә.

Хезмәтче

Теге... башы киселәсе яшь егетнең
Сеңлесе килгән анда, сезне сорый.

Анжело

Сеңлесе бармыни аның?

Төрмәче

Бар, әфәндем.
Сирәк очрый торган гаҗәп инсафлы кыз,
Монастырьга кермәкче иде шул көннәрдә,
Бәлки инде, кергәндер дә.

Анжело

Бар әйт, керсен.

Хезмәтче китә.

Ул уйнашчы хатынны син күчерерсең,
Сораганын бирерсең, тик юмартланма,
Махсус боерык булыр сиңа.

Луцио белән Изабелла керәләр.

Төрмәче

Ярый, сау булыгыз.
Анжело.Чү, торып тор! *(Изабеллага.)* Боерыгыз, нәрсә кирәк?
Изабелла

Кайгым бик зур, сездән шәфкать сорыйм, синьор,
Тыңлагызчы үтенечемне.

Анжело
Йә, әйтегез.

Изабелла

Бер гөнаһ бар... минем өчен иң җирәнеч,
Җәзаның иң катысына лаек гөнаһ;
Һич сорамас идем аны кичерүне,
Ләкин сорыйм, башка юл юк, мәҗбүрмен мин.

Анжело

Йә, әйтегез, нәрсә соң ул?

Изабелла

Минем абыем...
Үлем җәзасына хөкем ителгән ул.
Ялынып сорыйм. Гөнаһын сез җәзалагыз,
Әмма үзен кызганыгыз.

Төрмәче

*(үзенә)*

Раббым Хода,
Граф күңелен йомшартырлык көч бир кызга.

Анжело

Ничек инде! Гөнаһны җәзаларга,
Гөнаһ кылган кешене кызганырга?
Җинаятьне хөкем итеп торасы юк,
Аны закон хөкем иткән, әгәр дә мин
Гөнаһны тагын бер кат хөкем итеп,
Гөнаһ кылган кешене гафу итсәм,
Хакимлекнең ни мәгънәсе калыр иде?

Изабелла

Аһ! Гадел шул закон, ләкин бигрәк каты.
Болай булгач, мин абыйсыз калам икән.
Хак Тәгалә үзе сезне ярлыкасын...

Китәргә тели.

Луцио
*(Изабеллага)*

Чигенмәгез! Каршысына тезләнегез!
Чабуына ябышыгыз, ялыныгыз!
Сүзләрегез үтә салкын. Болай ялынып
Энә дә алып булмый. Йә, яңадан!

Изабелла

Ул үләргә тиешмени?

Анжело

Башка юл юк.

Изабелла

Бар андый юл. Аны сез кичерә аласыз.

Анжело

Мин кичермим.

Изабелла

Теләсәгез, кичерә аласыз.

Анжело

Теләмим мин, әнә шуңа кичерә дә алмыйм.

Изабелла

Кичерсәгез, аннан дөнья җимерелерме?
Әгәр дә сез аны миндәй кызгансагыз...

Анжело

Аңа инде хөкем чыкты, соңга калдык.

Луцио

*(Изабеллага акрын)*
Бигрәк салкын сөйләшәсез.

Изабелла

Соң, дисезме? Юк, соң түгел.
Әйткән сүзне кире алып булмыймыни?
Ышаныгыз: хакимлек гөрзие дә,
Падишаның башындагы алтын таҗ да,
Гаскәр башлыгының алмаз кылычы да,
Хакимнәрнең мәһабәт киеме дә

Шәфкать кебек балкый алмый — аңа тиң юк.
Абыем белән урыннарны алмашсагыз,
Мондый каты булмас иде минем абыем.

Анжело

Җитте!

Изабелла

Сезнең урында мин булсам әгәр,
Ә сез миннән рәхим-шәфкать сорасагыз,
Шундый миһербансыз булыр идемме мин?
Судьяның да, җәзаланыр кешенең дә
Хәлен аңлый алыр идем.

Луцио
*(Изабеллага акрын гына)*

Шәп. Дәвам ит!

Анжело

Абыегызны гадел закон хөкем итте,
Сүзегезне юкка әрәм итәсез.

Изабелла

Аһ!
Хәсрәт! Хәсрәт! Кайчандыр һәр җан иясе
Котылгысыз һәлакәткә дучар булган.
Ләкин Алла булып Алла кичерә алган.
Әгәр бөек Хода сезнең үзегезне
Гөнаһларга карап кына хөкем итсә,
Сез нишләрсез? Әгәр шуны уйласагыз,
Яңа кеше булырсыз сез, сулышыгыздан
Рәхим-шәфкать җылылыгы аңкый башлар.

Анжело

Буйсыныгыз язмышка, әй, мөлаем кыз.
Мин түгел бит, закон хөкем итте аны.
Туган энем яки улым булса да ул,
Язмышы шул булыр иде. Ул үләчәк
Иртән таңда.

Изабелла

Иртән таңда? Аһ, ничек тиз!
Кичерегез! Үлемгә ул әзер түгел.
Ашка дигән чебине дә
Вакыты җитми суймыйбыз бит.
Ходай каршысында бурыч
Үз карныбыз каршындагы бурычтан да
Киммени соң? Олуг граф,
Уйлагызчы, зинһар, мондый гөнаһ өчен
Моңарчы кем җаны белән җавап биргән?
Ә бит күпләр бу гөнаһны кылып килгән.

Луцио
*(Изабеллага акрын гына)*

Әйбәт! Бик шәп.

Анжело

Законыбыз йоклый иде,
Ләкин әле исән иде. Әгәр дә без
Тәүге гөнаһ кылучыны җәзаласак,

Башкалары батырчылык итмәс иде.
Хәзер закон күзен ачты — барын күрде
Карап үзенең серле көзгесеннән:
Саксызлыктан үрчеп киткән бозыклыкның,
Яңа туып килә торган гөнаһларның
Күплегенә хәйран калды, һәм, моннан соң
Бозыклыклар булмасын дип, барын-барын
Тумас борын бетерергә карар кылды.

Изабелла

Ичмасам, чак кына шәфкать күрсәтегез!

Анжело

Катылыгым белән шәфкать күрсәтәм мин.
Кешеләрне
Катылыгым белән саклыйм һәлакәттән,
Берне үтереп, бик күпләрне коткарам мин;
Җинаятьче каршында да хаклы булам:
Бер җинаять өчен аңа җәза биреп,
Икенчесен эшләвеннән тыеп калам.
Җитте. Тыңла, үлем аңа. Сау булыгыз.

Изабелла

Әүвәл башлап сез чыгарган бу хөкемнең
Иң беренче корбаны минем абыем.
Чиксез көчкә ия булу шәп, әлбәттә,
Ләкин аннан файдалану — әшәкелек.

Луцио
*(Изабеллага)*

Шулай, шулай! Бик шәп булды!

Изабелла

Һәрбер кеше хуҗа булса күк күкрәүгә,
Юпитерның колаклары тонар иде,
Иң кечкенә өтек түрә юкка-барга
Дөбер-шатыр күк күкрәтә башлар иде.
Күкрәү-яшьнәү тынмас иде бер минутка.
Тәңрем, Тәңрем! Син бит яшен утың белән
Зәгыйфь миртны түгел, калын имәннәрне
Сугып көлгә калдырасың. Әмма кеше,
Бер минутлык хакимлеге-көче белән
Масаюдан башын җуеп, гайрәт чәчеп,
Онытып үзенең мескенлеген-зәгыйфьлеген,
Усал маймыл кебек ярсып, котырып китеп,
Күк каршында эшли шундый әкәмәтләр,
Фәрештәләр үкереп елый. Әгәр алар
Кеше булса, күреп мондый әкәмәтне,
Ярылганчы көләр иде.

Луцио
*(акрын)*

Кыюрак, кызый, бирелә башлады ул!

Төрмәче
*(үзалдына)*

Алла ярдәм бирсен аңа.

Изабелла

Һәркемне үз аршинына үлчәмә син,
Өстен халык изге хисне таптый бирә,

Аларда ул тапкырлыкка исәпләнә,
Түбән халык оятсызлык дип атый аны.

Луцио

Юлын таптың, әйдә, әйдә, кыюрак бул!

Изабелла

Түрәнең иң гади сүгенү сүзен әгәр
Солдат кабатласа, аны кяфер диләр.

Анжело

Бу сүзләргә минем нинди катнашым бар?

Изабелла

Өстен кеше юлдан язып куйса ялгыш,
Кулда хөкем булгач, җиңел котыла ул.
Шакыгыз үз күңелегезгә, сорашыгыз,
Абыем кылган татлы гөнаһ таныш микән?
Таныш диеп җавап бирсә күңелегез,
Абыема шундый хөкем чыгарырга
Телегез бармас.

Анжело
*(үзалдына)*

Сүзләрендә аның шундый тирән мәгънә,
Хәтта минем күңелемне биләп алды.
*(Кычкырып.)*
Хушыгыз.

Изабелла

Чү, ашыкмагыз, хөрмәтле граф.

Анжело

Ярый, яхшы. Мин уйлармын, иртәгә кил.

Изабелла

Туктагыз, мин сатып алмак булам сезне!

Анжело

Ничек? Мине сатып алмак буласызмы?

Изабелла

Әйе, сезне, бүләк биреп. Тик ул бүләк
Ходай белән икегезгә уртак була.

Луцио

*(Изабеллага акрын гына)*
Хур иттегез дисәм, ярый, төзәттегез.

Изабелла

Капчык-капчык алтын акча белән түгел,
Назлануга карап хакы үзгәрүчән
Төрле-төрле асылташ белән дә түгел.
Гаршеләргә ашкынучы дога белән,
Фани дөнья ләззәтеннән кул селтәгән
Саф күңелле кызлар гыйбадәте белән.

Анжело

Ярый, яхшы. Сез килегез иртә белән.

Луцио

Шулай! Бик шәп, хәзер әйдә кайтыйк инде.

Изабелла

Хак Тәгалә ярлыкасын сезне.

Анжело
*(үзалдына)*
Амин!
Күңелем тәмам азып бара. Бу азгынлык
Гыйбадәт кылырга да ирек бирмәс.

Изабелла

Кайчан килим?

Анжело

Үз вакытыгыз белән, иртән.

Изабелла

Сезне Алла сакласын, граф.

Изабелла, Луцио, Төрмәче китәләр.

Анжело
Әйе, синнән!
Күңелемне җилкендергән сафлыгыңнан!
Чү, нәрсә бу, кем гаепле — улмы, минме?
Аздыручы гөнаһлымы? Азучымы?
Юк, ул мине аздырмады, үзем аздым.
Мин, хуш исле миләүшә янындагы
Үләксә күк, саф һаваны бозып торам...
Хатын-кызның дәртеннән дә бигрәк, безне
Гыйффәте җилкендерә микәнни соң?
Шулкадәр киң мәйдан барда,
Фәхешханә салу өчен
Гыйбадәт йортын вату нигә кирәк?
Синме соң бу? Сафлыгы өчен бу кызның син
Гыйффәтен таптарга телисеңме?
Исән калсын, яши бирсен аның абые!
Судья үзе урлашканда,
Каракларның йорт басарга хаклары бар.
Нишләдем мин? Гашыйк булдым микәнни соң?
Һаман-һаман тавышын ишетәсем,
Карыйсым килә аның күзләренә.
Ни телим мин? Аһ, хәйләкәр, Иблис ләгыйнь!
Пакьлекне җим итәсең дә кармагыңа
Үтә сабыр әүлияны аулыйсың син.
Бу дөньяда иң куркыныч вәсвәсә бу,
Җилкендереп күңелләрне сафлык белән,
Азгынлыкка, бозыклыкка алып бара.
Иң мөлаем, иң тылсымлы чибәрләр дә
Күңелемне эреткәне юк иде әле.
Әмма бүген бу гафиф кыз җиңде мине.
Кайчан гына мәхәббәттән көлә идем,
Гашыйкларны дивана дип белә идем.

Китә.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төрмә бинасы.
Бер яктан монах киеме кигән Герцог, икенче яктан Төрмәче керәләр.

Герцог

Сәлам сезгә! Ялгышмасам, сез — Төрмәче?

Төрмәче

Әйе, бу мин. Нәрсә кирәк, изге ата?

Герцог

Изге бурычым һәм намусым кушканлыктан
Тоткынлыкта җәфа чиккән кардәшләрнең
Хәлләрен белергә дип килгән идем.
Алар белән күрешергә рөхсәт сорыйм.
Сөйләшергә, рухи ярдәм күрсәтергә
Җиңелрәк булсын өчен, һәркайсының
Нинди гаеп өчен монда эләгүен
Бәйнә-бәйнә сөйләп миңа аңлатыгыз.

Төрмәче

Сезнең өчен артыгын да эшли алам.

Джульетта керә.

Менә берсе. Затлы дворян нәселеннән,
Яшьлек дәрте белән артык мавыгып китеп,
Кызлык намусын җуйган. Хәзер бала көтә,
Егетенең башы киселергә тиеш.
Анысы да яшь. Газиз башын кистергәнче,
Бу гөнаһны икенче кат кабатласа,
Килешлерәк булыр иде аның өчен.

Герцог

Аны кайчан җәзалыйлар?

Төрмәче

Иртән бугай.
*(Джульеттага.)*
Мин барын да әзерләдем, сез көтегез,
Озакламый сезне алып китәчәкләр.

Герцог

Сылу кызым, әйтче: кылган гөнаһ өчен
Үкенәсеңме?

Джульетта

Бик үкенәм, изге ата,
Хурлыгын да күтәрәм һич пошынмыйча.

Герцог

Үкенүең яки тәүбәң — чын тәүбәме?
Шуны ничек тикшерергә өйрәтим мин.

Джульетта

Өйрәтегез, изге ата.

Герцог

Әйтче, кызым,
Бу хурлыкның сәбәпчесен сөясеңме?

Джульетта

Әйе, сөям, нәкъ үземне сөйгән кебек,
Мин дә аның үлеменә сәбәпче бит.

Герцог

Һәлакәткә алып барган бу гөнаһны
Сез үзара ризалашып кылдыгызмы?

Джульетта

Ризалашып.

Герцог

Ул чагында сезнең гөнаһ
Аныкыннан авыррак.

Джульетта

Авыррак,
Шуңа күрә үкенәм дә. Кичер, Раббым!

Герцог

Шулай, кызым, шулай, дөрес. Тик шунсы бар:
Әгәр, кылган гөнаһ өчен кайгырмыйча,
Оялудан, гарьләнүдән кайгырсаң син,
Хак Тәгалә гөнаһыңны ярлыкамас,
Чөнки үзең өчен генә кайгыру бу.

Джульетта

Юк, гөнаһым өчен әрни минем күңелем,
Хурлыгын күтәрергә һич тартынмыйм.

Герцог

Шулай кирәк, гел шулай бул. Егетеңне
Иртән таңда җәзалыйлар дип ишеттем,
Инде аңа киттем. Ярый, сау бул, кызым.
Хак Тәгалә шәфкатеннән ташламасын.

Китә.

Джульетта

Ул үлемгә бара, ә мин торып калам.
Аһ син, язмыш, яшәү миңа нигә кирәк.
Минем өчен ул үлемнән дәһшәтлерәк.

Төрмәче

Аһ, кызганыч мескен егет, бик кызганыч.

Китәләр.

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Анжело өенең бер бүлмәсе. Анжело керә.

Анжело

Гыйбадәт тә кыла алмыйм, уйлый да алмыйм:
Үзем дога укыйм, әмма хыялларым
Изабелла тирәсеннән китә алмый һич;
Сагыз итеп чәйним һаман Алла исемен,
Ә йөрәктә ялкынлы дәрт, хайвани хис.
Дәүләт эше — күптән таныш китап кебек:
Эчтәлек шәп, ләкин коры, эчпошыргыч.
Горурланып йөрткән кырыс данымны мин,
Валлаһи, дим, — берәрсе ишетмәсен, —
Рәхәтләнеп җил иркендә очып йөргән
Җип-җиңел кош мамыгына алышыр идем.
Аһ, дәрәҗә! Аһ, син, тышкы мәһабәтлек!
Күркәмлегең белән ахмак күңелләрдә
Курку хисе тудырып кына калмыйсың син,
Хәтта акыл ияләрен сихерлисең!
Җилкендергән ялкын ялкын булып кала.
Әйдә, Иблис мөгезенә «бу изге» дип,
«Фәрештә» дип язсыннар — моннан миңа

Зарар булмас.

Хезмәтче керә.

Кем бар анда?

Хезмәтче

Ниндидер кыз.
Монах киеменнән, сезне сорый.

Анжело

Керсен.
Раббым!
Бөтен каным йөрәгемә җыйналды күк,
Тыным кысыла, буыннарым дер-дер килә.
Җаным тетри, бөтен тәнем хәлсезләнде.
Һуштан язган кешене дә менә шулай
Ахмак төркем тирә-яктан сырып ала.
Егылганга ярдәм итәм дип уйлый ул,
Әмма аңа көч бирәчәк саф һаваны
Томалавын һич кенә дә аңлый алмый.

Изабелла керә.

Йә, ни йомыш, әйтегезче, мөлаем кыз?

Изабелла

Хөкемегезне белергә дип килдем, граф.

Анжело

Ул хөкемне сорамыйча белүегез
Күңеллерәк булыр иде минем өчен.
Абыегыз үлә.

Изабелла

Ярый, нишлисең бит,
Хак Тәгалә ярлыкасын үзегезне.

Китәргә тели.

Анжело

Ләкин яши алыр иде сезнең кебек,
Минем кебек; тик шулай да үләчәк ул.

Изабелла

Хөкемегез шулмы?

Анжело

Әйе.

Изабелла

Кайчан? Зинһар, әйтегезче.
Озакмы ул, тиз буламы, шул арада
Гөнаһлардан арынырга өлгерсә иде.

Анжело

Бик әшәке гөнаһ бит бу! Сез уйлагыз:
Сау-сәламәт кешене юк итүчене
Гафу итеп булса да, зина кылып,
Качып-посып ялган акча суккан кебек,
Законсыз балалар үрчетүче
Уйнашчыны җәзаламый мөмкинме соң?
Кеше үтерү, ялган акча сугу,
Законсыз бала ясау — өчесе бер.

Изабелла

Күктә генә шулай, җирдә алай түгел.

Анжело

Шулаймыни? Алай булса әйтегезче —
Үз сүзегез белән тотам хәзер сезне —
Абыегызның таңда башы киселсенме,
Әллә аның җанын саклап калу өчен
Кызлык намусыгызны корбан итәсезме?

Изабелла

Ышаныгыз, җанымны хур иттергәнче,
Тәнемне вак кисәкләргә туратырмын.

Анжело

Сез җан дисез, мәҗбүри гөнаһ бит бу,
Моның өчен берни булмый.

Изабелла

Ни дидегез?

Анжело

Хәер, моны расламыйм мин, киресенчә,
Бу фикерне кире кагам. Сез әйтегез:
Гадел закон исеменнән
Абыегызны мин үлемгә хөкем иттем.
Хәзер аны гөнаһ кылу юлы белән
Коткарырга мөмкин булмас иде микән?

Изабелла

Коткарыгыз! Гөнаһын үз өстемә алам.
Гөнаһ булмас бу, мәрхәмәт-шәфкать булыр!

Анжело

Бу гөнаһны өстегезгә алсагыз сез,
Кылган гөнаһ белән шәфкать тигезләнә.

Изабелла

Аның җаны өчен ялыну гөнаһ булса,
Мин гыйбадәт кылу өчен көч сорармын!
Сезнең аны кичерүегез гөнаһ булса,
Кушармын да аны мин үз гөнаһыма,
Иртә һәм кич икешәр кат дога кылып,
Ярлыкавын сорармын — сез борчылмагыз!

Анжело

Мине ялгыш аңладыгыз. Нәрсә соң бу?
Беркатлымы, әллә юри кыланамы?

Изабелла

Беркатлы да булыйм әйдә, начар булыйм,
Белмәсәм ул кимчелекне, мин бәхетле.

Анжело

Үткен акыл белән хәйран итү өчен,
Зирәклекне кайчак юри яшерәләр,
Кара битлек кигән матур кызларга да
Күбрәк кызыгабыз ич. Ярый... тыңлагызчы,
Аңлашылсын өчен гади итеп әйтик:
Абыегызның башы киселә.

Изабелла

Әйе.

Анжело

Гөнаһы зур,
Мондый гөнаһ өчен аны безнең закон
Тик үлемгә хөкем итә.

Изабелла

Беләм.

Анжело

Әйтик, аны коткарырга юл да бар ди,
Тик аңлагыз, ул юлны мин тәкъдим итмим,
Болай гына әйтәм! Аның туганы сез,
Әйтик, сезгә бер кешенең күзе төшкән;
Зур кеше ул. Судьяларга да бик якын,
Хөкеме дә үз кулында, абыегызны
Һәлакәттән коткарырлык көче дә бар.
Шул кешегә гыйффәтеңне бирүдән тыш
Абыегызны коткарырга юл булмаса,
Нишләр идегез?

Изабелла

Үзем өчен нишләсәм мин,
Абыем өчен дә нәкъ шуны эшләр идем.
Үзем үлем җәзасына дучар булсам,
Тәннәремне яралаган камчы эзен
Җәүһәр-якут кебек күреп, кабергә мин
Никах түшәгенә яткан кук ятармын.
Әмма гафиф тәнемне, юк, хурлаттырмам.

Анжело

Димәк, абыең үлә.

Изабелла

Анысы җиңелрәк.
Сеңлесен салып тәмуг утларына,
Яшәгәнче бу дөньяда хурлык күреп,
Ул мескеннең хәзер үлүе әйбәтрәк.

Анжело

Бу кадәрле битәрләгән законнан сез
Кай ягыгыз белән генә шәфкатьле соң?

Изабелла

Шул хурлыкка риза булу — гыйффәт сату —
Шәфкать сорап ялыну белән бер булалмый,
Гадел закон нигезендәге шәфкатьне һич
Мәсхәрәле түләү белән тиңләп булмый.

Анжело

Менә ничек? Сез бит әле кайчан гына
Законны «бигрәк каты, рәхимсез» дип
Хурладыгыз. Абыегызның җинаяте
Уен гына булып тоела иде сезгә.

Изабелла

Аһ, граф, зинһар, кичерегез! Бик еш кына,
Алга куйган максатыңа ирешү өчен,

Үзеңә-үзең каршы килгән чаклар була.
Өзелеп сөйгән абыемның файдасы өчен
Җаным белән дошман күргән гөнаһны мин
Кичергәнмен.

Анжело

Барыбыз да шундый йомшак.

Изабелла

Бар кешенең йомшаклыгы — гөнаһы өчен
Минем абыем берьялгызы гаепле икән,
Үлсен әйдә.

Анжело

Хатын-кыз да нечкә, йомшак.

Изабелла

Каршыбызга элеп куйган көзге кебек...
Ялгыш кына бәрелсәк тә, хәзер ватыла,
Шәүләбезне дә бик җиңел чагылдыра.
Аһ, хатыннар... Алла ярдәм бирсен сезгә.
Ирләр сезне явызларча файдаланып
Хур итәләр. Әйе, безне нечкә хисле,
Ышанучан булган өчен йомшак, дисез.

Анжело

Әйе, дөрес.
Үзегезнең йомшаклыкны үзегез әйткәч,
Мин дә әйтим: без ирләр дә көчле түгел,
Нәкъ сезнең күк, азгынлыкка бирелүчән.
Кыюрак булыйм инде, үзегез әйткәч:
Йомшак икән — йомшак булып калыгыз да,
Сез — хатын-кыз, артыгы һич кирәк түгел,
Аннан сезгә зарар гына. Сез — хатын-кыз, —
Килбәтегез шул турыда сөйләп тора, —
Күрсәтегез шуның дөрес икәнлеген,
Үзегезгә хас киемгә төренегез.

Изабелла

Граф, мин бер телдә сөйлим, зинһар өчен,
Минем белән элеккечә сөйләшегез.

Анжело

Гади итеп әйтеп бирим: сөям сезне.

Изабелла

Минем абыем Джульеттаны өзелеп сөйде,
Шуның өчен ул үлә, дип әйттегез ич.

Анжело

Әгәр дә син мине сөйсәң, үлмәячәк!

Изабелла

О, аңладым, асылда, сез саф күңелле,
Әмма ләкин мине сынау өчен, юри
Үзегезне бозык итеп күрсәтәсез...

Анжело

Ышаныгыз, намусым белән ант итәм мин,
Чынлап әйтәм: күңелемнең теләге бу.

Изабелла

Шакшы теләк! Аһ, әшәке, икейөзле!

Саклан! Сине фаш итәм мин ил каршында.
Абыемның гаебен кичер, куй имзаңны.
Кичермәсәң, кычкырам бар җир йөзенә,
Битлегеңне ертам.

Анжело

Сиңа кем ышана?
Исемем данлы, үзем сабыр, тотанаклы,
Ил каршында дәрәҗәм зур өстәвенә,
Гаебемне тансам, үлчәү тәлинкәсе
Кем ягына басар? Шундук тончыгырсың,
Сине яла ягучы дип гаепләрләр.
Дулый минем хисләрем, һич тыясым юк,
Каршы килмә, котырам мин, бирел хәзер.
Кылануың ташла, оят бетсен, китсен,
Ул синең үз теләгеңне буып тора.
Абыеңның җанын коткар! Тизрәк бирел.
Буйсын минем ихтыярга! Юкса бел син:
Абыеңның башы киселеп кенә калмас,
Фәкать синең кирелегең аркасында
Чиксез каты газапларга дучар булыр.
Җавабын мин бүген димим, иртәгә бир.
Ләкин кара,
Ант итәм мин кайнап торган дәртем белән,
Кансыз тиран булырга да кыйбат алмам!
Теләгәнчә сөйлә, ләкин минем ялган, —
Бик белеп тор, кызый, — синең хаклыгыңны
Мәсхәрәләп таптап үтәр.

Китә.

Изабелла

Кемгә барыйм? Кайда мине яклаучылар?
Минем әйткән сүзләремә кем ышана?
Аһ, әшәке, ялганчы тел! Шул бер үк тел,
Законны үз теләгенә буйсындырып,
Нахагын һәм хагын анда-монда борып,
Йә үлемгә хөкем итә, яки аклый.
Абыема барыйм, үзен тыялмыйча
Бик зур гөнаһ эшләсә дә, намуслы ул.
Егерме башы булса, егермесен
Егерме балта астына илтеп тыгар,
Әмма сеңлен бу хурлыкка төшермәс ул!
Сафлык өчен туганымны итәм корбан,
Сафлык-гыйффәт кыйммәтрәк туганымнан.
Барыйм, әйтим: көчен җыйсын, борчылмасын,
Газраилне батырларча каршыласын.

Китә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төрмә бүлмәсе.
Монах киеме кигән Герцог, Клавдио һәм Төрмәче керәләр.

Герцог

Син графтан шәфкать өмет итәсеңме?

Клавдио

Һәлакәткә төшүченең дәвасы бер:
Ерактагы өмет нуры. Яшәргә дә
Өмет итәм, үләргә дә әзер торам.

Герцог

Син үләм дип уйла. Әгәр яшәү килсә,
Куанырсың, үлүе дә җиңел булыр.
Тормышка син болай диген:
«Сине җую — нәрсә миңа?
Җүләрләрнең генә сиңа исе китә.
Син үлемнең уенчыгы, аңардан син
Котылмакчы, ә үзең гел куенына
Сыенасың. Батырлыкмы инде шушы:
Еланның ике аерылы телен күрсәң
Котың оча. Иң әйбәт ял сиңа — йокы,
Чакырасың аны. Әмма үлемнән син
Дер тетрисең. Ә бит ул да йокы гына.
Бай булсаң да, эштән чыккан бер фәкыйрь син.
Алтын йөге төяп барган ишәк кебек,
Чиксез авыр йөктән синең сыртың сыгыла,
Ә ул йөкне үлем генә алып ташлый.
Яшьлекне дә белмисең син, картлыкны да,
Синең өчен алар бары төш шикелле.
Яшьнәп торган яшьлегең дә картлык төсле —
Бәлтерәгән картлыктан ул хәер сорый.
Карт көнеңдә баесаң да, рәтең китә:
Дәртең дә юк, дәрманың да, ямең дә юк,
Байлыгыңның рәхәтен һич күралмыйсың.
Кайда соң ул синдә рәхәт ямьле тормыш?
Һәр почмакта чекерәеп үлем тора».
Без куркабыз аннан... ә бит шушы үлем
Бар газапка, каршылыкка чик куючы.

Клавдио

Рәхмәт сезгә, изге ата. Мин аңладым...
Тормыш диеп, үлем белән очрашам,
Үлемемә омтылуда тормыш табам.
Шулай булгач, үлем килә бирсен әйдә.

Изабелла
*(Сәхнә артыннан)*

Әй, ачыгыз, кем бар анда, сәлам сезгә!

Төрмәче

Кем ул? Керегез, кер, сезнең ният изге —
Хөрмәт белән каршылауга лаеклы сез.

Герцог

Улым, сиңа соңрак тагын килермен мин.

Клавдио

Чын күңелдән рәхмәт сезгә, изге ата!

Изабелла керә.

Изабелла

Абый белән сөйләшергә кирәк миңа.

Төрмәче
*(Изабеллага)*

Рәхим итегез. *(Клавдиога.)* Сеңлегез килде сезгә.

Герцог
*(Төрмәчегә)*

Бер генә сүз!

Төрмәче

Теләгән кадәр рәхим итеп.

Герцог

Мине хәзер берәр җиргә яшерегез,
Алар сүзен ишетер идем.

Герцог белән Төрмәче китәләр.

Клавдио

Ни бар, сеңлем? Юанычлы нинди хәбәр?

Изабелла

Һәр хәбәр күк, синең өчен күңелле ул.
Барсы да әйбәт, әйе, бар да әйбәт.
Анжелоның күкләрдә йомышы бар,
Ашыктырып сине шунда җибәрә ул.
Вәкил булып мәңге анда каласың син,
Әйбәт итеп әзерлән хәзер юлга,
Иртән сәфәр.

Клавдио

Котылырга юл юкмыни?

Изабелла

Бар, бер генә: башкаеңны саклау өчен,
Йөрәгеңне урталайга ярдырасың.

Клавдио

Бар бит әнә!

Изабелла

Әйе, абый, яшәп була;
Хакимең Иблис кебек шәфкатьле икән:
Барып ялын, җаныңны ул саклап калыр,
Әмма үзеңә гомерлеккә богау салыр.

Клавдио

Гомерлек төрмәмени?

Изабелла

Әйе, төрмә.
Бар дөньяга олы хуҗа булсаң да син,
Бәйдән мәңге ычкынмассың.

Клавдио

Ничек инде?

Изабелла

Шулай. Әгәр күнсәң дә ул куйган шартка,
Намусыңны тире итеп тунап ала,
Шыр ялангач каласың син.

Клавдио

Аңлатып әйт!

Изабелла

Аһ, абыем, синең өчен куркам, тетрим,

Алты-җиде елга гомер озайтам дип,
Намусыңны мәңгелеккә җуймасаңчы!
Ул кадәр үк коточкыч түгел бит үлем.
Ялгыш кына басып сыткан мескен коңгыз
Җаны белән саубуллашкан гигант төслүк
Газапланмыймыни?

Клавдио

Нигә оялтасың?
Ирлек көчен чәчәк кебек зәгыйфь кыздан
Алыр бу дип уйлыйсыңмы? Ышан, сеңлем,
Җаным белән хушлашырга язган икән,
Үлемне мин кәләшемдәй каршыламын.

Изабелла

Менә монысы абыем сүзе! Әйтерсең лә
Кабереннән торып әткәй сөйли моны!
Әйе, шулай! Син үләсең. Мин бит беләм:
Син намуслы. Җаның саклар өчен генә
Андый хурлык сукмагына басмассың ич.
Аһ, әшәке ул, монафыйк, икейөзле!
Вак кошларның котын алган карчыга күк,
Салкын күзе, карлы-бозлы сүзе белән
Яшьлек рухын куркытучы шушы «изге»
Асылда чын Иблис икән! Эчендәге
Бөтен нәҗес-шакшылыгын алып атсаң,
Җәһәннәм авызы кебек буш икән бит!

Клавдио

Ничек? Изге Анжелога шундый сүзләр?

Изабелла

Бар да ялган! Кылану-суфилану.
Тыштан изге кием кигән уйнашчы ул!
Уйлап кына кара, абый: әгәр аңа
Кызлыгымны бирсәм, сине коткара ул.

Клавдио

О юк, булмас!

Изабелла

Әйе! Кылсам шул гөнаһны,
Син дә уйнаш итә аласың теләгәнчә.
Йә мин бүген шул җирәнгеч эшне кылам,
Йә иртәгә синең башың киселәчәк.

Клавдио

Юк, бу эшне кылмыйсың син!

Изабелла

О, әгәр дә
Минем җаным турында гына сүз барсайкән,
Синең өчен җанымны мин, һич икеләнми,
Гади энә кебек кенә җуяр идем.

Клавдио

Рәхмәт сиңа, сеңелкәем.

Изабелла

Әзерлән син,
Иртә белән үлем килер сиңа, абый.

Клавдио

Алай. Димәк, ул да дәртсез түгел икән,
Димәк, ул да әле генә үзе керткән
Гадел закон чигәсенә ялтырата!
Болай булгач, минем гөнаһ гөнаһ түгел,
Булса да иң кече гөнаһ.

Изабелла

Ничек кече?

Клавдио

Кече булмый? Шулкадәр зур гөнаһ булса,
Шундый акылы була торып ул, Анжело,
Бер минутлык ләззәт өчен үзенең җанын
Мәңгелек ут диңгезенә ташлармыни?
Аһ, сеңелкәш!

Изабелла

Йә, абзыкай, әйт сүзеңне.

Клавдио

Үлем бигрәк куркыныч шул!

Изабелла

Анысы шулай,
Әмма ләкин намус җуеп яшәү — хурлык.

Клавдио

Үлү — бетү... һич билгесез җиргә китү...
Хәрәкәтсез ятып, шунда череп бетү...
Кайчандыр җып-җылы тәнле, тере кеше
Гүргә керсен, туфракка әверелсен...
Яңа гына рәхәт сөргән иркә җаның
Ялкын диңгезенә чумсын. Йә коточкыч
Мәңгелек боз яланында ялгыз калсын,
Йә котырган җил-өермә, бөтереп алып,
Бөтен галәм киңлегендә очрып йөртсен,
Күңелдәге тойгыларын үкереп-улап
Аңлатучы ерткыч җәнлек арасына
Ташлап китсен. Аһ, коточкыч картлык, төрмә,
Теләнчелек, зәхмәт, хәсрәт белән тулы
Иң җәфалы, иң газаплы авыр тормыш,
Әҗәл белән очрашуга караганда,
Җәннәт булып тоела миңа.

Изабелла

Абау, нинди хәсрәт!

Клавдио

Сеңелкәем-сылукаем! Бирче рөхсәт!
Зинһар, яшим! Туганыңны яклау өчен
Кылган гөнаһ гөнаһ түгел, киресенчә,
Ул җинаять изгелеккә әйләнәчәк.

Изабелла

Аһ син, ерткыч, аһ син, куркак! Намусың кайда?
Сеңелеңне хурлыкка төшереп, син
Үз җаныңны коткарырга телисеңме?
Аһ! Башыма нинди авыр уйлар килә...
Газиз әнкәм зина кылды микәнни соң?
Әткәй каны акса әгәр тамырыңда,
Бу кадәре түбән җанлы булмас идең,

Шуны бел син: мин баш тартам синнән! Дөмек!
Минем тик бер иелүем һәлакәттән
Сине йолып алу өчен җитсә дә, юк,
Мин иелмәм! Синең әҗәлеңне теләп
Мең гыйбадәт кылырга да әзер, әмма
Котылуың теләп бер сүз әйтәсем юк!

Клавдио

Изабелла, гафу ит!

Изабелла

Хурлык, хурлык!
Очраклы түгел икән бу гөнаһың —
Кәсебең шул икән синең. Димәк, хәзер
Мәрхәмәтем — шакшы димче ясый мине,
Шулай булгач, үлүең мең кат артык.

Клавдио

Ялынып сорыйм, Изабелла, тыңла мине!

Герцог керә.

Герцог

Яшь сеңелкәш, зинһар, рөхсәт итсәгезче,
Бер генә сүз!

Изабелла

Нәрсә кирәк сезгә миннән?

Герцог. Бер минут вакытыгыз булса, сезнең белән сөйләшер идем. Киңәшем сезнең файдага.

Изабелла. Минем вакытым юк, хәзер миңа башка эшкә билгеләнгән вакытны бүләргә туры килә. Шулай да мин сезне тыңларга әзер.

Бер читкәрәк китә.

Герцог *(Клавдиога акрын)*. Улым, сеңлең белән сөйләшкәнеңне тыңлап тордым, Анжелоның беркайчан да аны аздырырга уйлаганы юк. Ул юри генә, сынау өчен генә намусына кагылып караган. Шунда аның пакь намуслы кыз икәнен белгән, бозык тәкъдимне кире кагуына бик нык куанган. Мин Анжелоның рухани атасы, аны яхшы беләм. Булмас өмет белән хыялланып ирлегеңә тап төшермә, иртәгә син үләргә тиеш. Бар, гыйбадәт кыл, үлемгә әзерлән.

Клавдио. Сеңлемнән гафу үтенергә рөхсәт итегез. Тормышымнан шундый туйдым! Тизрәк үлсәм, котылыр идем шикелле.

Герцог. Шул фикереңнән кайтма.

Клавдио китә. Төрмәче керә.

Төрмәче. Ни кирәк сезгә, изге ата?

Герцог. Хәзер чыгып китегез, мине бу кыз белән икәүдән-икәү калдырыгыз, күңелемдәге уйларымны, өстемдәге киемнәремне күреп торасыз, минем белән калудан кызга һичбер төрле зыян килмәс.

Төрмәче. Ярый, рәхим итегез.

Китә.

Герцог. Юктан бар итүче Тәңре Тәгалә сезне намуслы итеп яраткан. Намуссыз матурлык бик тиз шиңә. Күңелегез изге хисләр белән тулы булгач, сез һәрвакыт гүзәл булып калырсыз. Мин очраклы рәвештә Анжелоның намусыгызга кагылуын белдем. Кеше табигатен белмәсәм, мин моңа гаҗәпләнгән дә булыр идем. Абыегызны саклап калу өчен хәзер сезгә нишләргә? Анжелога буйсыныргамы?

Изабелла. Хәзер мин аңа барам да, үзем законсыз бала тудырганчы, абыем законлы рәвештә үлсен дип әйтәм. Ярабби Ходаем! Герцог нигә шулкадәр ышана бу Анжелога. Герцог кайту белән ничек тә булса янына үтеп кереп, шул әшәке җанны фаш итмәсәмме?

Герцог. Файдалы булыр иде бу... Ләкин хәзер эшләр шулай тора: син куйган гаепләрне кире кагар бит ул, сынадым гына, дияр. Шуңа күрә минем киңәшне тотыгыз. Бу юлда изгелек эшләү өчен мин бер чара таптым. Шул уңай белән сез бәхетсез бер кызга бик зур яхшылык эшли аласыз; намусыгызга һичбер тап төшермичә, абыегызны да коткара аласыз. Герцог кайтып, бу хәлләрне белә калса, аның өчен дә бу бик зур куаныч булыр.

Изабелла. Сөйләгез, сөйлә, намусыма тап төшермәсә, теләсә нинди эшкә дә көчем җитә минем.

Герцог. Изге күңел кыю була, сафлык куркуны белми. Мариана дигән кыз турында ишеткәнегез бармы? Кораб батканда диңгездә һәлак булган батыр Фредрико сеңлесен.

Изабелла. Ишеткәнем бар... Бик әйбәт кыз, диләр.

Герцог. Анжело аңа өйләнергә тиеш иде. Туй көне дә билгеләнгән иде. Туй алдыннан гына әлеге бәхетсезлек булды. Абыйсы диңгезгә батты. Шунда Мариананың бирнәләре дә су төбенә китеп харап булды. Күрегез инде язмышның рәхимсезлеген: бичара кыз гаҗәп игелекле абыйсын югалтты, бирнәгә дигән бөтен байлыгыннан, ярәшкән киявеннән, тыштан изге күренгән Анжелосыннан мәхрүм калды.

Изабелла. Дөресме бу? Анжело аны ташладымы?

Герцог. Ташлады. Яшьләренә буылып елаган кызны юатып та тормады. Алай гына да түгел, миңа хыянәт итте дип, кызга яла ягудан да тартынмады.

Изабелла. Шундый кешене ничек җир күтәрә?! Мин ул кызга нинди ярдәм күрсәтә алам?

Герцог. Аның күңел ярасын син бик тиз дәвалый аласың. Моның белән син абыеңны коткару гына түгел, намусыңны да саклап калырсың.

Изабелла. Өйрәтегез, изге ата, ничек итеп?

Герцог. Бичара кыз аны һаман сөя... Бу гаделсезлек аның мәхәббәтен сүндерергә тиеш иде. Ләкин Анжелоның рәхимсезлеге, су юлында торган киртә кебек, кызның кайнар хисләрен тагын да көчәйтә, ярсыта. Анжелога барыгыз, аның теләгенә күнгән булыгыз. Кавышырга ризалык бирегез, тик берничә шарт куегыз: беренчедән, аның янында озак кала алмыйсыз, икенчедән, караңгыда кавышасыз, сөйләшмисез, ниһаять, җылы урын билгеләвен сорыйсыз. Ул, әлбәттә, барына да күнәр. Шулай итеп, безнең ниятебез дә барып чыгар. Без, алдан сөйләшеп, сезнең урынга Марианананы җибәрербез. Кавышуның нәтиҗәсе мәгълүм булгач, Анжело чигенергә мәҗбүр булыр. Шулай итеп, абыегыз исән калыр. Бичара Мариана максатына ирешер. Анжело фаш ителер. Кыз белән үзем сөйләшермен, үзен ничек тотарга кирәген аңлатырмын. Йә, бу эшкә сез ничек карыйсыз?

Изабелла. Бу фикер үзе генә дә мине тәмам тынычландырды. Ниятебез барып чыгар дип уйлыйм.

Герцог. Бөтен эш сездән тора. Тизрәк Анжелога барыгыз. Әгәр ул, бүген кичкә үк килегез, дисә, риза булыгыз. Мин хәзер изге Лука хөҗрәсенә киттем. Кимсетелгән Мариана шунда тора. Сез дә шунда килерсез. Барыгыз, Анжело белән мөнәсәбәтегезне тизрәк җайлагыз.

Изабелла. Ярдәмегез өчен бик зур рәхмәт. Хушыгыз, изге ата.

Икесе ике ишектән чыгып китәләр.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төрмә алды.
Монах киеме кигән Герцог, Терсәк, Мәзәкче һәм сакчылар керәләр.

Терсәк. Юк, сезгә пычрак кәсебегез белән яшәргә ирек куйсаң, бу дөньяда аракы һәм уйнаштан туган балалар гына торып калыр.

Герцог. Ярабби! Бу нинди чүп тагын?

Мәзәкче. Эх, дөньяда күңел ачарлык нәрсә дә калмады. Уйнашчыларны кавыштыручы белән бер ростовщик бар иде, шуларның шаян күңеллесен бөлдерделәр, иң әшәкесенә закон туны кидерделәр, салкын тидереп, авырып китмәсен дигәннәрдер инде. Тунның да ниндиен! Эче сарык, тышы төлке, белеп торыгыз, янәсе: төлке хәйләкәрлеге һәрвакыт сафлыктан өстен булыр.

Терсәк. Әйдә, әйдә, акыл сатма. Алла ярлыкасын үзегезне, изге ата.

Герцог. Сине дә шулай ук, ата кеше. Нинди гаеп эшләде бу?

Терсәк. Законны хурлады. Шуның өстенә урлаша да бугай. Янында йозак ваткыч тимер табылды. Без аны граф Анжелога җибәрдек.

Герцог

Оял, шакшы, уйнашчылар хезмәтчесе,
Авыр гөнаһ кылырга син булышасың,
Шуның белән көн итәсең. Уйлап кара,
Шакшы кәсеп белән тамак туйдыруың,
Киенүең-ясануың әйбәт эшме?
Йә, әйт инде үз-үзеңә, «кешеләрне
Хайваннардай кавыштыру аркасында,
Ашыйм, эчәм, киенәм мин — яшим» диген!
Шундый шакшы, сасы исле тормышыңны
Яшәү диеп атыйсыңмы? Бар, тәүбә кыл!

Мәзәкче

Дөрес, бераз сасырак инде ул сасылыкка,
Шулай да мин сезгә исбат итсәм...

Герцог

Син итәрсең исбат, шайтан ярдәм итсә.
Юк, җәзалап арт сабагын укытмыйча,
Төзәтергә мөмкин түгел бу хайванны.

Тереәк. Башта аны граф Анжелога алып барырга кирәк, җәнабы гали. Ике тапкыр кисәтелде инде ул, граф андый бәндәләрне үлеп дошман күрә: мондый кәсеп белән көн итүче кеше аның күзенә чалынмасын инде. Ух! Бу бәндәнең аннан берничә чакрым читтәрәк торганы яхшы.

Герцог

Аһ! Һәркем тыштан күренгәнчә пакь булса иде!
Гөнаһ изге кием киеп йөрмәсә иде!

Тереәк. Борчылмагыз, изге ата! Сезнең билегезне буган бау аның муенын буар.

Мәзәкче. Менә ярдәм дә килде, ул мине йолып алыр. Әнә игелекле егет килә, минем дустым ул!

Луцио керә.

Луцио. Ә, исәнме, сөекле Помпей! Бу ни хәл, Цезарь арбасы артына бәйләделәрмени әле үзеңне? Курчакларың кайда, хатын-кызларың, дим? Син аларны, Пигмалион кебек, бик тиз бар итәсең ич. Алар синең кесәңне актаралар. Йә, ни дисең син моңа? Ә? Ошыймы сиңа бу җир? Яңгыр астында калып тавышыңны җуйдыңмы әллә? Йә, ни дип җавап бирмисең, карт димче? Әллә хәзер башка телдә сөйләшәсеңме? Ни булган аңа? Кайгыга чумып шымып калган, холкын үзгәрткәнмени?

Герцог. Һаман да шул, хәтта әшәкеләнә төшкән.

Луцио. Ләззәт хәзинәбез нишләп тора? Хуҗа хатынны әйтәм, ә? Һаман элекке эшендәме?

Мәзәкче. Юк, әфәндем, тәмам рәте китте. Рәтләнмәмме дип, җылы сулы кисмәктә утыра.

Луцио. Бик шәп, дөрес эшли. Яшь чакта — фахишә, картайгач — хәлифә. Яшьләрне өйрәтә. Бик дөрес, тәртибе шулай. Алайса, син төрмәгә юл тотасың, ә, Помпей?

Мәзәкче. Шулайрак, әфәндем.

Луцио. Синең өчен бик файдалы бу, Помпей. Хуш. Әйт син анда, мин җибәрде, диген. Бирәчәкләр өченме бу, башка эш өченме?

Тереәк. Уйнашчылар кавыштырган өчен.

Луцио. Алайса икеләнеп тормагыз, утыртыгыз. Кавыштыручыга төрмә тиеш булса, моңа аның тулы хакы бар. Кавыштыручы ул борын-борыннан, ана карынында чакта ук шул эш белән шөгыльләнгән. Хуш, сөекле Помпей, төрмәгә миннән сәлам әйт. Хәзер син тәүфыйклы ир булырсың, биләмгә чыгып йөрмәссең.

Мәзәкче. Йолып алырсыз дип өметләнәм бит әле мин, әфәндем.

Луцио. Юк, Помпей, өметләнмә, хәзер ул мода бетте. Хәзер мин сине озаграк утыртсыннар дип кенә сорый алам. Заманы шул, Помпей. Әгәр син анда каршылык күрсәтсәң, бу әле төзәлмәгән, диярләр. Сау бул, хөрмәтле Помпей. Алла ярлыкасын үзегезне, изге ата.

Герцог. Сине дә шулай ук.

Луцио. Бригетта һаман бизәнәме әле, Помпей?

Тереәк. Йә, әйдә, әйдә, тукталма.

Мәзәкче. Алайса, әлегә йолып ала алмыйсыз инде?

Луцио. Әлегә дә, соңыннан да ала алмыйм, Помпей. Нинди яңалыклар бар, изге ата?

Тереәк. Әйдә, әйдә!

Луцио. Бар, Помпей, ояңа кер.

Тереәк, Мәзәкче, сакчылар чыгып китәләр.

Герцог турында берәр хәбәр ишетелмиме?

Герцог. Минем берни дә ишеткәнем юк, ә сез?

Луцио. Кайсы рус патшасы янына киткән, ди, кайсы Римда, ди. Сез ничек уйлыйсыз? Кайда икән ул хәзер?

Герцог. Белмим, кайда гына булса да, изге теләк телим мин аңа.

Луцио. Нинди эш инде бу, үз дәүләтеңнән качып-посып чыгып кит тә сукбай булып йөре. Килешә торган эшме шул? Аның урынына монда граф Анжело тырышып-тырышып хөкем сөрә. Хәтта кирәгеннән артык тырыша.

Герцог. Бик әйбәт итә.

Луцио. Мәхәббәт эшләренә бераз рәхимлерәк булса да зарар итмәс иде. Бигрәк каты кылана бит бу, изге ата.

Герцог. Бозыклык бик киң таралды шул. Аның тамырын тик катылык белән генә корытып була.

Луцио. Анысы дөрес инде, бозыклыкның нәселе бик зурайды, дәрәҗәле семьялар белән аралашты. Ләкин, кешеләрне ашау-эчүдән тыймый торып, аның тамырын корытып булмый, изге ата. Анжелоны борынгыдан сыналган юл белән яралмаган, ир белән хатыннан тумаган, диләр. Шул дөресме икән? Сез ничек уйлыйсыз?

Герцог. Башкача ничек ярალсын инде ул?

Луцио. Берәүләр аны, диңгез пәриеннән туган, ди, берәүләр, кипкән тәрәч балыклары ышкылудан, диләр; ләкин бер ягы ачык билгеле, агызган сыекчасы шунда ук боз булып ката. Монысын мин бик яхшы беләм. Гомумән, үзе кебекләрне тудырырга бөтенләй сәләтсез ул. Монысы көн кебек ачык.

Герцог. Шаярасыз, әфәндем, юкны сөйлисез.

Луцио. Йә, эшмени инде бу, чалбары котырган өчен генә кешенең башын кис, имеш! Герцог үзе булса шулай итәр идемени? Дөньяга законсыз йөз бала тудырган кешене асудан алда, Герцог мең кешене туйдыру өчен үз кесәсеннән түләргә тиешлеген уйлар иде. Андый күңел ачуларны аңлый бит ул. Бу эштә үзе дә бик зур тырышлык күрсәткән кеше, шуңа күрә шәфкать ягында булыр иде.

Герцог. Герцогның хатын-кыз белән кирәгеннән артык мавыгуын беркайчан да ишеткәнем юк.

Луцио. Аһ, изге ата, бик каты ялгышасыз бит!

Герцог. Юк, ул андый түгел.

Луцио. Улмы? Герцогмы? Ничек инде! Әнә илле яшьлек теләнче хатыннан сорагыз! Герцог аның тәлинкәсенә һәрвакыт алтын тәңкә салып китә. Әйе, гөнаһы бар инде аның. Әйтик, тыела алмыйча эчә, бу кадәресен үз күзем белән күреп беләм.

Герцог. Шик юк, сез аңа яла ягасыз.

Луцио. Абзыкай гынам, мин аның иң якын дусты. Бик шикле кеше ул, Герцогны әйтәм, хәтта ни өчен качып китүенең сәбәбен дә беләм дип уйлыйм.

Герцог. Нинди сәбәп соң ул?

Луцио. Кичерегез, анысын әйтә алмыйм, яшерен сер ул. Монда инде телгә ирек биреп булмый, шунысын гына әйтә алам, күпчелек аны акыллы дип уйлый, ә ул...

Герцог. Миңа калса, аны һич тә акылсыз дип булмый.

Луцио. Фәһемсез ул, надан, килде-китте бернәрсә шунда.

Герцог. Йә көнчелек бу, йә ахмаклык. Герцогның тормышы, хөкем сөрүе моның киресен күрсәтә. Кылган эшләре буенча хөкем итсәләр, хәтта көнчеләр дә аны күренекле галим, гаскәр башлыгы, дәүләт җитәкчесе итеп танырлар. Ә сез телегезгә ни килсә, шуны сөйлисез. Аны чынлап та белсәгез, бу сүзләрне сез усал ният белән сөйлисез.

Луцио. Юк, мин Герцогны беләм, аны яратам.

Герцог. Яраткач, әйбәтрәк белергә, белгәч, ныграк яратырга кирәк.

Луцио. Ышаныгыз, белгәнемне беләм инде мин.

Герцог. Авызыгыз әйткәнне колагыгыз ишетмәгәч, сезгә ышануы читен шул. Менә Герцог җәнаблары кайткач — ә без аның кайтуын чын күңелдән телибез — бу сүзләрегез өчен аның каршында җавап бирерсез. Сүзләрегез дөрес булса, курыкмыйча аның алдында да кабатларсыз. Сезне анда чакыру минем бурычым. Исемегез ничек?

Луцио. Луцио дип йөртәләр. Герцог мине бик яхшы белә.

Герцог. Ул кайтканчы яши алсам, сезне ул тагын да яхшырак белер.

Луцио. Мин сездән курыкмыйм.

Герцог. Сез Герцогны кайтмас дип уйлыйсыз яки мине үтә көчсез дошманга саныйсыз. Хәер, анысы дөрес тә инде, мин сезгә зыян китерә аламмы соң? Сез, андый сүз әйткәнем юк, дип ант итәрсез.

Луцио. Әгәр шулай икән, мине алдан ук асып үтерсеннәр. Син мине ялгыш аңладың, монах. Ярый, бу хакта җитеп торыр. Сез белмисезме? Клавдионы иртәгә үтерәләрме, юкмы?

Герцог. Ни өчен үләргә тиеш соң ул?

Луцио. Ничек инде, воронкадан агызып мичкә тутырган өчен. Мин хәзер Герцогның монда булуын теләр идем. Бу Анжело дигән алаша илебезне кешесез калдыра. Хәзер чыпчыклар да аның чормасына ояламый — бик дәртле бит алар. Герцог булса, караңгыда эшләгән эшне болай яктыга чыгармас иде. Аһ! Ул кайтса! Бичара Клавдио чалбар төймәсен ашыгып ычкындырган өчен генә үлемгә хөкем ителде. Сау бул, изге ата, зинһар, минем өчен дога кыл; шулай ук ышан син миңа: Герцог дигәнебез рузада бик әйбәтләп кенә сарык ите ашый. Аның гомере үтте инде, шулай да ул авызыннан арыш икмәге белән сарымсак исе аңкып торган теләнче хатын белән шаярудан да тартынып тормый. Әйт син аңа, Луцио шулай дип әйтте, диген, хуш.

Китә.

Герцог

Дәрәҗә дә, көч тә безне саклый алмый,
Изгеләргә гайбәт арттан хәнҗәр кадый.
Бармы хаким гайбәтчене тыя алырлык,
Бармы патша телен бәйләп куя алырлык?
Кемдер килә.

Эскал, Төрмәче, Таушалган ханым, сакчылар керәләр.

Эскал. Төрмәгә аны, төрмәгә.

Таушалган ханым. Мәрхәмәтле әфәндем, кызганыгыз! Шәфкатьле икәнегезне һәркем белә, әфәндем...

Эскал. Ике-өч тапкыр кисәтүгә дә карамастан, җинаятьле эшеңне һаман туктатмыйсың. Син бу кирелегең белән шәфкатьнең үзен, чыдамлыктан чыгарып, явызлыкка әйләндерәсең.

Төрмәче. Бу хатын, әфәндем, унберенче ел инде уйнашчылар кавыштырып көн итә.

Таушалган ханым. Анысы дөрес, әфәндем. Луцио дигән егет котыртты. Ул Герцог заманында ук «Арзанлы» дигән кызыбызга бала ясады, өйләнергә вәгъдә итте. Баласына ел да өч ай булып килә, үзем имездем. Ә ул мине беләсезме ничек җәберли?

Эскал. Йөгәнсез егет. Алып килегез үзен. Ә бу хатынны төрмәгә. Бер сүзеңне дә тыңламыйм, бар.

Сакчылар Таушалган ханымны алып китәләр.

Анжелоны һич күндереп булмый, Клавдио иртәгә үләргә тиеш. Аңа рухани чакырыгыз, тиешенчә юатсын ул аны. Аһ, Анжело минем белән исәпләшсә, Клавдио бу хәлгә төшмәс иде.

Төрмәче. Рөхсәтегез булса, менә бу монах аның янында булды инде, үлемгә әзерләде.

Эскал. Хәерле кич, изге ата.

Герцог. Ходай ярлыкасын үзегезне.

Эскал. Сез кайдан?

Герцог

Мин мондагы кеше түгел, изге Римнан,
«Рәхим-шәфкать» монастыре әгъзасы мин,
Атабызның йомышы белән килгән идем.

Эскал. Дөньяда нинди яңалыклар бар?

Герцог. Әллә ни юк, бары шул гына: изгелекне бизгәк тота, аны бу зәхмәттән үлем генә коткара. Бар да яңалыкка омтыла, картайганчы бер генә юлдан бару куркыныч хәзер. Күңелеңне бер генә нәрсәгә юнәлтеп, аннан аерыла алмау диваналыкка санала дип әйтимме? Җәмгыять иминлеге өчен хаклыкка гына таянып буламы-юкмы, әмма җәмгыятьне каргар өчен таянычлар җитәрлек. Кешелек акылы шул табышмак тирәсендә әйләнә. Бу хәбәрләр, әлбәттә, иске. Ләкин алар һәрвакыт яңалык булып торалар. Әйтегез әле, зинһар, Герцогыгыз ниндирәк кеше?

Эскал. Ул күбесенчә үзен-үзе аңларга тырыша иде.

Герцог. Бигрәк тә нәрсәләрдән ләззәт таба иде?

Эскал. Ул, үзе күңел ачудан бигрәк, башкаларның куанычын күрергә ярата торган кеше. Үтә сабыр, беркайчан да чамадан чыкмый. Ярый, аны без үз тәкъдиренә тапшырыйк, чын күңелдән игелекләр телик үзенә. Әйтегез әле, сез Клавдионы үлемгә әзер дип уйлыйсызмы?

Герцог. Хөкем ул кадәр рәхимсез түгел, мин аңа чын күңелдән буйсынам, диде. Шулай да шәфкать өмет итә иде. Мин ул өметне акрынлап таркаттым. Хәзер инде үлем белән очрашырга әзер.

Эскал. Сез Алла каршында да, тоткын каршында да үз бурычыгызны үтәгәнсез. Соңгы чиккә кадәр егетне коткарып калырга бик тырыштым, ләкин хөкем сөрүче юлдашым артык каты булып чыкты. Үзенә дә әйттем: рәхимсез законның мөҗәссам сурәте икәнсез, дидем.

Герцог. Үзенә карата да шундый каты булса, бик әйбәт. Инде очраклы рәвештә гөнаһка төшә калса, моның белән ул үзен-үзе хөкем итә.

Эскал. Мин тоткын янына керәм. Хушыгыз.

Герцог

Сәламәтлек телим.

Эскал белән Төрмәче чыгып китә.

Тоттыралар икән сиңа хаклык кылычын,
Саф бул үзең, күңелең дә пакь, гадел булсын:
Башкаларның гаебен һәм үз гаебеңне
Бер бизмәндә тигез итеп үлчи бел син,
Шул ук гөнаһ була торып үз күңелеңдә,

Кешеләрне хөкем итсәң син үлемгә,
Оят сиңа, хурлык сиңа! Анжело, син
Күз буйыйсың изге булып күренү өчен!
Башкаларның чүп үләнен йолкып ташлап,
Үзеңнекен үстерәсең илдән каплап.
Кайчак тыштан фәрештәгә охшый кеше,
Эче шакшы, мәкер була кылган эше.
Тыйнак булып, охшап изге әүлияга,
Хәйлә кора, астан гына утлар яга.
Үрмәкүчтәй мыштым гына корган ауга
Иң мәһабәт баһадирлар килеп каба.
Явызлыкны хәйлә белән богаулыйк без:
Кимсетелгән, җәберләнгән бичара кыз
Керсен бүген Анжелоның куенына —
Бу бик әйбәт, лаек җавап булыр аңа,
Тик соңыннан аңлап алыр эшнең төбен
Һәм ялгар ул үзе өзгән никах җебен!

Китә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Изге Лука чиркәве фермасы янында.
Мариана белән Паж керәләр.

Паж
*(җырлый)*

Өзелеп сөям, дип алдаган
Ал иреннәр, югалыгыз!
Сүндермәсен таңнарымны
Күздән яуган нурларыгыз.
Югалыгыз, дим, барыгыз!
Тик, зинһар, дим, үбүемне
Кире үземә кайтарыгыз.
Кайтарыгыз!

Мариана

Ярар, җитте, кит инде син. Әнә килә
Юатучым, хәсрәтләрне таратучым.

Паж китә. Герцог керә.

Кичерегез, изге ата, әле генә
Сез музыка тыңлавымны ишеттегез.
Ышаныгыз, бу тантана итү түгел,
Сагышымны җиңеләйтү өчен генә.

Герцог

Син борчылма, кызым. Тик мин шуны беләм:
Музыка ул тылсымлы моңы белән
Бозыкны да гөнаһлардан саклап кала,
Изгене дә бозыклыкка илтә ала.
Бүген мине сораучы булмадымы, кызым? Мин монда берәү белән очрашырга тиеш идем.
Мариана. Юк, беркем дә сорамады. Мин бүген көн буе өйдә утырдым.

Герцог. Мин сезгә ышанам. Билгеләнгән вакыт килеп җитте. Сез читкәрәк китеп торыгыз. Тиздән сезне чакырырмын. Бәлки, сезнең өчен күңелле бер хәбәр дә булыр.

Мариана

Чиксез бурычлы мин сезгә.

Китә.

Герцог

Хуш киләсез! Сәлам сезгә! Йә, әйтегез,
Хөрмәтле граф белән ничек сөйләштегез?

Изабелла

Бакчасы бар, койма белән уратылган,
Шактый биек таш коймадан көнбатышка
Ишек чыга: анда йөзем куаклары.
Йөземлекнең төн ягында агач капка.
Ачкычлары менә. Зурысы — капканыкы,
Кечкенәсе — арадагы ишекнеке.
Шәфәкъ баткач киләм, диеп вәгъдә бирдем.

Герцог

Анда барыр юлны яхшы беләсезме?

Изабелла

Бик җентекләп тикшереп, карап кайттым.
Кайнар дәртен көчкә тыеп, пыш-пыш килеп,
Ике тапкыр үзе үтте минем белән,
Күрсәтеп юл буендагы билгеләрне.

Герцог

Бүтән шартлар юкмы тагын? Марианага
Барысын да әйтик хәзер.

Изабелла

Бер шарт та юк.
Тик шул гына: караңгыда очрашырга...
Әйттем: сезнең янда озак калалмыйм дип,
Асравымны чөнки алып киләм, дидем,
Абыема шәфкать сорый дип белеп, ул
Тышкы якта мине көтеп торыр, дидем.

Герцог

Ярый, яхшы. Тик әле мин Мариана белән
Сөйләшмәдем.
*(Чакыра.)*
Мариана, килегез бире!
Менә, танышыгыз бу кыз белән,
Сезгә ярдәм итәм, ди ул.

Изабелла

Чын күңелдән!

Герцог

Миңа сез ышанасызмы?

Мариана

Изге ата, шикләнерлек һичбер сәбәп булганы юк.

Герцог

Ал кулыннан, җитәклә чын дустың итеп.
Тыңла: аның сиңа әйтер сүзләре бар.
Ә мин шунда сез килгәнне көтеп торам.
Ашыгыгыз, караңгы төн җитеп килә.

Мариана

Икәүләшеп бер әйләнеп килмибезме?

Изабелла белән китә.

Герцог

И хакимлек! И дәрәҗә! Миллион күзләр
Бертуктаусыз сезнең арттан күзәтәләр.
Бер-беренә капма-каршы уйдырмалар,
Төрле гайбәт артыгыздан калмый һаман.
Үзләренең хыялларын чынга санап,
Сезгә төбәп төрле мәзәк чыгаралар,
Әрнеттереп чәнчеп сездән көлә алар.

Мариана белән Изабелла керәләр.

Ә! Килегез! Йә, ничек? Кыз ризамы соң?

Изабелла

Барына да риза булды, әгәр дә сез
Ниятләгән эшкә каршы килмәсәгез.

Герцог

Каршы килмәү генә түгел, сорыйм сездән.

Изабелла

Аның белән сөйләшергә туры килмәс.
Чыгып киткән чакта гына сез, пышылдап,
«Абыемны онытмагыз» дип әйтегез.

Мариана
О, курыкмагыз.

Герцог

Сез дә бер дә курыкмагыз:
Ул бит сезнең ярәшкән киявегез,
Аның белән кушылу һич гөнаһ түгел,
Аңа сезнең хакыгыз бар. Бу алдауны
Шуның белән аклап була. Киттек тизрәк!
Уру өчен башта безгә чәчү кирәк.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төрмә бинасы.
Төрмәче белән Мәзәкче керәләр.

Төрмәче. Кил әле, егет! Син кеше башын кисә аласыңмы?

Мәзәкче. Өйләнмәгән булса, кисә алам, әфәндем. Өйләнгәч бит баш хатынга тапшырыла, хатын-кыз башын кисәргә минем гайрәтем җитми.

Төрмәче. Җитәр, сөеклем, боргаланма, туп-туры әйт. Иртәгә Клавдио белән Бернардинның башлары киселә. Төрмәдә җәллад бар, тик аңа бурычын төгәл итеп үтәү өчен ярдәмче кирәк. Син аңа ярдәм итсәң, богауларыңны салдырырлар, баш тартсаң, срогыңны тутыртырлар да ыштаныңны төшереп талчыбык белән ярырлар. Син бит уйнашчылар кавыштыручы?

Мәзәкче. Дөрес, әфәндем, борын-борыннан законсыз кавыштыручы идем... Хәзер инде менә законлы җәллад булам. Тик кәсеп-төшемнән кайбер киңәшләр сорар идем.

Төрмәче. Әй, Дәһшәтле! Кайда булды соң бу Дәһшәтле?

Дәһшәтле керә.

Дәһшәтле. Чакырдыгыз шикелле, әфәндем?
Төрмәче. Иртәнге җәза вакытында менә бу егет синең ярдәмчең булыр. Яраклы тапсаң, бер елга ялларсың да үз яныңа алырсың. Яраксыз булса, чыгарып җибәрерсең. Син тартынып торма, әллә кем түгел ул, уйнашчылар кавыштыручы гына.
Дәһшәтле. Кавыштыручы?! Тфү! Сәнгатебезгә тап төшерер бит ул.
Төрмәче. Ярый, ярый, бер-берегездән артык җирегез юк. Кайсыгыз шәп, кайсыгыз хәшәп — әлегә билгесез.

Китә.

Мәзәкче. Мәрхәмәт итегез, әфәндем, кыяфәтегез генә дар агачын искә төшермәсә, болай шәфкатьле күренәсез. Димәк, сез үз кәсебегезне сәнгать дип атыйсыз?
Дәһшәтле. Әлбәттә, сәнгать.
Мәзәкче. Сәнгать турында минем ишеткәнем бар, әфәндем: буяу белән рәсем ясау — менә ул сәнгать, ичмасам! Миндә кәсеп итүче хатын-кызлар да һәрвакыт буяу белән эш итәләр; битләрен, иреннәрен, керфекләрен буйыйлар, миңнәр төртәләр. Шулай булгач, минем кәсеп чын-чыннан сәнгать булып чыга. Ә сезнеке? Кешеләрне дарга асу, баш кисү сәнгать буламы соң инде? Ассагыз да аңлый алмам.
Дәһшәтле. Чын сәнгать ул, әфәндем.
Мәзәкче. Ни белән исбат итәсез?
Дәһшәтле. Элмәк каракның муенына тап-таман булсын. Каракка кысык булса, рәтле кешегә иркен була, рәтле кешегә иркен булса, каракка кысык була. Менә! Тап-таман дигәнемнең хикмәте шул.

Төрмәче керә.

Төрмәче. Килештегезме?
Мәзәкче. Мин аңа хезмәт итәргә риза. Нигә дисәгез, кавыштыручыга караганда җәлладны Алла тизрәк ярлыкар. Чөнки ул, һәр башны кискәндә, тоткыннан гафу үтенә.
Төрмәче. Иртән сәгать дүрткә бүкән белән балтаң әзер булсын.
Дәһшәтле. Әйдә, кавыштыручы! Мин сине үз һөнәремә өйрәтим. Минем арттан калма.
Мәзәкче. Чын күңелдән тырышырмын, әфәндем, өйрәнермен. Осталыгымны сынау өчен бүкәнгә үз башыгызны куйсагыз, миннән бик канәгать булырсыз, әфәндем. Бу кадәр яхшылыкка каршы миннән дә бер яхшылык тиеш ләбаса.

Төрмәче

Клавдио белән Бернардинны чакырыгыз.

Мәзәкче белән Дәһшәтле китәләр.

Клавдио бик кызганыч. Тегесе — юк.
Күпме кеше җанын кыйган. Шуңа күрә,
Туган энем булса да ул, һич кызганмам.

Клавдио керә.

Менә сиңа, Клавдио, хөкем — укы,
Хәзер төн уртасы, иртән таң атуга
Үлемсезлек сиңа. Кайда соң Бернардин?

Клавдио

Үлеп йоклый. Әйтерсең лә талган юлчы.
Уяталмадылар.

Төрмәче

Әйе, һич тә ипкә килми. Бар, әзерлән.

Ишек шакыйлар.

Нинди тавыш?.. Ходай ярдәм бирсен сиңа.

Клавдио китә.

Хәзер, хәзер! Чапкын хәбәр китергәндер. Клавдиога, бәлки, шәфкать хәбәредер.

Герцог керә.

Сәлам сезгә, изге ата.

Герцог
Төнге рухлар
Юлдаш булсын сезгә. Беркем килмәдеме?

Төрмәче

Утлар сүнгәч, беркем дә килгәне юк.

Герцог

Ә Изабелла?

Төрмәче
Юк.

Герцог
Килер әле.

Төрмәче

Клавдио өчен куанычлы хәбәр бармы?

Герцог
Өмет кенә.

Төрмәче

Хакимебез бигрәк кансыз.

Герцог

Алай димә. Тормышта да, хөкемдә дә
Гадел закон нигезендә эш итә ул;
Үз хисләрен тыя белгәч, изгеләрчә,
Башкаларны тыярга ул хаклы була.
Әгәр, шул ук гөнаһ булып үз күңелендә,
Кешеләрне хөкем итсә ул үлемгә,
Кансыз тиран булыр иде. Ә хәзер ул
Хаким генә.

Ишек шакыйлар.

Кемдер килде.

Төрмәче китә.

Күңеле йомшак. Төрмәчеләр арасында
Кешеләргә шәфкатьлесе сирәк була.

Тагын шаку.

Нинди шау-шу? Кем шулкадәр кабалана,
Төрмәнең бар стенасын дер тетрәтеп?

Төрмәче керә.

Төрмәче

Көтсен капка саклаучыны уятканчы.
Аны хәзер уяталар.

Герцог

Йә, нәрсә бар?
Кичерергә дигән хәбәр килдеме әллә?
Димәк, егет исән кала.

Төрмәче

Юк, килмәде.

Герцог

Гәрчә озак калмаса да таң атарга,
Яңа хәбәр ишетерсез.

Төрмәче

Белмим, бәлки.
Сезгә генә мәгълүм хәбәр бардыр, ахры,
Ләкин белмим. Рәхим-шәфкать көтеп булмый,
Әлегәчә андый хәлләр булганы юк.
Шунысы да бар: граф Анжело ачык әйтте
Ул егеткә, рәхим-шәфкать көтмә, диде.

Йомышчы керә.

Әнә аның йомышчысы.

Йомышчы *(Төрмәчегә кәгазь тапшыра)*. Граф шушы язуны җибәрде. Телдән дә әйтергә кушты. Хөкемнең бер хәрефе дә үзгәрми. Вакытында җиренә җиткерелсен, диде.

Төрмәче

Барын да төгәл итеп үтәрмен.

Йомышчы китә.

Герцог
*(үзалдына)*

Үзгәртелде хөкем, егет калды исән.
Аһ, нинди хак түләнгәнен белсә икән!
Җинаять эшләү аңа берни түгел,
Кулда хөкем булгач, тыныч аның күңел;
Башкаларны гафу итү дә бик җиңел,
Үзе кылган гөнаһны ул кичерә гел.
*(Кычкырып.)*
Ни дип язган?

Төрмәче. Әйттем бит, граф Анжело миннән шикләнә, карарны үти алмас дип курка, шуның өчен мине кисәтергә уйлаган. Бик гаҗәп, элек ул мондый түгел иде.

Герцог. Укыгыз әле.

Төрмәче *(укый)*. «Хөкемне үзгәртү турында нинди генә боерык алсагыз да, аңа ышанмагыз, шуны ачык белегез: Клавдионың башын иртән сәгать дүрттә кисәргә. Карарның үтәлүен тәгаен белү өчен, нәкъ сәгать бишкә Клавдионың башын миңа китерергә боерам. Боерыкны төгәл итеп үтәгез, моны үтәүнең мәгънәсе бик зур. Карардан чак кына тайпылсагыз да, бәласе үз башыгызга төшәр». Моңа ни әйтәсез, изге ата?

Герцог. Төштән соң җәзаланачак Бернардин дигәнегез кем соң ул?

Төрмәче. Чегән нәселеннән. Ләкин үзе монда үскән, монда яшәгән, тугыз ел утыра инде.

Герцог. Ничек алай? Герцогыгыз аны йә җәзаларга, йә азат итәргә тиеш иде ләбаса. Ишетүемә караганда, гадәттә, ул шулай итә торган булган.

Төрмәче. Тоткынның дуслары әледән-әле җәзаны кичектерүне сорадылар. Шуның өстенә җинаяте дә әле яңа гына, граф Анжело хөкем сөргәндә генә ачылды.

Герцог. Җинаяте исбат ителгәнме?

Төрмәче. Шикләнәсе юк, ул үзе дә танмый.

Герцог. Үзен ничек тота соң ул? Кылган җинаяте өчен үкенәме?

Төрмәче. Шундый бер кеше ул, үлемне исереп йоклау шикелле генә күрә, бернәрсәгә дә исе китми. Шундый гамьсез. Үткәнне дә, бүгенгене дә, киләчәкне дә уйларга теләми. Котыла алмавын белсә дә, үлемнән һич курыкмый.

Герцог. Бәлки, аңа рухани кирәктер?

Төрмәче. Руханиларны тыңларга да теләми. Төрмәдә ул үзен өендәге кебек хис итә. Качарга мөмкинлек бирсәң дә качмый. Көненә берничә тапкыр эчеп исерә. Кайчагында көн буе исерек була. Җәзаларга алып барабыз, дип юри уяталар үзен, башын кисәргә дип язылган кәгазь күрсәтәләр, ләкин ул төкереп тә бирми.

Герцог. Ярый, аның хакында соңыннан сөйләшербез. Күп еллык тәҗрибәм алдамаса, сез бик намуслы, кыю күренәсез. Шуңа таянып, тәвәккәлләп бер серемне ачыйм сезгә. Клавдионың закон каршындагы гаебе үлемгә хөкем итүченекеннән артык түгел. Мин моны тулысынча исбат итә алам, тик

аңа дүрт көн вакыт кирәк. Шуңа кадәр сез, үзегезне шактый куркыныч астына куеп, бу эштә миңа ярдәм итәргә тиешсез.

Төрмәче. Нинди ярдәм ул, изге ата?

Герцог. Клавдионы җәзаламый торырга.

Төрмәче. Ай-һай, моны эшли аламмы соң мин? Җәза вакыты төгәл билгеләнгән, җәзадан соң мин аңа тоткынның киселгән башын илтеп тапшырырга тиеш. Боерыкны үтәмәсәм, үзем дә Клавдио хәленә калам.

Герцог. Хода белән ант итеп әйтәм, мин кушканны төгәл итеп эшләсәгез, сезгә берни дә булмый. Бернардинны җәзалагыз да Анжелога аның башын илтегез.

Төрмәче. Ул аларның икесен дә күреп белә. Бернардинны таныр.

Герцог. И, әҗәл кешене танымаслык итеп үзгәртә. Шуның өстенә сез аның чәчен кыркыгыз, сакалын кыскартыгыз... Үлем алдыннан үзе васыять итте, диярсез. Тормышта андый хәлләр була. Ходай белән ант итеп әйтәм, моның өчен сезгә рәхмәт белән бүләктән башка берни дә булмый. Мин сезне үзем яклармын.

Төрмәче. Изге ата, кичерегез, минем тарафтан ант бозу була бит бу.

Герцог. Сез кемгә ант иттегез, Герцогкамы, баскаккамы?

Төрмәче. Герцогка, шулай ук баскакка да.

Герцог. Бу эшегезне Герцог үзе хупласа?

Төрмәче. Акылга сыямы соң инде бу?

Герцог. Сыю гына түгел, чын-чыннан хуплый. Инде дәрәҗәм дә, киемем дә, сүзләрем дә тәэсир итмәгәч, шигегезне бетерү өчен тагын бер адым атларга мәҗбүрмен. Менә Герцогның имзасы белән мөһере, аның кулын таныйсыздыр? Мөһерен дә күргәнегез бардыр?

Төрмәче. Икесен дә таныйм.

Герцог. Бу хатында ул озакламый кайтып җитәчәген хәбәр итә. Соңыннан, вакытыгыз барда укып чыгарсыз. Анда күрерсез, Герцог ике көннән монда булачак. Анжело бу хакта берни дә белми. Киресенчә, ул бүген бөтенләй башка эчтәлекле хат алды. Анда «Герцог әллә үлде, әллә монастырьга керде» дип язылган... Бәхеткә каршы, бу хәбәрләрнең берсе дә дөрес түгел. Карагыз әле, таң нурлары көтүчеләрне уята, озак уйлап тормагыз. Эшнең төбен аңласагыз, бөтен кыенлыклар да җиңел булып тоелыр. Чакырыгыз җәлладны, ул Бернардин башын киссен, хәзер мин аны үлемгә әзерлим. Сез әле һаман аптырап торасыз. Ләкин бу хат сезне хәрәкәткә рухландырырга тиеш. Әйдә, әнә таң да сызылып килә.

Китәләр.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төрмәнең икенче бүлмәсе. Мәзәкче керә.

Мәзәкче. Күнегеп тә өлгердем, әйтерсең мин үзебезнең фәхешханәдә, әйтерсең лә Таушалган ханым өендә. Аның иске танышлары да монда бик күп. Әйтик, Елдам әфәнде бер төргәк саргылт кәгазь белән имбир өчен утыра. Аннан Сикергеч әфәнде, аны бер сәүдәгәр утырткан. Хәзер аңа дүрт төргәк кызыл атлас өчен үзенә кызарырга туры килә. Яшь-җилкенчәк Җилкуар әфәнде дә, Сүгенүче әфәнде дә, Бакыршпор белән Сарышешә әфәнделәр дә — барысы да монда. Безнең кәсепнең өрлек баганалары бит алар! Хәзер монда Алла хакына сәдака өмет итеп утыралар.

Дәһшәтле керә.

Дәһшәтле. Әй син, малай, Бернардинны чакыр.

Мәзәкче. Бернардин әфәнде! Торыгыз да тизрәк башыгызны бүкәнгә куегыз, Бернардин әфәнде!

Дәһшәтле. Әй, Бернардин!

Бернардин *(сәхнә артыннан)*. Бугазыгыз тыгылсын, үләт кырсын үзегезне! Нигә бу кадәр акырасыз? Сез кем?

Мәзәкче. Якын дустыгыз, әфәндем, җәллад! Рәхим итеп торыгыз, хәзер башыгызны кисәбез...

Бернардин. Кадалып китегез, кабахәтләр! Минем йокым килә.

Дәһшәтле. Әйт аңа, тизрәк торсын.

Мәзәкче. Зинһар, дим, әфәндем, уяныгыз инде, торыгыз, башыгызны гына кисик тә аннан теләгәнчә йокларсыз.

Дәһшәтле. Бар, алып кил үзен.

Мәзәкче. Әнә үзе дә килә, аяк астында салам кыштырдый.

Дәһшәтле. Балта бүкән өстендәме?

Мәзәкче. Барысы да әзер, әфәндем.

Бернардин керә.

Бернардин. Исәнме, Дәһшәтле! Нәрсә бар?

Дәһшәтле. Менә шул, әфәндем: доганы укы, хөкем карары килде.

Бернардин. Аһ сез, юньсезләр. Төн буе аракы эчтем бит мин, үлемгә бөтенләй әзер түгел.

Мәзәкче. Бик әйбәт, әфәндем. Төн буе эчкән кешене иртә белән асалар да инде. Шуннан ул рәхәтләнеп йоклый.

Дәһшәтле. Карагыз, әнә рухани килә, бу юлы без шаярмыйбыз.

Элеккечә, монах киеменнән Герцог керә.

Герцог. Озакламый фани дөнья белән бәхилләшәсең дип ишеттем. Минем бурычым сине тәүбә иттерү, бергәләп гыйбадәт кылу.

Бернардин. Куй әле, монах! Мин төн буе аракы эчтем. Әйбәтләп үлемгә әзерләнү өчен миңа вакыт кирәк. Күсәкләр белән кыйнап миемне агызсагыз да, мин бүген үләргә риза түгел, шуның белән бетте-китте.

Герцог. Шуны син бел, әҗәлдән һич калып булмый. Барыр юлың турында син ныгытып уйла.

Бернардин. Ант итеп әйтәм, мине беркем дә бүген үләргә күндерә алмый.

Герцог. Тыңлагыз әле...

Бернардин. Уйлап та карамыйм. Миңа әйтер сүзегез булса, ояма рәхим итегез, бүген мин аннан бер адым да читкә чыкмыйм.

Герцог

Мондый кеше тормышка да һич яраксыз,
Үлемгә дә. Таш йөрәкле кеше бит бу.
Тотыгыз да көчләп алып чыгыгыз үзен.

Мәзәкче белән Дәһшәтле китәләр. Төрмәче керә.

Төрмәче

Йә, ничек соң, тоткынны, дим, күрдегезме?

Герцог

Бигрәк тупас, үлемгә һич әзер түгел,
Бу хәлендә ахирәткә озату аны
Бик зур гөнаһ булыр.

Төрмәче

Монда, изге ата,
Бүген төнлә каты бизгәк авыруыннан
Бер юлбасар үлде, Рагуз шәһәреннән.
Клавдионың яшьтәше ул. Чәчләре дә,
Сакалы да аныкына бик нык охшый.
Бернардинга тәүбә өчен вакыт биреп,
Шул юлбасар башын илтсәк Анжелога,
Ничегрәк булыр икән?

Герцог

Бик шәп булыр,
Алла ярдәм итә безгә. Тизрәк җибәр.
Билгеләнгән вакыты да җитеп килә!
Боерыкның үтәлүе төгәл булсын.
Бу тоткынны хәзер тәүбә иттерим мин.

Төрмәче

Шулай итәм, изге ата... Бернардинны
Бүгеннән дә калдырмыйча җәзаларга.
Ләкин шунысы: Клавдионы нишләтәбез?
Аның исән икәнлеге мәгълүм булса,
Һәлакәттән котылып булмас.

Герцог

Болай итик:
Икесен дә аулак җиргә урынлаштыр.

Көләч кояш ике тапкыр күтәрелеп
Җир йөзенә сәлам биреп нурлар сипкәч,
Бу бәладән котыласың, ышан миңа.

Төрмәче

Барысын да сез әйткәнчә эшлим хәзер.

Герцог

Башны тизрәк җибәрә күр.

Төрмәче китә.

Анжелога

Хат языйм мин. Төрмәче илтеп бирер.
Юлга чыктым, кайтып киләм, дип белдерим.
«Мөһим сәбәп аркасында шәһәргә мин
Тантаналы төстә кайтып керәм», — диим.
Шәһәрдән бер миль чамасы Изге чишмә,
Шунда чыгып, мине үзе каршыласын.
Бөтен ягын уйлап, шунда Анжелоны
Нишләтергә икәнен мин хәл итәрмен.

Төрмәче керә.

Төрмәче

Менә ул баш, хәзер үзем илтеп бирәм.

Герцог

Ярый, яхшы... Ләкин тиз кайт, озак торма,
Үзеңә генә әйтә торган серләрем бар.

Төрмәче

Мөмкин кадәр тиз йөрермен.

Китә.

Изабелла
*(сәхнә артыннан)*

Сәлам сезгә! Ачыгыз әле.

Герцог

Изабелла тавышы бу. Абыйсының
Котылуын белү өчен килгән инде ул.
Аның исән икәнлеген әйтми торыйм,
Вакыты түгел, соңыннан, һич көтмәгәндә
Әйтермен дә куандырырмын мин аны.

Изабелла керә.

Изабелла

Мөмкинме?

Герцог

Сәлам сезгә, сылу кызым.

Изабелла

Сезнең сәлам минем өчен бик кадерле.
Йә, ничек, граф абыемны коткардымы?

Герцог

Коткарды... Тик фани дөнья газабыннан.

Абыегыз җәзаланды. Башын кисеп
Анжелога җибәрделәр.

Изабелла

А... Юк, булмас!

Герцог

Ләкин бу хак. Сабырлыгың җуйма, кызым,
Акыллы кыз икәнеңне күрсәт хәзер.

Изабелла

Киттем аңа! О! Күзләрен чокып алам.

Герцог

Хәзер сине аңа якын җибәрмиләр.

Изабелла

Аһ, бичара Клавдио! Бәхетсез мин!
Әй син, шакшы дөнья! Ләгънәт, ләгънәт сиңа,
Кансыз адәм!

Герцог

Синең аһ-ваһыңнан
Аңа һичбер зарар килми, үзеңә дә
Файдасы юк, хәсрәтеңне сүзсез кичер,
Барсын Ходай иркенә тапшыр, кызым.
Тыңла мине, бу сүзләрнең барсы да хак,
Иртәгә Герцог кайта, син елама,
Моны карт бер монах хәбәр итте. Герцог
Графка да, Эскалга да хат җибәргән.
Алар, каршы чыгып шәһәр капкасына,
Хакимлекне аның үзенә кайтаралар.
Киңәшемне тотсаң, явыз графтан да
Үч алырсың, ил халкының мактавына,
Герцог мәрхәмәтенә дә ирешерсең.

Изабелла

Мин буйсынам.

Герцог

Менә шушы хатны Петр атага илт,
Әйт син аңа, бүген төнлә, шәфәкъ баткач,
Марианага килсен. Сезнең икегезне
Аңа тапшырырмын. Сезне Петр ата
Иртән Герцог каршысына алып барыр.
Менә шунда Анжелоны фаш итәрсең.
Ә мин — монах, биргән антым аркасында
Сезнең янда була алмыйм. Бар, тынычлан,
Яшьләрең сөрт. Хатны хәзер илтеп тапшыр.
Кемдер килде.

Луцио керә.

Луцио. Хәерле кич. Әйтче, монах, Төрмәче кайда?
Герцог. Чыгып китте.

Луцио. Аһ, мөлаем Изабелла! Кайнар яшьтән кызарган күзләреңне күреп, йөрәгем әрни, түз, сылуым! Минем үземне дә кысыр ашка утырттылар. Иртән дә, кичен дә солы боткасы белән су. Баш кайгысы тамакны кыса — корсак буш. Туйганчы бер генә ашасам да, башым рәтләнер иде. Әле шуны ишеттем: иртәгә Герцог кайта икән. Намусым белән ант итеп әйтәм, Изабелла, абыеңны бик ярата

идем. Әгәр дә безнең тиле-миле Герцогыбыз, безгелдәп йөрмичә, өендә генә утырса, абыең да исән калыр иде.

Изабелла китә.

Герцог. Әфәндем, мондый мактавыгыз өчен герцог сезгә рәхмәт әйтмәс. Бу сүзләрдә бер тамчы да дөреслек юк.

Луцио. Монах! Герцогны син мин белгән кадәр белмисең бит. Хатын-кызга ничек хирыслыгын башыңа да китерә алмыйсың.

Герцог. Яхшы, яхшы. Бу сүзләрегез өчен кайчан да булса бер җавап бирерсез әле. Хушыгыз.

Луцио.Чү, сабыр ит! Мин дә синең белән барам. Герцог турында сиңа тагын да шәбрәк әкәмәтләр сөйлим әле.

Герцог. Болай да бик күп сөйләдегез инде. Анда тамчы кадәр хаклык булса, бәхетегез. Инде чепчи ялган булып чыкса, үтергәнче каезлау өчен берсе дә бик җиткән.

Луцио. Бер тапкыр ул мине үзенә чакырып алды, бер кызга бала ясаган өчен.

Герцог. Андый гаебегез чынлап та булдымыни?

Луцио. Ничек кенә булды әле! Ләкин мин «дөрес түгел» дип ант иттем дә котылдым. Юкса сөрсеп беткән урам кызына көчләп өйләндерәләр иде.

Герцог. Әфәндем, сезнең бу сүзләрегез, әдәпле булудан да бигрәк, кызыклы.

Луцио. Намусым белән ант итеп әйтәм, мин сине урам чатына кадәр озатам. Әдәпсез сүзләр яратмасаң, сөйләмим. Мин бит тигәнәк сыман бер ябыштыммы — ычкынмыйм.

Китәләр.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Анжело сараеның залы.
Анжело белән Эскал керәләр.

Эскал. Язган хатларында капма-каршы фикерләр.

Анжело. Бик гаҗәп. Уйларында һичбер бәйләнеш юк. Кылган эшләре дә шашкан кешенекенә охшый... Алладан шуны сорыйм: акылына гына зәгыйфьлек килмәсен иде. Ни өчен без аны шәһәр капкасы төбендә каршыларга тиеш? Хакимлекне шунда гына тапшырырга куша.

Эскал. Һич акылым ирешми.

Анжело. Ни өчен без, аның кайтуына бер сәгать калгач, халыкка белдерү ясарга тиеш? Белдерүе дә нинди: безнең эшебездә гаделсезлек күргән кешеләр аңа шунда урамда ук гариза бирә алалар.

Эскал. Ул аны болай аңлата: булачак шелтәләрдән безне коткару өчен бөтен шикаятьләрне берьюлы тикшерә дә соңыннан зарланырга урын калмый.

Анжело

Ярый, яхшы. Алайса, сез бу хәбәрне
Халыкка белдерегез... Иртәнчәк мин
Үзем сезгә керәм. Барлык түрәләр дә
Бердәм чыгып каршыларга әзер торсын.

Эскал

Барысын да үтәрмен. Хуш, сау булыгыз.

Анжело
Хәерле төн.
Эскал китә.

Каушап калдым... Баш эшләми.
Нишләргә соң? Кыз намусын таптаган ул!
Кем дисезме? Нәкъ шундый ук гөнаһ өчен
Башкаларның газиз башын кискән кеше!
Үз хурлыгын фаш итүдән тартынмаса,
Бу кыз мине ил каршында хур итә бит!..
Юк, ул андый юлга басмас, акылы булса:
Ил каршында зур ышаныч яулап алган,
Дан казанган шундый затка яла ягу
Аның үзен хур итәсен белә бит ул!
Әйе, егет кызу канлы, яшь иде шул,
Хурлык белән сатып алган гомере өчен
Соңыннан үч алуыннан курыкмасам,

Әлбәттә, ул рәхәтләнеп яшәр иде...
Әйе! Хаклык нуры сүнсә йөрәгеңдә,
Аптырыйсың, белмисең ни кирәген дә!

Китә.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шәһәрдән читтә ачык бер урын.
Үз киемнәрен кигән Герцог белән Петр ата керәләр.

Герцог

Бу хатларның барын аннан миңа тапшырырсың.
*(Хатларны бирә.)*
Төрмәчегә мәгълүм безнең бөтен план.
Без башладык. Киңәшләрне исеңдә тот.
Туры килеп, кайчак шулай барыр юлдан
Бераз читкә тайпылсаң да коелып төшмә.
Алга куйган максатыңа омтыл һаман.
Бар, җәһәт бул. Кичекмәстән Флавига бар,
Минем кайда икәнлекне әйт син аңа.
Валентинга, Красска да, Роландка да
Белдер — алар быргычылар чакырсыннар.
Ләкин башта Флавины миңа җибәр.

Петр ата
Ярый, киттем.

Китә. Варри керә.

Герцог

Рәхмәт сиңа, хөрмәтле Варри.
Вакытында килеп җиттең. Әйдә тизрәк.
Анда күптән мине дуслар көтеп тора.

Китәләр.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Шәһәр капкасына якын урам.
Изабелла белән Мариана керәләр.

Изабелла

Җепнең очын яшереп сөйләү авыр миңа,
Мин туп-туры дөресен генә сөйләр идем.
Сезгә җиңел — аны шәпләп гаеплисез.
Ә мин монда, уртак максат дигән булып,
Карт кушканны гына сөйлим.

Мариана

Тыңлагыз сез аны.

Изабелла

Тагын шуны да әйтте:
Әгәр дә, ди, сезгә каршы сөйләп куйсам,
Сез аңа, ди, бер дә гаҗәпләнмәгез, ди.
Ул сүз дару кебек ачы тоелса да,
Илтәчәк, ди, имеш, татлы нәтиҗәгә.

Мариана

Петр ата тизрәк килеп җитсен иде...

Изабелла

Чү! Әнә ул.
Петр ата керә.

Петр ата

Йә, әйдәгез, киттек тизрәк!
Җайлы урын таптым сезгә. Герцог сезне
Аннан бик тиз күреп алыр. Вакыт җитте.
Инде ике тапкыр быргы кычкырттылар.
Затлы ирләр, шәһәрнең зур түрәләре —
Барысы да җыйналдылар, озакламый
Герцог кайтып төшәр. Әйдә, тиз булыгыз!

Китәләр.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шәһәр капкасы янында мәйдан.

Мариананың йөзе пәрдә белән капланган. Изабелла белән Петр ата читтәрәк торалар. Бер яктан Герцог, Варри, сарай хадимнәре, икенче яктан Анжело,

Эскал, Луцио, Төрмәче, сакчылар, шәһәр халкы керәләр.

Герцог
*(Анжелога)*

Сәлам сиңа, намуслы кардәшкәем!
*(Эскалга.)*
Иске дустым, сине күрүгә мин бик шат.

Анжело, Эскал
*(икесе бергә)*

Сау-сәламәт кайтуыгыз белән котлыйбыз!

Герцог

Икегезгә дә зур рәхмәт чын күңелдән!
Сезнең хакта әйбәт хәбәр килеп торды,
Гадел хөкем сөргән өчен бик мактыйлар.
Ил каршында котлыйм сезне, бик зур рәхмәт.
Хезмәтегез тиешенчә бүләкләнер.

Анжело

Зурлавыгыз өчен чиксез бурычлымын.

Герцог

Хезмәтегез көчле чаңдай яңгырый сезнең,
Моны әйтмәү гаделсезлек булыр иде.
Заман кулы сөртеп ташлый алмас өчен,
Бу хезмәтләр язылыр бакыр такталарга.
Бир кулыңны, күрсен халкым, хисләремне —
Рәхмәтемне менә шулай аңлатам мин.
Эскал! Сиңа мин икенче кулны бирәм,
Ышанычлы таяныч сез икегез дә.

Петр ата белән Изабелла алга чыгалар.

Петр ата

Вакыт җитте! Кыюрак! Кычкырып әйт!
Тезлән тизрәк!

Изабелла

Гадел хөкем сорыйм, бөек хөкемдарым!
Күз салыгыз мыскылланган... аһ, әгәр дә
«Кызга» дип әйталсам икән! О хөкемдар!
Минем зарны тыңлап хөкем чыгармыйча,

Юнәлтмәгез күзегезне башкаларга.
Гадел хөкем сорыйм сездән, гадел хөкем!

Герцог

Нинди гозерең бар? Әйт, кем җәберләде?
Кыскарак тот. Граф Анжело тора менә.
Зарыңны син тартынмыйча аңа сөйлә,
Хөкем аның кулында бит.

Изабелла

Хакимебез!
Сез Иблискә ялварырга кушасыз бит!
Юк, үзегез тыңлагыз сез минем сүзне.
Ялганчы дип санасагыз, җәзалагыз,
Ышансагыз, минем өчен үч алыгыз.
Аһ, тыңлагыз, тыңлагыз, дим, хәзер, шунда...

Анжело

Хөкемдар! Ул акылыннан шашкан бугай.
Абыйсы өчен ялынып миңа килгән иде.
Әле күптән түгел абыен гадел закон
Үлемгә хөкем итте.

Изабелла

Гадел хөкем?

Анжело

Шуңадырмы сүзләре дә артык гаҗәп...

Изабелла

Әйе, гаҗәп, ләкин дөрес! Анжелоның
Ант бозуы гаҗәп түгелмени?
Граф Анжело уйнашчы ул, кыз көчләүче,
Икейөзле — гаҗәп түгелме бу?

Герцог

Гаҗәп!

Изабелла

Гаҗәп булган кебек үк, бу — чын хакыйкать!
Граф Анжело булуы хак булган кебек,
Мактаулы бу эше дә хак, йөз кат, мең кат.
Хаклык хаклык булып кала нишләсәң дә.

Герцог

Алыгыз бу бичараны, саташкан ул,
Акылы камил түгел аның.

Изабелла

Аһ, хөкемдар!
Ялынып сорыйм, бу тормыштан башка тагын
Рәхәт дөнья барлыгына ышансагыз,
Шашкан бу дип, мине читкә какмагыз сез,
Булмас кебек күренгән бу җинаятьне
Чынлап булган дип санагыз.
Анжелодай, дөньяда иң явыз кеше
Иң намуслы, иң әдәпле, иң саф булып
Күренә алган бит; ни өчен шул Анжело,
Зур хөрмәткә, дәрәҗәгә ирешкәч тә,
Кабахәтлек эшли алмас дип уйлыйсыз?

Ышаныгыз, хөкемдарым, изге булып
Күреналмаса, ул чүп кенә булыр иде.
Кабахәт дип кенә әйтү йомшак була.
Аның асылын аңлатыр сүз табылмаган.

Герцог

Мин ант итәм, акылыннан шашса да ул,
Сүзләрендә үткен акыл, төпле мәгънә.
Шашканнарның сүзе белән фикерендә
Бәйләнеш бик сирәк була.

Изабелла

Аһ, кирәкми!
Кабатламагызчы, зинһар, бу сүзләрне,
Ялынып сорыйм, аның шакшы җинаяте
Булмас кебек күренгәнгә карап кына,
Шашкан кеше сүзе бу дип уйламагыз.
Кушыгыз эшкә хәзер сез үз акылыгызны,
Яшеренергә мәҗбүр булган хаклыкны ул
Караңгыдан яктылыкка чакырып алсын,
Хаклык булып кыланучы чи ялганны
Мәсхәрәләп читкә сөрсен!

Герцог

Сәламәт дип исәпләгән кешедә дә
Бу кадәрле тирән мәгънә сирәк була.
Ни әйтмәкче буласың син?

Изабелла

Абыемны,
Уйнашчы дип, граф үлемгә хөкем иткән.
Шуннан абыем мин урнашкан монастырьга
Луцио дигән бер кешене...

Луцио

Әйе, шулай.
Мин булам ул Луцио, дөрес әйтә,
Абыйсының йомышы белән бардым аңа.

Изабелла

Әйе, шулай.

Герцог
*(Луциога)*

Мин сөйләргә боермадым.

Луцио

Сүзегез дөрес, җәнабы гали, әмма ләкин
Сөйләмәскә дип тә боерык бирмәдегез.

Герцог

Хәзер боерам, исеңдә тот, ләкин кара,
Үзең өчен сөйләр вакыт килеп җиткәч,
Телләрең, дим, тотлыкмасын.

Луцио

Юк, тотлыкмас.

Герцог

Тотлыкмасмы? Иманыңны укы.

Луцио

Укыйм.

Изабелла

Бу егет мин әйтәсе сүзне әйтте.

Луцио

Әйбәт итеп.

Герцог

Үз вакытың җитмиенчә
Кысылуың әйбәт түгел. Йә, сөйләгез!

Изабелла

Шуннан соң мин шушы явыз кабахәтнең
Каршысына бардым.

Герцог

Тагын саташтыгыз.

Изабелла

Кичерегез, тик бу сүзләр бик урынлы.

Герцог

Белмим инде. Ярый, шуннан?

Изабелла

Сузмас өчен
Ничек итеп рәхим-шәфкать соравымны,
Каршысына тезләнеп ялынуымны,
Аның кире кагуларын сөйләп тормыйм.
Ахырыннан, иң хурлыклы өлешеннән
Башлап китим... Авыр да, бик оят та...
Хайвани хисләренә азык итеп
Кызлыгымны сорады ул, пакь тәнемне.
Шул хурлыклы түләү белән абыема
Шәфкать сатып алырга мин тиеш булдым.
Бик газаплы эчке көрәш барды башта,
Ахыр чиктә таң алдыннан бирелдем мин.
Максатына ирешкәч тә, шул ук таңда
Абыемның газиз башын кистерде ул.

Герцог

Менә монысы бераз чынга охшый кебек.

Изабелла

Охшаудан да бигрәк, чын бу, чын хакыйкать.

Герцог

Хода белән ант итәм мин, шашканлыктан
Телең нәрсә сөйләгәнне ишетмисең,
Яла ягып, графны күздән төшерү өчен
Ялладылармы әллә сине? Беренчедән,
Ул шөбһәдән өстен тора, икенчедән,
Шул ук гөнаһ булса аның үз күңелендә,
Мондый каты хөкем чыгаралмас иде,
Абыеңның гөнаһын үз аршынына
Үлчәр иде. Абыең исән калыр иде.
Котырткannar сине, хәзер әйт дөресен:
Кем котыртты?

Изабелла

Шулмы хөкем? Әй Тәгалә,
Бир чыдамлык! Фаш ит, Раббым, явызлыкны,
Үзең сакла мине җәбер-хурлыклардан.
Ярый, китим, мин татыган хурлыклардан
Хак Тәгалә үзе сезне саклый күрсен.

Герцог

Әйе, китәр идең бугай, әй сакчылар!
Алыгыз үзен. Җандай күргән якыныма
Пычрак яла актырамы күз алдымда?
Кемнәрдер сүз берләштереп, яла ягып
Аны күздән төшермәкче. Әйт, кем кушты?
Кемнәр белде синең монда киләсеңне?

Изабелла

Берәү белде, аһ, ул монда булса иде! —
Людовико ата.

Герцог

Әһә, руханиең.
Әйт, кем белә ул монахны?

Луцио

Мин беләм, мин.
Бигрәк әрсез, җенем сөйми шул монахны.
Ух, өстендә изге кием булмасамы,
Сезне хурлап сөйләве өчен, мин ул картны
Күптән кыйнап ташлар идем.

Герцог

Безне хурлап?
Алайса, шәп монах икән. Бу кызны да
Анжелоны хурлау өчен җибәргән ул.
Табарга ул монахны!

Луцио

Кичә генә
Мин төрмәдә күрдем кызны шул карт белән.
Бик оятсыз, әрсез монах, ыштыр бит ул.

Петр ата

Сәлам сезгә, хөкемдарым,
Монда чеп-чи ялган сөйләп
Рәнҗетәләр сезнең изге колакларны.
Бар да гайбәт, бу хатын-кыз ялган сөйли,
Дәрәҗәле саф кешегә яла яга.

Герцог

Людовико атаны сез беләсезме?

Петр ата

Яхшы беләм. Саф күңелле изге кеше.
Бу әфәнде әйткәнчә, һич әрсез түгел.
Ыштыр бит тә түгел, әйтәм чын күңелдән.
Ул карт сезне берничек тә хурлый алмый.

Луцио

Оятсызларча хурлады, дим, ышаныгыз.

Петр ата

Ярый, яхшы... Вакыты җиткәч, ул үзе дә
Акланыр. Әмма хәзер авырып ята,
Каты бизгәк тота аны, җәнабы гали.
Графка каршы төрле сүзләр булуын белеп,
Кайсысы хак, кайсы нахак икәнлеген
Үз исеменнән каршыгызда сөйләргә дип
Җибәрде ул мине монда. Үз фикерен
Раслау өчен күп дәлилләр китерәчәк ул.
Бу хатын-кыз турында мин шуны әйтә алам:
Анжелоны ялалардан йолу өчен,
Аның үзен хәзер шундук фаш итәм мин.
Ялганлавын ул үзе үк икърар итәр.

Сакчылар Изабелланы алып китәләр. Мариана якын килә.

Герцог

Граф Анжело, сезгә көлке түгелме бу?
Күрәсез ич, шыр тилеләр гайбәте бу.
Әй, урындык бирегез, мин — тамашачы,
Карап торыйм. Монда хаким сез бит әле?
*(Марианага.)*
Иң элек син йөзеңне ач, аннан сөйлә.

Мариана

Хөкемдарым, кичерегез, ирем үзе
Боерык бирми торып, йөзем ача алмыйм мин.

Герцог

Сез ирдәме?

Мариана

Юк, хөкемдар.

Герцог

Алайса, кыз?

Мариана

Юк, хөкемдар.

Герцог

Тол хатынмы?

Мариана

Юк, хөкемдар.
Герцог. Алайса, кем дип эндәшим? Ничек соң ул хатын түгел, кыз да түгел, тол да түгел.
Луцио. Бәлки, фахишәдер, җәнабы гали, аларның бит күбесе иргә дә чыкмый, кыз да булмый, тол да калмый.

Герцог

Томалагыз әле, зинһар, шуның авызын,
Үзе өчен дә сөйлисе бик күп аның.

Луцио

Мин буйсынам, хөкемдарым.

Мариана

Әле иргә чыкканым юк, шул ук вакыт
Кыз да түгел, иремне татыдым мин.
Әмма ирем белми мине татыганын.
Луцио. Алайса, ул лаякыл исерек булган. Башкача булуы мөмкин түгел.

Герцог. Менә син лаякыл исерек булсаң, дәшми торыр идең, ичмасам.

Луцио

Буйсынам, хөкемдарым.

Герцог

Бу сүзләрнең графка нинди катнашы бар.

Мариана

Хәзер аны яклый башлыйм. Әле генә
Бер кыз аны «уйнашчы» дип гаепләде.
Шул бит инде минем ирем. Ләкин әйтим:
Кызның сүзе дөрес түгел. Нәкъ шул көнне,
Ул күрсәткән вакытта — нәкъ таң алдыннан —
Минем ирем үз куенымда ята иде.
Моны раслап ант итә алам.

Анжело

Алайса, ул
Башка ирне гаепләгән, мине түгел.

Мариана

Башка ирне түгел шул, граф.

Герцог

Ничек инде?
Үзегез «минем иремне» дип әйттегез ич.

Мариана

Әйе, хөкемдар, Анжело — минем ирем,
Куенында булган кызны мин дип белми,
Изабелла дип уйлый ул.

Анжело

Бу нинди эш?
Ач йөзеңне!

Мариана

Ирем кушкач ачам инде.

Пәрдәсен ача.

Менә ул йөз, әйтүеңә караганда,
Аңа карап син сокланып туймый идең.
Менә кулым. Син, шул кулны кыса-кыса,
Миңа антлар иткән идең. Менә үзем
Караңгыда йөзем бакчалары аша,
Изабелла булып, синең яныңа кердем.

Герцог
*(Анжелога)*

Сез танышмы?

Луцио

Таныш кынамы соң, әнә
Хатын үзе әйтеп тора.

Герцог

Туктыйсыңмы?

Луцио

Туктыйм, туктыйм, җәнабы гали.

Анжело

Хөкемдар, һич яшереп булмый, без танышлар.
Моннан төгәл биш ел элек мин бу кызга
Өйләнергә тиеш идем. Әмма ләкин
Эш чыкмады. Вәгъдә иткән бирнәләр дә
Бирелмәде, аннан бигрәк кызның холкы,
Акылы да камил түгел, дип әйттеләр.
Биш ел инде очрашып сөйләшкән юк,
Күргәнем юк, нишләгәнен белгәнем юк,
Намусым белән ант итәм мин.

Мариана
*(тезләнә)*

Җәнабы гали!
Бирелгән ант әгәр коры сүз булмаса,
Анжелоның ярәшелгән хатыны мин.
Аннан тагын сишәмбе көн, төнлә белән
Бакчадагы өенә бардым. Шунда мине
Хатыны итеп татыды ул. Шул сүзләрем
Дөрес булса, сау-сәламәт торып басам,
Ялган булса, мин, тезләнгән килеш, шунда
Таштан юнган һәйкәл булып катып калыйм.

Анжело

Моңача мин көлеп кенә тыңлап тордым.
Хәзер сезнең рөхсәт белән, җәнабы гали,
Хөкем итә башлыйм, артык чыдап булмый.
Күреп торам, ниндидер бер көчле дошман
Бу бичара ярты акыллы хатыннарны
Миңа каршы корал иткән. Хөкемдарым,
Бирегез рөхсәт, сүтеп ташлыйм бу мәкерне.

Герцог

Чын күңелдән рөхсәт итәм,
Теләгәнчә җәзалагыз сез боларны.
Ә син, җүләр монах, син дә, җүләр кызый,
Әлеге хатын белән сүз беркетеп,
Антлар эчеп, изгеләрне шаһит итеп,
Каршыбызда шулкадәр зур дан казанган,
Ышаныч яулап алган шундый затны
Хур итәргә уйладыгыз. Эскал, килче!
Бу кабахәт эшнең төбен тикшерергә
Ярдәм ит син, анда тагын бер монах бар,
Кичекмәстән анысын да китертергә.

Петр ата

Әйе, әгәр килә алса... Кызларны бит
Ул җибәрде. Төрмәчегә боерыгыз,
Аның кайда торганын ул яхшы белә.

Герцог
*(Төрмәчегә)*

Тизрәк табып китерегез.

Төрмәче китә.
*(Анжелога.)*

Ә сез, газиз туганым, бу җинаятьнең
Төбенә төшми туктамагыз.
Явызларны теләгәнчә җәзалагыз.
Мин беразга китеп торам. Тик карагыз,
Җинаятьнең төбен-тамырын айкамыйча
Урыныгыздан кузгалмагыз.

Эскал

Хөкемдарым,
Борчылмагыз, бик җентекләп тикшерербез.

Герцог китә.

Эскал. Луцио әфәнде, сез Людовико атаны намуссыз дидегез шикелле.

Луцио. Аның изгелеге киемендә генә. Герцогыбыз турында әллә нинди әшәке сүзләр сөйләп йөри.

Эскал. Сез китми торыгыз, шул әйткән сүзләрегезне үз алдында расларсыз. Ә монах, чынлап та, хәтәр кеше булырга кирәк.

Луцио. Ант итеп әйтәм, шәһәрдә аннан да әшәке кеше юк.

Эскал *(хезмәтчеләрнең берсенә)*. Изабелланы да алып килегез, миңа аның белән дә сөйләшергә кирәк.

Хезмәтче китә.

Кызга сорау бирергә рөхсәт итегез, граф. Менә күрерсез: мин аны бик тиз чишендерермен.

Луцио. Юк, сез барыбер граф кадәр булдыра алмассыз.

Эскал. Нәрсә?

Луцио. Сезгә икәүдән-икәү калырга кирәк иде, дим, кеше алдында чишенергә оялыр бит ул.

Эскал. Шәмен сүндерәм мин ул кызның.

Луцио. Бик дөрес, әфәндем, шәм сүнгәч, хатын-кыз күндәмрәк була.

Сакчылар Изабелланы алып керәләр.

Эскал *(Изабеллага)*. Якын килегез, туташ. Менә бу хатын сез әйткәннәрнең барын да юкка чыгарды.

Луцио. Әфәндем, әнә теге әдәпсез монах Төрмәче белән килә.

Эскал. Бик әйбәт. Мин чакырмый торып, аның белән сөйләшмәгез.

Луцио. Авызымны да ачмыйм.

Монах булып киенгән Герцог белән Төрмәче керәләр.

Эскал. Җавап бирегез, бу хатыннарны графка яла ягарга сез котырттыгызмы? Алар яшермиләр, сез кушканга шулай эшләдек, диләр.

Герцог

Ялган бу.

Эскал

Нәрсә? Сез кайда икәнегезне беләсезме?

Герцог

Урыныгызга хөрмәт! Кайчак Иблисне дә
Тәмугтагы тәхете өчен хөрмәтлиләр.
Герцог кайда? Аңа әйтер сүзләрем бар.

Эскал

Хәзергә без, Герцог, монда, без тыңлыйбыз,
Аң булыгыз: сөйләгез тик дөресен генә.

Герцог

Дөресен сөйләрмен мин, алай куркып тормам.
Әй бичара бәрәннәр, сез, хаклык эзләп,
Шушы төлке каршысына килдегезме?
Хаклык бетте. Герцог тагын юкка чыкты.
Шулай булгач, харап сезнең эшләрегез!
Герцогыгыз гадел түгел — начар иткән,
Гаепләүче — фаш итүче шаһитларны
Ерткычның үз кулына биреп киткән.

Луцио

Кара, нинди кабахәт җан! Әйттем бит мин!

Эскал

Нәрсә дидең син, әдәпсез, динсез монах?
Житте-бетте! Котыртып бу хатыннарны,
Пакь кешегә пычрак яла яктыруың
Җитмәгән! Син әле тагын, монда килеп,
Ил каршында аны ерткыч дип атадың?
Герцогка тел тидерергә оятың житте!
Алыгыз үзен! Җәзалагыз! Бу гайбәтнең
Чыганагын әйттермичә туктамагыз!
Кара син, ә? Герцог гадел түгел, имеш.

Герцог

Чү, кызмагыз,
Герцог үзен җәзалый алмаган кебек,
Миңа ул бармагын да тидерә алмый.
Аның хөкеме йөрми миңа, мин чит илдән,
Бу шәһәргә эш белән мин бик еш киләм.
Күрәм сездә азгынлыкның, бозыклыкның
Хәттин ашып, чиктән чыгып киткәнлеген.
Җинаятькә каршы төрле законнар бар,
Ләкин алар чәчтарашның ишегендәге
Язу кебек мәгънәсез буш кәгазь генә.

Эскал

Хөкүмәтне мыскыл итә, алыгыз үзен.

Анжело

Йә, Луцио, бу хакта сез ни әйтәсез?
Сез сөйләгән әрсез монах шул түгелме?

Луцио. Нәкъ үзе, җәнабы гали, кил әле монда, такыр маңгай. Мине танныйсыңмы?

Герцог. Тавышыгыздан таныйм, әфәндем, мин сезне. Герцог кайтудан алда төрмәдә очраткан идем.

Луцио. Шулаймы? Герцог турында ниләр сөйләгәнеңне хәтерлисеңме?

Герцог. Бик яхшы хәтерлим.

Луцио. Алайса әйт инде, безнең Герцог уйнашчы, куркак, тиле-миле, шулаймы? Син бит аны шулай дип мактаган идең.

Герцог. Безгә урыннарны алмашырга кирәк. Аны шулай дип хурлаучы кеше — сез. Әле аннан да әшәкерәк нәрсәләр сөйләдегез.

Луцио. Минме? Ах син, каһәр суккан монах. Шуның өчен мин сине танавыңнан эләктереп сөйрәп йөртмәдемме?

Герцог. Юк, ант итеп әйтәм, Герцогны мин үземне сөйгән кебек сөйдем.

Луцио. Ишетәсезме? Оятсызларча сүгенүләреннән баш тартып котылмакчы була.

Эскал. Бу кеше белән озак сөйләшеп торасы юк. Әй, төрмәгә алып китегез үзен. Кайда Төрмәче? Төрмәгә! Аяк-кулларына богау салыгыз. Нәрсә аны тыңлап торырга! Бу әшәке хатыннарны да монах белән бергә илтеп ябыгыз.

Төрмәче Герцогка тотына.

Герцог. Ашыкмагыз, әфәндем, сабыр итегез.

Анжело. Ничек? Әле карышамы? Луцио, ярдәм итегез.

Луцио. Әйдә, әйдә, дускай, зарар юк. Эх, син, такыр маңгай, ялганчы! Ничек төренгән. Имансыз йөзеңне күрсәтергә ояласыңмыни, үләт кыргыры нәрсә? Җирәнгеч кыяфәтеңне күрсәт тә бер сәгать асылынып тор.

Герцогның киемен салдырып ала.

Герцог

Монахны Герцог иткән беренче син,
Кабахәт җан.
*(Төрмәчегә Петр атаны, Марианнаны, Изабелланы күрсәтеп.)*
Өчесен дә алам йолып.

*(Луциога.)*
Кайда киттең, тукта, дускай! Монах белән
Исәп-хисап өзәсең бар. Алыгыз үзен!
Луцио. Монысы дарга асылудан да хәтәррәк булыр, ахры.

Герцог
*(Эскалга)*

Сез әйткән сүзләрне мин гафу итәм,
Утырыгыз.
*(Анжелога.)*
Ә сез рөхсәт итегез инде,
Бу урынга утырыйм мин... Йә, әфәндем...
Хәзер сиңа бу хурлыктан котылу өчен
Телең, акылың, битсезлегең җитәр микән?
Тапсаң берәр дәлил, әле таяналасың,
Ачсам хәзер бар гаебеңне — эшең харап.

Анжело

Хөкемдарым, бөтен кылган гөнаһымны
Алла кебек белүегезне күрә торып,
Аны йомып калдырырга исәп тотсам,
Мең кат зуррак гөнаһ кылган булыр идем.
Үтенеп сорыйм, артык сузып маташмагыз,
Үлемгә дип тизрәк хөкем чыгарыгыз.
Шуны гына сорыйм сездән, хөкемдарым.

Герцог

Мариана! Килегез бире! Аның белән
Вәгъдәләштеңме син?

Мариана

Әйе, хөкемдарым.

Герцог

Бар, хәзер үк никах укыт. Изге ата,
Араларын никах белән беркетегез,
Эше беткәч, кире монда китерегез.
Төрмәче, син артларыннан ияреп бар.

Анжело, Мариана, Петр ата, Төрмәче китәләр.

Эскал

Аһ, хөкемдар, гаҗәп эшләреннән бигрәк,
Мәсхәрәгә калуы һич башыма сыймый.

Герцог

Килегез бире, Изабелла, юатучы
Руханидан Герцогыгыз булып куйдым,
Тик шунысы: киемнәрем үзгәрсә дә,
Сезгә булган хисләрем һич үзгәрмәде.

Изабелла

Аһ, хөкемдар, кичерегез мине, зинһар,
Танымыйча ил хакимен борчыганмын.

Герцог

Мин кичердем,
Сез дә мине кичерегез, мөлаем кыз.
Абыегызның үлеме бик борчый сезне.
«Ник яшеренеп йөрде Герцог, киемен салса,

Абыем исән калыр иде», — дип уйлыйсыз.
Аһ, сөеклем,
Барсына да шомлы үлем җәзасының
Ашык-пошык үтәлүе сәбәп булды.
Көтмәгәндә планымны бозып куйды.
Кабере нурлы булсын инде, бездән китте,
Шомлы үлем куркынычы мәңге бетте.
Бу дөньяга караганда шәбрәк анда.
Борчылмагыз, ул бәхетле.

Изабелла

Анысы шулай.

Анжело, Мариана, Петр ата, Төрмәче керәләр.

Герцог

Әнә үзе никахланып кайтып килә.
Сезнең кызлык намусыгызга орынды ул,
Бу гөнаһны
Мариана хакына сез кичерерсез.
Әмма ләкин абыегызны җәзалавы
Аның гаебен арттырды икеләтә.
Гафиф кызны хурлады ул, өстәвенә
«Коткарам» дип биргән изге антын бозды,
Законның иң мәрхәмәтле сүзе шушы:
«Клавдионың башы өчен — үз башыңны,
Җаны өчен — үз җаныңны», бетте-китте!
Нәкъ үзенчә: хөкеменә күрә хөкем,
Чамасына күрә лаек чарасы да.
Анжело, син гаебеңнән баш тарталмыйсың —
Ашык-пошык Клавдионың башын кискән
Бүкәнгә куй үз башыңны кичекмәстән.
Нәкъ үзе күк ашык-пошык җәзаларга.

Мариана

Аһ, хөрмәтле Герцог, миңа бу ирне сез
Әллә мәзәк өчен генә бирдегезме?

Герцог

Үзе сезгә мәзәк өчен ир булды ул.
Фәкать сезнең намусыгызны саклау өчен
Никах белән беркеттем мин арагызны.
Беркетмәсәм, мәсхәрәгә кала идегез.
Инде аның милке закон буенча да
Сезгә тиеш, ә без аны хәзер сезгә
Тол хатынның өлеше итеп тапшырабыз.
Байлык булгач, юньлерәк ир табылыр сезгә.

Мариана

Миңа бүтән бернинди ир кирәк түгел.

Герцог

Әйтмәгез дә, хөкемем нык, үзгәрми ул.

Мариана

Мәрхәмәтле хөкемдарым...

Тезләнә.

Герцог

Ялынмагыз! Алыгыз үзен, кичектерми җәзалагыз.
*(Луциога.)*
Йә, әфәндем, чират сезгә!

Мариана

Хөкемдарым!
Якын дустым, Изабелла, ялынып сорыйм:
Тезләнегез минем яныма, зинһар өчен,
Бар гомеремне, дустым, сезгә багышлармын.

Герцог

Ни сорыйсыз? Акылыгыз бармы сезнең?
Анжелога рәхим-шәфкать сораса ул,
Абыйсының рухы килеп каршысына
Җанын алыр.

Мариана

Аһ, сөеклем Изабелла,
Яныма килеп, зинһар, тезләнегез генә,
Күтәрегез кулыгызны сүзсез генә,
Догасын мин үзем укыйм.
Кайчагында иң зур гөнаһ ияләре,
Тәүбә кылгач, әүлияга әйләнәләр,
Бәлки, минем ирем дә нәкъ шулай булыр.

Герцог

Клавдио үлеме өчен әҗәл аңа.

Изабелла
*(тезләнә)*

Хөкемдарым, аны хөкем итегез, тик
Абыемны сау-сәламәт дип уйлагыз.
Чөнки аны хөкем иткән чагында ул
Чын күңелдән гаепләгән, гадел булган,
Сеңле барын уйламаган, шуңа күрә
Исән калсын. Абыем кылган гөнаһы өчен
Һәлак булды. Ә Анжело...
Алга куйган ниятен ул үтәмәде.
Фәкать коры ният кенә булып калды.
Ният бит ул фикер генә.

Мариана

Фикер генә.

Герцог

Ялынудан һич мәгънә юк, торыгыз, дим...
Чү, туктагыз, бер җинаять искә төште.
Төрмәче, әйт, ни өчен соң Клавдио
Законнан тыш сәгатьтә җәзаланды?

Төрмәче

Шундый боерык булды миңа.

Герцог

Нинди боерык? Язма боерык идеме?

Төрмәче

Юк, язма түгел,
Телдән генә әйтелде ул.

Герцог

Моның өчен
Эш урыныңнан коры калдың. Бир ачкычларны.

Төрмәче

Кичерегез,
Үзем дә мин ялгыштыр дип уйлый идем.
Күңелем дә һич ятмады. Соңыннан да
Бик үкендем, моңа шундый дәлил дә бар:
Телдән генә биргән боерык нигезендә
Бер тоткынны җәзаларга тиеш идем,
Шикләндем дә ул боерыкны үтәмәдем.

Герцог

Нинди тоткын ул?

Төрмәче

Бернардин.

Герцог

Аһ, әгәр дә син
Клавдионы да шулай саклап калсаң!..
Бар, алып кил, мин күрергә телим аны.

Эскал
*(Анжелога)*

Ничек соң бу? Шундый галим, шундый зирәк
Була торып, сез, Анжело, хискә бирелеп,
Шулкадәре түбәнлеккә төшә алдыгыз?

Анжело

Үземә дә чиксез авыр,
Авыр кайгы салдым сезнең күңелегезгә.
Гаебем чиксез, рәхим-шәфкать өмет итмим,
Үлем көтәм, фәкать үлем.

Төрмәче, Бернардин, ябынчагына төренгән Клавдио, Джульетта керәләр.

Герцог

Кайсысы Бернардин?

Төрмәче

Менә, җәнабы гали.

Герцог

Бу кешене ишетеп беләм бер монахтан.
Күңелең тәмам тупасланган икән синең.
Бу тормыштан ары берни күрә алмыйсың.
Дөньяда син шуннан чыгып эш итәсең.
Хөкем булган инде сиңа, тик шулай да
Кылган гөнаһларыңны мин гафу итәм.
Кадерен бел. Бу мәрхәмәт киләчәктә
Әйбәтрәк тормышка юл ачсын сиңа.
Изге ата, синең кулга тапшырыла,
Туры юлга күндер үзен. Ә бусы кем?

Төрмәче

Монысы да мин коткарып калган тоткын,
Клавдио белән бергә үләсе иде.
Аңа охшый да ул, коеп куйган кебек.

Клавдио битен ача.

Герцог

*(Изабеллага)*

Алай сезнең абыегызга охшый икән,
Кичерәбез. Кулыгызны бирегез, зинһар.
Үзегез миңа булсагыз сез, Изабелла,
Миңа да ул туган була, ләкин сабыр...
Бу хакта без соңыннан сөйләшербез.
Анжелоның күзләрендә өмет нуры,
Эшнең кая барганлыгын күреп тора,
Каты җәза чын бәхеткә әверелде.
Анжело, сез хатыныгызны яратыгыз,
Аның гаҗәп гүзәл рухи сыйфатлары
Сезнең абруйны һичшиксез күтәрәчәк.
Һәр кешене кичерәсем килә бүген.
Тик берәүне һич кенә дә кичерә алмыйм.
*(Луциога.)*
Шулай итеп, мин, синеңчә, ахмак, куркак,
Уйнашчы һәм чеп-чи надан, шашкан кеше?
Әйтегезче, нинди җәбер күрсәттем мин?
Ни сәбәптән бу кадәрле хурлыйсыз сез?

Луцио. Дөресен генә әйтсәм, җәнабы гали, мин бит болай гына, шаярып кына лыгырдадым. Моның өчен дарга асарга да хакыгыз бар инде, әлбәттә. Ләкин шулай да гафу итүегез әйбәтрәк булыр иде.

Герцог

Әйе, башта камчыларга, аннан дарга.
Хәбәрчеләр бөтен илгә кычкырсыннар:
Бу уйнашчы харап итеп ташлап киткән
Кызны эзләп тизрәк табып китерсеннәр.
Өйләндерәбез шул кызга. Никахтан соң
Бик әйбәтләп камчыларга, аннан дарга.

Луцио. Ялынып сорыйм, җәнабы гали, зинһар, дим, өйләндермәгез инде шул себеркегә. Үзегез яңа гына әйттегез ич, мин бит сезне монахтан Герцог ясадым, ә сез шул яхшылыкка каршы мине мөгезле ир ясарга итәсез.

Герцог

Намусым белән ант итәм мин, өйләнәсең;
Тик шуннан соң миңа яккан ялаларны,
Гайбәтеңне — кылган бөтен гөнаһыңны
Гафу итәм. Ә хәзергә сиңа — төрмә.
Бу хөкемне төгәл җиренә җиткерегез.

Луцио. Шул себеркегә өйләндерәсезмени инде, җәнабы гали? Бу бит әҗәлдән дә, камчыдан да, дардан да хәтәррәк.

Төрмә сакчылары Луционы алып китәләр.

Герцог

Ил хакимен хурлаучының җәзасы шул — өйләнәсең.
Клавдио, кәләшеңне бу хурлыктан
Арындыр син тизрәк. Сиңа, Мариана,
Шатлык телим. Анжело, син ярат аны,
Рухани да булдым аңа, яклаучы да,
Шунда күрдем аның гүзәл сыйфатларын.
Сиңа, Эскал, батырлыгың өчен рәхмәт,
Киләчәктә бүләге дә булыр аның.
Син, Төрмәче, нинди серләр саклый белдең!
Тугрылыгың өчен сиңа рәхмәт укыйм.
Югарырак булыр тиздән хезмәт урының.
Син, Анжело, кичер аның алдашуын —
Бер юлбасар башын илтеп биргән өчен.
Мондый алдау аклый үзен тулысынча.
Изабелла, сиңа мәгълүм үтенечем:
Күңелең тартса, мин — синеке, син — минеке.

Әйдәгезче, сарайга һәммәгез дә,
Калган ягын аңлатырмын шунда сезгә.

Китәләр.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Афина. Тезей сарае.
Тезей, Ипполита, Филострат һәм сарай хадимнәре керәләр.

Тезей

Гүзәлкәем,
Никахлану сәгатебез якынлаша:
Тагын дүрт көн калды яңа ай туарга.
Тик искесе, абау, бигрәк сүлпән инде,
Кайнар теләгемә киртә булыр тора,
Зарыктыра явыз үги ана кебек.

Ипполита

Дүрт көн төнгә ияреп тиз үтеп китәр;
Дүрт төн йокы белән йотылыр, сизелмәс тә...
Яңа ай — киерелгән көмеш җәя —
Туебызны котлап зәңгәр нурын сибәр.

Тезей

Филострат, бар!
Афина яшьләренең барысын кузгат,
Дәртләндер, күңелләре канатлансын.
Кайгы-хәсрәт җеназалар өчен калсын,
Чытык йөзле кунак безгә кирәк түгел.

Филострат китә.

Сине бит мин кылыч белән яулап алдым,
Мәхәббәтеңне куркытып талап алдым.
Ләкин туйны башкача үткәрәм мин,
Тантаналы, күңелле итеп, купшы итеп.

Эгей, Гермия, Лизандр һәм Деметрий керәләр.

Эгей

Бәхетле бул, герцогыбыз данлы Тезей!

Тезей

Рәхмәт яусын сиңа, Эгей, Йомышың ни?

Эгей

Хәсрәтем зур, шикаять белән килдем.
Гермиягә — әйе, туган кызкаема —
Сездән гадел хөкем өмет итеп килдем.
Деметрий, кил! Хөкемдарым, кызымны мин
Менә шушы егеткә бирмәкче идем.
Лизандр, син дә кил бире, якынрак!
Хөкемдарым! Монысы минем кызкаемны
Сихерләде. Син, син, Лизандр! Син

Шигырьләр яздың аңа, әгъваладың,
Тәрәзәсе төбендә ай яктысында
Гыйшык җыры җырлаган булып йөрдең!
Аның күңлен аулау өчен беләзекләр,
Чәчтән үргән йөзекләр, кәнфит, чәчәк,
Әллә нинди ялтыравык, шалтыравык
Тәтиләр алып килдең, кызыктырдың;
Тәҗрибәсез яшь кызга шул җитә калды!
Атасына буйсынучан мөлаем кыз
Үҗәтләнде, усалланды, эштән чыкты!
Хөкемдарым, әгәр дә ул сезнең алда
Деметрийгә никахланудан баш тартса,
Борынгы йолабызны кулланам мин:
Кыз минеке, димәк, минем ихтыярда;
Карарым шул — Деметрийгә чыга яки,
Әлеге йола буенча, аңа — үлем.

Тезей

Йә, Гермия, мөлаем кыз, ни әйтәсең?
Уйлап кара: ата хакы — Тәңре хакы.
Ул сине бар иткән шундый сылу итеп:
Калдырса да, юк итсә дә аның ирке.
Деметрий бөтен яклап сиңа лаек.

Гермия

Лизандрым да нәкъ шулай ук.

Тезей

Әйе, әлбәттә,
Ләкин атаң каршы булгач, тегесе лаек.

Гермия

Әткәй минем күзем белән караса иде!

Тезей

Юк, сылуым, синең күзләр
Әтиеңә буйсынырга тиеш булыр.

Гермия

Кичерегез, җәнабы гали, ялынып сорыйм.
Белмим, каян килде миңа бу кыюлык?
Мөмкин булмас микән хәзер
Миңа, әдәп киртәсеннән чыкмый гына,
Сезнең алда иркенләп сөйләшергә?
Миңа шуны белергә иде: әйтегезче,
Деметрийгә чыкмасам, минем өчен
Иң начары нәрсә булыр?

Тезей

Нәрсә? Үлем. Яки мәңге иргә чыкмый
Яшь гомереңне япа-ялгыз үткәрәсең.
Әтиеңнең хөкеменә буйсынмасаң.
Син яшь, күңелең җавап бирсен шуңа:
Монастырьга ябылып, мәңге кысыр калып,
Салкын айга карап, мөнәҗәтләр җырлап,
Моңаеп гомер итә алырсыңмы?
Җирдә яшәп, кызлык юлын үтү кирәк.
Йолаларга буйсынган кыз бәхетлерәк.
Юкса гыйффәт агачында япа-ялгыз
Чәчәк атып, яшәп, аннан үлеп китү
Бәхетмени?

Гермия

Хокукымны анның кулына тапшырганчы,
Япа-ялгыз яшәп, тизрәк үлүем артык.
Минем күңелем анның ләгънәт арбасына
Җигелергә теләми һич!

Тезей

Уйла, сылуым!
Яңа ай туган көнгә җавап әзер булсын.
Хәл ит шуны:
Әтиеңә буйсынмыйча үләсеңме,
Ул сайлаган егетне күп күрәсеңме?
Әллә, мәңге иргә чыкмый, япа-ялгыз
Монастырьга ябылып гомер сөрәсеңме?

Деметрий

Карышма, Гермия! Ә син, Лизандр,
Миңа тиеш нигъмәткә нәфсең сузма.

Лизандр

Деметрий,
Атасы сине шулай сөя икән,
Үзең өйлән аңа,
Кызны миңа бир син.

Эгей

Аһ, әдәпсез! Әйе, аны яратам мин,
Милкемне аңа бирәм барысын да.
Кыз минеке — кызга булган хокукымны
Тулысынча Деметрийгә тапшырам мин.

Лизандр

Хөкемдарым, нәселем дә затсыз түгел,
Байлыгым да аныкыннан һич ким түгел,
Кызны исә Деметрийдән ныграк сөям...
Дәрәҗәм дә һич тә аннан түбән түгел, түгел.
Дөресрәге, мин аңардан өстенрәк,
Иң мөһиме — кыз үзе дә мине сөя.
Нигә миңа хокукымнан баш тартырга?
Ә Деметрий — менә йөзенә карап әйтәм —
Еленага, Недар кызына гашыйк иде.
Җилкендерде кызны. Елена бичара
Шушы җилкуарны өзелеп сөя,
Буш куыкны Алла итеп күрә.

Тезей

Дөресен әйтәм, ишеткән идем мин дә,
Анның белән сөйләшмәкче идем хәтта;
Ләкин мөһим эшләр белән мавыгып китеп
Онытканмын. Деметрий, әйдә миңа,
Син дә, Эгей! Әйдәгез икегез дә,
Сөйләшергә сүз табылыр анда безгә.
Син, Гермия, хыялыңны әтиеңнең
Теләгенә буйсындыру юлын кара.
Юкса әлеге йоланы кулланыр ул
(Без үзгәртә алмыйбыз ич ул йоланы):
Үлем яки иргә чыкмый ялгыз яшәү.
Йә, Ипполита... Ни дисең, сылукаем?
Киттек... Эгей, Деметрий, киттек әйдә!
Минем сезгә йомышым бар, тантанага
Аны-моны әзерләргә кирәк булыр.

Шунда сезнең йомышны да тикшерербез.

Эгей

Бурычыбызны үтәргә без һәрвакыт шат.

Тезей, Ипполита, Эгей, Деметрий һәм сарай хадимнәре чыгып китәләр.

Лизандр

Йә, сылуым? Синең тәмам төсең киткән!
Шул арада кинәт кенә гөлең шиңгән!

Гермия

Яңгыр юкка түгел микән? Бу давылда
Минем күзләр дымланырга тиеш иде.

Лизандр

Аһ, сөеклем! Әлегәчә ишеткән юк,
Укыган юк, — тарихта да, әкияттә дә
Чын мәхәббәт юлы такыр булганлыгын.
Нәселләрнең тиң булмавы дисеңме...

Гермия
Аһ,
Түбән катлам өстеннәргә әсир булсын!..

Лизандр
Яшь ягыннан аерма...

Гермия
Аһ, мәсхәрә!
Яшь кәләшкә — бәлтерәгән, картайган ир!

Лизандр

Яки дуслар, кардәшләр сайлаган кыз...

Гермия

Кеше сайлаганны ничек сөймәк кирәк?

Лизандр

Сайлау һәркемгә хуш килсә, сугыш чыга
Яки үлем яный һәрчак мәхәббәткә.
Һәм ул бик тиз сүнеп куя эһ дигәнче,
Караңгыда елкылдаган яшен кебек.

Гермия

Инде язмыш шундый икән, гашыйкларга
Газап, михнәт, җәфа чигү тиеш икән,
Сынауларга бирешмик без, сабыр булыйк.
Ул җәфалар гашыйк өчен гадәти йөк,
Һич артыннан калмый, аны озатып бара.
Хыял, әрнү, күз яшьләре, татлы уйлар —
Мәхәббәтнең бичара юлдашлары!

Лизандр

Сүзең дөрес... Йә, Гермия, тыңла мине:
Бер апам бар минем. Үзе тол хатын ул,
Байлыгы зур, ялгыз, бала-чагасы юк,
Өе моннан җиде генә чакрым.
Ярата ул мине, үз улыдай күрә.
Әнә шунда барып никах укытырбыз.
Афинаның шәфкатьсез йолалары
Анда безгә кагыла алмас.
Сөюең хак булса әгәр, иртәгә кич

Өегездән чыгып кит шыпырт кына.
Афинадан өч чакрым ераклыкта
Бер урман бар, хәтерлисеңдер, бервакыт
Елена белән икегезне очраттым ич,
Шунда көтеп торырмын мин.

Гермия
Аһ, Лизандр!
Ант итәм Купидонның угы белән,
Иртәгә кич шул урманда булырмын мин.

Елена керә.

Лизандр

Сүзеңдә тор... Чү, кара әле, Елена бит!

Гермия

Сәлам! Кая киттең болай, гүзәл дустым?

Елена

Минме гүзәл? Куйчы, зинһар, көлмәсәнә.
Гүзәллегең белән син ул Деметрийне
Әсир иттең. Бәхетле син! Аның өчен
Синең күзләр йолдызлардан да нурлырак,
Тавышың тургай моңыннан да ягымлырак...
Матурлык йогышлы чир булса иде,
Шул чирне мин үземә йоктыралсам иде,
Үземә күчералсам иде
Күзләреңнең нурлылыгын,
Тавышыңның моңлылыгын...
Әгәр бөтен дөнья минем кулда булса,
Үземә тик Деметрийне алыр идем,
Калганын барысын сиңа бирер идем!
Өйрәт мине,
Деметрийнең күңелен ничек аулый алдың,
Бу бәхеткә ирешү өчен ни кулландың?

Гермия

Мин каш җыерам — ул ныграк сөя мине.

Елена

Минем елмаюларымда шундый кодрәт булса иде!

Гермия

Әрлим үзен — гыйшкы һаман дөрли генә.

Елена

Аһ, мин ялынып кайтаралса идем үземә!

Гермия

Ачулансам — җылына гына безнең ара.

Елена

Мин ягымлы булган саен, ул тик тупаслана бара.

Гермия

Мин гаепле түгел аның шашуына.

Елена

Матурлыгың!.. Аһ, мин ирешә алсам шуңа!

Гермия

Борчылма: без бүтән очрашмабыз инде,
Бөтенләйгә ташлап китәбез бу илне.
Борынга гыйшык исе кермәс борын,
Афина җәннәт иде киң галәмдә.
Менә хәзер, хисләремне чикләгәндә,
Җәннәтем әверелде җәһәннәмгә.

Лизандр

Елена дус, серне ачыйм инде сиңа:
Бу соңгы көн, иртәгә без таң алдыннан
Китәчәкбез чыгып шәһәр капкасыннан.

Гермия

Хәтерлисеңдер, еш кына без урманда,
Гөл-чәчәкләр арасында
Икәү генә серләшә идек,
Яшьлек хыялларыбызны бүлешә идек.
Лизандр иртәгә шунда
Мине көтеп тора, әзерләнеп юлга.
Без китәбез шәһәрдән таң сызылуга.
Хуш, исән бул, сабый чактан
Бергә уйнап үскән дустым!
Ак бәхетләр телә безгә,
Деметрий белән килешергә
Язсын сезгә. —
Сүз бер булсын, Лизандр, тот хәтереңдә,
Күз йоммыйбыз бүген төнлә.

Лизандр

Булды, вәгъдә, сылукаем...

Гермия китә.

Хуш, Елена!
Деметрийнең мәхәббәте кайтсын сиңа.

Китә.

Елена

Нинди бәхетле ул! Ләкин
Шунсын да әйтим:
Матурлыгым белән бит мин
Аңарга тиң...
Тик Деметрий илтифатсыз, белмим нигә,
Һәркем күргәнне күрергә теләми дә.
Акылын җуеп, Гермиягә ул мөкиббән,
Мин дивана шашып сөям аны күптән.
Мәхәббәт ул түбәнлекне дә кичерә,
Кимчелекне батырлыкка әйләндерә.
Күзе күрми аның, күрә күңле генә,
Мәхәббәтне сукыр, диләр шуңа күрә.
Канатлы ул, әмма күзсез,
Үтә җитез,
Кабалана
Ул гөнаһсыз сабый бала,
Шуңа күрә гел алдана.
Малайлар бит уйнаганда
Ант итә гел,
Моның өчен дә алдашу берни түгел.
Деметрий дә, Гермияне күрмәгәндә,
«Сөям!» диеп минем алда ант итте гел;

Гермиянең күзендәге нурны күреп,
Онытты ул изге антын, китте эреп,
Әйтим барып, Гермия кача, диеп.
Мөгаен, ул бүген таңда
Барып чыга шул урманга.
Шундый кыйбат түләү хакына
Рәхмәт ишетә алсам әгәр,
Юаныч булыр миңа берникадәр:
Урманга барырбыз бергә,
Аннан өйгә!

Китә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Афина. Балта остасы өендә бер бүлмә.
Бүрәнә, Кәтүк, Боргы, Йончыган, Танау, Пычкы керәләр.

Бүрәнә. Барыбыз да җыйналдык шикелле?

Кәтүк. Ә син тикшереп чык, исемлек буенча.

Бүрәнә. Менә исемлек. Герцог белән бикәнең никахлашу бәйрәмендә интермедиябезгә катнашырга яраклы дип табылган кешеләр.

Кәтүк. Иң элек, хөрмәтле Питер Бүрәнә, син безгә шуны әйт: бу ин... ин... интемутта нәрсә күрсәтелә? Шуннан катнашучыларның исемнәрен кычкыр. Шулай итсәң, эшнең асылына тиз барып җитәрбез.

Бүрәнә. Дөрес! Безнең пьеса — бик кызганыч комедия. «Пирам белән Фисбаның үтә дәһшәтле үлеме».

Кәтүк. Бик әйбәт нәрсә, мин сиңа әйтим, бик күңелле. Йә, хөрмәтле Питер Бүрәнә, инде катнашучыларны әйтеп чык. Җәмәгать, сафка тезелегез!

Бүрәнә. Исемегез чыккач та җавап бирегез. Ника Кәтүк! Тукучы!

Кәтүк. Монда. Нинди роль икәнен әйт тә кычкыруыңны бел.

Бүрәнә. Сине, Ника Кәтүк, Пирам роленә билгеләдек.

Кәтүк. Кем соң ул Пирам? Сөяркәме, әллә тиранмы?

Бүрәнә. Сөяркә. Мәхәббәт аркасында бик әйбәт итеп үзен-үзе үтерә.

Кәтүк. Әһә! Алайса, моны тиешенчә уйнаганда, күз яше түгелергә тиеш. Бу рольгә мин алынам икән инде, тамашачылар яулыклар әзерләп килсеннәр. Кыямәт куптарырмын мин, өзгәләнгән булырмын... Дәвам ит!.. Шулай да минем чын талантым тиран ролендә шәбрәк күренер иде. Еркулисны яки башка шундыйрак рольне менә дигән итеп уйнар идем: җир чәйнәү дисеңме, вату-җимерү дисеңме...

Каты үкерде,
Орды да бәрде —
Ватты-җимерде
Төрмә йозагын.

Фиб, күктән торып,
Ләгънәт дәрьясын
Җибәрде борып!
Ни кирәк тагы?

Йә, ничек? Шәпме? Ә?.. Әйдә, башкаларны кычкыр! Менә бу, ичмасам, Еркулисча, тиранча була. Сөяркә роле елак була бит ул.

Бүрәнә. Френсис Боргы! Өргечләр төзәтүче!

Боргы. Мин монда, Питер Бүрәнә!

Бүрәнә. Син Фисба ролен аласың.

Боргы. Кем соң ул Фисба? Ил гизүче рыцарьмы?

Бүрәнә. Юк, кыз кеше ул, Пирам аңа гашыйк була.

Боргы. Юк! Ялынып сорыйм, хатын-кыз булып уйнарга көчләмәгез. Сакалым бар ич минем.

Бүрәнә. Зарар юк, битлек киеп уйнарсың, нечкә тавыш белән чыелдарсың.

Кәтүк. И! Битлек белән уйнарга булса — бирегез, Фисбаны да үзем уйныйм. Мин коточкыч нечкә тавыш белән сөйли алам: «Синеке, синеке... Аһ, Пирам, кадерле сөяркәм! Мин синең кадерле Фисбаң, кадерле сөяркәң!..»

Бүрәнә. Юк, юк. Син Пирамны уйнарга тиеш. Ә син, Боргы, Фисбаны.

Кәтүк. Йә, килештек. Дәвам ит әйдә!

Бүрәнә. Робин Йончыган, тегүче!

Йончыган. Мин монда, Питер Бүрәнә.

Бүрәнә. Йончыган, син Фисбаның әнисен уйнарсың. Томас Танау! Бакырчы!

Танау. Мин монда, Питер Бүрәнә.

Бүрәнә. Син Пирамның әтисе буласың. Мин Фисба әтисен уйныйм. Пычкы, өстәлләр ясаучы. Сиңа Арыслан роле. Менә булды. Рольләр дөрес бүленде шикелле.

Пычкы. Арыслан роле күчерелгәнме? Сез аны хәзер үк бирегез, юкса мин бик авыр ятлыйм — хәтерем начар.

Бүрәнә. Монда ятлап торасы юк, болай да уйныйсың син аны. Монда бит үкерергә генә.

Кәтүк. Бирегез, Арысланны да үзем уйныйм. Шундый итеп үкерермен, рәхәтләнеп тыңларсыз. Шундый үкерермен, герцог үзе кабатлавымны сорар: «Йә әле, тагын үкерсен әле, тагын үкерсен», — дияр.

Бүрәнә. Син коточарлык итеп үкерсәң, бикәне, ханымнарны куркытасың. Алар җәнҗал куптара. Һәммәбезне дә дарга астыру өчен шул җитә кала.

Барысы да. Әйе, әйе, барыбызны да асып үтерерләр.

Кәтүк. Бәхәсләшмим, дуслар. Бикәләрнең, ханымнарның котларын алсак, безнең муеннарга бау салудан да акыллы эш булмас. Ләкин мин тавышны шундый үзгәртермен, йомшак кына итеп үкерермен мин, күгәрчен баласы кебек, сандугач сыман!

Бүрәнә. Сиңа Пирамнан башка рольне уйнарга ярамый. Чөнки Пирам сөйкемле кеше, андый чибәр егетне көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмассың, тәрбияле, әдәпле, нәфис хәрәкәтле, нәкъ синең кебек, суйган да каплаган. Сиңа шул гаҗәеп гүзәл Пирамны гына уйнарга кирәк.

Кәтүк. Ярый, риза. Бирегез рольне. Нинди сакал белән уйныйм икән мин аны?

Бүрәнә. Теләсәң нинди белән.

Кәтүк. Мин аны салам төсле яки ялкын сыман җирән сакал белән уйныйм. Йә булмаса кып-кызыл сакал куям. Әллә француз акчасы шикелле сары сакал белән уйнаргамы?

Багана. Француз акчасына охшар өчен башыңдагы чәчләрең, барлык төкләрең коелып бетәргә тиеш. Ул чагында шәп-шәрә ияк белән, сакалсыз уйнарга туры килер... Ягез, җәмәгать. Менә рольләрегез. Сорыйм сездән, үтенәм, ялынам — иртәгә кичкә кадәр әйбәтләп ятлагыз. Кич белән сарай урманына килерсез. Шәһәрдән бер генә чакрым. Анда ай яктысында репетиция ясарбыз. Чөнки шәһәрдә уйналудан мәгънә юк, хәбәр бөтен шәһәргә таралыр. Хәзер мин пьесага кирәкле әйберләрнең исемлеген төзим. Үтенеп сорыйм, мине уңайсыз хәлгә куймагыз.

Кәтүк. Килербез. Репетицияне анда һич тартынмыйча, иркенләп ясарга мөмкин булыр. Тырышыгыз инде, йөзгә оят килерлек булмасын. Хәзергә сау булыгыз!

Бүрәнә. Герцог имәне төбендә очрашабыз.

Кәтүк. Яхшы. Үлсәгез дә, калсагыз да шул урында булыгыз.

Китәләр.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Афина янындагы урман.
Фея белән Пэк икесе ике яктан керәләр.

Пэк

Ә, исәнме, Фея! Кая юл тотасың?

Фея

Таулар, яланнар аша,
Камышлыклар аркылы
Мин очамын анда-монда,
Сулар, утлар аркылы,
Ай нурын үтеп китәм.

Бикәгә хезмәт итәм.
Үләннәр, гөлләр өстенә
Чык суы сибеп үтәм.
Күр, ничек җем-җем итә
Саф алтындай,
Ут — ялкындай,
Яшел чирәм өсләре,
Аңкый чәчәк исләре!
Җем-җем чык тамчыларын җыясым бар,
Сәйлән итеп тезәсем бар.
Йә, хуш, егет, сау булып тор! Эш күп анда.
Эльфаларның бикәсе килә монда.

Пэк

Патшаны да көтәләр ич. Аны монда
Бикә белән очратырга ярамый һич,
Ачуланган ул бикәгә, беләсең ич,
Янындагы теге малай өчен инде —
Һинд патшасы улы өчен. Безнең бикә
Мавыга бит шуның белән, исе китә.
Ә Оберон — көнче, аны үз янына,
Сакчылары сафына алырга итә,
Әмма бикә малайны бирми аңа.
Менә шуңа күрә алар
Су буенда йә болында очрашсалар,
Шул минуттук пыр тузышып талашалар.
Яннарындагы эльфларның котлары оча,
Җәһәт кенә кайсы кая кереп поса.

Фея

Син бит... әгәр ялгышмасам,
Холкың, фигылең, кыяфәтең...
Хуш күңелле, үтә шаян Робин бит син?
Кич утыручы кыз-кыркынны куркытасың,
Тегермән ташларын тотып туктатасың,
Май атлаучы кызларны кытыклыйсың,
Сөт өстеннән каймакны да син урлыйсың.
Адаштырасың да төнге юлчыларны,
Артларыннан карап, үртәп, хихылдыйсың.
«Дускай» диеп эндәшкәнне үз күрәсең,
Андыйларның өенә бәхет китерәсең.
Син — Пэк?

Пэк

Әйе, хуш күңелле Робин булам.
Шаян рух мин, кызык эзлим, мутлык кылам,
Падишабыз Оберонны да көлдерәм.
Айгыр күрсәм, бия булып кешнәп куям.
Яки, пешкән алма булып, мыштым гына
Түтәйнең кәсәсенә кереп утырам,
Ул эчәргә җыенгач та сикереп торам,
Түтәйнең авызына башны тыгам,
Изүенә кәсәдәге чәйне түгәм;
Кинәт шунда
Өч аяклы урындыкка әвереләм.
Егыла түтәй урындыкка утыру белән,
Ютәлли, ыңгыраша, төкеренә.
Көтелмәгән бу мәзәктән бар да көлә...
Йә, Фея, тиз ычкын! Әнә патша килә.

Фея

Анда — бикә. Бик уңайсыз чакта килә.

Бер яктан үзенең иярченнәре белән Оберон, икенче яктан шулай ук иярченнәре белән Титания керә.

Оберон

Хәерлегә була күрсен, айлы төндә
Тәкәббер Титанияне очратам.

Титания

Синме бу, көнче Оберон? Әй, эльфлар,
Киттек моннан! Җенем сөйми кыяфәтен
Һәм түшәген.

Оберон

Чү, әдәпсез! Ир түгелмени мин сиңа?!

Титания

Әйе, сиңа хатын булдым. Тик мин беләм,
Яшь көтүче Корин булып, сорнай уйнап,
Филладага гыйшык җыры җырлау өчен
Феялар иленнән син качып киттең.
Нигә ерак Һиндстаннан монда килдең?
Сөяркәңне, итекле амазонкаңны
Бүген Тезей хатын итеп алгангамы?
Чын күңелдән сәгадәт, бәхет теләп,
Аларның түшәген котларгамы?

Оберон

Оял, оял, Титания! Ипполитага
Дус булганым өчен мине битәрлисең?
Тезеяны сөюеңне беләм ич мин,
Йолдызлар җемелдәгән төндә аны
Бичара Перигенаның куеныннан
Көчләп алып китүче син түгелме?
Ариадна, Антиопа Эгмеядан
Аерылырга мәҗбүр иткән син түгелме?

Титания

Бу сүзләрең барысы да көнчелектән.
Быел безгә урман, кырда, үзәнлектә,
Шаулы елга буендагы болынлыкта,
Чишмә буе, чияле тау итәгендә
Яки диңгез ярындагы ком өстендә
Җырлап-биеп әйлән-бәйлән уйнау кайда!
Акырып-бакырып уенны гел бозасың син.
Ахры, юкка исәбез, дип, җилләре дә
Диңгездән куе томан күтәрделәр,
Елгалар ташып чыкты ярларыннан,
Үгезләр җир сөрә юкка, файдасызга,
Игеннәр үсеп җитмәс борын чери;
Көтүлекләр су астында, мал кырылды,
Каргалар үләксә ашап симерделәр...
Тугайларда сукмаклар — эзләр бетте,
Куе үлән каплады һәммәсен дә.
Кешеләр көтә тизрәк кыш килүен,
Кичке җырлар бөтенләйгә тынып калды...
Диңгез хөкемдары — айның ачуыннан
Төсе качкан, һаваны дымландыра,

Буын сызлау авырулары һаман арта,
Шуңа елның фасыллары буталдылар:
Чәчкә атып утырган кызыл гөлне
Ак чәчле кыш билгесе — бәс каплады,
Кыш бабайның бозлы башын
Кызыл гөлдән үрелгән таҗ бизәде.
Мәһабәт көз, ачулы кыш, яз белән җәй
Киемнәрен алмашалар.
Аптырап хәйран калган дөнья хәзер
Фасылларны бер-береннән аера алмый.
Бу бәлаләр без үзара талашканга.
Сәбәпче — без.

Оберон

Бар да синең ихтыярда. Әйт, ни өчен
Титания Оберонны интектерә?
Синнән бары малайны гына сорыйм ласа.

Титания

Юкка башың авырттырма,
Тылсымлы илеңә дә алмаштырмыйм.
Әнисе аның минем өчен изге иде.
Без еш кына аның белән
Һиндстанның хуш исле төннәрендә,
Диңгез ярындагы алтын комга утырып,
Корабларны күзәтә идек. Җилкәннәрнең
Шаян җилдән буазланып күперүеннән
Рәхәтләнеп көлә идек. Ул шаярып
Киерелгән җилкән булып атлап китә
(Ул чак әлеге малайга авырлы иде),
Шуннан борылып, кыйммәтле мал төяп кайткан
Кораб булып миңа таба килә иде.
Күп тә үтми, шул малайны тудырганда
Үлеп китте, мескенкәем. Малайны мин
Аның төсе итеп тотам үз янымда.
Бирмим сиңа, сорап башың авырттырма.

Оберон

Озак торасыңмы монда син, урманда?

Титания

Тезей туен үткәргәнче. Безнең белән
Тату булып, җырлап-биеп айлы төндә
Күңел ачыйм дисәң инде, ихтыярың,
Булмый икән, бар, кит хәзер. Мин дә китәм.

Оберон

Бир малайны, мин дә синең белән китәм.

Титания

Илеңә дә алмаштырмыйм. Әй, эльфлар,
Төнге рухлар, киттек әйдә. Китми калсам,
Бозылышабыз бөтенләйгә.

Титания иярченнәре белән китә.

Оберон
Юк! Китмисең,
Хурлаганың өчен үчемне алмыйча
Җибәрмим мин. Сөекле Пэк, килче бире!
Исеңдәдер, дельфин сыртына атланып,
Җырлап килгән серенаны тыңладым мин!
Шундый моңлы, нәфис иде аның җыры,

Шашкын океан тәэсирләнеп тынып калды,
Йолдызлар да шунда, җиргә якынаеп,
Гаҗәеп җырны йотылып тыңладылар.

Пэк

Хәтерлим.

Оберон

Нәкъ шул чакта җир белән ай арасында
Коралланган Купидонны күреп калдым.
Көнбатышта хөкем сөргән Весталкага
Төзәп атып җибәрде ул алтын укны,
Мең йөрәкне тишә алырлык бер көч белән.
Әмма ләкин ялкынлы ук кинәт сүнде,
Айның дымлы һавасыннан сүрелде ул.
Ә Весталка тыныч кына китеп барды,
Йөрәгенә гыйшык уты кабынмады.
Ә мин шунда күреп калдым алтын укның
Сөт шикелле ак чәчәккә төшкәнлеген.
Чәчәк гыйшык ярасыннан алсуланды!
Аны «гыйшык чәчәге» дип йөретәләр.
Табып китер хәзер. Аны таныйсың син.
Әгәр дә без шул чәчәкнең суын сыгып
Йоклап яткан кешенең күзенә сөртсәк,
Уянгач, тәү күренгән җан иясенә
Гашыйк була. Табып китер шул чәчәкне.
Ләкин тиз кайт.

Пэк

Ярты сәгать эчендә мин
Җир шарын әйләнеп чыгам.

Китә.

Оберон

Чәчәк суын йоклап яткан Титания
Күзенә сибәм. Уянгач, кем күренсә дә —
Арысланмы, аю, бүре, үгезме йә
Җитез маймылмы — ул шундук гашыйк булыр.
Шул арада аның сихрен кайтарганчы
(Моның өчен бүтән үлән кулланам мин),
Малайны миңа үзе бирәчәк ул!
Кем килә бу? Зарар юк. Мин, күренмичә,
Тыңлап торыйм адәмнәрнең сөйләшкәнен.

Деметрий, аның артыннан Елена керә.

Деметрий

Яратмыйм мин сине! Кит янымнан!
Йә, Гермия кайда, кайда Лизандр?
Үтерәм мин аны, — мине кыз үтерде!
Урманга качтылар, дип әйттең ич син...
Кайда соң ул? Гермиянең эзе дә юк.
Кит янымнан! Якын килмә!

Елена

Үзеңә тарттың мине, магнит мәрхәмәтсез,
Тимер булмасам да, тарттың йөрәгемне,
Сөйгәнемә тугры булган йөрәгемне.
Тарту көчең бетсен — мин һич якын килмәм.

Деметрий

Синең янда бөтреләмме?.. Иркәлимме?

Мин ачыктан-ачык сиңа әйтеп киләм:
Яратмыйм мин сине, мәңге яратмам да.

Елена

Менә шуңа күрә сине яратам да.
Синең этең бит мин, әйдә, кыйна мине —
Җавап итеп фәкать койрык болгармын мин.
Этең итеп сана мине, сук, типкәлә,
Ташла, оныт; тик рөхсәт ит миңа, зинһар,
Лаексызга үз артыңнан иярергә.

Деметрий

Ярсытма, дим, сабырлыгым бетеп бара.
Сине күрсәм авырыйм, саруым кайный башлый.

Елена

Ә мин авырыйм, сине күрми торсам әгәр.

Деметрий

Ташлап китеп туып үскән шәһәреңне,
Дошманыңа тапшырып син үз-үзеңне,
Коточкыч зур тәвәккәллек кыласың ич.
Шомлы төндә, аулак урман эчләрендә
Гыйффәтеңне җуюдан курыкмыйсыңмы?

Елена

Нигә куркыйм? Саклый мине синең намусың,
Төнне көнгә әйләндерә нурлы йөзең.
Шомланмыйм мин бу урманда, син бар монда,
Минем өчен бит син монда — бөтен дөнья.
Бөтен дөнья йөземә карап торган чакта,
Мин ялгыз дип буламы соң?

Деметрий

Ә мин китәм, кара урманга кереп качам,
Калдырып сине ерткыч җәнлекләргә.

Елена

Аһ! Иң усал ерткыч җәнлек рәхимлерәк.
Ярый, бар, кит. Әкиятләрне үзгәртербез:
Аполлон куркып качар, Дафна куар,
Болан өереп куып йөртер юлбарысны,
Күгәрчен — карчыганы. Нишлисең бит,
Батырлар куркаклардан кача икән...

Деметрий

Җитте, артык тыңлый алмыйм! Җибәр! —
Әгәр минем арттан бара торган булсаң,
Белеп тор: урманда сине җәберлим мин.

Елена

Аһ, син мине җәберлисең һәр урында:
Чиркәүдә дә, шәһәрдә дә, яланда да.
Оял! Мине хурлап, барлык хатын-кызны
Хурлыйсың син, мыскыллыйсың.
Без түгел, сез ялынырга тиеш безгә.
Юк, мин калмыйм. Сөйгән кулдан үлү — бәхет.

Деметрий белән Елена китәләр.

Оберон

Хәерле юл сиңа, кызый! Бүгеннән соң
Син түгел, ул синең арттан йөгерәчәк.

Пэк күренә.

Сәлам сиңа, сәяхәтче. Йә, таптыңмы?
Чәчәкне, дим.

Пэк

Таптым. Менә.

Оберон

О, бир тизрәк!
Тау буенда куе үлән үсә күкрәп,
Чәчәкләрдән хуш ис аңкый тирә-якта;
Шул тирәдә, үзәндәге куаклыкта,
Үрмә гөлләр бер-беренә сарылышудан
Гаҗәп аулак табигый бер чатыр булган.
Әйлән-бәйлән уйнап арыгач, шунда кереп
Ятып йоклый бикә изелеп, тәмам эреп.
Шунда кереп күзенә сөртәм, бер саташсын,
Гашыйк булып берәрсенә тәмам шашсын.
Беразын ал: бездән ерак түгел шунда
Бер кыз йөри адашып кара урманда,
Бик тәкәббер бер егеткә гашыйк булган.
Тәкәбберңең күзенә сөрт мул иттереп.
Күзен ачып җибәрүгә, кызны күреп
Гашыйк булсын, онытып бар дөньясын.
Бар, эзләп тап шул егетне. Тик абай бул,
Шәһәр егете — Афина киеменнән ул.
Тиз бул. Әтәч кычкырганчы кайтып җит, дим.

Пэк

Хөкемдарым, борчылма,
Барын да эшлим.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урманның икенче өлеше.
Иярченнәрен ияртеп Титания керә.

Титания

Түгәрәккә тезелеп бераз җырлагыз да
Өч минутка бу тирәдән югалыгыз.
Тазартыгыз корттан кызыл чәчәкләрне,
Ярканатлар тотыгыз — эльфларга
Ябынчалар тегәрләр шул ярылардан.
Ябалакларны куыгыз тирә-яктан —
Төн буе ухылдыйлар безгә карап.
Тирбәтегез мине бераз, аннан — эшкә.

I эльф
*(җырлый)*

Аеры телле җиз еланнар,
Чәнечкеле керпеләр,
Китегез бикә янынnan,
Суалчаннар, кәлтәләр.

Хор

Моңлы кошчык сандугач,
Бикәбезнең күңлен ач!

Бәлли-бәлли, бәлли бәү,
Бәлли-бәлли, бәлли бәү!

Шомлы уйлар килмәгез,
Йокысын бүлдермәгез.
Йокла, бикә, бәлли бәү,
Бәлли-бәлли, бәлли бәү!

I эльф

Озын аяк үрмәкүч,
Бу тирәгә килмә һич!
Әкәм-төкәм, кит ерак,
Очма, коңгыз, бызылдап!

Хор

Моңлы кошчык сандугач,
Бикәбезнең күңлен ач!
Бәлли-бәлли, бәлли бәү,
Бәлли-бәлли, бәлли бәү.

Шомлы уйлар, килмәгез,
Йокысын бүлдермәгез.
Йокла, бикә, бәлли бәү,
Бәлли-бәлли, бәлли бәү!

II эльф

Тирә-як тын. Киттек юлга,
Беребез калсын каравылга.

Эльфлар югала. Титания йоклап китә. Оберон керә.

Оберон
*(Титаниянең күзенә чәчәк суын сыга)*

Уянып күзең ачуга
Нинди җәнлек күрсәң, шуңа
Гыйбадәт кыл, табын син,
Күңелеңә ут кабынсын!
Аю, бүре, юлбарысмы,
Ата мәчеме, дуңгызмы,
Чын күңелдән сөй аны,
Онытып бар дөньяны.

Китә.
Лизандр белән Гермия керәләр.

Лизандр

Бәгырькәем, йөри-йөри арыдың бит син.
Дөресен әйтим, юлдан читкә тайпылдым мин.
Әллә ятып торасыңмы таң атканчы?

Гермия

Ярый, була. Җайлы урын тап үзеңә,
Ә мин менә монда ятам, мүк өстенә.

Лизандр

Мин дә ятыйм шунда бергә синең янга,
Җаныбыз бер — түшәгебез дә бер булсын.

Гермия

Юк, юк, Лизандр, мин сине яратам, тик
Читкәрәк ят, зинһар өчен, ялынып сорыйм.

Лизандр

Бу сүземне, зинһар, ялгыш аңлый күрмә,
Моны аңларга мәхәббәтең ярдәм итәр.
Мин шуны әйтәм: мәхәббәт, дим, гаҗәп бит ул —
Ике йөрәкне бер итә.
Антлар белән беркетелгән ике йөрәк
Кыяматкә кадәр тугры бер-беренә.
Кирәк түгел аерым түшәк, ышан миңа,
Бәгырькәем, мин хыянәт итмәм сиңа.

Гермия

Телең үткер, сүзне оста сайлыйсың син.
Әгәр сине ялганчы дип гаепләсәм,
Мин үземне мыскыллаган булыр идем.
Шулай да син, мине сөйсәң, ят читкәрәк;
Беләсең ич, егет белән кыз кешегә
Ул кадәре якынаерга кушмый әдәп.
Тыныч йокы, бәгырькәем, хәерле төн,
Кабергәчә сүрелмәсен мәхәббәтең.

Лизандр

Амин, амин — үзем дә мин шуны телим,
Хыянәт итсәм сиңа, шундук үлим!
Менә монда ятам мин. Хуш, хәерле төн!

Гермия

Сиңа да мин шуны телим.

Икесе дә йокыга китәләр. Пэк керә.

Пэк

Айкадым бар урманын,
Кайда гына булмадым,
Чәчәк суын сынарга
Беркемне табалмадым.
Төн... Тирә-як шундый тын...
Шылт та юк... Чү! Анда кем?
Шул үзе! Бу шул егет,
Киеме дә шул кебек.
Кызы да киткән оеп,
Мүк мендәргә баш куеп.
Аһ, мескен! Шундый гүзәл...
Күрәсең, бик арыгандыр,
Тәкәббернең янына
Ятарга кыймагандыр.
Аһ, тәкәббер, туң йөрәк!
Сабыр ит, хәзер менә
Бу сихерле тамчыны
Тамызам керфегеңә.
Тәкәббернең йөрәгендә
Гыйшык уты дөрләсен,
Дөрләсен, сүрелмәсен.
Уяныр вакыт җитә...
Киттем — Оберон көтә!

Китә.
Деметрий белән Елена керәләр.

Елена

Аһ, сабыр ит! Үтер мине! Үтер!

Деметрий

Югал тизрәк күз алдымнан! Кит, дим!

Елена

Мине ташлап китәсеңме? Ялгызымны!..

Деметрий

Калдыр мине, юкса... Җибәр! Җибәр! Кит, дим!

Китә.

Елена

Аһ, арыдым! Эштән чыктым, бетте хәлем.
Тик ярсыта аны кайнар ялынуларым.
Аһ, Гермия, бәхетле кыз!
Күзләре йолдыз кебек балкый гелән,
Әсир итә күзләренең нуры белән.
Ул нурлар тозлы яшьтән түгелдер ич?
Бик еш елыйм шул мин, тыелалмыйм һич!
Юк, мин шыксыз, аю кебек килбәтсез мин,
Ерткычлар да куркыр миннән, шөкәтсез мин.
Деметрийнең качуы гаҗәпмени?..
Кем бу ята? Лизандр! Үтерелгәнме?
Кан күренми. Йоклыймы? Әй, Лизандр, тор!
Уян!

Лизандр
*(уяна)*

Янган утка керәм, син боерсаң,
Елена! Мин пакьлегеңне күрәм.
Кайда Деметрий? Ул хаин, намуссыз ул!
Тураклыйм мин аны шушы кылыч белән!

Елена

Юк, юк, Лизандр, андый сүз әйтә күрмә.
Сөя бирсен Гермияне, битәрләмә.
Кыз бит сине өстен күрә — куан шуңа.

Лизандр

Куанырга? Юк! Үкенәм, җаным туңа,
Күзсез булып, күпме табынып йөрдем шуңа!
Гермияне түгел, сөям Еленаны.
Чәүкә биреп былбыл алдым — бел син шуны.
Йоклап яткан акыл шулай уяна, ди.
Уянды да әйтә миңа:
Иң гүзәл кыз — Елена, ди.

Елена

Бу ни өчен мондый хурлау,
Бу мәсхәрә, бу мыскыллау?
Нигә мондый җәбер һичбер гаепсезгә?
Сөеклемнең читләтүе азмы сезгә?
Гыйшык игълан иткән булып, сөйгән булып,
Тырышасыз йөрәгемне әрнетергә.
Оялырга кирәк сезгә. Йә, хушыгыз!
Сезне мондый әдәпсез дип белми идем.

Лизандр

Гермияне күрмәде ул!.. Йокла әйдә,
Безнең юллар аерылды бөтенләйгә.
Туйдым синнән, үтләдем мин, биздем тәмам.
Әйтерсең хак юлдан язып
Гөнаһ кылдым, күңелем азып.
Күңелемне аздырган син,
Мине юлдан яздырган син.

Еленаны сөям җаным-тәнем белән!

Йөгереп чыгып китә.

Гермия
*(уяна)*

Коткар мине, Лизандрым! Кил тизрәк!
Куенымдагы еланны ал тизрәк!
Дерелди бөтен тәнем... Коточкыч төш!..
Йөрәгемне кара елан суыра, имеш!
Тыным кысыла, буылам, имеш, эшем харап!
Син елмаеп торасың читтән карап.
Лизандр!.. Юк! Киткәнме? Әй, җан дускаем!
Ишетми ул? Җавап бирче, бәгырькәем!
Мәхәббәтебез хакына! Ялынып сорыйм!
Җаным тетри, куркуымнан... Аһ, ни кылыйм?
Китәм, китәм... Эзләп табам сөйгәнемне
Яки табам әҗәлемне!

Йөгереп чыгып китә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман.
Титания йоклый.
Бүрәнә, Пычкы, Кәтүк, Боргы, Танау, Йончыган керәләр.

Кәтүк. Барыбыз да җыйналдыкмы?

Бүрәнә. Барыбыз да. Репетиция ясау өчен менә дигән урын. Бу яшел алан сәхнәбез булыр. Менә бу куаклар артына яшеренеп киенербез. Нәкъ герцог алдында уйнаган кебек төгәл итеп уйныйбыз.

Кәтүк. Питер Бүрәнә!

Бүрәнә. Ни йомыш, сөекле Кәтүк?

Кәтүк. Пирам белән Фисба турындагы әлеге комедиядә беркемгә дә ошамый торган урыннар бар. Беренчедән, Пирам үзен-үзе үтерү өчен кылычын чыгара. Бу күренешне хатын-кызларының берсе дә күтәрә алмас. Моңа ни дисең?

Танау. Аһ, чәнчелгере! Бу бик куркыныч.

Йончыган. Минемчә, ул үтерү күренешен сызарга туры килер.

Кәтүк. Һич кирәкми. Мин аның хәйләсен таптым, менә дигән булачак. Сез миңа пролог языгыз. Пролог тамашачыга ачык итеп шуны аңлатсын: безнең кылычлар беркемгә бернинди зарар китерә алмый. Пирам үзен-үзе чынлап үтерми. Инде тамашачыны моңа тәмам ышандыру өчен үзем аңлатма бирермен мин: Пирам чын Пирам түгел, Кәтүк исемле тукучы мин, диярмен. Шулай дигәч, барысы да тынычланыр.

Бүрәнә. Бик шәп, пролог яздырырбыз, уналтышар, уникешәр иҗекле шигырь белән.

Кәтүк. Дүрт иҗекне кызганмагыз инде, барысы да уналтышар иҗекле булсын.

Танау. Бикәләр арысланнан курыкмасмы соң?

Йончыган. Курыкмыймы соң, котлары алыныр.

Кәтүк. Дуслар, үзегез уйлап карагыз. Хатын-кыз каршына Арыслан чыгару... Алла сакласын! Бу бит коточкыч. Арысланнан куркыныч җәнлек юк лабаса. Җитмәсә, тере арыслан. Моны уйларга кирәк.

Танау. Икенче Пролог аның Арыслан түгеллеген аңлатсын.

Кәтүк. Юк, болай итик — ул үзенең исемен әйтеп бирсен. Шуның өстенә арыслан тиресе астыннан ярты бите күренеп торсын. Шунда әйтсен ул: «бикәләр», яки «сөекле ханымнар, сорыйм сездән», яки «үтенәм сездән», йә булмаса: «Ялынып сорыйм, бикәләр, курыкмагыз, дерелдәмәгез, мин сезнең өчен җанымны бирергә әзер! Әгәр чын арыслан булсам, монда минем хәлем бик мөшкел булыр иде. Мин арыслан түгел, барлык адәм балалары шикелле үк бер кеше», — дип. Менә шунда ул үзенең исемен әйтсен: мин өстәлләр остасы. Пычкы кушаматлы кеше, дисен.

Бүрәнә. Ярый, шулай итәрбез. Тагын ике төрле читенлек бар: ничек итеп бүлмәгә ай яктысы кертергә? Беләсез ич, Пирам белән Фисба ай яктысында кавышалар.

Танау. Безнең кичәдә ай калкыр микән соң?

Кәтүк. Календарь, календарь! Карагыз альманахны. Айны табыгыз, айны!

Бүрәнә. Әйе, ул көнне ай калкырга тиеш.

Кәтүк. Бик әйбәт, без уйный торган бүлмәнең тәрәзәсен киңрәк итеп ачарбыз да ай күренеп торыр.

Бүрәнә. Әйе шул, аны болай да эшләп була: беребез кулына фонарь тотып керә дә «мин ай яктысы булам» дип белдерә, бик шәп була бу! Тагын бер читенлек — стена кирәк була безгә, чөнки безнең әсәрдә Пирам белән Фисба стена ярыгы аша сөйләшәләр.

Танау. Бүлмәгә стена алып кереп булмый бит инде. Синеңчә ничек, Кәтүк?

Кәтүк. Тагын беребезгә стена булып уйнарга туры килә. Без аны балчык яки цемент белән сылыйбыз да стена була. Бармакларын менә болай тырпайта — стена ярыгы була. Пирам белән Фисба шуның аша сөйләшәләр.

Бүрәнә. Болай булгач, безнең эшләр һәрьяктан җайлана. Инде утырышыгыз, рольләрегезне укыгыз. Пирам, син башлыйсың, сүзең беткәч, куаклар артына китәсең. Һәркайсыгыз үз ролегез буенча кирәкле урында шунда китәрсез.

Аларның артында Пэк күренә.

Пэк

Нинди ирләр шаулый анда,
Безнең бикә йоклаганда?..
Репетиция барамыни?
Алайса, мин тамашачы,
Бик кирәксә, артист булам.

Бүрәнә

Башла, Пирам, ә син, Фисба, әзерләнеп тор.

Кәтүк

«Аһ, Фисба, нәкъ сасы чәчәктәй...»

Бүрәнә

«Хуш исле чәчәктәй».

Кәтүк

«Хуш исле чәчәктәй
Аңкып тора сулышларың!»
Чү! Ниндидер тавыш. «Шунда торып тор син,
Бик тиз, бик тиз әйләнеп керермен мин».

Китә.

Пэк

Пирамның мондыен һич күргәнем юк.

Китә.

Боргы

Хәзер минем сүздер инде?

Бүрәнә. Әйе, синеке, тик шуны исеңдә тот, ул нинди тавыш икәнен белергә дип кенә чыгып китте, хәзер яңадан керергә тиеш.

Боргы

«Пирам, син актан да аграк,
Алсудан да алсурак,
Батырлардан батыррак,
Сөйкемлеләрдән сөйкемлерәк,
Ышанычлы аргамактан
Мең мәртәбә ышанычлырак...
Изге Нин зиратында
Синең белән кавышабыз...»

Бүрәнә. «Изге Нин кабере янында», дускай. Тик бу сүзләр соңыннан, Пирамга җавап итеп әйтелә. Ә син бөтен ролеңне берьюлы сөйләп бетерергә ашыгасың. Пирам, ни булды сиңа? Репликаны ишетмәдеңмени? Сиңа реплика: «Мең мәртәбә ышанычлырак».

Боргы

Әһә! «Ышанычлы аргамактан
Мең мәртәбә ышанычлырак».

Пэк һәм ишәк башлы Кәтүк керәләр.

Кәтүк

«Мин тик синең өчен генә
Шундый матур булыр идем...»

Бүрәнә. О! Коточкыч! Җен эше бу! Тәкбир әйтегез, дуслар, дога укыгыз! Каравыл! Качыгыз, дуслар!

Бүрәнә, Боргы, Пычкы, Танау һәм Йончыган йөгерәләр, качалар.

Пэк

Мин сезнең арттан китәм, адаштырып йөретәм;
Чытырманнар, әрәмәләр, сазлыклар аша үтәм.
Ат булам, эт булам, дөрләгән ут булам,
Яндырам мин, өтәм, куркытам, өркетәм,
Дуңгыздай мыркылдыйм, чыелдыйм, шаркылдыйм,
Кешним дә пошкырам, акырам, бакырам!

Артларыннан йөгерә.

Кәтүк. Нигә болай барысы да качалар? Мине куркыту өчен юри кыланалар.

Танау йөгереп керә.

Танау. Аһ, Кәтүк! Сине алмаштырганнар! Нәрсә ул җилкәңдә?

Кәтүк. Син нәрсә? Үз җилкәңдәге ишәк башын күрдеңме әллә?

Танау йөгереп чыгып китә. Бүрәнә йөгереп керә.

Бүрәнә. Алла сакласын үзеңне, Кәтүк! Алла сакласын! Сине ни эшләткәннәр?

Кача.

Кәтүк. Күреп торам, шаярталар. Алар мине, ишәк хәленә куеп, адәм көлкесенә калдырырга, куркытырга маташалар. Ә мин шылт та итмим. Ни генә кылансалар да һич исем китми. Тик арлы-бирле йөрим, кычкырып җырлыйм. Ишетсеннәр, күрсеннәр, мин алардан курыкмыйм. *(Җырлый.)*

«Әй кара чыпчык,
Сап-сары томшык.
Матур сайрыйсың,
Мөлаем кошчык!»

Титания
*(уяна)*

Нинди фәрештә бу мине уятучы?

Кәтүк
*(җырлый)*

«Сайрыйлар бар да,
Моңсыз кошлар да;
Кәккүк тә әнә
Һаман күкелди:
Күк-күк, күк-күк, ди,
Яшәрсең күп, ди.
Һәркемне шулай
Алдый да алдый.
Ник алдыйсың, дип,
Бер кем әйтә алмый».

Чөнки беркем дә ахмак кош белән бәхәскә керергә теләми.

Титания

Чибәр егет, җырла тагын бераз гына!
Җаным эри синең моңлы тавышыңа!
Хәйран калдым мәһабәт буй-сынына,

Чибәрлегең мине тәмам сихерләде,
Гашыйк булдым сиңа, өзелеп сөям сине!

Кәтүк. Миңа калса, ханым, моны һич кенә дә акыллы эш дип булмый. Хәер, дөресен әйтсәк, акыл белән мәхәббәт арасында татулык бик сирәк була бу заманда. Берәр әүлия гына татулаштырмаса, ул яктан эшләр хөрти. Күрәсез, җае чыкканда мин дә шаяра беләм.

Титания. Акылың да күркәм икән, килеш-килбәтең шикелле.

Кәтүк. Һич алай түгел, теге яктан да, бу яктан да салам кыстырмагыз. Бу урманнан чыгып китәрлек акылым булса, миңа шул җиткән.

Титания

Бу урманнан китәргә!.. Юк, уйлама да,
Телисеңме-юкмы — монда каласың син.
Мондагы рухларның иң көчлесе мин.
Минем илдә һәрвакыт яз. Сине сөям.
Эльфлардан сиңа хезмәтчеләр куям,
Су төбеннән энҗеләр китерерләр.
Йоклаганда җырлый-җырлый тирбәтерләр.
Адәмгә хас тупаслыгың бетәр монда.
Җиңеләерсең.
Очып йөрерсең болытлар арасында.
Килегез бире, Керәнзадә, Хушисле Борчак,
Пәрәвезкәй, Күбәләк.

Дүрт эльф керә.

Хушисле Борчак

Мин монда!

Пәрәвез

Мин дә!

Күбәләк, Керәнзадә
*(икесе бергә)*

Без дә!

Дүртесе бергә

Нинди эш кушасыз безгә?

Титания

Хезмәт итәрсез менә бу әфәндегә.
Әйләнәсендә биерсез, җыр җырларсыз.
Йөзем, инҗир, бөрлегән белән сыйларсыз.
Кыргый кортлар тәпиеннән
Балавызлар алырсыз да шәм коярсыз,
Тычкан уты җыеп шәмне кабызырсыз;
Әфәндемне йокларга яткырырсыз,
Күбәләкләр канатыннан
Җилпәзәләр ясарсыз да
Күзенә төшкән таң нурларын
Әледән-әле куып торырсыз.
Хәзер аңа баш иегез, сәламләгез!

Эльфлар

Сәлам сиңа, адәм улы, сәлам, сәлам!

Кәтүк. Чын күңелдән рәхмәт сезгә мәрхәмәтегез өчен. Исем шәрифегезне белергә мөмкин булмасмы?

Пәрәвез. Пәрәвез.

Кәтүк. Сезнең белән якыннанрак танышыр идем, сөекле Пәрәвез ханым. Бармагым киселсә, батырчылык итеп сезгә килермен инде. Сезне кем дип белик, әфәндем?

Хушисле Борчак. Хушисле Борчак.

Кәтүк. Әниегез Борчак абыстайга, әтиегез Кузак әфәндегә сәламемне күндерсәгез иде. Сезнең белән якыннан таныша алсам, бик шат булыр идем. Сезнең исем шәрифегез, әфәндем?

Керәнзадә. Керәнзадә.

Кәтүк. Керән нәселеннән икән. Хөрмәтле Керәнзадә, мин сезнең сабырлыгыгызны яхшы беләм. Үтә мәрхәмәтсез симез ит, майлы куырдак сезнең гаиләнең күпме улларын, кызларын йотып тора. Керән нәселе аркасында мин үзем дә күпме күз-яшь түктем. Якыннан танышуыма бик-бик шатмын.

Титания

Сөеклемне кертегезче ятагыма.
Ай елаган төсле күренә минем күзгә.
Ул елагач, чәчәкләр дә күз-яшь түгә.
Сафлыгын җуя кемдер бүген төнлә.
Авызын бәйләп алып керегез шым гына.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урманның икенче өлеше.
Оберон керә.

Оберон

Титания йокысыннан торды микән?
Беләсе иде, башлап кемне күрде икән,
Кемгә гашыйк булып башын җуйды икән?
Әнә илчем.

Пэк керә.

Әйтче, зинһар, шаянкаем,
Бүген нинди яңалык бар бу урманда?

Пэк

Гашыйк булды бикәбез бер килбәтсезгә.
Бикә йоклап яткан аулак аланлыктан
Тезей патша туенда уйнар өчен
Спектакль әзерләргә җыйналганнар.
Ул төркемнән Пирам ролен уйнаучы ир
Берзаман куаклыкка кереп посты.
Шунда аңа, җүләрлеген исәпкә алып,
Ишәк башы кидердем мин ипләп кенә.
Сәхнәгә чыгуы булды, иптәшләре,
Сунарчыдан куркып качкан казлар кебек,
Мылтык тавышы ишетеп очкан чәүкәләр күк,
Төрлесе төрле якка таралдылар.
Урманда шау-шу купты. Кычкыралар.
Кемнәрнедер ярдәмгә чакыралар.
«Курыкканга — куш, карасаң — буш» — дөрес мәкаль.
Кара урманда бар да шомлы, бар да серле,
Җансызлар да җанлы булып тоелалар:
Качучының кемдер бүреген алып кала
Йә җиңеннән эләктерә,
Яки тотып аягыннан,
Кинәт җиргә атып бәрә.
Ә мин, уңга, сулга борып,
Йөртәм һаман адаштырып.
Пирам исә аланлыкта торып калды.
Бикә шунда уянды да йокысыннан,
Шул ишәккә гашыйк булды.

Оберон

Мин көткәннән шәбрәк килеп чыккан.
Үтәдеңме соң икенче боерыгымны?
Теге егет күзенә су тамыздыңмы?

Пэк

Тамыздым. Бик каты йоклап ята иде,
Уянуга күрәчәк ул кызны шундук.

Деметрий белән Гермия керәләр.

Оберон

Чү! Әнә ул үзе килә!

Пэк
Кем? Аңламыйм.
Кызы шул, тик егете бүтән.

Деметрий

Сөйгәнгәме шундый каргыш ява миңа?
Ачуыңны сакла явыз дошманыңа.

Гермия

Дошманым — син, йоклап яткан Лизандрны
Үтергәнсең, аның канына баткансың син!
Үтер әйдә мине дә — чум тирәнгәрәк!
Көнгә тугры булган нурлы кояш кебек,
Миңа тугры иде бит ул!
Ай Җир шарын тишеп чыгып
Агасы ягына күчеп китә алса да,
Лизандрым йоклап яткан сөйгәнен һич
Ташлап китә алмас иде.
Әйе, аны син үтердең!
Коточкыч син, йөзең шомлы,
Кулың канлы!

Деметрий

Юк, мин — мәет, мине үтерде сөйкемле кыз,
Йөрәгемне телеп үтте ул аткан боз.
Шундый сылу, мөлаем һәм горур ул кыз,
Әйтерсең лә һавадагы Зөһрә йолдыз.

Гермия

Аһ, нигә бу төче сүзләр?
Әй сөеклем, Лизандрым,
Син кайда, кайда, күз нурым?
Кызган мине, әйт, кайда ул?

Деметрий

Аның мәетен ташлар идем мин этләргә!

Гермия

Син үзең эт! Ничек түзим мин бу хәлгә?
Димәк, аны син үтердең?
Бүгеннән ил ләгънәт укыр сиңа, ләгънәт!
Дөресен әйт, гомереңдә бер дөрес сүз әйт:
Күзләренә карарга курка идем,
Йоклап яткан чагында суйдым, диген!
Зур батырлык! Хәшәрәтләр эше бит бу,
Шулай чага астыртын тик юха елан,
Ә син еланнан да яман!

Деметрий

Ачуланасың син миңа... Ләкин юкка.
Лизандрны суйганым юк,
Миңа калса, аңа берни булганы юк.

Гермия

Алайса әйт: сәламәт ул, исән, дип әйт!

Деметрий

Әйткән өчен нинди бүләк?

Гермия

Сиңа бүләк? Кит, хәшәрәт!
Сине мәңге күрмәсә идем,
Барлыгыңны, юклыгыңны белмәсә идем!

Йөгереп чыгып китә.

Деметрий

Ул ярсыган, иярүдән мәгънә чыкмас,
Бераз сабыр итүдән дә шәбе булмас.
Ятып торыйм, бәлки, йоклап китә алырмын.

Ята, йокыга китә.

Оберон

Нишләдең син? Бөтен эшне, аһ, бозгансың,
Тамчыны син һич кирәкмәс
Кеше күзенә тамызгансың,
Саф күңелле гашыйкны син
Хыянәткә чакыргансың.

Пэк

Дөнья бит бу, шул ягын да уйласаңчы:
Бу дөньяда
Саф күңелле бер гашыйкка мең ялганчы.

Оберон

Оч тизрәк бөтен урман өчен күзләп,
Шәһәр кызы Еленаны тап син эзләп.
Гыйшык чире көйдерә аны, сулган йөзле,
Аһ-ваһлардан каны качкан, моңлы күзле.
Йоклап яткан егетне мин имләгәнче,
Җәһәт кенә кызны табып китерсәңче.

Пэк

Киттем, очтым аткан уктай.

Китә.

Оберон

Кызыл гөлем, тыңла сүзем,
Тылсымлы тамчыларыңны
Тамызсана тиз генә
Бу егетнең күзенә.
Кызны күргәч, йөрәгенә
Гыйшык уты кабынсын,
Сәҗдә кылсын — табынсын.
Сөй мине, дип ялынсын!

Пэк керә.

Пэк

Хөкемдарым, күрсәнә:
Елена килә әнә!
Бая мин ялгыш имләгән
Егет аңа ияргән,
Мөлдерәтеп күзләрен,
Сибә гыйшык сүзләрен.
Күзәтик шунда калып.
Җүләр дә соң бу халык!

Оберон
Читкәрәк кит.

Пэк

Бер кыз артыннан икәү!
Бу бит адәм көлкесе.

Лизандр белән Елена керәләр.

Лизандр

Белмим, нигә ышанмыйсың —
Мыскыллама, көлмә, дисең.
Көлгән чакта кеше күз-яшь түгәме соң?
Чын күңелдән ант итәм мин яшь аралаш,
Изге антны мыскыл диеп буламы соң?

Елена

Ай-һай оста хәйләгә син! —
Каршымда яшь аралаш ант итәсең! —
Әллә инде Гермиягә кул селтәдең?
Аңа биргән антыңны һәм бу антыңны
Үлчәүгә салып кара тиңләштереп —
Икесе дә җип-җиңел, мамык кебек.

Лизандр

Акылсыз булганмын аңа ант иткәндә.

Елена

Акылың камилләндемени
Аңа хыянәт иткәндә?

Лизандр

Деметрий бит аны сөя, сине түгел.

Деметрий
*(уяна)*
Елена! Аһ, илаһи кыз! Мөлаем йөз!
Күзләреңне нәрсәгә тиңлим икән?
Кристалл — тонык! Иреннәрең чия кебек,
Балкып тора үбешергә җилкендереп.
Кулларың шундый нәфис, шундый йомшак.
Тавр тавы башындагы кардан да ак.
Рөхсәт итче, бер үбимче!

Елена

Аһ җәһәннәм! Аһ мәсхәрә! Икәүләшеп
Мыскылларга килдегезме сүз берләшеп?
Саф күңелле чын ир булсагыз сез әгәр,
Мыскыллый алмас идегез бу кадәр.
Кайчандыр бер-берегездән көнләштегез,
Хәзер мине хурлау өчен берләштегез.
Егетлек бу! Афәрин! Сез көләсез,
Кыз кешенең күз яшьләрен түктерәсез.
Икегез дә мәрхәмәтсез, миһербансыз,
Яклаучысыз кызны үртәп,
Кызык табарга булгансыз!

Лизандр

Яхшы түгел, Деметрий, дөресен әйтим.
Гермияне сөюеңне беләһәркем.
Аңа булган хисләремнән

Баш тартам мин чын күңелдән.
Сөекле Еленаны бир син миңа,
Кабергәчә тугры булырмын мин аңа.

Елена

Ничек түзим бу хурлыкка?

Деметрий

Юк, Гермия миңа һич кирәк түгел.
Элекке кәләшемнән бизде күңел.
Гермиядә күңелем фәкать кунак иде,
Хәзер ул Еленага күчеп килде —
Бөтенләйгә.

Лизандр

Ышанма син бу сүзләргә!
Хурлама саф мәхәббәтне, тый телеңне,
Тыймасаң, алырсың кирәгеңне!
Борылып кара, күр әнә сөйгәнеңне.

Гермия керә.

Гермия

Караңгыда күз күрмәсә,
Колакларың үткенләшә,
Әйбәтрәк ишетәсең икеләтә.
Лизандр, мин күрмәсәм дә, сине күзләп,
Тавышыңнан таптым эзләп.
Нигә ташлап киттең мине карурманда?

Лизандр

Ничек китмисең мәхәббәт чакырганда?

Гермия

Нинди мәхәббәт ул сине чакыручы?

Деметрий

Йолдызлардай балкып торган нурлы күзле
Елена ул, мөлаем, күркәм йөзле.
Аңламыйсыңмыни? Синнән күңелем бизде.

Гермия

Ышанмыйм, юк, мөмкин түгел!

Елена

Ничек! Син дә алар белән бер сүздәме?
Өчәүләшеп мыскылларга керештегез?
Аһ, Гермия, мәкерле дус, икейөзле!
Шуларга ияреп син, җан дустыңны
Мәсхәрәләп, явызларча көләсеңме?
Кайчандыр без бер тугандай якын идек,
Уйларыбыз, серләребез уртак иде.
Шуларның барысы да онытылдымы?
Сабый чаклар, керсез дуслык, сабакташлык,
Бер мендәргә янәшә утырып,
Икәү бер өлгедән күчереп
Бер чәчәкне икәүләшеп чигә идек,
Тәннәребез, җаннарыбыз бергә кушылып,
Бер үк җырны әкрен генә суза идек.
Бер сабакта янәшә үскән чиялердәй,
Тәннәр аерым, җаннарыбыз бер иде ич,
Шундый изге дуслык җебен өзәсеңме? —
Шул ирләргә ияреп миннән көләсеңме? —

Бу эшең, әйт, дусларчамы, кызларчамы?
Бу хурлыкны берьялгызым татысам да,
Сиңа ләгънәт укыр барлык хатын-кызлар.

Гермия

Ярсулы сүзләреңнең мәгънәсе ни?
Мин хурламыйм, киресенчә, син хурлыйсың.

Елена

Син булмый, кем йөзләремне, күзләремне
Мактарга Лизандрны котыртучы?
Мине тибеп очырырга әзер торган
Деметриең нигә миңа изге рух ди?
Илаһи кыз, мөлаем йөз, фәрештә ди?
Җаны-тәне белән мине дошман күргән
Егет нигә шулкадәре юхалана?
Лизандр ник, өзелеп сөйгән ярын ташлап,
Миңа гыйшык игълан иткән булып йөри? —
Син котырттың аларны, син җилкендердең.
Дөрес, минем сөйкемле сөягем юк,
Кая миңа синең белән тиңләшергә!
Мондыйларны хурламыйлар, кызганалар.

Гермия

Һич аңламыйм, бу сүзләрнең мәгънәсе ни?

Елена

Шулай, шулай, кайгырган булып кылан,
Артымда мине үртәп мыскыллап көл,
Күз кысышып, уфылдашып шаярыгыз.
Бу сыйфат, әлбәттә, мактанырлык.
Күңлегездә шәфкать яки намус булса,
Хурлый алмас идегез мине болай.
Сау булыгыз! Гаепле бит монда мин дә.
Үлем яки аерылышу
Төзәтәчәк һәммәсен дә.

Лизандр

Чү, сөеклем! Сүз әйтергә ирек бирче,
Бәгырькәем, хәятым син, газизкәем!

Елена

Искиткеч!

Гермия

Мыскыллама, бәгырькәем!

Деметрий

Ялынма, мин хәзер мәҗбүр итәм аны.

Лизандр

Мәҗбүр булмам. Ялынуга да күнәсем юк.
Мин бирешмәм янауга да, ялынуга да.
Ант итәм мин җаным белән,
Еленаны өзелеп сөям.
Сөйми, диючегә сүзем:
Елена өчен җаным бирәм!

Деметрий

Ә мин сине аңардан ныграк сөям.

Лизандр

Алайса кил, исбат ит сөюеңне.

Деметрий

Әйдә киттек!

Гермия

Лизандр, бу ни дигән сүз?

Лизандр

Кит, зәнки!

Деметрий

Әйбәт, әйбәт! Ха-ха-ха-ха!
Ярсыган булып кылана, әмма үзе
Урыныннан кузгалмый. Ах куркак куян!

Лизандр

Кит, кырмавык, ябышма! Кит, азгын мәче!
Кара елан урынына селтәп ташлыйм!

Гермия

Нинди тупас сөйләшәсең! Үзгәрдең син,
Дустым...

Лизандр

Дустың? Кит, шөкәтсез! Җирәнгеч йөз!
Кит, зәһәрле, кит, әшәке!

Гермия

Шаярасың?
Елена

Әйе, синдәй шаяра ул.

Лизандр

Деметрий, мин үз сүземдә торам.

Деметрий

Имзаңны куеп миңа язу бир син,
Сүзгә генә ышанмыйм.

Лизандр

Мин кыйныйммыни,
Үтериммени аны? Юк, мин дошман күрәм,
Әмма ләкин кызганам.

Гермия

Дошманлыгың
Иң каты каһәреңнән хәтәррәк.
Мине дошман күрә! Мине! Әйт, ни өчен?
Мин Гермия, син Лизандр түгелмени?
Мин һаман да элеккечә матур, сылу,
Шушы төндә генә мине сөйдең ич,
Шул ук төнне ташлап киттең. Димәк, чынлап.
Бу шаяру түгел?

Лизандр

Нинди шаяру ди!
Чынлап киттем, бөтенләйгә, һич шикләнмә.
Өметләнмә, ялынма да — бар да дөрес:
Синнән тәмам биздем. Сөям Еленаны.

Гермия

Алай икән! Хыянәтче, алдакчы кыз,
Явыз карак! Димәк, төнлә басып кереп,
Йөрәген урлап киттең?

Елена

Чү, Гермия, зинһар, миңа ачуланма.
Мин һәрвакыт якын күрдем сине, сөйдем.
Барлык яшрен серләреңне саклый килдем.
Әмма кичә, Деметрийне сөйгәнлектән,
Сезнең яшрен уегызны әйттем аңа.
Ул шунда ук сезнең арттан китеп барды,
Ә мин аңа иярдем. Ул мине куды,
Кыйныйм, дип янады, үтерәм, диде.
Җибәрегез, тиле акылым белән бергә
Шәһәргә кайтып китим, сезне ташлап.
Җибәрегез, мин беркатлы, акылсыз мин.

Гермия

Бар, китсәнә, монда сине кем тоткарлый?

Елена

Йөрәгем кала монда, шул тоткарлый.

Гермия

Лизандрда каламы?

Елена

Юк, Деметрийдә.

Лизандр
*(Еленага)*

Елена, куркытма, Гермия сиңа тимәс.

Деметрий

Юк, тия алмас, әлбәттә, син булышсаң да.

Елена

Гермия ачуланса бик хәтәр ул.
Мәктәптә дә искиткеч усал иде.
Тәбәнәк булса да ул, зәһәр, явыз.

Гермия

Әнә тагы «тәбәнәк» ди! Буй тикшерә.
Нигә сез мине мыскыл иттерәсез?
Җибәрегез аның янына!

Лизандр

Кит, кәрлә,
Зәгыйф орлыктан яралган! Кит, әкәлә!
Бөҗәк, төймә!

Деметрий

Ә син юкка куштанланма,
Ул һич синең яклавыңа мохтаҗ түгел.
Калдыр аны! Яклама да,
Аңа гыйшкың турында да авыз ачма,
Үкенерсең.

Лизандр

Мин иректе! Еленага
Кайсыбызның хокукы зур икәнлекне

Хәл итәргә дисәң, әйдә минем арттан.

Деметрий

Синең арттан? Юк, янәшә чыгыйк әйдә.

Лизандр белән Деметрий чыгып китәләр.

Гермия

Бу хәлләрнең барына да син гаепле!..
Кая киттең? Тукта!

Деметрий

Сиңа ышана алмыйм.
Синдәй усал кеше белән мин кала алмыйм.
Сугышка шәп булса синең йодрыкларың,
Качарга шәп минем озын сыйракларым.

Йөгереп чыгып китә.

Гермия

Гаҗәп хәл! Һич аңлый алмыйм.

Китә.

Оберон

Син бутадың! Хатадан һич башың чыкмый!
Кайчагында юри шулай шаяртасың!

Пэк

Юк, падишам, юри түгел, ялгышканмын.
Үзең әйттең,
Ул яшь егет Афинадан килгән, дидең,
Шәһәр киеме кигән, дидең.
Мин нәкъ шундый киемлегә тап булганмын,
Тамчыны шуның күзенә тамызганмын.
Әмма ләкин, дөресен әйтим, һич үкенмим:
Карап тору бигрәк кызык,
Әрләшәләр кызып-кызып.

Оберон

Сугышырга дип аулакка китте алар.
Тизрәк төнне караңгылат, томан бассын,
Йолдызларны кара болыт томаласын,
Сугышучы көндәшләрне юлдан яздыр,
Адашсыннар, берсен-берсе таба алмасын.
Ары барып Лизандр булып кычкыр,
Каты сүгенеп Деметрийнең канын кыздыр,
Бире килеп Деметрий булып үкер —
Лизандрның ачуын китер.
Берсен-берсе куып йөреп алҗысыннар,
Икесе дә хәлдән таеп егылсыннар.
Егетләрнең керфекләрен
Йокы басар әкрен-әкрен.
Ә син шунда Лизандрның күзләренә
Шул тамчыны тамызырсың ипләп кенә.
Егетебез саташуларыннан айныр,
Күз карашы табигый хәлгә килер —
Дөрес күрер.
Уянгач та көндәшләрнең икесе дә
Монда булган хәлләрне төш диеп белер.
Иртән кайтып ук китәрләр,
Тату итеп көн итәрләр.

Ә хәзер мин җәһәт кенә,
Син боларны адаштырып йөреткәндә,
Титания янына барыйм.
Аннан теге һинд малаен — пажны сорыйм,
Әкәмәт гыйшкыннан да арындырыйм.

Пэк

Җәһәтрәк: таң йолдызы калыкты әнә,
Төнге рухлар ашыгып кайта ләхетенә.
Юл чатына, су төбенә күмелгәннәр
Инде күптән гүрләренә яшеренгәннәр;
Мәңге-мәңге караңгыда яши алар,
Яктылыкка чыгарга оялалар.

Оберон

Без бөтенләй башка төрле рухлар монда.
Аучы кебек йөри алам мин урманда,
Офык чите ахакланганчы,
Яшькелт диңгез алтынланганчы,
Рәхәтләнеп уйный алам таң нурында.
Шулай да син бик юанма, җәһәтрәк,
Эшебезне тизрәк бетерергә кирәк.

Китә.

Пэк

Алып китәм теге якка,
Ары якка, бире якка.
Чакырам анда, чакырам монда,
Борам сулга, борам уңга!
Берсе килде.

Лизандр керә.

Лизандр

Кайда син, әй, Деметрий, каһәр суккан?

Пэк

Монда, монда, кылыч кулда,
Үзең кайда, кабахәт җан?

Лизандр

Хәзер киләм.

Пэк

Юк, син әйдә минем арттан,
Монда урын тигезрәк.

Лизандр Пэк тавышы килгән якка китә. Деметрий керә.

Лизандр, әй! Кайда соң син, куркак куян?
Куаклыкка постың мәллә куркуыңнан?

Пэк

Үзең куркак!
Сугышам дип ай каршында шапрынасың,
Әмма үзең куаклыкка яшренәсең!
Камчылыйм мин сине, малай, кил, сузыл, ят!
Синең белән кылыч чәкәштерү оят.

Деметрий

Кайда соң син, чәнчелгере?
Тукта!

Пэк

Монда сугышып булмый, кил син бире!

Китәләр.
Лизандр керә.

Лизандр

Үзе һаман мине чакыра, үзе тая.
Якынайсам — юкка чыга әллә кая.
Адым саен чокыр, төпсә... Юк, ял итәм.
*(Ята.)*
Төнне көтәм.
Таң сызылу белән барыбер эзләп табам,
Үчне алам.

Пэк белән Деметрий килеп керәләр.

Пэк

Аһа! Куркак! Ник килмисең, аяулы җан?

Деметрий

Син көтеп тор! Юкса качасың бит һаман,
Якынайсам — шым буласың карак сыман.
Кайда соң син?

Пэк

Монда мин. Кил якынрак!

Деметрий

Юк, шаярма! Көт азрак!
Яктыргач очрашырбыз, бар, китеп тор!
Салкын түшәгемә авам.
Иртән кирәгеңне бирәм, бик белеп тор!

Ята, йокыга китә.
Елена керә.

Елена

Аһ, бу озын газаплы төн!
Тизрәк үтсен!
Таң нурлары сибелү белән,
Миһербансыз кешеләрдән
Качып, кайтып китәр идем.
Төн үткәнче йоклый алсам,
Сагышымнан арына алсам,
Азрак тынычланыр идем.

Ята, йокыга китә.

Пэк

Йоклагыз рәхәт-рәхәт.
Шушы тылсымлы чәчәк
Шифалы суы белән
Саташуларны җуйсын.
*(Чәчәкнең суын сыгып Лизандр күзенә тамыза.)*
Уянгач аңа кара,
Килешегез үзара:
Тәүге гыйшык терелсен,
Уйларыгыз, хисләрегез

Мәкальгә туры килсен:
«Һәркем үз ишен белсен,
Үзенең ярын сөйсен».
Һәрбер җайдак ялгышмыйча
Үз биясенә менсен,
Эш шулай төгәлләнсен.

Китә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук.
Лизандр, Гермия, Деметрий, Елена йоклыйлар. Титания белән
Кәтүк, алар артыннан эльфлар керәләр. Арткы планда Оберон, ул боларга
күренми.

Титания

Сөеклем, кил, утыр гөлләр арасына,
Кадерле башкаеңны сөйим, сыйпыйм.
Маңгаеңны кызыл гөлләр белән бизим,
Үбим, назлыйм сөйкемле колагыңны.
Кәтүк. Кая китте Хушисле Борчак?
Хушисле Борчак. Монда.
Кәтүк. Башымны кашы, Хушисле Борчаккаем. Пәрәвез кайда?
Пәрәвез. Монда.

Кәтүк. Пәрәвез ханым, рәхимле ханым, берәр нәрсә белән коралланып, әнә теге тигәнәккә кунган кызыл сыйраклы төклетураны үтерегез дә бал янчыгын алып китерегез. Тик, карагыз аны, сөекле Пәрәвез ханым, янчык шартламасын: балга буялмагыз. Миңа бик күңелсез булыр, кадерлем. Керән әфәнде кайда?

Керәнзадә. Мин монда!

Кәтүк. Кулыгызны бирегез, сөекле Керәнзадә. Тәкәллефсез генә, зинһар, дим.

Керәнзадә. Ни боерасыз?

Кәтүк. Әллә ни түгел, хөрмәтлем, Хушисле Борчак әфәндегә ярдәм итегез — башымны кашыгыз. Чәчтарашка барырга иде, хөрмәтлем — бөтен битемне йон басып китте шикелле. Шундый бер назлы ишәк инде мин, берәр йон бөртеге кычыттымы, түзә алмыйм, кашынырга тотынам.

Титания. Музыка тыңлыйсың килмиме, сөеклем?

Кәтүк. О! Музыкага минем колак бик сизгер, дөмбердәтсеннәр әйдә.

Кайгылы музыка.

Титания. Ә бәлки, ашыйсың киләдер, кадерлем?

Кәтүк. Болай азыктан баш тартмас идем шикелле. Әйтик, берәр соскы әйбәт солы булса яки... Юк, иң әйбәте — бер кочак печән китерегез, хуш исле печәннән дә шәбе булмас.

Титания

Искиткеч булдыклы хезмәтчем бар минем:
Тиеннең келәтен актарып,
Чикләвек китерер ул сиңа.

Кәтүк. Бер, ике, өч кипкән борчак китерсә, әйбәтрәк булыр иде. Тик хәзергә кирәкми әле. Хезмәтчеләрең мине борчымасын, йокым килә.

Титания

Кил, йокла, кочаклыйм муеныңнан,
Барыгыз, китегез һәммәгез.

Эльфлар китә.

Нәкъ шулай кочаклый имәнне ак зелпе,
Үрмәле гөл коча карама ботагын.

Аһ, сөям мин сине өзелеп, газизем!

Йокыга китәләр.
Пэк керә.

Оберон

Карасана, нинди назлы, шигъри күренеш!
Кызгана башладым бичараны.
Күптән түгел аланлыкта күрдем үзен.
Шушы килбәтсезгә чәчәк җыеп йөри.
Әрләдем, оялтырга тырыштым мин.
Килбәтсезнең шөкәтсез йонлы башын
Хуш исле чәчәкләр белән бизи.
Чәчәкләрдә җемелдәгән чык тамчысы
Күз яшедәй күренде, бичаралар
Гарьләнеп елый төсле шул хурлыктан.
Бик оялткач, миннән гафу үтенде ул.
Шунда мин һинд малаен таләп иттем.
Карышмады, шундук бирде. Кичекмәстән
Малайны минем өйгә илтергә, дип,
Эльфларга боерды Титания.
Хәзер инде минеке ул һинд малае.
Бикәне арындырам саташудан.
Син дә, Пэк, Афина сукбаеның
Башындагы әкәмәтне алып ташла.
Уянсын ул да, башкалар белән бергә
Афинага кайтып китсен кичекмәстән,
Монда күргән маҗараны төш дип белсен.
Иң элек мин бикәне арындырыйм.

Тылсымлы чәчәген Титаниянең күзенә тидерә.

Кайт элекке хәлеңә,
Күңел күзең ачылсын.
Тылсымлы гөл кагылуга,
Саташулар җуелсын!
Титания! Уян инде, бикә генәм!

Титания

Падишаһым! Гаҗәеп төш күрдем бит мин!
Имеш, гашыйк булганмын бер ишәккә!

Оберон

Менә ул сөйгән ярың.

Титания

Кит! Чынлапмы?..
Абау, абау! Карарга куркыныч бу!

Оберон

Чү... Акрын, Пэк,
Алып ташла башыңдагы әкәмәтне!
Ә син, бикә, уйнат серле музыкаңны,
Бишесен дә каты йокы биләп алсын.

Титания

Йоклата торган серле моң яңрасын!

Талгын музыка яңгырый.

Пэк

Уянгач та яңадан җүләр булырсың син.

Оберон

Чәчелсен моң! Бир кулыңны, әйдә китик,
Дәртләнеп биик әле, җир тетрәтик!
Яңадан дуслаштык бит, бикә генәм!
Икәүләшеп иртәгә, ай калку белән,
Юнәлербез Тезей хаким сараена,
Кәеф-сафа корырбыз төн буена.
Тантаналы биюләрне җитәкләрбез,
Хуҗаларны никах белән тәбрикләрбез,
Менә бу гашыйклар да бергә шунда
Никахланыр тантана вакытында.

Пэк

Таң сызылды, Оберон...
Чү... Ишет тургай җырын!

Оберон
*(Титаниягә)*

Бир кулыңны! Шым гына,
Яктырып җитмәс борын,
Тиз очып китик ерак,
Җир шарын чыгыйк урап.

Титания

Кузгалыйк әйдә, ярым!
Ник монда калуымны,
Йокыга талуымны —
Юлда сөйләрсең барын.

Очып китәләр.
Боргы тавышлары.
Тезей, Ипполита, Эгей һәм иярченнәре керәләр.

Тезей

Берәрегез урман сакчысына барсын.
Тиешле йолаларны үтәдек без.
Көн башланды. Хәзер мин сөеклемә
Ау этләре музыкасын тәкъдим итәм.
Ычкындырып җибәрегез барысын да
Көнбатыш тугаена! Тиз булыгыз!
Үзебез тау түбәсенә меник әйдә,
Кайтавазга кушылып көчле яңгыраган
Этләр хорын тыңлап торыйк югарыдан.

Ипполита

Берчак шулай Геркулес, Кадм патша
Крит урманы аюына
Спарта этләре өерен җибәрделәр.
Андый көчле, гаҗәеп аһәң белән
Яңгыраган этләр хорын беркайчан да
Ишеткән юк иде минем. Бөтен дөнья —
Урман,таулар, әрәмәләр гөрләп торды.

Тезей

Минем этләр дә спарта нәселеннән,
Иякләр һәм төсләреннән танып була.
Күкрәкләре охшый үгез күкрәгенә.
Җитезләр дип булмый, әмма тавышлары
Нәкъ кыңгырау шикелле яңрап тора.
Әнә тыңла! Чү! Бу нинди кызлар ята?

Эгей

Хөкемдар, бу минем кызым йоклап ята.
Лизандр да монда, менә Деметрий,
Недар кызы Елена да — барысы бергә.
Ни сәбәптән алар монда килеп чыккан?

Тезей

Май йоласын үтәргә дип килгәннәрдер.
Безнең монда киләсене белгәнлектән,
Тантананы көтеп монда калганнардыр.
Әйтче, Эгей дустым, бүген синең кызың
Ир сайларга тиеш иде түгелме соң?

Эгей

Әйе, шулай, хөкемдарым.

Тезей

Сунарчылар
Боргы уйнап яшьләрне уятсыннар.

Боргы тавышлары. Лизандр, Деметрий, Елена, Гермия уяналар, урыннарыннан торалар.

Валентин көне, дуслар, узды ласа,
Әмма кошлар әле яңа оя кора.

Лизандр

Кичерегез, хөкемдарым!

Барысы да тезләнәләр.

Тезей

Торыгызчы!
Белеп торам, сез — көндәшләр. Ничек болай
Килештегез әле? Көндәш белән көндәш
Бер-береннән шикләнмичә бергә ята!

Лизандр

Хөкемдарым, белмим ни дип әйтергә дә:
Өнме, төшме, берничек тә аңлата алмыйм,
Ни сәбәптән монда килеп эләктем мин?
Миңа калса... Дөресен генә әйтәсе иде...
Юк, юк, түгел... Дөресе искә төште:
Без Гермия белән килдек Афинадан,
Анда булган йолалардан качмакчы идек.

Эгей

Җитте, булды, аңлашылды, хөкемдарым.
Йола! Йола аның башына афәт булып төшсен!
Афинадан качмакчылар. Деметрий,
Алар безне төп башына утыртырга,
Сине — кәләшеңнән, мине хокукымнан
Мәхрүм итеп калдырырга җыенганнар.

Деметрий

Хөкемдарым,
Аларның качарга җыенуын
Елена әйтте миңа. Мин шунда ук
Артларыннан куып килдем бу урманга;
Елена минем арттан ияреп килде.
Ә мин монда... Мин үзем дә белмим, шаһым,
Ниндидер көч... әйе, шулай, ниндидер көч
Мине тәмам биләп алды. Кайчандыр

Гермиягә булган дәртем тәмам эреп
Юкка чыкты, бала чакта бик яратып
Уйнаган уенчыкка охшап калды.
Хәзер минем бар шатлыгым, уем-хисем
Сөекле Еленага кайтып кала,
Тик ул гына газиз миңа!
Электән үк, Гермияне күргәнче үк
Ярәшелгән иде миңа бу сылу кыз.
Чирләгәндә ашамлыктан күңел бизә,
Терелгәч тә рәхәтләнеп ашыйбыз ич.
Хәзер аны сөям, күңелем аңа тарта,
Аңа мәңге тугры булып калырмын да.

Тезей

Сезне монда очратуга мин бик шатмын.
Бу хакта без иркенләп сөйләшербез.
Эгей, сиңа килешергә туры килер.
Бүген гыйбадәтханәдә бу гашыйклар
Безнең белән бер уңайдан никахланыр.
Көн башланды, бүген ауга чыкмабыз без.
Һәммәбез дә Афинага кайтыйк бергә.
Өч пар булып киттек, өч туй, өч тантана.
Әйдә киттек, Ипполита!

Тезей, Ипполита, Эгей һәм иярченнәре чыгып китәләр.

Деметрий

Бөтен нәрсә кичерәйгән кебек миңа.
Таулар да болыт булып таралгандай.

Гермия

Әйтерсең лә күзләрем ике төрле.
Һәрнәрсә ике булып күренә миңа.

Елена

Миндә дә нәкъ шундый ук хәл.
Деметрийне таптым төсле.
Ул минекеме, түгелме —
Ачык итеп әйтә алмыйм бит.

Деметрий

Миңа калса, без йоклыйбыз, төш күрәбез.
Герцогны без монда чынлап күрдекме соң?
«Бергә кайтыйк» дигән сүзне әйттеме ул?

Гермия

Әйе, күрдек. Әтине дә.

Елена

Ипполитаны да.

Лизандр

Гыйбадәтханәгә бергә барыйк, диде.

Деметрий

Димәк, йокламыйбыз. Әйдә, тиз булыгыз,
Төшебезне сөйләрбез кайта-кайта.

Китәләр.

Кәтүк *(уяна)*. Минем реплика килеп җиткәч, әйтерсең мин монда. Нәүбәттәге репликам — «сөекле Рирам»! Әй, Питер, Бүрәнә!.. Боргы! Өргечләр төзәтүче!.. Танау, Бакырчы!.. Йончыган!.. Йа Рабби

Ходаем, качканнар. Кара урманда берүземне калдырганнар. Искиткеч төш күрдем мин. Аны сөйләп бирү өчен адәм акылы гына җитмәс. Аны юрарга батырчылык иткән кеше ишәккә әвереләчәк. Имеш, мин төшемдә... Кем булдым соң әле мин? Әйтә алмыйм. Имеш, мин төшемдә... Нәрсәм бар иде соң әле? Аның нәрсә икәнен әйтергә алынган кеше шыр дивана булыр. Адәм күзе ишетмәгән, адәм колагы күрмәгән, адәм кулы татымаган, адәм теле аңламаслык, адәм йөрәге әйтә алмаслык әкәмәт төш иде ул. Күргән төшем турында Бүрәнәдән баллада яздырам. Баллада «Кәтүк төше» дип аталачак, чөнки ул кәтүк җебе кебек очына чыга алмаслык буталчык. Мин аны спектакльдән соң герцог каршына чыгып җырлыйм. Тәэсирлерәк булсын өчен Фисба үлгән минутта җырлыйм мин аны.

Китә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Афина. Питер Бүрәнә өенең бер бүлмәсе.
Бүрәнә, Боргы, Танау, Йончыган керәләр.

Бүрәнә. Йә, ничек, Кәтүккә кеше җибәрдегезме? Өенә кайтканмы?

Йончыган. Эзе дә юк, исе дә юк. Мөгаен, ул җенгә әверелгән.

Боргы. Ул кайтмаса, спектакль харап була, берни эшләп булмый.

Бүрәнә. Әйе, аннан башка уйнарга ярамый. Бөтен Афинаны кыдырып эзләсәң дә, Пирам роленә аннан да кулайрак кеше табып булмый.

Боргы. Юк, булмый! Афина һөнәрчеләренең иң акыллысы — Кәтүк.

Бүрәнә. Шуның өстенә ул иң матур кеше. Тавышы шундый ягымлы, җырлап җибәрсә, аферист уенын тыңлагандай буласың.

Боргы. Арфист димәкче идең. Аферистлар белән аралашмыйбыз, Аллага шөкер.

Пычкы керә.

Пычкы. Дуслар, герцог гыйбадәтханәдән кайтты. Аһ, спектаклебез уйналса, барыбыз да адәм рәтенә керер идек.

Боргы. Аһ, Кәтүк, Кәтүк, булдыклы егет! Көненә алтышар пенстан мәхрүм калды лабаса. Пирам роле өчен аңа герцог бөтен гомере буена һәр көн саен алтышар пенс түли иде. Алтышар пенстан ким булса, менә башымны кистерәм.

Кәтүк керә.

Кәтүк. Кайда сез, егеткәйләрем, кайда сез, бәгырькәйләрем?

Бүрәнә. Кәтүк! Менә бит ул хәерле көн, бәхетле сәгать!

Кәтүк. Аһ, дусларым, шундый хәлгә тарыдым мин, сөйләп бирсәм, исегез китәр! Ләкин сорашмагыз. Аны сезгә сөйләмәсәм, иң намуссыз кеше булырмын мин. Күргәнемне төгәл итеп сөйләп бирәм.

Бүрәнә. Без тыңлыйбыз, сөекле Кәтүк!

Кәтүк. Минем хакта ләм-мим! Әйтер сүзем шул: герцог төшке ашын ашады. Кирәкле әйберләрегезне алыгыз, сакалларыгызга яңа тасмалар, туфлиләрегезгә яңа бантлар тагыгыз. Барыбызга да патша сарае алдына җыйналырга. Һәркем әйбәтләп ролен карап чыксын. Кыскасы, тегеләйме, болаймы, безнең пьесаны күрсәтергә булганнар. Һәрхәлдә, Фисба чиста ыштан кияргә тиеш. Арыслан ролен уйнаучы тырнагын кисмәсен. Ябынган тире астыннан ул арыслан тырнагы булып күренергә тиеш. Иң мөһиме, кадерле актерлар, суган, сарымсак ашамаска. Бездән татлы ис аңкып торырга тиеш. Мин һич шикләнмим, тамашачылар «татлы комедия» дип әйтәчәкләр. Бәхәсләшмәскә! Бер сүз дәшмәскә! Киттек!

Китәләр.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Афина. Тезей сараеның бер бүлмәсе. Тезей, Ипполита, Филострат, сарай хадимнәре керәләр.

Ипполита

Бик гаҗәп бу гашыйкларның сөйләгәне.

Тезей

Гаҗәп, ләкин хак булудан шактый ерак.
Андый серле шаккатыргыч әкиятләргә
Мин ышанмыйм.
Гашыйкларның барысы да шыр дивана,
Хыяллары акылларын җиңеп китә.
Гашыйклар, шагыйрьләр һәм диваналар —
Барысы да буш хыялдан яралганнар.
Җәһәннәмдә булмаган шайтаннарны
Очраталар. Гакылыннан шашкан гашыйк
Чегән кызын фәрештә итеп күрә.
Хыялый шагыйрьнең шашкан күзе
Гел адашып йөри җир, күк арасында.
Фараз итә җыен тузга язмаганны,
Бар дип белә дөньяда һич булмаганны,
Терелтә ул шуны — күзе белән күрә,
Ахыр чиктә хәтта аңа исем бирә.
Хыялы шундый җиңел уйный аның,
Күңелендә шатлык туса, ул шунда ук
Күрә аның ишарәсен, хәбәрчесен.
Әгәр курыкса, киресенчә —
Куак аю булып күренә.

Ипполита

Алай димә; бүген төнлә булган хәлләр
Коры хыял җимеше генә димәс идем, —
Кинәт кенә тойгылары үзгәргән ич.
Миңа калса, сүзләрендә дөреслек бар.
Шулай да бик сәер, кызык!

Тезей

Әнә килә үзләре дә куанышып.

Лизандр, Гермия, Деметрий һәм Елена керәләр.

Сәлам, дуслар! Күңлегездә бәхет нуры
Мәңге шулай сүрелмәсен, балкып торсын.

Лизандр

Безнең теләк: хакимлек юлыгызны
Бәхет, шатлык нурландырсын.

Тезей

Йә, нишлибез? Маскарад ясыйбызмы, биибезме?
Кичке аш белән йокы арасын, дим.
Мәңгелектәй сузылачак өч сәгатьне
Ничек итеп кыскартабыз? Кайда безнең
Күңел ачу эшләрен җитәкләүче?
Бүгенгә ул безгә нәрсә тәкъдим итә?
Филострат!

Филострат

Мин монда, хөкемдарым!

Тезей

Бүгенгә син безгә нәрсә әзерләдең?
Маскарадмы, биюләрме?
Коточкыч сузылачак вакытны без
Мәзәктән башка ничек үткәрәбез?

Филострат

Менә монда исемлектә күрсәтелгән.
Боерыгыз, нидән башлап җибәрергә?

Кәгазь бирә.

Тезей
*(укый)*

«Кентаврлар сугышы. Арфага кушылып
Афиналы монах җырлый». Юк, кирәкми:
Бабабыз Геркулесны искә алып,
Сөеклемә үзем сөйләп биргән идем.
«Исерек вакханкалар тарафыннан
Ботарланган җырчы Орфей легендасы».
Иске: миңа бер кат күрсәттеләр инде аны,
Фивадан җиңү белән кайтканнан соң.
«Фәкыйрьлектә вафат булган Фәнне жәлләп
Музаларның яшь түгүе». Туй көненә
Туры килми торган берәр сатирадыр.
«Фисбаның Пирамга мәхәббәте.
Кыска, ләкин сузыла торган
Бик күңелле трагедия».
Үзе кыска, әмма ләкин сузыла торган.
Җитмәсә, бик күңелле трагедия.
Кап-кайнар боз. Боларны ничек итеп
Бер-беренә килештереп булыр икән?

Филострат

Хөкемдарым, бары ун сүз озынлыгы,
Аннан кыска пьесаның булганы юк.
Аның артык җире дә шул — әлеге ун сүз,
Әнә шуңа сузыла ул. Бер генә дә
Рәтле сүз юк анда, рәтле актер да юк.
Шуңа карамастан трагедия.
Каһарман Пирам үзен-үзе үтерә.
Репетициядә көлдем елый-елый.
Гомеремдә көлгәнем юк иде минем болай.

Тезей

Кемнәр уйный?

Филострат

Барысы да Афинадан,
Һөнәрчеләр, кулларын эшләтеп тә,
Миләрен эшләтергә күнекмәгән
Гади халык. Туегызда уйнарга дип
Шундый әсәр язганнар азапланып.

Тезей

Менә шуны карыйк инде.

Филострат

Юк, хөкемдар,
Сезгә лаек түгел. Үзем карадым мин:
Берни дә юк анда, мәгънәсез, чүп.
Шулай да, бәлки, кызык булыр сезгә
Күңлегезне ачарга тырышулары.

Тезей

Карыйбыз ул әсәрне.
Ихлас белән тәкъдим иткән нәрсә
Ул кадәр үк начар булмас. Чакырыгыз!
Ханымнар, утырыгыз.

Филострат китә.

Ипполита

Фәкыйрьлектән көләргә? Юк, күңлем тартмый,
Саф күңелнең хур булуын теләмим мин.

Тезей

Юк, сөеклем, андый хәл булмаячак.

Ипполита

Берни дә юк, мәгънәсез чүп, дип әйтте ич.

Тезей

Әнә шул чүп өчен рәхмәт әйтербез без,
Хаталарын кичерербез. Кайчак кеше
Кимчелеген тырышлыгы белән аклый.
Кайчагында мине шулай галим ирләр
Әзерләнгән нотык белән каршылыйлар.
Кинәт шунда, фикер җебе өзелеп китеп,
Әзерләнгән матур сүзләр онытылса,
Агарынып тынып кала, бичаракай.
Ышанамсың, шулай тынып калуда мин
Сәламләвен, ихтирамын күрәм аның,
Каушап калган тыйнаклыкта хөрмәт тоям.
Самимилек, зур ихтирам, зурлау күрәм.
Купшы итеп такылдауга караганда,
Тыйнак кына сүзсез тору мәгънәлерәк.

Филострат керә.

Филострат

Җәнабыгыз тыңлыйм дисә, пролог әзер.

Тезей

Керсен!

Borгы тавышлары.
Бүрәнә керә, ул Пролог ролендә.

Пролог

«Килдек сезгә барыбыз бергә
Түбәнчелек белән сәлам күндерергә.
Тантана булмаса әгәр,
Суксын каһәр,
Кыймас идек без гомергә
Үзебезнең даһилыкны күрсәтергә.
Безнең максат — сезне хурлау
Йә кимсетү. Түгел нурлау.
Уебыз шул. Барыгызга да ярарга
Һич тә теләмибез. Сезне җәзаларга
Актерлар килде әнә — күрерсез,
Белергә тиешлесен белерсез».

Тезей. Бу егет тыныш билгеләре белән бер дә исәпләшеп тормый.

Лизандр. Моның прологы өйрәтелмәгән айгыр кебек: кая туктарга белми. Моннан шундый гыйбрәт, хөкемдар: сөйләү генә җитми, сүзнең дөрес булуы да кирәк.

Ипполита. Чыннан да, моның прологы сабый баланың флейта уйнавы кебек: тавышы бар, тик аны оештыра белми.

Тезей. Аның сүзе чуалган чылбырга охшый: бөжраларының барысы да бар, тәртибе генә юк. Хәзер нәрсә була?

Пирам, Фисба, Стена, Ай, Арыслан керәләр.

Пролог

«Әфәнделәр, бәлки, сезгә гаҗәп тоелыр,

Гаҗәпләнегез, ахырдан ачыкланыр.
Таныштырыйм: бу яшь егет Пирам булыр,
Кызның исеме — гүзәл Фисба, мәгълүм булсын.
Стена дип белегез бу балчыклысын,
Гашыйкларны аеручы явыз киртә.
Яшьләр шушы стенаның ярыгы аша
Эч серләрен бүлешә — пышылдаша.
Бу — фонарьлы, куаклы һәм этле кеше —
Мөлаем Ай — яшьләр юлын яктыртучы.
Бу — Арыслан киек. Сөйгән яры белән
Кавышырга килгән кызны куркытучы.
Бичара кыз куркып качып барган чакта,
Ябынчасы төшеп кала,
Арыслан шундук аны кабып ала,
Авызыннан ябынчага кан буяла.
Фисба белән кавышырга килгән егет,
Канлы ябынчаны күреп,
Фисба үзен-үзе үтергән дип белеп,
Хәнҗәр кадый күкрәгенә.
Кыз да шулчак,
Егетнең үлемен күреп,
Йөрәгенә кадый пычак.
Вакыйганы менә болар
Сезгә уйнап бирәчәкләр:
Ай, Стена, Арыслан һәм яшь йөрәкләр».

Пролог, Пирам, Фисба, Арыслан һәм Ай чыгып китәләр.

Тезей. Беләсе иде, Арыслан сөйләшерме икән?
Деметрий. Шулкадәре ишәкләр сөйләшкәндә, Арысланга нигә сөйләшмәскә?

Стена

«Хөрмәтле тамашачылар,
Таныш булыйк: исмем — Танау.
Стена ролен миңа тапшырдылар.
Мин шундый стена: тишегем, ярыгым бер.
Гашыйклар шул тишек аша
Акрын гына пышылдаша.
Күрегезче: бу балчыклар
Стена икәнемне аңлатырлар.
Менә ярык — уң ягымда, сул ягымда.
Гашыйклар сөйләшерләр килеп шунда».
Тезей. Балчыкның шуннан да әйбәтрәк сөйләвен өмет итеп буламы?
Деметрий. Моннан да әйбәтрәк сөйли торган стена барын ишеткәнем юк.

Пирам керә.

Тезей

Акрын! Пирам стенага килә.

Пирам

«Аһ, кара төн! Көн югында һәрвакыт син
Шомлы хаким!
Аһ, төн, аһ, төн! Абау, абау! Аһ, төн!
Фисба әллә онытканмы үз вәгъдәсен?
Аһ, Стена! Мәрхәмәтле ак Стена,
Зинһар, ярдәм итче миңа,
Күрсәтсәнә ярыгыңны,
Карыймчы сөйгән ярымны.

Стена бармакларын тырпайта.

Рәхмәт, рәхмәт, Стена,

Ярдәм иткән өчен миңа!
Тик күрмим анда берни дә!
Кайда Фисба? Күренми дә!
Ләгънәт сиңа, Стена, китче,
Нинди хәл бу, хыянәтче?»

Тезей. Минемчә, Стена моңа җавап бирергә, сүгенергә тиеш.

Пирам. Юк, хөкемдар, тиеш түгел. «Хыянәтче» дигән репликага Фисба килеп керергә тиеш. Ә миңа стена аша аны күрергә кирәк. Менә күрерсез, нәкъ мин әйткәнчә була. Әнә ул үзе.

Фисба

«Әйтче, Стена, рәнҗедем мин күпме сиңа,
Миннән яшереп торасың, дип, сөеклемне?
Чиядәй иреннәрем белән үптем
Балчык белән сылаган кирпечеңне».

Пирам

«Тавышын күрәм: ярыкка якын килим,
Ишетерменме сөеклемнең нурлы йөзен?
Аһ, Фисба!»

Фисба

«Син бит бу, бәгърем?
Ә мин уйлыйм...»

Пирам

«Ни уйласаң да, мин фәкать синең ярың.
Лизандр күк, сиңа тугры мин һәрдаим».

Фисба

«Ә мин мәңге тугры сиңа Еленадай».

Пирам

«Шафал Прокрусаны сөймәгәндер болай».

Фисба

«Мин дә Шафалдан ким түгел.
Син шуны бел».

Пирам

«Ярык аша үп мине бер, сылукаем».

Фисба

«Тик ярыкны үбәм, сине үбә алмаем».

Пирам

«Нин кабренә килерсеңме, алтын алмам?»

Фисба

«Үлсәм дә мин килми калмам».

Пирам белән Фисба чыгып китәләр.

Стена

«Стена роле менә шунда бетә,
Шуңа күрә иплә кенә чыгып китә».

Китә.

Тезей. Күршеләрне аерып торган стена, димәк, юкка чыкты.

Деметрий. Стенаның колагы бар, киткәне яхшы.

Ипполита. Мондый мәгънәсез нәрсәне күргән дә, ишеткән дә юк.

Тезей. Мондый әсәрләрнең иң һәйбәтләре дә күләгәләрдән тора. Хыялың эшләмәсә, рәте булмый. Хыялың катнашса, аламасы да карарлык була.

Ипполита. Бу бит сезнең хыял, аларныкы түгел.

Тезей. Безнең хыял аларныкыннан начар булмаса, ул әсәрләр менә дигән булып күренәчәк... Менә иң әйбәт ерткычлар килә — Ай белән Арыслан.

Арыслан белән Ай керәләр.

Арыслан

«Ханымнар, сез үтә нечкә күңеллесез,
Тычкан фәлән күренсә дә дерелдисез.
Тик белегез: мин Арыслан. Явыз түгел,
Исемем — Пычкы. Мин үзем дә нечкә күңел.
Әгәр дә мин Арыслан булып керсәм
Һәм үкерсәм,
Күрсәтерләр иде миңа күрмәгәнне».

Тезей

Нинди юаш хайван, үзе нинди акыллы.

Деметрий

Мин күргән хайваннарның иң сөйкемлесе.
Лизандр. Бу арыслан батырлыгы белән төлкегә охшаган.
Тезей. Дөрес. Әмма акылы белән казга охшаган.

Деметрий. Алай ук түгел, җәнабы гали, аның батырлыгы акылын җиңә алмый, төлке бит казны һәрвакыт җиңә.

Тезей. Һәрхәлдә, моның батырлыгы акылын җиңә алмый, чөнки казның беркайчан да төлкене җиңгәне юк. Шулай да, без аны үз акылы белән калдырып, Айны тыңлыйк.

Ай

«Бу фонарь ай булыр сезгә.
Ә мин — айда күренә торган кеше».

Тезей. Менә монысы иң зур хата: кешене фонарь эченә урнаштырырга кирәк иде. Болай бит ул ай кешесе була алмый.

Деметрий. Фонарь эченә керергә ул курыккан. Анда бит әнә шәм янып тора.

Ипполита. Туйдым мин бу айдан. Аңа инде үзгәрергә вакыт.

Тезей. Акыл нурының зәгыйфьлегенә караганда, ул инде шактый кимегән. Ләкин без хөрмәт йөзеннән көтәргә тиеш булабыз.

Лизандр. Дәвам ит, Ай.

Ай. Әйтергә теләгәнем шул гына: аңлатып бирим, фонарь — ай, мин — айдагы кеше; бу куак — минем куак, эт тә минеке.

Деметрий. Боларның барысы да фонарь эчендә булырга тиеш ләбаса. Чү, акрын, әнә Фисба килә.

Фисба керә.

Фисба. «Нин кабере менә шушы. Иркәм кайда?..»
Арыслан. «У-у-у!..»

Фисба йөгереп чыгып китә.

Тезей. Әйбәт үкерәсең, Арыслан!
Ипполита. Әйбәт яктыртасың, Ай! Чынлап. Ай бик әйбәт яктырта.
Тезей. Әйбәт ботарладың, Арыслан!
Деметрий. Хәзер Пирам чыга...
Лизандр. Арыслан да югала.

Пирам керә.

Пирам

«Зур рәхмәт, Ай, кояш нуры сипкән өчен,
Бик зур рәхмәт төнне якты иткән өчен.
Җемелдәгән алтын нурың ярдәмендә
Мин күрермен сөеклемнең күркәм йөзен.
Чү, ни күрәм?
Нинди бәла
Әзерләдең,
Явыз язмышкаем?

Күрми күзем...
Аһ! Нишләдең,
Чулпан йолдызкаем?
Күрәм канлы
Ябынчаңны!
Инде ни кылаем?
Әй, фурияләр.
Тизрәк килеп җитегезче,
Гомерем җебен кисегезче,
Тураклагыз, хур итегез,
Үтерегез, бетерегез!»
Тезей. Сөеклесен җуйган кешенең бу кадәр өзгәләнүен күреп хәсрәтләнергә дә мөмкин шул.
Ипполита. Ант итеп әйтәм, мин кызганам бу кешене.

Пирам

«Әй, Табигать, ник яраттың арысланны?
Харап итсен дипме минем сөеклемне?
Иң гүзәл кыз иде бит ул җир йөзендә,
Аның белән тиңләп булмый һичбер кемне!
Хадимнәр, тиз үтерегез,
Бетерегез!
Хәнҗәр, кадал,
Җанымны ал,
Кадал менә
Йөрәгемә!

Йөрәгенә хәнҗәр кадый.

Үлдем, беттем,
Беттем, киттем!
Җаным оча гарешләргә,
Сөякләрем кала җирдә.
Телем — тынды,
Күзем — сүнде,
Ай, кит инде!

Ай чыгып китә.

Бетте, булды,
Күз йомылды».
Үлә.

Ипполита. Ай нигә алай иртә чыгып китте? Фисба килеп Пирамны эзлисе бар бит әле.
Тезей. Ул аны йолдызлар яктысында эзләр. Әнә үзе. Кызның һәлакәте белән әсәр тәмам була.
Ипполита. Миңа калса, мондый Пирам өчен хәсрәтләнеп озак еламас ул.
Деметрий. Кайсы кайсыннан артык икәне үлчәүгә салсаң күренер: Пирамымы ир буларак, Фисбасымы кыз буларак (ташка үлчим!).
Лизандр. Әнә күрде сөеклесен мөлаем күзләре белән.
Деметрий. Хәзер аны кызганып такмаклый башлый.

Фисба керә.

Фисба
«Йоклыйсыңмы?.. —
Чү!.. Ни булды? —
Килде мәллә үлем?
Ач күзеңне,
Әйт сүзеңне!
Ник дәшмисең, гөлем?
Нигә тындың?..
Вафат булдың!
Томаланган күзең,
Алсу борының,
Аксыл иренең,
Сулган гөлдәй йөзең!

Һәрбер гашыйк килсен,
Күз-яшь түксен,
Күреп яшькелт күзен!
Аһ, мойралар,
Рәхимсезләр,
Аны харап иттегез сез:
Килеп бүген
Гомер җебен
Ашык-пошык кистегез сез!
Тукта, телем!
Килсен үлем,
Тугры хәнҗәр, җәһәтрәк!
Менә йөрәк,
Кадал тизрәк.

Күкрәгенә хәнҗәр кадый.

Хушыгыз, дуслар!
Бу минем иң соңгы каләм:
Сәлам, сәлам, сәлам!»

Үлә.

Тезей. Ай белән Арыслан мәетләрне күмәргә калдылар.

Деметрий. Әйе, Стена да калды.

Кәтүк. Юк, валлаһи, дип әйтәм, күршеләрне аерып торган стена хәзер юк инде... Хәзер эпилогны карыйсызмы, әллә ике актер башкаруында бергам биюен тыңлыйсызмы?

Тезей. Эпилог кирәкми: бу әсәрегез өчен гафу үтенеп торасы юк. Актерларның барысы да үлгән булгач, беркемне сүгеп булмый. Бу әсәрне язучы Пирам ролен үзе уйнап, Фисбаның ыштан бавына асылынып үлсә, менә дигән трагедия булыр иде. Хәер, болай да әйбәт. Бергам биюен күрсәтегез, эпилог кирәкми.

Бию

Сәгать төнге уникене сукты әнә.
Гашыйклар, түшәкләргә ашыгыгыз!
Төнге рухлар йөри торган вакыт җитте.
Шушы әсәр белән мавыгып,
Ярты төнне җиткергәнче утырганбыз.
Ятыйк, дуслар, юкса иртән торалмабыз.
Безнең бәйрәм ике атнага сузылачак,
Уен-көлке, төрле мәзәк күп булачак.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук.
Пэк керә.

Пэк

Үкерә ач арыслан,
Бүре улый төнката,
Арып талган сукачы
Гырылдап йоклап ята.
Бу вакытта өрәкләр,
Торып каберләреннән,
Әйләнәләр акрын гына
Зират тирәләреннән.
Караңгыда без иркенләп
Очабыз анда-монда,
Кыштырдамый тычканнар да,
Өйләрдә без барында.
Тымызык ут яктысында
Чүп-чарның барысын да
Себереп түгәм гелән

Шушы себерке белән.

Титания белән Оберон иярченнәрен ияртеп керәләр.

Оберон

Йокыга талган бу өйгә
Тымызык нур сибегез.
Тирә-юньдә кошлар кебек
Пырлап очып йөрегез.
Минем җырны кабатлап,
Матур итеп биегез.

Титания

Әйлән-бәйлән әйләнеп,
Кабатлыек сүзләрен.
Явыз рухлар шомлыгыннан
Каравыллыйк өйләрен.

Җырлыйлар, бииләр.

Оберон

Таңга кадәр барыгыз,
Өйләргә таралыгыз!
Яшьләр янына керим,
Фатихабызны бирик.
Рәхәт гомер сөрсеннәр,
Тугрылыклы булсыннар,
Балалары-чагалары
Сау-сәламәт тусыннар.
Ким-хурлыктан, зәгыйфьлектән,
Ямьсезлектән, гариплектән
Бар да имин булсыннар!
Рәхәт-рәхәт торсыннар!
Сез, барыгыз, гашыйкларның
Ятагына керегез.
Тынычлык һәм бәхет теләп
Чык сулары сибегез.
Барыгыз, тиз, ашыгыгыз,
Җәһәт кенә йөрегез.
Көнчыгышта таң сызылгач,
Хозурыма килегез.

Оберон белән Титания иярченнәрен ияртеп чыгып китәләр.

Пэк

Күрсәтелгән бу әсәрдә
Хата тапсагыз әгәр дә,
Тиз төзәтә аласыз —
Күргәнебез саташулар,
Төш диеп уйласагыз.
Хәерхаһлык күрсәтсәгез,
Хаталарны кичерсәгез,
Әрләмәсәгез безне,
Төзәтербез, бетерербез
Кимчелекләребезне.
Күңелегезгә ошасак,
Начар хис кузгатмасак,
Алкышласагыз әгәр,
Фәкыйрегез шат булачак,
Киләчәктә тырышачак
Кулыннан килгән кадәр.
Китә.

## ЭЧТӘЛЕК

ГАМЛЕТ
*Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсе*

ОТЕЛЛО
*Габдулла Шамуков тәрҗемәсе*

ВЕНЕЦИЯ СӘҮДӘГӘРЕ
*Габдулла Шамуков тәрҗемәсе*

ЧАМАСЫНА КҮРӘ ЧАРАСЫ
*Габдулла Шамуков тәрҗемәсе*

ТЫЛСЫМЛЫ ТӨН, ЯКИ ҖӘЙГЕ ТӨШ
*Габдулла Шамуков тәрҗемәсе*

Литературно-художественное издание

**Шекспир** Уильям

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В двух томах

**Том 2**

Составитель **Бикчантаев** Фарит Рафкатович

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Шекспир** Уильям

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

Ике томда

**2 том**

Төзүчесе **Бикчәнтәев** Фәрит Рәфкать улы

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, С.Н.Галимуллина, Г.М.Хәбибуллина, Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 10.04.2007. Форматы 70г100 1/16.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 42,25+форз.0,33+вкл.1,30. Шартлы буяу-оттиск 91,65. Нәшер-хисап табагы 52,80+форз.0,53+вкл.1,28. Тиражы 2000. Заказ С-422.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066.
Казан, Декабристлар урамы, 2.